*Суфиян Поварисов*

# ПӘЙГАМБӘР ТАҢЫ



Роман

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-44
П 51

**Поварисов Суфиян**

П 51 Пәйгамбәр таңы: Роман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 287 бит.

Әлеге китапта XIX һәм XX гасырлар кисешкән чорда шәхес буларак формалашкан язучы Галимҗан Ибраһимовның балачак һәм яшүсмер еллары сурәтләнә.

ISBN 5-298-01430-5 © Татарстан китап нәшрияты, 2004



*Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә... Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, биек яшәү белән яшисе килә.*

*Галимҗан Ибраһимов*

---

*Беренче бүлек*

# БАЛА КӨТКӘНДӘ...

Карынымны ярып чыктың,
балам-гөлем,
И күз нурым, йөрәк-бәгърем,
якты көнем;
Үс сөелеп иман белән, булып матур,
Сынма җилдә,
давылларда нык, каты тор!

*Ана фатихасы*

## I

Хәсәнә абыстайны өч көн инде тулгак тота. Тышта бертөзлексез март бураны котырына. Әллә нинди кыш булды бу. Көйсез кияү белән бер. Декабрь суыгында бәгъзе чыпчык очкан җирдән туңып тәгәрәп төште. Гыйнвар уртасында, каты күңелле кешенең авыр кайгыга түзә алмыйча яшь түккәне сыман, капыл яңгыр яварга тотынды. Аннан соң янә салкынайтып, үзәккә үтәрдәй ачы җилләр исеп, юлларга бозлавык түшәлде. Таеп егылып, аяк-кул, кабырга сындыручы, баш имгәтүче күп булды. Февраль исә, гыйнвар агасының бу йомшаклыгына үч иткәндәй, сыер мөгезен төшерер дәрәҗәдә зәһәрләнде. Житмәсә, сеңлесе Март колагына: «Бирешмә, җебемә, нык тор», — дип пышылдады. Шашынды да китте март. Күз ачкысыз ыжгыр-ачы бураннарда әллә күпме юлчылар адашып үлде.

Ишелеп-ишелеп яуган кар биек итеп үрелгән читәннәрне дә, ярлыларның аннан-моннан әтмәлләгән тәбәнәк абзар-кураларын да, тавык кетәге зурлыгы вак-вак өйләрне дә күмеп, әле монда, әле тегендә тау-тау булып өелде. Тик ул япма карлар, күпме генә ярсып-шашып өем-өем ябырылмасыннар, байларның ерактан караганда ук солтанат кыяфәтле горур байбичәләрен хәтерләтеп торган биек, чибәр, купшы йортларның биленә дә җитә алмый әле.

Авыл халкының ярты гомере көндез кар көрәп үтә. Шулай да моңа берәү дә сукранмый: кар ява — икмәк ява. Әлбәттә, эш нык бүленә. Ярлы-ябагай ир-атның бил бөкрәйтеп, күз чекерәйтеп чабата ясыйсы, бәләкәй чана тартып утынга барасы, хатын-кызның чыртлатып сагыз чәйни-чәйни бәйләм бәйлисе, авыр тормыш төсен чагылдырып торган кылка киемнәрнең ертык-мыртык урыннарын ямыйсы, болардан тыш тагын тавык та чүпләп бетерә алмаслык мең төрле вак-төяк шөгыльләре бар. Аларны гөрләшә-гөрләшә, кайгы-хәсрәтләрне уртаклаша-уртаклаша, күңел ачу өчен вакыт-вакыт җырлый-җырлый, кич утырып та эшләргә мөмкин булыр иде. Ләкин күпләрнең, ичмасам, сукыр лампалык та майлары юк. Шулай да Ходай мул итеп биргән бу озын, моңсу, таң аттыра алмый ялыктырган газаплы кышкы төннәрне эшсез заяга үткәрмәү җаен табучы эзле, юньчел кешеләр дә бар. Алар чыра яндыра. Әмма аның да әллә күпме четерекле яклары бар. Чыра яндырсаң — өй ыслана. Ул ыс танау тишекләренә керә, әрсезләнеп, авызга тула, керфек очларына, чәч төпләренә сеңә, күз алмаларыңа кадәр сарылып, яшь түгәргә мәҗбүр итә. Әле аның анысына да түзәр идең, чыра өчен каен агачы табу — үзе бер зур бәла. Анысы да аның байларда гына була. Халык күбрәк салам, торф, җәй көне юнәтеп киптереп куйган сыер тизәкләре яга. Бәләкәй чана тартып бара икән урманга, аннан чыбык-чабык, коры-морды гына төяп кайта ала. Чырага ярарлык шәмдәй зифа каеннарны кисәргә аңа ярамый.

Бәгъзе берәүләр бу кытлыктан чыгу җаен да таба. Бергәләшеп, күмәк-күмәк җыйнаулашып, кич утыручаннар. Берсе — берсен, икенчесе — икенчесен, өченчесе өченчесен үзе белән алып килә. Шуннан тамчылардан күл җыелган кебек була. Бу «бәхеткә» эләкмәгән ярлы-гидай баш астына әлеге кырык ямаулы бишмәт-фәләнен, сырмасын, тунын-мазарын сала да как сәкегә тәгәри. Мамык мендәр, түшәк, иркәләп кенә йоклата торган йомшак юрган аның җиде ятып бер төшенә дә керми. Ә бит шул ширпы кабы зурлыгындагы балчык өйләрнең күбесендә җиде-сигез, бәгъзесендә ун-унике кашык иясе бар. Бер-бер артлы туган ул балалар өй эчендә мичкәгә тозларга тыгызлап-тыңкычлап тутырган ба-

лык урынына мыжылдашып тора. Дөрес, халык бу очракта да мәмрәп югалып калмый; ярлы тәкәббер, горур икәнлеген дә онытмый. Төкерәм мин синең ефәк юрганыңа, мамык мендәреңә, ди дә, сәке буйлатып, алагаем салам түши. Анда урын җитмәсә, саламны җир идәненә җәя. Нишлисең: Ходай җан биргәнгә юнь бирә — ярлы ямана да юана, бай җайлана да майлана. Бүгенге көчле буранда ярлылар, иртәнгә чаклы өйләрен кар күмеп китәчәкне белеп торсалар да, ишекләрен көчкә-иллалла ябып, әрсез-усал җил даими рәвештә сызгыра-сызгыра кереп мазасызлаган тишек-пошыкларның авызын томалап, җитез йомраннар кебек, өй эчендә җыйнаулашып сеңәргә мәҗбүр булалар.

Бу — ял түгел. Бу — зур газап. Җил-буран йә ач бүре булып улый, йә котырган эт кебек чиный, йә яшь бала шикелле елый. Бала бала инде. Яткач та әле алар бермәл «кхи да мыхи», «чыш та пыш», «ыр да мыр» килеп шаярышырга тотыналар; ул да булмый, чеметкәләшеп, төрткәләшеп, елашып та алалар; аз гына ирек куйсаң, бөтенләй давыл куба: саламнар оча башлый, берсе икенчесенең колагын бора да аны кәҗә итеп бакырта, аннан йодрыклар хәрәкәткә килә. Мондый гау-ызгыш ата кеше матчадагы чыбыкны алгач кына тына. Аннан соң инде балалар, көчле атакадан исән-аман калып ялга туктаган солдатлардай, тирән-тәмле йокыга тала.

Ата-ана күңеле һаман әле мең төрле уйлар давылы өермәсендә адашып йөри. Һәр бала — бер кашык. Ун бала — ун кашык. Иртәгә һәр кашыкка чеметеп салырлык та он юк. Ун бала аягына егерме чабата кирәк. Балалар берсенең бишмәтен икенчесе киеп үсә. Кием эләккәне көндез тыш һавасын иснәп, карда бер аунап керү бәхетенә ирешә ала. Киемсезе, күшеккән тавыкка охшап, өй эчендә моңаеп утыра бирә. Болар — һәм шуның кебекләр — һәр ярлы өчен уртак кайгы. Шуларны уйлый-уйлый җиде төн урталары җитә. Ә керфеккә йокы күләгәсе кунмый да кунмый. Шаулатып, моңлы итеп, йөрәкләрне ярсытып, беренче әтәч кычкыра. Юк, йокы алмый. И-их!.. Алып батырга бирмәстәй гаярь ир-егетләрнең алтын вакыты әнә ничек харап була.

...Авыл әле йоклый. Кар катламына күмелеп, изрәп йоклый. Тик Гыйрфан өендә генә икенче әтәчкә чаклы унлы лампаның яктысы сүнмәде. Ул да, зилзилә мәлендәге куркынычны хәтерләтеп, котырынган бу буранлы төндә, оҗмахҗәннәт хозурлыгындагы голәма кебек, гамьсез-моңсыз гына вакыт үткәрүче бер пошамансыз зат түгел иде. Ярый, кар кирәк. Күп кирәк. Мул кирәк. Бу инде һәр мужикның аягындагы чабатасы, һәр мулланың башындагы чалмасы кебек мәгълүм хәл. Әмма ләкин табигатьнең иблис кебек болай җенләнүе, җил-давылның, кыямәт көне якынлашканда,

шайтаннарның котырынуы чамасында кыланып, ярлы-ябагайның бармак белән төртсәң аварга торган өй түбә саламнарын туздырып ташлавы, болай да авыр тормыш кичергән адәм балаларына мең төрле мәшәкать-газап китерүе кемгә хаҗәт? Бүгенге авыл халкы хәятындагы китек-митек, ертык-мыртык яклар, хәерчелек, һәр язны ачлык белән каршылау аның да йөрәк тамырларына кара кайгы сөреме булып сарылган. Ул — мулла. Мөэмин-мөселман кешесенең әдәпле, миһербанлы, шәфкатьле булырга тиешлеге турында вәгазь сөйли, бер Алланы зурларга, хөрмәт итәргә, аның өчен сәҗдәгә китәргә өнди; намаз укырга, мәчеткә йөрергә, алдашмаска, урлашмаска куша. Чөнки ул — авылда дин, Алла тарафыннан куелган иман мөнәүвире[1]. Авылда иман нуры, фәрештәләр канатларына төяп даими ташып торган гыйззәтлелек, илаһилык кодрәте саклансын, алар рәхмәте илә иңдерелгән бөек-гали аклыкка инсаният күңелен томалаучы кара тап төшмәсен! Әмма ләкин... ач кешенең ачуы яман. Ач кешене матур сүз белән сыйлау бик кыен. Ач булса, аюны да биергә өйрәтеп булмый бит. Боларны ул ихлас күңелдән, самимиилаһи хис-тойгысы белән аңлый. Шуңа күрә карт-корыга, күп балалыларга, гарип-горабага иганәсен кызганмый. Бу кадәресе бер Алланың үзенә дә мәгълүм. Ходайга шөкер, бу җәһәттән илаһият алдында йөзе ак, йөрәге пакь, күңеле саф.

Болары инде аны туктатырга аслан имкян[2] булмаган даими агып яткан агымсу төсле, һәркөн, һәр сәгать, һәр минут, һәр тын алганында эшләнә торган иҗтиһадлылык. Ә менә остабикәсенең — хәләл җефете Хәсәнәнең — өч тәүлек буе тоткан тулгаклавы, аңа дүртенче бала бүләк итәргә җан-фәрман килүе (иманы камил — малай булачак; ул моны төшендә күрде) — хосусан вакытлы күренеш.

— Остабикә!.. Вакыт җитте, шәй... сызланасың түгелме?.. Әллә Әхмәдулланы Хәмдия абыстайны[3]... кендек әбисен дип әйтүем... алып килергә җибәрәбезме?.. — дип, өченчекөн үк сораган иде.

— Юк, юк, мулла, әле иртәрәк... — диде ул, бу көчле буранда хезмәтчеләре Әхмәдулланы җибәрергә кыенсынып.

Аннан, Ходайга шөкер, исән-имин генә төн үтеп китте. Төнлә дә аның йөрәк җимеше — бу фани дөньяга киләчәк нәние — үзенең ана карыныннан чыгып, инде хәзер йомшак-нәфис күз нурларында иркәләнергә тиешлеген, шуңа ашыгуын сиздереп кенә торды. Кичтән хәле ул кадәр мөшкел-куркыныч түгеллекне тәмам аңлагач, Гыйрфан мулла тыныч-

---

[1] Иман мөнәүвире — иман дине таратучы.
[2] Имкян — мөмкин.
[3] Авыл халкы хөрмәтле әби-чәбиләрне «Абыстай» дип йөртә.

ланып ятып йоклады. Төнге сыкрану-сызлануны остабикәсе аңа сиздермәскә тырышты.

Ходайның рәхмәте киң дигәндәй, иртән дә, көндез дә әлеге йөрәк җимеше бу якты дөньяга ул кадәр ашкынып-җилкенеп торуын нык сиздермәде. Шуңа күрә мулла абзый үз эшләре белән мәшгуль булды: ат карады, абзар тазартты, малларга печән салды, кар көрәде... Әмма әлеге «җимешнең» дулап-дулап алган чаклары да еш була. Ә инде мулласы килеп керсә, — әллә күз карашларында бер-бер шифанур бармы, югыйсә, — үзендә шул мизгелдә үк җиңеллек сизә башлый.

Шулай итеп көн үтте. Икенде намазын, ахшам намазын, ястү намазын парлап укыдылар. Хәсәнә абыстайга — йөкле кешегә — бөгелеп-сыгылып, бер ятып, бер торып, элеккечә мулласы белән ярыша-ярыша, намаз уку бик кыен иде. Әгәр авыру кешенең басып торырга хәле юк икән, аңа утырып укырга рөхсәт ителә. Утырып та мөмкинлеге булмаса, уң ягына ятып, кыйблага карап башкара ала бу изге эшне. Монысына да көч җитмәсә, аякларын кыйблага сузып, чалкан яткан килеш гамәлгә ашыра ала. Әгәр инде авыру боларның һәммәсеннән дә мәхрүм чиккә җитсә, намаз кичектерелә. Шулай да ул моны Аллаһы Тәгаләгә җиткерергә тиеш. Гыймран сүрәсендә: «...Кем дә кем баскан килеш, утырып һәм уң ягына яткан килеш: «И Раббыбыз! Син моны бушка гына барлыкка китермәдең. Сиңа дан, шөһрәт булсын! Син безне ут газапларыннан сакла инде!» — дип, Аллаһы Тәгаләне искә алсалар, һәм күкләрнең, һәм җирнең барлыкка китерелүе турында фикерләсәләр...» — дип әйтелә.

Мулла, әгәр авыр булса, остабикәсенә укымаска, әнә шул сүзләрне әйтеп кенә ялварырга кушкан иде. Әмма Хәсәнә абыстай әле хәзергә үзен ул чиккә үк җиткән итеп тоймады. Биш вакыт намаз фарыз. Ул бик авыр вакытларда да укыла. Ә инде бала көткәндә, бер генә ана да җиңеллек эзләми. Берчә басып, берчә утырып укыды Хәсәнә абыстай намазны. Ястү намазыннан соң да әле үзен сират күперен үтәрдәй алиһә итеп санады. Әмма ярты төн уртасыннан соң, янә нык авыраеп китте. Мулла абзый киенә үк башлады.

— Атасы... сиңа әйтәм... кая болай... төн заманында?..

— Хәмдия абыстайны алып киләм...

Һаман шул бер үк сүзләрне кабатлады остабикәсе:

— Юк, юк, мулла, кирәкмәс, мәшәкатьләнмә, бу күз ачкысыз буранда бата-чума ни эшләп йөрмәк кирәк; әле хәлем син уйлаганча бер дә авыр түгел; таң аткач, Алла боерса, тагын да парлап иртәнге намазны укырбыз, аннан соң кирәк булырдай тоелса гына алып килерсез абыстайны, көн күзендә... Бик ерак торалар бит...

Шулай да иртәнге намазны парлап укырга насыйп булмады. Таң алдыннан Хәсәнә абыстай ныклап авыраеп киткәч:

— Инде Ходай үзе шаһит булсын, моннан ары синең бер кәлимә сүзеңә колак салмыйм, остабикә, алып киләм, — дип, аягына олтанлы киез итекләрен, өстенә толып, башына кырлы бүреген киеп чыгып китте.

Өйалды ишеген ачып җибәрсә, карның болдыр-күтәрмәгә үк тулганлыгын күрде ул. Ә буран һаман котыра, җенләнә, атлап китәргә ирек бирми. Алдына гүя йөзләгән хәерчеләр тезелделәр дә икмәк-нан бирмисез дип, йөзенә вак таш томырырга керештеләр. Ләкин хәзер боларның берсенә дә игътибар бирү форсаты юк. Алдыңа мең тимер киртә корып куйсалар да, син аны, ватып-җимереп, таптап-сытып үтеп китәргә тиешсең. Шулай да ул кичә хезмәтчесе Әхмәдулланы Корманай авылына җибәрүенә, бер-икене кунып кайтырга рөхсәт итүенә нык үкенде. Эчтән генә үзен тиргәп тә алды: акылсыз баш аякка тынгылык бирәмени ул, дип әрнеде. Әхмәдулла өйдә булса, әйтү белән, җәһәт киенеп, яшен ташы урынына томырылыр иде кендек әбисен алып килү өчен. Ярый, үткән эшкә салават, ди, хәзер инде болай гамьсез күркәдәй басып торуда бер хасият тә юк. Бөтен көчен җыеп, үзен крепость алырга әзерләнгән солдаттай нык торырга тырышып, бата-чума урамга чыкты. Кара син аны: Ходайның рәхмәте, әллә бу күк йөзе бөтенләй тишелдеме, бөтен йолдызлар кар булып ябырыламы, ни хикмәт инде бу — кичә кич кенә күрәгән тап-такыр урыннарда янә кар таулары кукраеп утыра. Бу җиле тагын. Аның кайсы яктан искәнен дә чамалап булмый. Әле йөзеңә китереп бәрә, әле сул колагыңны йодрыклый, әле уң колагыңа тондыра. Бәй, менә син агай, бусы нинди галәмәт була инде моның тагы: бер кар өере төрле яктан китерде дә кысты. Ул хәзер әйтерсең ап-ак ефәккә уралган хур кызлары кочагына эләгеп изрәде. Юк икән шул, юк икән, берләр генә дә хур кызлары түгелләр икән, рәхмәт төшкере, түгел икән; бу кар өермәсе аз гына иркәләп торгандай итте дә, янә котырынган җенгә әйләнеп, биленнән алагаем кысып күтәреп алды да мулла абзыйны, һавада аз гына бөтерелдереп, уйнатып, яңадан җиргә китерде дә салды. Йа Хода, монысы ни инде тагын? Әллә мең-мең шайтан котырамы югыйсә? Мулла кеше, Ходай бәндәсе, гөнаһсыз зат дип уйларга тиешләр ләбаса алар.

Бик озак ятмаска тырышты мулла абзый. Кеше-мазар күрмәсә ярар иде дип, тизрәк аякка басу җаен карады. Кешеләр юк иде әле. Кем йөрсен мондый әшәкедә? Яхшы хуҗа этен дә оясыннан чыгармас. Нигә котыра буран? Кем үч

итә? Нишләп бала көткәндә болай көйсезләнә соң әле бу табигать? Юлы уңсын өченгә аз гына укынып алды ул: «Раббәнә әтинә фид-дүнья хәсәнәтән вә фил-ахыйрәти хәсәнәтән вә кыйнә газабән-нар.

Шулай укына-укына, усал буран-давыл белән көрәшә-көрәшә, бата-чума, әле егылып, әле торып китеп, мең газап кичерә-кичерә барып җитте ул кендек әбисенә. Тик монда да аны итле бәлеш төбе көтеп тормаган икән. Хәмдия абыстайның җиргә сеңгән балчык өенең морҗасы гына күренеп тора. Нишләргә хәзер? Казып чыгарыр иде — көрәк юк. Күршесе Галләметдингә сугылыргамы? Килешерме? Беркөн әйткәләшеп алганнар иде бит. Сүгенгәне өчен шелтәләгән иде. Хәер, Галләметдин эчкерле кеше түгел. Яманлыкка әйтмәгәнне аңлагандыр. Бәй, бәй, бирәсе килгән колына, чыгарып куйган юлына, ди; әнә үзе үк килә. Кулында — агач көрәк. Димәк, йомран хәлендә бикләнеп калган Хәмдия абыстайны якты дөньяга чыгару өчен ашыга. Күрше хакы — Тәңре хакы дип тә уйлыйдыр, бәлки.

Төннең кара пәрдәсе ертылып, яктылык канат кага башлаган иде инде. Гәрчә буран һаман чүл бүресе урынына чыелдап, күзләргә китереп бәреп торса да, йөзгә-йөз килүче берберсен танымый калырлык түгел. Сүзне Галләметдин башлады:

— Әссәламегәләйкем, мулла абзый, бик иртәләгәнсез, Хәсәнә абыстай авырып китмәгәндер бит?

— Вәгаләйкем әссәлам, Галләметдин туган, күңелең сизенә икән, шулайрак булып китте бит әле, тик менә Хәмдия абыстай гына...

Галләметдиннең шаярта торган гадәте дә бар иде. Әле дә менә, авыр эшне җиңеләйтү нияте белән кылангандай, җор сүзләр чәчәргә тотынды:

— Хәмдия абыстай өчен болай күмелеп калу оҗмах ул, мулла абзый. Нигә дисеңме? Тәрәзәдәге тишек-мошыклардан җил өрми. Бишектәге бала кебек изрәп тик ята ул. Ә буран ыжгыруы аның колагына моңлы җыр булып кына ишетелә.

Галләметдин өстенә каткан кыска тун, башына иске мескен бүрек кигән иде. Аягында ыштыр белән урап кигән чабата. Өзлексез сөйләнә-сөйләнә, агач көрәге белән кар ергаларга тотынды. Тәүдә «каты холыклы», «акман-токман» бураны турында азрак такмаклап та алды:

Хәмәлдә әмәлеңне
Котыртырмын, дигән.
Март ишектән бактырыр,
Сәнәк-көрәк яктырыр.

Акман-токман алты көн,
Алты айдан да каты көн.
Хут чыга,
Хәмәл керә.

Эшкә мулла абзый да дәртләнеп тора иде.

— Бир әле көрәгеңне, Галләметдин, азрак ял ит, мин дә кар көрәмәгән кеше түгел бит,— диде ул.

Гыйрфан мулланың теләсә нинди кара хезмәттән курыкмаганлыгын, дөньяны дер селкетеп көткәнлеген Галләметдин яхшы белә. Шулай да әле бер дә эшем иясенә охшамаган. Толып киеп кар көрә, имеш. Моны мулла абзый үзе дә сизде. Хәтта ахмаклыкка исәпләде. Нигә кигән ул аны? Әлеге кашавойларга утырып чыгып китү гадәтеннән калганмы? Ат җигеп килмәкче дә булган иде ул. Әлеге дә баягы көрттә чумып ятудан, вакыт әрәм итүдән курыкты.

Шулай да Галләметдин хезмәтен уртаклашмый калмады ул. Кулындагы көрәген алып, тиргә батканчы кар көрәде.

Хәмдия абыстай үзен кар капламыннан коткарырга килүчеләр барлыгын сизде. Иртән ата-ана, ябылган бишекне ачып, баласының нурлы йөзен карарга ярата. Гәрчә илле яшьләр чамасында булса да, әле үзен сабый бала хөкемендә хис итте ул. Әйтерсең ул әле бишектә, ата-анасы, ябылган япманы ачып, аның сулышын тоярга ашкыналар. Тыштагыларкарны көрәп бетергәч, ишекне эчке яктан үзе ачты ул.

— И Галләметдин, юкка гына намаз укыган саен сиңа бәхет-тәүфыйк теләп дога кылмыйм икән; рәхмәт инде, балакаем, Ходай озын гомер биреп, мине сөендергәнең өчен, урының җәннәттә булсын,— дип сөйләнде.

Галләметдин үзенчә шаяртты:

— Тәүфыйк дигәне син теләгәнчә генә бирелмәс аның анысы, Хәмдия абыстай, бәхет дигәне дә шылайрактыр, бу фани дөньҗада[1] безнең ише кара халык, аңгыра сарыкка тәтемәде инде ул, тешләрен генә ыржайтып күрсәтте, ә мына[2] җәннәткә өметләндерүең белән килешәм, җимеш ашап, хур кызларын кочып, ә... хи-хи...

Алар өй эченә шулай шаян сүзләр сөйләшә-сөйләшә керделәр. Башта Хәмдия абыстай мулла абзый барын шәйләмәгән иде. Күреп алып, сәлам биргәч, аптырап, уңайсызланып китте. Толып киеп, бу буранлы иртәдә мулла кешенең ярлыябагай янына килүенең бер дә юкка түгел икәнлегенә дә төшенде ул. Дөрес, кендек әбисе бер ул гына түгел. Үзләре тирәсендә — якында гына да бар. Ләкин ул барысына кара-

[1] Бу авылда «җ» белән сөйләү көчле.
[2] Мына — менә.

ганда да мәртәбәлерәк. Имеш, кулы җиңел. Ул көткән сабый якты дөньяга тизрәк килүчән. Бу, имеш, аның эчкерсез, матур күңелле булуына бәйләнгән. Бөтен авылга шундый изге хәбәр таралмаса, олы башын кече итеп, мулла кеше таң күзеннән синең артыңнан килер идеме? Сүзне үзе үк башлады кендекәй (аны яратып шулай дип тә йөртәләр):

— Хәсәнә авырып киттеме? Шылай булыр тип уйлаган идем лә аны, кичә йөзендә үк сизелеп тора ите, мына син агай, нишләмәк кирәк...

Мулла абзый гафу үтенгәндәй сөйләште:

— Ат җигеп киләм дисәм, юлларны көрт баскан...

Хәмдия абыстай сөйләнә-сөйләнә киенде:

— Син шылай димә әле... кем... Гыйрфан... Әйе... Ике аягым исән булсын. Мәккәгә тәпи-тәпи китәрлекмен... Мәккәгә... Шылай мына... аңгыра тавыктай... ызба эчендә бикләнеп ятыр чагыммы...

Ул киенгән арада, мулла абзый өй эченә игътибар итте. Саман балчыктан өелгән бу өйнең тәрәзәсе дә карындыктан. Җир идән. Сәке белән ишек арасы ике адым чамасы гына. Әгәр сәкегә озын кеше сузылып ятса, аягы, һичшиксез, ишеккә тиеп торачак. Хәмдия абыстайга бу фикерне әйтергә ярамый, билгеле. Ул үз тормышыннан канәгать. Ач тамагым, тыныч колагым, дип, шушы бәләкәй ояда яши бирә.

Гыйрфан мулла мондый караңгы баз кебек балчык идәнле өйләргә керергә, утырып дога кылырга бер дә кыенсынмый. Әле дә, бәләкәй йортка олы фатиха булсын дигәндәй, башта аз гына укынып алды, аннан соң амин тотты. Галләметдин, ияк астын гына сыпырып куйса да, Хәмдия абыстай мулла догасына ихлас күңелдән кушылды.

* * *

Буран, чабышта ярсып килгән атның хәл алгандагы мәле кебек, бераз тынып торгандай итте. Авыл халкы, дәррәү күтәрелеп, тагын кар көрәргә чыкты. Бу дулкыннан Гыйрфан мулла да читтә ыргытылып калмады. Менә Ходай уң кылса, дөньяга дүртенче баласы борынлар. Аннан соң дус-иш, кардәш-ыру, күрше-күлән, карт-коры, туган-тумача дулкыны агымы башланачак. Авылда үзенең чибәрлеге, инсафлыгы, шәфкатьлелеге белән мәртәбәле булып өлгергән аның остабикәсе Хәсәнә абыстай янына кешеләр төркеме чылбыры өзелмәячәк. Шуңа күрә ихатаны, капка төпләрен, аларга килә торган юлларны көрәп, ялт иттереп куярга кирәк. Гыйрфан мулла ялкау, мәгънәсез, дөнья көтә белми дип уйламасыннар.

Аягына олтан салган киез итек, өстенә кыска тун, башына мескен бүрек киеп:

— Хәмдия абыстай, сиңа тапшырдым, Хәсәнәнең хәле бик шәптән түгел шикелле, кара инде, син авылда иң иҗтиһадлы кендек әбисе бит, — дип, кар көрәргә чыгуын әйтте.

Хәмдия абыстай Гыйрфан мулланың кара сакалларына кадәр дерелдәп торуын, остабикәсе язмышы өчен нык борчылуын йөрәге, күңеле белән сизде.

— И-и... мына тагы... шылай бик кайгырырга ярамый бит инте... Авылның бер генә ызбасында да минем хәер-фатихамсыз дөньяга килгән бала юктыр... шылай булгач... бар, бисмилланны әйтеп, эшеңә кереш... ыңгырашма... Мына тигән туптай малай күтәп торыр әйләнеп керүеңә, Алла боерса...

— Афәрин!.. Хәмдия абыстай!.. Әйткәнең фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килсен!..

* * *

Кар көрәргә тыныч күңел белән чыгып китте ул. Агач көрәк кулында уйнаклап торды. Хәер, кырык биш яшьлек ирнең гайрәтен дә тоймаса, нинди көрәк була инде ул. Карны әле бу якка, әле теге якка чәчкәләгәндә, һаман яраткан хәләл җефете Хәсәнә язмышы, туачак бала, аның киләчәге турында уйланды.

Һәй, гамьсез балачак, тиле яшьлек еллары, аннан соң бил бөкрәйтеп, күз чекерәйтеп дөнья көтү, балалар тәрбияләү, матур яшәү өчен көрәш... Ә тормышның чишмә башы ифрат саф, бәрәкәтле, бәхетле булган лабаса. Әхмәт ахунны — аның картәтисен — бирегә Бөре ягыннан алып килгәннәр. Аның улы Нурмөхәммәт — бу Солтанморат авылында имам. Нурмөхәммәтнең сигез улы, дүрт кызы була. Гыйрфан — Нурмөхәммәтнең өченче улы. Әтисе Нурмөхәммәтнең унике баласы — унике тамыр. Ул тамырлардан янә кәүсә хасил була, аннан ботаклар тармаклана, ботаклар яфрак яра; шулай итеп, нәсел-нәсәп арта, үрчи, еракларга тарала. Гыйрфан башта Уфадан әллә ни ерак булмаган Кыешкы авылында Мирсәяф ахун мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлагач, гәрчә яхшы мәгълүматлы булса да, эш таба алмау сәбәпле, анда пишкадәм булып кала. Шулай да ул бу хезмәт өчен артык түбәнсенми. Чөнки тиздән танышлары Троицк шәһәренә мөдәррис итеп чакыра. Анда Рәхимкуловлар мәдрәсәсендә хисап, Коръән язу буенча укыта.

Әнә шунда таныша Гыйрфан Хәсәнә белән. Кызның әтисе Җиһангир хәлфә иде. Ул инде шактый өлкән яшьтә, берничә бала атасы. Гыйрфанны ул тырыш, тәртипле, иҗтиһадлы, низамлы, оста мөдәррис булганы өчен яратты. Җиһангир хәлфә үзе дә шәкерт язмышын һәрвакыт уңай хәл итү, аларның күңелен яктырту, кешелек сыйфатларын югары тоту

өчен көрәшүче кеше иде. Карт хәлфә белән яшь мөдәррис йөрәген шундый уртак күркәмлекләр якынлаштырды шикелле. Буйдак егет Гыйрфанны ул еш кына үзләренә чәйгә, ашка чакыра торган булып китте. Җиһангир хәлфәнең остабикәсе Газизә абыстай аны гел якты чырай, күтәренке күңел, җитди бер ихласлык белән каршы алды. Илле яшьләр чамасында булса да, ак һәм мөлаем чыраенда яшьлек матурлыгы чаткылары һаман әле сизелеп тора иде. Мөкиббән елмаюы, күз карашларының ягымлылыгы, сүзләренең татлылыгы аны күркәм сыйфатлы бөек ана итеп таныта иде. Йөзен күрсәтмәскә тырышып йөргән кызы Хәсәнә әнисенә караганда да чибәр, ипле, итагатьле, инсафлыдыр кебек тоелды аңа. Ул уртача гына буйлы, бик хәрәкәтчән, тиз йөрүчән дә иде. Бер килгәндә, әнисе өйдә юк булу сәбәпле, чәй табынын ул әзерләде. Ап-ак күлмәк кигән. Җил-җил атлап әллә ул йөри, әллә аккош үтеп китә. Ашамлыкларны җитез-җитез китереп куйганда, мамык йомарлагы төсле бәләкәй генә ап-ак кулын да күреп калды. Зур ак самавырны җилтерәтеп күтәреп алып килгәндә дә әлеге аккоштай йөрү дәрәҗәсен аз гына да киметмәде. Әмма алдан бәйләгән ефәк ак яулыгы һаман әле йөзенә рәхәтләнеп тутырып карарга комачаулап тора. Ул гына да түгел, самавырны, ашамлыкларны куйганда ул әле йөзен читкә борырга да онытмый. Гыйрфан, билгеле, бу матурлык фәрештәсенә күз атып утыруын, бер күрергә зар-интизар булып авыз суын түгүен, үз җанының аның җанына кушылып китүен сиздермәскә тырыша. Чөнки мөселман кызлары йөз күркәмлеген, намус сафлыгын яулык каплап сакласа, мөселман егетләре дә ул сафлыкка үтә әдәпле кагылырга кирәк икәнлекне яхшы белә. Тешләргә безелдәгән кигәвендәй кылану аслан килешми. Ахмак кызлар күрсә, кыза, тизрәк кулын суза, дигәне дә бар. Ахмаклык күрсәтә торган урын түгел бу.

Ашап, чәй эчеп туйгач:

— Менә бу Хәсәнә чиккән сөлге, менә монысы ул теккән күлмәк,— дип, әтисе кызының алтын куллы икәнлеген дә искәртеп куйды.

Болар егетнең болай да ашкынып-кымырҗып торган йөрәген тагын да ярсытып, күңелен мең кәррә җилкендереп җибәрде. Ул чигүләрдә кызның кайнар хисе, күз нурлары, йөрәк ялкыны балкып тора кебек тоелды. Бер күзе аның бармак очларыннан тамган матурлык белән чигелгән чигүдә булса, икенче күзе, әтисенә сиздермәскә тырышып, суда йөзгән балыктай шома атлап йөргән кызны күзәтү иде. Ни гаҗәп, Җиһангир хәлфә әлеге чигелгән, тегелгән әйберләрне алып куйганда, кызның йөзен рәхәтләнеп, күз тутырып карарга насыйп булды. Йа Хода! Әллә ай балкыды, әллә кояш нур сипте. Әлеге зур корсаклы ак самавырны күтәргәндә бул-

ды бу. Өздереп бер карап алмасынмы Гыйрфанга. Гел шулай ач кеше икмәккә тилмереп карагандай ымсынып утырасың, мә, күр, кинән дип уйладымы? Чибәрлеге белән масаю өчен эшләдеме моны? Әллә өмете бармы югыйсә? Гыйрфан да төшеп калганнардан түгел лә инде. Кара чибәр дип йөртәләр аны. Сызылып киткән кара мыек, карлыгач канатыдай куе кара кашлар, елкылдап торган кара, йомшак, куе чәчләр, шомырттай кара күзләр, уртачадан аз гына озынрак килешле гәүдә, сүз көрәштергәндә фикер тирәнлеген күрсәтә белү...— тагын да әллә күпме уңай яклары бар ич аның. Белемле, кешелекле булу да бизидер әле аны. Шулай булмаса танышлары авылдан шәһәр мәдрәсәсенә мөдәррис итеп чакырмаслар иде. Әйе, ул кара чибәр. Ә Хәсәнә ак чибәр икән. Монысы тагын да шәп. Бөтен хыялы ак чибәрне сайлау иде бит. Холыкларда да капма-каршылык бар. Әтисе беркөн кызының ифрат дәрәҗәдә йомшак күңелле, әдәпле, инсафлы булуы турында әйткән иде. Гыйрфан үзен алама кешегә санамый. Шулай да холык-фигыленең корырак икәнлеген белә. Бу хакта танышлары, дуслары, туганнары да әйтә. Каты холыклы ир, тырт-мырт итеп, сызган шырпыдай тиз кабынып китә торган хатын белән килешеп тора алмый. Эче караңгының йөзендә нур булмас, ди бит. Бу йөздән караңгылык эзләү — йомыркадан җөй эзләү булыр иде.

Хәсәнәнең җылы агым кебек бер йомшак карашы гына да йөрәгендә мәңге сүнмәстәй ут кабызды да куйды. Тик ул җылы агымда, рәхәтләнеп, колач җәеп, йөзә генә алмады әле ул. Монысы киләчәк. Бик якын киләчәк. Әгәр аның йөзен якты ай йөзенә тиңли икән, ике арага болыт пәрдәсе дә тартылырга мөмкин. Чибәр кызларга тозак салучылар бетмәгән. Кызлы йорт — кызыклы йорт, дип тә әйтәләр.

Ул төнне юньләп йоклый алмады Гыйрфан. Аккоштай йомшак кына басып йөргән, җылы агымнар чәчеп өздереп бер карап алган, йөзендә генә түгел, нечкә билле нәфис гәүдәсендә дә нур балкып торган Хәсәнә күз алдыннан китмәде.

Гыйрфанда кыюлык та бар иде. Икенче көнне әтисе, әнисенең өйдә юклыгын белеп, китап сораган атлы булып, тагын да килде ул кыз янына. Өй һәрвакыттагыча таза. Җыештырылган. Нindидер әйтеп аңлата алмаслык бер сихри нур, нәфислек балкып тора. Бөтен өй эче биредә уңган хуҗабикә булу турында сөйли. Кыз бала — өй зиннәте, дигәне шушыдыр.

Бүген Хәсәнә алсу күлмәк кигән иде. Ишек шакып, рөхсәт сорап кергән Гыйрфанны күрү белән, башына әлеге ак яулыгын салып, тиз генә йөзен яшерде.

— Мин Җиһангир әфәндене өйдәдер дип уйлаган идем... Гафу итегез... болай килеп керүемнең сәбәбе... бер урысча

китап сорап тору иде... — дип, өзек-өзек җөмләләр белән сөйләде ул, үзен болай тышкы яктан үтә кыю күрсәтергә тырышса да, эчтән мәлҗегәнен сизде.

Кыз моңа игътибар итмәде.

— Нindие... кемнеке... кирәк соң сезгә, Гыйрфан әфәнде?..— дип, оялып кына әйтеп куйды да шкафтан бер китап алып китереп бирде. Әмма йөзен күрсәтмәде, читкә борды. Кызу канлы Гыйрфанны кызның һаман шулай юаш болан баласыдай кылануы, йөзен гарәп кызлары кебек каплап йөрүе ярсытты да җибәрде.

— Хәсәнә!.. Мин бүген нурлы йөзеңне туйганчы карарга килдем... — дип, моны үзенчә бер уенга санап, тиз генә яулыгын тартты да алды.

Кыз өчен егетнең бу мутлыгы бик сәер тоелды.

— Ни эшләвегез бу, Гыйрфан әфәнде, нигә болай әдәпсез кыланасыз, хәзер әти кайтачак, икебезгә дә уңайсыз булачак, бирегез яулыгымны...— дип ялынды кыз. Яулыгын алырга дип үрелгәндә, Гыйрфан янә бер мутлык күрсәтеп өлгерде: кызның кулыннан тотты да алды.

Тагын да нинди тарткалашу булыр иде — боларның икесе өчен дә мәгълүм түгел — өйалдындагы аяк тавышы аларны сискәндереп җибәрде. Хәсәнә, яулыгын тартып алып, эчке бүлмәгә йөгерде. Җиһангир әфәндене Гыйрфан берни булмагандай каршыларга тырышты. Шулай да эчтән калтырана иде ул.

— Әлхәмделилла!.. Кунак бар икән ләбаса! Ходайга мең шөкер!.. Тик нигә ул түргә узмый, нигә ишек төбендә каккан кадак кебек басып тора икән, — дип, ачык йөзле, киң күңелле, мәрхәмәтле булырга тырышты Җиһангир хәлфә.

Гыйрфан судан коры чыгу ягын карады:

— Минем урыс телен начар белүемне, моның өчен ифрат түбәнсенүемне аңлыйсыз, Җиһангир әфәнде, шуны яхшырак өйрәнү өчен дип, китап сорарга килгән идем, әмма сезнең өйдә юклыкны белмәдем, шуңа күрә Хәсәнә туташтан сорарга туры килде, ул китереп биргәч, әле менә чыгарга гына тора идем... Үзегезгә мәгълүм... шәһәрдә яшәп, урысча сөйләшә белмәү бик читен...

Җиһангир хәлфә аның ихлас күңелдән, мөкиббән сөйләгән сүзләрен җөпләп куйды:

— Әйе, әйе, ифрат дөрес әйтәсең. Син бик зирәк кеше, тиз өйрәнерсең...

Шуннан хуҗа егетне түргә узарга кыстады, чәй эчәргә тиешлекне әйтте. Ләкин Гыйрфанда ашау кайгысы юк иде.

— Танышларым көтеп тора, тиз генә кайтырга куштылар; зинһар, гафу итә күрегез инде, — дип, җәһәт кенә чыгып китүне мәгъкуль күрде.

* * *

Мәхәббәт дәрьясына батты егет. Уф, ул дәрьяның тирәнлеге, киңлеге. Йөз бер аркылы, бер буй, чум төбенә, эзлән, кирәк энҗеләрне тапмый калма. Ул әле сине диңгез төбендә генә яткырмый, аннан тартып чыгарып, бер караганда, канатлы кош итә, зәңгәр күк төпкеленә алып менеп китә дә әллә нинди аңлаешсыз саф-садә дөньяда очырып йөртә; икенче вакыт, җиргә төшереп, чәчәкле болыннарда йөгертә, кошларның сихри моңнарын тыңлата, алсу таңнарда, айлы кичләрдә акылдан шашар чиккә җиткереп моңландыра.

Хәсәнәнең чибәр булуы турында ишеткәне бар иде аның. Ләкин болай уктыр дип уйламый иде. Ни гаҗәп, ак чырайлы кешенең чәче сары, күзе йә яшькелт, йә соргылт булучан. Ә моның чәчләр кара бәрхет кебек елкылдап тора. Юан камчы шикелле үрелгән ике толымы аркасы буйлап сузылган. Алар җанлы, сихерле, тылсымлы булып тоела. Зур кара күзләрдә моңсулык, ямансулык, уйчанлык чаткылары сизелә.

Матурлыктан саба җиле агымыдай бөркелгән садә мәхәббәт аны акыллы да итте, тилертте дә; төн йокыларын качырып, берникадәр йомшартты, бәлтерәтте дә; сират күперен кичеп, җәннәткә эләккән җан ияседәй, хозурландырып та җибәрде.

Хәсәнәнең үзе белән сөйләшергәме? Ачыктан-ачык, йөрәкне йөрәккә куеп, күз нурларын бүләк итешеп, мәхәббәт моңнарына манчылган күңел җепләрен бер-береңә сузышып. Ләкин моннан ни файда? Ата-анадан рөхсәтсез өйләнү шәригать тарафыннан тыелган. Кыз белән егетнең аулакта очрашып сөйләшүе — зина кылу белән бер. Сөйләшер, киңәшләшер өчен авылга — әти-әнисе янына кайтып килергәме? Ике як та риза булмаса ни эшләрсең? Чыбыкны тоткан җирдән үк һәр очракта сындыра алмаса да, мәсьәләнең мөгезеннән эләктерә белә торган гадәте юк түгел иде Гыйрфанның. Кыюлыгы ычкынмаслык итеп кулына йомарлап, Хәсәнәнең әтисе белән маңгайга-маңгай куешып, ихлас күңелдән, чын егетләрчә, мөкиббән сөйләшергә булды ул. Сөйләгәндә бөтен күңеле, йөрәге, бар булмышы белән яратуын әйтүдән дә тыелып кала алмады; кызын бәхетле итү өчен тау-тау вәгъдәләр дә биреп ташлады, өрмәгән җиргә утыртмаячагын әйтте.

Кызлы өйгә егетләрнең кызыгып караганлыгы билгеле хәл. Килмәделәр түгел. Күп килделәр Хәсәнәнең кулын сорап. Ата кеше тиз генә җавап бирми, «карарбыз әле», «уйлашыйк», «бераз сабыр итик», «Хәсәнә унҗидедә генә бит әле» кебек сүзләр белән очлый мәслихәтләшүне. Чөнки берсе дә тиз генә күңелгә ярып керә алмый: йә төсе юк, йә буе кыска, йә сүз рәте белми. Егет җиле белән йөрер, ди бит. Килгәннәрнең берсендә дә җил әсәре сизелми. Ә менә ачык күңел-

ле, берникадәр шаян табигатьле, кыю, кара чибәр Гыйрфан бик тиз генә йөрәк төпкеленә керде дә утырды. Шулай да егетнең күләгәле, китек-митек, ырдым-мырдым яклары, күңелгә шик чаткылары кебегрәк нәстәкәй салуы, җиде үлчәп, бер кисәргә дә куша. Берникадәр кырыслык, мутлык, усаллык та юк түгел ич анда. Кыз бирү — муллага хәер бирү түгел. Кияү сайлау — кибеттә яки базарда күлмәк-ыштан сайлау гына түгел. Шулай уйланды кызның әтисе. Ләкин тора-бара китек-митек, ертык-мыртыклар ямала, егет тирәсендәге күләгәләр акрын-акрын гына кояш нурлары эченә йотыла башлады. Һәр кытыршы як шома шәмгә әйләнде дә куйды. Ата-бабаларыбызның «Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын»; «Юаш эткә таяк белән, усал эткә ачык күңел белән бәр»; «Тырыш булган — кырыс булыр» кебек мәкальләрен искә төшереп, булачак кияведән алып йөрәкле ир-егет ясады да куйды. Шулай да әдәплелек саклап, этептөртеп бирә бу дип уйламасын өчен, озак кына ялындырып маташты.

— Хәсәнәгә иртәрәк бит әле, ашыкма әле син, кабалануны берәү дә мәгъкуль күрми: китап та, бәндәләр дә...

Гыйрфан кырт кисте:

— Юк инде, Җиһангир әфәнде, кабалануны хуп күрмәү вакыты үткән; үзегезгә мәгълүм, мәдрәсәдә унбиш ел чиләнү, эш булмаганлыктан, анда пишкадәм булып тору, монда мөдәррислеккә килү... Хәзер инде минем өчен уты, ялкыны бергә. Өйләнәм. Вәссәлам... Уналты яше тулган кыз энә өстендә бии, дигәнне ишеткәнегез бардыр...

Егетнең тәвәккәллеге, яратуын чын ир-егетләрчә, ихлас күңелдән, матур итеп аңлатып бирүе Җиһангир әфәндегә нык ошады. Дәртен яшергән, дәрманын тапмас, ди. Бу дәртен дә, ялкынын да, утын да яшереп маташмый. Шуңа күрә бу изге эшне һаман җилем урынына сузуда бер фәтва да булмас. Вәгъдәне ул хәтта шаярыбрак та бирде:

— Ярый, күрәм, син мут егеттән котылып булмастыр: язмышыгызны бер Ходайның үзенә тапшырдык, тик Хәсәнәнең йомшак табигатьле, оялчан, инсафлы икәнлеген онытма,— дип, аның кулын кысты.

Кул кысышу, билгеле, вәгъдәне иман белән беркетү кебегрәк иде.

Аннан соң кияүләп йөрү, ике яктан да кода-кодагыйлашу, куйлар, елкылар суеп чакырышу, бихисап бәлеш, сумса, коймаклар белән сыйлану китте; туй мәшәкатьләренә күмелеп, тынгысыз көннәр, вакыт-вакыт юкка-барга вак-төяк низаглашу, үпкәләшү кебек күңелсезлекләр дә булгалап алды.

Ярсу диңгездәй дулкынланулар бервакыт тынып калды. Яшь йөрәкләр аерым бер бүлмәдә баллы-майлы айларын

үткәреп, сөю-сөелүнең кадерен белеп, мәхәббәт кайнарлыгыннан исереп-әсәрләнеп яши башладылар. Ике яшь йөрәк тә, ике якның ата-аналары да бик канәгать иде бу илаһи хозур, нурлы, бәхетле тормыштан. Тик күп тә үтми кияү кешенең әлеге мут, кырыс, усал яклары үзенең барлыгын башта акрын-акрын, азлап-азлап, аннан күпләп-күпләп, тиз-тиз сиздерә башлады. Беркөн ни теләгәнен ярды да салды ул:

— Шәһәр тормышы миңа ошамый, үз авылыма — Солтанморатка кайтам, мал асырап, иген игеп, чын крестьян булып яшисем килә,— диде.

Башта Җиһангир хәлфәнең күзләре шардай булды, ачудан бөтен тән әгъзалары дерелдәп куйды, чәчләре үрә торды.

— Ялгышасың, кияү, үз бәхетеңә үзең аяк чаласың, алай тиз генә шайтан котыртуына бирелмә әле син; үкенерсез бит, бәгъзе берәү калага килеп ничек борын төртергә белми, ә син, һавадагы торнага алданып, кулыңдагы былбылны очырасың. Тәгаен, шайтан котыртуы бу. Тәүбәгә кил. Чыгарып ташла бу яман уеңны башыңнан.

Бу яктан сөйләшүнең файдасы тимәгәч, мәсьәләне кызы язмышы белән аңлатмак булды ул.

— Хәсәнә шәһәрдә туып үскән кыз, аның авылда кара кулга әйләнүен һич теләмим,— дип киреләнде. Хәтта куркытып, катырак итеп тә әйтеп карады. Әмма төрле янау-куркытуларга да, үгет-нәсихәтләргә дә бирешмәде Гыйрфан. Киявенең сынмас-бөгелмәс зат-шәхес икәнлеген аңлагач, инде башны ташка орырдай булып кылануның да файдасы сукыр бер тиенлек кенә булгач:

— Ярый инде, юлыгызга ак җәймә,— диде бабай кеше.

Мондый рәнҗүле фатиха белән канәгать түгел иде Гыйрфан. Ярый, үзенең күңеле кителсен дә ди. Ләкин Җиһангир әфәндене хафага салырга теләми ул. Шуңа күрә максатны ачыграк, башка төрлерәк итеп әйтергә булды:

— Без анда үзебез яңа мәктәп ачып, мөгаллим-мөгаллимә булып эшләячәкбез. Моның өчен минем дә, Хәсәнәнең дә мәгълүматы җитәрлек икәнлекне беләсез ич инде...

Бу сүзләрне ишеткәч, Җиһангир хәлфәнең аксыл-саргылт йөзе ачылып, нурланып киткәндәй булды. Киявенең кулын кысуы эченә йөгергән җылыны аңлату билгесе иде.

* * *

Ихатаны, капка төпләрен көрәгәндә, Гыйрфан мулла шул хакта уйланды. Ә кар-буран, юкка мазасызланасың, абзыкай дигәндәй, гүя бөтен дөньяны күмеп-җимереп ташларга теләп, һаман котырына да котырына. Ялап куйгандай тап-такыр урыннарга карны китереп сылап кына тора. Мулла абзый-

ның үз күңелендә дә буран давылы гарасаты иде. Кызын озатканда,ниләр генә әйтмәде ул:

— «Хәсәнә» дигән сүзнең мәгънәсе бик зур, кияү — гүзәл, күркәм, матур, изге, яхшы дигәнне аңлата. Әмма ләкин, кояшта да тап булган кебек, Хәсәнәнең дә җитешсез яклары юк түгелдер. Аны бетерү, аңа шәфкатьлелек, тәүфыйклылык нурын даими өстәп тору вазифасы инде сиңа йөкләтелә. Иншалла, ул якты тормышыңа беркайчан да кара пәрдә япмас. Катылыгыңны беләм. Шуның белән син хәлфәләр арасында да өстен идең. Инде хәзер кирәк чакта хәләл җефетеңнән миһербанлык мөмкинлегеңне дә кызганма.

— Кайгырма, бабай, Хәсәнәдән Ходай матурлык-инсафлылыкны да, хатын-кыз өчен хас булган кешелек-күркәмлелекне дә, барлык асыл сыйфатларны да кызганмаган. Низаг белән яшәмәбез, мин аны түгел, ул мине низамлы итәр әле. Ул — минем бәхетем-сәгадәтем. Шундый илаһи фәрештә затны тәрбияләвегез, аны миңа бүләк итүегез өчен сезнең алда чиксез мәэсүрмен[1].

Әтисе Нурмөхәммәт имам әйтүенчә, ул башкалардан зиһенлелеге белән мөмтаз, имеш. Шуңадыр, бәлки, Гыйрфанның күңеле даими рәвештә үзе дә аңлап-төшенеп бетмәс дәрәҗәдә ярсу булды. Ниндидер яктылыкка, матур, күңелле тормышка, әллә нинди иҗтиһадлыкларга ашкынды. Әллә язмыш, әллә ялгыш дигәндәй, вәгъдә иткәнчә, мәктәп ача алмады; шуннан шашкын күңелен ул җир эше белән басмак булды. Мал үрчетүдә дә ниндидер рәхәтлек тойды. Боларда да ул кадәр дан табылмагач, чабыш атлары булдыру хәстәрен күрә башлады. Әмма иң зур, мөкаддәс, садә хыялы — ерак тарих төпкеленнән килгән нәсел-нәсәп тамырларына беркем тарафыннан да балта белән чабарга ирек бирмәү, ә бәлки, ул тамырларны һаман ныгыта бару, җир йөрәгенә янә тагын да ныграк үтеп керерлек итәргә кирәклекне аңлап яшәү. Моны ул һич тә эрелек өчен эшләми. Бу олуг максатны аңа сүздә дә, басмада да җиңел генә, өстән-мөстән генә исбат итү бик читен. Моның өчен әгәр хаслап сөйләшсәк, күп бала булдыру, аны мөкамәл[2] үстерү, адәм арасында ким-хурга калмаслык итеп тәрбияләү лазем. Арадан, һичюгы, берсе генә булса да тирә-якка нур чәчеп, әлеге чал тарих төпкеленнән килгән тамырларны алтын кәүсәгә әйләндереп яшәсен. Кәүсә киләчәктә ботаклар җибәрер, ботаклар яфрак ярыр. Агачта яфрак ничаклы, алар нәселе шулчаклы булсын.

Әмма һич тә чама чамага туры килми. Һәр чама салулый торган чанага төялгән кебек. Дөресен генә әйткәндә, беренче

---

[1] Мәэсүрмен — тоткынмын, бурычлымын.
[2] Мөкамәл — камилләшкән.

җимешенең үк ир бала булуын өмет итте ул. Тик кыз бала пәйда булды бу фани дөньяга. Әнисе Хәсәнә кебек ап-ак йөзле чибәр иде. Төрле исемнәр тәкъдим ителде. Шулай да Гыйрфан мулла күңеленә берсе дә ошамады. Бер булсын, бердәнбер булсын, икенчесе малай булсын дип, аңа Фәрдәнә[1] исеме куштырды. Һәр атаның ир бала көтүе табигый хәл. Ләкин кыз туса да, ул һич тә ризасызлык белдерми. Һәркем үз ризыгы, үз бәхете, үз язмышы белән килә бу якты дөнья күзенә. Әйдә, яшәсен, бәхетле-сәгадәтле, шәфкатьле-мөрәүвәтле булсын. Гыйрфан мулла да шулай уйлады. Әмма Фәрдәнә озак яшәмәде — мәңгелек дөньяга ашыкты.

Икенчесе дә кыз бала булды. Аңа да исемне озак эзләделәр. Бу юлы да аны ата кеше тапты — Нәгыймә[2].

— Ир бала көткәнеңне беләм, Гыйрфан, тик нигәдер...— дип, аны юатмакчы да булды остабикәсе, ләкин мулла абзый беркайчан да акланырга, моның сәбәбен тикшереп маташырга, вакланырга форсат бирми. Гаепне үз «вөҗданына» алып, Хәсәнә абыстайның күңелен шаян сүзләр белән күтәрергә ашыга:

— Ни чәчсәң, шуны урасың инде ул, әй!

Мөселман халкында ир белән хатынның бер-берсенә исеме белән эндәшү сирәк очрый торган хәл икәнлекне белә Хәсәнә абыстай. Бер-берсенә игътибарлы, шәфкатьле, ягымлы булу өчен «син» дип сөйләшүчәннәр. Гыйрфан исә артык үз итеп, яратып, берникадәр шаяртып гәпләшкәндә «әй» ымлыгын кулланырга ярата. Әлеге «Ни чәчсәң, шуны урырсың» дигәнгә, «әй»дә өстәлгәч, Хәсәнә абыстайның күк кабагы нык ачылып китә. Ә инде «Нәгыймә» сүзе Хәсәнә абыстайның бөтен теләге ачып салырлык булгач, мулласының (иренең) шуның өчен җан-фәрман тырышканлыгын аңлап, ул ифрат дәрәҗәдә нык шатланды.

Янә ике елдан соң абыстай «әй«енә ир бала бүләк итте. Аңа Шакирҗан[3] дип исем куштылар.

1884 ел иде бу. Ир бала өчен бик тә шөкер, рәхмәтле, риза иде мулла абзый. Кеше кадерен белүче җан булсын дип, «җан» сүзен дә «җилемләп» куйдылар. Бик яратып, якын күреп, ягымлы итеп эндәшкәндә, Хәсәнә абыстай, иреннән үрнәк алып, үзе дә «әй» ымлыгын кыстыра башлады.

— Иншаллаһ, Ходаем насыйп итте, инде теләгем кабул булды. Аллага шөкер, синең нәфсеңне канәгатьләндердем,

---

[1] Ф ә р д ә н ә — ялгыз, берүзе, бердәнбер кыз.

[2] Н ә г ы й м ә — бәхет, иминлек, мул тормыш; татлы тәм, ләззәт; нигъмәт, йомшак күңелле, бәхетле.

[3] Ш а к и р — шөкер итүче, рәхмәт әйтүче, бар булганына риза кеше; рәхмәтле, кеше кадерен белүчән.

әй,— дип шатланды балага исем кушып, өй эчендә икәүдән-икәү генә калгач.

Исеме җисеменә туры килә дигәндәй, Шакирҗан, чыннан да, изге күңелле, әдәпле, инсафлы, кеше кадерен белүче булып үсеп килә. Акылы да, зиһене дә, уйлау сәләте дә бар. Тик әнисе кебек йомшак табигатьле булуы гына берникадәр күңелне кыра. Ни дисәң дә, бу таләпчән-каты тормышта нык-лы, мәртәбә яулардай откырлык, урыны белән хәтта усаллык та кирәк. Шакирҗан тормыш дулкыннарында оста йөзә белүче шәхсән бер пәйгамбәр була алмас кебек. Көрәш мәйданында, тормыш сукмакларында, яшәү дәрьясында ниләр булыр — бу хакта әле аның гаме юк. Әмма әнисенә еш кына:

— Нигә минем энем юк? — дип, сорау биргәләп кенә тора.

Менә аның да — Шакирҗанның да — теләге кабул булыр чак җитте. Әнисен өч көн инде тулгак тота. Кемне алып кайтыр икән әнисе аңа: энекәшме, сеңелкәшме? Әлбәттә, энекәш булуын тели Шакирҗан. Ул үсә төшкәч, Кондызлы күлгә бергәләп балык тотарга барачаклар. Зәңгәр чишмә суын учлап-учлап эчү дә күңелле булачак. Исәнбикә болыннарында чәчәкләр җыярлар иде. Яманташ дигән урын куркынычрак. Ә инде көзен андагы янып торган кып-кызыл миләш тәлгәшләрен карап йөрүгә ни җитә. Авыргазы белән Турсәгәле елгасы кушылган урын... Шунда су керүләр...

Авыл тирәсендәге бөтен матурлыкны Шакирҗанга әтисе күрсәтә. Ә инде булачак энесен, үсә төшкәч, кулыннан җитәкләп, ул — Шакирҗан — йөртер иде. Әмма энекәш һаман юк та юк, күз ачкысыз ачулы буран һаман котыра да котыра.

* * *

Кендекәй килгәндә, Хәсәнә абыстайның хәле шактый мөшкел иде. Сызлана. Үрсәләнә. Авырлыкны теш кысып, урт чәйнәп үткәрергә тырыша.

— И Раббым!.. Илаһият көч бирсен!.. Бу киң вә иркен хәяткә чиксез нигъмәте, бәхете-сәгъдәте, мәсгудияте, тәүфыйгы белән килсен... Мин шуңа шәһадәт булыйм... Алла хөкемен тәсдыйк итим...— дип укынды кендек әби.

— Ак түти... сине күрү белән тыннарым иркенәеп китте... Иншаллаһ, вөҗүдкә чыгарырга муаффыйк булсын...— дип, теләккә каршы теләк белән җавап бирде Хәсәнә абыстай.

Кендек әбисе аның чәчләреннән сыйпады, йөзеннән сөеп-назлап алды, күз карашларына ягымлылык нурлары бөркеде. Үзе һаман сөйләнде дә сөйләнде:

— Һи, мәрхәмәтлем, бигрәк садә вә тәкәллефсез бит син, нигә мине — ком гарәбе төсле кап-кара йөзле бер мескенне — Ак түти дип әйтәсең әле, адәм куркырлык ямьсезмен ләбаса...

— Шөйлә исә дә[1] ... син матур... Бу атаманы мин түгел, бөтен авыл халкы биргән бит... Күңелең ак булганга...

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, чәй эчте. Гыйрфан мулланы да якты йөз, күтәренке күңел белән каршыладылар.

— Вакыйган[2]... өй эченә нур өләштең, Хәмдия абыстай, икегез дә балкып утырасыз, — дип шатланды Гыйрфан мулла, — синдәй мөктәдир[3] кеше юктыр бу дөньяда. Җитмәсә, буран да басылырдай булып тора...

Әйе, буран вакытлыча тынган шикелле иде. Хәсәнә абыстайның да нык сыкрануы сизелми. Шуңа күрә кендек әби кайтып китмәкче булды. Әмма Гыйрфан мулла аны җибәрмәде. Ул китсә, ниндидер күңелсез хәл килеп чыгар кебек тоелды. Ул шулай булды да. Кичкә таба шималь[4] җилләре исте, тагын да коточкыч буран купты. Тышта нидер ыжгыра. Буран тәрәзәләргә чатнатып китереп суккандай тоела. Дөнья әйтерсең зилзилә хәвефенә эләкте. Гүя кыямәт көне якынлаша. Хәсәнә абыстайны тагын да нык тулгак тотарга кереште. Гыйрфан мулла, Нәгыймә белән Шакирҗанны күршеләргә кертеп куеп, инде туачак баланың башкача тагын да ялындырып маташмаячагына инанган хәлдә, ихатада тегесенең тегеләй, монысын болай итеп, абзарда малларга печән, салам салыштырып йөрде. Әмма күңелен даими рәвештә ниндидер бер кара мәче тырнап торгандай булды. Аны һаман бер үк сораулар борчыды: «Нигә котырына бу буран?», «Нигә туачак бала бу фани дөньяга бик ялындырып килә?»

Дүртенче баланың чынлыкта галим булачагы турында әйтәләр. Бирсен Ходай. Бәхете, тәүфыйгы, кешелек гыйззәте белән килсен! Ул, бу хакта әле берәүгә дә сер ачмаса да, ифрат дәрәҗәдә ир бала көтә. Тик давыллы-буранлы көндә туганнарның тормышы да шикаять вә низаг белән үтәр, ди бит. Ник басылмый буран? Нигә табигать аның теләгән коточкыч салкын-ыжгыр буран белән күмеп тора?

Чү! Бу ни хәл? Нигә Ак түти чәчәрдәй булып килеп чыкты? Хәсәнә, ниһаять, котылганмы? Юк, бер дә аңа охшамаган. Ниндидер күңелсез хәл бар кебек.

— Гыйрфан мулла!.. Харап булдык... Әйдә тизрәк,— диде дә, суга чумган балык кебек, тиз генә юк булды.

Гыйрфан, селәүсендәй ыргып, ишеккә ташланды; бәреп кереп, өс-башын да салып тормыйча, караватта тынсыз яткан остабикәсе янына барып басты.

— Хәсәнә!.. Хәсәнә!.. Хәсәнәм!..— дип өзгәләнде ул.

---

[1] Шөйлә исә дә — шулай булса да.
[2] Вакыйган — чынында исә.
[3] Мөктәдир — куәтле, сәләтле.
[4] Шималь — төньяк.

Ләкин Хәсәнәсе җавап кайтармады, өнсез-тынсыз ята бирде. Бер мизгелдә әллә күпме чуалчык уйлар килде башына: «Дөнья белән хушлашуы шушымы?»; «Кая алып барырга хәзер аны?»; «Бәлки, җаны да чыкмагандыр әле?»; «Уфага алып китәргәме?»; «Өч ат җигеп чапса, кар-буран өемнәрен дә ерып үтәр, бәлки?»; «Алай дисәң, күз белән каш арасы юл түгел бит — сиксән чакрым чамасы»; «Барып җитә алырмы?»

Тормышына фәкать күркәмлек, яктылык, нур биреп яшәүче булганга, күңеле ифрат күтәренке мәлдә, мең-мең рәхмәт яудырырга теләгәндә, искиткеч ачылып китеп, «матурлык фәрештәм» дигән чаклары да була иде. Әле менә, артык гасабиланып китеп:

— Хәсәнә!.. Хәсәнәм!.. Матурлык фәрештәм!.. — дип, аның йөрәгенә сул колагын куйды: тибәме, җаны бармы, калдырып китмиме — шуны беләсе килә иде.

Әллә артык дулкынланудан, әллә чыгырдан чыгардай кылanудан, әллә күңеле шашар дәрәҗәгә җитеп тетрәнүдән — колак төбендә матурлык фәрештәсе йөрәге тибүнең әсәре дә сизелмәде. Шуннан, җан ачуы белән өс-башын салып ыргытып, ниндидер бер җенлелек кыяфәтенә кереп, матурлык фәрештәсен кочаклап алды да авызына тын өрергә кереште. Озак шулай итте ул. Ни өчен икәнлеген үзе белмәде дә. Бу мәлдә әйтерсең остабикәсенә фәкать аның тыны җитми. Тын өрсәң — ул яшәячәк, шалкандай тере малай бүләк итеп, аны мәңгегә шатландырачак, бәхетле ир итәчәк. Ни гаҗәп, Хәсәнә бервакыт күзен ачты, ирен күреп, хәтта елмаерга тырышты: кайгырма, җаным, мин тере, үлемгә алай тиз генә бирелмәячәкмен, яратуың көчле икән, мәхәббәтеңне кайнар тының белән аңлаттың, минем өчен кыйммәтле бер мизгел булды бу дигән мәгънә аңлатты да, елан кебек бөгәрләнеп, вакыт җиткәнлекне сиздерде. Кендек әбисе, ым кагып, аңа чыгып китәргә кирәклекне белгертте:

— Ак түти... Хәмдия абыстай... мәгәр... сиңа инабәтем зур... Матурлык фәрештәмне коткарсаң... бер күлмәк... — диде ул, чыгып киткәндә.

Кендек әбисе күлмәк тә, яулык та, исле сабын да... — бер нәрсә дә өмет итми иде. Ул дөньяга яңа кеше килүгә шат. Дөнья яңгыратып, ачы тавыш белән елап туа бәгъзе бер бала. Ул гүя, мин килдем ләбаса сезнең сафка, ишетегез тавышымны, дәгъвам зур, бәхетле итегез, дип оран сала. Тавыш никадәр көчле яңгыраса, кендек әбисенең дә шатлыгы шулкадәр зур була: туды бала, сау-сәламәт, ниһаясез өн чыгарды — иншаллаһ, яшәр, гомер итәр, тормыш диңгезендә үз колачы белән йөзәр.

Шулай да артык акырып-бакырып, чәүчәләкләнеп, елапыңгырашып килмәде якты дөньяга өзелеп-тилмереп көткән

бу бала. Менә, ниһаять, мин дә пәйда булдым дигәнне сиздереп, бер аваз салды да тынды. Тереме? Яшәрлекме? Бөтен мөчәсе дә тигезме?

Ходайга шөкер, барлык әгъзалары да урынында. Булырдайның буыныннан билгеле дигәндәй, карап торуга ук терекөмештәй тере икәнлеге сизелеп тора. Ир бала. Гыйрфан мулланың үзе кебек текә-биек маңгайлы, кара малай. Кар давыллары котырынган мәлдә туды. Тормыш давылларын җиңеп яшәсен!

1887 елның 12 март (яңа стильдә) көне иде бу. Гыйрфан мулланың шатлыгы дөньяга сыймады. Үзенчә, һичкемгә әйтмичә, Таш маңгай дип тә атады әле аны. Хәсәнә абыстайның да күңеле гали хәят күгендә йөзде. Нәкъ мулласына охшаган тере малай тапканына ихлас шат иде ул. Хәмдия абыстайның да күк кабагы тиз генә ябылмаслык булып ачылды: авылга — Солтанморат авылына — бер адәми затның өстәлүе әйтерсең аның маһирлыгына бәйләнгән иде. Нәгыймә белән Шакирҗанның да шатлыктан аяклары җиргә тимәде. Кулларын чәбәкәй итә-итә, бер басасы урынга биш басып, сикерә-сикерә очкынланып йөрделәр.

## II

Кеше туды!
Бөек-гали зат иясе!
Илаһи җан!!! Гарше көрсиләрдән — күк тәхетләреннән — яңа җан иясенә нур-шәфкать агылды. Гавам халкы, бәхет-сәгадәт теләп, алагаем кул чапты. Янә бер мәшәкать — исем табу. Исеме җисеменә туры килердәй булсын. Йөрәк тибешен, эчке дөньясын, күңел хәзинәсен, холык-фигылен... — бар вөҗүден аңлатып торсын. Бик борынгы заманнарда төрки халыклар исемне баланың туган вакыты-мизгеленә карап та кушканнар. Бу үзенчәлек әле дә сакланмый түгел. Шуны искә алып, көндезге мәлдә туганга, Көнбатыр дип исем кушарга тәкъдим итүчеләр дә булды. Кабул итмәде мондый «кыланчык» исемне Гыйрфан мулла. Дөнья күзенә буран-давыл-гарасат ярып чыкканга күрә, Буранбай дип атарга да тырыштылар. Бу исем Гыйрфан мулланың да, остабикәнең дә күңеленә ятмады. Арыслангали тәкъдим ителде. Арысландай көчле, гаярь, пәһлеван булсын, янәсе. «Батыр», «буран», «арыслан» кебек җисмәни көчне тәгъбирләүче сүзләрне кеше исеменә сылап куюны яратмый иде ата кеше. Алар мәрхәмәтле-шәфкатьле ана күңеленә дә хуш килмәде. Коры, тышкы, җисмәни көчне чагылдыручытасвирлаучы «ялтыравыклы» исемнәргә исләре китми ич

аларның. Ниндидер эчке сыйфат-күркәмлекне, бөтен мөчә-әгъзаларында кайнаган гакли вә җисмәни көчне, аның һәммә тәрәккыятен бизәүче исем булсын.

Шушы үзенчәлек табылмаса, исеме җисеменә аслан туры килмәсә, бик кадимге ата-бабаларыбыз унсигез яшьләргә җиткән ир баланың исемен алыштырырга мәҗбүр булганнар. Аны «ир аты» (ир исеме) дип атаганнар. Бу очракта ир-егетнең унсигез ел буе сыналып, тормыш бизмәненә салып үлчи-үлчи килгән барлык үзенчәлекләре, — тышкы һәм эчке сыйфаты, рухи халәте, холкы-табигате, хезмәткә мөнәсәбәте, — кыскасы, һәммә мөмтазы[1] искә алынган.

Кадимге төркиләр балага исемне үз сүзләре белән кушкан. Ай, кояш, җил, йолдыз, чәчәк, таң, көн, күз, чәч... — ниләргә генә игътибар ителмәгән. Исем эзләүдә алар чын мәгънәсендә иҗади зирәклек күрсәткән. Ә инде унынчы йөзләрдә, ислам дине кабул ителеп, гарәп-фарсы сүзләре дулкын-дулкын агыла башлагач, әлеге иҗади ялкын сүрелә төшә. Исем табу өчен зыялылар, ишаннар, муллалар баш ватарга тиеш була. Аларның бертөрлеләре гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләрнең эчке мәгънәсен, аһәңен, асыл сыйфатын аңлап эш итә: балага исемне нәсел-нәсәбенә, ата-ана абруена, үзенең төс-битенә, сизелеп торган табигатенә карап сайларга тырыша. Икенчеләре — ул сүзләрнең мәгънәсен белгәннәре — бәгъзе берәүнең баласына аңлы рәвештә, «начар» эчтәлекле исем эзли — авызыннан юньле сүз чыкмаган, коега төкереп, кешегә кабер казып, тырнак астыннан кер, алтын базыннан чүп эзләп йөргән ахмакка матур исем әрәм итәсе килми. Ул сүзнең тышкы яңгырашы болай һич тә күңелсез түгел. Әмма эчтәлеген әлеге надан-томана ата-ана белми. Шулай да исем кушучыга ата-ананың рәхмәте дә, садакасы да, мәрхәмәте дә ифрат зур. Ә инде өченчеләре — гарәп-фарсы сүзләренең мәгънәсен бөтенләй белмәгән наданнары — исемне сүзнең эчтәлеген аңламый куша. Гавам халкы — әлифне таяк дип белмәгәннәре — мондый надан дин әһелләренә дә зур инабәт[2] баглый.

Мәдрәсәдә унбиш ел буе шәкерт булып михнәт чиккән, гарәп-фарсы сүзләрен ятлап ми череткән, соңыннан шул ук мәдрәсәдә пишкадәмлек хезмәте үтәп чиләнгән, аннан Троицк шәһәренең атаклы мәдрәсәсендә мөдәррислек әһеленең бөтен нечкәлекләрен белеп эш иткән Гыйрфан мулла боларның барысын да биш бармагы кебек яхшы белә.

— Исем табуда акыл да, зирәклек тә, мантыйк та кирәк, — диде ул остабикәсенә.

Бу хакта мең-мең баш ватып, тәмам гаҗиз булып, исе-

---

[1] Мөмтазы — башкалардан аерылып торган сыйфаты.
[2] Инабәт — ышаныч.

акылы чуалган җептәй буталып беткән иде инде Хәсәнә абыстайның:

— Соң, мулла, исем кушарга нибары ике көн вакыт калды, Ходай язмаган эш булмас, шул мин әйткәнне — Гайнән дигәнне — тотыйк та тәвәккәллик инде,— диде, бер сөйләшкәндә.

Гыйрфан мулла, ут кебек кызып, тузынды да китте:

— Соң, Алла колы, Гайнән, «үзгәртмичә», «ничек булса, шул көенчә» дигән мәгънәне аңлата бит ул. Мин баламның дөньяны үзгәртмичә, ничек булса, шул килеш яшәвен теләмим. Әтиең абыеңа бу исемне белеп кушкандыр, бәлкем. Әллә ул шуңа яшьли дөнья куйгандыр. Яраткан абыеңның исемен йөрәгеңдә йөрткәнеңне беләм анысы. Әмма ләкин минем улыма бу исем һич тә муафыйк түгел. Акыл белән уйлау, әтрафлы мөхакәмә[1] кирәк монда.

Шуннан Гыйрфан мулла җиде буынын тикшерергә кереште. Аны белү һәр мөэмин-мөселман баласының изге, мөкаддәс бурычы. Локман улы — Ибраһим, Ибраһим улы — Хисаметдин, Хисаметдин улы — Әхмәт, Әхмәт улы — Нурмөхәммәт, Нурмөхәммәт улы — үзе — Гыйрфан. Нәсел тамырлары ифрат еractан килә. Ул тамырлар җир-ана йөрәгенең төпкеленә җибәрелеп җәелсен. Картәтисе Әхмәт — Солтанморатта ахун. Әтисе Нурмөхәммәт — имам. Җиләктәй дүрт кыз, сөлектәй сигез ул үстерә. Гыйрфан — шул «сөлекләрнең» берсе. Хәзер тирә-юньгә нур чәчеп, дан шаулатып, ут уйнатып дөнья көтүче мәртәбәле бөек зат. Менә бу буран-давылларны ерып дөньяга килгән Таш маңгай андагы яшәү чаткыларын хосусан ялкынга әйләндерерлек көч-кодрәт булсын иде. Юк, бу, кемдер фараз иткәнчә, айга сикерергә чамалаган ахмак арыслан түгел, яшен ташын учында уйнатырдай пәһлеван гына да түгел, җиде кат күк дөньясының, җиде кат җир астының серләрен ачучы, зиһене белән зилзәбәрләрне җиңә белүче, дәвер пәйгамбәре исемен йөртерлек укымышлы, акыллы, галим кеше, алтын баш булсын иде. Әһә, тапты исемне! Эзли, чокчына торгач, мантыйкны авызлыклап эшкә җигә белгәч, үзеннән-үзе пәйда булды бу исем аның ми күзәнәкләрендә. Бу эзләнү, ихласлап әйтсәк, әллә күпме тау актарып, бер бөртек алтын табуга бәрабәр булды. Аның Таш маңгае киләчәктә зур ачышлар ясый алачак дәвер пәйгамбәре — галим кеше булачак. Исеме җисеменә туры килгән. Алтын савытка каплаган алтын капкач кебек мач килеп тора. Галим дигән ат-исем кушарга. Исеме дә галим, үзе дә галим булсын. Юк, ул гына да җитенкерәми. Бисмилласын,

---

[1] Әтрафлы мөхакәмә — төрле яклап уйлау, хөкем чыгару.

иншалласын әйтеп, Алла исеменнән «җан» сүзен дә җилемләп кую мәслихәт булыр. Димәк ки — Галимҗан. Ул үзе дә төшеп калганнардан түгел. Әмма бала атадан батман артык туарга тиеш. Ата данын бөек тотарлык булсын!

Шушы фикерен остабикәсенә әйтте. Аз гына арттырырга, әлеге тау-тау балчык арасыннан алтын бөртеге табу җиңел түгеллекне мантыйкка бәйләп аңлатырга кирәклекне әйтергә, фикере өчен мактанып алырга да онытмады.

— Менә шулай, әнкәсе, пәйгамбәр Ибраһим галәйһиссәламне беләсең, — берчак гәпләшкән идек бит, — безнең дә нәсел тамырыбыз Ибраһим хәзрәттән килә, кем белә, шул Ибраһим пәйгамбәр затыннандырбыз, бәлкем; шуңа күрә фамилиясен дә картәтисе Нурмөхәмməттән алмыйк, һаман шул Ибраһим кояшы балкысын. Иштә... Галимҗан Ибраһимов була бу Таш маңгай. Алла зур бәхет, матур тормыш, галимлек мәртәбәсе насыйп итсен! Син дә, мин дә эчкерсезбез. Гөнаһка баткан адәми зат түгелбез. Иншаллаһ, бер Ходай теләгебезне кабул итми калмас.

Хәсәнә абыстайның да күңел күге чалт аяз кояшлы көн кебек иде. Баладан соң, ул тагын да матураеп, балкып, сылуланып, яшәреп китте. Кыз чактагы садә, самими, чибәр вакытларын сагынып, искә төшереп, кешегә сизелер-сизелмәслек кенә итеп, битенә кершән-иннек сөртте, ике бит очына бик аз гына ал якты. Күзгегә карагач, әле яшьлек ялкынының, нурсөйкемлелекнең бөтенләй үк җуелып бетмәвен тойды.

— Тфү, тфү, күз тимәсен, син чын фәрештә булдың да киттең ләбаса, әйкәем, яшьлегеңә кире кайттың, — дип, Гыйрфан мулла аны әллә ничә мәртәбә мактап та алды.

Авылда башкортлар, мишәрләр, алатыр татарлары яши. Авыл халкы арасында бала тапкан кешегә аш-су китерү гадәте элек-электән килә. Гәрчә моңа мохтаҗ булмасалар да, Хәсәнә абыстайга да ташып кына тордылар. Хәер, Хәсәнә абыстай, авылда кем генә бала тапмасын, үзе дә аш-су тулы табак-савыт күтәреп йөгерергә ашыга. Шулай инде ул: бәйрәм ашы — кара-каршы.

Беркөн башкорт Котлызаман бичәсе Көнсылу бишбармак пешереп китергән. Башта ул алып килгәнен бирергә кыенсынып торды:

— Һәй, Хәсәнә абыстай, мин һинең кеүек аш-һыуға һис кенә лә оста түгелмен дә инде; бына үземсә бишбармак бешергән булғайным, килтермәйенсә калыуҙы бер генә лә килештерә алманым шул; ерәнмәһәң — аша, ерәнһәң — малдарыңа бирерһең... — дип уңайсызланды.

Хәсәнә абыстай аның күңелен тиз тапты:

— Ни сөйлисең, Көнсылу, чакырышып йөрибез ләбаса, го-

мер бакый синең бишбармак, бәлеш, сумса, коймакларыңны мактап ашаганны әллә оныттыңмы? Ни эшләп мин син кадер-хөрмәт итеп китергән нигъмәт-ризыкны малга бирим ди. Аштан олы булу — үзеңне иманнан югары тоту кебек бит ул.

Алар утырып чәйләп тә алдылар. Көнсылу аннан биш-алты яшькә кечерәк. Көнсылу — кара чибәр. Уйнаклап торган шомырттай кап-кара күзләр. Куе кара кашлар. Төн карасыдай елкылдап торган кап-кара чәчләр. Ачык йөз. Эчкерсез, мөлаем караш. Энҗедәй тезелеп киткән тешләр. Алсу ирennәр. Уртачадан югарырак буй. Тал чыбыгыдай бөгелеп-сыгылып торган нечкә бил. Дала тавышлары чыгарып шыңгырдатып җырлавы, бер бөртек кайгы күрмәгән иркә кыздай яңгыратып көлүе, һәр сүзнең ямен-тәмен татып сөйләшүе, башка күркәм сыйфатлары аны болын чәчәкләре арасында гына үскән илаһи бер гүзәл зат итеп күрсәтә. Алты бала тәрбияләүче утыз биш яшьлек хатын дип берәү дә әйтмәс.

Гыйрфан мулла алардан чабыш аты колыны сатып алган иде. Аларның дуслык җебе шул чакта ныклап төйнәлеп китте. Көнсылу аңа бервакыт болай дигән иде:

— Һәй, абыстай, мин дивана, күлмәгем менән генә ике катлы бер бәндә, һин ауылыбыҙға килен булып төшкәс, юк йомошомдо бар итеп, һеҙгә һинең сибәрлегеңде бер карап китергә килә торғайным. Матурлыкка һоклана белеү күңелде оторо күтәреп, сафландырып ебәрә бит ул.

Әле дә менә мактап бетерә алмады:

— Карасы... тфү, тфү, күз теймәһен бер үк... Ихлас әйтәм бына... яңынан ныклап матурайып киткәнһең... хәс тә бешкән алма... гупси йәшәргәнһең... Теге ни... нисек әйтәйем һуң... хур кыҙҙары кеүек... һәй, әттәгенәһе... һәй, йән кисәккәйем...

Бу гөнаһлы дөньяны афәт-фаҗига гарасаты белән күмәргә, бөтен кара-пычрак якларын калын ак кар белән капларга, яшәүгә фәкать аклык теләгәндәй котырынган-шашынган буран тынганга өч көн булып китте инде. Дус авыр язмыш хәл ителгәндә сынала дигәндәй, Хәсәнә абыстайның бу юлы баланы үтә кыенлык-җәфа белән табуы күрше авылларга да барып ишетелгән. Бу хәбәрне әллә ыжгыр җил-буран, әллә кешеләр бер-берсе аша җиткергән. Буран басылып, авыллар арасына янә юл салынгач, ат җигеп, биш чакрым ераклыктагы Юламаннан чуаш дуслары Әптерәй дә бичәсе Кәтринә белән килеп җиткәннәр. Аларның танышып-дуслашып китүе дә тиктомалдан гына түгел. Уллары Әләксәй — ат чабыштыру остасы. Үткән җәй сабан туенда Гыйрфан мулланың чабыш атына аны атландырдылар. Тоҗырылып

кына килде тимер күк. Беренчелекне алды Әләксәй. Мәгәр Гыйрфан мулланың түбәсе күккә тиде, мәртәбәсе гарше көрсигә җитте, йөргәндә, шатлыктан аяклары җиргә тияр-тимәс атлый башлады.

Әптерәй белән Кәтринә (Солтанморат халкы Андрей белән Екатеринаны шулай дип атады), пар күгәрчендәй гөрләшеп килеп кереп, өстәл өстенә күпереп пешкән бодай күмәче китереп куйдылар. Бу тирәдә чуашлар күп яши. Алар өч телне белә: үзенекен, урысныкын, татарныкын. Дөрес, татарныкын ватып-җимереп тә сөйлиләр. Шулай да бер генә чуаш та йөрәгендә кайнаганын, күңел түрендә йөрткәнен, тел очында булганын аңлатмый калмый. Башта Әптерәй такылдарга кереште:

— Гирпан мылла... пес пәпәйне кутлар үчун килгән... Бына пудай икмәге. Динепес пер пулмаса да, кунүпес пер бит... Гунах пула тисәңес... ашамакыс... малга пирекес...

Сүзгә Кәтринә кушылды:

— И... Кәсәнә әпестәй... и мылла апзый... кәеп итмәкес инде... икмәген күңелескә әллә укшар, әллә укшамас... пуш кул пелән килмәс үчун генә инте... Пынауы пит... парапыс та парапыс... ашкынды да турды... Мылла апзый да, Кәсәнә әпестәй дә пик простойлар, ти... Знакум да пулып киткәч...

Гыйрфан мулла аларны да юатырга тырышты:

— Әптерәй кордаш... Кәтеринә туташ... Ислам дине башка дин тотучыларны дошман күрергә кушмый. Адәм баласы, нинди генә диндә булмасын, бәндәчелекне бер Ходай үзе кушканча югары тотарга тиеш. Кешелеклегең булмаса, Алланы искә алуда да, динле булып кылануда да бер фәтва да юк. Бер акыл иясе — шагыйрь — әнә ни дигән:

Бер сәгать гадел кылмак яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш ел озаграк.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә, гөрләшә-гөрләшә, тирли-тирли чәй эчтеләр.

Инде алда янә бер зур мәшәкать — бәби туе көтә.

* * *

Бу көннәрдә Гыйрфан мулла ифрат нык дәртләнеп, бөтен инсаниятkә, хәятка, кешеләргә фәкать изге хәерхаһта булып, күңеле белән җиде кат күк дөньясында йөзде. Бәй, бәянелхак имкям[1] инде: Гыйрфан сүзе үзе үк: аң, белем, тәрбия дигән

[1] Бәянелхак имкям — дөресе дә шул.

мәгънәләрне аңлата. Исеменең чын асылы, дәхи дә тирәнрәк фикер йөртеп сөйләшсәк, «белем вә тәрбия арасында барлыкка килгән булдыклылык» икән. Бәс, шулай булгач, аның кояштай балкып яшәргә тиешлеге заһир имди[1]. Тик шулай да әллә Ходай насыйп итми, бу олуг максатка хосусан ирешеп бетә алмады шикелле. Бәй, ни хикмәт, заманы да шулай томанлы килә бит әле аның. Монда берүзең башыңны ташка бәрә-бәрә үрсәләнсәң дә, әллә ни кырып булмый. Син, кояшка үрелгән гөл кебек, яктылыкка омтыласың, кемдер килеп, итәгеңнән бөтереп ала да караңгылыкка тарта. Хәзер менә бу «таш маңгайларда» инде өмет. Шөкер, мәдрәсәләрдә яңача укыту турында баш ваталар икән. Бирсен Ходай! Иншаллаһ, киләчәк дилбегәсе, хәяти мәшәкать, икътисади, сәяси хәлләр аларның корыч кулында булыр. Дилбегәне кылдан ишеп, мәңге ычкынмаслык итеп нык тота алсалар, ул куллардан хөр яшәү кодрәте ычкынмаса, яшәүхәят ялкыны даимән дөрләп торса, дөнья корабы теләсә нинди давылда да оста вә тигез йөзәр. Ә хәзергә борын төбендә борчып торган иң мөкаддәс максат — бик мәртәбәле итеп, югары һәм илаһи дәрәҗәдә бәби туе үткәрү. Моның өчен Аллаһы Тәгалә үзе шаһит, бөтен авыл халкын шаккатырырлык итеп әзерләнде. Туй бала туганнан соң җиденче көнне үткәрелергә тиеш. Хәдисләрдә заһир ителүенчә, моның өчен бер куй-сарык фида кылу сөннәт[2] санала. Авылда тугантумача, кардәш-ыруг, дус-иш, күрше-күлән бихисап. Берьюлы өч куй-сарык чалды Гыйрфан бай.

Бәбидән исән-имин котылгач, Хәсәнә абыстайның да шатлыгы эченә сыймады. Ниһаять, ул мулласына төсе-бите, текә маңгае, шомырт кара күзе, бөтен вөҗүде-сыйфаты белән ике тамчы су кебек охшаган ир бала табып бирде. Илаһым, суйган да каплаган инде менә. Дәхи дә... мулласының шулкадәр биниһая илһамланып китүе, төн заманында кендек әбисенә кар-буран ера-ера үзе баруы, яшәү вә үлем белән көрәшкән авыр мәлдә шифалы-вөҗүб тынын өреп, сөеп-сөенеп яшәү хәяты бүләк итүе, Хәмдия абыстайга бәбидән соң ук күлмәк алып бирүе, һәм дә ки шуларга охшаш мең төрле зур һәм вак мәшәкатьләрне калын җилкәсенә чын ир-егетләрчә ала белүе... — җәмгысы аның пәһлеван вә ихлас ир икәнлеген тәсдыйк итте.

— Минем өчен бу арзуларың[3] бик гайрәтле, гаярь, шәфкатьле ир икәнлегеңне күрсәтте, муллакаем, әйкәем, рәхмәт

---

[1] Заһир имди — ачык, билгеле ич инде.
[2] Сөннәт — гадәт, Мөхәммәтнең сүзләре, эшләре.
[3] Арзуларың — тырышуларың, омтылышларың.

инде; Ходай Тәгалә икебезнең дә күңел канатыбызны, бөтен рухыбызны һаман шулай иман нуры белән ныгытып, һәр мөчә-әгъзаларыбызга саулык-сәламәтлек, уйларыбызга аклык-пакьлек биреп, балаларыбызны тәүфыйклы, кешелекле итеп тәрбияләп, тигез яшәргә насыйп булсын инде,— дип амин тотты Хәсәнә абыстай, бәби туе мәшәкатьләре үтеп киткәч.

— Әйткәнең фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килсен, әйкәем, остабикәкәем, әлгаязе биллаһи, Ходай хәвеф-хәтәрләрдән сакласын берүк, бигайниһи[1] ир бала табып биргән хәләл җефетенә кайсы ирнең рәхмәте илаһи зурдан булмас икән...— дип, ихлас күңелдән шатланганлыгын белдерде мулла абзый.

Әмма ул, бу әле тормыш җимешләребезнең бик азы гына, моңа һич кенә дә канәгатьләнергә вә разый булырга ярамый, күңелеңне киң тотып, иҗтиһадлылыгыңны аз гына да киметмичә, киләчәк авыр-мәшәкатьле тормышка җиң сызган дигән мәгънәне әйтер өчен, бер гәп куерткан да, сүз чылбырын өзмәскә уйлап, тагын да дәвам итте:

— Алгы итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын, дигән сүзләрне кабатларга ярата иде картәти. Әнинең алгы итәгенә унике бала басты. Мәгәр пакь-пөхтә, горур, авырлыкка баш имәс, сыкранмас булды. Ә менә арт итәгенә мал бастыру — монысы инде ир кеше эше. Андый ата: «Әлхәм шөкер, җилкәм чокыр, ашарга ныкмын, эшкә юкмын»,— дип яши алмый. Бала башында — бер кайгы, ата башында — мең кайгы, дигәнне дә әйтергә ярата иде картәти. Ата кеше һәммәсен мөлдерәмә тулы үтәргә тиеш.

Мондый ихлас күңелдән, мөкиббән, йөрәкне йөрәккә куешып, пар күгәрчендәй гөрләшеп сөйләшү сирәк була. Иртә таңнан кичке эңгер-меңгергәчә эш артыннан әвәрә булып мәш килү. Мең төрле дөнья мәшәкате дулкынына чуму, ястү намазыннан соң инде тәмам арып-алҗып, вакыт-вакыт кыл өзәрлек көч калмау чигенә җитү...— әйтәсе килгән иң кадерле-мөкаддәс сүзне дә күңел сандыгында һаман бикләп яткыра бирә. Эшкә бер күмелеп китсә, бөтен иҗтиһады белән керешсә, Хәсәнә абыстай аның янына барырга, гәрчә бик иплеНизамлы рәвештә генә сүз катарга теләге көчле булса да, үзенең болай да сабыр табигатен тагын да сары алтынга әверелдерергә мәҗбүр була. Ә инде эштән бушап бер ачылып китсә, сөйләшергә тел кычытып торса, әйтер сүзләре күп булса, сандугач урынына сайрый башлавын әйкәе үзе дә сизми кала. Болай матур, эзле, мәгънәле сөйли. «Борынгылар шулай дигән», «ата-бабаларыбыз болай әйткән» дип, фикерлә-

[1] Бигайниһи — нәкъ үзенә охшаган.

рен мәкаль-әйтем белән беркетеп, бизәп куярга да ярата. Әле аның нәкъ менә шулай ихлас күңелдән ачылып китеп, сөйләшергә сайрар теле кычытып, түземсез йөрәге ашкынып, шашкын күңеле дулкынланып-җилкенеп торган чагы. Ул менә ошбу гаҗәп мәшәкатьле, авыр көннәрдә, бермәл бик берәгәйле генә черем итеп алганда, үзләренең нәсел-нәсәп тарихы сәхифәләренә алтын хәрефләр белән язып куярлык илаһи бер тәмле-татлы төш күргән икән. Төшне ул тәмләп-тәмләп, урыны-урыны белән әле сизелер-сизелмәс кенә көмешләнә башлаган кара сакалын сыпыра-сыпыра, менә минем тел-лисан сәнгатем нинди кодрәтле дигәндәй, ихлас бер мөкиббанә[1] белән сөйләде.

Ул, имештер, төшендә җир белән күк йөрәге кушылган урында кешеләрне бәла-казадан коткаручы сәмруг кош булып очып йөри. Әүвәл искиткеч караңгы төн, давыл-гарасат, коточкыч җил-давыл була. Бервакыт бөтен кара-кучкыл дөнья шартлап-ертылып, сызылып алсу таң ата. Караңгылыкны ярып, канатына алсу таң нурлары төяп килгән Аллаһы Тәгалә илчесе-хәбәрчесе Мөхәммәт пәйгамбәргә Алла тарафыннан мөкәүвән ителгән[2] Коръән Кәримне иңдерүче Җәбраил фәрештә белән очраша. Җәбраил фәрештә аңа дүрт нам-кодрәт булу турында әйтә: берсе — Аллаһы Тәгаләнең дусты Ибраһим, икенчесе — Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре Муса, өченчесе — Аллаһы Тәгаләнең мәхлугы Гайса, дүртенчесе — Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре Мөхәммәт. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җәбраил аркылы Мөхәммәт пәйгамбәргә шул вәхи ителмештер: бәндәләр бу фани дөньяда камиллек-бәхет хасил итеп, аны мәңгелеккә хәят нуры урынына мөкаддәр кылырга[3] тиешләр. Аллаһы Тәгаләнең кәрәмкяр[4] дусты Ибраһим бу бәхет-сәгадәт нурларын җир өстенә мул итеп өләшүче кояшның үзе булып исәпләнә, имеш. Ибраһим нәселеннән булып, инсаният бәхете өчен яшәүче Нурмөхәммәт улы Гыйрфан шул кояш нурларының бер чаткысы икән ләбаса. Менә ни өчен Җәбраил, киң вә талмас канатларына утыртып, аны оҗмах-җәннәттә йөртеп алып кайтты. Анда Гыйрфанны кәүсәр күлендә коендырды. Бу су шундый саф, йомшак, ләтыйф — ул сине сабый балага әйләндерә дә куя. Күлнең тирә-ягында үскән җимеш агачлары, аллы-гөлле ефәкләргә уралган хур кызлары, тагын да янә мең төрле күркәм-

---

[1] Мөкиббанә — яратып, сөеп, дусларча.
[2] Мөкәүвән ителгән — барлыкка китергән.
[3] Мөкаддәр кылырга — алдан билгеләргә, тәкъдим итәргә.
[4] Кәрәмкяр — киң күңелле, шәфкатьле, рәхимле.

лек-гүзәллек дулкыннары матурлыгы әйтеп тә, язып та аңлатып бетерерлек түгел. Шул дулкыннар, хозурлыклар, алсулыклар эчендә ләззәтләнеп озак-озак йөреткәч, Җәбраил аны янә Җир йөзенә алып кайтып бастырды. Монда да бөтен матурлыкка мәгъдән сәҗдә итәрлек[1] иде — пәйгамбәрләр дөньяга килә торган алсу, моңсу, илаһи гүзәл-хозур таң. Аның дүртенче баласы — Таш маңгае — буранлы-давыллы көндә түгел, нәкъ менә ошбу ләтыйф[2] таңда — пәйгамбәр таңында туган, имеш. Шуннан Җәбраил аның колагына өрде, аннан йөрәгенә керде. Гыйрфан мөхикъ[3] сахабәгә[4] әйләнде. Ул да әйтте: «Балаң пәйгамбәр таңында туды, пәйгамбәрләрне заман-дәвер барлыкка китерә, улың дәвер пәйгамбәре булыр»,— диде.

Уянып киткәч, һушына килә алмыйча, озак кына иңкетиңке килеп утырды ул. Шуннан киштәдән Коръәнне алып, беренче битенең үк бер кырыена «Пәйгамбәр таңы» дип язып куйды.

Сөйләп бетергәч, ни әйтерсең дигәндәй, сораулы караш ташлады ул хәләл җефетенә:

— Менә шулай, остабикә, хосусан бер гаҗәп төш булды бу!..

— Әйе, әйе, матур төш,— дип, аның сүзләрен тәсдыйк итте Хәсәнә абыстай, тик ниндидер нәтиҗә чыгара алмады. Ана бәхете — балада дип уйланды.

Бу вакытта аларның икесе дә әле бишектә тын гына яткан Таш маңгайның киләчәктә яшьлегенең бер матур таңында: «Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә... Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә»,— дип язып куячагы турында аз гына да уйлый алмыйлар иде.

Давылда туган улларының тормышның искиткеч кара, гарасатлы-өермәле, котырган давыллары эчендә кайнаячагынчайкалачагын, матур, изге, бөек яшәү өчен көрәшеп, гомер буе коточкыч авыр чир кичерәчәген, «халык дошманы» дигән «дан» алачагын, шуны раслау өчен кулына каләм биргәч, шул каләмнең очлы ягы белән җан ачуы килеп үз күзенә үзе кадаячагын болар һич кенә дә акылларына китерә алмыйлар иде, билгеле.

---

[1] Мәгъдән сәҗдә итәрлек — чын мәгънәсендә баш иярлек.
[2] Ләтыйф — йомшак, гүзәл, мөлаем, нәфис.
[3] Мөхикъ — хаклы, гадел, хаклык ягында булучы.
[4] Сахабә — Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кеше.

# ТӘПИ БАСЫП КИТКӘЧ...

И газизем, аяк бастың киң дөньяга,
Юлдаш булсын зур бәхетләр —
атла алга;
Гөлләр сипсен
фәрештәләр юлларыңа,
Авыр булса, һич сыкранма —
түз барына.

*Ана фатихасы*

## I

Һәр сәнәнең[1] үзенчәлеге бар. Быелгысы, Ходайга шөкер әле, майлы табада шуган коймак кеби, җай, шома гына бара. Усал мартта агачлар, өй бүрәнәләре шартласа да, акман-токман бураннары бөтен дөньяны кырып бетерердәй җенләнеп, котырынган арыслан шикелле кыланса да, бервакыт көннәр, каты көрәшләрдән соң капылт тынып калган сугыш яланыдай, тынычланды да куйды. Авыл халкы: «Көннең аягы озын атлый, мартның буыны шартлый»,— дип шатланды.

Гыйрфан мулла һәр ел-сәнәнең «холкын», «гореф-гадәтен», «кәеф-кыяфәтнамәсен» яза бара. Шуның белән ул яз, җәй, көз, кышның ничек килерен алдан фараз итә. Бу хосуста тирән, ышанычлы караш булдыру өчен, аның уйлавынча, табигатьнең йөрәк серен, күңел хәзинәсен, тын алышын, җанын-вөҗүден белү лазем. Быелгы язмалары үзе бер дәфтәр була язды. Шуның белән бергә ул башка елгыларныкын да карап алырга онытмый. «Май ае салкын булса, игенгә туклык булыр, чебенгә юклык булыр»; «Май яңгыр күп булса, арыш уңар» дигәннәрне әнә 1879 сәнәдә үк язып куйган икән.

Апрельнең егермеләрендә дә әле, елак-көйсез баланы хәтерләтеп, кар катыш яңгыр яуды. Бу чорда да күзәтте ул апрель аеның ничегрәк күкрәк тутырып сулыш алышын. Май аенда исә табигать йөрәгенә әле уң колагын, әле сул колагын куеп тыңлауны, хиссиятене игътибарда тотуны ул тагын да көчәйтеп җибәрде. Үлән, чәчәк, гөл, каен, карама, тал, имәннәрнең тын алышына, җилнең нинди көнне кайсы яктан исүенә, кояш, ай, йолдызлар йөзенә...— барына, һәммәсенә нык игътибар итте. Табигатьнең кәеф-сулышында, йөрәк тибешендә, үлән-үсемлек, хайваннар дөньясында сизелгән-күренгән һәр яңалыкны дәфтәренә теркәп барды. Дәхи дә 1883 елда ук: «Карама агачында чәчәк күп булса, карабодай

[1] Сәнәнең — елның.

уңар», — дип язып куйганына да игътибар итте. Вакыйган, сынамышлар тәсдыйк ителде. Май салкыны иген туклыгы китерде. Шулар җөмләсеннән аның карабодае да уңды. Авыл халкы болай «кыш бабай» алдына елый-елый, яшь түгә-түгә икмәк сорап бармастыр. Һәркемнең бура төбе хәзергә ыңгырашып ятмый әле. Халыкның кышны җай үткәрәчәгенә иманы камил.

Инде декабрь. Чатнама суыклар башланды. Һәркем үз ызбасында, үз ихатасында, үз дөньясында, үз эше-мәшәкате белән мәшгуль. Бүген уникесе. Таш маңгай туганга нәкъ тугыз ай. Ни гаҗәп, ошбу көнне тәпи басып китте Галимҗан. Нинди вакытта бит әле. Таңда ук торып, бер-бер артлы тәһарәт алып, алар парлап иртәнге намазны укыды. Аннан бергәләп, балалар белән гөрләшә-гөрләшә, иркенләп чәй эчтеләр. Көндезгелеккә Хәсәнә абыстай карабодай боткасы пешерде. Аны Таш маңгай бик тә яратып ашый. Әнә шул ботканы ашау өчен табын әзерләгәндә, тәүге мәртәбә тәпи басты Галимҗан. Басты да бер мизгел хәрәкәтсез торды. Нәкъ тораташ. Өй эчендәгеләр, тын алырга куркып, сабыйның беренче адымын көтә. Ни булыр? Атлап китә алырмы? Егылмасмы? Менә ул беренче адымны ясады. Ике кул алга сузылган. Алар очып китәргә әзерләнгән кош канатын хәтерләтә. Әлбәттә, анда әле һич тә очып китү гаме юк. Фәкать бер максат — тәүге адымны ясау. Менә икенче адым. Уң кулы артка таба хәрәкәтләнде. Күрәсең, куллар гәүдә тигезлеген саклау, егылып китү куркынычын булдырмау өчен кирәк. Менә өченче адым. Әһә, уйлап баса, тигезлек саклана, тәгәрәп китмәүнең барлык чаралары күрелә. Шуннан... инде булды, тәмам төшенеп алдым, хәзер җилдерәм генә дип уйлады булса кирәк: беренче мәртәбә чабып китәргә ирек куелган тай кебек, кинәт алга ыргылмасынмы бу; ыргылды да маңгае белән как идәнгә барып та төште.

— И Ходаем, харап булдык, башын бәрде, — дип, Хәсәнә абыстай аны йөгереп килеп күтәреп алды.

— Йә, җитеп торыр, алай тиз генә булмый ул, өйрәнер әле, берәү дә, әкияттәге батыр кебек, «ә» дигәнче йөгереп китмәгән, әйдә ашап алыйк, — диде әти кеше.

Әмма бер генә кашык та ботка ашата алмадылар аңа. Әнисенең алдыннан шуышып кына төшә дә тагын тәпи баса. Бер адым... ике... өч... дүрт... тагын тәгәрәп китә, тагын барып торгызалар.

Әтисе:

— Инде җитте, ашатыгыз бу Таш маңгайны, кара син аны, нәкъ чабыш аты, — дип, бер үк сүзләрне мең кәррә кабатласа да, берәүне дә санга сукмады сабый: ни боларга ашарга

ирек бирмәде, ни үзе бер тәгам ризык капмады. Басып тора-тора да китә дә бара, янә тәгәри, янә торып китә; әлеге Таш маңгай бәреләбәреләкүгәреп бетсә дә, мәгәр ыһ та итми, күздән яшь чыгаруның ни икәнлеген дә белми; ул гүя тамаша кылып торучыларның әле көлүләренә, әле егылганы өчен әрнүләренә үч итеп шулай кылана: күрегез, белегез, күңел сандыгыгызга салып куегыз, мин һич тә сезнең кебек йомшак җан булмам, артка чигенмәм, куйган максатыма алдымдагы мең каршылыкларны җимерә-җимерә барырмын, дип әйтә иде.

Ботканы ул тәки ашамады. Нык басып китә алганчы кыланды.

— Мотлакан, ир-егет солтаны булыр бу, сүзен сүз итеп яшәр, теләгенә ирешү өчен Таш маңгаен ташка бәрүдән дә курыкмас,— дип горурланды ата кеше.

Фәрдәнә, Нәгыймә, Шакирҗан, әнә, яшьләре үткәч кенә тәпили башлаганнар иде. Анда да әле менә бу Таш маңгай кебек, ярсу атка охшап, тиз генә, бер тын алуда уптым илаһи йөреп китә алмадылар. Атна буе иза чигеп, кат-кат маңгай канатып, курка-курка, көчкә-көчкә-иллалла йөреп киттеләр. Вакыйган, борынгыларның шул: «Булырдайның буыныннан билгеле»,— дигәннәре рас инде. Мондый сөземтәне аслан башка балаларын кимсетү өчен ясамый ул. Менә бу ир-егет солтаны булачакның бер селтәнүдә һәммәсен тәгамә итердәй кылануыннан чыгып фикер йөртә. Тегеләрнең телләре дә ике-өч яшьтә генә ныклап ачылды. Ә бу ташбашның фикере гали булачагы да сизелеп тора. «Әттә», «әннә», «мәммәм» кебек сүзләрне биш-алты айда әнкәсе артыннан тәкрарлый да башлады. Ә хәзер,— әле нибары тугыз ай гына бит,— теле һич кенә дә тик тормый, әллә ниләр пупалый, сөйли дә сөйли; инде килеп, тәпи басуының беренче көнендә үк, ярсый-ярсый йөгереп китә язды хәтта. Афәрин! Йөрү рәвешен күр син аның, йөрү рәвешен! Шул кош тәпие зурлыгындагы аяклары белән идәнегезне сындырам дигәндәй, каты баса бит. Кара син аны! Менә Ходайның рәхмәте! Вакыт-вакыт әнкәсенә кушылып җырлап та җибәрә бит әле ул!

Бер-бер артлы ике кыз тапкач: «Ни чәчсәң, шуны урырсың»,— дип борчылган иде бит ул. Аннан соң дөнья йөзенә пәйда булган ир баласы өчен дә, гәрчә ул су сөлеге кебек матур-фәсахәт булса да, әллә нигә артык шатлык-горурлык кичермәде. Әлбәттә, бу хакта ул хәләл җефетенә бер кәлимә сүз әйтмәде. Шулай да ана кешенең моң тулы сизгер күңеле, бала язмышы өчен һәрдаим сыкранып-өзгәләнеп типкән йөрәге атаның балага нинди караштa булуын тоемламый буламы? Әллә илаһилыгым җитмиме, алиһә була алмыйммы, ана-

лык кабилиятемне[1] сиздерә белмимме дип борчылып яшәде Хәсәнә абыстай. Әнә ничек язылган Коръән Кәримнең Әл-Мөлек сүрәсендә: «Сүзегезне әйтсәгез дә яки әйтмәсәгез дә Алла белә: нинди серләр ята күңелегездә»; «Ничек белмәсен инде ул үзенең яратканын Ул бит күрә һәрбер сернең төбендә ни ятканын». Димәк ки, Аллаһы Тәгалә ана күңелендә, бала йөрәгендә нинди энҗе-мәрҗән сакланганын тәгаен белеп тора. Бәс, шулай булгач, Ходай Тәгалә тарафыннан яратылып бирелгән җаның-тәнеңдәге һәммә асыл сыйфатларны бала күңеленә алтын хәзинә итеп сала бару хәерле. Дөрес, барысы да балага карынында чагында ук бирелә: төсең-битең, кыяфәтең, саф-самимилегең, кан йөрешең, сулау дәрәҗәң... Тугыз ай буе ана карыны дөньясында яши бала. Аңа барлык илаһият алган сулышың, җыйган ризыгың, сөйләгән сүзләрең аша сеңә бара. Әмма бу йөрәк җимеше тышкы дөньяга дә аслан битараф түгел. Сизеп-белеп ята ул. Тышкы дөнья рухы аңа ананың тән күзәнәкләре аша үтеп керә. Низаг, акырышу-бакырышу, сүгенү аны зур хафага сала. Тәмле-татлы сүз, җыр-моң, күңел сафлыгы аның бөтен вөҗүденә рух нуры булып сеңә.

Менә шуларны искә алып, йөрәк җимешенең карында чакта ук өлгерә башлавын теләде ана кеше. Баланың әмәле, ананың гамәле дигәндәй, теләк кенә аз, билгеле. Теләгеңне гамәл фарыз. Намазны пышылдап укуга күчте ул. Аның пышылдау аһәңендә, кайнар тынында, моңлы авазында бала өчен әйтерсең яшәүнең мәңгелек шифасы бар. Ул хәтта хосусан балага багышланган нәфел намазы[2] укый башлады. Берүзе генә калганда карынындагы «гәүһәр төшен» (ул аны шулай итеп тә күз алдына китерә иде) җыр-моң белән дә иркәләде. Бу мизгелдә инде «гәүһәр төшен» карында түгел, ефәк бәллүдә ята дип хис итте. Көе-моңы да — үзенеке. Кайдадыр, кемнәндер ишеткән түгел. Сүзләре дә йөрәк түреннән кайнап чыкты:

Син хәзергә йокла, ял ит, и газиз җан,
Шифа булсын — җыр-моңнарым белән назлан.
Син тугачтыйн сихәт булыр кайнар сөтем,
Оҗмах кошым, җәннәт гөлем, и өметем!

Гәрчә буранлы төннәр давылындагы авырлык белән килсә дә бу фани дөньяга, аны җыр-моң каршы алды. Җыр-моң иркәләп йоклатты. Җыр-моң назлап уятты. «Әттә», «әннә»

---

[1] Кабилият — сәләтлелек, булдыклылык, кулдан килү.

[2] Нәфел намазы — мәҗбүри булмаган, савап өчен укыла торган намаз.

дигән сүзләрне ул даими рәвештә тәкрарлап торды. Әмма «әттә»не күбрәк әйттерергә тырышты. Аның теле әнә шул мәгънәви куәте гали-шөһрәт булган «әттә» сүзе белән ачылды. Ата кеше аны кулына алса, «әттә», «әттә», «әттә» дип такылдарга керешә. Әйтерсең шуның белән ул атаның анага булган зур ихтирамын, баланың сөю-сөелүенә изгелек кылучы серле мәсьәләләрне хәл итә. Җыр-моңга да ул бик иртә кушылып китте. Мулла абзый игътибар белән карап тора-тора да:

— Илаһым, хосусан бер оста шагыйрь ясыйсың бит син, әй, бу Таш маңгаебыздан. Карачы, бөтен йөрәк моңыңны үз йөрәгенә сала бара бит бу шатлыгыбыз, — ди.

Остабикәнең бу мактаулардан күңеле мең кәррә күтәрелеп китә. Соңрак ул инде сүзләрнең тамырларын гына түгел, кушымчаларын да катлауландырып әйттерә башлады: «Әттә-ттә-тә», «әттә-тә-тә», «әттә-тә-тә-тә». «Тә»нең берничә мәртәбә кабатлануы «тәтәй» дигәнне аңлата иде. Димәк ки, «әттә тәти», «әттә тәти», «әттә тәти» була. Боларны ишетеп, Гыйрфан мулла шатлыгыннан буылып-буылып көләргә тотына. Ул гына да түгел, остабикәсе инде аны әллә күпме сүз әйтергә дә өйрәткән. Дөрес, ул әле мөстәкыйль сүзләрне кушып, алар белән билгеле бер фикерне аңлату өчен, җөмлә төзү осталыгын белми. Шулай да аерым-аерым, өзек-өзек әйтелгән сүзләр сабый күңелен аңларга ярдәм итми калмый. Ул шуларны да әйтә ала: «Әттә-тә-тә-тә... әннә-нә-нә-нә... я-ра-та...», «Әт-тә-тә-тә-тә... ма-ма-ма-тур...»

Гыйрфан мулланың фикер йөртүенчә, Галимҗанның, башка балалары белән чагыштырып караганда, болай якты дөньяда үзен тиз балкыта алуы, шөбһәсез, матур күңелле, сәләтле анасының тәрбиясе җимеше. Моны башкача аңлату гөнаһ саналадыр.

Ә инде баланың тәпи басып китүе, шул көнне иң яраткан карабодай боткасын да авызына кабып карамавы (аны ашатуны барлык гаилә әһелләре теләгән иде дә бит), һаман бер тәгәрәп китеп, бер яңадан аякка басып йөрүе, далага томырылган яшь тай урынына кылануы, маңгае күгәреп бетсә дә, үзен әзмәверләрчә тотарга тырышуы, беренче адымнарыннан зур ләззәтлек, илһам, горурлык алуы, үзен шуның өчен генә дә әллә кем итеп чамаларга тырышуы бөтен өй эченә бәйрәм, тантана төсе кертте, шатлык шаукымы иңдерде.

Сабыйның бүген идән мәйданында шөһрәт казануы атаананы да, апасы Нәгыймәне дә, абыйсы Шакирҗанны да зур шатлык-куаныч дәрьясында йөздерде. Беренче адымы котлы булсын! Тәпиләре ныгысын! Аны киләчәктә киң дөньяга алып чыксын! Амин!

## II

— Эти! Эти! Кара сакалыңа ак бөртек кайдан төшкән?

— Һм... кайдан, кайдан, имеш... Тормыш бүләк итте...

— Кем соң ул тормыш?

— Тормышмы? Шушы инде... Аллаһы Тәгалә биргән үз хәятыбыз...

— Алла бабай кайда яши?

— Чү, гөнаһлы булма... Алланы бабай димиләр. Ул барлык бабайларны... бөтен кешеләрне... инсаниятне барлыкка китерүче... Сине дә, мине дә...

Галимҗан кычкырып көлеп җибәрде:

— Хи-хи-хи... Белмәдең... Мине Алла ясамаган... Әни мине Әбелхәяттән[1] алып кайткан... Үзе әйтте... Безнең әни алдаша белми...

Ата кеше кызды да китте:

— Йә, җитәр, әллә ниләр сөйләп, мине гөнаһка батырып бетерәсең, Алла сугар үзеңне...

Малай матчадагы чыбыкка карап алды:

— Алла кай төшкә сыздыра?

— Башыңа.

— Синең кебек арт аякка түгелмени?

— Әниең, мин өйрәткән сабакларны гел кабатлап торсаң, тәүфыйклы булсаң, Алла бер җиреңә дә сукмас, ахирәттә җаның оҗмахта булыр.

— Ахирәт кайда? Оҗмах кайда?

— Уф! Җитте диләр.

Әле алар өй эчендә икесе генә иде. Остабикәсе кендек әбисе Хәмдия абыстай янына китте. Сырхабрак тора икән. Сумса, каймак, катык-сөт, күмәч...— тагын да әллә ниләр алды. Ул инде намус вә инсаф кагыйдәләрен шәригать кушканча үти.

Хәмдия абыстайга олуг вә изге кадер-хөрмәт тиеш. Инде бишенче баласы аның — шәфкатьлелек-мөрәүвәтлек белән күңеле тулы кешенең — йөрәк кайнарлыгы кушып биргән фатихасы белән килде дөньяга. Һәммәсе аның җылы кулы аша үтте, барысын да нурлы күз карашлары белән коендырды. Хәят йөзенә билхәер кабул итүе, риясыз булуы бөтен галәмгә билгеле. Нәгыймә белән Шакирҗан әле җиләк җыярга китте. Яшь ярымлык Нәфисә бәллүдә йоклап ята. Аратирә, анда-санда аны да барып караштыргалап ала Гыйрфан мулла. Һай, рәхмәт төшкере, әллә бер-бер тәмле төш күрәме

[1] Әбелхәят — мәңгелек суы, тереклек суы.

югыйсә: чиядәй алсу иреннәрен чәпелдәтеп, йокы аралаш елмаеп-көлеп ята бит, әйтерсең рияз кочагына чумган. Билләһи, исеме җисеменә тач туры килә. Нәфис Нәфисә бу!

Әле авыл халкының иркенләп, күкрәк киереп тын алган мәле. Бер көне ел туйдыра торган язгы чәчү чоры гөрләп үтеп китте. Алда — сабантуй бәйрәме. Печәнгә төшкәнче ул кадәр зур мәшәкатьләр күренми. Быелгы яз да башкаларыннан әллә ни аерылып тормады. Авыргазы, Турсәгәле елгалары шашынып алды. Боз киткәнне карап торулар үзе бер хозурлык. Хәяти җирлегеңне онытып, өй зурлыгы боз кисәкләре өстенә баскан килеш, әллә нинди хыялый дөньяга агып китәсе килә. Урамнарда аккан гөрләвекләрдә дә ниндидер моң бар кебек. Болары да үтеп киткәч, бакчаларда алма, чия агачлары, сирень, сәрби куаклары чәчәк атты. Бөтен авылда сулап туя алмаслык хуш ис аңкып тора. Болыннар мең төрле чәчәкләр япмасына күмелде. Ерактан карaганда ук диңгезне хәтерләтеп торган Кондызлы күл кешеләрне даими рәвештә үзенә су коенырга, балык тотарга чакыра. Исәнбикә болыны, Яманташ тирәсе урманнарындагы чыпчык башы зурлыгы пешкән кып-кызыл җиләкләр һәркемне яннарына чакырып, йөрәкне ярсытып торалар.

Бу бай-нигъмәтле җирләрне ташлап, кемнең генә шәһәрнең таш диварлары арасына барып кысыласы килер икән. Ярый, кысылдың да ди. Алар унике бала шаулашып-гөрләшеп үстеләр. Бер уйласаң, бу үзе генә дә ата-ана өчен искиткеч зур каһарманлык бит. Менә мин ничек яшәдем дип, йодрыгы белән күкрәген төеп сөйләшергә батырчылыгы бар. Унике баланы җил-яңгырдан саклап үстергән Нурмөхәммәт шулай итте дә. Күкрәк төеп сөйләште. Ата юлыннан китте Гыйрфан. Ходайга шөкер, бишенче бала бәллүдә булачак энеләрен, сеңелләрен өмет итеп ята. Иншаллаһ, булырлар. Бала һәр җәһәттән атаны уздырып җибәрергә тиеш. Бәй, шулай булмаса олы максат куеп яшәмәсәң, нигә ишәк урынына зур колаклы, кыска ботлы булып гомер сөрергә бу кунакка килгән фани дөньяда?

Ул шулайрак фикер йөртә. Аларның барысы да чынбарлыкка туры килеп тә бетмидер, бәлки. Җәһаләтлек[1] көчледер. Чөнки дөнья үзгәрә, алга тәгәри, ә синең сакалың һаман агара, тормыш мәшәкатьләре аңа кырау төшерә. Җитмәсә, менә бу Таш маңгай, миллион сораулар биреп, башны диңкетә. Аңа бит әле нибары дүрт кенә яшь. Ә укый башласа, уйлап кына кара, фикер йөрт, нинди генә сораулар биреп диварга китереп терәмәс тә, бер кәлимә сүз әйтмәслек итеп,

---

[1] Җәһаләтлек — наданлык.

авызыңны алагаем ябып куймас, ә?! Менә бит ул мәсьәләнең мөгез өлеше кая барып терәлә. Менә терәкә.

Әле алар, бишектә гамьсез генә йоклап яткан Нәфисәне исәпләмәсәк, өй эчендә Галимҗан белән икесе генә. Мәгәр үзенә охшап, гәрчә әле дүрт кенә яшьтә булса да, күңеле белән бу серле галәмнең әллә күпме яшерен якларына үтеп керергә чамалап маташа. Әллә нинди катлаулы сораулар биреп башыңны бутап бетерә. Афәрин! Ибраһим пәйгамбәр эше генә дә булмас әле, бәлкем!..

Янә шунысы бар: эш арасында анысын алай, монысын болай итеп йөргәндә,— әллә аңлый,— ул бит беркайчан да назлы мәче урынына килеп сырынмый сиңа. Ул менә бүгенге көнге кебек тыныч мизгелне күзәтеп тора (ничек башына килә диң син аны). Әтисенең эштән аерылып җиңел тын алуын шәйләсә, килә дә сарыла.

— Әти! Әти! Әни кая китте?

— Кендек әбисенә, улым.

— Кендекнең дә әбисе буламы? Менә бит минем кендегем. Кем аның әбисе?

— Менә тагын... юньсез малай... Тапкан бирер сорау... Бәләкәйсең әле... Үскәч белерсең монысын...

— Мин үскән инде... Менә...— Галимҗан дүрт бармагын күрсәтте.

Ата кеше алдында зур башлы, зур колаклы, биек маңгайлы малай басып тора. Кешеләрне сынау, хәяти тәҗрибә, бизмәнгә салып үлчәү ягыннан караганда, әтисенә улы өчен горурланырлык сыйфатлар күп икән ләбаса. «Акыллы баш зур булыр, кечкенә колак бур булыр»,— диләр бит. Моның колагы, ай-һай, шәп: әрекмәнмени!»; «Биек маңгайлы кеше акыллы булыр»,— дип тә әйтәләр. «Борыны зур кеше гайрәтле булыр»,— дигәне дә бар бит әле аның. Моның борыны да сөбханалла икән ләбаса. «Чәче йомшак кешенең табигате йомшак»,— дигәне дә юк түгел. Чәченең катылыгын әйтеп торасы да юк. Ала башласаң, пәке кире сикерә. Әйтерсең ул чәч түгел, тимер бөртеге. Ә менә Шакирҗанныкы ефәк белән бер иде. Шулай булса да әле, чәчен ала башласаң, куркак куян шикелле, терт-мерт итеп, соры күзләрен яшьләндереп, аларны бер ачып, бер йомып, мәлҗерәп утырыр иде. Ә бу Таш маңгайның һич гамендә юк. Кытырдатып кырасың шул тимерчыбыктай каты чәчен, ә ул ых та итми утыра бирә. Авыртса да аслан сер бирми. Түзә. Яшь турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Елатырсың аны. Тик артык үзсүзле булуы гына саруны кайната. Шакирҗан аңа җанын өзеп бирергә әзер тора. Нәгыймә дә шулай. Әмма ләкин вакыт-вакыт икесенең дә сүзләрен колагына да элми. Бәй, беркөн шулай, тышка уйнарга алып чыгу өчен, Шакир-

җан бишмәтен кидермәкче булды. Ә бу — Таш маңгай — карышыпмы-карыша. Шуннан Нәгыймә ярдәмгә килде. Ул, янәсе, арада иң өлкәне, аны тыңламый калмас.

— Галимҗан, акыллым, алай ярамый, Шакирҗан сиңа абый кеше, ә абыйның сүзен тыңларга кирәк, ки бишмәтеңне, — дип, әнисенә охшап, йомшак кына итеп әйтте.

Ә бу әрекмән колак, изгелеккә явызлык кылгандай, гаҗәп киреләнеп, кулына тоттырган бишмәтен атты да бәрде. Бәй, хәзердән әнисен тыңламаса, анасының, абыйсының сүзен аяк астына салып таптаса, мин мин микән, мин кем икән, дип, борын чөеп үссә, киләчәктә нindiрәк рәтле адәм чыгар икән бу үзсүзле, кирегә бөтәшкән нәмәкәйдән? Шуны уйлап, ыргытып бәргән бишмәтен алып киярга әмер бирде ул. Юк, ата булып ата кешене дә санга сукмады. Шуннан, матчадагы тал чыбыгын алып, чажт итеп, арт ягына берне тамызып алды. Мәгәр еламый. Шомырт кара күзләрен әйләндереп-тулгандырып, акайтып бер карады да, синең күңелең кырылмасын өчен генә инде, бу нәмәстәкәегезнең пычагыма да кирәге юк, дигән кыяфәт күрсәтеп, Нәгыймә бишмәтен янә кидерә башлагач, яңадан карышып маташмаска булды. Ачулы Галимҗан Нәгыймә апасына да, Шакирҗан абыйсына да, гәрчә икесе ике яктан килеп кулыннан алсалар да, җитәкләргә ирек бирмәде; сарык тәкәседәй тып-тып басып, башын шактый югары тоткан хәлдә, горур гына атлап чыкты да китте. Апасына, абыйсына аңа иярүдән башка чара калмады. Ишек ябылгач, чыбыгын тагын да матчага кыстырып, озак кына үртәлептәләһһефләнеп торды ата кеше. Аннан:

— Ай-һай, эре бәрәңге булмакчы, хәзердән үк шулай, үскәч ни эшләр бу? — дип кәефсезләнде.

Остабикәсе аны юатырга тырышты:

— Тынычлан әле, атасы, үзеңне кулга ал, кызу канлылык тәртә арасына сыймаган пырдымсыз ат кебек бит ул. Ипсез ат тәртә сындырыр, холыксыз кеше өен туздырыр, дигәнне ишеткәнең юкмыни соң? Тотасың да чыбыкка үреләсең.

— Аларны башкача җиңеп буламы? Әти дә аз ашатмады тал чыбыгын. Аркамда эзләре һаман бар.

— Тыңламагансыңдыр. Кире булгансыңдыр.

Бу урында ул елмаеп куйды.

— Кирелек галәмәте бар иде инде ул анысы...

— Әтиең унике бала караган, әле бит безнеке... бишәү дисәм... аның да берсен җирләдек... Баш бала бәхетле була, диләр иде. Баш баланы да саклый алмадым бит, үзем гаеплемендер инде, үзем...

— Йә, куй әле, анасы, йомшаклыкны, күз яше яратмаганымны беләсең бит... Ходай шулай кушкандыр...

— И… Ходай, саклангганны саклармын, дигән бит әле ул.
— Үлгән артыннан үлеп булмый бит инде.

Бала тәрбияләү, аларны аякка бастыру, кеше итү турында сөйләшү даими рәвештә булып тора. Шулай да ул беркайчан да җәбер дәрәҗәсенә барып җитми. Хәсәнә абыстайның сабыр холкы, түземлелеге, акыллы эш итүе мулла абзый йөрәгендә кайнаган теләсә нинди дулкын-давылны баса да куя. Үзен-үзе онытып, чыгырдан ычкынып кәефсезләнгәндә, остабикәсенең мөлаем, садә, самими, сабыр йөзенә карарга гадәтләнеп китте ул.

— Йә инде, бозма холкыңны, ир кешегә болай чәбәләнү, утка баскан мәче урынына кылану бер дә килешкән эш түгел, — дип әйтеп торган кебек була ул.

Шул мизгелдә үк үзендә нindидер бер уңайлык сизә мулла абзый. Ә инде чыбык белән балага кизәнүне дә, сугуны да Хәсәнә абыстай бик авыр кичерә.

— Атасы, безнең ише диндар кешеләргә матчада чыбык тоту һич кенә дә килешкән эш түгел, әллә алып ташлыйсыңмы, вакытлыча куркыту көчсезлек билгесе ич ул, — диде остабикәсе ул чакта, балалар тышка чыгып киткәч. — Әле менә син шул күз алмасы кебек нәни балага суккач, күз алларым караңгыланып китте, аңа түгел, минем йөрәгемә пычак белән чәнечкәндәй тоелды. Сугылган-кагылган балада акрынлап кире сыйфатлар күбәя тора.

— Ярый, моннан бүтән сукмаска тырышырмын, ә чыбык хәзергә торсын әле, шунсыз булмый, — дип, бу хакта башкача сүз көрәштермик дигән төс-кыяфәт күрсәтте ул.

Алар тышка чыкты. Ни гаҗәп, Галимҗанның бишмәте болдыр рәшәткәсендә эленеп тора иде. Димәк, бишмәтне өй эчендә әтисе чыбык белән сыйлаган өчен генә кигән булган, ә инде тышка чыккач, апасы белән абыйсының көче җитмәячәкне аңлап, яңадан салып ыргыткан; тегеләре исә моны кереп әйтергә курыккан: усал атаның тал чыбыгы өчесенең дә аркаларын кашып алырга мөмкин ич.

Көн кояшлы, матур, җылы иде. Нигә мондыйда аңа бишмәт киеп йөрергә? Шуны аңлаганмы акылы кот булган бу малай? Эчке сиземләве, тоемлавы көчлеме? Ә көн һаман җылына барды. Бишмәт бәхәсе акрынлап Галимҗан файдасына хәл ителде. Һәммәсен дә кияргә көчләүнең һич тә хаҗәте булмаганлыкны аңлады. Ә инде чыбык чыжлатып, баланың йомшак җирен бүрттерү тәгаен ахмаклык икәнлек көн кебек ачыкланды. Шул инде: «Бала багуы — елан агуы», — дигәннәр бит. Елан агуын бүген ата кеше чәчте. Моның кирәкмәгәнлегенә хәзер иманы камил дә бит, ләкин соң инде. «Өстән бишек тирбәтеп, астан баланы чеметмә» дигәне дә бар бит әле аның. Бала алдында иманың саф булырга

тиештер ул. Галимҗан кебек дүрт яшьтә үк үзенең һавалы-зиһенле икәнлеген адым саен сиздереп торганнар каршында бигрәк тә.

* * *

— Әти! Әти! Әни нигә кайтмый?
— Хәзер кайтыр. Сабырсызланма.
— Нәгыймә апа, Шакирҗан абый?..
— Алар җиләккә китте бит.
— Ә нигә миңа әйтмәгәннәр?..
— Йоклап калдың.
— Ә нигә уятмаганнар?
— Син бәләкәйсең әле.
— Мин зур инде, Нәфисә бәләкәй...

Әллә үзенең тавышын ишетеп уяндымы югыйсә. Башта, ыгы-мыгы килеп, үзенчә мыгырданып ятты да (яшь ярымлык булса да, тәпи дә йөрми, сөйләшә дә алмый әле ул), әллә минем өн-тавышымны ишетмисезме, күрсәтим әле үземнең кем икәнлегемне, үрле-кырлы китерим әле дигәндәй, кычкырып еларга да тотынды.

— Ай-һай ла, кыланган булуы, тавышын күр син аның, таң тынлыгын ярып кычкырган әтәчнекеннән аз гына да ким түгел: әйтерсең ишетмиләр, бер ул гына бу дөньяда Алланың кашка тәкәсе; соң, әнкәң-гүзәлең кайтып җиткәнне көтсәң, шул тәмле төшләреңне күрә-күрә тыныч кына йоклап ятсаң булмаганмы инде,— дип сөйләнә-сөйләнә барды ата кеше бәллү янына.

Барса, ни күзе белән күрсен: өстендәге япмасын тибеп очырган, аяк-куллары очып китәргә канат кагынган кош канатыдай өзлексез талпына, хәрәкәт итә: ә инде елавы бер дә юкка түгел икән — асты юешләнгән, «сары буяу» барлык та сизелә. Бәллүнең икенче ягына Галимҗан да килеп тотынды.

— Ихи-хи-хи-хи, хе-хе-хе-хе, кәкәй иткән, шуңа елый, ха-ха-ха...— дип, бер көлде, бер чыраен сытты, бер борынын җыерды ул.

Инде ни эшләргә? Менә син агай! Нигә һаман юк та юк остабикәсе? Ни эшләп болай озаклады соң әле? Әллә Хәмдия абыстайның хәле авыраеп киттеме? Әллә бер-бер күңелсез хәл булдымы? Менә сиңа кирәк булса тагы!.. Ичмасам, кызы Нәгыймә кайтып җитсен иде тизрәк — бер-бер хәл кылыр иде. Ул инде, әнисенә охшап, теләсә нинди эшне тиз гамәлгә ашыра. Юк бит, кайтмый, кайтмый, кайтмый... Ә Нәфисә, үч иткәндәй, менә этлән әле әнкәй өйдә юк чакта, бала карауның кадерен бел, мин шуны аңлату өчен дөнья яңгыратам дигән кебек, ныклап сөрән салырга тотынды.

— Йә, җитте инде, җитте, тавышыңның таш ярырдай икәнлеген аңладым лабаса: таманысы, булгач та булырсың икән, уф, карачы; әттә ә-ттә-тә-тәт... ыгы-ыгы, тайт-тайт, әнә шулай, әнә шулай, менә терәкә, гел шулай көлеп кенә, елмаеп кына ят, озак яшәрсең, акыллы булырсың...— дип сөйләнгәндә, әһә, җиңдем мин сине, үземә буйсындырдым, әни юкта барымны да белми идең, менә хәзер янымда энәгә баскан кешедәй кылан инде дигән шикелле, бернитиклем «ыгы-ыгы», «үә-үә», «эммә-эммә» дип, үзенчә сөйләнеп ята да тагын күгәреп-катып бакырырга керешә. Шуннан ата кеше аны янә җылы сүзләр белән сыйлауга күчә: — Тукта әле, Нәфисә кызым, тыңла әле син менә аз гына, кешеләрчә тыңла, мәгәр яныңда дүрт яшьлек абыең Галимҗан басып тора, ул бит тугыз ай дигәндә йөгереп китте, теле дә тәтелдәп кенә тора иде, бәллүдә без аның беркайчан да ыңгырашканын күрмәдек, ул бит сугып җибәрсәң дә еламый, сиңа бит инде, күбәләккәем, яшь ярым, әмма ни тәпи басу турында уйламыйсың, ни бер кәлимә сүз әйтергә кодрәтең юк, җитмәсә, акырганбакырган буласың,— дип сөйләнде.

Әтисенең ихлас күңелдән әйткәннәрен тыңлый сабый. Әмма ләкин сөйләүдән туктагач, тагын да оран сала. Аңлый ата кеше: ни пычагыма кирәк синең бу «кызык» сүзкәйләрең, әткәччәем, хәлем бик мөшкел ләбаса, бел шуны, зинһар, коткар мине тизрәк бу юеш оядан, дип әйтә инде.

Ата кеше, ниһаять, аңлады кызының әмәлен, инде үзенең гамәлен күрсәтәсе генә калды. Бала акырып-бакырып ята бирде, ә ул, җиз таска җылы су салып, кызын әлеге «баткаклыктан» коткару чарасын күреп йөрде. Барысы да җиренә җиткерелгәч, кызын бишектән алды да тастагы җылы суга китереп бастырды, үзенчә бөтен шартын җайлап, аны юарга кереште. Үзе даими рәвештә сөйләнеп торуын да онытмады:

— Әттә-тәт, әттә-тәт, әллә-ләл, әллә-лә, нигә шулкадәр тыпырчынасың әле син болай, бакыруыңа карап, җырчы булыр дип уйласам, инде тиберченүең буенча фикер йөрткәндә, оста биюче булырсың, шәт,— дип сөйләнде ул.

Бу минутта Галимҗанның ни уйлаганын аңлау кыен иде. Ул күзләрен тоҗрайтып карап тик тора. Ничек кенә булмасын, зәңгәр күзле, сары чәчле, алсу иренле сеңлесе Нәфисәне бик ярата ул. Аның елавын, борчылуын, әле менә юештә ятуын һич теләми. Әтисе алып юа башлагач, иркен тын алып куйды: әһә, яраткан сеңлесе зур бәладән котыла, янәсе.

Әтисе хәтта Нәфисәнең чүпрәкләренә кадәр юып элде. Бу мәшәкатьләр бетүгә, остабикәсе дә, җиләкчеләр дә кайтып керде. Җиләкчеләрнең юлы уңган: икесенә чүмәкәй тулы ике савыт җиләк алып кайтканнар. Нәгыймә, Галимҗанга уч тутырып, җиләк алып килеп бирде. Ләкин энесе аны

кабул итмәде. Моңа барысы да аптырап калды. Сәбәбен әтиләре аңлатты:

— Ияртмәгәнгә үч итә, янәсе, әллә-ләл; кара, нинди икән бу. Үзенчә мәгъруурлык күрсәтә, мин төшеп калганнардан түгел, ди инде.

Аннан сүз Хәмдия абыстайга күчте:

— Озаграк тордым шул, тиз генә чыгып китеп булмады, авызына берни капмый икән, шулай да мин алып барганнарны ашады. Килүемә бик шатланды, мәгәр кат-кат рәхмәт әйтте. Иртәгә, Алла боерса, тагын да барырмын инде, — дип сөйләнә-сөйләнә, кулына кызы Нәфисәне алды ул.

Шунда Гыйрфан мулла кызы Нәфисә белән булган маҗараларны көлә-көлә сөйләп бирде:

— Мин бер хакыйкатьне аңладым әле, әнкәсе, бу дөньяда бала караудан да авыр эш юк икән. Уникe бала тәрбияләп үстергән әнкәемнең нигә кадерен белмәдем икән мин? Хәзер менә яңадан балага әверелсәм, бернинди кирелек тә күрсәтмәс идем, әти-әни әйткәнне гел тыңлап кына йөрер идем...

Хәсәнә абыстай да шаярыбрак сөйләшүгә күчте:

— Әтиеңнән арттырып җибәрмәк буласың ич... димәк, безнең балаларыбыз ундүрт... уналты... унсигез...

Гыйрфан мулла башын тотты:

— Җитте, җитте, шашма, ул кадәр үк...

## III

— Бисмиллаһир-рахманир-рахим!.. Башладык, улым, әйдә, изге сәгатьтә, Ходай кулыңа көч-куәт, йөрәгеңә дәрт, күңелеңә илһам бирсен; әмма ләкин бик ашыкма, каудыр кыланма, пычкының аның үз көне бар, шул көйне тапмадыңмы — беттең дигән сүз.

Бисмилласын-Алласын әйтеп, Шакирҗан улын да шулай пычкы белән утын кисәргә өйрәткән иде ул. Әмма Шакирҗан бер тында, ых дип әйткәнче, юан каен бүрәнәне кып итеп кенә кисеп ташламакчы. Бөтен җан көче белән баса пычкыга. Ә үзе күз ачып йомган арада кара тиргә бата. Шулай булмасын өчен улы Галимҗанга пычкы тартуның бөтен серен, хикмәтен, җаен сөйләп бирде ул башта. Ләкин тарта башлагач, шул ук хәл кабатланды. Дөрес, монысы Шакирҗан кебек каушап-калтыранып калмады, үзенең төпсез чуманнан төшеп калган малай түгел икәнлеген күрсәтергә теләп булса кирәк, менә мин нинди эш әһеле дигәндәй, алагаем кизәнеп, кызу-кызу тартырга керешә.

— Әй, һәй, ашыкма болай, әйттем ләбаса инде, аңлатып бирдем, җаена гына тарт, дидем; әнә шулай, әнә шулай, ә-әх,

булмады, кыек киттек; басма, минем арттан гына ияр, ата юлы белән киткән бала салуламый ул…

Бераз тарткач, әти кеше пычкының барачак юлын кадак белән сызып куярга мәҗбүр булды.

— Менә шушы сызык буенча гына барсын пычкың, аң бул; тормышта да шулай ул: юлың-сызыгыңнан тайпылдыңмы — упкынга тәгәрәвең бар. Бу фани дөнья кылдый-былдый, кыек-мыек, кәкре-бөкре юлдан җилдерүчеләрне яратмый. Ярый, күп сүз китапка гына яхшы, әйдә, киттек…

Җәйге кояшлы көн иде бу. Ихатада әтәч, тавыклар мәш килеп йөри. Хәсәнә абыстайның да үз шөгыле бар: яшелчә бакчасына кереп, кыяр, суган түтәлләрен уаштырып, анысын алай, монысын болай итеп йөрде; җае туры килгән саен, утын кисүчеләргә дә күз ташлап алырга онытмый. Үзе һаман бер үк төрле уйлар давылы эчендә тибрәнә: и Ходаем, алты яшьтә генә бит әле, аның пычкы тартыр җире бармы; илаһым, куллары да күгәрчен тәпие зурлыгында гына бит әле; башка бай-муллалар симез ит, бәлеш төбе ашап, кикереп, хозурланудан башканы белмиләр; җиткән балалары урамда трай тибеп йөри әнә; ә бу һаман шул киндер күлмәген, киҗеле ыштанын кия дә теркелдәп эшләп тик йөри; җитмәсә, сабыйларга да тынгылык бирми, икенче бер мулла әнә әллә ничә хезмәтче тота, ә бу шул бердәнбер Әхмәдулласын да юньләп эшләтми…

Моны Гыйрфан мулла үзе дә яхшы белә. Әле менә остабикәсенең читләтеп кенә кырын караш ташлап киткәнен дә сизеп тора. Аңлый: улын кызгана. Ә бит үзе — остабикәсе — баланы карында чакта ук тәрбияләргә кирәклек турында әйтә. Ә инде туу белән бишек тәрбиясе башлана. Җыры-моңы-көе белән керә бала йөрәгенә. Нәгыймәне энә тотарга өч яшьтән күнектерде. Хәзер Нәфисә белән мәшгуль. Ә ата кеше ир балаларын ни-нәрсәгә өйрәтсен икән? Ир баланың кулы балта, пычкы, чүкеч тотарга биш-алты яшьтә үк күнегә башларга тиеш ләбаса. Соңладың — оттырдың дигән сүз. Абзар эчендә менә дигән остаханә дә төзеп куйды ул. Әнә Шакирҗан… иптәшләре белән шунда мәш килә. Барысы да бар: балта, аркылы пычкы, бәләкәй пычкы, өтерге, чүкеч… Бәгъзе бервакыт куллары кара канга тузып бетә. Бетсен. Канасын. Әтисе Нурмөхәммәт карт та аларны әнә шулай хезмәтне бәләкәй чакта ук татып белергә өйрәтте. Әллә-ләл, каты булды, әллә-ләл «миһербансыз» иде. Бәй, дөрес эшләгән ул: ир балаларының мүктән төргән бер хәчтерүш булуларын теләмәгән. Дөнья күзенә алтынчы баласы пәйда булды инде. Габделхәким дип исем куштылар. Әле ул бәллүдә изрәп йоклап ята. Анысын да өйрәтергә кирәк булачак киләчәктә пычкы, балта тотарга. Дөньяның ачысын-төчесен та-

тып үссеннәр. Ә бит ул ташбашлар, балык кеби үрчеп китеп, бервакыт бөтен ызбаны бассалар, ун... унике... уналты... тфү... тфү... бөртек булсалар, ничек бөтенесенә берьюлы тоттырырсың адәм баласын илаһи кеше итә торган эш коралын?..

— Менә шулай, әнә шулай, әһә, әһә, төшендең бит, әй, тиз төшендең, сөбханалла, укуга гына түгел, эшкә дә кулың ятыр кебек, Алла боерса: иншаллаһ, әзмәвер ир-егет булып үсәрсең. Ир-егетнең көче йөрәгендә дә, беләгендә дә ул, улым!..

Ата кеше, үзенә сиздермәскә тырышып, улына анда-санда күз ташлап ала. Хәтта көләсе килеп тә куя. Сизә: малайның беләкләре тала, күз аллары караңгылана; хәзер инде ул йончу хәленә җитте. Әмма сер бирми, җебегәнен сиздерми, текә маңгаена чыккан тир бөртекләрен дә сөртеп алмый, үзенчә бер гайрәт күрсәтмәк була инде.

Пычкы җай гына тартыла башлагач та әле, шатлыгын хәзер бөтенләй аз гына да яшерә алмыйча, һаман сөйләнде дә сөйләнде ата кеше:

— Әнә сизденме?.. Сиз!.. Тыңла!.. Пычкының җае-көе генә түгел, җыр-моңы да бар аның!.. Ә бит җырлап тора. Ни ди ул, ә? Болай ди:

Уйнап торыр пычкы, балта
Галимҗанның кулында
И-и-х!..
Утлар чәчрәп чыгып калыр
Аның йөргән юлында.

Бүрәнә ул кадәр юан түгел иде. Шәмдәй төз, тиз, җиңел киселә торган каен агачы иде бу. Җитмәсә, пычкыны алдан бик нык үткерләп-игәүләп куйган иде әти кеше. Хезмәтнең михнәткә әйләнмәскә тиешлеген яхшы белә ул. Артык күп эшләтергә дә кирәкми. Беренче көнне үк күңеле сүрелмәсен. Берничә буын кискәч, пычкысын тиешле урынга илтеп куеп, кулына балтасын алды Гыйрфан мулла:

— Хәзер карап кына тор, эшчән улым,— монысы әле сиңа ярамый,— мин ярып торам, син аны әнә теге койма буендагы урынга әйбәтләп, рәтләп тезелгән утыннар янына ташы, аннан соң икәүләп өярбез; кыш көне инде май кебек җылы өйдә безгә бик тә рәхәт булыр. Тормыш шулай бит ул: диңгез кеби, ә без — корабль — шунда оста йөзәргә тиешбез, ыххым, ыхы-хы, уһу-һу, ә йөзә белмәсәң — батасың. Бәс, шулай булгач, хәрәкәт кирәк, хәрәкәттә — бәрәкәт...

Галимҗан әтисенең сүзләрен шул зур колак яфракларын торгызып, ихлас тыңларга тырышты, ә үзе, башка вакыттагыча, аны әллә нинди сораулар белән мазасызламады. Чөнки урыны ул түгел. Хезмәт, диләр моны. Ә хезмәт һич тә бәрәңге

ашау кебек җиңел бер шөгыль түгел икән. Монда кулны да, башны да эшләтергә кирәк. Шулай да үзен борчыган, аңлап бетерә алмаган нәрсә турында сорамый калмады ул:

— Әткәй, Габдрахман абзыйлар әнә кышкылыкка дип, сыер тизәкләре җыеп киптерә, ә нигә алар да каен утыны әзерләми?

Бу сорау ата кешене нык уйланырга мәҗбүр итте. Кара син аны ни уйлый? Ә бит Шакирҗан белән дә кистеләр утынны, әмма ләкин мондый сорауны ул беркайчан да бирмәде. Нигә кирәк булган әле бу Таш маңгайга мондый четерекле, каршылыклы, серле якларны тикшерү?

«Дөнья шулай инде, улым, адәм балалары өчен ул һич тә тигез корылмаган» дип әйтергәме? Әгәр моны әйтсәң, шуның артыннан сиңа мең төрле яңа сорау яудыра башлаячак: «Нигә тигез корылмаган?»; «Нәмәстәкәй соң ул дөнья тигезлеге?»; «Нигә берәү ак калач ашый, ә икенченең кара икмәге дә юк?..» Мондый сорауларга аның башы җитә. Бер төпченә башласа, җиде буыныңа төшә, тәкатеңне корытып бетерә, миеңне утлы борау белән бораулый. Җавабың дөрес булмаса, кашын җыера, әрекмән колагын торгыза, текә маңгаен киереп, күзеңә чәчрәп керердәй булып карап тора. Сүз әйтми, билгеле. Ул, бәлки, белмәгәнеңне белеп, эчтән генә каһкаһә көлеп торадыр. Шуларны уйлап:

— Ярый, ярый, бик тирәнгә кермәле син, батарсың, нигә шулай икәнлеген соңрак аңларсың, үсә төшкәч... — дип, утын ярырга кереште ул.

Аның шактый юан бүкәне бик тигез итеп киселгән. Шуның өстенә ярачак утын кисәген куйгач, әле тиз генә эшкә керешми. Чөнки мәсьәлә монда һич тә утын яруда түгел. Аны Әхмәдулла да эшли ала. Мәсьәлә — бу ташбашны эшкә өйрәтү. Монда да башта аның фәһем бирә торган өлешеннән башлый.

— Карап тор, улым, иң әүвәл аякларны менә шушылай ике якка аерып куярга кирәк: алай-болай һич аңгармастан ялгыш балта тиярлек булмасын. Инде... моны эшләгәч... балтаң белән... һоп... Әмма ләкин... бер сугуда утын... шундук кап урталай ярылып... икесе ике якка очарлык булсын... Төшендеңме? Әткәй мине шулай төгәл булырга өйрәтте. Һоп... менә тәрәкә...

Ләкин ата кешенең әмәле гамәлгә ашмады бу юлы. Утын шундук ярылып, ярымтыкларның икесе ике якка очмады, Галимҗанга бу җитә калды. Бу юлы ул хәтта астыртын мыскыллау, киная беләнрәк көлде:

— Хи-хи-хи... утын ике якка ярылып очты... Ха-ха-ха... Каргалар, чәүкәләр кебек очты... Хи-хи-хи...

Малайның кинәт болай мыскыллап көлүе әтисенең күңелен рәнҗетте:

— Тукта, ашыкма әле син, Таш маңгай, һәр селтәнүдә бөтенесе дә ал да гөл булып тормый ул; барып чыкмаса, аны икенче төрле кыландырасың, менә болай... әһә, монда, каһәр төшкере, ботак бар икән ләбаса... Хәзер икенче балта белән без аңа... һоп... һоп... Шуннан ярыла да китә ул...

Утын яруның төрле ысулларын күрсәтеп, бу эшне түгәрәкләп куйгач:

— Хәзер инде, минем көләч улым, болай итәбез: син ат буласың, йөк ташучы ат, ә мин төяп торучы. Суз әле ике кулыңны алга, әмма хәзергә күп төямим, берничәне генә салам, авыр булып, билеңә сукмасын. Хезмәт ул күңел кайтарырлык булырга тиеш түгел. Артык майлы аш ише бер маемлатса, аңа карыйсы да килми башлый. Булды. Җитте. Атла, на-а-а... Әйдә...

Галимҗан урыныннан кузгалмагач, әти кеше тагын да сөйләнә башлады:

— Әһә, авырракмы? Бәс, шулай булгач, димәк ки, берсен алырга кирәк. Баштук әйтәләр аны.

— Юк, юк, әткәй, алма, тагын берне сал. И-и-и... җипҗиңел лә инде... Бер тавык авырлыгы да юк бит соң бу...

Гыйрфан мулла кычкырып көлеп җибәрде.

— Ха-ха-ха... Хи-хи-хи... Ә-ә-әх... Минем Таш маңгаем бәләкәйдән үк көч-куәт күрсәтмәкче була инде. Менә, алайса, тагын берне... һоп... җитте... Кузгал, малкай, на-а-а!..

Шулай шаярыша-шаярыша, көлешә-көлешә тәмамладылар эшне. Әти кешенең күңеле бик шат иде. Ә бит беренче мәртәбә төягәндә, Шакирҗан чыраен сыткан иде.

— Авыр түгелме, балам, әллә берәрсен алыйммы? — дип сорагач, ифрат дәрәҗәдә шатланып:

— Ал, әткәй, ал, бик авыр бит бу, алып барып җиткергәнче минем кулларым талыр, — дигән иде.

Әлеге: «Булырдайның буыныннан билгеле», — дигәнне янә бер мәртәбә күңеленнән кичерде әти кеше.

* * *

Еллар! Еллар! Адәм балаларын бер караганда сөеп-назлап, икенче тапкыр тукмап-йончыгып килгән мең-мең, миллион-миллион еллар! Синдә яшәүнең мәгънәсе ни? Фани дөньяның кабилияте нинди? Инсаниятнең мең-мең ата-аналары үзләренә, күз алмасыдай газиз-мөхтәрәм күргән баланарасыйларына бәхет-сәгадәт теләп ялвара Хак Тәгаләдән. Алар ярма бөртеге зурлыгы әйбернең үзәк-күзәнәгендә дә

самими-сәгадәтле яшәү өчен чиксез энҗе-гәүһәрләр булуын күңеле, бөтен әгъза-вөҗүде белән тоя. Бу гәүһәр-энҗене гомер буе эзли. Шуны табу өчен бәгъзе берәү гомеренең алсу таңында ук изге максат куя.

Җиде буынга өзелмәс, тутыкмас алтын чылбырдай сузылган нәсел-нәсәп тамырлары Гыйрфан муллага ачык мәгълүм. Һәр баласы — бер гәүһәр бөртеге. Бу гәүһәр бөртекләрен ничек утка да бирешми торган алтындай нык итеп үстерергә? Мондый әгъла максат, дәхи дә килер буын язмышы турында уйлану адәми затны Аллаһы Тәгалә каршында да, халкы алдында да зурлый һәм көчле итә. Әмма беренче атлап киткәндә үк җир күкрәгенә ут чыгарырдай басып, менә әле утын кискәндә дә үзенең мөмтаз икәнлеген күрсәтергә маташкан улының, гәрчә аның киләчәктә нәсел тамырыннан үсеп чыккан бер балкыш булачагына бөтен йөрәге белән ышанса да, унтугыз яшьлек чагында ук намуслы яшәү өчен шундый олуг, уйландыргыч, адәм балаларына иман шартыдай тәэсир итә торган: «Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә... Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә»,— кебек сүзләрне язып калдырачагы турында хәзергә аң түгел иде әле. Бу яшәештә пычкы моңының да бер хасияте бар.

Әмма яшәеш пычкы моңы гына түгел. Яшәеш — миллион-миллиард моң-матдәләр җыелмасы. Шушы бихисап моң-матдәләр эчендә адәм баласы мәңге аңлап бетерә алмаслык илаһи серлелек. Бу серлелекне һаман ача бару өчен һәр заманның үз пәйгамбәре кирәк. Егерме яшькә дә җитмәгән Галимҗанның илаһияте, изге, бөек яшәү турындагы уйлануы — пәйгамбәрләр кыйбласына бәрабәр. Ләкин инсаният бәхете өчен олы, максатлы көрәш юлында һәр пәйгамбәр зур авырлык кичергән. Киләчәк бәхет, матур яшәү өчен хәят мәйданына аяк баскан Галимҗанны да алда коточкыч салулаулар, чокырлы-чакырлы юллар, тирән упкыннар көтә. Авыр чир. Зиндан. Халык бәхете өчен көрәшүче «пәйгамбәр» йөзенә салынган «халык дошманы» дигән кара тамга. Бу нахакны, хурлыкны, ак күңеленә кара дегет булып тамган пычраклык авырлыгын күтәрә алмый Галимҗан. «Халык дошманы» икәнлеген тәсдыйклап имза куяр өчен аның кулына җәллад каләм тоттыргач, ул шул каләмнең очлы башы белән, яңадан бу шәхси кәгазьне һәм палачны күрмәс өчен, үз күзләрен үзе чокып алып үлә.

...Пычкы тартуда да зур мөмтазлык күргән ата улының бу киләчәк авыр язмышы турында аз гына да уйлый алмый, әлбәттә.

*Икенче бүлек*

# БӘЛА – АЯК АСТЫНДА...

Тормыш юлы түгел бит ул
шома көзге —
Көрәшәләр анда яман белән изге;
Йөргән җирең булмас
һәрчак чәчкә дә гөл,
Аяк асты тулы бәла — син шуны бел.

*Ата-ана кисәтүе*

## I

Чатнатып-дөбердәтеп күк күкрәде. Уйнаклап-чәчрәнләп яшен яшьнәде. Коеп-ишеп яңгыр яварга тотынды.

Иртән көн бер дә болай көйсез булыр кебек түгел иде. Таң кызыллыгы ахшамсафа гөле чәчәге балкышын хәтерләтте. Сандугачлар моңлы-аһәңле тавышлары белән һәр тарафны мактап, сөеп сайрадылар. Дөнья илаһилык, күңеллелек тәэсирендә җәйрәде. Ә кичә кичен Галимҗанның әнисе борынгы Мисыр һәм Кәнган илләрендә булган вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән мәхәббәт риваяте «Кыйссаи Йосыф» турында бик тәфсилләп, күңелләрне тетрәндереп, сихерләү дәрәҗәсенә җиткереп сөйләгән иде.

...Зөләйха төшендә бер матур сурәт күрә. Күркәмлек, матурлык, җисмәни көч иясе Йосыф Мисыр солтаны-газизе, имеш. Бер күрә сурәтне, ике, өч... Бу хакта Зөләйха әтисенә җиткерергә, мәхәббәт хис-тойгыларыннан йөрәге тәмам телгәләнү, йөзе сулу, акылы шашу дәрәҗәсенә җиту турында әйтергә мәҗбүр була. Зөләйханың әтисе Мисыр патшасына бу хакта бәйнә-бәйнә тәгъбир итеп хат яза. Мисыр патшасы Зөләйханың йөрәк ялкыны тулы мәхәббәтен кабул итә. Үз янына килергә куша. Зөләйханың әтисе зур бүләк белән озата кызын. Юл газабы — гүр газабы дигәндәй, мең бәла, газап, ифрат күп авырлыклар чигә-чигә, ком сәхрәләрен ера-ера килеп җитә кәрван-каравышлар Мисыр солтанына. Әмма ни гаҗәп, Зөләйханы төшендә күргән матур сурәт түгел, Мисырның картаеп беткән солтаны-патшасы Кыйтфир каршы ала.

Шулай да соңыннан әлеге гүзәл сурәт — Йосыф белән очраша Зөләйха. Йосыфны агалары коега сала. Аны юлчылар-кәрванчылар коткара. Йосыфны Мисырда кол сыйфатында саталар. Аңа үзе авырлыгы алтын сорыйлар. Зөләйха аны шул алтын бәрабәренә сатып ала. Йосыфның җитмеш

төрле һөнәре була. Чибәр, акыллы, әдәпле, шәфкатьле, мөрәүвәтле, алып йөрәкле, күп телләр белүче, кырык ирдән артык җисми көче булуы белән ул тирә-якка нур чәчеп яши.

Улын сагынып, әтисе пәйгамбәр Ягъкубның күзләре сукырая. Йосыф пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрелә. Бервакыт Мисыр мәлиге-патшасы була. Ул ил, халык мәнфәгате белән яши. Сабах җиле атага дөньяда яраткан улы Йосыфның барлыгы, кешелекле, кечелекле, матур, саф күңелле булуы турындагы изге хәбәрне алып килә. Ягъкуб саба җиленең күбрәк, ешрак, даими рәвештә исеп торуын тели:

Акрын искел, сабах йиле, нә үтәрсән,
Хакыйкать Йосыфымда ич дотар сән.
Җәрәхәтем уңалдырмага сән йитәрсәң,
Сән искәли шат-хөррәм улдым имди.

Сабах җиле Ягъкубның йөзенә яшәү шифасы булып сарыла. Шуннан ата кешенең күзләре ачыла.

Бервакыт Йосыф янына әлеге аны коега салган агалары да килә. Йосыф үч алмый. Зур йөрәклелек, кешелеклелек, инсаниятлелекнең иң асыл сыйфатлары мул булуны күрсәтә.

Күп сөйләде әнисе сабах җиле, пәйгамбәрләр, фәрештәләр турында.

— Фәрештәләр, улым, канатларына бәхет-сәгадәт төяп, тирә-якка нур чәчеп, гарше көрсидән адәм балаларына алып килгән илаһилыкны мул-мул ташлап китәләр. Шуларны сабах җиле кешеләргә өләшеп йөри,— диде ул.

Галимҗан, никадәр генә зирәк, үткер булмасын, әнисе сөйләгән хәдисләрнең эчтәлеген бөтен нечкәлекләре белән йөрәккүңеленә сыйдырып бетерә алмый. Әнисен һаман сораулар белән диңкетергә тотына:

— Фәрештәләр нигә күзгә күренми?

— Элек пәйгамбәрләр күп булган, нигә хәзер юк?

— Сабах җиле ул фәрештәләр алып килгән бәхетне нигә кешеләргә тигез өләшми?

Хәсәнә абыстай мондый мәгълүматларны һәр баласына биреп барырга тырыша. Мулласы бу җәһәттән шәп кеше. Тик Галимҗан, башка балаларыннан аермалы буларак, әтисен дә, әнисен дә һаман әле ерып чыга алмаслык сораулар давылы эченә алып кереп китә. Аның биргән сөальләре җебе сузыла да сузыла. Шуңа күрә әткәсе кебек, ана кешегә дә:

— Монысын соңрак, үскәчрәк белерсең,— дип чикләнергә туры килә.

Ә инде «Кыйссаи Йосыф»ны Галимҗан аеруча яратып тыңлый. Йосыф пәйгамбәрнең кешелеклелек, кечелеклелек сыйфатлары, аның зинданда утырганда да бәндәләргә карата

булган миһербанлылык тойгылары белән яшәве, Зөләйханың искиткеч маҗаралы мәхәббәте...— барысы да сабый күңеленә яшәүнең бер биниһая яктырткыч көче булып салынасеңешә бара.

Әнисенең сөйләгәндә матур елмаеп куюы, вакыт-вакыт тирән сулыш алуы, ягымлы-шәфкатьле, кешеләргә илаһи бер зур мәхәббәт белән яратып-сөеп карый торган нурлы күз карашлары бүләк итүе, йомшак куллары белән башыннан, йөзеннән сыйпап алуы, бит очларыннан назлы гына итеп үбеп шатландыруы...— һәммәсе дә әнә шул күк тәхетеннән алып килгән бәхетне өләшеп йөрүче канатлы фәрештәләр иркәләведәй тоела. Әйтерсең матур сәхрәләрдә искән сабах җиле күзләрне назлый, бөтен тәнгә сеңеп, йөрәккә шифа булып кереп сарыла.

Кичтән шундый хис-тойгылар назында йокыга талган иде Галимҗан. Әнисе барысын да,— Нәгыймә апасын да, Шакирҗан абыйсын да, Нәфисә сеңлесен дә, әле бәллү белән хушлашырга бик ашкынып тормаган Габделхәким энесен дә,— шулай назлап-иркәләп йоклата, иртән назлап-иркәләп уята. Хәзер инде ул Нәгыймә апасына, Шакирҗан абыйсына фәрештәләр, пәйгамбәрләр турында бик тәфсилләп сөйләми. Хәер, аларга әйтеләсе әйтелеп бетелгәндер. Хәзер инде тыңларга иң ихлас кеше булып ул — Галимҗан — калгандыр.

Аның әнисе вакыт-вакыт күрше балаларын да җыеп сөйли бит. Кадер кичәсе көнендә әнә әллә унлап күрше-күлән түтиләр, җиңгиләр балаларын ияртеп килгәннәр. Кич буе китап укыды, риваятьләр сөйләде, пәйгамбәрләр тормышы турында бик кызыклы хәлләрне хикәя кылды. Барысы да йотылып тыңлый. Алар чыгып киткәч, һаман сөйләде дә сөйләде әнисе. Әмма аны Нәгыймә апасы, Шакирҗан абыйсы мөкиббанә тыңламады. Күпне белергә тырышкан Галимҗан монда да соравын бирми калмады:

— Ә нигә Нәгыймә түткәй белән Шакирҗан абый син сөйләгәнгә әллә ни колак салмадылар?

— Мин бу хакта аларга әллә ничә кат бәян кылган идем инде, улым, бер белгәнне һаман кабатлап тору һич кенә дә күңелле түгел ул, шуңа күрә ана кешегә һаман-һаман яңаларын табып торырга кирәк. Синең өчен бигрәк тә. Әле берәүнең дә әтиеңне дә, мине дә гелән генә сораулар белән бу кадәр аптыраткан бала юк иде. Синең күпне, бик күпне беләсең килә бит. Аннан соң син тыңларга да яратасың. Колакларың белән генә түгел, йөрәгеңне куеп тыңлыйсың. Соңгы вакытта әтиең дә, мин дә күп укый башладык. Сиңа һәрдаим үзебезнең белгәнне күбрәк бирергә тырышабыз.

Бу вакытта, билгеле, Галимҗан киләчәктә — хәятының сикәлтәле юлларында — Йосыф пәйгамбәр кебек кат-кат зинданда утырачагы, анда әнә шул зур йөрәкле илаһи затларга охшап, үзен ничек тотачагы, кешелекклелек сыйфатларын ни дәрәҗәдә саклап калачагы хакында аз гына да хәбәрдар түгел иде. Ошбу матур җәйге кичтә дә ул, ана назын бөтен йөрәге белән татыган хәлдә, аның җыр-моңын ефәк юрган итеп ябынып, тирән йокыга талды. Иртән ана иркәләве дә, тәрәзә аша кергән кояш нурлары назы да уятты аны. Озаграк йокларга хәзергә Нәфисә белән Габделхәкимгә генә рөхсәт ителә. Башкалар аякка кояш нуры белән бергә басарга тиеш. Телгә шактый оста ата кеше «борынгылар шулай дигән», «ата-бабалар болай әйткән», «әткәй әйтмешли» дип, эшчәннәр, ялкаулар турында әллә күпме мәкаль-әйтемнәрне тәкрарлап кына тора: «Икмәге юк — ач, ялкау кеше — ялангач», «Иренгәннең йөрәгенә мүк үсәр», «Иренчәк белән ялкау өметтән буш калыр»...

Иртән — һәркемнең үз шөгыле. Ата-ананың иң тәүге мөкаддәс эше — намаз укып алу. Аннан Хәсәнә абыстай сыер сава. Моңа Нәгыймә дә ярдәм итә. Гыйрфан мулла абзар-кураны, малларны карый. Шакирҗан да шунда кайнаша. Малларны көтүгә кугач, әти һәм әни кеше кыр эшенә китә. Арбага ат җигеп. Бәгъзе бер көнне әти кеше арбага барысын да төяп алып китә. Нәгыймә, Шакирҗан хәзер инде яхшы эш кулы. Быел Галимҗан да тырма тырмарга, сабан тоткасы тотарга өйрәнде. Ә инде иртән көн менә-менә еларга торган чытык бала йөзен хәтерләтсә, балалар өйдә кала. Ул вакытта өй эчендәге эш арканы хуш күңелле Нәгыймә кулына күчә. Ул нәкъ әнисе сымак булырга тырыша. Иренми, йөзеп, ихлас күңелдән эшләп йөри. Башкаларга да боегып утырырга ирек бирми.

Бүген, гәрчә иртәнчәк көн шат күңелле кешенең елмаюын хәтерләтеп торса да, Гыйрфан мулла кырга берүзе генә китте. Чөнки әле язгы чәчү бетеп, иркенләп тын алган мәл. Озакламый печәнгә төшәчәкләр. Максаты да әллә ни зурдан түгел иде югыйсә — басудагы шытымнарны, болындагы печәнлекләрне карап кайту. Бармаса да мөмкин иде. Ләкин түземсез күңеле аны кырларга, болыннарга тартты. Аның бит әле шушы мәлдәге табигать серләрен күзәтәсе, аларны махсус дәфтәренә язып куясы да бар. Ләкин өйлә якынлашып килгәндә, чатнатып-дөбердәтеп күк күкрәде, уйнаклап-чәчрәнләп яшен яшьнәде, коеп-ишеп яңгыр яварга тотынды. Ни кызганыч, Нәгыймә белән Шакирҗан җиләккә киткәннәр иде. Үзләре белән Галимҗанны да ияртteләр. Киләчәк фаҗигане ана күңеле сизми буламы соң? Сизде ана. Нин-

дидер күңелсез хәл булыр кебек тоелды. Шуңа күрә Галимҗанны җибәрмәскә тырышты. Әмма балалар һич тә ирек куймады шул.

— Әнкәй, бер күңел ачып кайтыр, алып китик аны да,— дип инәлде Нәгыймә.

— Аның тездән төшәр вакыты күптән үтте бит инде, әнкәй, ә син аны һаман нык иркәлисең, дөнья күзеннән яшереп тотмак буласың,— дип үпкәләде Шакирҗан.

Балаларның сүзендә ихласлык та, дөреслек тә, чынлык та бар иде. Атасы да аңа башка балаларына караганда игътибарны күбрәк бирә. Әлеге дә баягы шул «дәвер пәйгамбәре» ясарга тырышу хикмәтедер инде. Ул үзе дә Галимҗанны артык карый, күләгәдә тотарга тырыша, хәтта уенга чыгарырга да бәгъзе бермәл риза булмый. Ана йөрәге Галимҗанның сәламәтлеге йомшак булуын сизә. Төнлә өстенә япканны тибеп очыручан. Тәмле-татлы йокысын бүлеп, ана кешегә аны да барып карап килергә кирәк. Тирләүчән дә ул. Бу да йомшаклык билгесе. Ашауга да бик исе китеп бармый. Саташып, әллә ниләр мыгырданып ята торган гадәте дә бар. Буранлы мәлдә туган балалар шундый була, имеш. «И Ходаем, чирләшкә булмаса ярар иде!» дип әрнегән чаклары күп була Хәсәнә абыстайның. Бала күңеле бик сизгер була. Аларны алдау — гаҗәп кыен хәл. Галимҗанны артык иркәләгәнне Нәгыймә дә, Шакирҗан да сизә. Моны алар җае чыккан саен әйтә киләләр иде. Ә инде бүген җиләккә җибәрергә куркып торгач, алар үзләренең ризасызлыкларын ачыктан-ачык әйттеләр. Шуңа күрә җибәрми чарасы булмады. Кайтып кергәндә алар күшеккән тавыктан һич тә ким түгелләр иде.

Нәгыймә белән Шакирҗан чыныкканнар инде. Аларга берни дә булмас. Галимҗан өчен нык кайгырды Хәсәнә абыстай. Ул нык өшегән: калтырана. Теше тешкә тими. Лычма су киемен салдырып корыны кидерсә дә, ул һаман әле бизгәк тоткан кеше сымак калтырануыннан туктамады.

— Яңгыр яуганда нигә берәр җирдә ышыкланып тормадыгыз? Яшеренер урын бетмәгәндер ләбаса? — дип әрнеде ана.

— Яшеренгән идек, ул агачны яшен сукты,— дип җавап бирде Нәгыймә.

Аның сүзләрен Шакирҗан дәвам итте:

— Ярый әле аннан китеп өлгергәнбез... Бераз ераклашкач... агачны яшен уты китереп бәрде... Без һуштан язып егылдык... Җыйган җиләгебез дә шунда түгелгән... һушка килгәч... йөгерәбез дә йөгерәбез... яңгыр коя да коя...

Ана үзен-үзе кая куярга да белмәде:

— И балакайларым... И гөлкәйләрем... Үлемнән көчкә

котылып калгансыз бит... И Галимҗаным!.. Ник җибәрдем икән... Аның сәламәтлеге болай да яхшы түгел иде бит... — дип өзгәләнде.

* * *

Галимҗан төне буе авырып чыкты. Тәне ут кебек кыза. Иреннәренә кадәр дерелдәп тора. Өзлексез су сорый. Тамагына кичтән дә, иртән дә берни дә капмады. Шулай да ул үзенең көчле ут эчендә ятканлыгын, үлем белән яшәү дулкыны арасында тибрәнгәнен сиздермәскә тырыша. Әнисе килеп:

— Хәлең ничек, балам, кай җирең авырта? — дип сораса:

— Хәлем әйбәт, әнкәй, бер җирем дә авыртмый, — дип җавап бирә.

Әтисе сораса да шул ук сүзләрне әйтә.

Нәгыймә белән Шакирҗанга да кыен иде. Әниләренең каршы килүенә карамастан, алар көчләп алып киттеләр бит җиләккә. Алар хәзер әниләренең күзенә туры карарга да куркып йөриләр. Гәрчә сүз әйтмәячәген белсәләр дә, әниләренең әрнүле йөзен күреп тору бик кыен иде алар өчен. Әтиләре, җае туры килгән саен, гел әниләрен битәрләп торды:

— Җибәрмәскә кирәк иде, кырлар, болыннар белән хозурландырырга аларны әллә үзем алып бара алмыйммы... — кебек сүзләрне әйтеп кенә торды.

Балаларына тел тидермәскә тырышты ана:

— Мин гаепле монда... Көн бик матур булгач, бар, улым Галимҗан, күңел ачып кайт, дип әйткән идем шул, — дип сыкранды.

Ананың бөтен кайгыны үз җилкәсенә алырга тырышуы балаларны тагын да авыр хәлдә калдырды. Нәгыймә, әтисенең нинди дер авыр сүз әйтүеннән куркып:

— Әткәй!.. Әткәй!.. Монда әнкәйнең бер гаебе дә юк... Ул Галимҗанны җибәрмәскә тырышкан иде... Без көчләп алып киттек... — дигән сүзләрне әйтергә мәҗбүр булды.

Апасының сүзләрен Шакирҗан да раслап куйды:

— Әйе, әйе, әткәй, Нәгыймә апа дөрес әйтә: бөтен гаеп бездә...

Ата кешегә аларның яклашуы ошамады.

— Йә, җитте, барыгыз да судан пакь, сөттән ак булырга тырыша, күз буяп яшәмәкче буласызмы, юл куймам моңа, чыбык сынганга масаясызмы, әллә аны табу бик авырмы, — дип, бу хакта башкача тел тибрәтмәслек итеп, үзенең каты ата икәнлеген янә бер мәртәбә күрсәтү өчен идәнгә алагаем уң аягы белән тибеп алды.

Өч көн ятты ут эчендә Галимҗан. Уфа шифаханәсенә алып китәм дип, әллә ун мәртәбә ат җиккәндер Гыйрфан мулла. Моңа остабикәсе гел каршы төште дә торды:

— Мулла, харап итәбез баланы... Ерак юлга чыдый алмаячак Галимҗан... Анда кем кулына туры килә бит әле ул... Кемгә газиз синең балаң...— дип сөйләнде.

Гыйрфан мулла, авыр мәсьәлә хәл иткәндә мөгезне күпме генә үзе куярга тырышмасын, остабикәсенең акыллы сүзенә колак салмый калмый. Уфада яшәгән таныш Сәфәргали мулла биш яшьлек баласын әнә шул гамьсез табиблар кулына тапшырып харап итүе хакында сөйләгән иде бит. Үпкәсенә салкын тигәч, илткәннәр дә салганнар шифаханәгә. Шифаханә түгел, «агуханә» булган ул. Җил өреп торган тәрәзә янындагы урынга салганнар баланы. Юньләп карамаганнар. Тиешле даруы да бирелмәгән. Нәтиҗәсе мәгълүм инде: сабый шул җил өреп торган тәрәзә янында күзләрен мәңгелеккә йома. Бердәнбер бала иде бит әле ул. Сәфәргали мулла бу хакта соры күзләреннән яшь коя-коя, коңгырт-сары чәчләрен уа-уа тәләһһефләнеп, аһ орып сөйләде. Шуларны искә алып, остабикәсенең фикерен дә тыңлап, авыру улын озын юлга алып чыкмаска булды ул.

Якындагы биш-алты авылга, һич югында, бер табиб булса, ни әйтер иден дә бит, юк, юк, юк... Әлбәттә, им-том белән шөгыльләнүче әби-сәбиләр дөнья тулы. Бермәл, аңа ун яшьләр булганда, эче белән бөгәрләнде дә катты ул. Шуннан әтисе Нурмөхәммәт әлеге шул им-томны белүче Гайникамал карчыкны алып килде. Әллә нәрсә кайнатты да эчерде бит бу. И ачы, и тәмсез, и костырта... Әйтерсең зәкъкум[1] агачының яфрагын кайнатып эчерде.

— Тәгаен бетердең баланы, үтердең, харап иттең,— дип, Гайникамал карчыкны куып чыгарган иде ул вакытта әтисе (ә бит әтисе өчен ул киләчәктә нәсел орлыгын үрчетергә тиешле кадерле бала иде). Шуннан соң теләсә кемнең шифасыз кулына, алдак тулы нурсыз күзенә, ихлас булмаган күңеленә ышанмый башлады ул. Андыйларга иман зәкяты бүләк итүне үзе өчен зур гөнаһ санады. Бу һич тә кешегә ышанмау бәласе түгел. Күп яхшы, изге күңелле, шәфкатьле бәндәләр. Әнә шуларның саф йөзенә тап төшерүче, авызыннан тере саескан очыручы алдакчылар да аз түгел. Алдашуның урлашуга беренче адым икәнлеген дә яхшы аңлый хәзер Гыйрфан карт. «Ертык киемне җил табар, ялган сүзне чын табар» дигәне дә бар. Чын сүз белән капларга кирәк ялган йөзен. Теге вакытта Гайникамалның ялган йөзе әтисе Нурмөхәммәтнең чын сүзе белән капланды.

— Акны карадан аера белмәгән надан башың белән адәм баласын алдап йөрмә моннан ары,— дип тә әйткән иде.

---

[1] Зәкъкум — агулы җәһәннәм агачы; үтерә торган дәрәҗәдәге ачылык, зәһәрлек.

Боларга карап кына им-томга ышануын бөтенләй үк югалтып та бетермәде Гыйрфан мулла. Табигать серләрен, шифалы һәм агулы үләннәрнең эчке хосусиятләрен үзе үк ныклап өйрәнә башлады. Ютәлләү, томау төшү, салкын тию вакытында нинди үләннәр кайнатып эчү кирәклекне ул үзе дә белә. Аларны остабикәсе белән бергә киңәшләшеп өйрәнәләр. Әмма ләкин үпкәңә салкын тисә, ныклап белми торып, сыналмаган теләсә нинди үлән суын эчеп кенә сихәтләнеп булмый. Авыл баласының күбесе әнә шул чир белән харап була. Ныклысы чыныга-чыныга үсеп китә ала. Йомшагы фани дөнья белән ахирәт чигендә имгәнеп харап була. Ахирәт җиле суыра андыйларны. Баш балалары Фәрдәнә мәрхүмә дә шул җил шаукымына эләкте шикелле. Ярый, анысы инде үткән бәла. Остабикәсенең йомшаклыгы булды бугай. Хәзер инде аның өчен терсәкне тешләп булмый. Менә бу Таш маңгайны коткарырга кирәк. Әллә тышкы күренеше генә ташмы? Эче йомшак көпшәме?

Авыруның дүртенче көнендә Галимҗан нык хәлсезләнде. Авыр тын ала. Һаман шулай ут эчендә изрәп ята. Авызына судан башка берни капмый. Ә инде бишенче көнендә телдән язды, сөйләшмәс булды. Күзләре мәзәкләнеп, иреннәре көеп калды. Җитмәсә, Хәсәнә абыстай үткән төндә күңелсез төш тә күргән иде: кулындагы балдагы кое төбенә төшеп югалды. Моны ул беркемгә дә әйтмәде. Иртәнге җилгә генә сөйләде. Җил аны каядыр алып китеп адаштырырга тиеш иде.

Эш шуңа барып җитте: Галимҗанга ясин чыгарга булдылар. Бу инде гөнаһсыз сабыйны җәннәт кошы итү дигән сүз иде. Башта аны әйтергә Гыйрфан мулла үзе дә, Хәсәнә абыстай да куркып торды.

— Хәзер инде икеләнеп тору вакыты үтте, остабикә, кая, булмаса, тәһарәт алыйм да ясин укыйм, яки син үзеңме?.. — диде ул.

— Юк, юк, мулла, мин булдыра алмам, күңелемнең йомшак икәнлеген беләсең, елап җибәрермен, әйдә, үзең генә укы инде...

Ясинны артык кычкырмый, моңлы итеп, йөрәкләрне әрнетер дәрәҗәдә хис-тойгы белән укыды ата кеше. Хәсәнә абыстай еламас өчен тешләрен кысты, уртын чәйнәде, ике йодрыгы белән күзләрен каплап торды. Шулай да эчке хистойгыларын ничек кенә җиңәргә тырышмасын, булдыра алмады, елап җибәргәнен сизми дә калды. Нәгыймә дә, Шакирҗан да аңа кушылып яшь түкте. Мәсьәләнең төбен-тамырын аңлап бетермәгән Нәфисәнең дә күзләре яшьләнде. Хәтта тәпи басарга чамалап, бер егылып, бер торып йөргән Габдел-

хәким дә, кеше кыланганны кыланырга кирәк дигәндәй, ару гына басып барган җиреннән егылып китеп, кычкырып еларга тотынды.

* * *

Дус-иш, кардәш-ыру, туган-тумача, күрше-күлән килеп кенә тора. Ләкин аларның да төрлесе бар. «Тегеләй ит», «болай ит», «фәлән ит», «төгән ит» дип, башны тәмам каңгыратып бетерәләр. Әрекмәнгә төрү, күкрәгенә үги ана яфрагы каплау, яңа суйган яшь бәрән тиресенә урап яткыру, төрле шифалы үләннәрне кайнатып, шуларның суын эчерү...— төрлечә кыландырып карадылар. Берсенең дә файдасы тимәде. Шулай да ясин укыганнан соң, Галимҗан йомык күзләрен ачты, иркенләбрәк бер тирән сулыш алып, яшәргә бөтенләй үк өмет бетмәгәнлекне белдерде.

Нәкъ шул вакытта кендек әбисе Хәмдия абыстай килеп керде. Ул инде монда әллә ничә мәртәбә булган иде.

— Иң җараткан улымны... мына шылай бәлтерәп... тереалтмичә каламмы сың,— дип сөйләнә дә үзенчә төрле дәва кулланып чыгып китә.

Соңгы килгәндә ул:

— Әйе, әйе, күп баш ватасы түгел, тәгаен үпкәсенә салкын гына тигән мының, даруын беләм дә сың, безнең авылда җук бит ул, чуашларда былмый калмас, шыларга киттем,— дип сөйләнде.

Әле менә яшь кызларга хас җитез хәрәкәт белән килеп керде дә төенчеген чишәргә тотынды. Иң оста табиб сыман кыланды ул. Үзе һаман сөйләнде дә сөйләнде:

— Мына шылай инде ул тырмыш... Бәла аяк астында... Абынасың да җыгыласың... Ә безгә җыгылганны тыргызырга кирәк... Тик сез, газизкәйләрем, барыгыз да чыгып тырыгыз... Мына күрерсез, Аллаһы боерса, иртәгә үк аякка басыр... И-и-и... шылай яшь түгеп... кеше терелтеп былами... Былмай... былмай...

Галимҗан ике тәүлектән соң аякка басу дәрәҗәсенә җитте. Дөрес, ул бик хәлсез иде әле. Шулай да хәзер сөйләшә, азлап-азлап ашый, хәтта берникадәр елмая башлады. Елмаерга аны кендек әбисе мәҗбүр итә. Әллә ниләр сөйләп ташлый:

— Мына, Алла боерса, син терелгәч, бер хикмәт сүйләрмен әле... кош булып ычып, җәннәт-оҗмахларны карап кайткан синең кебек бер үткер-изге малай турында... Ходай кушса, сине дә җибәрермен. Канат куермын да... күкнең җиде кат дөнҗасын күреп кайтырсың. Мына шының өчен тизрәк терелергә кирәк сиңә... Син бөркеткә...

Икенче ана назын ала Галимҗан кендек әбисе Хәмдия абыстайдан. Әнисенең ап-ак чыраенда күпме миһербанлылык-шәфкатьлелек бар. Аның әнисе чибәр булганга нык яратыладыр, бәлки. Ә менә бу кара йөзле ямьсез кендек әбисендә ни эшләп шулкадәр яраттыру көче бар икән? Аны Ак түти дип тә йөртәләр бит әле. Кара шадра икәнлеген әллә күрмиләрме? Тирән шадра дип тә әйтәләр. Әмма әнә шул һәр шадра-чокыр эчендә шәфкать нуры балкый төсле. Күңел аклыгы аларның барысын да каплап торадыр. Шулай фикер йөретте Галимҗан. Ә нигә, бу хакта уйланырлык чамасы юкмы аның хәзер? Кешеләрне аера белү сәләте юкмы? Бар ул. Бар.

Ярый, дүрт-биш тәүлек кайгыдан даимән энә очына басып тору, шомлык кылу, котырынып-шаулап искән җил шикелле, шөкер, инде үтеп китте. Малай аякка басты. Бу эштә Ак түтинең өлеше бәяләп бетергесез. Дөньядагы иң оста табиблардай җиң сызганып ул тотынмаса,— тфү, тфү, хәзер инде әйтү дә, уйлау да куркыныч, — баш балалары Фәрдәнә язмышына охшап, моның да кыл өстендә торган гомере өзелү мөмкин иде бит.

— Ничек терелттең, нинди дәва-шифалар кулландың, Ак түти, Хәмдия абыстай, нигә яшерәсең, нигә әйтмисең?..— дип сорашты Гыйрфан мулла.

— Һм... Сезгә барын да сайрап салырга кирәктер шыл... Көллегез хәйран былдыгыз да калдыгыз...— диде дә шул каратуткыл йөзендә, шадра чокырларында нур балкытып, кеткелдәп көлеп җибәрде.— Минем эчемдәге тышымда икәнлекне, күлмәгем белән генә ике кат былыуымны беләсез ич инде... Мыны да әйтмичә калмам, тик көлмәгез, ачуланмагыз...

— Сиңа бер күлмәк, Ак әби. Сөйлә, тартынма...

Бәй, кара син аны, менә Ходайның рәхмәте, әллә ни катлаулы сере дә юк икән ләбаса. Ярдәмгә чуаш дуслар кул сузган. Көмешкә фәкать аларда гына бар. Солтанморатта аны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый. Моны белә Хәмдия абыстай. Китә җәяүләп әлеге Гыйрфан мулла ызнакумы Әптерәйләргә. Мәсьәләнең җитдилеген, баланың яшәү белән үлем кылы өстендә басып торуын, дәвалау өчен көмешкә кирәк булуын ашыга-ашыга сөйләп бирә. Көмешкә белән алагаем, бөтен тән күзәнәкләренә генә түгел, һәммә эчке тән әгъзаларына үткәрерлек дәрәҗәдә сыларга кирәк. Шуннан ап-ак сөлге-тастымал белән кысып-кысып урау зарур. Моны кат-кат эшләү таләп ителә. Бер үк вакытта дуңгыз мае белән дә, һич җирәнми-нитми, лачкылдатып-лачкылдатып сылау кирәк. Чуаш халкы им-томның төрлесен белә. Алар да зәһәр чос халык.

— Ә ниңә Гыйрфан мулла пезгә үзе килмәде, күпме ярсуп турган чабыш атлары пар пит, ниңә сине епәрте? — дип кызыксынды Әптерәй.

Хәмдия абыстайга серне ачарга туры килде:

— Һәй, әллә алар дуңгыз маена, көмешкәгә риза булырлар идеме?..

Моны әйткәч, Әптерәй кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Хи-хи-хи... Ха-ха-ха... Бик яхшы куртка пит син... Хәмдия апыстай... Пеләм пит мин сине...

Шуларны сөйләп биргәч, Гыйрфан мулла да, Хәсәнә абыстай да рәхәтләнеп бер көлеп алдылар.

— Мин ул Әптерәй ызнакумны бер куй суеп сыйлыйм быел, Алла боерса, — дип, сүзен тәмамлады Гыйрфан мулла.

* * *

Әйе, сабан туе көннәрендә пар куй да суелды, туган-тумача, кардәш-ыру, күрше-күлән дә, шулар белән бергә ызнакум дус Әптерәй дә сыйланды, Хәмдия абыстай да яңа күлмәк киде. Галимҗан ныклап аякка басты. Тик ул вакытлыча гына булды шикелле. Галимҗан чирләшкәгә әверелде. Авылда һәр малайның кушаматы бар: Тыңкыш, Чәүкә, Кара борын, Чыпчык, Песнәк, Ярканат, Кысык күз. Ә Галимҗанныкы юк иде әле. Дөрес, Таш маңгай дип әйткәләделәр. Бу әлеге дә баягы шул атасы авызыннан урам авызына күчте шикелле. Ничек кенә булмасын, бу һич тә дәрәҗә төшерә торган кушамат түгел. Аны ишетү Галимҗан өчен горурлык кына иде. Чөнки әтисенең «Ахмак кешенең башы кеч-кенә», «Акыллының маңгае киң булыр», «Батыр башы ташка бәрелгәнгә еламас» кебек мәкаль-әйтемнәрне җае чыккан саен ни өчен кабатлаганын Галимҗан белә иде инде. Ә менә чирдән сәламәтләнеп, йомшап калгач, урамда уйнаганда ачуланышып китсәләр, малайлар аны Чирле чәүкә дип үрти башлады.

Бу атамадан да ул кадәр шүрләп калмады Галимҗан. Ни дисәң дә, ул әле кешелек сыйфатын төшерә торган «чәүкә» дә, «чыпчык» та, «куян» да түгел. Дөньяда Хәмдия абыстай дәрәҗәле оста «табиб»лар булса, аңа беркайчан да түшәккә сеңәргә ирек куелмас. Чир табигать тарафыннан бирелгән икән, шул ук табигать аны бервакыт барыбер үзе алмый калмас.

Шулай да бөтенесе дә үзе һәм әтисе, әнисе уйлаганча ук килеп чыкмады. Үпкәгә тигән салкын, вакыт-вакыт үпкә чиренә әверелеп, һаман үзенең барлыгын сиздереп торды.

Дәрья төбе
энҗе-мәрҗән белән тулы,
Аны чүпли оста ир-егетләр кулы;
Чүплә, улым,
тормыш диңгезеннән энҗе,
Син шатландыр
аклың-холкың белән безне.

*Ата-ана таләбе*

* * *

Бүгенге кич Гыйрфан мулла гаиләсе өчен илаһи бер хозурлык, матур тойгылар белән башланды. Иң әүвәл Галимҗан имәнеч нык шатландырды. Ул, алтын тапкан кешедәй куанып, әнисе янына йөгереп килде дә ахшамсафа гөленең чәчәк атуын хәбәр итте. Хәсәнә абыстай әллә күпме гөлләр үстерә: тамчыгөл, рәйхангөл, лаләгөл, сөмбелгөл... Нәфисә тугач, аңа исем кушарга бер көн калганда, Көнсылу янә бер яңа төр гөл шытымы китереп бирде. Һәй, уйнаклап-уйнаклап, шул чегән кызларыныкына хас өзелеп төшәргә торган нечкә билен мең төрле боргалап, шомырттай ялтырап торган кап-кара күз алмаларын әйләндереп-тулгандырып, үзе белән дала-болыннар матурлыгын алып килүен хәтерләтеп, керер-керешкә тәтелдәргә тотынды:

— И Хәсәнә абыстай! Һин биш бала таптың, ә мин алтыны. Был дөньяны ауыр тиҙәр. Һәй, һәй, уны кем күтәреп караган инде. Ибетә. Ул турала уйларга вакыт бармы һуң. Ходай фатихаһы менән йыл һайын шалкандай бер малайҙы карт ирем Котлоҙаманға бүләк итәм дә торам. Хи-хи. Ә ул, мәхәббәтһеҙ, кыҫык күҙҙәрен киреп, йоҙроктай кабарып торған бит остарын бейетеп, кәзә һакалын алағайым һелкетеп, йылмайып карап тора-тора ла аркамдан бер һөйөп куя. «Аллаға шөкер, бисәм уңдырышлы булды» тип мактай. Һәй, һәй, башкорт баланан туямы һуң. Ибетә. Әсе теллелеге, тоғролого өсән кайһы берәүҙәр яратмай үҙен. Теле каты булһа ла, күңеле йомшак икәнлекте аңламайҙар. Кешелекле бит ул. Әле бына нимә ти: ни, ти, иртәгә, ти, Ғирфан муллалар кыҙҙарына исем куштыралар икән, ти, нимә бүләк итербеҙ икән, ти, шуның өҫен баш ватып йөрәйөм, тигән була. Кыҙҙарына Нәфисә тип исем кушалар икән, тинем, бер күреп сыктым, тинем, гөл кеүек нәфис, матур кыз, тинем, ахшамсафа гөле бүләк итәм, тинем. Бына әле шуның шытымын килтерҙем. Бәбәй туйығыҙ котло булһын!

— И Көнсылукаем! Син үзең дә гөл кебек балкып килеп керәсең бит. Рәхмәтләр генә яусын инде бу гөл өчен! Аны

үзем дә эзли идем әле. Шул тиклем игътибарлы булырсың икән. Әле иртәгә бәби туена чакырырга дип, Нәгыймәне сезгә җибәрергә тора идем.

— Юк инде, абыстай, юк, без килә алмабыҙ. Һеҙҙең ише остаҙ кешеләр табынында ултыруы һиҫ килешмәй.

— Алай димә әле син, Көнсылу, Гыйрфанның да, минем дә кеше аермаганны беләсез бит инде. Дуслык җебен ярлылык төйнәтә, байлык өзә, дигәнне ишеткәнең бардыр бит. Әгәр килмәсәгез, үпкәбез зур булачак. Ул вакытта без дә сезгә аяк басмабыз.

Көнсылу, мөлаем карашларыннан шатлык нурлары чәчеп, елмаеп-көлеп, Хәсәнә абыстайны килеп кочаклады:

— И Хәсәнә абыстай, башкорт әйтмешләй, гәүһәр төндә лә күренә: һин караңғылыкты яктыртыусы йондыҙ бит.

Алар һәрвакыттагыча сөйләшә-сөйләшә, гөрләшә-гөрләшә, тирли-тирли чәй эчтеләр. Хәсәнә абыстай аны бик җылы сүзләр белән озатты:

— Рәхмәт, Көнсылукаем, бик зур бүләк китергәнсең — күңел бүләге! Мәңге онытылмаслык бүләк! Мондый бүләкне синең кебек матур күңелле кеше генә бирә ала.

...Ахшамсафа гөленең тышкы һәм эчке матурлыгы бар. Тышкы күрке башка гөлләрнекеннән әллә ни аерылып тормый. Тамырлана. Үсә. Яфрак яра. Ә инде эчке сере-сыйфаты янып торган алсу-кызгылт чәчәге балкышында төсмерләнә. Ул ахшам вакытында — кояш баеган мәлдә — чәчәк ата. Шуңа күрә «ахшам» исеме бирелгән. Чәчәге нәкъ офыктагы ахшам кызыллыгы төсле балкый. Анда җете кызыллык та, шәмәхә төс тә, алсулык чаткылары да бар. «Сафа» да — гарәп сүзе. Рәхәтлек, кәеф, хозурлык, кайгысызлык дигән мәгънәләргә ия. «Ахшам» гөле кояш баешы мизгелендә аткан чәчәген таңда коя. Димәк, ахшам вакытында гына ул кәеф-сафа сөреп, рәхәтлек, хозурлык, кайгысызлык мәле кичерә. Шуңа күрә халык «ахшам» атамасы янына «сафа» сүзен дә китереп кушуны мәгъкуль күргән. Шулай итеп, ул «ахшамсафа гөле» була.

Бу вакыйгага — ахшамсафа гөлен утыртуга — дүрт ел үтеп китте инде. Нәфисә дә дүрт яшьне түгәрәкләде. Ахшамсафа гөле дә, тармакланып-тармакланып, колач җәеп, бөтен тирә-якка сыймастай булып үсте. Әмма дүрт ел эчендә әле бер мәртәбә дә чәчәк атмады. Бәлки, атадыр да. Ул бит бер мизгелдә — әнә шул аяз көнне офык балкышы мәлендә — чәчәк ата икән. Ә таңында инде коела. Кем аны саклап тора ала? Ел да атмыйдыр да әле ул! Табигатьнең серле бер гөле икән — аннан теләсә нинди мәгънәвият, эчке яшеренлек көтәргә мөмкин. Бу хакта балаларына да, аларның әткәсенә дә кат-кат сөйләгән иде инде Хәсәнә абыстай. Әле аның

эчке серендә янә дә бер илаһият бар икән: кем дә кем чәчәк аткан чакны тәүдә күрә, шул бәхетле була.

Ана кеше, билгеле, һәр баласының бәхетле булуын тели: бармакның кайсын тешләсәң дә авырта ич ул. Шулай да бу чәчәкне иң башта Галимҗан күрүгә ифрат шат иде ана.

Галимҗан әйтү белән, ахшамсафа гөленең чәчәген күрергә дип, фәрештә бәхет өләшкәндә ятып калмыйм әле дигәндәй, һәммәсе йөгерешеп барды. Көне дә нинди иде бит. Апаяз. Зәңгәр күк йөзендә кул яссуы кадәр дә болыт әсәре күренмәде. Чатнап торды көн. Эссе булды. Шырпы сызсаң, кабынып китәрлек. Икенде белән ахшам арасында кояш ут шарын хәтерләтеп торды. Баегач, офык йөзендә санап бетергесез алсу-кызгылт төсмерләр калдырды. Ахшамсафа гөле чәчәген нәкъ әнә шул ахшам кызыллыгына охшатып атты.

— И улым, Галимҗаным, күз нурым, йөрәгем минем, син ахшамсафа гөленең безнең өйдә чәчәк атуын иң тәүдә күрүче, бик-бик бәхетле булырсың, Алла боерса! — дип шатланды Хәсәнә абыстай.

«Әх, остабикә сүзне чамаламыйрак ычкындырды лабаса, акыллы баш та бәгъзе берчак уйламыйрак фикер йөртер икән, нигә әле бөтен бәхетне аның алдына гына алтын арба белән китереп түгәргә, әле булганнар, тагын туачаклар да бар бит» дип уйлады да:

— Әйе, барыбыз да бәхетле булыйк, бөтен гаиләбез өчен кәттә бәхет-сәгадәт булып балкысын бу чәчәк, — диде дә, шуны раслагандай, тамак кырып куйды мулла абзый.

Шуннан, икәүсе генә калгач, Галимҗан әнисен килеп кочаклады:

— Әнкәй, әнкәй, мин ахшамсафа гөле булам.

Ана кешенең фикере бөтенләй башка иде. Ул бит ахшамсафа гөле серләрен һич тә шуңа охшар өчен сөйләмәде. Гөл — гөл инде. Ә кеше — кеше булып кала. Гөл вакытында чәчәк ата. Кеше дә шулай. Аның яшьлеге шул чәчәк ату вакытыдыр, бәлки.

Әнисе Галимҗанны күкрәгенә кысты:

— И улым, күз нурым, сез барыгыз да минем өчен гөлчәчәк инде. Тик үзеңне гөл чәчәгенә тиңләргә ашыкма. Гөл чәчәге вакытлы ул. Ә кеше — мәңгелек. Үзе үлсә, нәселетокымы кала, токым корымый...

Шундыйрак сөйләшү булып алды. Аның эчке мәгънәсен, табигый ки, бала күңеле аңлап та бетерә алмады. Хәер, ничек кенә булмасын, бу сөйләшү Галимҗан күңелендә киләчәк яшәү өчен үзенчә бер орлык булып тамырланды. Ул орлык шытты, кәүсәләнде, яфрак ярды. Тик... аның өчен әлеге ахшамсафа гөле чәчәк аткан көн генә рәхимле-рәхмәтле булмады. Бер уйласаң, баш та җитми, күңел дә ышанмый моңа. Кем хатасы? Анықымы? Әтисенекеме? Бәй, бер дә юктан

чыкты тавыш. Иртән аны — Галимҗанны — галим җанлы кешене — абыйсы Шакирҗан рәнҗетте. Имеш, ул — Галимҗан — Шакирҗанның яшереп куйган чынаяк ватыкларын[1] урлаган. Әлбәттә, Шакирҗан инде чынаяк ватыклары белән уйный торган яшеннән үтеп киткән иде. Шулай да һаман табылып торган тәтиләрне ул гел җыя бара. Нинди дә булса бер матур, зиннәтле, кыйммәтле чынаяк ватылса, бөтен гаилә өчен кайгы-хәсрәт була. Ә Шакирҗан өчен — шатлык: әлеге иске тәтиләр өеменә яңалары өстәлә. Аларны ул келәт почмагы астына яшереп куя иде. Бүген барып караса — юклар. Шуннан... тотынмасынмы бу Галимҗанга бәйләнергә.

— Син генә алгансың, кая куйдың, китер хәзер, — дип җикеренде.

Чынында исә аларны Галимҗан алмаган иде. Гомумән, ул — Галимҗан — чынаяк ватыклары җыю белән артык мавыкмады. Аны хатын-кыз шөгыле дип исәпләде. Шулай да аларга карата бөтенләй үк битараф та түгел ул. Чөнки болар — матурлык. Матур әйбернең ватылуы аркасында барлыкка килгән бизәкләр-тәтиләр. Әмма Шакирҗан җыеп барган тәтиләрне ул урламаган иде. Ни өчен абыйсы шундый ахмаклык күрсәткәндер инде? Нигә, син генә урлагансың, дип, аның якасыннан алгандыр? Галимҗан гаделсезлекне авыр кичерә иде. «Урлагансың» дип якасыннан алгач, абыйсының кул аркасына үткер тешләрен батырды. Шакирҗан исә, әллә нинди карт кәҗә тавышлары чыгарып, бөтен дөньяны яңгыратып кычкырды:

— Җитте, юньсез малай, әшәке җан, — дип, аягы белән тибеп җибәрде.

Нәкъ шул вакытта, алар якалашкан мәлдә, әтиләре килеп чыкты. Аларны аеру өчен әлеге матчадагы тал чыбыгы ярдәм итте. Икесенең дә арт якларына — йомшак җирләренә — чаж да чож җибәрмәсенме бу. Ә тегеләр:

— Әттә-тәтәт, әттә-тәт... — дип, елан чаккандай сызлаган җирләрен угаларга керештеләр.

Ата кеше исә гаепнең юан башы кемдә икәнлекне тикшереп тормады.

— Белегез... акылсыз малайлар... тагын шулай кылана торган булсагыз... бу тал чыбыгы сезнең өчен күп чажлар әле, — дип, чыбыкны матчага янә кыстырып куйды.

Әтиләре чыгып киткәч, Шакирҗан, матчадагы чыбыкны алып, аны җан ачуы белән сындырып ташлады. Аның бу кыланышы «чыбык заманы» бетүне аңлата иде. Мәсьәләгә бу яктан караганда, әлбәттә, аның кыюлыгы бәяләп бетергесез. Тик әнә шул баһадирлык җәһәтендә куркаклык күрсә-

---

[1] Солтанморатта бала-чаганың матур-матур чынаяк ватыкларын җыя һәм шулар белән төрле уеннар оештыру гадәте бар иде.

түе генә күңелсезрәк килеп чыкты. Әтисе әйләнеп кереп, ике арадагы низаг дулкынын басу өчен матчага караса, анда әлеге «шифа бирү таягы» юк иде инде.

— Кайда?.. Кем алган чыбыкны?..— дип ярсыды ата кеше. Шуннан ул әле Шакирҗанга, әле Галимҗанга шелтәләп карады.— Син алдыңмы, Шакирҗан?

— Мин түгел лә инде...

— Синме, Галимҗан?

Атаның көр, иманеч калын тавышыннан Шакирҗан дер калтырап тора иде. Ә Галимҗанда өркү-шүрләү чаткысы аз гына да сизелмәде. Киң маңгаен киереп, күзләрен тоздай итеп, аз гына елмайган хәлдә, әтисенә карап тик торды.

— Димәк, синең эш бу, Галимҗан?..

— Әйе, мин сындырып ыргыттым чыбыкны...

Менә тагын бер галәмәт килеп чыкты. Кыюлык күрсәтә, курыкмый, янәсе. Шакирҗан өчен үтергеч гарьлек булды бу. Ни эшләп һич уйламый болай ялганлады соң әле ул? Ни күзе белән карар киләчәктә энесенең йөзенә? Аңа абый була белү шөһрәтен күрсәтергә кирәк ләбаса. Ярый әле, соң булса да тиз генә үзенең хатасын аңлап алды.

— Юк, юк, әткәй, ул түгел, мин сындырдым,— дип акланды.

Мондый җаваптан тәмам гаҗиз булган ата ни эшләргә дә белмәде.

— Кара инде син боларны... икесе дә «мин» дип танау киереп торалар... Бер-берсен яклашалар, алдашырга өйрәнәләр...— дип, җилкенеп тышка чыгып китте. Хәсәнә абыстай да аңа иярде — мулласын тынычландырырга кирәк иде.

Тышта якты иде әле. Офык һаман ахшамсафа гөле чәчәге кызыллыгын хәтерләтеп балкый. Абыстайның алсу йөзе дә шуларга охшабрак тора. Ул әле ике улын кызганудан, мулласының артык ярсып китү кайгысыннан да ут кебек яна. Хәсәнә абыстайга моңа чаклы да әллә ничә мәртәбә әйткән сүзләрне кабатларга туры килде:

— Мулла, тынычлан әле, болай гел генә кызып китүең һич кенә дә килешкән эш түгел, балаларны бу юл белән тәрбияләсәк, каты бәгырьле булып үсәрләр, аларның алдашуы да шуңа бәйләнгән; күрдең ич Шакирҗанны — коелды да төште балакай, чыбыкны сындыручы ул бит, куркуыннан гына әйтмәде башта...

Алар шактый озак сөйләште. Гыйрфан мулла башка вакытта «Тавыкны йомырка өйрәтми», «Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска», «Хатын әйткәннең киресен эшлә» дип уйлаучанрак иде. Бүген исә, гәрчә остабикәсенең һәр сүзе күңел кылларын кытыклап-мытыклап алса да, урынсыз ирлек горурлыгыннан котылу җаен карады ул — хәләл җефетенең алтынга торырдай акыллы сүзләрен җитди тыңларга мәҗбүр булды. Чыннан да, бөтен авылга шәфкатьлелек-мө-

рәүвәтлелек нуры чәчеп яшәгән, һәркем тарафыннан макталып телгә алынган остабикәсенең йөрәк җылысына төренеп бирелгән шифалы сүзләренә нигә колак салмый, ни өчен игътибарсызлык күрсәтә соң әле ул? Алай дисәң, мәсьәләнең икенче ягы бар бит әле ул: «Ир — баш, хатын — муен»,— диләр бит. Хакыйкать ки, ул баш имәндәй каты, калын муен өстендә утырырга тиеш. Бәс, шулай булмаса, кибәк тутыргандай җиңел баш белән, ай-һай, эш итәлмәссең, һәлак булырсың. Тик... менә бу муен, карап торуга гәрчә сыек-йомшак сыман тоелса да, артык катыланып бара түгелме? Дәхи дә... һич кенә дә муен булып кына калу чамасы юк, башка үрмәләп маташа. Ул — баш, син муен булып калуың да мөмкин. Менә кайчан комга сеңгән су урынына юк була синең ирлек шөһрәтең.

— Менә шул, мулла, әйкәем, һаман бер үк сүзләрне кабатлыйм: матчада чыбык тотмыйк без, чыбык тәрбиясе алган балада ваемсызлык көчле була. Баланы садә итү өчен ата-ананың акыллы сүзе, шәхси өлге-үрнәге, башкаларга уңай йогынты ясый торган үз иҗтиһаты кирәк. Галимҗанны төшендә таң пәйгамбәре итеп күргәнсең. Галимҗанда сиңа охшап кире сыйфатлар да җитәрлек. Кире кешенең күңел кылы бик нечкә була. Ялгыш кагылдыңмы — өзелде китте дигән сүз...

Бәй, бәй, бу «муен» тәгаен «башка» әйләнеп бара лабаса, түбәгә кунып, сандугач булып ук сайрарга тотынды: менә әкәмәт, менә ирлекнең һәлак булуы, менә терәкә дип уйлады мулла абзый. Шулай да яңадан йонын кабартып маташмады. Бер олыныкын, бер кеченекен тыңла, дигәне дә бар бит әле аның. Ир — келәт, хатын — йозак, дип тә әйтәләр. Ирлек гайрәтен, гаярьлекне, көч-куәтне акылың келәтенә җыя бару гына җитмидер, аның йозагы да булырга тиештер, күрәсең, дип уйлады да, кулын селтәп куйды ул. Кул селтәү галәмәтен аңлап бетерә алмады Хәсәнә абыстай. Ризалашу билгесеме, синең сүзләрең минем өчен тишекле бер тиен, дип әйтүеме? Чынында исә бу селтәнү, аныңча, ярар инде синеңчә булсын, бәхәстә хатын-кыз өстен булырга тырыша, киләчәк күрсәтер кемнең хак икәнлеген, дип әйтүе иде.

Бераздан өй эчендә барысы да үз җаенда иде инде. Нәгыймә әлеге ахшамсафа гөле чәчкәсенең өлгесен ала. Аны канвага җайлаштырып, йә сөлгегә, йә кулъяулыгына чигәчәк икән. Нәфисә, мөлаем карашлы күзләрен чекерәйтеп, аңа карап тора: их, тизрәк үссәм, апам кебек табигать матурлыгын мин дә сөлгегә, кулъяулыгына күчерер идем дип уйлыйдыр, бәлки. Габделхәким дүрт аяклап әле тегендә, әле монда җилдерә. Галимҗанга охшап тиз генә ике аяклап тәпиләргә бик ашыкмый, күрәсең. Шакирҗан кычкырып китап укый. Галимҗан, әрекмән колакларын торгызып, мөкиббән тыңлап уты-

ра. Бала ачуы — искән җил, дип тә әйтәләр бит. Ни арада ачуланышалар, ни арада дуслашып та алалар. Билхак остабикәсе ихлас дөрес әйтә: аларның вак-төяк ыгы-зыгысына, ык-мык килүләренә һәрвакыт чыбык белән кизәнү бөтенләй лөгатькә сыймый торган бер ахмаклыктыр.

— Ярар, әнкәсе, кая, булмаса, мин абдәстханәгә киттем, ястү намазы якынлаша икән ләбаса, ачу-кочуны онытыйк, намаз алдыннан килешми,— диде ул, бөтенләй йомшап, миһербанлы ир-ат кыяфәте күрсәтеп.

Ястү намазыннан соң, мулла абзыйны әлеге ахшамсафа гөле чәчкәсен күрсәтергә тагын да алып килде абыстай.

— Менә, муллакаем, әйкәем, карачы моның чәчкәсен, тфү, тфү, күз тимәсен, билҗөмлә ахшам кызыллыгы бит монда. Бөтен өй эче матурлыгы булып балкый бит бу, сөбханалла…

— Әйе, әйе, шулай икән шул,— дип килеште мулла абзый,— шулай икән шул, гөлләрең дә үзең кебек чибәр була синең, Хәсәнә, синең көләч йөзеңне хәтерләтеп балкый бит бу!..

Тик… икенче көнне, ни гаҗәп, иртәнге намазга торганда, ахшамсафа гөле чәчәге коелган иде инде. Һәй, гомерләр!.. Чәчәк гомере!.. Кеше гомере!..

* * *

Таңнар атып тора, сабах җилләре исеп тора, гомер дигәнең үтеп тора. Болары инде аның кеше маңгаена язылган язмыш кебек табигый хәл. Аслан үзгәртә торган түгел. Тик менә шул маңгайга язылганны вакытында белеп булсын иде дә, укып булсын иде. Их, шуның буенча гына яшәр идең дә бит: юк икән, юк, һич син уйлаганча барып чыкмый бу фани дөньяда. Троицк шәһәрендә бабасына биргән вәгъдәсен дә үти алмады Гыйрфан. Мәктәп ачабыз, Хәсәнә белән икебез дә балалар укытабыз, дигән сүзләре язгы мәлдә бер көн явып икенче көн эрегән йомшак кар кебек кенә булып калды. Кем гаепле моңа? Аңламассың. Хәсәнә инде хәзер алты бала анасы. Җитмәсә, башы-аягы белән чумды дөнья мәшәкатенә. Балаларны укыту, аларга дөрес тәрбия бирү, күзләрен ачу… — бөтенесе аның өстендә. Дөрес, бу юнәлештә Гыйрфан мулланың да өлеше шактый зур. Чыбык белән генә түгел, кулыннан килгәнчә балаларны аң даирәле итү өчен бөтен мөмкинлеген бирә. Шулай да аларны укыту күбрәк ана җилкәсенә йөкләтелә. Чөнки ул — инде чын мәгънәсендә мөгаллимә. Мәктәп ачып, бөтен авыл баласы язмышын аңа тапшырганда, бик шәп булыр иде дә бит, әмма һич тә син фикер йөреткәнчә килеп чыкмый. Уфага барып, яңа төр мәктәп ачу турында сүз кузгаткач, үзенә бер-бер артлы сорау биреп карадылар. Кылыңны төрле яклап тарткалыйлар икән

анда. Мантыйк[1], һәндәсә[2] сарыф[3], нәху[4], тарих, фәлсәфә...— тагын да әллә нинди фәннәр дөньясына алып кереп адаштырдылар аны. Тәҗвиттә[5] ул сынатмады. Тарихел-әнбиядә[6] дә мах бирмәде. Ысулы тәгълим[7] буенча да уй казанының буш түгел икәнлеген исбатлый алды. Ә менә мантыйк, һәндәсә, фәлсәфә буенча бирелгән сораулар аның ми күзәнәкләрендәге дулкыннарын бутап кына бетерде. Аңа, җайлап кына, ислахте гыйльмия[8] турында сөйләп бирделәр. Фөнүне җәдидә[9] кояшы балкыячак, имеш.

Шуларны уйлап, инде үзенең яңа шартларда аслан оста мөгаллим була алмаячагына төшенгәч, «мәктәп» сүзен күңеленнән сызып ташларга булды ул. Мәктәп мәдрәсә генә түгел, күрәсең. Анда — мәктәптә — бөтен дөньяны танып-белә торган фәннәр укытыла, янәсе. Хуп, мәйле булсын, Ходай бирсен!

...Шакирҗан өченче ел укый инде бу яңа мәктәптә. Үзе, остабикәсе укытучы булмаса да, мәктәпне ачарга бөтен көчен куйды ул. Акчалата ярдәм дә итте хәтта. Сәет исемле бер егетне китерделәр. Болай карап торыр күзгә бик иҗтиһадлы, булдыклы, белемле егеткә охшаган. «Мәктәп» дип түгел, «учительская школа» дип атады әле ул аны. Димәк ки, урысча укыту була. Әмма теләсә ни булсын. Әнә гаярь егетләр әллә кайларга — Төркиягә, Бохарага — барып әһле гыйлем булып кайта. Алар инде адәм арасында йолдыз булып балкырдай әһелләр. Булмады инде үзеннән. Булмады. Бөтен өмет — балаларында. Бигрәк тә Галимҗанында.

«Школа» дигәне дә аның бик тә абруйсыз бер өй эче генә бит әле. Өч еллык ул. Өч сыйныф кына. Анда хәлле кеше балалары гына укый. Әлеге ызба эчендә мыжгылдап торган балалар йөрми монда. Кайсысының киеме юк, бәгъзе берсенең уку ике ятып бер төшенә дә керми. Аның өчен җил мәгърибтән исте ни дә, мәшрикътан исте ни.

Галимҗан бу «школага» әйткәндәй, шактый чарланып, игәүләнеп, шомарып барды. Әтисе Нурмөхәммәт әйтте бервакыт Гыйрфанга:

— Бу малаең — Галимҗаның — бик башлы булмакчы, Гыйрфан улым, сакла син аны, киләчәктә мәгариф яулар гайрәте сизелеп тора,— диде.

---

[1] Мантыйк — логика.
[2] Һәндәсә — геометрия.
[3] Сарыф — морфология.
[4] Нәху — синтаксис.
[5] Тәҗвит — Коръәнне дөрес уку кагыйдәләре.
[6] Тарихел-әнбия — пәйгәмбәрләр тарихы.
[7] Ысулы тәгълим — методика.
[8] Ислахте гыйльмия — белем бирү эшләренә реформа.
[9] Фөнүне җәдидә — яңа фәннәр.

Шуны уйлап, кулыннан килгәнчә, Галимҗанны мәгълүмат-мәгариф диңгезендә өч-дүрт яшьтә үк йөздерә башлады ул. Әлбәттә, барлык ата кебек Әбҗәдне башына сеңдерергә кереште: «Әбҗәд, һәүвәз, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт, сәхоз, зазог...» Бу сүзләрнең мәгънәсен Гыйрфан мулла үзе дә аңлап бетерми иде. Бәләкәй чакта, әтисе Нурмөхәммәт ишан өйрәткәндә, шуларны ятлап тәмам мие череде. Ләкин тиз генә ала алмый иза чикте ул. Кич ятлаган иртәнгә онытыла да куя. Бер сүздә ялгыштыңмы, ата кешенең күзе әлеге матчадагы тал чыбыгын эзли башлый. Әмма менә бу Таш маңгай — дүртенче баласы Галимҗан — бер әйтүдә су эчкән кебек йота да куя. Икенче көнне сорасаң — сандугач урынына сайрый да бирә. Менә кемнең ми казаны яхшы эшли, менә кемдә зиһен, менә кемдә хәтер... Шуңа күрә башка балалары арасында газиз бер пәйгамбәргә әйләнде дә куйды ул, асыл сыйфатка әверелде. Әлбәттә, аның белән күбрәк әнисе шөгыльләнде. Чын мәгънәсендә бөек мөгаллимә була алды. Әкият дөньясына алып кереп китү, төрле риваятьләр сөйләү, җыр-моң диңгезендә йөздерү... — берсе дә калмый. Укытучы кулына башлы, зиһенле, көчле укучы буларак барды ул.

Укытучы өч сыйныф балаларын да шул бер бүлмәгә утырта. Әлбәттә, монда «парта» дигән төшенчә әле аслан юк. Әлеге дә баягы шул мәдрәсәдәгечә идәндә аяк бөкләп утыралар. Галимҗан беренче сыйныфка барганда, Шакирҗан өченчедә иде инде. Укытучы һәр сыйныф өчен махсус эш бирә. Беренче сыйныф укуны «а» аваз-хәрефеннән башлый. Икенче сыйныф иҗекләрне кушып укырга өйрәнә. Бәгъзе берсе йөгерек укуны да үзләштереп ала. Өченче сыйныф грамматикага төшә: сарыф (морфология), нәхү (синтаксис) өйрәнә.

Боларның бөтенесе дә Галимҗан өчен бик кызыклы, әһәмиятле, күңелле иде. Ләкин бервакыт ул тәртип боза башлады. Мөгаллим хәтта моны ата-анасына җиткерүне мәгъкуль күрде.

Озын гына буйлы, ачык йөзле, мөлаем карашлы, егерме биш яшьләр чамасындагы бу мөгаллим авыл халкы арасында абруй казанып өлгергән иде инде. Моны Гыйрфан мулла да, Хәсәнә абыстай да яхшы белә. Шуңа күрә аны яхшы, якты йөз, күтәренке күңел, ачык чырай белән каршы алдылар. Тик Галимҗанның тәртибе бик шәптән түгел икәнлек әйтелгәч кенә, ата-ананың йөзен шундук кара сөрем каплады.

— Ни эшләгән соң ул, нигә алай тәртип боза икән? — дип сорады Хәсәнә абыстай.

Сүзгә Гыйрфан мулла да кушылды:

— Әйе, безнең бик беләсебез килә... Аның бит укуга дәр-

те гаҗәп зур... Шулай булгач, ни эшләп дәрес вакытында сөйләшеп утыра икән ул, ә?..

— Ул башкаларга комачаулый... йә көлеп җибәрә, йә аларны мыскыл итә...— дип зарланды мөгаллим.

— Ярар, килүең өчен рәхмәт, үзебез сөйләшербез, моннан ары алай тәртип бозмас ул,— дип, улын тәртә арасына кертергә сүз биреп калды ата кеше.

Ә инде ныклап тикшереп карасалар, гаеп һич тә Галимҗанда гына түгел икән. Дөрес, аның уй-фикерендә мөгаллимне хөрмәт итмәү хис-тойгысы юк түгел түгеллеккә, чөнки мөгаллим Сәет, мәдрәсә хәлфәсе кебек, даими рәвештә тал чыбыгы чыжылдатып тора икән. Тыңламаганнарга, «кибәк башларга» тамызып алырга да күп сорамый, имеш. Галимҗанга да кизәнгән беркөн. Шулай да сугарга батырчылыгы җитмәгән. Текә маңгаен киереп торуыннан, утлы күз карашыннан курыккандыр, бәлки. Абруйлы-низамлы ата-анасы барлыкны да искә алгандыр.

Галимҗан үзләренә — беренче сыйныфка тиешле дәресне бик тиз үзләштереп ала икән. Урыс алфавитын бер көн эчендә ятлаган да бетергән. Ә инде сыйныфташлары, мышмыш килеп, еш-еш борын тартып, корчаңгы алаша урынына кашынып утыралар, имеш. Галимҗан кебек сәләтле «шәкерт», кирәген җәһәт алып өлгергәч, дәрестә башкача һич тә тын гына утыра алмый. Ул тынгысызлана, борчыла, иҗтиһадлыкны киметә башлый. Галимҗанга бит әтисе дә, әнисе дә, инде өченче сыйныфта укыган абыйсы да ярдәм итә. Ул инде тиз арада икенче, өченче сыйныфныкын да үзләштереп алды. Гәрчә өч ел буе иза чиксә дә, кушып укый белмәгән мәмәй авызлар да бар әле. Укый башласа, бәгъзе берсенең борын очыннан тир ага, мөгаллим таягыннан куркыптыр инде, тавык урлаган кеше кыяфәтендә, дер-дер калтыранырга тотына. Мондый чакта Галимҗанның көлеп җибәрә торган гадәте дә бар. Дөрес, ул мыскыл да итми, үзен шөһрәт өчен көрәшүче итеп тә күрсәтми, белдекле булып кыланырга да теләми. Мөгаллимгә олылаудан башка берние дә юк. Ә инде аның чыбык чыжлатуын Галимҗан да, Шакирҗан да аслан килештерми. Чөнки алар матчасыннан «тәрбиянең» бу «коралы» мәңгелеккә алып ташланды ич инде.

Гыйрфан мулла үзе дә авызы белән йолдыз чүпләп йөрүчеләр чирүеннән түгел лә инде. Вакытына күрә шактый абруйлы шәһәр мәдрәсәсендә мөдәррис вазифасын башкарды. Яман сабак бирмәде. Остабикәсендә мөгаллимәлек шөһрәте күренеп үк тора. Яңача мәктәп ачып, аны мөгаллимә ясый алмавына үкенеп бетә алмый Гыйрфан мулла. Ярый, монысы шулай булсын ди. Үткән эшкә салават. Җилне кирегә истереп, суны үргә агызып булмый. Ә менә мөгаллимне ва-

кытында урынына җайлап-майлап утырту кирәкле вә әһәмиятле шәйдер.

— Сәет туган, мин дә мөгаллимлек кылган кеше, уку-укыту эшләренең авыр, четерекле, кытыршы якларын белмим түгел, әмма ки җәбер белән алдыру бик кыен. Дәхи дә шулай булгач, һәр баланың үз имкямен искә алу мәслихәт булыр. Галимҗан инде бик күп нәрсәгә кадир кеше. Аны без дә канат астына алыйк. Сез дә дәресләрне өсте-өстенә биреп торыгыз. Кем әйтмешли, зур карапка зур диңгез кирәк. Сай елгада йөздерсәк, аның комга төртелеп харап булуы бар. Иштә, аны тирән йөздерү дөрес булыр. Мин аны һич тә амиранә әйтмим. Бала язмышын килешеп, мәслихәтләшеп хәл итү лаземдер. Ә инде чыбык чыжлату мәсьәләсенә килгәндә...

Соңгы фикеренә йомгак ясый алмады мулла абзый. Аны мөгаллим дәвам итте:

— Сезнең матчадагы чыбык та чыжылдарга гына тора бит?..

Гыйрфан мулла елмаеп куйды:

— Әйе, елан белән бер иде. Әмма ул еланның башы өзелде инде. Хәсәнә абыстаңны беләсез: өй эчендә дә, кешеләр күңелендә дә агулы елан булуны яратмый. Ул минем эчтәге елан агуын да шифалы сүзләре белән юк итеп бетереп бара шикелле.

— Күңелегездә елан булуга ышанмыйм, мулла абзый, халык сезне нык хөрмәт итә, миңа да файдагыз күп тиде. Абыстай да, сез дә чын мәгънәсендә халык укытучысы...

Гыйрфан мулла күз буярга тырышуны яратмый иде:

— Куй, мактама, килешми, ә елан дигәне һәрберебездә бар ул: берәүдә — күбрәк, икенчедә — азрак; аларны, Хәсәнә әйткәнчә, чыбыклап түгел, акыл белән бетерергә кирәктер. Моны соңгы вакытта әти карт та аңлаган иде шикелле. Ләкин канга сеңгәнне тиз генә юып ташлап булмый. Минем канны да озак кайнатты ул агулы елан. Инде котылдым бугай. Шуны сиңа да киңәш итәм. Шәт, аңларсыз дип уйлыйм. Безгә фидаилек җитеп бетми.

Мондый ихлас, чын күңелдән, маңгайны маңгайга куешып сөйләшү, фикер алышу, бәхәсләшү еш була башлады, Сәет Илһамовка Гыйрфан мулланың үз-үзен хөкем итүе ошый иде. Аныңча, үзеңне-үзең аңлау, танып-белү, гәрчә алар әллә ни күп булмаса да, кара ягыңны күрү дәрәҗәсенә күтәрелү — аңлы кешеләр эше. Халык күңелендәге мондый асыл сыйфатларны ул үзенчә гыйлем билфигыль[1] дип атады. Халыкның: «Кеше күңеле — тирән дәрья»,— дигәненә ихлас ышанды.

---

[1] Гыйлем билфигыль — төпле, чын гыйлем, халык педагогикасы мәгънәсендә дә.

*Өченче бүлек*

# ХУШ, АВЫЛЫМ, ХУШ ИНДЕ!..

Сабах җиле исеп тора илләр буйлап,
Исә төрле язмыш белән уйнап-уйнап;
Син яшәмә,
язмышлардан узмыш юк, дип,
Чын яшәүнең мәгънәсе дә
узмышта бит.
*Бала озатканда уйланулар*

## I

Җәй белән Көзнең кул кысышып, бил алышып, аерылышыр вакыты җитте. Әйтте Җәй: «И Көз! Китәм инде. Хуш инде! Начар якларым булса — бигайбә». «Күз өчен Җәй яхшы, авыз өчен Көз яхшы», — диләр.

«Мин болыннарны аллы-гөлле, яшелле-зәңгәрле, алсу-кызыл чәчәкләр белән күмдем. Дөнья йөзен мең төрле матурлык белән бизәдем. Бу гүзәллекне бөтен гавам халкы мөкиббанә хәйран калып, вакыт-вакыт хыялый хис-тойгыларга бирелеп, галибанә илаһи сихерләнеп күзәтте. Бу бизәк, зиннәт җиһан-җәннәтне сөеп карый торган мең-миллионнарның нурлы күз төпләренә сарылып, йөрәкләренә арзу шифа булып ятты. Ходай Тәгалә бүләк иткән ошбу кырларда күпертеп-күпертеп иген-нигъмәтләр үстердем. Кабул кылып ал инде, Көз агам! Әмма минем җитди васыятем дә бар: «Аллаһы Тәгаләдән чын-чыннан оялыгыз, чөнки ул сезнең алдыгызга ризыкны ничек бүлсә, әхлакны да нәкъ шулай ук күңелләрегезгә бүлгәләп салган. Мөхәммәд пәйгамбәрнең үгет-нәсихәтләрен дә искә алыгыз: мираска калдырган малны бүлешкәндә, бер-берегезне рәнҗетмәү, адәмнәргә карата инсафлы булу, дошман белән сугышканда куркаклык күрсәтмәү, табышны үзара бүлешмәс борын аңа кул тыкмау, залимнәрдән изелгәннәрнең-кыерсытылганнарның хакын алу; көчләүчедән көчсезнең хакын яулау. Васыятем белән мирасым аерылгысыз. Васыятем мирасымны дөрес файдалану өчен истинтаҗ»[1].

Моңа каршы җавабында әйтте Көз: «И матур Җәй! Ямьле Җәй! Нурлы Җәй! Тыныч күңелең белән кит. Син быел инсаният алдында мәрхәмәтле иҗтиһадлы булдың. Җилләрең вакытында исеп, яңгырларың вакытында яуды. Күпер-

[1] Истинтаҗ — нәтиҗә чыгару, йомгак ясау өчен.

теп үстергән игеннәрең, иншаллаһ, бураларга кыйммәтле алтын-гәүһәр булып агыла. «Бәләкәй генә бөкре — бөтен кырны бетерде», — дигәнне онытма. Бәләкәй генә бөкреләр — кыр ураклары — чормалардан алынып, үткерләп-игәүләп куелды. «Күз өчен Җәй яхшы, авыз өчен Көз яхшы», — дигәнеңне мөкиббән аңлыйбыз. Әмма: «Аяк тәпелдәмәсә, авыз чәпелдәми», — дигәнне дә онытма, Җәй! Кыш буе авызларны чәпелдәтү өчен, Көз абзаң билен биштән буып куйды».

Әлбәттә, җәй — җәйгә, көз — көзгә, кыш — кышка, яз — язга бер тамчы су дәрәҗәсендә охшамый. Кешеләр дә шулай. Бармаклар да тигез түгел.

Бу җәй Гыйрфан мулла гаиләсе өчен, арттырып әйтсәк, җәйрәп яткан яшел болын төсле булгандыр. Яшеллек — яшьлек төсе. Җәйне көзнең яшьлеге дип исәпләсәк, көзнең яшьлеге сау-сәламәт, ап-ару, җегәрле-гайрәтле булды. Эшнең каты икәнлегендә шик-шөһбә юк. 70 — 80 дисәтинә җиргә чәч. Бодаен, тарысын, арпасын, арышын... яшь баланы иркәләгәндәй, сөеп-назлап үстер. Көзен җыеп ал. «Елга бозлары нинди көндә киткән булса, игенне шул көнгә туры китереп чәч», — дип, табигать серләренә зур колакларын сала белгән Гыйрфан мулла яз көне үк сөйләнеп йөрде. Вакыт-вакыт хәтта тын алмый күзәтте яз балкышы галәмәтләрен. Шул Табигать-Алла кушканча эшләргә тырышты. Аннан соң бөтенесен җәй ихтыярына тапшырды. «Җәйнең җәймәсе киң, ләкин дә җәелеп утырмауны бел», — дип кисәтте һәрвакыт.

Атасының кырыс табигатенә, гаделлегенә, эш сөючәнлегенә гадәтләнгән балалар аның һәр сүзен иман шарты чамалы кабул итәргә гадәтләнеп киттеләр: «Ата әйтә — хак әйтә»; «Ата сүзе — иман»; «Ата йөзе — ил йөзе»...

Үткән ел коен яңгырлар булып, игеннәр җиргә бөркеп чересәләр, быел, киресенчә, халыкның миен кайнатырдай эссе кояш нурлары хөкем сөрде. Бер куркыныч: алай-болай көтелмәгән яңгыр башланганчы, булган кадәресен җыеп, келәт авызына салу. Аннан соң инде ул халык авызына юлны үзе табар.

Бу максатка да ирешелде шикелле. Каты куллы Гыйрфан мулла яз, җәй, көз айларында гаилә бөртекләрен уптым илаһи җигә белде. Кызганмады. Аямады. Һәрберсен кәҗә мае чыгар дәрәҗәдә эшләтте. Бәй, шунсыз булмый. Ни пычагыма: «Хәят — тереклек», — дип әйтәләр. Бәс, шулай булгач, хәятта ирәеп, җиң салындырып, авызыңнан ала карга очырып, тереклек хакында уйламый яшәп буламы? Булмый. Мең кат булмый. Ихлас.

Боларның җәмгысы Гыйрфан мулла гаиләсе өчен җәй кыздырган, көз сүрәнләнгән кояштай мәгълүм. Әйе, әле

көннәр сүрәнләнә бара: артта — көләч җәй, алда — моңсу көз.

Менә шушы моңсу көздә Галимҗан, әтисе җиккән арбага Шакирҗан агасы белән парлап утырып, Ырынбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга китәргә тиеш. Моңа кадәр алар Солтанмораттан биш-алты чакрым ераклыкта булган Кешәнкедәге Гарифулла мәдрәсәсендә дә укыдылар. Димәк ки, берүк вакытта ата-ана биргән ихлас, нигезле, җирле мәгълүмат, авылдагы «Русская школа» тәгълиматы. Кешәнке мәдрәсәсендә алган белем таянычы бар.

Мәдрәсәләрдә уку язын умырзая кар астыннан баш төрткән мәлдә тәмамлана. Гәрчә әле ул җиде-сигез яшьлек кенә шәкерт булса да, буыннары шыгырдык арба шикелле кәкшәкләп торса да, әйтәләр аңа: бар, оланкай, бу кырыс тормыш гелән генә китап бите ялауны хуп күрми, билеңне бөк, тезеңне чүк, сабан сөр, тырма тырма, иген ик һәм дә ки шуңа охшаш мең төрле эш башкар — крестьян баласы җир йомарлагы булып үсәргә, игәлергә, чарланырга тиеш. Мәдрәсәләрдә уку иген бөртекләре бураларга шыбырдашып тулып, әлеге бәләкәй генә бөкре чормага янә менеп кунаклап, беренче күбәләк карлар канат җәйгән мәлдә генә башлана. Бу катгый канун Гыйрфан мулла гаиләсе өчен дә ят түгел. Кыр эшләре бетеп, авыл халкы күкрәк киереп иркен тын алып куйгач, Гыйрфан мулла Ырынбурга сәфәр чыгачак. Шулай да кыш килүен хәбәр итүче уйнак карлар күренүне көтмәскә булды. Алдан килгән урын өчен, арттан килгән тамак өчен, дигәнне искә алып, ике баланы яхшылап урнаштыру нияте белән, иртәрәк кузгалырга булды.

— Атасы, балалар кыр эшендә бик йончыды, нигә ул кадәр ашыгасың әле, һич югы, атна-ун көн хәл алсыннар иде: болай коры тотуыңны аслан мәслихәт күрмим,— дип карады балалары язмышы өчен һәрдаим борчылып яшәгән ана.

Гыйрфан мулланың үзенең дә сәфәргә әле менә бүген генә аягы тартмый иде. Сәбәпсез сәнәк тә урыныннан алынмый дигәндәй, аяк карышуның берничә сәбәбе бар. Кичә капка башына кунып, койрыгын өй ягына куеп, өч мәртәбә шыгырдады бер юньсез саескан. Бу инде — афәт килүне хәбәр итү. Юлдамы? Менә хәзерме? Анысы гына очып киткән иде — бер карга килеп кунды. Монысының: «Кар-каркар,— дип каркылдавы,— юлың тар-тар-тар, курыкмасаң, барбар-бар», — дигәндәй тоелды. Ул бит әле, ләгънәт, тиз генә очып китәргә чамаламый, синең икеләнүеңне белеп ирештергәндәй, каһкаһә мыскыл иткәндәй, борынын сузып, һаман каркылдавын белә. Аптырагач, җирдә яткан бер бәләкәй ташны алып томырырга мәҗбүр булды. Үзе тирә-якка караш-

тырып алды: карга, саескан белән низаглашып йөрүен күрмиләрме, янәсе — мулла кешегә аслан килешми ич мондый шөгыль. Ярый, бу көрәшнең авызы шул таш белән капланды шикелле. Ихатада үзенең өстенлегеген сизеп, эре генә атлап китсә, койма башына бер чыпчык килеп кунды. Канатларын кагып, чырылдарга керешмәсенме монысы тагы: «Чепчеп-чеп, чек-чек-чек,— дигәне гүя,— чык-чык»,— дигәнне аңлата. Саескан, карга, чыпчык кебек кошлар «лыгырдавын» тыңлап йөрүенә үзе дә аптырады Гыйрфан мулла. Әмма мәсьәләнең икенче ягы бар ла: аларның җаны бик сизгер бит, шайтан алгыры. Ә инде күктә торналар тезмәсе: «Торыйк-торыйк-торыйк»,— дигән аһәң калдырып киткәч, вактөяк кошлар тавышы бөтенләй онытылды да куйды. Аларның моңлы тавышы да җәй белән көз хушлашуын хәтергә төшерде. Еракка-еракка, җылы якларга сәфәр чыктылар. Уйландыра, хисләндерә, әллә кайларга чакыра торган бу моң Гыйрфан мулланы да юлга өндәгәндәй тоелды.

Аяк тартмауның икенче бер сәбәбе — остабикәсенең сабырланырга кушуы. Вакыт-вакыт аның да зиһене кошлар сизгерлеген сиздереп куя лабаса. Шулай да мәсьәләнең янә бер җитди ягы бар. Мәдрәсәдә берничә ел ми кайнаткан шәкерт-мәкертнең бәгъзе берләре җәен төрле тарафка акча эшләргә тарала. Алар көзен уку башлануга гына кайта. Чөнки аның ышанычлы урыны бар. Ә инде беренче сыйныфка барганнар бу бәхеттән мәхрүм әле. Бусы — бер булсын, ди. Икенчесе — сәбәпнең иң берәгәйлесе шул: мәдрәсәгә әле сине иң әүвәл кылычтан үткер, кылдан нечкә сират күпере аша үткәрәләр. Имтихан дигән нәмәстәкәе дә бар. Йөзеңә, төсеңә, буй-сыныңа, барлык сыйфатыңа игътибар ителә. Сәләт тә, сәламәтлек тә кирәк.

Гыйрфан мулла мөдәррис буларак Троицк мәдрәсәсендә беренче сыйныфка шәкертләр кабул иткәндә харап кыйлана иде бит. «Буш тубал» белән килгәннәрне җене сөйми иде аның. Барысын да нечкә иләктән иләргә яратты ул. Булмастай хәлсез хәчтерүшне үткәрмәскә тырышты. Үтмәгәннәр — башка мәдрәсәгә китә.

Шакирҗан белән Галимҗанның башында җил уйнамый. Бу хакта уйласа, аның күңеле — күктә. Гыйлем мәсьәләсендә алар арасында мөнәсәбәт юк түгел. Галимҗан өстенрәк тә. Кешәнке мәдрәсәсендә дә кояш булып балкыды. Солтанморат шкулында да йолдыз булып елтырады. Мөгаллим Сәет Пуш... Пуш... кем соң әле?.. Әйе... Пушкин язган китап бүләк итте. Җитмәсә... әйткән... Пушкин, дигән, унтугызынчы гасырда, дигән, урыс дөньясында пәйгамбәр булды, дигән, син бик башлы, Галимҗан, егерменче гасырда татар пәйгамбәре бул, дигән.

Сәет мөгаллим үзе дә башкалардан үзгә бәндәләргә, гыйлем-мәгърифәткә гашыйк зат икән ләбаса. Аңлаган бит Галимҗанның акыл казанында нинди алтын ятканлыкны. Гыйрфан мулланың үзенә дә җиткерде ул бу изге хәбәрне. Галимҗанны, диде, Ырынбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә җибәрергә кирәк, диде, анда хәзер яңача укытылачак, диде, тик, диде, урысчасын ташламасын, диде.

Моның шулай тиешлеге Гыйрфан мулланың үзенә дә мәгълүм хәзер. Галимҗанның кара болыт эченнән якты кояш булып балкып чыгару өчен бер пот тоз ашагандыр инде. Иллә дә мәгәр кояш та һәрдаим балкып кына тормый бит әле ул. Болыт аның йөзен кешеләрдән яшерергә генә тора. Галимҗанның сәламәтлеге шәптән түгел, Троицкида, алтын базыннан чүп эзләгәндәй, үзе теләсә кемнең вөҗүденнән энә очы зурлыгы шик капшап караган кебек, «Хөсәения»дә дә шулай миһербансыз кылансалар, пәйгамбәр буласы балаң үтмәсә, егыл да үл.

Шулар хакында әйтте ул остабикәсенә. Иртәрәк баруның сәбәпләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде дә:

— Син инде, остабикәм, аларны язын ашлык чәчтергәнгә, тырма тырматканга, җәен утау утатканга, көзен иген урдырганга, сабан сөрдергәнгә мине битәрләмә; максатым анык вә ачык: аларның бөтенлеге өчен кара сакалыма кырауның иртәрәк төшкәнен беләсең; бернинди атна-ун көн юк, әзерлән, иртәгә юлга чыгабыз, вәссәлам. Ходай язмаган эш булмас. Язмышларын бер Аллага тапшырдык. Канаты җиткән кошны ояда озак тотып булмый. Ул инде очып китәргә тиеш. Иншаллаһ, яман очмаслар!..

— Әйе, анысы да дөрес, юлларына ак җәймә инде, бәхет орлыклары уңдырышлы булсын балакайларымның, — дип, дога кылып куйды абыстай. Шулай да аның эче тулы ут иде. «И Ходаем, сәламәтлегенең йомшаклыгына карап, Галимҗанны анда кабул итмәсәләр, бу кайгыларны ничек күтәрә алыр икән ул? Чынлыкта Галимҗанның чирләшкә булуында ул үзе гаепле бит. Нигә җибәрде ул аны теге вакытта җиләккә? Бер ялгыш адым харап итә шул адәм баласын. Бер ялгыш адым. И Раббым!.. Киләчәк бәлаләрдән үзең сакла инде. Юлларына фәрештәләр ак җәймә җәйсен, чәчкәләр сипсен!.. Ходай үзләрен шайтан күзеннән сакласын…

Шундый уйларны кичерә-кичерә, сәяхәтчеләргә ак юл тели-тели, аларны тәмле-татлы йокыдан бүлмәскә тырышып, төне буе юлга ризык-нигъмәт әзерләде абыстай: сумса, бәлеш пешерде, ит кыздырды — таңны тамчы да черем итми каршылады…

## II

Алсу таң атты.

Мич алдында төне буе мәш килүдән алсуланган Хәсәнә абыстайның да йөзе шушы таң балкышы төсле иде. Никадәр генә арыган-алҗыган булмасын, тәһарәт алып, мулласы белән бергә иртәнге намазны укып алды ул. Үзләренә, халыкка, бөтен инсаниятә, дөнья йөзенә, хәяти яшәешкә бәхет-сәгадәт, иминлек, җан тынычлыгы теләп, дога кылдылар. Балалар да аякка басты. Ашап-эчеп алгач, ата кеше ат җигәргә чыгып китте. Оһ, каһәр төшкере, оһ, гөнаһ шомлыгы, күтәрмәдән төшсә, аны әллә кемнең кара песие каршы алды. Кем песие бу? Нигә кергән? Ни кирәк аңа? Әх, юньсез нәмәстәкәй, әх, йөзе кара!.. Бак син аңа, күзләрен тоздай итеп карап тора. Имансыз... Перрәс... Ул әле кугач та китми тора. Чыбык алгач кына сыпырды. Әллә кая кереп посты, ләгънәт!..

Кара песи юлга ак җәймә түгел, кара җәймә җәюче иде. Күңеленә янә шом төште мулла абзыйның. Яшәештә була торган ак-кара көрәше ак песи белән кара песигә дә бәйләнгәнме? Һм, җиңәрсең Гыйрфан мулланы. Якалашып кара син аның белән. Ул — мөмтаз зат. Әллә нинди ырым-мырымнардан мең кәррә өстен тора.

Шулай уйланып йөргәндә, ишегалдында җигелүне көтеп сәфәргә ашкынып торган арбаны, юлда сынатмассыңмы дип булса кирәк, янә бер караштырып-тикшереп алганда, бик җитди, әмма куркыныч кыяфәттә Хәсәнә абыстай килеп чыкты. Аның йөзендәге таң алсулыгы сүнгән иде инде. Ул йөздә хәзер — курку катыш кайгы сөреме. Ниндидер күңелсез хәл булганлыкны ахмак та аңлarлык.

— Мулла, атыңны җикми тор әле...

— Ни булды тагы да? Нигә күгәреп каттың?

— Галимҗан коса да коса... Башын тоткан идем... ут кебек яна...

— Ә нигә уянгач та әйтмәгән чирләгәнен?

— Ул бит авыруны кешегә сиздермәскә тырыша...

* * *

Галимҗан өч көн ут эчендә ятты. Аннан, аякка басып, акрын-акрын йөри башлады. Атна дигәндә инде, шактый сихәтләнүен сиздерде. Шулай да юлга чыгарга кабаланмадылар.

— Ашыккан — ашка пешкән, сабыр иткән — морадына җиткән, дигәнне беләсең бит инде, атасы, бер дә ул кадәре ут йотып йөремә әле, берәүнең бәхет арбасына икенче утыра

алмый, аларга тиешле урынны бер Ходай үзе тәгаенләп куйган инде ул,— дип юатты Хәсәнә абыстай мулласын.— Тагы да бераз хәл җыйсын инде Галимҗан.

Хәсәнә абыстай юлга чыгарга дип ялкынланган ата кешенең йөрәк утын басып тору уе белән, үзен даими рәвештә сабыр итеп күрсәтергә тырышты. Әмма үзенең күңел уты бер дә анықыннан ким түгел иде. Инде җәй аеның соңгы җилләре көзгә ашыккан мәл булса да, көннәр һаман җылы тора әле. Кыр эшләре тәмамланган көнне, шул шатлыктан булса кирәк, Шакирҗан белән Галимҗан су коенырга китте. Әйтте ана Шакирҗанга:

— Галимҗанның йомшаклыгын беләсең, су суык булса, артык озак кермәгез берүк,— диде.

Көне буе тирләп янган тән су салкынлыгын башта әллә ни тоймады. Алар балыктай йөзеп тә киттеләр, кат-кат чумдылар да, су чәчрәтешеп тә уйнадылар. Ә бервакыт Шакирҗан Галимҗанның иреннәре күм-күк булганны, бөтен тәне калтырана башлаганны күрде.

— Әйдә, чыгыйк инде, Галимҗан, сиңа салкын тиюе бар,— дигән сүзләренең энесенә кире тәэсир иткәнлеген сизми дә калды ул.

Бу сүзләрне Галимҗан түбәнсетү дип уйлады. Болай да «чирле чәүкә» дигән даны бар. «Салкын тиюе бар» дигән сүзләрне шуның өчен әйткәнлекне әллә ул аңламыймы? Инде килеп бертуган агасы кимсетәме? Юк, ул беркем тарафыннан да үзен кыерсытырга беркайчан да юл куймас. Үзенең шактый эре бәрәңге икәнлеген чамалый ул. Агасына үч итеп, әле балыктай йөзеп китте, әле чумып ләззәтләнергә керeште, су чәчрәтеп уйнарга тотынды. Шуны сөйләп биргәч:

— Сүзне һәркемнең табигатенә карап сөйләргә кирәк, Шакирҗан улым, Галимҗанның холкы корырак; күңел — пыяла, дөрес чиртмәсәң — уала, диләр бит, ул нахакны бик авыр кичерә; аң бул, юкка рәнҗетеп ташлама тагы, аны Ырынбурга сиңа ышанып җибәрәбез...— диде әнисе.

— Аны күп вакыт тыңлатуы кыен, әнкәй, ул бит чыгымчы ат белән бер.

— Кадерен белүеңне сиздерсәң, чыгымчы ат та карышмый, балам. Нык күз-колак бул. Ул унике яшьтә генә бит әле. Шуны уйлап, икегезне бергә җибәрергә булдык. Кешедән кактырма-суктырма. Моны колагыңа киртеп куй.

Шакирҗан шаяртуга күчте:

— Киртек колак белән ничек укырмын, әнкәй?

Хәсәнә абыстай да елмаеп куйды:

— И Ходаем, атасына охшап, монысы да шаяртырга гына тора тагы.

## III

Галимҗан, сәламәтләнеп алгач, ерак сәфәргә чыкканчы, үз авылы табигате дөньясында сәяхәт кылып алырга булды. Мең мәртәбә көмеш суын эчеп ләззәтләнгән зәңгәр чишмә буйлары, ерактан караганда ук бөтен гүзәллекне үзенә җыйган диңгезне хәтерләтеп торган Кондызлы күл, мәңге сөеп карап туймаслык Исәнбикә болыны, Түрсә гөленең Авыргазы елгасына килеп кушылган урыны...— барысын, һәммәсен янә бер кат күрәсе, аларга һәрвакыттагыча күз алмаларың талганчы карап торасы, зәңгәр күк йөзендә җәйге төсен сизелер-сизелмәс кенә үзгәртеп йөзгән кояшның җылы, бәлләвер нурларында көннәр буе иркәләнәсе, хозурланасы, үзе дә аңлап бетермәгән илаһи бер хис-тойгылык белән ләззәтләнәсе килә иде аның. Дөньяның җәннәте-оҗмахы булып тоелган бу табигать гүзәллегендә хәзер Шакирҗан абыйсы белән йөзәсе килми иде инде аның. Чөнки алда әле аның белән бергә булачак саналмаган көннәр, атналар, айлар, еллар бар. Бергәләп менәсе таулар, йөзәсе сулар, укыячак китаплар — бихисап. Шуңа күрә ул бу көннәрдә әбиләр чуагы матурлыгын һаман җуймаган табигать кочагында Мохтар белән бергә булырга тырышты. Мохтар — аннан ике яшькә генә зур туганнан туган абыйсы. Күрше булып яшиләр. Әмма Галимҗан аңа беркайчан да «абый» дигән сүзне әйтмәде. Ике яшь арасы аларның берсен зур, икенчесен кече итеп күрсәтмәде. Мохтар холкы белән Шакирҗанга тартымрак иде. Әгәр Галимҗан белән уен вакытында аз-маз чәкәләшеп алсалар, ул да озакка бармады, ачу төеннәре, кем әйтмешли, чыпчык канат кагып алган арада чишелде. Иң әүвәл колакларны ярырдай итеп каты сызгырырга Мохтар өйрәнде. Бу һөнәрне чын әһелләрчә үзләштерү Галимҗанга да әллә ни авырга туры килмәде. Тора-бара ул хәтта Мохтарныкына караганда да ачырак сызгыра башлады. Уенга бер-берсен сызгырып чакыра торган булып киттеләр. Ә инде парлап сызгыра башласалар, арттырыбрак әйтсәк, әллә ничә чүл бүресе чыелдаган тавышлар ишетелә. Мондый чакта олылар аларны битәрләп-гаепләп тә ала.

Бөтенесе дә вакытлыча гына. Балалык шуклыгы, шаянлык, гамьсез үткән еллар сагынып сөйләргә генә кала. Ырынбурдагы тирә-якта дан тоткан «Хөсәения» мәдрәсәсенә барачак Галимҗанга хәзер унике яшь. Ул инде үзен балалык бакчасыннан чыгып, яшьлекнең яшел бакчасына аяк баскан зат итеп тоя.

Беркөнне Галимҗан кендек әбисе Хәмдия абыстай янына бармакчы булды. Аны ул икенче ана дәрәҗәсендә хөрмәт

итә. Ул — аны ана карыныннан якты дөньяга иң беренче хөрмәтләп кабул итүче алиһә. Ул — аны теге вакытта үлемнең үткер тырнагыннан тартып алып калучы бөек җан. Аның кара шадралары эчендә йолдызлар бар кебек. Йөзен шул нурлар балкытадыр, мөгаен. Ул нурлар йөрәк түреннән үк киләдер әле. Бу нурлар кешеләргә чәчелә. Кешеләрне назлый, иркәли, аңлап бетерә алмаслык ниндидер матурлык дөньясына өметләндерә. Үз әнисенең моңын, илаһилык белән типкән йөрәк сулышын аның карынында чакта ук үз йөрәгенә, тән күзәнәкләренә, бөтен күңеленә шифа итеп сеңдереп яткан. Аннан соң алиһә ананың йөрәк моңы, үтә дә сөеп карый торган күз нурлары бишектә чакта аңа бәхет-сәгадәт нурлары булып агылган. Ак түти дә аңа шундый ук нурларны чәчә кебек. Аның иркәләп-сөеп каравы, миһербанлылык-шәфкатьлелек белән тулы елмаюы, башыңнан эчке бер җылылык белән сыйпап куюы үз анаңнан алган мең төрле назлану мәсгудиятенә янә мең төрле рәхәтлекләр өсти. Ул бит әле берүзе генә түгел. Ак түтинең җылы кулыннан үткән Галимҗан кебекләр авылда йөзләгән. Ак түти бит шуларның барысына да йөрәк җылысын, күз нурын, сөйкемле елмаюын өләшә белә. Ул йөрәктәге матурлык гәүһәрләре һич өләшеп бетерә торган түгелдер. Шуңа күрә инде хәзер җитеп беткән кызлар, егетләр дә аңа матур итеп, өздереп, ихлас бер мөкиббәнлек белән яратып, йә Ак түти, йә Кендекәй, йә Кендек әби, йә Хәмдия абыстай дип эндәшәләрдер. Башка авылга кияүгә китәсе кызлар да аңа фатиха алырга килә. Бәхет эзләп шахтага, урман кисәргә, заводка китәсе егетләр дә Ак түтинең хәер-фатихасына мохтаҗ.

Моны Галимҗан яхшы белә. Аңа да башкалар кебек Ак түти алдында сәҗдәгә китү кирәкме? Ә ничек эшләргә моны? Аңа нинди җылы сүзләр әйтергә? Бу кадәресен ул аңлап бетерми иде шикелле. Һаман шул кешеләрнең күңелен, йөрәген, тын алышын аңлаучы күз карасыдай газиз әнкәсе ярдәмгә килде.

— Балам, Галимҗан улым, теге көнне сез сәфәргә әзерләнгәндә, Хәмдия абыстай өйдә юк иде, шуңа күрә әйтмәдем, ул инде кунактан кайткан, бар, аңа хәер бир, менә сиңа акча... — дип, кулына бер көмеш тоттырды.

Бу көмеш аның өчен бәхет кошыдай тоелды. Аны нык итеп учына кысты. Юлда гүя аның очып китүеннән куркып, һаман шулай көмешне учына кыскан килеш атлады.

Бәй, килеп җитсә, монда бит бөтенләй башка хәят. Аларның йорты ике катлы. Ул сирень, сәрби, алма, чия агачлары эчендә кукраеп утыра. Бакчада төрле чәчәкләр, гөлләр. Ә биредә? Бармак белән төртсәң, авып китәрлек тузган читән. Аларныкыдай купшы итеп эшләнгән капка кайда инде ул.

Капка урынына утыртма читән кебегрәк итеп үрелгән бер нәмәстәкәй. Ул да үлем алдыннан соңгы сулышын алып интеккән сырхау кеше кебек бер якка хәлсезләнеп кыегаеп төшкән. Күрәсең, капка урынына булган аралыкны ачып вә ябып торуның хаҗәте юктыр биредә. Ихатада өй ишегенә алып бара торган тар сукмак. Аның тирә-ягында әрем, кычыткан, тигәнәк урманы. Тавык кетәге зурлыгындагы абзар бөтенләй ишелеп төшкән. Балчык-саманнан өелгән өй дә кайгы-хәсрәттән бите танымас дәрәҗәгә җитеп җыерчыкланган туксан яшьлек картны хәтерләтеп тора. Өйнең кыеклап ябылган түбәсе юк. Төп-төз түбәгә җәелгән балчык өстенә кеше буе алабута үскән. Бу күренешкә хәйран калып озак кына карап торды Галимҗан. Һәм, ниһаять, кулы чабата киндерәсеннән эшләнгән ишек бавына үрелде. Ачып керсә, өйалдындагы җир идәндә ниндидер бер каккан казыкка бәйләнгән кәҗә басып тора. Башта караңгырак иде. Чөнки күз тышта калган. Тора-бара алар бер-берсе белән бик тиз танышып алды. Кәҗә, башта сакалын аз гына да селкетми, күзләрен тоздай итеп, аңа мөкиббанә карап торды. «Син кем? Исемең кем синең? Нинди язмыш җилләре ташлады сине бу өйгә?» — ди кебек иде ул. Аннан соң, ниһаять, кәҗә телгә килде: «Мә-ә-ә, мә-ә-ә, мә-ә-ә»,— дип куйды. Син: «Мә дә мә»,— дисең, миңа бер бирер әйберең дә юк ла инде дип уйлап, ярый, ачуланышмыйк, дус булышыйк дигән хис белән ул кәҗәнең башыннан, мөгезеннән, сакалыннан сыйпап куйды. Аннан өй ишегенең тоткасына үрелде. Ул да аларныкы ише тимердән түгел икән. Агачның чатлы ботагыннан эшләп кадакланган бер гарип тоткыч. Ишекне акрын гына шакыгач, эчтән ниндидер ирнең шактый калын, шул ук вакытта тупас, тутык тавышы яңгырады:

— Кәҗә... мәлгунь... Әле мин бәйләп куйган җебеңне өзденме?.. Һич тынгы бирми бу сакаллы мөртәт...

Галимҗан ни эшләргә дә белми аптырап тик торды. Ак түтинең өйдә юклыгын, монда ниндидер ирнең хуҗа булуын аңлады ул. Ачуы килеп, җенләнеп, үзен-үзе кая куярга белмичә, кәҗәнең бер мөгезеннән сыйпап алып, яңадан ихатага чыкты: кире кайтып китүдә иде исәбе. Бераз басып торгач, бу уеннан да кире кайтты. Әтисе бервакыт әйткән иде бит:

— Кире чигенү — ир-егет өчен хурлык,— дигән иде. Димәк ки, нинди генә авыр шартлар булмасын, тоткан юлыңнан тайпылма, салулама, мәлҗемә, кыйблаңа кыю атла. Шуны уйлап, янә икеләнеп-микеләнеп тормыйча, кире борылып килде дә, кабат шакып-нитеп маташмыйча, ишекне алагаем ачып, эчкә керде. Керсә, ни күзе белән күрсен, сәкедә утыз биш яшьләр чамасындарак бер ир җәелеп утыра. Монда да җир идән икән. Сәке дигәне түр башына җәелгән. Анда

сузылып ятсаң, биш-алты кешене тыгызлап-тыңкычлап урнаштырырга мөмкиндер. Мич тә шул, чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, бәләкәй өйнең чамасын исәпләп салынган. Шулай да ул мич, кайбер ярлы кешеләрнеке кебек, алалы-тиләле түгел, ак йөзле. Ак түти аны бик яхшылап, пөхтәләп агарткандыр. Бердәнбер тәрәзә кашагасына эленгән сөлге ике яклап асылынып төшкән. Бу үзенчә, өй эченә аз булса да нәфислек, матурлык биреп тору өчендер инде. Сул як диварда намазлык эленеп тора. Кыскасы, бу бәләкәй өйгә шуннан артык җәннәт нуры өстәү мөмкин түгелдер. Ничек кенә булмасын, Ак түтинең өй эчен үз күңеле кебек матур итәргә тырышканлыгы сизелеп тора. Ә инде шул бәләкәй, тар сәкедә ишелеп утырган ир кешенең сәерлеге һич тә башка сыя торган түгел. Җитмәсә, аның алдында аракы, икмәк сыныгы, бер кисәк суган. Кем бу? Ни пычагыма Ак түтинең ак күңеленә кара тап ябып йөри ул? Авыл халкы беләме моны? Белсәләр — нигә юл куялар? Шундый сораулар яшен тизлегендә талап үттеләр аның ми күзәнәкләрен.

Әле генә менә, кәҗә белән күзгә-күз карашып калган кебек, алар бер-берсенә сөзеп караштылар. Галимҗан аның алдында телсез иде. Теге дә, иманын йоткан бер кеше шикелле, телен аркылы тешләп, Галимҗанга карап катты. Аның алдында башына түбәтәй, өстенә аксыл күлмәк өстеннән камзул, аягына читек кигән малай басып тора. Моның бай оясыннан чыккан «кош» икәнлеген исәр дә аңларлык. Ярый, монысы шулай да булсын ди. Аракы шешәсе алдында кукраеп утырган кеше кем ул? Галимҗан өчен бер сер иде бу. Ул әле берникадәр маймылны да хәтерләтә. Шәп-шәрә утыра. Күкрәге йон белән тулы. Озын чәч үстергән. Әллә чалбар, әллә ыштан кигән, аны аеру бик кыен: һәрхәлдә, киндердән әтмәлләгән бер нәмәрсәкәй булса кирәк. Күкрәге киң. Алып батырныкы кебек. Мускуллары гер ташы ишедәй бүртеп чыккан. Галимҗан хәтта аңа кызыксынып карап торды: их, минем дә тышкы күренешемдә шундый җисмәни көч балкып торса икән, дип уфтанды. Аның башына: «Әллә Алып батыр дигәннәре шушы үземе?» — дигән сорау килде.

Бераз карашып торгач, «Алып батыр» сүз башлады:

— Син, пәнимәеш, нигә әле миңа күзләреңне чекерәйтеп карап каттың, минем шылай көмешкә эчеп ытыруым, суган кимереп... зәкусивәт итүем, шыр ялангач келмәксез былывым ыкшамыймы?

Галимҗан аның бу урынга күптән килеп утырган мишәрләр теле белән сөйләшүен аңлап алды. Урыс сүзләрен катнаштырып лыгырдавы буенча фикер йөрткәндә, аның зимагур затыннан икәнлеген исбат итү дә кыен түгел иде. Ә шулай да кем соң бу? Шадралыгы буенча фикер йөрткәндә,

ул Ак түти туганы булырга тиеш. Дөрес, моның шадрасы кара шадра түгел. Ак шадра. Шадра чокырларының төбендә Ак түтинеке кебек, кара тимгелләр күренми. Ак шадра. Кара шадра. Кызык та инде. Боларның аермасын, мәгънәсен, эчке хосусиятен ачыклау да кыен. Ничек кенә булмасын, «шадра — йөрәк яндыра» дигәне дә бар бит әле. Билгеле, боларның Галимҗан өчен сукыр бер тиенлек тә кирәге юк. Артык киңәймәскә тырышып, «Алып батыр»га җавап бирде ул:

— Мин Кендекәйгә хәер китергән идем.

«Алып батыр» аңа янә карап катты:

— Хәер?.. Хи-хи-хи. Ха-ха-ха... Дә-ә-ә... Аңа хәер бирәләр. Пәчәму? Пәтәмүште ул кендек әбисе... Вәт кәк... ул битнәшкә шыл тиннәр белән яши дә... Шыннан килгән акчага бер кәҗә бәкәе сатып алганныйы... Ул үсте инде... ыйалдында бәйләүле тыра ана... Кергәнсеңдер... Ну мут хайван да инде... Кетүгә чыгарсаң, сакалын мәминт бер селкетеп, күзләрен акайтып, кетүчегә кыйрыгын гына күрсәтеп, прәме... сыпыра гына... Тавык ырлаган малаймыни... Шыннан... мин сиңа әйтәем... артыннан эзләмәсәң... вопче кайтмый... Кайда гуләйт итә... Шайтаным белсен... Вәт сабака диң син аны... Нәстәйәшши хам... Хи-хи... Шыңа кирә бәйләп тыта аны Ак түти. Кешегә баш бирмәй... Бы яктан караганда... ул миңа ыкшаган... Бирмә махны кешегә... ивчу... тәк бит... жизин... быраг... Ярай... сүздән аркан ишеп булмый... Син өзең былай бик чибәр күренәсең... Кем малае быласың соң әле?..

— Гыйрфан мулла улы булам мин...

— Ә-ә-ә... әһә... прикраснә... атаең шәп кеше... билләһи... Былтыр сабантыйда сезнең Алмачывар беренчелекне алды бит әле... ну ат әй... дәртле урыс марҗасы шикелле биеп тора прәме... Ат җаратам бит мин... ат җаратам... Шыңа күрә Ат карагы дигәнгә гүпчи гәрләнмим... Күкрәк йонымның бөртеге дә селкенми... вәт тәк... пәнимәеш... Ә син кырыкмайсыңмы ат карагы алдында басып торырга?..

Галимҗан тиз генә җавап бирмәде. Маймылга охшаган бу шөкатьсез бәндә аңа башта бик куркыныч, хәтта берникадәр җирәнгеч булып тоелган иде. Ә хәзер аның сүзләрен тыңлавы күңелле. Галимҗан ишан хәзрәт, муллалар, зыялылар нәселеннән. Җиде бабасының нәсел-нәсәп тамырын белә хәзер. Аларның өй эчендә, туган-тумача, кардәш-ыруг арасында бөтенләй башка тел. Нинди тел ул? Үтә дә нәзакәтле, күркәм, сылу-матур тел! Бөгелмәле-сыгылмалы, бизәкле-чачаклы, аллы-гөлле тел! Боз күңелләрне эретә, рухсызларны рухлы итә, шәфкатьсезләрне шәфкатьле итә, йөрәккә таш урынына шифа бирә торган тел! Ә биредә бөтенләй башка тел.

Таштай каты, боздай салкын, әремдәй ачы тел. Галимҗанны баллы-татлы тел тәрбияләп үстергән. Бу халыклар каты тел, тәртипсез тел, агач тел белән сөйләшә. Ә шулай да тыңлап тору кызык. Галимҗан тыңларга аеруча ярата. Хаклыкны бигрәк тә. Менә бу «Алып батыр» үзенең ат карагы икәнлеген дә яшерми хәтта. Аның белән мактанадыр да әле. Әнә ул нинди көчле кеше, пәһлеван, янәсе.

— Юк, агай, курыкмыйм, — дип, кыска гына җавап бирде Галимҗан.

«Алып батыр», далада әллә нинди айгыр кешнәгән тавышлар чыгарып, кычкырып көлеп куйды:

— Ха-ха-ха, хо-хо-хо... Вәйт мәләдис... Мин шындыйларны... синең кебек куркак булмаганнарны җаратам... пәнимәеш ли... куркак бәндә әпәсне ул... Куркакмы?.. Әй, ул куркак... Беләсеңме?.. Куркак атасын да, анасын да сатарга мужыт... Ә син... Гыйрфан мулла малае... Хи-хи-хи, ха-ха-ха... Әпәт тәки... һм... Мин буталдым... Мына нимә... синең анаң... Хәсәнә абыстай, ул бит фәрештә катын!.. Аңлыйсыңмы син шуны, юкмы?.. Ә?..

Галимҗанга аның сүзләре һаман әле төрле яклап тәэсир итеп торды. Әтисен, әнисен зурлавы аеруча мөкаддәс иде. Ата рухы, ана фатихасы белән яшәргә кирәклекне ул белә ич инде. Монысы аның әле бер хәл. Болар инде аның өчен чәйнәп ташланган сагыздай мәгълүм нәрсә. Ә менә аның алдында утырган «Алып батыр» — ачылмаган китап сәхифәсе.Ниләр бар аның күңел сәхифәсендә? Хәзер инде Галимҗанның шуны беләсе килә:

— Агай, сез нигә ат урлыйсыз?

«Алып батыр», олы авызын колакларынача ерып, әллә нинди тутык тавышлар чыгарып көлде:

— Хо-хо-хоу-у-у... Ни өчен ат ырлыйммы? Шыны да белмисеңме? Хәзер әйтәм...

Көлгәндә аның тешләрен дә күреп алды Галимҗан. Аларның күбесе төшеп беткән шикелле. Калганнары — сап-сары. Күрәсең, беркайчан да агартылмаганнар. Ул шешәсендә бетеп барган аракысын кире чынаякка акрын гына койды да, тәмләп-тәмләп йотып, ипи кисәге белән суган кабып куйды. Аннан бераз торгач, ат пошкырган тавышлар чыгарып, ямьсез итеп төчкереп җибәрде. Өй эченә суган белән аракы катнашуыннан хасил булган имәнеч сасы ис таралды.

— Нигә ат ырлыйммы? Хәзер әйтәм. Сезнең ничә ат бар? Ә? Эндәшмисең. Пәчәму минем ат юк? Ә? Пәтәмүште мин ярлы. Бермәл шылай сезнең Алмачыварны чәлдермәк булдым. Җук... намыс җитмәде. Пәчәму? Пәтәмүште этиең, әниең яхшы кешеләр. Алма агачыннан җырак тәгәрәми ул. Шакирҗан да, син дә, башкалар да шылай миһербанлы-

дыр. Беләм бит мин сезне. Теге җылда атаең ачлыктан алып калды. Вечны онытасым җук. Ынытсам... сабакы булыйм... Вәт тәк. Мин алама кеше атын ырлыйм. Ырлагач, әле атнаун көн фарсит итәм. Пәтәмүште мин дә үземне атлы кеше дип пәнимәет итәм. Ат ырлаумы?.. Хи-хи... ха-ха... Аңа йөрәк кирәк. Сиртсы. Вәт тәк.

«Алып батыр»ның фәлсәфәсе күпмегә сузылган булыр иде — билгесез. Өйалдында Хәмдия абыстайның кәҗә белән сөйләшкәне ишетелде. «Мына шылай ул, мына шылай, җүнсез кешегә дә, җүнсез малга да көн җук бу дөнҗада, алама малны бәйләп тоталар, алама кешене таптап изәләр», — дип сөйләнә-сөйләнә керде ул. Керү белән, бер як кырыйда басып торган Галимҗанга игътибар итмәстән, «Алып батыр»га ташланды:

— Нигә син көпә-көндез минем өемдә аракы эчеп...

— Аракы түгел бу, Ак түти, көмешкә, теге ни... ызнакум чуаш Ычтапан бирде... Ишеген төзәткән өчен...

Ак түти, ниһаять, Галимҗанны күреп алды:

— Бәй, бәй, мына син агай, улым килгән ләбаса, күрми дә тырам, и-и-и... Нишләп?.. Нигә киләсе иттең?.. Кара, мына дигән җегет булып киткәнсең бит. Синең ише тәтәй җегет керә торган базмы соң бу... — дип сөйләнә-сөйләнә Галимҗанны кысып-кысып сөеп куйды Ак түти.

Галимҗан, ниһаять, инде кайчаннан бирле уч төбен кычытып торган көмешне Хәмдия абыстайга сузды.

— Әнкәй хәер җибәргән иде.

— Әй Ходаем, әле беркөн генә Хәсәнә абыстай үз кулы белән дә биргән иде бит инде, Шакирҗан белән Галимҗан Ырынбурга укырга китә, хәерле юл теләп, дога кыл, дигән иде.

— Без ул вакытта бара алмый калдык шул...

— Әйе, ишеттем...

— Бер-ике көннән китәбез.

Ак түти, көмешне алгач, «Алып батыр»га ташланды:

— И җүнсез, и имансыз, нишләп син ул «җыланыңны» мында алып килеп эчәсең, җәшер җәтрәк, ки күлмәгеңне...

«Алып батыр» калган көмешкәсен сәке астына яшерде дә почмакта яткан киндер күлмәген алып киде. Шуннан соң гына Хәмдия абыстай, дога кылып, Галимҗанга хәерле юл теләде:

— Барыр җулларыгызга фәрештәләр гөл сипсен, балакаем, Аллаһы Тәгалә тырмышның ачысын-кайгысын күрсәтмәсен, Ходай үзегезне җил-давылдан гел саклап тырсын!.. Амин!..

Галимҗан, саубуллашып, инде чыгып китәргә торганда, бер чибәр хатын килеп керде. Керде дә «Алып батыр»ны тиргәргә кереште:

— И дөнҗасын оныткан... и оятсыз... Тагын эчкән... Миннән качып эчә... Әллә сизмәс, диме... Эчсә... аның бер кашы сикерә башлый... Танавы җыерыла... Ана, күрдегезме?..

Галимҗан, бу чибәр хатын әйтмәсә дә, аның вакыт-вакыт бер кашын сикертеп, борынын җыерып-җыерып куйганлыгын хәтерләгән иде инде. Бу кыяфәт, бу ямьсез йөз, бу йонлы күкрәк аның күз алдында озак вакытлар котсызлык тамгасы булып торачак әле. Бу чибәр хатын аның хәләл җефете икәнлекне дә аңлап алды ул. Хатыны матур, чибәр. Өстендәге киндер күлмәге дә аның матурлыгына һич тә кара якмый. Ул әле, Галимҗан уйлаганча, артык чибәр дә түгелдер, бәлки. Әмма көләч йөзе, миһербанлы күз карашлары аны ифрат дәрәҗәдә сөйкемле итеп күрсәтә.

Сөйкемле хатын Галимҗанга да игътибар итте:

— Бу нинди тәти җегет суң әле?

Аңа Ак түти җавап бирде:

— Гыйрфан мулла улы Галимҗан бит. Хәер китергән.

Сөйкемле хатын Галимҗанга тутырып карады:

— Әйт әле, акыллым, бу җөнле күкрәк ат урлау белән мактанмадымы?

— Мактанды.

— Ни диде?

— Мин ат карагы, диде.

Сөйкемле хатын, көмеш тавышлар чыгарып, кычкырып көлеп җибәрде:

— Нинди ат карагы булсын. Кешенең энәсенә дә тими бит ул. Бервакыт төшендә ат урлаган да, авызын тутырып, шуны чын итеп сөйләп йөри. Аның әтисен «Алдакчы Айдар» дип йөреткәннәр. Алдауга килгәндә, мынысы биш өлеш арттырып җибәрә. Аңа Хөрмәтулла дигән матур исем кушканнар. Аннан соң Хөрмәйгә әйләнде. Хәзер инде Хәрти булып калды. Мына шышы сүзне ишетсәм, җөрәгем телгәләнә, күңелем җарсый, җир тишегенә керердәй булам. «Сугыш чукмары» дигән даны да бар. Тик... үзен дә изәләр. Дөнҗа шылай бит ул, Ак түти, әйт бәгъзе берәүгә авыр сүз, ул да сиңа әйтә; тукма берәүне, ул да сине тукмый; рәнҗет бер бахырны, ул да сине рәнҗетә. Мына шыны аңламый бу җөнле күкрәк, шыны аңламый. Һы, ат урлый җәнәсе дә. Аңа җөрәк кирәк. Ул синдә җук...

Тора-бара «Алып батыр»ның кем икәнлеген тәмам аңлады Галимҗан. Былтыр сабан туенда кинәт сугыш чыккан иде. Шуннан бервакыт халык арасында төрлечә кычкырыш китте:

— Хәрти килә, җәмәгать, Хәрти, юл бирегез.

— Мәгәр изә хәзер.

— Боламык ясый.

— Кемне яклар икән?
— Аның өчен барыбер.
— Арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит.
Хәрти килеп кенә керде дә сугыш мәйданына, көрәктәй куллары белән әле берсенә, әле икенчесенә чәпәргә кереште. Сугып җибәргәч, бәгъзе берсе биш-алты адым ераклыкка мәтәлеп барып төшә. Шулай «урды-урды» да, сугыш мәйданыннан чыгып, киң күкрәген алга киергән хәлдә, озак кына басып торды. Аннан, тирә-якка усал үгездәй бер карап алып, акрын гына атлап китеп барды.
Кемне яклаган? Кайсы якны? Ни өчен кергән сугыш мәйданына? Моны соңыннан шулай сөйләделәр. Ул, гомумән, берәүне дә якламаган. Кулына ирек бирүнең ике сәбәбе бар икән. Беренчесе. Болар, имеш, сугыша белми. Сугышулары хатын-кызның чәч йолкышуы кебек кенә. Ул, янәсе, ирләр сугышуының чын «сәнгатен» күрсәтә. Икенчесе. Сабантуй — күңел ачу мәйданы. Анда, шуны аңламыйча, әтәчләнеп йөрүнең бер кирәге дә юк. Нигә шуны төшендереп бирмиләр сабантуй ямен җибәреп йөрүче теләсә нинди әтрәкәләмгә? Моны Хәрти йодрык белән аңлатмакчы булган. Моннан болай сабантуй күркен җибәреп йөрмәсен бу кыл койрыклар, янәсе.
Янә шундый хәбәр йөрде колактан колакка: тегеләр, берләшеп алып, бер җаен туры китереп, Хәртинең үз измәсен дә ару гына изгәннәр, кабыргаларын сындырып, тешләрен коеп бетергәннәр.
Галимҗан бу хакта хәбәрдар иде. Әмма ул аның йөзен теге вакытта сабантуйда ныклап күрмәгән иде. Әле менә кендекәй кайтканчы, бу чибәр хатын килеп кергәнче, берникадәр сизенгән иде сизенүен. Димәк, бу «Алып батыр» дөреслекне йодрык белән исбат итәргә йөрүче бәндә булып чыкты.
Хатыны бик битәрли башлагач, торыр да чукмардай йодрыгын эшкә кушар кебек тоелган иде Галимҗанга. Ләкин киресенчә булды.
— Җарый, Мәликә чибәрем, сукмә инде, мин бит балалар күрмәсен, син күрмәсен өченгә мында килеп эчмәк булдым... Хәмдия түтинең барасы җире булганга... Ычтапан биргән көмешкә генә ул... Вәт кәк... Ә мин Ак түтинең күңелен ачыйм дип... гармунны да култык астына кыстырып килгәнием... Ачыланганчы... Лутчы бер җырлап җибәр... Мәликә җаным...
Моңа Ак түти каршы төште:
— Кит, исәрләнмә, көпә-көндез гармун уйнап, җырлап утырырга җарыйдыр шыл, ишетелсә, хәзер ыстараста җүгереп килеп җитер.
Хәртинең үз туксаны — туксан иде:
— Көндез гүпчи ишетелми ул. Ыстарастаның бездән җы-

рак тормаганын беләсең бит, Ак түти, шыңа күрә уйнарга да сиңа килдем. Ә мин әкрен-әкрен, сикен-сикен[1]...

Ул сәке астыннан үзенең кәшәкә йодрыгыннан әллә ни зур булмаган гармун тартып чыгарды да, җайлап кына каешын киеп алгач, башта бераз телләрен челтерәтеп торды. Аннан әле сандугач сайраган, әле кәккүк кычкырган, әле күгәрчен гөрләгән тавыш чыгара башлады. Шуннан, уйнавыннан туктап, шул тавышларны үзе үк чыгарырга тотынды: йә сандугач булып сайрый, йә күгәрчен булып гөрли, йә торна булып торкылдый. Мәликә түти аңа нindidер бер эчке җылылык, мөкиббәнлек, гыйззәтлелек белән карап тора. Ак түтинең дә йөзендә бая сизелер-сизелмәс кенә булган ачу чаткысы шундук сүнде. Ул да бөтен күңеле, йөрәге, шәфкатьле йөзе белән сандугачлар моңы, күгәрченнәр гөре, кәккүкләр моңы дөньясына кереп югалды. Галимҗан да шул ук дөньяда йөзде. Кем уйлаган шундый ямьсез, шөкәтсез бәндә күңелне сөендерүче булыр дип?

Хәзер инде Галимҗанның баздай караңгы, җиргә сеңгән бу өй эченнән һич тә чыгып китәсе килми иде. Бу «баз» аңа сандугачлар оясы, моң оясы, мөкатдәс бер урын булып тоела башлады. Аның алдында хәзер «Алып батыр» гына түгел, «Алтын батыр» утыра кебек. Аның нык тәэсирләнүен, самими ихласлык белән тыңлавын, кеше йөрәген аңлау сәләте барлыгын Ак түти янә бер мәртәбә ныклап аңлады. Аркасыннан сөеп куйды да:

— Тыңла, балам, тыңла, асылташ һәркемнең күңелендә бар ул, син шуларны хәзердән үк күрергә өйрән, — диде.

Әмма болары әле асылташның бер ярма бөртеге кадәресе генә булган икән. Чын асылташның зурысы үзе уйнап, үзе җырлый башлагач балкыды. Башта ул җырламый гына уйнады. Юк, аны җырламый уйный дип әйтеп тә булмыйдыр әле. Йөрәге җырлый аның. Гармун моңына кушылып, йөрәге кычкырып куя. Ниндидер таныш булмаган моңнар чыга. Ул моңнарда Зәңгәр чишмә чылтыравы да, Исәнбикә болынында сайраган меӊ төрле кошлар тавышы да, җилле көндә дулкынланган Кондызлы күл шавы да бар кебек. Шуннан ул моңнарга үзе дә кушылып җырлый башлады. Акрын, кычкырмый, йөрәк моңын чыгарып. Гармун моңы белән йөрәк моңы бергә кушылып агылды.

Зәңгәр чишмәкәйнең суын эчтем,
Суын эчтем йөрәк янганга;
Кайгырмагыз, дуслар, кайгырмагыз,
Гомеркәйләр бик аз калганга.

---

[1] Сикен-сикен — ишеттерми, бик акрын.

Бәй, тора-бара бу асылташка Мәликә түти күңелендәге асылташ килеп кушылды. Алар парлап җырлый башлады. Гармун да бик акрын, тавыш түгел, моң чыгарып уйный. Болар үзләре түгел, йөрәкләре җырлый. Әдәпсезләнеп авыз ачып, көчәнеп, тырышып җырлау юк. Авызлар ачылмый да кебек. Иреннәр генә азрак дерелдәп куйгандай итә. Кычкырып җырларга ярамаганны Галимҗан белә. Гармун уйнау да тыела. Нигә шулай икән ул? Бөтен табигать моңы кеше йөрәгендәге моң белән бәйләнгән. Шул моңны менә шушындый баз кебек өй эчендә яшереп яткыр, имеш.

Галимҗан, инде чыгып китәм дип торганда, ишектән уникe яшьләр чамасы бер кыз килеп керде. Галимҗан шундук аның боларның кызы икәнлекне аңлап алды. Чөнки кыз белән ана ике тамчы су кебек охшашлар.

— Инәкәй, әткәй, нигә кайтмыйсыз инде, бер кеше килде, ул сезне таптыра,— диде ул, өй эчендәгеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә әдәпле генә караш ташлап.

— Җарар, көтер әле, сезгә әллә кем килмәс,— диде Ак түти, сабыр булырга тырышып,— мына безгә дә кунак килгән бит әле, Мәдинә кызым, син аның кем икәнлеген белмисеңдер дәле: бумы... Галимҗан бу — Гыйрфан мулла улы, икегез бер көнне тудыгыз бит, син Галимҗаннан аз гына соңрак килдең бу фани дөнҗага, икегез дә минем балаларым буласыз, икегезгә дә иң әүвәл дөнҗа күзе күрсәтүче мин булам...

Галимҗан белән Мәдинә бер-берсенә җиңелчә генә карашып алдылар. Ак түтинең моңа чаклы да бу хакта әйткәне бар иде шул. Бер үк көнне сөлектәй чибәр ир баланы, җиләктәй матур кыз баланы кулыма алырга насыйп булды. Аллага шөкер, икесе дә тормыш чәчкәсе кебек, ди иде. Мәдинә әнисе кебек ак чибәр икән. Шундук Галимҗанның башына Акчәчкә бу дигән уй килде. Алар аз гына вакыт тын тордылар. Тынлыкны Акчәчкәнең әтисе бүлде:

— Галимҗан алданрак тугач, сиңә агай тиешле була инде, кызым, җәле, агаеңа бер җырлап күрсәт әле, әкрен генә, элекке кеүек җөрәк моңың белә, курыкма, оялма да, мында ят-чит кеше җук бит...

Шулай диде дә әлеге үзенең йодрыгы зурлык гармунын сайрата да башлады. Мәдинә, оялып-тартынып, һәрберсенә күз сирпеп алды. Аның бит очларына ниндидер алсулык йөгерде. Бу әлеге акчәчкә уртасындагы алсулыкны хәтерләтә иде. Ул җыр башларга озак кына дәртсенми торды. Әнисе шикелле чәтрәнләп килеп керсә дә, хәзер инде юаш болан баласына охшап калды. Ак түти аны кысып бер сөеп куйды да:

— Җә инде, кызым, җә, җалындырма. Кендекәең кушкач, һич кенә дә оялып торма,— диде.

Ак түтинең сүзләрен Мәдинәнең әнисе куәтләде:

— Әйе, тартынма, кызым, җырла, авыр булса, үзем дә кушылырмын; шул... мин өйрәткәннәрне җырла.

Җыр башларга Мәдинәнең кыюлыгы һаман җитми торды. Әнисе «җырла инде» дип янә бер мәртәбә ым каккач кына, күкрәк тутырып сулыш алып, акрын гына, үзен бик әдәпле тоткан хәлдә, җырлап җибәрде ул. Ике җыр җырлады Мәдинә:

Их, дусларым, сезгә әйтәм:
Яшь гомердән туймагыз;
Яшь гомернең чәчәкләрен
Вакыт җитми коймагыз.

Кара күзләр түзем була
Кайгылар күргәндә дә;
Кара күзем, иркә гөлем,
Онытмам үлгәндә дә.

Матур җырлады Мәдинә. Әнисенә кушылырга, ярдәм итәргә дә кирәк булмады. Әтисе, әнисе сыман һич көчәнми, ашыкмый, иркен тын белән җырлый. Чын мәгънәсендә Акчәчкә бу! Өстендәге ак киндер күлмәге аның ак йөзенә ярашып тора төсле. Ап-ак кар төсле ак ул күлмәк. Киндер икәнлеге дә беленми хәтта. Әнисенең карар күзгә үк алтын куллы икәнлеге сизелеп тора. Ат яхшысы — тездән, хатын яхшысы күздән билгеле, дигәнне ишеткәне бар Галимҗанның. Күз карашлары ук аның бик тере, булдыклы, сөйкемле икәнлеген сиздереп куя. Мәдинәнең башындагы ак яулыгы да ак нур бөркеп тора. Аркасына яткан ике озын толымы гына да күңелеңне сихерләрлек. Җырлаганда бит очларындагы әлеге алсулыклар янә куера төшә. Алар инде хәзер — хас та ахшамсафа гөле чәчкәсе. Галимҗан аларга әллә ни игътибар итмәскә тырышты. Чөнки кыз балага сөзеп карарга ярамаганлыкны аңлый ич инде ул. Шулай да матурлыктан карашны яшерү бик кыен икән. Ул матурлык бер карауда гына да күңел түреңә җылы нур булып сирпелә. Бу матурлыкны ташлап, Галимҗанның хәзер чыгып китәсе дә килми иде инде.

— Җә, җитәр, безне көтәләр, китик инде, гаепләмә, Ак түти, үзең дә барып утыр; үлән чәй, якты чырай дигәндәй, әллә ни булмаса да...— диде дә ата кеше, гармунын култык астына яшереп, кузгала да башлады.

Ак түти аз гына сабыр итәргә кушты.

— Чәй кайнатыйм, казан чәе булса да...

Мәлик моңа юл куймады:

— Җук инде, Ак түти, килгән кешене көттерү килешми...

Ак түтине нидер канәгатьләндерми иде:

— Бәй, булгач булсын дигәндәй, Мәдинә кызым, теге үзең чыгарган нине... шигырьне дә әйтеп бирәсең мәллә? Әйт, әйт, тартынма, оялма, Галимҗан ишетеп китсен әле.

Бу фикерне әнисе дә кабатлады:

— Әйе, Ак түти тели икән, әйтми чараң җук, кызым! Теге... җаз көне чыгарганын...

Мәдинә бер шигырь әйтеп көлдерде:

Көннәр ямьләнә,
Эпиләр тәмләнә;
Кояш югары,
Эпи юк әле.

Барысы да рәхәтләнеп бер көлеп алдылар. Аннан соң Галимҗан да, тегеләр дә кайтып китте. Ак түти, һәркайсына хәер-фатихасын биреп, бәхет-сәгадәт, җан тынычлыгы теләп калды.

* * *

Галимҗан акрын гына атлады. Моңсу да, ямансу да иде бу көз урталары көне. Кояш җәйге эсселеген бик азлап, мыскаллап кына киметә бара. Җәй көне ул алтын нурлар койса, хәзергесе көмеш аклыгы, тоныклык хәтерләтә. Дөнья, акрын-акрын, ашыкмый гына яшел чапанын салып, соргылт япма белән төренә. Озакламый бу соргылт төс тә җуелып юк булачак. Усал җилләр бермәл агачлардагы соңгы хәлсез сары яфракларны өзеп ыргытачак. Көзге яңгырлар. Пычрак юллар. Баткаклык. Беренче карлар. Салкынлык. Кышкы бураннар. Матурлык белән котсызлык гел шулай алышынып торамы? Алар тәңгәл дә яши бит әле. Авыл читендә балчык-саманнан өелгән вак-вак өйләр. Эче баз кебек. Бу төшләрдә гүя нindидер фаҗигый хәят ыңгыраша. Авыл уртасындагы өйләрнең күбесе балкып, гөлбакча эчендә кукраеп утыралар. Матурлык — ямьсезлек. Әллә матурлык эчендә дә ямьсезлек бармы? Киресенчә дә буламы? Ямьсезлек эчендә матурлык гәүһәрләре яшиме? Ак түтинең караңгы баз төсле ызбасы. Шуның эчендә ак күңелле кешеләр. Алар уйный, көлә, шаяра, җырлый. Хөрмәтулла — Хөрмәйгә, аннан Хөртигә әйләнгән. Ат карагы дигән даны бар икән. Ә үзе кешенең энәсенә дә тими, имеш. Сугыш чукмары булып йөри. Дөреслекне йодрык белән аңлатмак була. Эче тулы моң. Аның җыры, моңы тышкы ямьсезлегенә матурлык нуры булып каплана. Егет көче беләктә дә, йөрәктә дә, дип тә әйтәләр бит. Беләге, йөрәге, эчке матурлыгы, үткенлеге белән яулагандыр ул чибәр кыз мәхәббәтен. Монда да әллә шул капма-каршылык канунымы: бер чибәргә — бер ямьсез, бер яхшыга — бер яман...

Уйлар! Уйлар!.. Су буе. Дәрья буе. Дөнья буе. Шул дәрья-дөнья эчендә әлеге Акчәчкә елмаеп басып тора. Җыр. Моң. Шигырь. Әтисе, еш кына: «Халык күңеле — тирән дәрья»,— дигән сүзләрне әйтергә ярата бит. Алай дисәң, андый дәрья үз өй эчләрендә дә, үзләренең күңелләрендә дә бар ич. Үзләрендә бертөрле дәрья, тегеләрдә икенче төрле дәрьямы? Әтисе: «Тормыш — кара урман»,— дияргә дә ярата. Ниләр генә юк ул кара урманда. Бәй, менә сиңа кирәк булса, кара урман эчендә дә теге Акчәчкә балкып тора. Акчәчкә! Акчәчкә! Акчәчкә! Җырлый. Моңая. Елмая.

Галимҗан, борылып, килгән ягына карады. Анда Мәдинә-Акчәчкә кул болгап торадыр кебек тоелды. Их, ашкына-ашкына, тилерә-тилерә, очып-очып барасы иде дә озак-озак сөйләшеп утырасы, җырлатасы, бергә-бергә күңел ачасы иде. Ни бу? Авылда Галимҗанның бергә уйнап йөргән дуслары шактый. Дус эзләгәндә ул «бай», «ярлы» дигән төшенчәләрдән ерак булырга тырыша. Хәер, дусны эзләп йөреп булмый ич ул. Дуслык фикердәшлек белән, туганлык-кардәшлек белән, дигәнне дә ишеткәне бар. Йә уйнаганда, йә сөйләшкәндә, йә балык тотканда дуслашып китәсең. Апуш әнә Ак түти вә башка бәгъзе бер ярлылар кебек, шул тавык кетәге зурлык өйдә яши. Аның чибәрлеге дә юк. Өстендә даимән ямаулы киндер күлмәк белән киндер ыштан. Әмма күңеле матур аның. Алдаша белми. Үзен юкка башкалардан өстен куярга тырышмый. Авылда аннан да остарак балык тотучы юк. Әгәр бүген синең кармакка аз эләккән икән, ул инде үзенекен бүлеп бирергә әзер тора. Галимҗан аның белән әнә шул кешелеклелек сыйфатларын аңлап дус булды. Тик әле ул Акчәчәккә карата дуслык хисләренең кабынып китү сәбәбен генә аңлап бетерми. Ир бала белән кыз баланың бергә уйнап үсә торган гадәте бар анысы. Бусы аның бәләкәйрәк чакта була. Хәзер инде андый йөгәнсез чаклар үткән. Акылыңны да, хисеңне дә йөгәнләр вакыт җиткән. Бу яшьтә инде ир бала белән кыз бала дуслыгына чик куеладыр. Акчәчәккә тартылган күңел әллә гыйшык-мәхәббәт чаткысының дөрли башлавымы? Гыйшыктан җан тынмас, дуслыктан җан тыныч булыр, дигәнне дә ишеткәне бар ич аның. Апуш янында җан тыныч. Ә бу Акчәчкә җанга ялкын сипте. Нәрсә бу? Моны ничек аңларга? Бер-бер кодрәтме бу? Мәхәббәт очкынымы? Әле очкыны да көйдерә. Ялкынга әйләнсә нишләрсең? Әмма үзе бу хакта уйларга да курыкты. Андый хис-тойгының күңелендә тиз кабынып китүенә аптырады. Әллә аңарда хатын-кызга хас йомшаклык та бармы? Ул бит матурлыкны да ярата. Айлы кичләрдә, алсу таңнарда, җәйге моңсу көннәрдә хыялый булу дәрәҗәсенә җитә. Чәчкәгә, гөлгә, йолдызларга гына түгел, матур ташларга да

хисләнеп карап тора. Бу мөнәсәбәт аның ир-егетлек табигатен кичерәйтмиме?

Шундый уйлар давылы эчендә кайтып керде ул өйгә. Ничек итеп кендек әбисе Ак түтигә хәер бирүе, әлеге Хөрмәтулладан Хәртигә әверелгән кеше һәм аның гаиләсе белән очрашуы турында әнисенә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Ул кеше Ак түтинең туганнан туган энесе була, бик усал нәстәкәй инде, сиңа алай-болай бәйләнмәдеме соң? — дип, Хәсәнә абыстай күңелендәге шик-шөбһәсен дә сиздереп куйды. Галимҗан мондый очракта сүзне су буе сузарга яратмый иде:

— Юк,— дип, бер сүз белән генә җавап кайтарды ул.

Шулай да ананың күңелендә: «Нидер яшерә, юкка җибәргәнмен баланы, үзем генә барасым калган»,— дигән уй кайнашты. Аннан соң: «Хәер, һәммәсен күреп-белеп яшәсен, акны карадан аерырга өйрәнсен, йомырка эчендәге чебеш түгел лә инде ул хәзер»,— дигән нәтиҗә-сөземтә ясады.

## IV

Хәрти сарык урлаган...

Бу хәбәр бөтен авылны тетрәндерде. Иң әүвәл ул ыстараста Тәхлискә мәгълүм булды. Мөбахис мәзин килде дә аңа:

— Тәхлис туган, күз белән каш арасында кара сарыгым юк булды. Эзләмәгән җир калмады. Өч көн инде ут йотабыз. Үгез дәүмәллеге иде бит югыйсә. Сугымга дип тота идек,— диде.

Ыстараста Тәхлис сарык эзләү мәшәкатен башта үз җилкәсенә алмаска тырышты:

— Соң, мәзин абзый, мин бит гавам халкы арасындагы низагларны булдырмау, тәртип саклау өчен сайлап куелган ыстараста, югалган малны эзләү-табу минем вазифам түгел лә инде.

— Анысы шулай. Моны гына аңларлык баш бар бездә, Аллага шөкер. Әгәр ул малны беркемсәсе чәлдергән булса, бу гавам халкы йөзенә кара ягу түгелмени, ә? Эндәшмисең? Бу бит иманга, дингә, бәндәләрнең ак күңеленә хилафлык кылу. Әллә бу низаг тудырмыймы? Хак Тәгалә насыйп иткән иманыбызга кара ягучыларны, урлашучыларны тәртип тәртәсенә кертү, аларга тиешле чара күрү ыстараста эше түгелме? Зур гөнаһ белән шакшы булмас борын, бу бәндәне һич кичекмәстән гакылга утырту лаземдер.

— Тел төбеңне аңладым, мәзин абзый: димәк ки, сарыгыңны бер явызы урлаган булып чыга. Кемгә йөгерә күңелең? Әйт ярып кына. Нигә уратасың? Нигә сузасың?

— Син аны үзең дә белергә тиеш.

— Мин әүлия түгел лә инде.

— Аяк өсте йоклап йөрсәң, ыстарасталыгыңнан да язарсың.

Мәзин абзыйның бу сүзләре Тәхлисне утлы табага бастырды. Кечкенә буйлы ул ыстараста Тәхлис. Шуңа күрә Бүксә Тәхлис дип тә йөртәләр. Әлифне таяк дип белмәсә дә, ике бозауга кибәк аерып сала алмаса да, үзен белдекле, башкалардан өстен, зиһенле итеп күрсәтергә тырыша. Әлбәттә, аның таш ярырдай тавышы бар. Ул тавыш, гәрчә юньсез кәҗәнекедәй чәрелдәп чыкса да, вакыт-вакыт йомшак сөякле кешеләрнең тез буыннарын ару гына калтырата ала. Кипкән балыкныкыдай чандыр гәүдәсе аңа һич тә җилдәй җитез йөрергә комачауламый. Баскан җирендә ут чыгара, дип тә әйтәләр аның хакында. Башы аның Хәрти йодрыгы зурлыгында гына. Борыны борчак кадәр генә. Тар маңгае ике илледән һич тә артык булмас. Кешеләрне куркытырга кирәк булганда, ут чәчеп торган соры күзләрен акайтып карый торган гадәте дә бар. Акылы юк башның маңгаенда акаеп торган чәркәдәй күз булыр, дигән мәкаль әйтерсең аның өчен чыгарылган. Ничек кенә булмасын, түрәләр алдында аның үзен мөмтаз зат итеп күрсәтә белү сәпәрәйлеге дә бар. Ыстараста дәрәҗәсен алуда шушы сыйфатлар да ярдәм иткәндер. Түрәләр тегермәненә су коя белсәң, алар сине коры итмиләр лә инде. Әмма түрәләр бик усал. Җайларына сыпырта белмәсәң, җидееллык шөпшә урынына тешләргә генә торалар. Әле менә мәзин абзыйның: «Аяк өсте йоклап йөрсәң, ыстарасталыгыңнан да язарсың», — дигән сүзләре дә аның бәләкәй башындагы акыл казанына бер бөртек агу тамызгандай тоелды. Аның күңеле Ат карагы Хәртигә йөгергән иде инде. Шулай да аны әйтергә тиз генә теле әйләнмәде. Кылган гамәлең нахакка чыкса, яшәү әмәлең җимерелде дигән сүз. Шуңа күрә «каракның» кем икәнлеген тәгаен генә әйтергә ашыкмады ул. Әмма хәзер, мәзин абзый шөпшәдәй тешләп алгач, уй җебен һаман җилем урынына сузып маташмаска булды ул.

— Үзегезгә мәгълүм инде, мәзин абзый, Солтанморатта Ат карагы Хәрти яши, тикшерүне шуннан башларга кирәк булыр; һич тә нәүмиз булмагыз, борчылмагыз, минем каты куллылыкны беләсез, сарыгыгызны таптырмый калмам, — диде.

Мәзин абзый бу җавапка ифрат канәгать иде:

— Менә бу сүзләрең синең алтын бәрабәрендә, күрсәт егетлегеңне, түләт сарыгымны шул ристаннан, шунда белербез дәхи дә кем икәнлегеңне, — диде.

* * *

Бу сөйләшү әлеге Хәмдия абыстай өендә аз гына вакыт эчендә күңел ачып, хозурланып, дөнья мәшәкатьләреннән бераз аерылып торган чакка туры килде. Мәдинә-Акчәчкә кемдер килү турында хәбәр иткәч, аның ыстараста булуы хакында берәү дә уйламаган иде. Ә инде Хәрти кайтканчы, барын да тикшереп, ыстараста сарыкны фәкать ул урлау турындагы мөһерне салып та куйды. Чөнки күршедәге Хәмәтдин карт кичә бу ызбадан ит исе аңкуы турында әйтте. Әмма моңа гына ышанып бетмәде әле ыстараста. Мондый четерекле мәсьәләләрне хәл итү өчен мәгълүм бер мисал булу лазем. Шуңа күрә Хәртинең ызбасына килергә мәҗбүр булды ул. Кызы Мәдинәне әтисен эзләп алып кайтырга җибәргәч, бөтен дөньясын бер итеп тикшереп чыкты. Ихатада сарык кабыргасы сөяге табылгач, ул инде үзен иң оста шымчыларның да остасы икәнлеген раслый белүче һөнәрмәнд дип уйлады. Моннан да артык дәлилнең булуы мөмкин түгел. Шушы мәсьәлә ачыкланып, башкача бу хакта баш ватып маташуның артык булуы беленгәч, сарыкны Хәрти урлаганлыгы бермәбер ачыкланды да куйды. Мәзиннең сарыгын Хәрти урлау турындагы яман хәбәр капыл бөтен авылга кара канат җәйде. Ул хәбәр колактан колакка, йөрәктән йөрәккә усал-ярсу җил булып кагылып үтте. «Ат урлавы җитмәгән, инде сарыкка керешкән», «Ул зобанидан бөтен этлекне көтеп була», «Иманын йоткан гыйфрит», «Авылдан әллә кайчан сөрергә кирәк иде аны» кебек сүзләр йөрде. «И Ходаем, нахак кына була күрмәсен иде инде», «Ул да адәм баласы лабаса», «Чит җирләрдә йөреп бозылып бетүендә кем гаепле» дип, ихлас, хакимәнә борчылып фикер йөртүчеләр дә күп булды. Хәлбуки Хәрти соңгы чиктә сарык урлаучы дип кабул ителде. Бу хәбәр бөтен авылга кара сөрем булып сибелде.

* * *

Бу кара сөрем, җанлы-гәүдәле кеше сыйфатында, Гыйрфан муллаларның да ишеген бәреп керде. Ни гаҗәп, инде сәфәр чыгыйк дисәләр, аяк астыннан бер кара бәла тешләрен ыржайтып янә башын күтәрә. Ырынбурга китәргә ат җигелгән иде. Хәрти турындагы хәбәрне ишеткәч, ук кебек атылып, Галимҗан ишекне бәреп чыгып китте. Урамга ташланса, ни күзе белән күрсен, Хәртине ат койрыгына тагып сөйрәтәләр иде. Мондый әкәмәтләрне Галимҗанның ишеткәне бар инде. Урлашучыга халык «урам хөкеме» ясый. Хөкем ителүчене ат койрыгына тагып йөртәләр. Имеш, башкаларга сабак булсын. Гарәп илләрендә әнә кеше әйберенә тигәннең кулын чабып өзәләр икән. Мондый «халык хөкеме» башка илләр-

дә дә бар, ди. Бездә исә ат койрыгына тагып җәфалыйлар. Әлбәттә, бу хөкемне теләсә кем күтәрә алмый. Җисмани яктан йомшак булган бәгъзе берәү шундук җан бирә. Кайсыберсе рухи яктан хурланып харап итә үзен. Хәрти белән ни булыр? Ул, билгеле, гайрәтле кеше. Үзенең җисмани вә рухи көчен исбат итә алыр. Әнә ничек бара ул. Шәп-шәрә тәне суелып-суелып канга тузган. Авыртудан сакланыр өчендер инде, ул даими рәвештә йомгак шикелле әйләнә-әйләнә, тәгәри-тәгәри барырга тырыша. Әмма аны булдыруның да читен яклары күптер. Чөнки кулы артка каерып бәйләнгән. Шулай булмаса ул әле тәнен ышкылып канатудан саклап, куллары белән дә берникадәр хәрәкәт итәр иде. Тик ул бу мөмкинчелектән дә мәхрүм. Ләкин «аю үлсә, теше кала» дигән кыяфәт күрсәтеп, ул әле үзенең авыр хәлен аслан сиздермәскә тырыша. Берара Галимҗан аның елмайганын күреп калды хәтта. Монысы: «Их, сез, кешеләр, бер-берегездән курыкмасагыз, Алладан оялыр идегез азрак», — дигәнне аңлата иде шикелле.

Галимҗан, билгеле, Хәртине мондый мөшкел хәлгә төшерү өчен күпме кеше кирәк булганын яхшы аңлап алды. Теге вакытта сабантуйда унлап сугыш чукмарын чәпәп-чәпәп җибәргәнен искә алганда, бу пәһлеванны сузып салыр өчен кимендә егерме адәми зат кирәк булгандыр. Ничек кенә булмасын, ат койрыгына тагылган Хәрти көлә-көлә күз алдыннан юк булды. Галимҗан күңелендә тирән кичереш, канлы яра торып калды.

Җигелгән ат турында бөтенләй онытты ул. Хәзер аңа югалган сарыкны эзләргә, табарга кирәк иде. Иманы камил, бу Хөрмәтулла абзый эше түгел. Кем белән эзләргә югалган кара сарыкны? Моңа Шакирҗан риза булмаячак. Чөнки аларның бар белгәне тизрәк Ырынбурга укырга китү. Ярып сызгыру остасы Мохтарга ым кагаргамы? Ул да ышанычсыз кебек. Дус өчен йөрәген өзеп бирергә әзер торучы Апуш дусты янына йөгерде ул. Апуш — ярлы кеше баласы. Әлеге шул тавык кетәге зурлыгы ызбада унлап кеше мыжылдашып яши. Бергә балыкка, җиләккә, кузгалакка йөргән чаклары булды. Әлбәттә, Апушка икмәк, сумса, ит тә тәкъдим итә иде Галимҗан. Тик Апуш ярлы тәкәббер булып калды шикелле. Чөнки күп вакыт Галимҗанның ярдәм кулы сузуын кабул итмәде. Син, туганкай, Галимҗан, кешене түбәнсетмә, аны икмәк кисәге белән генә алдап булмый, ул тамакка сатыла торган зат түгел, дуслыкны андый вак-төяк алдаулар белән вакламыйк дип уйлады булса кирәк. Әле менә, вакыйганы бәйнә-бәйнә сөйләп биреп, сарыкны табарга кирәклек турында әйткәч, Апуш, Галимҗанның бу тәвәккәллеге өчен ифрат шатланып, кем әйтмешли, башы-аягы белән ризалашты.

— Мин дә шулай уйлыйм, Галимҗан, ул сарык берәр чокырга төшеп чыгалмый ятадыр әле, Ат карагы сарык урлау кебек вак-төяк белән маташамы, — диде.

* * *

Бу вакытта Гыйрфан мулла өендә буран купты, давыл-гарасат котырынып, һәркайсының йөрәк-күңелен дер селкетте. Ат җигелгән. Пар ат. Тарантаска түгел, мең потлы дию пәрие утырса да, тәгәрмәчләре аз гына да ыңгырашмаслык нык арбага җикте ул пар атын. Чөнки ни дисәң дә, дүрт йөз чакрым чамасы юлга чыга. Көненә йөз чакрымлапны үтсәң, дүрт тәүлек мәшәкать дигән сүз бу. Кайтуга да шул чама кирәк. Тегендә — Ырынбурда — күпме торасың бит әле. Аның анысы бер Ходайның үзенә генә мәгълүм. Димәк ки, җиңелчә генә исәпләгәндә дә, ким дигәндә, атларга ун көнлек азык кирәк. Печәнен, солысын, тегесен-монысын кичтән үк төяп куйганнар иде. Шуның өстенә балаларның кирәк-яраклары, юлда гына түгел, тегендә баргач та әле ашарга тиешле ризыклары... — барысы шул бер тимер арбага җайлаштырылды. Инде кыласы догасын кылып, ак фәрештәләр юлга ак җәймә җәюне теләп, кузгалырга торганда, күз ачып күз йомган мизгелдә юк булды Галимҗан. Ай күрде, кояш алды, дигән кебек булды бу. Кая китте? Җир тишегенә кердеме? Гарше көрсигә күтәрелдеме? Йа Хода! Бала тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә, дигәне шушыдыр инде.

Башта Гыйрфан мулла бу хәлне соңгы вакытта үзенең йомшарып китү сәбәбенә сылтады. Матчага бер карап алырга да онытмады. Әмма анда теге «тәрбия коралы» юк иде шул. Әлбәттә, булган хәлдә дә ул аңа үрелмәс иде инде. Чөнки мөгаллим Сәеткә дә андый ахмаклык белән вакланмаска киңәш итте бит.

Хәрти сарык урлаган, имеш. Соң, андый хәбәрләр даими рәвештә ишетелеп тора лабаса. Галимҗанның ни кысылышы бар анда? Нигә яшен утыдай чыгып чапты шул хәбәрне ишетү белән? Каракны ат койрыгына тагып үлгәнче йөртү дә яңалык түгел. Шуны күрү өчен җан атамы?

Әлбәттә, аның каты куллы ата була белү шөһрәте әле аз гына да йомшамаган. Бармаклар да тигез булмаган кебек, балаларның холык-фигыле дә бердәй түгел икән шул. Һәрберсенең күңел кылына үзенчә чиртә белергә кирәктер ул. Нигә менә әле Шакирҗан чыгып чапмады да, Галимҗан күз белән каш арасында юк булды? Моның сәбәбен ахыр чиктә остабикәсенең артык дәрәҗәдә сабыр табигатьле булуына, балаларны кирәгеннән артык назлап-иркәләп үстерүенә китереп бәйләде.

— Син, остабикә, Галимҗанны артык очындырып, күз өстендәге каш итеп үстердең, нәтиҗәдә ул кем булып чыкты, — дип шелтәләде.

Хәсәнә абыстайга бу сүзләрне ишетү бик кыен иде. Бала тәрбияләүдә аның үз өслүбе бар. Бу ата-ана каныннан ук килә. Ул инде аның акыл-хыялына, хис-тойгысына, йөрәк тамырларына, бөтен тән күзәнәкләренә сеңешкән. Ул сүгү ысулыннан ерак тора. Моны мулласы яхшы белә ич инде. Нишләп әле менә балалардагы китек-митек, кырлы-мырлы, кара якларны аңа гына аударды да куйды?

— Минем ызгыш яратмаганлыгымны беләсең ич инде, атасы, бу миңа Ходай Тәгаләдән бирелгән сыйфаттыр. Галимҗан — үз иманына тугрылыклы. Бәндәләрне үз иманыннан читләштерүнең аны юк итү икәнлекне беләсең лә инде. Әле дә ул бер дә юкка торып йөгермәгәндер. Бер сәбәбе бардыр аның. Хәзергә ачуланышмыйк, тузынмый торыйк. Йомгакның очы табылгач аңлашылыр.

Ата кеше кызды да китте:

— Һм... һм... эһһем... һаман бутлый, һаман ефәккә урау ягында...

Шуннан ул Шакирҗанга җикеренде:

— Нигә син, пошмас җан, балтасы суга төшкән кеше кебек бәлтерәп торасың, ә? Бар, эзлә Галимҗанны, тапмый кайтма, күземә күренәсе булма, ишетсен колагың.

Атаның бөркет күзләре почмактарак басып торган Нәгыймәне дә эзләп тапты:

— Син нигә мәлҗедең әле, Нәгыймә, нигә эреп төштең, бар җәтрәк, эзләш Галимҗанны, җир тишегенә кермәгәндер бит, илаһым, уф!..

Нәгыймә белән Шакирҗан чыгып киткәч, Гыйрфан мулла ишекле-түрле йөреп алды, кулындагы еландай бөгәрләнеп торган каеш чыбыркысын почмакка атып, остабикәсенә акаеп карады. Акайган күздә акыл булмый, дигәнне ул үзе күптән белә. Монда ананың гына гаепле түгел икәнлеген дә аңлый. Бала тәрбияләү өчен каты куллы ата, матур күңелле ана кирәклек инде көн кебек ачык. Ходай Тәгалә аларга бусын да биргән ләбаса. Ләкин дә һәр адымда салулау, һәр адымда чокыр-чакыр, илаһым!..

Йомшак күңелле остабикәсе аны һәрвакыттагыча тынычландырырга тырышты:

— Атасы, юлга чыкканда болай авыр хәлдә булу һич кенә дә килешми ләбаса, тынычлан әле, Ходай кушмаган эш булмас, Алладан сабырлык сора, — диде.

Сабыр гына, мөлаем генә сөйләшсә дә, абыстайның үз күңелендә дә борчылу уты дөрли иде. Тик ул аны сиздермәскә генә тырыша. Бала тәрбияләүдә булган үз өслүбен сөйли:

— Бәгъзе берчак ахмаклыкта да акыл була, атасы; һәй, бу хакта сиңа сөйлисе бармы, син бит миңа караганда мең кәррә мөмтаз, теләсә нигә үткер; Галимҗанның бу акылсызлыгында бер акыллылык булмый калмас, менә күрерсең, — диде.

* * *

Барлык урамнарда шулай ат койрыгына таккан килеш йөртә-йөртә, инде тәмам эштән чыгып туктагач, авырлыкны зәһәр елмаю белән капларга тырышу галәмәте дә сүнгәч, Хәртине Нәҗметдин байның салкын келәте эченә китереп ыргыттылар да өстеннән бозау зурлыгындагы йозак белән бикләп куйдылар. Әле авыл халкының урам хөкеме булмаган икән. Әйткәннәр, имеш, Хәртигә:

— Әгәр сарык урлавыңны танмасаң, барысын да дөрес сөйләсәң, Мөбахис мәзингә сарык хакын бишләтә түләргә сүз бирсәң, коткарабыз сине, — дигәннәр.

Хәрти барыннан да баш тарткан.

— Мөбахис мәзиннең теге вакытта, моннан биш ел элек булса кирәк, аты югалган иде, аны мин урлап саттым, ә сарыгына тимәдем, мине Ат карагы дип хөкем итегез, — дигән, ди.

Шуннан егерме кеше ябырылып, Хәртине тукмап ташлаганнар да, ат койрыгына тагып, «кәмит» ясамак булганнар. Хәзер Хәрти яшәү белән үлем арасында яр башына ыргытылган балыктай үрсәләнеп ята, имеш. Урам авызы киң вә тирән. Җәһәннәм казаны зурлыгы бар. Анда мең имеш-мимешне, мең юк-барны, мең гайбәтне салып кайнатып була. Иртән бу казанга чебен зурлыгы имеш-мимеш салсаң, кичен ул фил дәүмәллегенә җитеп кайнарга тотына.

Хәрти турындагы имеш-мимеш тә, чебеннән филгә әверелеп, колактан колакка сөйләнелеп, Гыйрфан мулла гаиләсенең дә өй эченә тәрәзәсен чатнатып ватып килеп керде. Нәгыймә белән Шакирҗан Галимҗанны тапмый кайттылар. Шуннан ата кеше Шакирҗанның үзен генә утыртып алып китмәк булды. Ләкин бу уеннан да кире кайтты. Үзен-үзе кая куярга белмичә, башын ташка бәрердәй булып үрсәләнде-үрсәләнде дә, бер мизгелдә мең төрле шомлы уйларны башыннан кичереп, пар атны тугарып ташлады. Өй эчендә авыр, куркыныч, коточкыч тынлык урнашты. Ата кешенең йөзе кара көйгән иде. Ул инде хәзер нинди дә булса сүз әйтүне иләккә су салу кебек кенә күрә башлады. Сезгә әйтсәң ни, җилгә әйтсәң ни дигәнрәк төс белән йөрде. Шакирҗан белән Нәгыймә аның гаепләү карашыннанераграк булырга тырышты. Хәсәнә абыстайга да кыен иде. Галимҗан өйгә гаиләнең әнә шулай ифрат авыр сулаган вакытында, кояш

баер-баемас торган мәлдә кайтып керде. Апуш белән икәүләп көне буе сарык эзләсәләр дә, алар аны таба алмадылар.

— Кайда йөрдең?! — дип каршылады аны әтисе.

Галимҗан тиз генә җавап бирмәде. Киң маңгаен киереп, зур колакларын куянныкыдай торгызып, кара күзләрен чекерәйтеп карап тик торды. Анда курку-өркү галәмәте юк иде. Аның болай сугышта җиңеп чыккан солдаттай торуы ата күңелен мең кәррә ярсытып кына җибәрде. Ул соравын кабатларга мәҗбүр булды:

— Кайда йөрдең, диләр?

Сарык эзләүне әйтмәде ул. Әгәр инде тапкан булса, бер кешене үлем җәзасыннан коткарып калырлык кыюлык, каһарманлык, батырлык эшләсә, көне буе ашамый-эчми Апуш белән бөтен тирә-якны айкап йөрүен аслан яшермәс иде. Хәзер инде ул — юкны бушка әйләндереп йөрүче. Әтисе андый кешеләрне яратмый. Балаларының да көндез далада җил куып, кичен авызлары белән йолдыз чүпләп йөрүен һич теләми. Галимҗан хәзер әтисенең бу сыйфатына ихлас күңелдән нык ышана. Әтисенең алдашырга яратмаганлыгы да аңа биш бармагы кебек мәгълүм инде. Шуңа күрә менә хәзер гадел холыклы әтисен алдау аның өчен иман белән сату итү шикеллерәк тоелды. Аның сарык эзләп йөрүе Хөрмәтулла абзыйны үлем җәзасыннан коткару өчен ич. Бәс, шулай булгач, шул аянычлы язмыш тирәсенә бәйләнгән сүз әйтергә кирәк. Бусы инде һич тә алдашу булмас.

— Без Хөрмәтулла абзыйны карап йөрдек,— диде ул.

Ата кеше тагын да ныграк кызып китте:

— Ниен карыйсың аның? Урлаганмы сарыкны? Урлаган. Безсез дә хәл итәрләр...

— Сарыкны ул урламаган.

— Ә кем?

— Белмим.

— Уф, тиле малай. Синең аркаңда сәфәр чыга алмый калдык.

— Мин бармыйм Ырынбурга.

— Ә?!

Ата кешенең әйтәсе сүзләре бугазына таш булып утырды. Ул таш хәтта тынын буды. Шул ташны төкереп ташлау нияте белән булса кирәк, ниндидер яманлык эшләп куюдан да шикләнеп, тышка чыгып китте ул.

Бу ярсулы мизгелләрне үткәрү ана өчен дә җиңелдән булмады. Галимҗанны эчке бүлмәгә алып кереп, аның белән үзе генә, күзгә-күз текәшеп, йөрәкне йөрәккә куешып сөйләшергә булды.

— Улым, хәзер чынын әйт инде, бая әтиең сораганда, дөрес җаваптан курыкканлыгыңны күңелем сизеп торды. Әти-

еңнән кайчак нидер яшерсәң дә, минем алда син гел генә ихлас булдың бит. Бу сыйфатыңны киләчәктә дә югалтма, күз нурым!

Галимҗан дөресен сөйләп бирде. Шунда Хәсәнә абыстай үз өслүбенең өстен икәнлегенә янә бер кат ышанды. Курыккан бала йөрәген ата-анага беркайчан да ачмый.

* * *

Кичен Гыйрфан мулла янына Мөбахис мәзин килде. Әлеге югалган сарыгын урлаучыга тәмам бер чара күрү өчен сөйләшергә. Дөрес, алар арасында беркайчан да мөкиббанә дуслык, халык, ил язмышы турында гәпләшкәндә фикер уртаклыгы булмады. Гыйрфан мулла, фикер алышканда, ык-мык итүне, кылдый-былдый мантыйк белән сүз йөртүне, алдак-молдакны җене сөйми. Ул турыга ярырга, маңгайга бәреп-чәпәп сөйләшергә, дөреслекне мөгезеннән тотып алып бәхәсләшергә ярата. Бу сыйфаты аның картинәсеннән, әтисеннән үк килә. Бу үзенчәлеге үзен белгән бөтен тирә-як кешеләре күңеленә илаһи бер якты нур булып сибелгән. Шуңа күрә җыеннарда, урам хөкеме вакытында теге яки бу авыр, четерекле, җитди, бәхәсле мәсьәләне чишкәндә, хәлиткеч соңгы сүз аңа бирелә. Аның сүзе инде теләсә нинди җилгә бөгелгән тал чыбыгы түгел. Аның сүзе — давылларга бирешми торган горур имән белән бер. Тимерләнгән тамырлары Җир-Ананың тирән йөрәгенә киткән мәһабәт-гаярь имәнне мең адәми зат этеп аудара алмаган кебек, Гыйрфан мулланың көчле, иман мантыйгы белән әйтелгән сүзләрен бөтен бер җәмәгатьчелек егып сала алмый. Гыйрфан мулла әйтте — бетте.

Мөбахис мәзин белән Гыйрфан мулла Троицк шәһәрендәге мәдрәсәдә мөдәррис булып эшләгән вакыттан бирле таныш. Беренче ел укуга алганда, ул аны энә күзеннән үткәрүче, нечкә иләктән иләүче дә булды. Ул вакытта Гыйрфан аны яратмады түгел. Исеме дә җисеменә туры килеп тора. Мөбахис — бәхәс итүче, сүз көрәштерүче дигән мәгънәдә. Гыйрфан мөдәррис берничә сорау биреп карагач, гәрчә төпле җавап булмаса да, аның бәхәскә төшүе, сүз көрәштерүе начар тәэсир калдырмады. Тирәнрәк уйласаң, мантыйк дигәннәре шул бәхәскә, капма-каршы фикерләрне ача белүгә корылган бит. Җитмәсә, Мөбахис мәзәк сөйләп, көлдереп тә алды. Монысы да аны мәдрәсәгә кабул итүчеләрнең күңеленә хуш килде. Ә инде укый башлагач, аның катлы-катлы кәбестә шикелле икәнлеге дә ачыкланды. Кирәк икән, ул үзен авыру хәленә куя ала. Хәсрәтләнә белә. Ул вакытта яшь Гыйрфан боларның һәммәсен шәкертнең җитди бер сәләте дип карады. Теләсә нинди сыйфат-халәткә керә белү

һәркем кулыннан килми ич. Моңсу, ямансу, боеклык күләгәләре тулы шәкертләр күңелен аз гына булса да җанландыру, дәртләндерү өчен, әлбәттә, Мөбахис кебек шаян табигатьле затлар да кирәк.

Бермәл алар аерылышты. Укуын тәмамлагач, Мөбахис икенче бер мәдрәсәдә пишкадәм булып торды. Гыйрфан хәлфә өйләнеп, туган авылы Солтанморатка кайтты. Ә инде Мөбахис озак вакытлар диңгездәге йомычка хәлендәрәк булды. Дулкыннар аның белән теләсә ничек шаярды. Бер җирдә дә рәтле урын таба алмагач, борын төртер чамасы булмагач, киңәшкә, дөресрәге, ярдәм сорап, элекке өлкән хәлфәсе Гыйрфан мулла янына килде ул. Башта Солтанморатта бер генә мәчет иде. Гыйрфан тиздән өч мәхәлләгә өч мәчет булачакны әйтте. Ахун да, ишан да, муллалар да, мәзиннәр дә кирәклек көн кебек ачык иде. Мөбахискә ул Солтанморатка мәзин булып килергә киңәш бирде.

Элекке хәлфәсенең болай хөрмәт кылып чакыруына ул нык рәхмәт әйтте.

— Гомерем буе тугрылыклы колың булырмын, мулла абзый, бу сүзләремне Аллаһы Тәгалә үзе ишетсен, фәрештәләр ак күңелеңә язып куйсын, иманым белән ант итәм, — дигән иде ул чакта Мөбахис әфәнде.

— Син алай «кол» дигән сүзләр белән шаярма да, сату да итмә, Мөбахис туган, минем холкым-фигылемне Троицкидан үк беләсең, шәт, иштә бәндә баласына изгелекне аяк табанымны ялату өчен кылмыйм, андый гадәтем юк, — диде Гыйрфан мулла. Ул аңа гаиләсе белән күчеп килү, тәмам урнашу өчен бөтен көчен куйды.

Мөбахис мәзин башта үзен бик ипле, итагатьле, миһербанлы, яхшы кешеләргә хас сыйфатлар дәрәҗәсендә тотты. Моңлы итеп азан әйтте, кешеләр белән бөгелеп-сыгылып, вакытвакыт уң кулын йөрәгенә куеп исәнләшүе, кечелекле булырга тырышуы авыл халкы арасында аны тиз арада абруйлы диндар итте. Авылда шундый диндарларның берләшүенә Гыйрфан мулла ифрат шат иде. Әмма ул шатлыкны күбрәк эчтә тотты, аның үзенә сиздермәскә тырышты. Чөнки мактасаң, Мөбахис мәзиннең бик тиз очынып китеп, үзен әллә кемгә куеп, масаеп йөри торган гадәте бар. Аның бу кыланышын Гыйрфан мулла Троицкта чактан бирле белә. Шулай да Гыйрфан мулла кешегә бәяне андый китек-митек, вак-төяк, ул кадәр әһәмияте булмаган үзенчәлек-сыйфатлар буенча гына бирми. Аның өчен адәм баласының иң әүвәл әле аны бизи торган кешелеклелек сыйфаты булу шарт. Монысы — һәркем өчен кояш нуры балкышы. Кыяфәтендә, рухи дөньяңда, эчке халәтеңдә бар икән караңгы яклар, әнә шул нур балкышы аларны башкаларга күрсәтми, яшереп, каплап

торырга мөмкин. Әлбәттә, андый ук нур балкышы күрмәде Гыйрфан мулла Мөбахис диндарда. Әмма ләкин бизмәнгә салып үлчәсәң, кара төергә караганда, ак якларының авыррак тартачагына ышанды.

Шулай булып чыкты да. Тиздән Мөбахис мәзиннең хыялында адәмчә, матур, күркәм яшәү ялкыны барлык ачыкланды. Оҗмахка тиңләшердәй бай, гүзәл табигатьле авылга урнаштырганы өчен ул Гыйрфан муллага рәхмәтне мең тапкыр әйткәндер. Бик матур йорт салып, ямь өстенә ямь булсын дигәндәй, тирә-якка агачлар утыртты. Алма, чия бакчалары... Бу яктан ул Гыйрфан мулланың үзеннән дә уздырып җибәрде шикелле әле. Булсын. Ходайга шөкер. Бер тарлык та юк. Матур яшәү өлгесен иң әүвәл зыялылар күрсәтсен. Иншаллаһ, аңа акрынлап урта хәллеләр, ярлылар да иярер. Ходай Тәгалә адәм баласына һәммә байлыкны биргән — файдалансыннар әйдә: рәхәт, бәхетле, хозур яшәсеннәр. Амин!

Мөбахис мәзингә Гыйрфан мулла матди вә рухи ярдәм күрсәтеп торды. Йорт тергезгәндә, кирәк булса, акчасын да кызганмады. Шулай итеп, дустанә яшәү дәвам итте. Низаг кебек күңелсез хәлләр булмады. Әмма тора-бара Мөбахис мәзиннең комсызлык чаткылары башта бизмәненең караны үлчи торган ягына мыскаллап-мыскаллап тамса, соңга таба потлап-потлап өелә башлады. Әшенең таңында хәерне бик назланып, суфиланып, кыенсынып алса, соңга таба күп бирергә тиешлекне үзе үк сиздереп торудан да тайчанмады. Вакыт-вакыт үзен артык белдекле, Хода бәндәсе икәнлекне күрсәтергә тырышып, бәла-казага очраган кешеләргә «ярдәмгә» ашыкты. Моның өчен бәгъзе бер ярлының соңгы кәҗәсен алып суеп ашаудан да оялмады. Остабикәсе Хәернисаның да нәфесе бугазыннан табан астына төшкән булып чыкты. Мәзинен күп садака алырга котыртып кына торды. Аларның бу кыланышы Гыйрфан муллага да, Хәсәнә абыстайга да тамчы да ошамады. Авыл халкы да аларның чаманы белмәүләренә борчыла башлады. Солтанморатта юк иде ич әле андыйлар. Кайдан килеп чыкты мондыйлар? Гыйрфан мулла, чит кешеләр икәнлекләрен искә алып, никадәр генә маңгайга бәреп сөйләшә торган гадәте булмасын, аларга башта каты орылмады. Ә инде чамалары чаналарына сыймый башлагач, әйтте беркөн:

— Безнең авыл халкы, — мәзинме ул, мулламы, ишанмы, хәзрәтме, — эшләп ашауны хуп күрә, Мөбахис туган, бу мәсләктә миннән дә, ягъни мәсәлән, элекке остаз-мөдәррисеңнән дә өлге-үрнәк алаласың, син чаманы онытма әле, ярлы кешеләрне йончытма, — диде бер сөйләшкәндә.

Шунда Мөбахис мәзиннең башына капыл бер уй килде:

әһә, Гыйрфан мулла аннан көнләшә икән ләбаса; муллалыгын алырга омтыла дип тә уйлыйдыр әле, бәлкем. Кеше күңелендә нинди кара төер ятмас. Карбыз түгел бит ул, ярып карап булмый. Кисәтү-шелтәләү ешая төшкәч, аның бу уйлары янә кабарынды. Хәтта дошманлык белән эшли дигән фикергә килде. Бу фикернең һич тә шайтан котыртуы икәнлеген аңламады ул.

Гыйрфан мулланың:

— Хәерне безгә түгел, Хәмдия абыстай кебек ярлыларга бирегез әнә,— дигән сүзләрен ишетеп, ярылыр чиккә җитә ул.

Тик нигәдер аңа бәла-каза күбрәк килүчән. Теге чакта аты югалган иде. Ул вакытта да:

— Ат карагы Хәрти урлаган,— дигән аяклы хәбәрләр йөрде авылда. Ләкин Хәрти өйдә юк иде. Ул кайта-китә йөри. Тотылмаган бур — бур түгел. Ул чакта ат югалуны Хәртигә сылтый торган бер дәлил дә табылмады. Ә бу юлы — бар. Аның өй эченнән ургылып чыккан тәмле ит исе күршесе Хәмәтдин картның борынын кытыклап, ач карынына кадәр үтеп кергән дә эчәк, бавырларына уралып, авызыннан сулар китергән. Ыстараста ихатасыннан сарык кабыргасы тапкан. Менә шул. Нинди дәлил кирәк тагы да?! Иртәгә иртүк Хәртигә урам хөкеме булачак. Каты җәза көтелә. Соңгысы. Гыйрфан мулланың, гәрчә каты куллы булса да, кеше яклый торган гадәте бар. Чыгарачак хөкемне челпәрәмә китереп ташламасын. Шуңа күрә җайлап, ипләп, мәсьәләнең асылын аңлатып сөйләшү, җәза бирү өчен алдан бер нигезле фикер тупларга дип, ыстараста Тәслих белән Мөбахис мәзин Гыйрфан мулланың өенә килергә мәҗбүр булдылар.

Гәрчә икесе ике төбәктә туып, бер-берсенең дөньяда барлыгын белмичә яшәсәләр дә, аларның тышкы һәм эчке охшашлыклары да бар. Икесе дә кипкән йөзле, тар маңгайлы, бәләкәй борынлы, соргылт чепи күзле, чандыр гәүдәле. Аерма шул: ыстараста Тәслих — кәтүк буйлы, Мөбахис мәзин, сөбханалла, колгадай озын кеше. Янә бер аерма: ыстарастаның мыегы карар күзгә әйбәт кенә тоела, ә менә сакал чыгасы урында ике-өч бөртек бала йоны гына җилфердәп тора. Мөбахис мәзиннең исә, киресенчә, борын астында ирләрнекечә мыек түгел, ат кылына охшаш, берникадәр тимерчыбыкны хәтерләткән шырпы башы буйлыгы гына каты йон төртеп чыккан. Сакалдан болай Ходай мәхрүм итмәгән. Тик аны да биткә-йөзгә ир коты бирә дип әйтеп булмый. Сакалы кәҗәнекеннән бер дә артык түгел.

Эчке охшашлыклар: икесе дә чәрелдек тавышлы, куркып-шүрләбрәк яшәүчән, комсызлар, хәйләкәрләр. Шулар өстенә мәзин абзыйның еш кына төчкереп йөри торган гадә-

те бар. Моны ул үзенчә төрле сәбәпләргә сылтый: аңа, имеш, мунчадан соң томау төшкән; салкын җил бәргән, имеш; күлмәкчән килеш яныл-пешеп утын кискән дә... тире катканчы өстенә бишмәт кияргә оныткан, янәсе.

Алар бер-бер артлы килеп керде: мәзин — алдан, ыстараста — аннан соң. Ә менә мәзин абзый шәригать канунnарын белеп-үзләштереп бетермәгән диндар икәнлеген шундук күрсәтте. Аның шулай икәнлеген Гыйрфан мулла да, Хәсәнә абыстай да, хәтта балалар да сизеп алды: сул аягы белән атлап керде тупсаны. Кеше идәненә иң әүвәл уң аягы белән басарга тиеш адәм баласы. Ярый, надан ыстараста бәгъзе бер гореф-гадәтне, шәригать канунын, кешене кимсетә торган сыйфатларны белеп тә бетермәсен ди. Ә инде адым саен Алла исеменнән сөйләп йөреп, башкалар күңеленә иман нуры таратырга тиешле затның ак юлга энә очы зурлыгы гына булса да кара тап төшерүе аслан килешкән эш түгел.

* * *

Сөйләшү шактый озакка барды. Хәсәнә абыстай, мөселман хатын-кызларына хас әдәплелекне саклап, йөзен башындагы ак яулыгының бер як чите белән каплаган хәлдә, чыгып китте. Балалар да таралышты. Һәркайсы үз шөгыле белән мәшгуль булды. Тик Галимҗан гына, сүз Хөрмәтулла абзый язмышы турында барачакны белгәч, алардан ерак китмәде. Эчке бүлмәдән, әлеге әрекмән колакларын тырпайтып, тегеләрнең ярыша-ярыша, кычкырыша-кычкырыша, ярсыйярсый сөйләшүләрен тыңлап торды. Дөрес, сүз башта җилсез көндә җай гына аккан елга суы кебек тыныч барды. Сүз сарык урлаучыга нинди җәза бирү турында куергач, мәзин «терелəй күмәргә» дигән тәкъдим керткәч, әлеге тыныч елга давыллана, котырына башлады. Гыйрфан мулланың тавышы тәрәзә пыялаларын чатнатырдай булып яңгырады:

— Син нәрсә, Мөбахис, иманыңны сатмагансыңдыр бит, бер баш сарыкка кеше башы ашарга йөрисең, оят кирәк,— дигән сүзләре бүлмә тактасын җимереп чыгып, әлеге зур колак барабаннарын тетрәндереп кенә калмады, Галимҗанның йөрәк капкачын ачып кереп, бөтен тән әгъзаларына йөгерде.

«Дөрес әйтәсең, әткәй, мин дә шулай уйлыйм, бер сарык өчен кеше үтермиләр» дип кычкырасы килде.

Чыпчыкның да бизмәне бар дигәндәй, һәр бәндә күңеленең үз бизмәне булуны аңлады Галимҗан. Мөбахис бик күп вакыйгаларны үз бизмәненә салып үлчәргә тырышты. Имеш, күрше авылда әнә бер бидрә бәрәңге урлаган өчен, берәүне терелəй кабергә күмгәннәр. Ә инде ыстарастаның бизмәне

бөтенләй ике яклы хәнҗәр кебек икән. Аңа арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит. Ул үз җанын саклый. Хөрмәтулла абзыйны тереләй күмәләр икән — күмсеннәр. Тик аңа сүз генә килмәсен. Исән-сау калдыралар икән — калсын. Әмма моның өчен аны гаепләмәсеннәр.

— Ул сарык, бәлкем, исәндер, берәр җирдә адашып йөридер... Ни хакың бар шуны ачыкламый торып кешене ат койрыгына тагып урам буйлап йөретергә, — дип җикеренде Гыйрфан мулла.

— Мин бит, мулла абзый, үзем генә түгел, башкалар фикеренә колак салам, — дип акланды ыстараста.

Әтисе аның һәр сүзен капканга эләктерә барды.

— Диңгездәге йомычка син... Менә кем... Чайкаласың да чайкаласың, үз мәсләгең, үз кыйблаң, үз иманың юк...

Мөбахис мәзингә дә ару гына чәпәде әтисе:

— Комсызлыгың котырта сине, ахыр чиктә муеныңа елан булып уралыр әле ул, буып чагып ташлар. Минем дә бар кара сарык, Аллага шөкер, әйдә, җитәкләтәм дә җибәрәм, — диде.

Менә кем икән аның әтисе! Корырак, усалрак булганга, яратып бетермәгән чаклары да бар иде. Кеше күңеле — тирән дәрья, дигән иде әнисе беркөн. Аның әтисе күңелендәге дәрья иң тирәнедер әле. Әллә нинди асылташлар бардыр ул дәрья төбендә. Ата горурлыгы белән яшәргә куша иде бит әнисе. Моны аңлап бетерми иде әле ул. Ә нигә горурланмаска мондый ата белән!

— Иртәгә Ырынбурга китәм, мин кайткач хәл итәрбез, оныгыз урам хөкемен хәзергә, ишетсен колагыгыз, — дип бетерде ул сүзен.

Бу сүзләрдән соң Галимҗан әтисенең каты куллы, олы җанлы, горур кеше икәнлеген аңлады.

* * *

«Кунаклар» киткәч, Гыйрфан мулла үзен-үзе кая куярга белми аптырады. Аның каны тәмам кызган иде. Эчке бүлмәдән чыгып, улының каршысына килеп басканлыгын сизми дә калды хәтта. Дөресен сөйләргә өйрәнгән Галимҗан өчен алдашу иман сату белән бер иде. Ә инде ата кешене алдау намусны да, вөҗданны да, йөрәкне дә нык кыра. Шуңа күрә ахмаклыгың өчен сызланып йөрегәнче, туп-турысын әйтеп бирү хәерле.

— Әткәй!.. Әткәй!.. Мин бүген көне буе Апуш белән Мөбахис мәзиннең югалган сарыгын эзләп йөредем...

— Ни өчен син? Ни өчен башка берәү түгел?

— Хөрмәтулла абзый ат карагы түгел. Мәзин абзыйның

сарыгын да ул урламаган. Яхшы кеше бит ул Хөрмәтулла абзый.

— Кайдан беләсең?

— Беләм инде...

Ул арада Хәсәнә абыстай килеп керде. Аның йөзе моңсу, кайгылы, борчулы иде. Бер-берсенә яшь әтәч белән карт әтәч көдрәшкәндәй карашып торган ата вә баланы күргәч, йөрәге жу итеп китте, йөзендәге курку күләгәсе тагын да куера төште. Галимҗан, гәрчә әнисенең керүен сизсә дә, ятып калганчы атып калыйм дигәндәй, сүз чылбырын өзмәскә булды.

— Әткәй!.. Әткәй!.. Апуш белән без ул сарыкны тапмый калмаячакбыз... Иртәгә дә эзләячәкбез... Ырынбур качмас әле... Китми торыйк... — диде.

Хәсәнә абыстай бөтенләй коелып төште, үрле-кырлы килеп, үзен-үзе өзгәләп ташлар чиккә җитте. Менә инде тиле малай: ни-нәрсә сөйли бит, илаһым, күр инде син аны, күр, торышына кара, атасының каты карашы аның өчен сукыр бер тиенлек кенә; инде мең сәбәп бәла белән сәфәр һаман тоткарланып килгәнгә, әтисенең утка баскан мәче шикелле кыланып йөрүен белмиме әллә?.. Уф, Алла!.. Хәзер менә өй эчендә тагын давыл чыгачак, буран котырачак. Нәкъ уйлаганча килеп чыкты. Гыйрфан мулланың бала йоннары кабарып, маңгае сөзергә торган карт үгезне хәтерләтеп җыерылды. Ата белән бала арасында боз тавы килеп өелгәндәй тоелды ана өчен. Бәй, бәй, Ходайның рәхмәте, мынагаеш[1], күз ачып йомган арада калыккан боз тавы шундук эреп агарга да керешге. Сөзәргә торган карт үгезне хәтерләткән ата кешенең маңгаендагы җыерчык өеме кул белән сыпырып ташлагандай юк булды. Ул гына да түгел, ата кеше елмаеп, көлеп җибәрде хәтта. Ул елмаюда йөрәк кайнарлыгы бар идеме? Шул эретеп агыздымы әлеге боз тавын?! Галимҗанны чын аталарча кочаклап алды да Гыйрфан мулла, аркасына йомшак кына суккандай итеп:

— Бар, йокла, күземә күренмә, — диде.

Хәсәнә абыстай сыны белән катты. Галимҗан чыгып йөгергәч тә әле озак кына исенә килә алмыйча да торды. Мулласының кыланышы зиһенен алды аның. Ачуланасы, битәрлисе урынга әнә ничек йомшарды да төште. Хәзер инде үзе дә эреп аккан боз тавына охшап калды. Һәй, бу ирләрне аңламассың: әнә кара — усал бүре ул, менә кара юаш колын ул. Бәгъзе бервакыт үзе дә бөтенләй балага әйләнә дә куя.

Остабикәсенең кичерешен аңлады Гыйрфан мулла.

— Әнә нинди малай үстерәбез, — дип горурланды.

---

[1] Мынагаеш — Башкортстан татарлары телендә гаҗәпләнү ымлыгы.

Кайбер утын авыз кебек «Хәрти» дими бит. Матур итеп, авыз тутырып, олыларны кадер-хөрмәт итү йөзеннән, эчке бер җылылык, илаһилык белән «Хөрмәтулла абзый» дип әйтә. Димәк ки, һәр адәми затны кешегә саный. Ул гына да түгел, аның язмышы өчен ут йотып, үрсәләнеп йөри. Көне буе югалган сарыкны эзләп иза чиккәннәр. Дөрес әйтә бит, шайтан алгыры: «Ырынбур качмас әле»,— ди. Әйе, Ырынбур качмый да, югалмый да, җир дә упмый аны. Ә кеше югалса! Тап син аны яңадан бу фани дөньядан. Менә бит ничек зур уйлый Галимҗан. Пәйгамбәрләр башы бар анда. Пәйгамбәрләр башы!

Шуларны аңлатып бирде дә остабикәсенә:

— Китмибез иртәгә,— дип кырт кисте Гыйрфан мулла.

## *Дүртенче бүлек*

> Алда әле башланмаган олы юллар,—
> Һәрберсендә күпме
> бәхет-сәгадәт бар?
> Юллар илтә бәндәләрне
> киң дөньяга,
> Шунда гына ул үзенә гәүһәр таба.

### I

Гәүһәр! Аны диңгез төбеннән чумып эзлиләр. Әмма ул анда, диңгез төбендә, таудай өеп куелмаган. Аны табу, башка асыл ташлардан аерып алу өчен, бисмилланы мең-миллион кат әйтеп, диңгез төбендә, бер өем чүптән ярма бөртеге эзләгән тавык шикелле, чокчынырга, чокчынырга кирәк. Тормышта бәхет-гәүһәр табу һич тә аннан ким түгелдер. Авырлактыр да әле. Бу хакта һәр ата-ана җитди уйлана. Борчыла. Фикер йөртә. Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай өчен бу көннәр аеруча көчле пошаманлык дулкыны эчендә үтте. Ни гаҗәп, мәсьәләнең мөгезеннән тотарга, кылны кырыкка ярырга гадәтләнгән Гыйрфан мулла да соңгы көннәрдә берникадәр бәлтерәп калды. Аяк астыннан һич көтмәгән бәла-каза, низаг-мизаг килә дә чыга. Хөрмәтулла мәсьәләсе бөтенләй аяктан екты. Ата-бабаларыбыз чыгарган мәкальләрне дә искә алды ул: «Йөз юл — мең хата». Янә: «Карның белән кар ярып, борының белән боз ярып булса да, юлыңны тап»; «Ниятең кәкре булса, юлның турылыгы файда итмәс»...

Йөз юлда мең хата булу — анысы инде аның табигый хәл. Пәйгамбәрләр дә хатасыз яшәмәгән. Бу да аларның дөнья

серен аңлап бетерməвеннəн килə. Əйтик, шимбə — хəйлə көне. Шуны белми юлга чыккан алты пəйгамбəр (Салих, Нух, Гайсə, Муса, Ибраһим, Мөхəммəт галəйһиссəлам) бəхетсезлеккə очраган. Менə бит йөз юлның мең хатасы нигə барып бəйлəнə. «Борының белəн боз ярып булса да тап юлыңны». Менə терəкə! Ай-һай, каты əйтелгəн! Лəкин дə юлда ниятең дөрес булсын. Шунсыз сиңа ак җəймə җəймилəр.

Боларны Гыйрфан мулла яхшы белə. Биш бармагы кебек. Əмма лəкин юлга чыкканда көн сайлау мəсьəлəсе дə, əгəр арттырып əйтсəк, хатын ярəшү кеби җаваплы эштер. Гыйрфан мулла моны да яхшы аңлый. Җомга — мөселманнарның бəйрəм көне. Адəм галəйһиссəлам дөньяга килгəн көн бу. Аңа дога кылып, сəҗдəгə китеп, илаһилык эчендə хозурлана торган көн. Мондый чакта юлга чыгу килешеп бетмəс. Пəнҗешəмбе дə яман көн түгел. Аллаһы Тəгалəнең җəннəте вə җəһəннəме шушы көндə барлыкка килгəн. Җəннəте — əйбəт, җəһəннəме — шомландыра. Сишəмбе — Кабил Хабилне үтергəн көн. Үтереш, суеш — мəңгелек яманлык. Чəршəмбе. Бу көнне Юныс пəйгамбəрне балык йота. Ибраһим пəйгамбəрне Нəмруд лəгыйнь утка сала. Якшəмбе — мөселманнар өчен бəрəкəтле көн түгел. Һəр көнне Аллаһы Тəгалə үзе яраткан. Шулай да һəр көннең үзенчəлеге бар. Юлга дүшəмбе көнне чыгарга кушалар. Бу көн, имеш, алда башланмаган юлларны искəртə, һəрберсендə булган бəхетсəгадəттəн өлеш чыгара. Бу юллар бəндəлəрне киң дөньяга алып чыга. Шунда һəркем үзенə яшəү гəүһəре таба, имеш.

Дүшəмбе көнне чыкты юлга Гыйрфан мулла. Аның уенча, изге юл бу: Аллаһы Тəгалə юлга ак җəймə җəйгəн мəл. Сызылып таң атып килə. Аның алсу нурлары бөтен инсаниятне назлый, иркəли, юата, кайгылардан араландырып, үзенчə бер рухи шифа өрə төсле иде. Лəкин дə юлчыны син өмет иткəн оҗмах түгел, көтелмəгəн тəмуг каршы ала икəн. Авылдан чыгып китү белəн, əлеге таң алсулыгын кара-кучкыл болыт каплады, əллə нинди салкын җиллəр исеп, коточкыч буран купты. Җил əле бер яктан китереп суга, əле икенче яктан китереп бəрə. Ул гүя юлчыларның ныклыгын сыный, аз гына йомшаклык күрсəтсə, очырып, җəһəннəмгə алып олактырмак була.

Əле ни арба, ни чана түгел чак. Гыйрфан мулла əлеге телəсə нинди дыңгырдык юлдан үтəрдəй тимер арбасын пар атка җикте. Печəнен, солысын, азык-төлеген... — бөтенесен шунда төяде. Дилбегəне башта Шакирҗанга тоттырды: мə, йоклама, оеп барма, аң бул, инде шəлəй-вəлəй малай түгел, ир корына җитеп килүче, янəсе. Шулай да бераз баргач, дилбегəне үз кулына алды ата кеше. Чөнки, ни генə димə, ат дилбегəнең кем кулында икəнлеген тиз сизə. Дилбегə тимер

кулга эләксә, ул, колагын каты торгызып, башын күтәрә төшеп, аякларын каты-каты басып атлый. Камыр кулга эләксә, колакларын юешләнгән бияләй урынына салындыра, башы бөлтерәп кыегая башлый, аяк атлаулары ташка үлчимгә әйләнә. Дөрес, пар атның икесендә — ике төрле җәһәтлелек, сизгерлек, тоемлау. Туры бия, минем өчен Әхмәтдин ни, Мөхәммәтдин ни дигәндәй, кеше кулы сайлаучан түгел — үз җаена җилдерә бирә. Тимер-күк — башка калыптан: шәйләмирәк калсаң, холкын бозсаң, чыгымчылый торган гадәте бар хәтта.

Әлбәттә, атның юлда уңганлыгы аны җигә белүгә дә бәйләнгән. Бу җәһәттән Гыйрфан мулла осталыгына җиткән кеше авылда гына түгел, бөтен тирә-якта юктыр әле. Дугасы аның, тәкәббер кеше маңгае кебек, аз гына алга киерелеп торсын. Мәгәр нык торсын. Мең дию пәрие уптым илаһи берьюлы өрсә дә, ослан селкенерлек булмасын. Ерак юлга чыккач, атка бер минут та йомшаклык күрсәтергә ярамый. Кирәк чакта йөгерт. Чаптырып та ал. Тау итәгендә атлат. Ат йөртә белү — ир-егет эше. Ат — ир канаты ул. Шуларны өйрәтә-өйрәтә чәченә, сакалына кырау төште инде. Әмма ләкин һаман төрле яклап тәртә арасына кертеп булмый бу юеш борыннарны. Һич кирәкмәгәнгә дилбегәне әле уңга, әле сулга тарткалыйлар бит. Ни файдасын күрәдер шуның. Мондый катканак, кылдый-былдый юлда тәгәрмәчең бер түмгәккә эләксә — арбаң авып, әллә кая мәтәлеп барып төшүең бар. Менә сиңа мең хатаның берсе.

Дилбегәне үз кулына алырга булды ата кеше. Шакирҗан:

— Әткәй, үзем... син ял ит... — дип караса да, тыңламады.

— На-а-а... һәй, малкайлар, уңганнар, һайт, — дип, калын тавыш белән бер кычкырып, үзенең каты куллы икәнлеген сиздереп алгач, аңладык ниятеңне, хуҗа-әфәндем дигәндәй, атлар дәррәү уянып, җай гына юыртып киттеләр.

Галимҗанны ул толып белән төреп утырткан иде. Дөресрәге, моны әнкәсе эшләде.

— Кем... сиңа әйтәм... әйкәем... Галимҗанны берүк саклый күр инде... салкын тимәсен... гелән генә авырый да тора бит... — диде.

Шуңа охшаш янә мең төрле вәгазь әйтте. Дөрес, мондый чакта, үгет-нәсихәт тау-тау өелсә, Гыйрфан мулланың ачуы кабара, тәне кызыша, аркасы буйлап кырмыскалар йөгерешкәндәй тоела башлый. Аның бу кыргыйрак гадәтен, сүз белән кытыклауны яратмаганын остабикәсе белепме-белә инде. Шулай да ул хатын-кызга хас өйрәтү-төпчену үзенчәлеген, бала өчен ана йөрәгенең ни дәрәҗәдә өзгәләнгән-сызланганлыгын, бөтен илаһи бәхетенең шуларда икәнлеген сиздерми калмый.

Галимҗан, әнисенең сабак урынына кат-кат тугылаган йөрәк сүзләреннән чыкмаска тырышып, толып эчендә майдай «эреп» барды. Пәри туендагыдай уйнаклап-муйнаклап, котырынып искән салкын җилдә дә, кар катыш яуган яңгырда да әллә ни гаме юк иде аның. Үткән хатирәләр давылы эчендә йөзде ул. Давылларда, Алып батырны хәтерләтеп, Хөрмәтулла абзый кайнаша.

Нәҗметдин мәзин келәтенә ябып куйгач, болар өчен аны коткаруның бер авырлыгы да юк иде инде. Чөнки Галимҗан, Апуш, мәзин малае Кәли — балыкка бергә йөрүчеләр. Алар, әйтергә уңайлы булсын дип, исемнәрен дә кыскартып бетерделәр. Габдулла — Апуш, Кәлимулла — Кәли, Галимҗан Галим булып калды. Һәрберсенең икенче кушаматы да бар. Галимҗан — Чирле чәүкә, Габдулла — Чуртан, Кәлимулла — Кикрикүк. Чуртан кушаматы Апушка суда оста йөзгәнгә бирелде. Кәли әтәч булып кычкыра белә. Галимҗанныкы — чиргә бәйле.

Күп вакыт алар бер-берсенә әнә шул икенче кушамат белән эндәшергә ярата: моңа берәү дә үпкәләми. Бу — дусларча шаяру. Дуслык, янәсе, вак-төяк кети-метиләрдән өстен тора.

— Сарыгын әллә табабыз, әллә юк, әйдә, Чуртан, Хөрмәтулла абзыйны коткарабыз,— диде Галимҗан балыкчы дустына.

Тегесе җилкәсен кашып алды, аз гына уйланып торды:

— Ә ничек? Йозагы бозау зурлыгы бит...

— Кикрикүккә әйтик: ачкычын урласын...

— Башың тубал кебек синең, Чирле чәүкә...

— Соңыннан макташырбыз. Эшне гамәлгә ашыргач...

Барысы да, майлы табада шуган коймак шикелле, бик җай гына барды. Кикрикүккә ачкычны табу да, инде төн уртасында авыл тәмле йокыга талгач, йозакка аны ярату да әллә ни кыенга туры килмәде. Җитмәсә, каравылчы Садретдин карт та кайтып киткән. Тукмалып, имгәнеп беткән кеше түгел, бу таш келәтне шайтан үзе дә ватып чыга алмас, дип уйлагандыр инде. Тик бөтен эшне Хөрмәтулла абзый үзе бозды. Башта, билгеле, төн заманында ачып кергәнгә аптырап калды ул. Кем? Ни өчен? Аларга аннан ни кирәк? Дөрес, аның бу кичерешен ачып керүчеләр белми. Чөнки караңгы. Ай яктысы бераз төшсә дә, бер-береңне таныrлык түгел.

Алар башта, ни кылырга белмичә, беравык тын торды. Аннан, үзләренең кем икәнлекләрен әйтеп, дуслары исеменнән Галимҗан сөйләде. Каравылчы картның кайтып китүе, ачкыч табып, ишекне ачулары, коткарырга килүләре турында әйтте.

— Сез хәзер качыгыз, Хөрмәтулла абзый,— диде Галимҗан.

Хөрмәтулла тиз генә җавап бирмәде. Сөйли башлагач, аның көчкә-көчкә тын алуын, авыр хәлдә булуын аңладылар.

— Җук, малайлар, качмыйм, җарамый... Пәчәму?.. Пәтәмүште... җарамый... Мин ул ысволыч карун мәлгунь... мөртәт... кара җөрәк... ач күз Мөбахис хәсиснең сарыгын ырламаган... и вчу... Сарык ырларга минем башыма тай типмәгән бит... вәт тәк... мин шуны халыкка... урам хөкеме вакытында аңлатып бирергә... дакәзәйт итәргә тиеш... Качсам... сезгә дә сүз килер бит... Белмәй калмаслар... Минем өчен хатыным... балаларым ыстырадайт итәчәк... Качсам... сарыкны дисвителне шул Хәрти урлаган, диерләр... Ат карагы дигән «дан»нан курыкмыйм мин... Вәт тәк... пәнимәйт нады... Сарык буры даны алганчы... җыгылып үлим... и вчу...

Малайларга аның бу кыланышы бик сәер тоелды. Галимҗан өчен бигрәк тә. Теге вакытта беренче карашка гәрчә начар тәэсир калдырса да, аның эчендә ниндидер асылташ барлыгы аңлашылган иде. Ул асылташ әле менә зурая барды, зурая барды. Тора-бара ул кешелеклелек, горурлык бизәге булып балкыды. Әтисенең дә, әнисенең дә «Кеше күңеле — тирән дәрья» — дигән сүзләре раска туры килә. Тулган айдай балкып торган җәмәгате Мәликә түти дә, ак чәчәкне хәтерләткән кызы Мәдинә дә аның күз алдына фәрештә сынлы булып килеп басты.

Мондый очракта Галимҗан үзе нишләр иде икән? Качар идеме? Качмас иде. Бу бит намусыңнан качу була. Үз авылында начарлык калдырып китәсе килми Хөрмәтулла абзыйның. Дөреслек, намус өчен ул йодрыгы белән дә көрәшкән. Хәзер дөреслек өчен үлемгә бара. Чыннан да, тереләй күмеп куюлары бар бит. Мондый хәбәр тирә-як авыллардан килеп кенә тора. Хөрмәтулла абзый шуннан да курыкмыймы?

## II

Үкенче көнне Хөрмәтулланы халык хөкеменә алып чыктылар. Хөкем Алпавыт урамы уртасында булачак. Төне буе нур сипкән табактай ай, вәхшәтне мин дә күрим дигәндәй, яктыргач та әле зәңгәр күк йөзеннән күзләрен чекерәйтеп карап торды. Ул күзләр көянтә-чиләк күтәреп торган Зөһрә сылуныкы иде төсле. Нурлар, бәлкем, шул саф, садә, моңсу күзләрдән

түгелгәндер. Зөһрә ул моңсу сафлыкны Айга җир дөньясыннан алып менгән бит. Димәк, Ай йөрәге белән Җир йөрәге бер-берсенең сөю-мәхәббәт ялкыннары кайнарлыгын тоеп тибә. Шулай да Айның йөзе бүген боек, борчулы, кайгылы иде. Әллә Зөһрә-Алиһәнең Җир кешеләре язмышы өчен сызлануымы бу? Җир шартлап ярылырдай зур гөнаһлар эшлисез, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында ни җавап бирерсез, Адәм балалары фани дөньядан мәңгелеккә саф күңел белән килергә тиеш, диме?

Чулпанның да йөзе бүген башка көннәрдәгегә караганда сүренкерәк, моңсурак, хәсрәтлерәк тоелды. Ул таңны уятырга куркыбрак торды, хафаланмады, сабыр итәргә тырышты сымак. Һәркемнең үз йолдызы бар, ди бит. Димәк ки, Җир йөрәге белән Ай йөрәге, Кеше йөрәге белән Йолдыз йөрәге эчке нурлар, эчке яшәү җепләре, эчке чылбырлар аша берберсенә тоташкан. Кем белә, Чулпан — Хөрмәтулла абзый йолдызыдыр, бәлки. Шул йолдызның йомшак нурлары иркәләве хозурында килгәндер якты дөньяга. Шул кешене үлем көтә. Нахак бәла тактылар. Бу гаделсезлекне, бу фаҗигане, бу коточкыч хәлне күреп тетрәнмәсме Таң сылуы Чулпан? Тетрәнер, әлбәттә. Йөрәге ярылыр чиккә җитәр. Нур урынына яшь түгәр. Шулай да чыдар. Ыңгырашканын сиздермәс. Түзәр. Йолдызлар түземле була. Җир-Ана да түземле. Алар фани һәм ахирәт кануннарын белеп яши. Җир-Ана секундына 30 чакрым тизлек белән оча. Кояш җиле чапаны итәгенә ябышып. Әмма башка планеталарга орынмый. Үз юлы белән җилдерә. Адашмый. Белеп. Аңлап. Әдәплелек саклап.

Кешеләр әдәпсезләнә. Бер-берсен ашый. Ерткычлана. Ай белән Чулпанның йөзе бүген шуңа кайгылы булгандыр. Уттай янып чыккан кояш йөзләргә кызгылт нурлар сипте. Хәзер дөньяга мин хуҗа дигәндәй, колачын җәеп, акрын гына күккә күтәрелә башлады. Тегеләр шул кызгылт нурлар пәрдәсе артында яшеренеп калды.

Хөрмәтулланы кояш дилбегә буе чамасы күтәрелгәч алып килделәр. Алпавыт урамына. Һәркемнең үз дөньясындагы шәхси мәшәкате саеккан мәл. Иртәнге намаз укылып, чәйләр эчеп алынган. Көтүгә маллар куылган. Хәзер һәр кешенең, «менә мине күр», «кичә дә яныма килмәдең», «нигә тотынмыйсың» дигәндәй, кырык җирдә кырылып яткан кырык эше борынын сузып тора. Шуңа чаклы «Хәрти эшен» тозлап-борычлап, җайлап-майлап, яңадан мәңге баш күтәрмәслек итеп тапталган үлән кебек бастырып куярга кирәк.

Ыстараста Тәхлис, таң күзеннән торып, итәк астыннан ут йөртү хәстәренә кереште. Сүзе сыярлык һәркемнең — дусиш, таныш-белеш, күрше-күлән, кардәш-ыру — капкасын как-

ты. Дөрес, утны ул моңа чаклы да әллә кемнәрнең итәген көйдерер дәрәҗәдә йөртте. Аңа сүзен өскә чыгарырга кирәк. Сүзен боз капламасын. Кешеләр арасында адәм мәсхәрәсенә калдырып, аның өчен яшәү җәймәсе булып җәелгән вазифасыннан кибәк урынына җилпеп ташламасыннар. «Тереләй күмәргә» дигән карар чыгару өчен өч шаһит булу зарур. Аларын да тапты. Дөресрәге — яллады. Акча тамызып. «Бәхет бакчасы» вәгъдә итеп, кул кулны юа дигәнне аңлатып. Бер ярма бөртегенә алданып, пычак астына кергән аңгыра тавык кебек, Ходаның сынык икмәккә җан сатучы ахмаклары беткәнмени.

Мөбахис мәзин исә ыстараста төрткән хәйлә утына даими рәвештә ялкын өстәп торды.

— Чын ир-егет икәнлегең, пычрак эшләргә каршы көрәшүче илаһи зат булуың, кешелеклелегең менә шушы изге эшне мәртәбәле итеп башкарып чыга алуыңда күренер; Аллаһы Тәгалә алдында йөзең ак, намусың пакь булыр,— дип котыртты.

Тәхлис — хәйлә ялгашыннан бер пот тоз ялаган бәндә. Мөбахис ялкынын тиз генә дөрләтеп җибәрү ягында түгел. Аның да үз туксаны — туксан.

— Син шулай дисең дә ул, мәзин абзый, ул бит миңа гына бәйләнмәгән; кара халык — аңгыра сарык, дип сөйләшсәк тә, кара халыкның бөркет күзле, бүре тешле булганнары да бар; бәгъзе берсе бугазыңны чәйнәргә әзер тора,— диде.

Йодрык зурлыгы башын тотып, бераз уйланып торгач, ул янә дәвам итте:

— Үткер тешлеләр, үзең беләсең, байлар арасында да чәчеп үстергән кебек. Бар син, якалашып кара Гыйрфан мулла белән, җаныңны суырып алып, уч төбеңә китереп салыр. Теле белән тегермән тарта, акылы белән дөнья кайната, үткерлеге белән кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен үтә белә. Андыйлар белән чәкәләшү, ай-һай-һай…

Мөбахис мәзин, яктылыктан курыккан ябалак шикелле, Гыйрфан мулланы беркемнән дә мактатасы килми иде. Киресенчә, алтын базыннан чүп эзләгәндәй, аның үзенә дә, гаиләсе һәм балаларына да, җае туры килгән саен, пычрак ату ягын хуп күрде. Әле дә менә аның бакчасына таш атарга тотынды:

— Ходай каршында энә очы зурлыгы да гаебем юк, Тәхлис туган; үзең шаһит: Солтанморатка ямь өстәрдәй менә дигән дөнья тергездем, күпләр миннән өлге ала, тик шушы хакыйкатьне Гыйрфан мулла аңламый, мине адәм рәтле яшәгәнгә битәрли. Дәхи дә үз урынын яулап алуымнан шүрләп йөри. Бәс, шулай булгач, кем әйтер аны кара эчле түгел, дип. Кара эчлелек — мөселман бәндәсе өчен ифрат дәрәҗәдә ту-

бән сыйфат ул. Без Гыйрфан кебекләргә Аллаһы Тәгаләнең бәндәләргә биргән миһербанлыкларын аңлатырга тиешбез. Бу изге эш өчен көрәшү зарурдыр. Әлгаязе билләһи, дөрес эш өчен бер Аллаһының рәхмәте киңдер.

Адәм баласы Алла исеменнән әнә шундый төрле җаһиллеккә барудан һич тартынмый. Ап-ак сөт өстенә дегет тамызудан курыкмый. Бу мәсьәлә Мөбахис мәзин файдасына хәл ителсә, бөтен Солтанморатның ак күңелле халкы намусына кара тап сарылырга мөмкин. «Солтанморат» сүзе үзе үк тирән мәгънәгә ия. Солтан — хөкемдар, патша, газиз дигәнне аңлата. Морад — максат, теләк, теләнгән әйбер, аңлатылырга, белдерелергә уйланган нәрсә. Димәк ки, хөкемдарлылык, газизлек, мәһабәтлелек, изгелектә максатыңа ирешү өчен уйланган эшеңне сафлык илә гамәлгә ашыр.

Гыйрфан мулла кебекләр күңелендә шундый уй-хисләр кайнашты. Аңа киңәшкә якыннары, фикердәшләре, дус-ишләре килеп торды. Башкорт Котлызаман да кара кашлы, шомырттай кара күзле, өзелеп китәрдәй нечкә билле, бер басасы урынга биш басып торган дәртле бичәсе Көнсылуын ияртеп килеп җитте. Күрше авыл чуашы Ычтапан да көтмәгәндә пәйда булды. Гыйрфан мулла үзе дә аптырашта калды. Кем ул? Патшамы? Хөкемдармы? Әллә бу чуалган җеп очын ул гына табарга тиешме? Моның өчен берникадәр горурланып та ала. Эчтән генә. Беркемгә дә сиздермичә генә. Аның белән исәпләшәләр икән, димәк ки, ул тишек арба төбеннән төшеп калганнардан түгел. Ә инде Галимҗанның түбәсе күккә тия яза. Әнә кем икән аның әтисе! Халыкны, авылны афәттән, ялганнан, бәладән саклаучы олы җанлы, туры сүзле, миһербанлы кеше икән!

Галимҗан, һәр мөмкинлектән файдаланып, аларның сүзен әрекмән колакларын торгызып тыңларга тырышты. Ул сүзләрне күңеленә, йөрәгенә салып, янә ми күзәнәкләре дулкынында чайкалдырып, шулар аша кешеләргә бәя бирде. Ычтапан картны яхшы белә ул. «Кирфан ызнакум, пына син тыңна әле, бер пикер килде пашка» кебек сүзләр әйтәәйтә килеп керә дә, кулларын болгый-болгый сөйләргә тотына. Бу юлы да шулай итте. Исәнлек-саулык сорашып алу белән сүзгә кереште:

— Кирфан мылла... аны... Кәртине... Кәрмәйне... әй лә... Күрмәтулланы... пик якшы пеләм пит мин... Ишек ясап пирде... Кулы алтын прәме... Нәстәяшчи мужик... Шуңа акча пирдем. Ул акчага Әпсәләмдә сарык ите сатып алган... Шул итне пешергәндә... теге күршесе ач күз Кәмәтдин поронына тәмле ис килеп пәрелгән икән... ну пит сарык ырлаган дигән сүз түгел... Ашакач кабырка суйәкләрен ишегалдына чыкарып ташлаган икән... Пында кумакай Мүкә-

пис пәзин сарыкының ни катнашы пар... Ай-яй-яй, ай-яй-яй... Султанморатта пынтай алама кәлнең пулганы юк ите пит әле... Мин Күрмәтуллага азырак күмүшкә дә пиреп йебәргән идем. Әйдә, мин әйтәм, тутыккан табак төбен бер юып алсын... Жәл пит парин...

Ычтапан агай сөйләде дә сөйләде. Шуларның бөтенесен дә урам хөкеме вакытында әйтәчәген белдерде.

Галимҗанның моңа чаклы Ычтапан картка нык игътибар иткәне юк иде. Бүген аның ихлас күңелдән, чын йөрәктән, кеше язмышы өчен кайнар хис белән сөйләвенә мөкиббән бирелеп, эчке бер җылы тойгылар белән, һушы китеп тыңлап торды. Үзе бәләкәй генә ул Ычтапан бабай. Мондый кешене «кәтүк» дип йөртәләр. Ябыклыгы кипкән балыкны хәтерләтеп тора. Калак сөякләре дөя өркәче кебек калкып чыккан. Эчкә баткан яңаклары, нуры сүнеп кысылган күзләре, самавыр күрегенә охшап җыерылган тар маңгае... — барысы ачы, авыр тормыш тамгасы икәнлекне аңлатып тора. Шул карга күтәреп алып китәрлек карт чуашның эчке дөньясында, күңелендә, йөрәгендә күпме рухи байлык, кеше язмышы өчен яну-көю, сызлану...

Язгы кояш кебек балкып, җил-җил атлап, көлә-көлә, уйнаклый-уйнаклый, чегән кызларына хас кыюлык һәм җитезлек белән килеп керә торган Көнсылуны Галимҗан яхшы белә. Ә менә ире Котлызаман кыяфәтенә беркайчан да сынаулы караш ташлаганы юк иде. Аның бөтен гәүдәсе карт аюны хәтерләтеп тора. Карашы гүя сөзәргә әзерләнгән үгезнеке. Ике бит очы куш йодрыктай бүлтәеп, кабарып тора. Күзләре асылынып төшкән маңгай белән шул «йодрыклар» эченә кереп кысылган. Муены — самавыр юанлыгы. Дөрес, очларын бөтереп ике якка җибәргән (алар карлыгач канатын хәтерләтеп тора) куе кара мыегы йөз шөкәтсезлеген берникадәр күләгәләп тора. Яшь чагында ул ун ел буе өзлексез мәйдан тоткан, имеш. Сабантуйда берәүгә дә бил бирмәгән, ди. Шул батырлыгына, җисмәни көченә, кара мыегына, аюныкыдай гәүдәсенә кызыкканмы булдыклы, алтын куллы, эш сөючән, чибәр Көнсылу түти?

Бу юлы Котлызаман агай үзе генә килде. Әлеге дә баягы шул Хөрмәтулла абзый язмышы турында фикер алышырга, киңәшләшергә, мәслихәтләшергә. Галимҗан, бер почмакка посып, аны да тыңлап торды. Бу инде Ычтапан дәдәй кебекләрнең утызын арт ягына утыртып каезлардай пәһлеван. Галимҗан өчен шунысы сәер тоелды: бервакыт ул Хөрмәтулла абзый белән көч тә сынашкан икән. Мәгәр бирешмәгән Хөрмәтулла абзый. Моны ишетеп, Галимҗанның колаклары, чәчләре үрә торды. Әлбәттә, Хөрмәтулла абзый да нык кеше. Ләкин ул — Котлызаман агайның яртысы гына.

Мәсьәлә болай тора икән. Котлызаман агай көрәшүнең бөтен серен, нечкәлеген, җаен бәләкәй чакта ук өйрәнеп алган. Ә менә сугышканы булмаган. Сугышта бәгъзе берәү ерткыч бүрегә әверелә. Анда төлкегә хас хәйлә дә була. Гәрчә көрәштә әллә күпме еллар мәйдан тотса да, Котлызаман агай, Хөрмәтулла абзый кебек, сабан туе ямен җибәреп сугышучыларны йодрыклап йөрмәс иде. Менә сиңа адәм баласы. Менә сиңа инсаният хәяты. Менә сиңа бәндәнең бәләкәе, зурысы, бәхетлесе, бәхетсезе. Галимҗанның күз алдында әлегә өч сын: күшеккән тавыкка охшап калган Ы́чтапан дәдәй, аю кыяфәтле Котлызаман агай, маймылга тартым Хөрмәтулла абзый. Авырлыкларны үлчәү өчен бизмәнгә салсаң, беренче урынны — башкорт Котлызаман, икенчене — мишәр Хөрмәтулла, өченчесен чуаш Ы́чтапан алыр. Ә инде аң-акылларын салсаң бизмәнгә, ниндидер аерымлыклар булса да, өчесенеке дә бертигез тартырга мөмкин. Бу аларның авыр чакта да кешелекле була белүләренә бәйләнгән. Котлызаман агай да бит, нәкъ Ы́чтапан дәдәй кебек, Хөрмәтулла абзый язмышы өчен сөйләшергә килгән.

— Башкорт мактанырга яратмый, мулла абзый, ундай гәзәт миндә лә юк, үзең беләһең, һуғышыусыларзы ла енем һөймәй; көрәштә майдан тотһам да, мәгәр кешегә үлеп асыуым килгәндә лә тырнак менән сиртмәнем; тик был юлы Хөрмәтулланы тереләй күмергә йөрөүселәрзе бына был кәшәкә йозроғом менән һыйлайым әле...

Сөйләшү, фикер алышу, сүз куешу шактый озакка барды. Нәтиҗә-сөземтәне һәр очракта Гыйрфан мулла ясады. Ы́чтапан дәдәй, гәрчә күңеле саф булса да, сөйләгәндә, тел осталыгы җитмәгәнлектән, салулый торган гадәте бар.

— Уйламый әйтелгән бер сүз — аз ашка салынган күп тоз, Ы́чтапан кордаш, әгәр сөйләсәң, сүзләреңне чамалап чыгарырга тырыш, буталырлык булма, — дип кисәтте аны Гыйрфан мулла.

Котлызаманга да кисәтү ясады:

— Йодрык — берне, акыл меңне җиңгәнлекне беләсең бит инде, Котлызаман туган, син алай бик әтәчләнмә әле, мондый буталчыклыкта уйлап эш итү хәерлерәк булыр, — диде.

## III

Алпавыт урамы уртасына халык умарта күче урынына ябырылды. Карт-коры, бала-чага, әби-чәби, бичә-чәчә, кыз-кыркын, аксак-туксак, гарип-гораба... — кемнәр генә юк анда. Бәгъзе берсе, мулла-мәзин, мәтәвәли-фәлән, хәлле-мәлле кебекләре — җом-

гага, гаеткә барганда, аш-суга йөрешкәндә генә кия торган затлы чапан, казаки, түбәтәй, итек-читек кигәннәре — анда-санда тамак кырыштыру, үзләрен бөркет оясындагы асылташны әләктерә ала торган каһарман ир-егет икәнлекләрен күрсәтергә тырышып, чыш-пыш сөйләшеп йөриләр. Өсләренә укалы чибәр камзул, аякларына болгар читекләре кигән, башларына аллы-гөлле яулык бәйләгән байбичәләр төркеме дә агыла. Алар, инде түл җыеп та мәңге гәпләшеп туя алмаган ана үрдәкләрдәй, үзенчә бер горурлык сакларга тырышкан кыяфәт белән, мыгыр-мыгыр сөйләшеп атлыйлар. Ак күлмәк өстеннән кара камзул, аякларына көзгедәй елтырап торган күн итек кигән, бер басасы урынга биш басып торган түбәтәйле кыланчык, көяз, шаян, хәлле егетләр дә төркем-төркем булып масаеп йөри. Алар икенче бер төркемгә — һәрберсе бер чәчкәне хәтерләтеп торган кызлар җыелмасына — кырын-кырын карап узалар. Берсе — ак, икенчесе — кызыл, өченчесе — зәңгәр, дүртенчесе көрән күлмәк кигән бу кызлар ак, кызыл, зәңгәр, көрән чәчәкне төсмерләтә. Ак калфак өстеннән бәйләгән яулыклары да бер-берсенекенә охшамаган. Һәрберсендә бер чәчкә төсе бар. Алар нидер сөйләшә, серләшә, сүзләрдән бетмәс-төкәнмәс мәзәк тапкандай, егет-җиләнгә, өлкәннәргә сиздермәскә тырышып, җиңелчә генә көлешеп куя. Әлбәттә, әлеге кыланчык егетләргә бу купшы кызлар, йөзләрен усал караштан саклау өчен каплаган яулык читен ачып, анда-санда күз атып алырга да онытмыйлар. Үткеррәк егетләр моны сизеп тә ала. Ул яулык эчендә сөрмәле серле күз, ал яккан бит очы, пешкән чиядәй тулышкан ал иреннәр барлыкны аңлый. Шул гүзәллек эченә кереп чумасы килә аның. Ләкин — ярамый. Өлкәннәр кушмый. Алар — әдәплелек иманын яклаучылар. Егетләрнең йөрәген яндырырга, нәфесләрен тагын да ныграк кымҗыртырга, өмет чаткыларын дөрләтеп-ялкынландырып җибәрергә тырышып, кызлар өзелергә торган нечкә билләрен бөгелдереп-сыгылдырып, аркаларына сузылып яткан калын, нәфис толымнарын чайкалдырып, чулпыларын чыңлатып алырга да онытмыйлар.

Әбиләр чуагының иң матур кояшлы бер көне әйтерсең Солтанморатның хәлле кешеләренә бер-берсенә бәйрәмнәрдә генә кия торган иң затлы киемнәрен күрсәтешеп алу өчен бирелгән. Инде җәйге, көзге эшләр, кем әйтмешли, тозлап-борычлап тәмамлап куелган, саламы-печәне ташылып, лапас түбәләренә өелгән, бодае, борчагы, арпасы, солысы, тарысы...— һәммәсе, һәммәсе үзләренә тиешле бурага салынган. Халык гүя Хөрмәтулланы тереләй кабергә күмү өчен түгел, сабан туендагы тамашага җыелгандай, көзге икмәк туе бәйрәменә агыла. Дөньяда әйтерсең бернинди дә гөнаһ, шомлылык, күз

яше түгү, низаг-хәерчелек юк, фәкать матур киенгән затлы кешеләр һәммәсе тантана итә.

Бодай арасында буталган кырлыктай, гөлбакчаны ямьсезләгән чүп үләнедәй, матур-чибәр төсләләр тирәсендә алама-солама киемле гавам халкы да кайнаша. Җеп бишмәт киеп, билен тыгызлап буган, аксыл-саргылт сакаллары түшенә төшкән авыру күзле чуашлар да, алача күлмәк-ыштан кигән башкортлар да, алатыр татарлары да, мишәрләр дә, типтәрләр дә бар. Ертык-мыртык, кырык ямаулы кием кигәннәр үзләре бер тирәдә төркем-төркем булып йөри. Тегендә шау-шу, монда шау-гөр, бер урында чыш-пыш сөйләшү, икенче җирдә кычкырып-кычкырып, кул болгый-болгый бәхәсләшү китте. Һәркем булачак фаҗигагә карата үзенең хөкемен алдан ук әйтеп куярга ашыга.

Ыстараста Бүксә Тәхлис, хөкемне язып барырга тиешле сәркатип Галинур, Мөбахис мәзин, авылның кайбер куштаннары, бер әчмүхә чәйгә сатылган шаһитлар халык җыенының урта бер җирендә танавын танауга, колакны колакка куеп гәпләшә. Боларның бөтен максаты шул: Хөрмәтулланы тизрәк кара җир куенына тыгу.

Гыйрфан мулла, беркем белән дә әңгәмә-мәңгәмә кылмыйча, хөкемдарлардан әллә ни ерак булмаган бер урында басып торды. Галимҗан әтисе янында булырга тырышты. Хәсәнә абыстай, Хәмдия кендекәй, Көнсылу... тагын да берничә сылу-сылу, чибәр-чибәр киенгән хатын-кыз алардан ерак булмаган урында үзләренчә сөйләшеп тора. Аларның йөзләре боек, күңелләре сүренке, рухлары төшенке икәнлек әллә кайдан сизелеп тора. Шулардан ерак түгел бер урында — Хөрмәтулла абзыйның җәмәгате Мәликә түти, кызы Мәдинә. Галимҗан аларга әледән-әле күз сирпеп ала. Мәликә түти дә, кызы Мәдинә дә теге вакыттагыча киенгән. Мәликә түти, кадаклап куйган торараштай, шул урында катып калган. Мәдинә аның янына басып каткан. Алар кырына берәү дә килми. Алар беркем белән дә сөйләшми. Хәер, аларның сөйләшер хәлләре дә юктыр.

Галимҗан бер нәрсәгә аптырады: Чуртан белән Кикрикүк кайда икән? Башка малайлар чыж да выж йөреп тора. Ә алар — юк. Әллә һаман сарык эзләп йөриләрме? Нигә бу юлы Галимҗанга әйтмәгәннәр?

Менә бервакыт:

— Киләләр...— дигән каты тавыш яңгырады.

Халык дулкыны тынып калды. Өч каравылчы куллары артка каерып бәйләнгән Хөрмәтулланы алып киләләр иде.

Галимҗанның йөрәге жу итеп китте. Теге вакытта, төнлә, гәрчә ишектән аз гына ай яктысы төшсә дә, аның йөзен ул күрмәгән иде. Бу йөзгә хәзер карарлык та түгел. Бит очла-

ры, маңгае, ияге күгәреп-бүлтеп чыгып, кара канга манчылган. Теге вакытта Алып батырны хәтерләтеп торган пәһлеван хәзер бәләкәйләнеп, кечерәеп, өтек куркәгә охшап калган. Аның нык кыйналганлыгын җүләр дә аңларлык. Бетергәннәр кешене. Изгәннәр. Мескен иткәннәр.

Менә аны мәйдан уртасына китереп туктаттылар. Анда — бәләкәй генә өстәл. Өстәл артында вакыйганы язып барырга тиешле сәркатип Галинур утыра. Аның янында юан мичкә. Кыска буйлы Ыстараста Тәхлис шул мичкәгә басып сөйләргә тиеш. Менә ул, әллә күпме кешеләр ярдәмендә, шунда күтәрелде. Аннан, күрәсезме гайрәтемне дигәндәй, халык дулкынына күз йөртеп чыкты; үзенең мәртәбәле кеше икәнлеген аңлатырга тырышып булса кирәк, берникадәр мактану төсе дә сиздереп, байларча тамак кырып алган булды. Аннан, кулларын болгый-болгый, булган хәлне гавам алдына ачып салды, әмма хөкемне үзе әйтмәде — анысын шаһитларга калдырды: бу аның буталчык суда йөзмәгән балык икәнлеген күрсәтү өчен иде, сүзне ул Хөрмәтулланың күршесе беренче шаһит Хәмәтдин картка бирде.

Хәмәтдин картның яшереп тәмәке тартуын һәркем белә. Моны гәрчә кешегә сиздермәскә тырышса да, тәмәке төпчегеннән саргаеп каткан бармак-тырнаклары, сирәк тешләре, ярылып ергаланган иреннәре, ике-өч адымнан ук аңкып торган сасы исе әйтеп тора. Әлеге көнне Хөрмәтуллалар ягыннан тәмле ит исе килүе турында сөйләде. Үзенең еллар буе бер ит шулпасы капмавы, Хөрмәтулланың исә кеше сарыгы суеп ләззәтләнүе турында ачыргаланып әйтте. Әмма ул да, хәйләкәр Тәхлис кебек, хөкемен әйтмәде. Бу аның куркаклык билгесе иде. Ыстараста бер хәйләкәр төлкенең җиде бүрене сугыштырганын яхшы белә. Хәйлә тозагына эләккән Хәмәтдин карт ерткыч бүре түгел — куркак куян. Аны өркетү — бәрәңге ашау кебек җиңел хәл.

— Һәр юлның бер очы, һәр сүзнең бер азагы, сөземтәсе була, Хәмәтдин абзый; ул синең борыныңа тәмле ис алып килгән сарык итенең Мөбахис мәзин сарыгы ите икәнлекне яхшы беләбез, бу хакта сөйләп тору кирәкми инде. Сез хәзер шуны әйтегез: сарык урлаучыга ни җәза бирәбез?

Хәмәтдин карт кырык җирдән тишелгән, бәлшәеп беткән киез эшләпәсен салып, аны, шуның белән киңәшләшеп алгандай, учында кат-кат йомарлады; аннан, куркудан агарынып каткан йөзен халыктан яшерергә тырышып, башын аска иде, дер-дер калтыранып, җебеп төште. Ыстараста кат-кат әйтеп, аны йокысыннан айнытырга тырышты, әгәр тиешле сүзен ярып салмаса, Хөрмәтулла урынына үзен гаепләячәк белән куркытты. Шуннан соң гына, тотлыга-тотлыга, ыстараста алдан өйрәтеп куйганча, мең авырлык белән:

— Мин... ни... шуны әйтәм... Хәртине... Хөрмәтне... тереләй күмәргә... ыххым...

Шундый ук сүзләрне Тәхлис үзе әзерләгән янә ике шаһиттан — сатлык җаннардан әйттерде. Аннан, үзен ныгытма алган солдаттай горур тотып, тәмам җиңгәнен сизеп:

— Шуның белән халык хөкеме тәмам, җәмәгать, өч шаһитраслады, таралырга мөмкин,— диде.

Хөрмәтулла сүзсез генә басып торды. Башкалар да өнсез иде. Әйтерсең һәммәсе авызына су капкан. Шул суның түгелеп китүеннән курка. Әмма авызлар ачылды. Сулар түгелде. Халык диңгезе кайнашырга тотынды. Әллә күпме сүзләр яңгырады:

— Бу нинди ахмаклык...

— Авылның өч ачыган ялкавы кеше башы ашый...

— Сатылганнар алар...

— Халык хөкеме болай булмый...

Умарта күче урынына бераз гөжләп алгач, мәйдан уртасына Гыйрфан мулла чыгып басты.

— Мин дә бу хөкемгә каршы. Хөрмәтулланың сарык урлавына тамчы да ышанмыйм. Башкалар да сөйләсен. Алар да минем фикерне әйтер,— диде.

Аның сүзләрен башкорт Котлызаман куәтләде:

— Ғирфан мулла дөрес әйтә... уның һүҙҙәренә кушылам... Хөкем эше түгел был... Этем эше...

Аның соңгы сүзләреннән җиңелчә генә көлеп тә куйдылар. Чуаш Ычтапан кул күтәргәч, көлү янә көчәеп китте: ни әйтер инде бу «телсез», янәсе. Ул да күп сөйләмәде. Тиешен генә әйтте:

— Пез пер намәне аңлап петермәйпес... Кем күргән Күрмәтулланың сарык урлаганын?.. Пермәү дә күрмәгән... ул миңә ишек ясады... Шуңа акча пирдем... шул акчага ул сарык итен сатып алган... Мин Кирпан мулла яклы... хөкем дөрес түгел...

Халык дулкыны янә чайкала башлады. Бер-бер артлы төрле сүзләр ыргытырга керештеләр:

— Гыйрфан муллага кушылабыз...

— Хөрмәтулла сарык урламас...

— Мөбахис мәзиннең комсызлыгын беләбез...

Бер үк вакытта мәзин яклылар да күтәрелде:

— Каракны яклау — оят...

— Тереләй күмәргә...

— Беләбез Хәртине...

— Ат карагына сарык урлау бәрәңге ашау кебек кенә...

Тавышны Гыйрфан мулла бүлде:

— Туктагыз әле, җәмәгать, суган базары түгел ләбаса бу, шауламагыз, сүзне Хөрмәтулланың үзенә бирик...

Гыйрфан мулланың калын тавышыннан соң, йөзләгән күзләр канга манчылган Хөрмәтуллага төбәлде: аның нидер әйтүен көттеләр.

Хөрмәтулла ашыкмады. Күкрәк тутырып бер тын алды да «уф» дип куйды. Халык аның хәле авыр икәнлеген аңлады. Һаман да эндәшмәгәч:

— Әллә телдән калдымы...

— Бәй, шулкадәр тукмалуга...

— Изгәннәр бит...

— Моны күмәсе дә калмаган инде...

— Болай да җан биру чигенә җиткән...— диештеләр.

Хөрмәтулла янә бер авыр тын алып куйды. Аның күзләре мәзәкләнде. Бөтен тәне калтыранырга тотынды. Һаман эндәшмәгәч:

— Бетте бу...— диде кемдер.

Ләкин ул бетмәгән иде әле. Аның авызы тулы кан. Халык алдында шуны төкерергә кыенсынып торды. Хәзер инде, сүз әйтергә кирәк булгач, аны эчкә йотарга булды. Бусы да бик авырга туры килде. Төкерек йотар рәте дә калмагач, хәленең чыннан да мөшкел икәнлеген аңлады ул. Сөйләргә дип авыз ачса, тамак төбе гыжлады, тик сүзе генә чыкмады. Халык арасында тагын төрле сүз китте:

— Бетте бу...

— Ни сөйли ала инде ул...

— Нигә кирәк аның сөйләве...

Тавышны янә Гыйрфан мулла бүлде. Бу юлы ул гаепләнүченең үзенә мөрәҗәгать итте:

— Хөрмәтулла туган, монда синең язмышың хәл ителә. Күрәм — авырсың. Шулай да әйт бер-ике сүз.

Халык шактый озак көткәч, ниһаять, берничә сүз әйтерлек көч тапты ул:

— Мин... сарык ырламыйм... Мине төбәнсетмәгез... Мин ат карагы... ат ырлыйм... «ат карагы» дип хөкем итегез...

Халык шым булды. Күпләрнең күзе акайды хәтта. Кем инде үзенең ат карагы икәнлеген әйтеп торсын ди. Әллә акылдан язамы югыйсә? Бу сүзләрнең төбендә берәр серле хикмәт бармы? Ә инде Мөбахис мәзин өчен бу җитә калды:

— Менә, җәмәгать, ишеттегезме моның сүзен. Теге вакытта әйтә килдем, әйтә килдем, атымны шушы мөртәт кенә урлау турында әйттем. Сүзем өскә чыктымы? Чыкты. Хәзер аны «ат карагы» дип тә хөкем итәбез...

Баштан ук сүз әйтергә ярсып торган Мәликә:

— Туктагыз!..— дип кычкырып җибәрде.

Ул, атылып, мәйдан уртасына чыкмак булды. Кемдер аның беләгеннән тотып алды. Бу «ярамый» дигәнне аңлата иде. Хатын-кызга ир-ат алдында сөйләү гөнаһ, янәсе. Шулай да

ул чигенмәде. Бу пычрак гайбәт бөтен нәсел-нәсәп өстенә ябыла бит. Тәмам ярсыган Мәликәне тотып тордылар. Ә ул, ут чәчәрдәй булып, сөйләвен белде:

— Ат ярата ул... Бервакыт төшендә ат урлаган... Шуннан, мәзәк итеп, үзен «ат карагы» дип сөйләп йөри... Кешенең энәсенә дә тигәне юк аның... Әле менә «сарык буры» дигәнгә гарьләнүеннән әйтә... «Ат карагы» данлырак, янәсе... Хөрмәтулла!.. Нигә ялганлыйсың?.. Ат урласаң, болай ярлы яшәмәс идек бит...

Тәмам ярсыган Мәликә, үзенең халык алдында икәнлеген бөтенләй онытып, үксеп-үксеп еларга тотынды. Нәкъ шул вакыт сарык алып килгән дүрт малай күренде. Муенына җеп бәйләгәннәр. Бау — Апуш кулында. Арттагы өчесе сарыкны эткәләп-төрткәләп килә. Сарык, күрәсең, барырга карыша. Алҗыган-йончыгандыр, бәлки. Әллә ят кулларны сөймиме? Бик мөмкин. Хайванда хәйләкәрлек тә җитәрлек була. Ә малайлар сарык белән аслан исәпләшми. Өстерәпме-өстериләр.

Менә алар, тамаша кылып карап торган халыкны ера-ера, мәйдан уртасына җитте. Апушның үткен күзләре Мөбахис мәзинне эзләп тапты. Тапты да җепнең очын аңа китереп тоттырды.

Бу Мөбахис мәзиннең кара сарыгы иде.

## IV

Галимҗан, бу хәлләрнең барын да күңеленнән кат-кат кичереп, барлык вакыйгаларны акыл казанында кайната-кайната, аларны соңыннан үз хис-тойгы бизмәненә салып үлчи-үлчи барды. Иң үкенечлесе шул булды: сарык эзләргә соңгы мәртәбә барганда, Апуш аңа әйтмәгән. Моның ни сере, ни хикмәте, ни яшеренлеге бар икән тагы? Әллә аны, чыннан да, Чирле чәүкә дип кимсетәләрме? Көченә, чослыгына, үткерлегенә ышанмыйлармы? Андый-мондый көтелмәгән күңелсез хәл килеп чыкса:

— Кайгырма, балам, бер яманлыкның бер яхшы ягы булмый калмый ул,— дип юата иде әнисе.

Шуны уйлап, яманлык чүмәләсе эченнән яхшылык гәүһәре эзләргә тырышты ул. Күп чокчына торгач — тапты: әгәр Апуш белән тагын да сарык эзләп киткән булса, ул мондагы халык диңгезе манзарасын күрми калыр иде. Яхшылык белән яманлык кына түгел, әнисе әйткәнчә, матурлык белән ямьсезлек тә даимән тәңгәл йөриләрдер, күрәсең. Әтисенең көче, гаделлеккә җанын фида кылырга торуы, җиңеп чыгуы, кеше язмышы өчен йөрәк ялкыны белән көрәшүе аның

күңелендә мәңге сүрелмәслек горурлык уты кабызды. Тик Хөрмәтулланың кыланышын гына аңлап бетермәде ул. Ни өчен үзен ат карагы итеп күрсәтергә тырыша? Үлем чигендә дә үзсүзле пәһлеван булып калырга телиме? Шуның белән бәндәчелек кодрәте күрсәтәме? Ничек кенә булмасын, Хөрмәтулла абзыйсы аның күңелендә, теге вакыттагы кебек, яхшы тәэсир калдырды.

Мәликә түтинең чәчрәп чыгуы, ире язмышы өчен утка керергә әзер торуы, йөрәген өзеп бирердәй итеп сөйләве дә Галимҗанның күңел кузын күпкә дөрләтеп җибәрде. Янында сулыш алырга да куркып торган кызы Мәдинә чын мәгънәсендә Акчәчкә иде бит. Галимҗан аңа да вакыт-вакыт күз сирпеп алырга онытмады. Дөрес, Акчәчкә шиңеп бара төсле. Бу, мөгаен, әтисе кайгысыдыр. Шулай да ул һаман әле, шундый авыр мәлдә дә, усал җилләргә, кырауларга, көзге салкыннарга бирешми торган дала чәчкәсен хәтерләтә.

Яхшылык белән яманлык, шәфкатьлелек белән шәфкатьсезлек, бәхетлелек белән бәхетсезлек чәкәләште. Маңгайны маңгайга куешып якалаша-якалаша — элек тә шулай булганмы? Бу күңелсезлек гомер бакый дәвам итәрме?

Вакыйгалар да тиз үзгәрә. Көннәр дә, атналар да, айлар да, еллар да. Ул көнне җылы иде әле. Шуңа күрә халык җәйчә дә, көзчә дә киенгән иде. Яки яшьләр — җиңелчә, картлар — калын. Икенче көнне болар юлга чыкканда да, сандугачлы алсу таң ук булмаса да, табигать җәйчәрәк тын ала иде әле. Бераз баргач, җәй җилләре кайдадыр сеңде, аны көз җилләре алыштырды; ул гына да түгел, кара-кучкыл болытлар куера, канатына кар катыш яңгыр төягән усал, салкын җилләр котырынып килде. Галимҗан толып эченә чумды.

Атасы толыпны алмаска да тырышкан иде.

— Һи, әнкәсе, әле әбиләр чуагы лабаса,— дип карышкан иде.

— Соң, атасы, юлга чыкканда борынгылар да җәйге челләдә тунны калдырмаска кушканнар бит,— дип, үз сүзен сүз итте әнисе.

* * *

Уйлар диңгезендә йөзә-йөзә, Галимҗан, акрынлап, әвен базарына китә башлады. Йокларга теләмәгән иде ул. Гәрчә күз кабаклары авыраюын сизсә дә, бөтен тәненең ниндидер рәхәтлек эчендә оеп баруын тойса да, ул ләззәтлелектә эрергә теләми иде. Шулай да йокы җиңде. Татлы хыяллар толып тышында калды. Толып эчендә ул икенче бер хыялый дөнья дулкынында йөзә башлады. Дулкын. Ниндидер ефәк

дулкын. Шул дулкыннар, төреп алып, аны күккә чөйде. Бераздан ул янә җиргә төште. Бакса, җир өстен ниндидер кара дулкын каплады. Ул дулкын Галимҗанга таба да ябырылды. Инде бетәм, үләм, кара дулкын астында калам, дип куркып торганда, имәнеч зур канатлы бер кош очып килеп, аны тагын да күккә күтәреп алып менеп китте. Алып менеп тә китте, бер очлы тау башында калдырып, үзе икенче очлы тау башына барып кунды. Бәй, бервакыт ул өй дәүмәллеге ак кош кешегә әверелде. Бу кеше Хөрмәтулла абзый булып чыкты. Хөрмәтулла абзый тора-бара коточкыч зур Алып батырга әверелде. Киеме алтыннан, имеш. Үзе ул мәчет манарасыннан да озын. Башы казан дәүмәллеге. «Казанга» шул ук зурлыкта алтын такыя кидерелгән. Аягындагы искиткеч зур итекләре дә алтыннан. Бер алтын кош очып килде дә әнә шул алтын такыяга кунды. Бусы аның җәмәгате Мәликә түти булып чыкты. Мәликә түти башына бәләкәйрәк икенче бер алтын кош килеп кунаклады. Монысы — Акчәчкә. Бераз торгач, Хөрмәтулла абзый, аларның икесен ике уч төбенә утыртып:

— Курыкмагыз, акыллыларым, кара дулкын өстенә мин ак җәймә җәям; ул ак җәймә бөтен кешегә бәхет китерәчәк,— диде.

Бер өргән иде, чыннан да, кара дулкын өстенә көмештәй елкылдап торган ак җәймә җәелде. Шуннан ниндидер кодрәт белән Галимҗанны да үз янына тартып алды ул. Тартып та алды, Акчәчкә белән икесен бергә бастырып та куйды. Шулай итеп, алтыннан киенгән ике пар — ике куш мәхәббәт басып тора хәзер.

— Мин пәйгамбәр, син дә пәйгамбәр, Галимҗан, ә болар — фәрештәләр,— ди Хөрмәтулла абзый.

Бәй, ни гаҗәп, «Хөрмәтулла пәйгамбәр», «Мәликә фәрештә», «Акчәчкә фәрештә» бермәл очтылар да киттеләр. Галимҗан берүзе калды. Дөньяны караңгылык каплады. Шул караңгылык эчендә очты да очты Галимҗан. Ул яктылык эзләде. Ә яктылык юк та юк. Оча-оча канатлары сына башлады. Бу аның соңгы сулышы, соңгы минуты, яшәү өчен көрәшнең соңгы секунды иде. Сулыш кысылып, минутлар, секундлар өзелеп, канат челпәрәмә килгәч, ул караңгы базга гөпелдәп килеп төште.

Озак ятты базда Галимҗан. Калкыныр иде — аны ниндидер авыр таш белән бастырып куйганнар.

Менә бервакыт ташны кемдер алып ыргытты. Галимҗан аякка басты. Аны коткаручы кеше Хөрмәтулла абзыйсы иде.

Хөрмәтулла бер өргән иде — алсу таң атты. Кинәт әнисенең Галимҗанны пәйгамбәр итеп төшендә күрүе хәтеренә

төште. Димәк, бу алсу таң — Галимҗанныкы. Бу — пәйгамбәр таңы!

Уянып китсә, анын толыбы ачылган икән. Йоклаганда тирләгән булса, хәзер салкын җил өрә икән. Анын янында чикмәнгә төренгән Шакирҗан йоклап ята. Кар катыш яңгыр һаман сибәли дә сибәли. Кәҗән кигән Гыйрфан мулла артка әйләнеп караштыргаласа да, Галимҗанның хәлен шәйләмәгән иде. Хәзер инде аңлап алып, атларны туктатырга мәҗбүр булды.

— Их, юньсез малай, мин бит сине толыпка төргән идем, нигә ачтың, карачы, күшеккән тавык кебек булгансың бит, — дип тиргәде Галимҗанны әтисе.

— Йоклап киткәнмен бит, әткәй...

— Тыңламыйсың. Киресең. Шуңа «чирле чәүкә»сең... Мәдрәсәдә синдәйләрне бик яратмыйлар. Ярый ла кеше булалсаң, яхшы укысаң...

* * *

Әтисенең соңгы сүзләре — «ярый ла кеше булалсаң» дигәне — Галимҗанның йөрәгенә ут якты. Ә нинди кеше булырга? Хөрмәтулла абзый кебек кара дулкыннарга ак җәймә җәючеме? Җәя алырмы? Әллә үзен шул кара дулкыннарга ташлап изәрләрме? Аны азат иттеләр. Әмма авыл буйлап имеш-мимеш давылы котырынып йөреде. Имеш, Гыйрфан мулла Ырынбурга киткәч, Хөрмәтулла абзыйның хөкем эшен яңадан караячаклар. Мөбахис мәзин җиңелеп кала торганнардан түгел, янәсе. Ул әле киләчәктә, Ходай уң кылса, Гыйрфан мулла кебекләр белән гарше көрсидән торып сөйләшәчәк. Инде ни кирәк? Нахакка Хөрмәтулла абзыйның измәсен изгәннәр, кабыргаларын, кулларын сындырып, канга батырып ташлаганнар. Сарык табылды бит. Хәзер Мөбахис мәзиннең үзен хөкем алдына тезләндерергә кирәк. Ә ул, Ходайдан курыкмыйча, һаман келәт астыннан өреп яткан эт кебек кылана. Кеше булырга?! Нинди кеше?!

Бу сорауга тәгаен генә җавап бирә алмый иде әле Галимҗан. Хәер, кәбестә шикелле катлы-катлы булган бу мәсьәләнең асылына кем төшеп җиткән инде. «Көрәш» дигәне әллә үзе шулмы? Кем өчен кирәк ул көрәш? Кеше язмышы өченме? Бөтен дөньядагы кешеләр язмышы өченме? Бу уйлануларның йөрәгенә орлык булып сибелүен Галимҗан аслап аңламый әле. Ул орлыкларның шытып тамырлануын да аңлап бетерми. Киләчәктә шушы уйланулар аны зур язучы итәчәк турында хәзергә анын гамендә дә юк. Унтугызынчы гасырның соңгы айлары. Алар укырга килә. Ырынбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә. Нәкъ шушы 1899 елда булачак та-

тар классигы Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле әсәре нәшер ителгәнне Галимҗан белми әле. Шушы ук елда киләчәктә үзе кебек үк зинданнарда иза чигәчәк Гаяз Исхакыйның Пушкин әсәре «Капитан кызы»н тәрҗемә иткәнлеге аның әле ике ятып бер төшенә дә керми. Ул тирәякка даны таралган «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга бара. 1902 елда Гаяз Исхакыйның «Хөсәения» мәдрәсәсенә хокук белеме мөдәррисе буларак килүен алдан белсә дә, аның әллә ни исе китмәс иде. Чөнки аңа Гаяз Исхакый ни, тегесе ни, монысы ни — барыбер.

Тик Галимҗанга, Шакирҗан абыйсы кебек, Гаяз Исхакый дәресләрен тыңларга насыйп булмаган икән. Шакирҗан абыйсының эшләре һәрвакыт майлы табада шуган коймак кебек шома бара. Ә нигә Галимҗанга җил гел кире яктан исеп тора? Әтисе-әнисе әйткәнчә, әллә кешенең уңай сыйфатларын билгели торган холык-фигылендә кире яклар булгангамы? Ә ничек бетерергә ул кирелекне? Канга сеңгәнне пычак белән кырып ташлап та булмый, имеш. Ул, самавыр юшкыны шикелле, мәңге шулай каткан килеш торырмы?

Алмадылар Галимҗанны «Хөсәения» мәдрәсәсенә. Безне капчыкта яткырып булмый шул. Сәламәтлеген тикшергәндә, Гыйрфан мулла, оятын олтырак итеп булса да, алдашу юлына басты:

— Абыйсы Шакирҗан кебек инде...

— Бер чире дә юк...

— Белеме дә Аллага шөкер...— дигән сүзләрне әйтте.

Нәкъ шул вакыт Галимҗан буылып ютәлләргә тотынды. Ишек төбендә торган бер савытка барып кан төкерде. Юлда әлеге ачылган толыптан өргән җил, күрәсең, аның үзәгенә үткән.

— Мондыйны без кабул итә алмыйбыз,— диде табиб.

Мәдрәсә башлыгы мөдәррис аның сүзләрен хуплап куйды.

Гыйрфан мулла сүз көрәштерүнең файдасы юклыкны аңлады. Троицк мәдрәсәсендә үзенең дә шулай рәхимсез кылануын искә төшереп, үкенеп тә куйды. Кешегә аткан таш үзеңә кайтыр, җилгә төкергән төкерегең үзеңә чәчрәр, ди. Бу әллә шуның бер яшерен, серле гыйльләсеме? Син бит, үзеңчә, дөреслеккә барам дип уйлыйсың, кыек юлга кереп киткәнлегеңне сизми дә каласың. Менә хәзер, авыру дип кеше исәбеннән чыгарып, кайда куярга баланы? Кире алып кайтып китәргәме? Бу авырлыкны Хәсәнә күтәрә алмаячак. Мондый очракта «төртергә» кирәклекне белә Гыйрфан мулла. Әмма аның кешелеклелек сыйфаты, ялган юлдан качарга тырышып яшәве, дөреслек иманын тотарга тырышуы «төртү» кебек күңелсез хәл белән һич килешә алмый. Шуңа кү-

рә, язмыштан узмыш юк, дигән канунга буйсынып, Шакирҗанын калдырып, Галимҗанны «Хөсәения» мәдрәсәсеннән алып чыгып китәргә мәҗбүр булды ул. Белә: монда Вәли мулланың кадим мәдрәсәсе бар. Әмма ул җыен калдык-постык, гарип-гораба, надан-маданны кабул итә торган мәдрәсә. «Хөсәения» тау башында арыслан булып горурланса, бу — тау итәгендәге мескен куян. Шунда калдырыргамы баланы? Рухи яктан имгәнеп бетмәсме? Пәйгамбәрдән иблис килеп чыгуы мөмкин. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың бит. Вәли хәзрәт арбасының төбе тишек, күчәренең черек агачтан икәнлеген яхшы белә ул. Нишлисең, кем әйтмешли, бодай юк икән, арпа чәчәсең. Тик арпаны бодай итеп кенә булмый. Галимҗанны Вәли хәзрәт мәдрәсәсендә калдырып китәргә туры килде.

## V

Ырынбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсе ике катлы таш йорттан гыйбарәт иде. Аның беренче каты җирне уеп эшләнгән. Ул берникадәр солдат землянкасын хәтерләтә. Аның диварлары, эчтән дә, тыштан да суланып, мүкләнеп беткән. Тәрәзәләре карыш каткан. Идәннәр пычрак. Икенче кат та шуннан әллә ни ерак китә алмаган. Тар гына коридор. Ике якта ике ишек. Һәр ишекне ачып керү белән синең борыныңа күңел болгаткыч сасы ис килеп бәрелә. Килеп керүче аның ишек төбендәге чүп өелмәләреннән чыккан ис, ләгәндәге болганчык су буы кушылмалары исе икәнлеген абайламаска мөмкин. Янә аңа бик сирәк мунча керү аркасында шәкертләр тәненнән, киеменнән чыккан әчкелтем-төчкелтем ис өстәлә. Пычрак идәннән күтәрелгән тузан, шулар белән аралашып, кеше үпкәсе өчен зарарлы һава ясый.

Вәли әфәнде Гыйрфан мулланы хөрмәт илә каршы алды. Утырып дога кылышкач, ару гына хәер төртте дә Гыйрфан мулла:

— Мөхтәрәм Вәли әфәнде, бала язмышын бер Хода вә дәки сез остазга тапшырдык инде; ул, иншаллаһ, йөзебезгә кызыллык китермәс, пәйгамбәрләр зиһене булса да, зирәк күренсә дә, сәламәтлеге әлегә бигүк күркәм түгел шул, — диде.

Вәли мулла аның белән тәкъдирен хөрмәт итеп, олылап сөйләште. Галимҗанның сәламәтлеге йомшак икәнлекне искә алып, үткен җил тимәсен өчен, аны тәрәзәдән ераграк торган урта бүлмәгә урнаштырдылар. «Бүлмә» дигәне тактадан түгел, чүпрәктән эшләнгән. Кияү өчен әзерләнгән чаршау, дип әйтергә дә мөмкиндер аны. Чаршау белән әйләндереп алын-

ган һәр «бүлмә»дә икешәр, өчәр, дүртәр шәкерт тора икән. Вәли мулла иҗтиһады белән Галимҗан ике кешелек бүлмәгә урнаштырылды.

Гыйрфан мулла Вәли әфәндегә бихисап рәхмәтләр әйтеп, аңа янә дә өстәмә хәер төртеп, аның сау-сәламәтлеге, бәхет-сәгадәте өчен даимән дога кылып яшәргә вәгъдә бирде. Дөрес, бу кадим мәдрәсә аның күңелендә, табигый ки, яхшы тәэсир калдырмады. Троицкиныкында сафлык хөкем сөрә иде. Моны ул, уратып-чолгатып булса да, Вәли мулланың күңеленә кылчык кадамаска тырышып, саклык белән генә сөйләп тә бирде.

Вәли әфәнде Гыйрфан мулланың шактый мәгълүматлы, заһир, мөхтәрәм шәхес икәнлеген нык аңлады. Аның тәнкыйди сүзләрен чырай сытыбрак кабул итсә дә, тамак кырып, һич кирәкмәгәнгә сакалын сыпыргалаштыргалап, чалмасын рәтләштергәләп алып, ачу-фәлән, үпкә-сапка белдермәскә тырышты. Улы Галимҗанга даимән күз-колак булып торырга, аны кирәк чакта якларга сүз бирде.

Галимҗан әтисенең ачык күңелле, шактый киң даирәле булуы, кешелеклелек сыйфатлары ошады Вәли әфәндегә. Гыйрфан мулланың данлыклы Троицк мәдрәсәсеннән китеп, авылда җир эшләре, хуҗалык, малчылык белән шөгыльләнүенә хәтта шатланып та куйды. Баксаң, Вәли мулланың үз хыялында да андый омтылыш, һавалану, ярсу булмаган түгел икән. Әмма алар, үзе әйтүенчә, иртән төшкән чыкның кояш күтәрелә башлау белән юкка чыгуы кебек булып калган. Кыскасы, Вәли әфәндегә Гыйрфан мулла мисалында табигать кочагында яшәү насыйп булмаган.

Алар шулай фикер-фәтва алышып, киләчәктә хатлашып торырга сүз куешып, дусларча аерылыштылар.

— Укуда мөмтаз булачагың шөбһәсез, таш маңгаем, әмма ләкин бәндәчелек өчен ул гына җитми әле, үзеңне шәкертләр арасында да, Вәли мулла, хәлфә, мөдәррис, пишкадәмнәр, башка зыялылар алдында да инсафлы тотарга тырыш, — диде атасы хушлашканда.

Галимҗан:

— Ярар, әткәй, син дигәнчә булыр, кайгырма, исән-аман кайтып җит, — димәкче иде, әмма тамак төбенә ниндидер төер килеп тыгылды. Ул ютәлләргә кереште. Кан төкерде.

Кайткач, Гыйрфан мулла остабикәсенә юлда булган мәшәкатьләрне, табигатьнең рәхимсез булуын, мәдрәсәдәге хәл-әхвәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Тик Шакирҗанның «Хөсәения» мәдрәсәсенә, Ходай кушу буенча, бик җиңел үтеп китүе, Галимҗанның анда эләгә алмавы турында хәзергә әйтми торуны мәгъкуль күрде. Чөнки остабикәсенең шактый ябыгып, моңсуланып китүен сизде ул. Йөзендә, күз төплә-

рендә ниндидер аңлаешсыз кайгы күләгәсе. Аңлый: ул Шакирҗан һәм Галимҗан өчен борчылу галәмәте. Шуңа күрә, остабикәсен борчымаска теләп, ул вакытлыча алдашу юлына басты: икесен дә «Хөсәения»дә калдыру турында әйтте.

Гыйрфан мулла — алдашырга гадәтләнмәгән зат. Ул гомумән алдаша белми. Әгәр алдарга тырыша икән, бу кара якны каплап, аклыкны өскә чыгару өчен. Ләкин андый чакта да аның алдашканы күз карашыннан, бигүк ышанычлы сөйләмәвеннән, йөзен яшерергә тырышуыннан сизелеп тора. Боларны Хәсәнә абыстай яхшы белә. Бу юлы да аның сөйләүләре нигезендә ниндидер яшеренлек барын сизде ана күңеле. Хәсәнә абыстай кат-кат төпченеп, ныклабрак сөйләп бирүен үтенгәч:

— Соң, Алла колы, әйттем бит инде, икесенә дә бүлмә, «Хөсәения» мәдрәсәсендә калдылар,— диде дә, тотылудан куркып, башын читкә борды.

Зирәк күңелле Хәсәнә абыстай моны барыбер сизми калмады.

— Нидер яшерәсең, атасы,— дияргә теләгән иде, әйтмәде, юлдан арып кайткан кешене борчыйсы килмәде.

## VI

Галимҗанның күңеле китек иде. Тирә-якта дан тоткан «Хөсәения» мәдрәсәсенә абыйсы Шакирҗанны алдылар. Нечкә иләктән бик шәп үтте. Ә ул, Галимҗан, иләктән үтми калган көрпә. Шакирҗан абыйсы белән бер бүлмәдә торса, әнисе, Нәгыймә апасы биргән йомшак тәрбия, наз, сөелү хисе һаман өзелмәгән булыр иде. Дөрес, әтисенең үтенеп соравы сәбәпле, аны мәдрәсәнең тынчу һавасын инде биш ел сулаган, шәкерт тормышының газапларын күп татып каешланган, озын гына буйлы, какча гәүдәле, ябык йөзле, аксыл чырайлы, карар күзгә үк миһербанлы, шәфкатьле, әдәпле булып күренгән Йосыф исемле бер мәхдүм белән урнаштырдылар. Ул, Йосыф, Вәли хәзрәт әйткәнчә, олыларга да, мәдрәсәгә яңа килгән, Галимҗан кебек йомыркадан бу фани дөньяга күптән түгел генә чыккан чебеш шәкертләргә дә кадер-хөрмәт, ихтирам-илтифат, мөкиббәнлек белән карый. Аның шулай икәнлеген Галимҗан беренче көнне үк белде. Әтисе хушлашып китү белән, боегып калган сүренке йөзле Галимҗанның күңелен күтәрергә, аны шундук берникадәр хыялый-матур хәят манзаралары дөньясына алып китәргә тырышты. Моның өчен кайгы-хәсрәт тарата торган мәзәк, риваять, әкиятләр сөйләп алды, әйберләрен җайлап-җайлап куярга булышып, чәй кай-

натып эчерде. Галимҗан кечкенә өстәл өстенә әнисе җибәргән тәм-томнарны чыгарып куйды. Йосыф та саранланмады. Чәйдән соң ныклап танышу китте.

Йосыф Бөре өязенә кергән Илеш[1] авылыннан икән. Илеш үзе — волость үзәге. Ул яклар, Йосыф сөйләвенчә, укырга Казан мәдрәсәләренә китә, имеш, Йосыф нәсел-нәсәп чылбырының унике буынын сөйләде. Буынның чишмә башы авылга нигез салучы шул иҗтиһадлы, хезмәткәр Илеш бабайдан башлана икән. Йосыфның әтисе Нургали ишанның бер туганы Ырынбурда яши икән. Шуңа күрә Йосыфны шушында укытуны мәслихәт күргән.

Йосыф әти-әнисе, туганнары, авылының табигате белән горурланды. Быел җәй, ямьле июль аенда, әтисе аны Казан каласына алып барган. Пароход белән. Монысын Йосыф шигъри матур тел, хис-тойгы, йөрәк җылылыгы, күңел кайнарлыгы белән бәян кылды. Менә җырларда җырланган, үзендә сихри гүзәллекне саклаган ак сулы Агыйдел. Ул, имеш, тыйнак кына, моңсу гына, инсафлы чибәр кыз елмаюын хәтерләтеп ага. Бервакыт ул кара сулы Чулманга барып кушыла. Ак су — кара су. Агалар да агалар. Ләкин кушылып, аралашып китәргә ашыкмыйлар. Ак су. Кара су. Ак су — чибәр кыз. Кара су — баһадир егет. Чибәр кыз назлана, ояла, кыенсына, егет кочагына йомылырга ашыкмый. Баһадир егет кайнар мәхәббәтен аңлата, бу ләззәтле, сәгадәтле, бәхетле минутларны мең-миллион еллар тилмереп көтүе турында әйтә. Аннан соң да әле әдәпле, инсафлы, күркәм табигатьле кыз егет кочагына атылырга бик ашыкмый, сөйкемле елмая-елмая, назлана-назлана ага бирә. Бу сөйкемлелек, бу инсафлылык, бу илаһилык егетне тәмам ярсыта, шашындыра, акылдан язу чигенә җиткерә. Кыз үзенең чибәр, сылу, назлы булуын гына түгел, горур, көчле, каһарман икәнлеген дә әйтә. Аны шулай маһир, камил итеп Урал-Бабай тәрбияләгән. Урал-Бабай аңа матурлыгын-батырлыгын теләсә кемгә әрәм итмәскә, Урал буйларыннан алган гүзәллекне саклаган хәлдә, гөлләр-чәчәкләр, таулар-урманнар арасыннан нәфислек саклап агарга, Урал данын ерак-еракларга алып барырга кушкан. Аңлый егет кызның уй-хыялын. Аны җан-күңелдән гаять кабул вә олылау белән үзенә хөрмәт кыла, уй-хыялларын гамәлгә ашыру өчен ерак-еракларга, матур-матур илләргә алып барырга вәгъдә бирә. Шуннан гына алар, бер-берсенең кочагына мөкиббән керешеп, тәмам бер җан булып, бер йөрәккә әверелеп ага башлыйлар. Ак су,

[1] Илеш авылы Башкортстан белән Татарстанны аерып торган Сөн елгасы буенда. Аңа 1661 елда Илеш исемле бик иҗтиһадлы, җегәрле, кыю кеше нигез сала.

кара су аралашуыннан икенче сыйфатлы су барлыкка килә.

Бервакыт алар Идел-Ана кочагына барып сыена. Идел-Ана аларны Хәзәр диңгезенә җитәкләп алып китә.

Галимҗан моны хискә бирелеп тыңлады. Йосыф хәзер унҗиде яшьтә икән. Димәк ки, Галимҗаннан биш яшькә өлкәнрәк дигән сүз. Үзеннән шулкадәргә яшьрәк кешегә һич иренми әллә ниләр сөйләве, Вәли хәзрәт әйткәнчә, аның бик тә миһербанлы, кечелекле икәнлеген күрсәтә.

— Сандугач сайрашып, ат кешнәшеп, адәм баласы гәпләшеп таныша, син дә үзеңнең кайдан, нинди нәселдән, кайсы яктан икәнлегеңне сөйлә инде, Галимҗан, кеше үзеннән яшерсә дә, дустыннан яшерергә тиеш түгел,— диде Йосыф, бар булганын сөйләп бетергәч.

Галимҗанның күңеле Кондызлы күл, Зәңгәр чишмә, Исәнбикә, Түрсәгәле буйлары матурлыгына йөгерде. Андагы гүзәллекне, хозурлыкны, күркәмлекне сөйләп бетереп буламы? Янә шунысы бар: тыңларга яратса да, сөйләргә, Йосыф абыйсы кебек, артык һәвәс түгел ул. Аның күңелендә әле үзе дә аңлатып бирә алмаслык нindидер давыл купты. Тыштан сиздерергә тырышмаса да, эчтә ул давыл кайный, котыра, үрле-кырлы килә. Нindидер гүзәллек белән аралашкан давыл ул. Бу давыл-матурлык, бәлки, Агыйдел-кыз белән Чулман-егет мәхәббәте ялкыны тәэсиреннәндер. Ничек кенә булмасын, олы кеше алдында берникадәр тартынып, кыенсынып, сүз белән аны артык бимазаламаска тырышып, булган кадәресен, белгәнен сөйләп бирде; авылның күркәм табигатен, аның кешеләрен Йосыфның күз алдына китереп бастырырга тырышты; нәсел-нәсәбен, җиде буын ата-бабалар чылбырын сүтеп күрсәтергә дә иренмәде.

Бу вакытта Галимҗанның күңелендә нindидер яшерен шигъри моң, табигать гүзәллеге энҗеләре балкышы, хәяти аһәң чаткылары, кешеләр рухыннан алган садәлек, тагы да әллә нинди сихри нәрсәләр бар иде инде. Йосыф абыйсы аны үз авылы, Агыйдел, Чулман матурлыгы хакында сөйләп әсәрләндерде. Әмма Галимҗан киләчәктә зур язучы булачагы турында аз гына да уйламый әле. Шушы мәдрәсәдән куылу белән, 1907 елда, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәя язачагы аның өчен болыт артындагы кояш кебек әле. «Яз башы» исемле хикәясендә (1910 ел) үз авылының табигать матурлыгын шундый чагыштыру белән тасвирлаячагын әле ничек белсен ул.

«Бүген майның урталары булганга, кояш ерак, ләкин туры һәм матур карый. Бөтен җир йөзе язның гүзәллеге белән чолгана, һәр җирдә тын гына, акрын гына бер шатлык сизелә.

Инешнең ике ягына тезелгән таллар, яшел яфракка күмелеп, акрын гына, сак кына тавышлыйлар. Аның бөтен киле-

шенә җәелеп яткан киң яшел тугай китә. Бу киң вә тулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә».

...Йосыф сөйләгәннән соң, Галимҗанның әллә кайларда, ерак-ерак илләрдә, ниндидер серле-серле дөньяларда буласы, шул Агыйделнең Чулманга кушылган урыннарын, Идел елгасын, Хәзәр диңгезен, тагын да бик күп җирләрне күрәсе килеп куйды.

Галимҗан, тартынып-кыенсынып кына булса да, үзе дә начар сөйләмәде шикелле. Югыйсә:

— Авылыгызны бер барып күрәм әле, мин дә сиңа үзебезнекен күрсәтермен,— димәс иде Йосыф мәхдүм.

## VII

Кызык икән бу мәдрәсә тормышы. Әле генә бәгъзе берәү үз бүлмәсендә ялгыз сандугач кеби моңаеп утырса, йә булмаса, болар сыман, икәүдән-икәү чәй эчеп сайраша, кичен, шәкертләр җыелгач, шау-гөр, уен-көлке, җыйнаулашып шаярышу башланды. Өлкәнрәк шәкертләрнең Вәли хәзрәткә кышлык өчен утын кисәргә, аннан соң ниндидер баз казышырга, янә башка эшләр башкарырга киткәнлеген ишеткән иде Галимҗан. Әле менә, зур крепость алган солдатлардай горур атлап, имәнеч каты тавыш белән шаулашып-гөрләшеп, алар төркеме кайтып керде. Янә тагын әле тегеннән, әле моннан кузгалган шәкертләр, төнен аяк басылгач сунарга чыккан тычканнар өере кебек, тыз да быз йөрергә керешә. Ни бу? Нинди кайнашу? Әйтерсең дөньяның асты өскә әйләнә. Йа Хода! Чырчу, шау-шу, тавыш-гаугa купты. Гүя кыямәт көне. «Бисмилләһиррахмәнир-рахим», «ләхәүлә вә лә куәте», «әлгаязе билләһи» кебек сүзләргә сүгенү-кычкырынулары да катнашып китә. Хәтта динне, мулланы, мәдрәсә башлыгын тиргәү сүзләре дә яңгырый. Моның ни галәмәт икәнлеген Галимҗан белми әле. Йосыф мәхдүмнән сорар иде — ул кайдадыр чыгып китте. Ә төркем, бал алганда өркетелгән умарта күчедәй, гөж-мөж килеп йөрүен белде. Менә алар боегып, әллә нинди тирән уйларга чумып, үзен-үзе кая куярга белмичә утырган Галимҗан бүлмәсенә кереп тулды. Аларга, янәсе, яңа килгән шәкертнең акыл кылын тартып карау лязим. Берәүнең кулында шактый дөнья күргән, тузган чикмән. Шул чикмән белән төреп, Галимҗанга аның күтәрелгән җиңеннән карарга куштылар. Шул җиңнән әллә күпме йолдыз күренә,

имеш. Галимҗан, карагач, ничә йолдыз күрүе турында әйтергә тиеш. Һәй, бу надан шәкертләр!.. Һәй, бу томаналык!.. Һәй, бу күңел караңгылыгы!.. Мәдрәсәдә инде җиде-сигез ел ми черетеп, газап чигеп, сасы-тынчу һава иснәп, җиңнән карап йолдыз күренмәгәнлекне дә белмиләрме? Белә алар. Яңа килгән шәкертне белми дип уйлыйлар. Андыйлар да бардыр. Әмма ләкин нигә шундый вак-төяк кызык-мызык белән шөгыльләнергә? Яңа килгән шәкертнең зиһенен, аң-акылын, фикер йөретү офыкларын сынау өчен башка мәгънәлерәк «уен» юкмы? Бу хакта Галимҗан белә иде инде. Аны әтисе дә әллә ничә тапкыр көлә-көлә сөйләгән иде. Чикмәнгә төренгәч, син кемдер тартып торган җиңгә башыңны тыгарга тиеш. Шуннан бер ахмагы йә салкын, йә эссе су коя. Син су комагы хәлендә каласың. Аннан, чикмәнне ачып ташлап, шырык-шырык, ихахай-михахай, лых-лых көләргә тотыналар. Шулмы егермегә җиткән ир-егетнең ун-унике яшьлек баланы мәсхәрәләп ләззәтләнүе? Шулмы кешенең аң-акылын сынар өчен оештырылган кәмит? Шулмы егетлек?

Галимҗан бу хакта ләм-мим белмәгән атлы булып, чикмән эченә керде. Әмма җиң эченә башын тыкмады. Тыккан атлы булып: «Һәй, шәкертләр, мин инде бик күп йолдызлар күрдем. Алар бик матурлар. Барысы да чекерәешеп яналар»,— кебек җөмләләр әйтте. Комганнан су кою вакыты җиткәнен шәйләгәч, башын җиңнән чыгарып, чикмән эчендә катып калды. Су коелды. Аның тамчысы да тимәде Галимҗанга. Ул шунда утыра бирде. Ә тегеләр: «Бетте бу, коенды, эссе су таракан ясады, әллә тончыкты инде»,— кебек сүзләр әйтә-әйтә шырык-шырык көләргә тотындылар. Көлү чикмәнне ачып карагач кына тукталды. Тамчы да су тимәгән Галимҗанны күреп, алар шаккатты. Галимҗан сер бирмәде. Берничә йолдыз исемен әйтеп гаҗәпләндерде:

— Мин Чулпан, Җупитер[1], Марс, Пләйтән[2] йолдызларын күрдем,— дип алдашты. (Болар хакында аңа урыс теле мөгаллиме Сәет Илһамов сөйләгән иде.)

Галимҗанга бәгъзесе күзен чекерәйтеп, бәгъзесе кулын каш өстенә куеп, бәгъзесе коелып төшеп карады. Мәдрәсәгә яңа килгән күпме шәкерт-чебешне коендырдылар. Ә бу судан коры чыккан. Әллә бер-бер сихере бармы бу маңка малайның? Әллә йөзлеклеме? Галимҗан шәкертләрнең: «Нәрсә ул Җупитер? Нәрсә ул Пләйтән?» — дигән сүзләрен ишетеп, шул атамаларны да белмәүләренә аптырады. Шуннан соң аңа төрле сораулар яуды:

— Апаң бармы? Чибәрме?

---

[1] Җупитер — Юпитер.
[2] Пләйтән — Плутон.

— Әлиф белән таякның аермасы нидә?
— Мөхәммәт пәйгамбәр кайда, кайчан, ничәнче елда туган?

Беренче сорауга ул бик матур, төпле, шәкертләрнең күңелен җилкендерердәй җавап бирде:

— Нәгыймә исемле апам бар, бик чибәр, сөйкемле, акыллы, — диде.

Өлкән шәкертләр авыз суларын түгеп, күзләрен ялтыратып, дәрт кабынудан үзләрен кая куярга белмичә сулкылдап, чыдаша алмыйча көлешеп куйдылар:

— Уй-буй, аһ-уһ, үтерде бу маңка малай...
— Апасы тәгаен үземә, берәүгә дә түгел...
— Каениш, апаң минеке...

Калган ике сорауга Галимҗан, алар уйлаганча, маңка малай, селәгәй түгел икәнлеген аңлатырлык итеп җавап бирде:

— Әлиф белән таяк ни икәнен сораган кеше әлифне таяктан аера белмәүче мәхлук, пәйгамбәрнең туган көнен миннән белергә тырышу сезнең өчен түбәнлек, — диде.

Өлкән шәкертләр тораташтай катып калды. Берсенең авызы чалшайды. Икенчесенең күзе кылыйланды. Өченчесенең борыны борылды. Алар алдында торган маңка шәкертнең «буш тубал» белән килмәвен аңлау кыен түгел иде. Шуңа күрә сорауны кыскарттылар. Мондый маңка малайга сорау биреп, үзеңнең адәм ыстырамына калуың бар бит әле.

Алар таралышкач, Галимҗан иркен тын алып куйды. Аның ял итәсе, ятып йоклыйсы, шуның белән бөтен болганчык-кара уйлардан арынасы килә иде. Тик барып чыкмады. Күрше бүлмәләрдә кемнеңдер дуңгыз тавышы белән чыелдавы, бәгъзе берсенең карт алаша кешнәгәндәй хахайлавы, бәгъзесенең кәҗәдәй кычкыруы Галимҗанны бөтенләй айнытып, шул мәзәкләр арасына барырга кызыксындырды.

Барса, ни күзе белән күрсен, мендәр сугышы купкан. Бүлмәнең берсендә бәрешәләр-бәрешәләр, орышалар-орышалар да, анда сугышып туйгач, икенчесенә чыгып китәләр. Анда яңа көрәш башлана. Кем кемне чәпи, кем кемгә теш кайрый, кемдә кемнең ачуы бар — белмәссең, шайтан да аңларлык түгел. Зурлар, мендәрнең бер почмагыннан тотып, бәләкәйләрнең башына китереп ора. Теге мескен, чатай-ботай килеп, әллә кайда тәкмәчләп барып төшә. Шуннан, гаҗәеп бер кәмит күргән кебек, шаркылдап көләргә тотыналар. Моның ни мәзәге бар икән? Аны Галимҗан һич кенә дә башына сыйдыра алмый. Берара, син дә калҗасыз калма дигәндәй, бер калын гәүдәлесе Галимҗанга да китереп чәпәде. Кем уйлаган йомшак мендәрне шулай каты тияр дип? Күзләреннән аллы-гөлле утлар чәчрәде Галимҗанның. Идән уртасында орчыктай бөтерелеп торды-торды да, башы әйләнеп,

әллә кая барып сеңде. Бераздан берсе кулыннан тартып торгызган иде, икенчесе янә колак төбенә китереп сылады. Галимҗан тагын да туптай тәгәрәп китте. Тагын да шаркылдап-мыркылдап, ихахайлап-михахайлап көләргә керештеләр. Әллә нинди казан кыргандагы тутык тавышлар чыга. Кайсысыныкы бүре улаганны хәтерләтә. Бәгъзесенеке үгез мөгрәве кебек. Аларның бөтенесе бергә кушылгач, җен-пәриләр чыелдагандай тоела. Җитмәсә, берсе, Галимҗанны янә торгызып: «Син бая йолдыз санарга ирендеңме, безне алдап калдыңмы, хәзер кәҗә маеңны чыгарыйкмы?!» — кебек сүзләр әйтә-әйтә такылдады. Тагын да сугып җибәрергә тешләрен кыҗырайтса, аның мендәрен кайдандыр ялт килеп кергән Йосыф тотып алды. Йосыфка әллә күпме әшәке, нахак сүзләр яуды:

— Әле шул маңка малайны яклыйсыңмы?

— Сатылдыңмы?

— Сумсасы тәмле булдымы?

Тотындылар хәзер Йосыфның үзен тәпәләргә. Мендәр белән әле берсе китереп ора, әле икенчесе, әле өченчесе. Шуннан, бер мендәрне алып, Йосыф үзе дә тегеләргә чәпәргә керешә. Араларында Йосыфны яклаучылар да табылды. Тиз генә икегә бүленеп алдылар. Мендәрләр умырылып, ертылып бетте. Каз мамыгы белән идән тулды. Әйтерсең ап-ак кар йоны. Мамык, пыр тузып, очып та йөри. Гүя кар бураны купты. Мондагы мендәрләр эштән чыгып беткәч, икенче бүлмәгә күчтеләр. Анда да шул ук хәл. Өлкәннәр бәрешә. Бәләкәйләр тамаша кылып кына йөри. Хәзер инде төрле-төрле тавышлар яңгырый:

— Тимә минем мендәргә...

— Үз мендәрең белән сугыш...

— Туктагыз... җитте...

— Ахмаклык бу...

Башта ул шаяру гына иде шикелле. Әмма уеннан уймак чыкты. Тора-бара бер-берсенә булган ачуларын да чыгара башладылар:

— Син үткән ел җеназа вакытында миңа дигән хәерне чәлдердең, тирес бит...

— Үзеңне бел, азгын җан, сасы Мәрүскә янында иснәнеп йөрисең...

— Хәмер белән шаярганыңны хәзрәткә әйтсәм әле, чучка борын...

— Мин синең кебек тәмәке төпчеге җыеп йөрмим бит әле, эт җан...

Боларны ишетү Галимҗанга бик кыен иде. Ул үз колакларына үзе ышанмый торды хәтта. Абыйсы Шакирҗан мәдрәсәсендә дә — «Хөсәения»дә дә шулай микән? Юктыр. Анда

мондый вәхшилек булмас. «Вәли мулла мәдрәсәсе җәһәннәм төбе кебек ул» дигән сүзләрне ишеткән иде шул. Монда башка мәдрәсәгә үтмәгән җыен шәләй-вәләй, ачыган ялкау, чихут-михут, сантый-мантый, сугыш чукмарлары, кибәк башлар гына укый, имеш. Бәгъзе бер елда шәкерт саны җитми дә кала икән әле. Андый очракта Вәли мулланың коты оча. Чөнки, шәкертләр килмәсә, мәдрәсәнең абруе, дәрәҗәсе тагын да түбәнрәк төшә. Аңа бөтенләй ябылып кую куркынычы да яный әле. Шуңа күрә Вәли әфәнде һәр килгән яңа шәкертне илаһи бер күтәренке күңел, ачык йөз, шәфкатьлелек күрсәтеп каршы алырга тырыша.

Мендәр сугышы тынгач, бүлмәләрне җыештыру башланды. Кайбер бәләкәй шәкерт, мендәрсез калуына ачынып, елап та җибәрә.

Кичен чәй эчкәндә, Йосыф мондый хәлнең еш булуы турында сөйләде. Шулай да бу кадәр күңелсезлеккә барып җитмәгәнлекне әйтте. Бу шаяруның кайбер сәбәпләре дә бар икән. Аларның бәгъзесе бу тынчу дөньяда ун ел чамасы кибеп-корып яши икән. Ә менә җәй көне, түл җыйган үрдәк кебек, алар авылда шактый хәлләнеп килгән. Хәзергә әле алар маена чыдаша алмый кайнаша. Каннары кызган чагы. Дәртләре ташып тора. Кая барып бәрелергә-сугылырга белми аптырыйлар. 20–25 яшьлек егет йөрәгенә ни кирәген алар аңлый. Әмма кирәге табылмый. Аяк астында аунап ятмый ич ул. Рухи азык, күңел юанычы, яшәү хозурлыгы кирәк боларга.

Шулар хакында берникадәр үзенчә фикер йөреткәч:

— Син бик боек күренәсең, Галимҗан, беренче көнне үк күңелеңне нык төшерделәр, ләкин гел болай булмый ул, укырга тотынсалар, кикрикләре шиңә, кайберсе кипкән балыкка әверелә,— диде Йосыф.

Бераз уйланып торгач, янә дәвам итте:

— Күңел ачулар да була: җыр, бию, кубыз тарту, курай, сукыр тәкә уеннары... Адәм баласына барысы да кирәк.

Аның шул сүзләрен хуплагандай, кайсыдыр бүлмәдә кубыз тарткан тавыш ишетелде.

Йосыф янә сөйләп китте:

— Әнә... Әйттем бит... башланды... Алар инде мендәр сугышын оныткандыр. Шәкерт ачу сакламый. Моны шәригать тә кушмый бит. Өч көн саклаган ачу агуга әйләнә. Ә агу кешенең йөрәген кимерә. Ул акрынлап юньсез затка әверелә. Әйдә, Галимҗан, тамашадан калмыйк. Монда сарык тиресе ябынып, үз уйлары белән генә бикләнеп яшәүчеләрне дә бик яратып бетермиләр. Беренче көннән үк барын да күреп-белеп йөрүең хәерле. Яхшысын да, яманын да. Яхшысына — йөрәк капкачыңны ач, яманына — бикլә. Кай-

гырма, Йосыф абзаң янында ким-хур булмассың. Әйдә, Аллага тапшырдык.

Алар бер зур гына бүлмәгә барып керде. Монда шул баягы мендәр белән сугышучылар иде. Тик ул инде, Йосыф әйткәнчә, онытылган, күрәсең. Чандыр гына гәүдәле бер өлкән шәкерт кубызда уйный. Башкалар аңа карап каткан. Тын алырга да куркып торалар. Галимҗан, сиздермәскә тырышып, әле берсенә, әле икенчесенә карап ала. Берсендә ул йөрәк әрнеше барлыкны сизә. Икенчесенең күңеле тулганлыгын аңлый. Өченчесе елап җибәрер чиккә җиткән. Дүртенчесе елмаеп-елмаеп куя. Моң адәм баласын төрле сыйфатка кертә, күрәсең. Галимҗан бу минутта Хөрмәтулла абзыйсы, Мәликә апасы, Мәдинә яшьтәше моңнарын да хәтеренә төшерде. Гүя шул моңнар белән бу моңнар аралашып китте. Аралашты да Галимҗанның үз йөрәген дә тетрәндерде. Әллә ул моңга тиз бирешүчән йомшак җанмы? Аның шулай икәнлеген башкалар сизмәдеме? Шуны уйлап, ул үзен-үзе нык тотарга тырышты.

Уйнап туктагач, шәкертне кул чабып алкышладылар. Алкышлау шактый көчле булгач:

— Акрын... тышка ишетелмәсен... йә хәзрәт, йә казый килүе мөмкин бит... — диде Йосыф.

Шуннан акрынрак уйнарга, йә тышкы ишекне бикләп куярга, йә чиратлап сакта торырга сүз куештылар. Акрынрак уйнарга кирәк. Ишекне бикләү килешми. Эчтә нindидер «этлек» булуны аңлаячаклар. Иң яхшысы — ихатада сакта тору. Хәлфәме, хәзрәтме яки башка кемдер күренсә, тиз генә кереп әйтергә.

Сакчы кую белән Йосыф җитәкчелек итте. Башта ул үзе торып керде. Аннан берәм-берәм башкаларны чыгарды.

Менә бервакыт:

— Нигә Кылычбай бүген курай уйнамый, уйнасын, уйнасын, — дип шаулаша башладылар.

— Бында бит беззең арала кемдер итәк астынан ут йөрөтә, минең курай уйнаганды хәзрәткә әйтә; Вәли мулла үткән йыл да асыуланды, уйнаганыңды тагы ла бер ишетһәм, бына ошо салмалы башым менән ант итәм, мәзрәсәнән кыуам үзенде, тине.

Сөйләшүе буенча да, төс-битенә карап та Галимҗан аның башкорт егете икәнлеген аңлап алды. Шәкертләр исә янә шау-гөр килде:

— Уйнамаслык булгач, нигә кураеңны алып килдең?

— Кем икән ул әләкче дуңгыз?

— Тотып измәсен изәргә кирәк ул хаинның.

Шуннан соң башкорт ялындырып тормады. Курайда берничә моңлы көй уйнады. Аңа да алкышлап кул чаптылар.

Галимҗанның күңеле күтәрелеп китте. Бу караңгы дөньяны яктыртырга теләүче йолдызлар да бар икән әле. Җиде төн уртасында да алар күңел ачып, кат-кат самовар чыжлатып, алып килгән күчтәнәч, ризык-нигъмәт белән сыйлаша-сыйлаша, әле берсендә, әле икенчесендә җыйнаулашып чәй эчтеләр. Аннан соң тагын да уен дәвам итте. Вакыт-вакыт үкенечле сүзләр дә яңгырап ала:

— Их, егетләр, үтә бит яшь гомерләр…

— Ун ел буе мәдрәсә тузаны эчеп…

— Картаеп барабыз… бер җылы кыз кочагы күргән юк бит әле…

## VIII

Шәкертләр таң алдыннан гына тәмле йокыга талды. Галимҗан, мендәренә ятып, әллә кайчан сеңмәкче иде. Ул, башкалар кебек, арып-алҗып килгән генә түгел, шуның өстенә авыру да бит әле. Гәрчә «Хөсәения» мәдрәсәсендә кан төкерсә дә, монда килгәч, авыруы хакында ләм-мим белдермәскә тырышты. Чирле чәүкә дигән кушамат авылда чакта да күңеленә кара сөрем койды да торды. Анда ул сөремне туздырып ташлау, аның урынына ак нурлар салу, үзен өстен күрсәтү, малайлар белән яхшы мөнәсәбәт булдыру мөмкин иде. Мондагы киеренкелек әллә ничек. Шайтан үзе дә аңларлык түгел. Аз гына курку күрсәтсәң, әллә нинди яман атама салып куюлары бар. Аннан соң аны пычак белән дә кырып ташлап булмас.

Үзен ничек кенә нык тотарга, ихтыярлы итеп күрсәтергә, бирешмәскә, җебеп төшмәскә тырышмасын, безне капчыкта саклап булмаган кебек, эчтәгене йөзгә чыгармый калу мөмкин түгелдер, күрәсең. Зирәк табигатьле, үткер күзле, сынап караучан Йосыф мәхдүм:

— Галимҗан, син юлда йончыгансың, ят булмаса, мондагы тамаша бетмәс, сиңа авырып китүдән саклану хәерле булыр, — диде.

Галимҗан аны тыңламады. Кәҗә дә бакчага сәбәпсез керми дигәндәй, тыңламауның ике сәбәбе бар: беренчесе — әлеге «селәгәй малай» атамасы алудан курку, икенчесе — шәкерт дөньясы эченә беренче көнне үк керергә тырышу.

— Юк, юк, минем әле һич тә йокым килми, йончымадым да, авырмадым да, — диде ул.

Йосыф мәхдүм аның аркасыннан сөеп куйды:

— Ярый, йокы песигә генә моң, алданмыйк аңа, уйныйк, күңел ачыйк бүген; әле сүләшәсе сүзләр бик күп.

Галимҗан яткач та тиз генә йокыга китә алмады. Уй да-

вылы эчендә миңгерәде ул. «Әгәр бик тә иҗтиһадлы булып, ваемсызлык күрсәтмәсә, тырышып укыса, иншаллаһ, улыңыз янә ун елдан мөлля һәм мөдәррис булыр», — диде Вәли мулла аның әтисенә. Бу сүзләр әүвәл Галимҗанның колакларын назлап, күңеленә илаһи бер ләззәт биреп торды. Вәли мулла андый сүзләрне зур ышаныч илә әйткәндер. Ә менә хәзер, таң караңгылыгында үз уйлары-хыяллары белән япа-ялгыз гына калгач, хәзрәт вәгъдә иткән ун ел, әллә нинди җанлы сурәткә кереп, Галимҗанга йодрык төя, теш ыржайта, тел чыгарып күрсәтә кебек. Янә ун ел!.. Ул вакытта Галимҗан егерме өч яшьтә була. Ә монда унбиш ел укыганнар да бар икән әле. Алар әле мөдәррис тә, мулла да түгел. Бу тынчу, сасы, караңгы оядан кош кебек очып китеп, әллә кайларда үзенең асыл зат икәнлеген исбатлау бәхетенә ирешкәннәре дә бардыр. Ә бит бу төчкелтем дөньяда унбиш-уналты ел укып, саргаеп, кибеп, корып бетеп тә һаман әле канат ярмаган, очып китә алмаган, хәят мәсгудияте күрмәгән бахырлар да бар. Бәгъзе пишкадәмнәрнең дә язмышы аянычлы.

Ни чыгар Галимҗаннан? Ун-унике ел заяга үтмәсме? Чәчкәләр, гөлләр арасында, оҗмах-җәннәттән аз гына да ким булмаган бай, матур, гүзәл табигать кочагында, аның саф һавасында хозурланып, әнисенең йомшак тәрбиясендә назланып-иркәләнеп үскән бәхетле-сәгадәтле бала бит ул. Шул оҗмахтай табигать куенында иркәләнеп үскән малай бу тәмугны хәтерләтеп торган дөньяда бетеп, теткәләнеп, сугышып таланган әтәчкә охшап калмасмы? Әнә бит ничек үкенәләр, ничек өзгәләнәләр, әйтерсең аларның артында калган юллар гөнаһлы, күңелсез, караңгы, ә алда упкын көтә.

Шундый буталчык, болганчык, очына чыгу кыен булган уйлар парә-парә кискәләде Галимҗанның йөрәген. Аннан соң үз уйларыннан үзе курка башлады ул. Нигә алтын базыннан чүп эзләп маташа әле? Бу бит куркаклар, адәм баласының ак күңеленнән кер эзләүчеләр, иҗтиһадсызлар эше. Әтисе: «Йолдыз караңгыда яктырак яна», — дигән иде берчак. Ул хакта әнисе дә әйткән иде. Ян караңгыда йолдыз булып. Нурыңны башкаларга сип. Ул нурдан дөнья яктырсын. Әтисе гел шулар хакында тугылап торды лабаса. Башыңа, бөтен тән күзәнәкләреңә сеңсен дигән кебек.

## IX

Галимҗан, Авыргазы елгасының Агыйдел, Чулман, Идел белән кавыша-кавыша Хәзәр диңгезенә барып җиткәнен белгән кебек, өлкән мөдәррис Вәли мулла торган унике еллык кадим мәдрәсәнең соңгы чиге ниндирәк офыкка барып тоташачагын да

аңларга тырышып йөрде. Халыкның «Акыллы — тыңлар, акылсыз — такылдар» дигән әйтемен авылда чакта ук ишеткән иде инде ул. Ул тыңларга ярата. Ә менә сөйләргә беркайчан да атлыгып бармый. Бу табигатен хәзер ул яхшы белә. Тик кеше акылын «тыңлау», «тыңламау» бизмәненә салып үлчәргә ашыкмый. Бу сыйфат аңа ата-ана канынннан киләдер, бәлки. Әткәсе дә, әнкәсе дә шулай бит: кирәген әйтә, буш сүз уйнату белән шөгыльләнми.

Башта Галимҗан яңа килгән шәкертләр арасында үзсүзле буларак танылды. Ярык күргәнгә дә көлгән кыз кебек, һәр мәзәккә авыз ерып, ихахай да михахай, кыхый да михый килеп йөргән җил акыллы бәгъзе шәкертләр тиз арада аңа әллә күпме атамаларны сагыз урынына ябыштыра да башладылар: «Бер сүзенә бер бозаулы сыер сораучы», «телен йоткан ябалак», «акайган күз»... Тагын да әлләниләр, әллә нәрсәләр. Шулар арасыннан Акайган күз дигән кушамат аңа сыланды да куйды. Күрәсең, башкалар, ярыша-ярыша, тел чертләтә-чертләтә, уттай кабына-кабына, үзен күрсәтергә теләп сүз көрәштергәндә, Галимҗанның чупай ябалагы кебек тын гына, ләм-мим дими, чукаеп утырганы аларга сәер тоеладыр. Акыллы, мәгънәле фикерне колак торгызып, күзен зур ачып тыңлый торган гадәте дә бар. Димәк ки, ачылган күз бәгъзе берәүләр өчен акайган күз булып күренә. Акайган күздә акыл юк, дип тә әйтәләр. Әмма Галимҗанның ул «акайган күзләр» нурында нинди акыл барлыкны кети-мети уйлап, үз борын астын күрми йөргән шәкертләр белми шул әле. «Акайган күз», «ябалак» дигән сүзләрне әйтә башладылар хәтта.

Ордым-бәрдем була алмавы аны йомшак көпшә итеп тә күрсәтә шикелле. Әмма тиздән аның йомшак көпшә түгел, ә бәлки каты имән икәнлеге ачыклана башлады. Хәтта Йосыф аны Мисыр күгәрчене дип атады. Мисыр күгәрченнәренең бер төре энҗе чүпли, имеш. Моның өчен аңа ифрат дәрәҗәдә күп эзләнергә, күп очарга, шул үзенең гәүһәр бөртеген хәтерләтеп торган нәни борыны белән җирне актарырга кирәк икән. Бу иҗтиһадлык аңа Алла тарафыннан бирелгән, ди. Бәгъзе бер күгәрчен кеше авызына зар-интизар булып карап яши: бирсә — ашый, бирмәсә — юк. Инсаният өчен аның матурлык-гүзәллек сыйфаты гына бар. Ә бу күгәрченнәрнең тышкы күренеше тегеләрнекенә караганда да сылурак. Әлеге эчтәге энҗе бөртекләре каурыйларында, түшләрендә дә җем-җем килеп тора, имеш. Аларның энҗе чүпләүче күгәрчен икәнлекләрен шуннан беләләр икән. Аллаһы Тәгалә аларны җирдә исраф булып яшеренеп яткан энҗеләрне җыю, аларны халыкка өләшү өчен яраткан.

Моны Йосыфканиндидер бер акыл иясе сөйләгән. Шә-

кертләр ни өчен Галимҗанны Мисыр күгәрчене дип атавы турында төпченгәч, Йосыф аларга барын да бәйнә-бәйнә аңлатып бирде.

Моның сере шактый тирән, яшерен. Мәдрәсәдә унар-унике ел укып та, мең-миллион кәррә сабынлап юсаң да агармый торган карга кебек, аң-акылларын агарта алмаган карт шәкертләр бар. Аларның бәгъзе берсе, гәрчә моны тыштан сиздермәсә дә, үзенең надан икәнлеген яшерергә тырышса да, яшь гомерләренең заяга үткәнлеген аңлап, эчтән генә сыкрап, янып-көеп йөри. Моны алар җае чыккан саен: «Их, егетләр, үтә бит яшь гомерләр, бер кыз кочарга тилмереп яшибез. Кем чыгар бездән?» — кебек ачыргаланып әйткән сүзләреннән дә аңлады Галимҗан. Ләкин алар, әлеге теге төлке хәйләсенә алданып, койрыгы бәкедә бозга каткан бүре хәлендә калуларының серен аңлап бетермиләр. Ун ел буе гарәп сүзләрен мәңге чәйнәсәң дә, мае чыкмаган чүбек урынына чәйнәп, алар мәгънәсен белми яшиләр.

Әгәр унике ел тырышып укыса, Галимҗанның бу мәдрәсәдә мөдәррис булачагы турында әйтте Вәли мулла. Шул сүзләрне ишеткәч, әтисенең йөзе башта кояштай балкып куйды. Аннары ул кояш балкышын тиз генә болыт күләгәсе каплагандай булды. Монысы ни өчендер — аның сәбәбен Галимҗан, кем әйтмешли, төбе-тамыры белән аңлап бетерә алмады. Әтисе вакыт-вакыт Троицк мәдрәсәсендә шактый мәшһүр мөдәррис булуы хакында сөйли иде. Аны ташлап китүенә үкенгән чаклары да була. Китмәсә, имештер, аннан шаккатарлык гыйлем иясе чыгар иде. Вәли мулла Галимҗанның унике елдан соң мөдәррис булачагын әйткәч, әтисенең күк кабагы дәррәү ачылуны аңлау кыен түгел иде. Димәк ки, нәсел-нәсәп кояшы киләчәктә бөтен тирә-якка нур чәчәчәк әле. Ул нурлар алама-кара болыт эчендә йотылмасын.

Зирәк, сизгер күңелле, мәсьәләнең асылына төшәргә тырышкан Галимҗан аңлый боларның һәммәсен: уку «Шәрхе Габдулла»[1]дан башланырга тиеш икән. Бу хакта аның мәгълүматы юк түгел. Кешәнне мәдрәсәсендә дә, гәрчә ачыктан-ачык булмаса да, ул турыда колак очына эленеп калырдай гына төшенчә бирделәр. Әтисе дә мең тапкыр тугылагандыр:

— Менә Ырынбурдагы зур мәдрәсәгә барырсыз, «Шәрхе Габдулла»ны укырга туры килер, аңа чаклы менә боларны, менә шушыларны бел,— дип, гелән генә бер үк нәрсәләрне тәкрарлап торды. Шакирҗан абыйсын да шуңа өйрәтә иде. Аннан соң тора-бара икесенең дә акыл кылларын тартып карый.

[1] «Шәрхе Габдулла» — гарәп морфологиясенә фарсы телендә аңлатмалар биргән грамматика дәреслеге.

Ике ел буе «Шәрхе Габдулла»ны ятлап, аны, кем әйтмешли, су урынына эчкәч, нәху[1] төшәргә тиешләр икән. Әтисе аның да кагыйдәләрен ятлата-ятлата тәмам бәгыренә тия иде. Ләкин берәр сүзнең мәгънәсен сораса, әтисе йә җилкәсен кашырга, йә сакалын сыпырырга керешә. Аннан:

— Аның сиңа кирәге юк, мәдрәсәдә бу хакта әйтмәячәкләр дә, сорамаячаклар да, — дип ачулана иде.

Ничек кенә булмасын, рәхмәт әтисенә, улы өчен зур гыйлемгә юл ярган. Ата күрсәткән йолдызга карап атлау горурлык та, рәхәт тә, җиңел дә.

Шуннан соң алар әнмүзәҗ[2]не өйрәнергә тиеш икән. Мулля дигәне дә бар. Монысы — мантыйк, имештер, сүз көрәштергәндә, фикереңне ачык, анык, мәгънәле әйтә белү өчен зарур. Бусы хакында да Галимҗанның төшенчәсе юк түгел. Әтисе мәдрәсәдә аның буенча шәкертләргә сабак та биргән хәтта. «Суның тирәнлеген таяк белән, кеше акылын телефикере белән үлчиләр», «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел», «Күңеле аламаның теле алама» кебек мәкаль-әйтемнәрне һәр очракта тәкрарлап торырга ярата иде. Шуның белән ул үзенең маһирлыгын, мәгълүматлы, фикерле икәнлеген аңлатырга тырышты, күрәсең. Әнисе турында әйтеп торасы да юк. Үзе бер алиһә ич ул! Сөйләгәндә авызыннан энҗе чәчә. Сүзләре йөрәгеңә, күңелеңә сары май булып ята. Әлеге күгәрченнәр чүпләгән энҗе әллә шундый матур сөйләүчеләрнең сүзеннән коелганмы җиргә?!

Галимҗан үзе хәзергә авызыннан энҗе коючы күгәрчен түгел. Әлегә ул — энҗеләрне үзе җыючы. Һәр мулла, хәлфә, мөдәрриснең сүзен, әлеге дә баягы шул зур колакларын торгызып, йөрәгеңә үтәрдәй карашлы күзләрен зур ачып, мөкиббән китеп тыңлый. Тик, ни гаҗәп, әлеге күгәрченнәр чүпли торган энҗеләр табылмый.

Солтанморатта мөгаллим Сәет һәр көн үткәрә иде дәресне. Башта үзе сөйләп аңлата. Шуннан укып белергә, аны кабатларга куша. Өйгә эш тә биреп җибәрә. Икенче көнне сорый. Ә монда әллә ничек, бөтенесе дә чуалып беткән җеп кебек. Очы кайдадыр — монысын Ходай үзе генә белә, күрәсең. Мәдрәсәдә җәмгысы алты хәлфә. Алар шәкертләрне бүлеп алды. Галимҗанга озын гына буйлы, кылыч борынлы, ач яңаклы Зарф исемле хәлфә туры килде. Ул беренче дәресне «Шәрхе Габдулла»дан башлады. Озын буйлы булганлыктан, шәкертләр аны Колга дип атады. Бу атаманы да бирмәсләр иде, бәлки. Анысы аның — ачудан. Чөнки укы-

---

[1] Нәху — синтаксис.
[2] Әнмүзәҗ — гарәп грамматикасы.

туының рәте-чираты юк. Ул кулына озын чыбык тотып керә. Башта, яшен уты уйнагандай, аны берничә кат чыжлатып ала. Бу сезнең өчен, янәсе. Шуннан үзе берни сөйләп тормый. Укырга фәлән биттән фәлән биткә хәтле бирә дә, чыбыгын янә уйнатып, күз белән каш арасында юк була.

Икенче көнне көтсәләр, әллә җир уптымы үзен, эзе дә юк. Кайда йөри? Нигә килми? Шайтан белсен. Озакка сузылган болытлы көзге көннәрдә әллә нидә бер күренгән кояш шикелле, атнасына бер генә килеп киткән чаклары була. Анда да, берәр шәкерт ык-мык итеп торса, яткызып, әлеге чыбыгы белән «сыйларга» тотына.

* * *

Чыбык сыен көннәрдән бер көнне Галимҗан да чак татып карамады. Ул Зарф хәлфә тарафыннан бирелгән кадәресен тиз үзләштерә. Уй казанында җил уйнаган кайбер шәкертләр кебек, мыш-мыш килеп, кашына-кашына, озак-озак күз чекерәйтеп утырмый. Чөнки аның уй казанында әтисе-әнисе салган гыйлем орлыгы бар. Анда әтисе-әнисе ташлаган чаткылары да җитәрлек. Фән-гыйлемнән ул энҗе-гәүһәр бөртекләре генә җыярга тырыша. Бөтенесен уптым илаһи кочаклап алырга омтыла. Бәгъзе бер шәкерт, хәлфә сорый башласа, бизгәк тоткандай калтыранырга тотына, рухы, җисмәни көче юк булу чигенә җитә. Галимҗан исә, киресенчә, әллә нинди сораулар биреп, хәлфәнең үзен аптырата. «Шәрхе Габдулла»-да әллә нинди шәкелләр бар. Аларның төрлесе төрле мәгънә аңлата. Бервакыт ул «зар»ның мәгънәсен сорады. Хәлфәнең моңа үлеп ачуы килде.

— «Зар-зар»ның акырып, кычкырып-кычкырып елау икәнлеген өч-дүрт яшьлек бала да белә; синең шуңа да башың җитми,— диде.

Шәкертләр тынып калды. Хәлфә дәвам итте:

— «Зар-интизар»ын да әйтеп бирергә кирәкме?

Галимҗан авызының бер як чите белән генә елмаеп куйды. Аның бу гадәтен хәзер хәлфә дә, шәкертләр дә белә. Сүзсез генә елмаюы гаҗәпләнүне аңлата. Гәрчә Галимҗан аны кешедән каһкаһә көлү нияте белән эшләмәсә дә, башкалар тарафыннан ул шулайрак кабул ителә. «Зар»ның гарәптә тавыш белән елаучыны, иңелдәп, үкереп елаучыны, дәрмансыз, көчсез булуны, зәгыйфьлекне аңлатканны белә ул. Аның «Шәрхе Габдулла»да икенче мәгънәсе бар: «үзе кушылган исем белдергән әйбернең күп була торган урынын белдерүче кушымча («лык», «зар» мәгънәсендә); мәсәлән, гөлзар — чәчәклек».

Кат-кат төпченә-төпченә шуны сорады Галимҗан.

Хәлфә икеләнеп сүзсез калды. Шомлы хис-тойгы кичерде.

— Бу кадәресе сиңа зарури түгел,— дип, бу хосуста үзенең сай йөзгәнлеген сиздерде дә чыбыгын чыжлатып алды.

Шулай да Галимҗан чигенмәде. Зарф хәлфәгә җае чыккан саен, һәр форсаттан файдаланып, сорауны яудыра бирде. «Зариф» гарәп телендә ягымлы, нәзакәтле, чибәр, күңелне тартып торырлык итеп сөйләшүче кеше, оста сүзле кеше кебек мәгънәләрне аңлата. Ә нигә бу хәлфә үзен «Зариф» дип түгел, «Зарф» дип йөртә? «Зарф» гарәпчәдә «савыт», «футляр», «конверт», «дәвам», «эч» дигән төшенчәләрдә йөри. Бу сүз «Шәрхе Габдулла»да да бар икән: зарфе заман (вакыт рәвеше), зарфе мәкян (урын рәвеше).

«Зариф» хәлфәнең рухи халәтенә, эчке үзенчәлегенә аслан туры килми. Чөнки ул ягымлы да, нәзакәтле дә, чибәр дә түгел. Ул, ягымлы сөйләшкән кешеләр кебек, һич тә күңелне тартып тормый. Киресенчә, күңелне кайтаручы, эч пошыручы наданлык. Мендәргә җәелеп утыра да тотына әллә ниләр такылдарга. Мондый мәлдә ул, мактана-мактана, үзен пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрә. Ул, имеш, бәхәс вакытында әллә күпме ишан, хәзрәт, муллаларның авызын каплаган оста мантыйкчы. Ә инде Галимҗан кебек гыйлем диңгезендә тирән йөзәргә килүчеләр мантыйк кылын тарткалый башлагач, ул кылның тутыклыгы, өзелергә торуы сизелде. Галимҗан «зариф» белән «зарф» аермасын сорагач, аның төссез соры күзләре песинекедәй елтырады, ач яңагы эчкә тагын да ныграк баткандай тоелды, колгадай озын буе чайкалып куйды. Димәк, әйтә алмый, белми. Бу юлы Галимҗан, башка вакыттагы кебек, авыз чите белән елмаеп кына калмады. Икесенең дә мәгънәсен чатнатып әйтте дә бирде:

— «Зариф» «ягымлы» дигәнне аңлата, «зарф» «савыт» була,— диде.

Бераз торгач янә:

— Буш савыт була,— дип өстәде.

Хәлфә сыны белән катты. Ә шәкертләр, әллә нинди нәзек-тутык тавышлар чыгарып, мәдрәсәнең черек диварын аударыр чиккә җиткереп, шаркылдап көлеп җибәрделәр. Хәлфә дә чыгырыннан тәмам чыкты шикелле. Җенләнгән кеше төсенә кереп, Галимҗанга кизәнеп килде. Галимҗан да кызып китте. Бер мәлдә аңа әллә шайтан көче кердеме? Хәлфәнең чыбыгын, ялт тартып алып, ике кулына тотып, тезләренә бәрә-бәрә сындырып ыргытты.

Шәкертләр аһ итте. Аларның күзләре тоздай булды. Әллә нинди атамалар тагып бетергәннәр иде бит Галимҗанга. Хәзер кемгә тиңләргә инде аны? Арыслангамы? Бөркеткәме?

Мәдрәсә тарихында булган хәл түгел бу. Моны унар ел

шушында ми чиләндерүче берәр аю гәүдәле шәкерт эшләсә, бер хәл иде әле. Күрер күзгә әле һич тә ул кадәр каһарманлык сыйфаты сизелмәгән яшь шәкертнең болай кылануы акылга сыйгысыз. Әллә ул бер диванамы? Андый сәер яклары турында моңа чаклы да уйланмадылар түгел. Өч-дүрт ай эчендә, хәлфә әйткәнне дә көтмичә, әллә кайда керде дә китте. Ике елга дип тәгаенләнгән «Шәрхе Габдулла»ны ерып чыкты. Дәхи дә әллә нинди урыс китаплары ташый. Хәлфә сораганга аһ та итмичә чатнатып җавап бирә. Әллә аңа Ходай үзе әйтеп торамы? Берәр сихерле көч гыйлем серләрен колагына өрәме? Шул зур колаклар аша ул тиз генә ми күзәнәкләре дулкынына барып керәме?

Аның турында шундыйрак фикер йөртәләр иде.

— Син бик бәхетле, Галимҗан,— дигән сүзләрне әллә ничә мәртәбә әйткәндер инде бүлмәдәше Йосыф.

Ә менә бу ахмаклыкны ничек аңларга? Барлык бүлмәләрдә шул хакта сүз барды. Бүлмәдәше Йосыф исә әлеге бәхетлелекнең киресен әйтте:

— Су эчкән коеңа төкергән кебек, үз бәхетеңә аяк чалу бит бу, Галимҗан,— диде.

Бу хәбәр яшен тизлегендә «Хөсәения» мәдрәсәсенә барып җитте. Икенче көнне, иртәнге намаздан соң ук, абыйсы Шакирҗан килеп җитте. Ул бик борчулы, кәефсез, кайгылы иде. Ләкин, кырыс холыклы икәнлеген искә алып, җай гына сөйләшергә тырышты:

— Алай ярамас иде, Галимҗан энем, менә сине хәзер мәдрәсәдән куачаклар; әти-әнине нинди авыр кайгыга салганыңны аңлыйсыңдыр...— диде.

Сөйләшкәндә бүлмәдәше Йосыф та бар иде. Ул сүзсез генә тыңлап торды. Бераздан авыр тынлык урнашты. Аннан янә Шакирҗан телгә килде:

— Вәли мулла алдында да кыен бит әле.

Галимҗан гаҗәпсенеп карады:

— Ә монысы ни өчен тагы?

— Сине бит «Хөсәения»гә алмадылар. Вәли мулла да башта каршы килгән. Тик ул әтинең ялынуы аркасында гына ризалашкан.

— Мин хәзер сәламәт инде, теләсә нинди мәдрәсәгә китәрмен.

Бер-ике айдан Галимҗан чыннан да үзен яхшы сизә башлады. Моңа бик шат иде ул. Шакирҗан исә аның сәбәбен үзенчә ачыклады. Әнисе аны нигәдер артык иркәли иде. Монда ана канаты юк. Шәкерт халкы чирле бәбкә кебек йөрүчеләрне яратмый. Таңда сикереп торырга, салкын су белән тәһарәт алырга, намаз укырга, чиратлап эшләргә, үзеңә ашарга юнәтергә кирәк. Әтисе бер мәртәбә килеп киткән

иде инде. Акчаны Шакирҗанда калдырды. Чөнки әткәсе Галимҗанның акча тота белмәгәнен аңлый. Ә Шакирҗан аңа, Галимҗанга, акчаны азлап-азлап кына тамыза.

Ярый, кем әйтмешли, болары әле аның баш ярылып күз чыгардай галәмәт кайгы түгел. Менә монысы инде — хәлфә чыбыгын сындырып ыргыту кадәресе — аслан акылга сыя торган түгел. Бу хакта сүз кузгалгач, Галимҗан абыйсы Шакирҗанга да, бүлмәдәше Йосыфка да:

— Шулай кирәк, — дип кенә куйды.

Бу күңелсез хәлне Зарф хәлфә иң тәүдә Заһидулла хәзрәткә[1] җиткерде. Заһидулла хәзрәт исә мәдрәсә хуҗасы Вәли муллага йөгерә-атлый китте. Алар өчесе җыйналып, Галимҗанга каты җәза бирү турында озак кына гәпләштеләр.

— Чыбык белән бик каты, тәмам хәлдән тайганчы, телдән язганчы каезларга кирәк, — диде Зарф хәлфә.

— Әйе, шулай мәслихәт булыр,— диде Заһидулла хәзрәт.

Мәдрәсәдән шуннан соң гына куу муафыйк булыр, дигән фикергә килделәр.

Галимҗанның, дини сабаклардан тыш, ниндидер урыс китаплары, «әхлаксызлыкка» өйрәтә торган әллә нәрсәләр укуы, барлык акчасын шуңа сарыф итүе бөтенесенә дә мәгълүм иде инде. Аның бу «ахмаклыгы» да боларны уттан курыккан бүре хәленә куя башлаган иде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, инде бу кыланышы болай да тирә-якка яманаты чыккан мәдрәсә өстенә кара сөрем булып капланды. Чүпне вакытында утамасаң, иген басуын да каплап китә, бакчаларны да харап итә. Вакытында котылмасаң, мондый тыйнаксызлар, мәдрәсәң эчендә ике аяклы шайтаннарның мыжылдап үрчүен көт тә тор. Әле мәдрәсәгә борыны гына кергән. Әмма шәкерт борыны түгел бу. Пычрактан ризык-нигъмәт эзләгән дуңгыз борыны.

Февраль урталары иде бу. Март аенда уку тәмамланачак. Шуңа күрә, икенче елга килмәсен өчен, сүзне җеп урынына сузып маташуның аслан файдасы юк; мәдрәсәнең эчке низамына яраклы рәвештә, моннан канатын сындырып чыгарып җибәрү хәерле булыр. Мондый динсез, әхлаксыз, ашаган табагына төкерүчеләрне асрап, Аллаһы Тәгалә каршында үзең гөнаһлы булып калуың бар. Ходай сакласын! Ходай сакласын!

Шулай да алар бер изгелек күрсәтмәк булды. Югары сыйныфта булса, менә бүген үк җилперләр иде. Аның үзен

---

[1] Заһидулла чынында исә мәдрәсәнең назыйры (эчке тәртип саклаучысы). Нишләптер аңа хәзрәт исеме бирелгән.

генә чыгарып җибәрү куркыныч. Авыллары шактый ерак. Әтисе килеп алсын. Моның өчен Гыйрфан муллага хат язарга булдылар. Бу «мөкатдәс» эшне Вәли мулла үз җилкәсенә алды. Хатны ул болай артык тузынып язмады. Үзен инсафлы, Алла каршында гөнаһсыз, әдәпле итеп күрсәтергә тырышты. Менә ул:

*«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле булып торгучы Гыйрфан әфәнде! Үзеңә вә хәләл җефетеңә күптин-күп сәламнәр күндерәм. Сәлам соңра сезләр өчен бигүк күңелле булмаган хәл турында хәбәр кылырга мәҗбүрмен. Мәгълүм ки, улыңыз Галимҗан йомшак вә бимар[1] бала иде. Шул сәбәпдин аны «Хөсәения»гә дә алмадылар. Бән үзем, сезнең мулла икәнлеңегезне, мәдрәсәдә мөдәррис булуыңызны да искә алып, сезнең белән муалят[2] мөгамәләгә кереп, авыр булса да, ихтирам-хөрмәт йөзеннән, улыңызны алып калырга җөрьәт иттем. Сез улыңыз Галимҗанны мактаган идеңез, билфигыль[3] билгакес[4] килеп чыкты. Бу һич кенә дә муасигъ түгелдер[5]. Мәдрәсәнең низам-интизам кадәресе дә аның өчен гүяки бер нафилә[6] нәрсәдер. Хәтта ки, Зарф хәлфә белән якалашу чигенә барып җитте. Ул гайре табигый мохтәслек[7] колы. Нахәлял[8] эшләр белән мәшгуль. Илтифатлылыкның ни икәнлеге аның уенда да юктыр. Бунның шулай булуы безем өчен би нишан[9]. Алла сакласын инде. Бинабәрин[10] безләр — мәдрәсәнең хәзрәте Заһидулла, хәлфәсе Зарф җәнаплары, дәхи дә башка гыйлем ияләре — билмөшарәкә[11] фикер алышкач, моназарә кылгач, улыңыз Галимҗанны мәдрәсәдән азат итәргә дигән карарга килдек. Иншаллаһ, безләрнең бу карары аның киләчәк язмышы өчен илаһи бер сабак булыр. Башка урында андый хилафлык кыйлмас. Алла үз канаты астына алсын инде. Чирне вакытында кисеп ташлау хәерле. Шулай итмәгән хәлдә, Ходай Тәгалә каршында сез дә, без дә бихисап гөнаһлы булып калыр идек. Аларны үз иманына билмөшәрәкә кайтару безем иң мөкатдәс максатыбыздыр. Улыңыз әлегә биттәфсыйль-*

[1] Бимар — авыру.
[2] Муалят — дусларча.
[3] Билфигыль — чынлыкта исә.
[4] Билгакес — киресенчә.
[5] Муасигъ түгел — башка сыйдыра торган түгел.
[6] Нафилә — буш, кирәксез, файдасыз, тиешсез.
[7] Мохтәс — бер нәрсәгә хаслашу, шуның буенча үзенчәлекле булу.
[8] Нахәлял — тыелган, дөрес булмаган.
[9] Би нишан — билгесез.
[10] Бинабәрин — шуңа күрә.
[11] Билмөшарәкә — берләшеп.

*гә[1] килерлек имәс. Вәләкин, яшен искә алып, аны әле бүгендин үк мәдрәсәдән чыгарып җибәрү ягында түгелмез. Шулай эшләсәк, безнең тарафтан бәндәчелексезлек күрсәтелмеш булыр иде. Бинабәрин улыңызны үзеңез килеп алыңыз!»*

## X

Хатны алгач, Гыйрфан мулланың оҗмах-җәннәткә тиң өй эче капылт тәмугка әйләнгәндәй булды. Ата кешенең куллары хатны укыганда ук дер калтырап торды. Бөтен тәне-вөҗүде камырдай йомшап, күзләре чекерәеп, колаклары тонып калды. Түбәгә кемдер чукмар белән китереп тондыргандай тоелды. Илаһым! Бар икән күрәчәкләре. Ни гөнаһлары бар икән аның Аллаһы Тәгалә каршында? Инсаниятчелек дигәндә — кем аның илаһи ак намусына кара тап төшерә алыр икән? Ә менә балалар төшерә. Шакирҗаны мәмәй авыз булды. Ни караган шунда? Нигә энесе янына даими килеп йөрмәгән? Нигә күзәтмәгән? Нигә үгетләмәгән яхшы якка? Һәр нәмәрсәкәйне бозыла башлаганчы карау мотлак. Бозыла башладымы — шул төшен кис тә ыргыт, кис тә ыргыт. Ник ул мәмәй авыз шулай итмәгән? Нигә энесенең һәр ертык урынын ямый бармаган? Селәгәй. Кибәк баш. Буш җилек. Уф! Егыл да үл. Җир тишегенә кер. Чәнчелеп кит. Гарьлеге ни тора моның. Дус бар, дошман бар, туган-кардәш бар. Алар ни әйтер? Җиң сызганып көн-төн эшли, чукынырдай булып дөнья көтә, артына ут капса да, биш вакыт намазын калдырмый, вәгазь сөйли, үгет-нәсихәт кыла, ә менә бер маңка малаена көче җитми, диннән язган, иманын саткан, шуңа күрә мәдрәсәдән куганнар, диярләр, илаһым! Баланың тездә чакта сөйдерүе, тездән төшкәч көйдерүе шушы икән. Көйдерә болар. Йөрәгеңне яндыра. Күңелеңне өтә. Менә сиңа таш маңгай. Менә сиңа пәйгамбәр. Менә сиңа нәсел орлыгыннан шытып үсеп чыккан агачны һаман үстерү, яшелләндерү, күркәм сыйфатта тоту. Үстерде ди. Тот капчыгыңны. Үстерми болар. Корыталар. Алар бүгенге көн кояшы белән яши. Үз корсагы кояшы кыйммәт аңа. Аның өчен нәсел кояшы, халык кояшы, ил кояшы сукыр бер тиен дә тормый. Күктәге кояш менә бүген сүнсә дә, гамьнәре юк. Әллә-лә-лә-ләл. Әллә-лә-лә-ләл. Уф! Илаһым! Бердәнбер ышанычы иде бит. Бердәнбер.

Хатны ул, үзе дә сизмәстән, учында йомарлады. Остабикәсе, ни дип әйтергә дә белми аптырап, тик торды. Мулла-

[1] Биттәфсыйль — җентекләп аңлату.

сының акайган күзләрен, көзге яфрактай дерелдәп торган иреннәрен, җыерылган маңгаен күреп, яман хәбәр килгәнлекне аңлау кыен түгел иде. Ул һаман шулай элеккечә тыныч, салкын канлы булырга, шул салкынлык белән иренең утын сүндерергә тырышты:

— Мулла, син бөтенләй бетеп калдың. Аңлыйм: яхшы мәктүп түгел, шулай да Ходайдан сабырлык сора, үзеңне кулга ал. Аллаһы Тәгалә авыр кайгыларга да бирешмәскә кушкан бит...— дип, янә дә шуларга охшаш күпме җылы сүзләр әйтеп юатмакчы булды.

Ләкин ул баллы-майлы, җылы-кайнар, ялкынлы сүзләр мулласының таштай каткан йөрәген эретерлек түгел иде. Киресенчә, бу мәлдә алар ачуын гына кабартты, җенен генә кузгатты:

— Мә, укы,— диде дә Гыйрфан мулла, хатны остабикәсенең битенә бәрде.

Аның лөгатькә сыймаслык бу кыланышы «баланы син генә боздың» дип әйтү билгесе иде.

Моны эшләгәч, үзен кая куярга урын тапмыйча җенләнеп-котырынып, тышка чыгып китте.

Хәсәнә абыстай бер мизгелгә ни кылырга да белми аптырап тик торды. Мулласы артыннан чыгаргамы? Һаман шулай:

— Атасы, бу кадәр сабырсызланма әле, Ходай кушмаган эш булмас, тынычлана күрче, балаларга кайгылы йөз күрсәтү килешми,— кебек сүзләрне әйтә-әйтә, тәкрарлый-тәкрарлый юатыргамы?

Бәгъзе берчак аңа да килми бит әле ул — кулын гына селтәп җибәрә: кит, янәсе, мыегымны чуалтып йөрмә.

Шундый уйларны кичереп, үзен кулга алгач, идәндә йомарланып яткан кәгазьгә күзе төште. Аның эчендә ниндидер дәһшәт, давыл, өермә бардыр кебек тоелды. Шул дәһшәт аның йөзенә ут йомгагы булып томырылды.

Кәгазьне абыстай курка-курка гына алды кулына. Аны өстәлгә җәеп, әйбәтләп укырлык дәрәҗәгә җиткәнче төзәтте. Укып чыккач, никадәр генә йомшап китмәскә тырышмасын, Ходайдан сабырлык сорап изаланмасын, күз яшьләре аның ихтыярына буйсынмады.

Әле иртә иде. Балалар эчке бүлмәдә йоклый иде. Ярый, рәхәтләнеп, йөрәктәге кайгы утын түккәнче, күңелен тәмам бушатканчы елаганын күрмәделәр. Тик ул ялгышкан икән. Кызы Нәгыймә, һәрвакыттагыча песи кебек йомшак кына басып, башкаларны уятмас өчен авыр тын да алмыйча, бу якка чыккан икән.

— Әнкәй, әнкәй, ни булды, нигә елыйсың?

— Еламыйм, кызым, менә күземә чүп кергәние.

— Юк, юк, әнкәй, яшерәсең. Әллә әти рәнҗеттеме?

— Иртәнге сәгатьтә нинди рәнҗетү булсын.

Хәсәнә абыстай, кызына күрсәтмәс өчен, елаудан шешенгән күзләрен яулык чите белән каплап, тышка чыкты. Ә менә хатны алырга оныткан. Өстәл өстендә калдырган. Аны укып чыккач, барын да аңлады Нәгыймә. Әнисе кебек, әлбәттә, буылып-буылып еламады, оһ итмәде. Башта бу мәсьәләгә битараф кеше кебегрәк кыланды. Шулай да бу усал хәбәр аның да йөрәген таштай катырды. Әтисе хәзер яраланган арыслан кебек кыланачак. Әнисе мескен кайгы утында яначак. Өй эчендәге низаг зилзиләдән ким булмас. Бу хурлыкка әтисе түзә алмас.

Менә әнисе бераздан әйләнеп тә керде. Ул инде күз яшьләрен ныклап сөрткән. Бая яулык эченнән чыгып торган чәчләре дә күренми хәзер. Шулай да ул һаман да әле кызына туры карамаска тырышты.

Нәгыймә:

— Әнкәй, әнкәй, бик борчылма инде, Галимҗанның табигатен беләсең бит, ул барыбер үзенекечә эшли,— дигәч, ана йөрәге дерт итеп китте.

— Нигә алай дисең әле, кызым, ни булган...— дип, барын да яшерергә тырышты. Кызының кулындагы хатын күргәч кенә мәсьәләне аңлап алды.

Нәгыймә үзенчә аз гына үпкә белдерергә дә онытмады:

— Әнкәй, нигә мондый хәлләрне миннән яшерәсең әле, бала түгелмен дә инде хәзер,— диде.

Әйе шул, нигә кайгыны да, шатлыкны да уртаклашып яшәгән кызына бу авыр хәлне белдермәскә тырыша соң әле ул? Җитмәсә, Нәгыймә менә-менә канатланырга торган гүзәл кош ла инде. Хәсәнә абыстайның бианасы, 12 бала тәрбияләп үстерү белән горурланган. Шуларның берсе — аның ире Гыйрфан мулла. Бу минутта Нәгыймәнең 16 бала анасы булачагы хакында әнкәсе ялгыш кына да уйлый алмый әле.

Шул көнне үк Гыйрфан мулла юлга чыгарга — Ырынбурга барырга әзерләнә башлады. Шул көнне үк хәләл җефете Хәсәнә абыстай түшәккә ятты. Башы чатнап ярылырдай булып сызлый. Вакыт-вакыт күз аллары караңгылана. Керфек очларында да хәтта гер ташыдай ниндидер авыр нәрсә асылынып торгандай тоела. Ара-тирә аягын нык кына көзән җыера. Тамак төбенә әллә нинди имәнеч зур төер килеп тыгылгандай була.

Шулай да төшкә чаклы аны сиздермәскә тырышып йөрде. Өйлә намазын укыганда, намазлыкка тәгәрәп китүен абайламый да калды. Аны ястыкка алып салдылар.

Гыйрфан мулла ике ут арасында калды. Бер ут — остабикәсе. Икенче ут — Ырынбур. Кайсы утны сүндерергә башта? Әлбәттә, монысын. Бу утны сүндерми торып, юлга чы-

гарга ярамый. Ә нишләп шулай, ваба чиренә эләккән кешедәй, капыл-кинәт тәгәрәп китте соң әле ул? Галимҗан кайгысы шулай иттеме? Юк, ул гына түгел иде. Андый кайгыларга аслан бирешми иде бит ул. Киресенчә, аның үзен авыр кайгылардан аралап яшәргә тырышты. Бер-бер күңелсез хәл килеп чыкса, гел борчылмаска кушты. Юк, аңа гына түгел, кыен мәлләрдә күрше-күлән, кардәш-ыруг, дус-иш...— һәммәсенә, һәммәсенә сүз шифасы таба алды, назлы карашларын бүләк итте, йөрәгенә үтеп керде. Юк, әле менә Галимҗан кайгысы гына екмады аны аяктан. Иренең юньсезлеге яткызды түшәккә. Йомарланган хатны тот та аның йөзенә бәр, имеш. Бу инде — илтифатсызлыкның илтифатсызлыгы. Бу инде — әдәпсезлек. Бу инде — шәфкатьсезлекнең шәфкатьсезлеге. Бу — бәяләп бетергесез ахмаклык, юләрлек, түбәнлек. Шундый фәрештә күңелле остабикә бит әле ул. Кырт-мырт итеп торган, кылдый-былдый йөргән, синең бер сүзең өчен авызыңа мең бердәгәйле сүз каплаган зәһәрле хатын булса, әллә-лә-лә-ләл, бәрер иден битенә болай. Бәрсәң дә, ул синең ипи шүрлегеңә табагач белән китереп сылар иде. Матурлык-изгелек фәрештәсенең ак-нурлы йөзенә кара-пычрак кул белән кизәнгән иблис кебек булды бу. Шул гарьлеккә чыдый алмый ауды ул киселгән агач урынына.

Алтыдагы — алтмышта, дигәне шушымы? Нишләтергә бу холыкны? Әйтәләр ләбаса: «Акылыңа акыл куш, ачуыңа сабыр куш», «Ачу — акыл дошманы», «Ачу алдан йөри, акыл арттан йөри». Тагын да әллә нинди ләре бар әле аның. Этисе дә, картәтисе дә әйтә иде. Борынгылар сүзе, дип. Алтын бәрабәренә торырдай ул акыллы сүзләр бер колагыннан кереп икенчесеннән чыгып китеп торганмы? Миенә барып җитмәгәнме?

Нишләргә хәзер? Барып гафу сораргамы? Ул, әлбәттә, кичерәчәк. Әмма ләкин аннан ни файда? Ичмасам, шартлап ярылырдай итеп бер авыр сүз әйтсен иде. Бу ахмак күңелгә бер тукмак булыр иде.

Шундый утлы уйлар өермәсе эчендә бөтерелеп йөрде Гыйрфан мулла.

Хәсәнә абыстай исә капыл тәгәрәп китү сәбәбен аннан эзләп бимазаланмады. Ир хакы — Тәңре хакы. Әле әнә бәгъзе бер ир хатынын изеп ташлый. Шулай да түзә, йөрәк канын эчкә йота, күгәргән битен, сынган кабыргасын кешегә сиздермәскә тырышып йөри. Сорасалар, «егылдым» дип җавап бирә. «Ир хакы — Тәңре хакы» дигәнне ул яхшы аңлый. Ә шулай да: «Хатын хакы ни икән?» — дигән сөаль дә борчый аны. Шул сөальгә җавап булып томырылдымы йөзенә әлеге кәгазь йомарлагы? Ул, әлбәттә, нык гарьләнде,

түбәнсенде, чыдый алмас хәлгә җитте. Шул изде шикелле аны. Шул екты.

Менә бервакыт мулласы аның янына килде. Салкын кулы белән кайнар маңгаена кагылды. Сизә: кулы дерелдәп тора. Димәк, ул борчыла. Кылган ахмаклыгы өчен үкенә. Сызлана.

Менә ул сүз башлый:

— Йә, остабикә, ачуланышмыйк инде, кичер мин юньсезне, гаеп тәртәсе икебезнең дә йөрәккә килеп төртеләдер. Галимҗанның болай тәүфыйксыз булуында икебез дә гаепледер.

Гыйрфан мулла нык дулкынлана иде. Сөйләгәндә аның калтыранып-калтыранып алуын, сүз таба алмый интегүен сизде Хәсәнә абыстай. Акрын, салмак, йомшак тавыш белән сорап куйды:

— Юлга әзерсеңме?

— Анысы аның качмас иде лә ул. Менә син бит әле... Чирле кешене нишләп ташлап китим...

— Юк, юк, атасы, аңа карама, Нәгыйманең уңганлыгын беләсең... бүген үк чык юлга...

— Бүген соң инде, остабикә, иртәгә иртүк кузгалырмын, дүшәмбе көн юлга чыксаң, фәрештәләр ак җаймә җәя, имеш.

— Галимҗанга бик каты авыр сүз әйтмә инде, мулла, андыйны яратмый ул, үзең беләсең; һәркемдә бер кире сыйфат булмый калмыйдыр шул инде.

— Ярый, анасы, фатиханда бул инде, каты рәнҗеттем, үпкәләмә берүк...

## XI

Гыйрфан мулла эшне иң әүвәл мәдрәсә хуҗасы Вәли мулладан башламак булды. Атын аның капкасы төбенә үк китереп туктатып, шундагы бер баганага бәйләп куйды да, тамак кыракыра, эчкә узды. Ишек шакыгач, башына кызыл фәс кигән унике яшьләр чамасы бер малай килеп чыкты. Гыйрфан мулла аның йомышчы икәнлеген аңлап алды.

— Вәлиулла галиҗәнаплары өйдәме, улым? — дип сорады ул.

— Өйдә,— дип җавап бирде малай.

— Керергә рөхсәт сорасаңчы. Мин е613 ерактан килдем. Галимҗан мәхдүмнең әтисе булам.

Малай ялт өйгә кереп китте, бераздан әйләнеп тә чыкты.

— Вәлиулла галиҗәнаплары сезне көтә,— диде дә янә юк булды ул.

Шуннан Гыйрфан мулла, арбасы янына янә әйләнеп ки-

леп, аннан ике тозлаган каз, бер савыт кәрәзле бал, тагын да вак-төяк күчтәнәчләрен алып, өй эченә юнәлде. Вәли мулла түр башында тәсбих тартып утыра иде. Ул болай ару гына мөлаем күренә. Түгәрәкләнеп торган кара сакалы килешле генә. Башындагы Бохара дуплысы да кызарып торган бит очларына ямь өсти кебек. Биш билле кара камзулы «менә мин нинди зыялы әфәндене затлыйм» дип мактана шикелле.

— Әссәламегаләйкем! — дип, үзенчә бер түбәнчелек, әмма ләкин гаҗәп олылау, зур мөхтәрәмлек белән сәлам бирде Гыйрфан мулла.

— Вәгаләйкемәссәлам! — дип тамак кырып, үзен гарше көрсидә утырган илаһи зат хәлендә күрсәтергә теләп, эре кыяфәт белән каршылады аны Вәли мулла.

Башта сүзләр әллә ни берекмәде. «Әйе», «ә», «җәме», «җә» кебегрәк файдасыз, салкын, кыенсынып сөйләшү дәвам итте. Гыйрфан мулла алып килгән күчтәнәчләрен аның алдына тезеп куйгач кына, тегесенең һавалы йөзе бераз ачыла төште: шунда гына ул тәсбихен куеп, еraktan килгән кешегә илтифатлылык лазем булуны аңлады. Шулай да, эре кыяфәтен тиз генә вакларга ашыкмыйча, үзен әллә кемгә куеп, мөхтәрәмлелек югалмасын дигәндәй, һаман әле ачылып китәргә ашыкмады. Гыйрфан мулла аның ихлас булмавын беренче күрешкәндә дә сиземләгән иде. Ә хәзер инде, улы шундый хәлгә төшкәч, аның тәкәбберлеге янә мең тапкыр артачак — мәгълүм хәл. Бу аның сүз башлавыннан ук сизелде.

— Ху-у-у-ш, Гыйрфан әфәнде, ни йомыш? — дип сорады ул, улы Галимҗан турында ләм-мим хәбәрдар булмагандай бер пошамансызлык белән. Әйтерсең булган хәлләр аның өчен әһәмиятсез бер вакыйга иде.

Гыйрфан мулла үзен бик түбәнчелекле тотарга тырышты. Биредә сырт кабартуның хәләл җефет алдында кәпрәю түгел икәнлекне аңлый иде ул.

— Сезнең хат буенча килдем, Вәлиулла галиҗәнаплары, шул инде: әлеге дә баягы углым Галимҗан хакында… — диде ул, итагатьлелекне сакларга тырышып, юаш, басынкы тавыш белән.

Сөйләшү шактый озакка сузылды. Вәли әфәнде Гыйрфан мулланы бетереп тә ташламады, күккә күтәреп мактамады да. Сүзләренә караганда, аның тел төбе Галимҗанның гаиләдә яхшы тәрбия алмавына барып төртелә иде. Имештер, Галимҗан гәрчә ак нәселдән булса да, нәҗес эшләр белән мәшгуль.

Шуннан сөйләшү, акрын гына аккан агымсу үз юлын тапкан кебек, чыбык мәсьәләсенә барып төртелде. Галимҗанның Зарф хәлфә чыбыгын сындырып ыргытуы, Вәли мулла уйлавынча, көфернең Мөхәммәд пәйгамбәргә таяк белән ки-

зәнүе кебек икән. Мондый нәҗеслек мәдрәсә хәятендә моңача әле булмаган. Аның «тәрбиясез» улы Галимҗан мәдрәсәдән шуның өчен куыла. Бетте китте. Вәссәлам.

— Мондый нәүгъларны безем мәдрәсәдә тоту нәмәхрәм шул, Гыйрфан әфәнде,— дип сүзен тәмамлады ул.

Шулай да Гыйрфан мулла язгы кардай эреп төшмәде, куркак куяндай кирегә бөкләргә дә ашыкмады. Әйдә, чәнчелеп китсен аның башбирмәс малае, укыйсы килми икән, кайтсын, сабан сөрсен, тырма тырмасын, иген чәчсен, иген урсын, печән чапсын; Ходайга шөкер, анда эш җитәрлек. Муеннан. Тик, көрәш мәйданында бил сындырган йомшак җан кебек, болай җиңелеп кайтып китүе кыен бит әле. Вәли мулла аны тәгаен мыскыл итте. Бала тәрбияли белмәгән бер мәмәй авызга чыгарды. Бу хурлыкны күтәреп кайтып китсенме ул Солтанморатка? Юк инде. Булмый. Ул бит әле теләсә кем түгел. Троицк мәдрәсәсендә баш мөдәррис булган абруйлы шәхес.

Гыйрфан мулла шуларны янә бер мәртәбә искәртеп үтүне мәгъкуль күрде. Шуннан килеп, улы Шакирҗанның өй матчасындагы чыбыкны сындырып ташлавы турында да әйтте. Чыбыктан мөгаллим Сәетнең баш тартуын да искә алды. Чыбык белән «тәрбияләүнең» гүзәл нәтиҗә бирмәячәген ярып салды.

Аларны, билгеле, салкын кан белән, ашыкмыйча, һөҗүм кылмыйча аңлатырга тырышты. Акрын-акрын, уйлап-уйлап, җиңү дәрте белән сөйләште. Вәли мулланың уй казанында фикер сыек булганлыкны аңлады ул. Ахмакны һәр очракта акыллы сүз белән җиңеп булмаячакны да белә. Шулай да монда ордым-бәрдем белән эш итү дә бик читен. Кинәт күз алдына остабикәсенең битенә кәгазь йомарлыгы белән бәрү ахмаклыгы килеп басты. Галимҗанны бөтенләйгә алып кайтса, мәдрәсәдән мәңгелеккә мәхрүм итсә, аның күзенә ничек карар да, ялварулы карашларына ни җавап бирер. Телең булмаса, күзеңне әллә кайчан карга чукыр иде, шул бала язмышын хәл итәр рәтең дә юк икән, дип сыкранырга мөмкин. Боларны ул, әлбәттә, әйтмәячәк. Әнә шул әйтмәве үтерә бәгъзе бер вакыт.

Йомшак, әдәпле, мөкиббән сөйләшкән саен, Вәли мулланың һавалана баруын, борын чөюен, очынуын аңлады ул. Шуңа күрә бүртеп торган кызгылт бит очларына салкын җил истерүне мәгъкуль күрде.

— Мәдрәсәгез бик йончу, безнең авылда мондый бинага малны да япмыйлар, низам-интизам юк, Вәлиулла әфәнде, мин шикаять кылам, буны аслан да тәһдид[1] ысулы дип кабул итмәгез,— диде ул.

[1] Тәһдид — куркыту, янау.

Гыйрфан мулла аның нәкъ авырткан җиренә китереп басты. Ул инде әллә күпме ел шул шикаять дигәннәреннән куркып яши. «Кадим мәдрәсә» дигән яманаты бар. Аңа килергә ашкынып тормыйлар хәзер. Менә шушындый Гыйрфан кебек мөмтаз, гайрәтле, гаярь ирләр җыйнаулашып шикаять кыла башласа, мәдрәсәң, кем әйтмешли, карга оясы урынына туздырылырга мөмкин. Шуны уйлап, баштук каты итеп тоткан сүз тезгенен акрынлап-акрынлап бушата барырга уйлады ул.

— Хи-хи-хи, хи-хи-хи... усаллык белән алдырмак буласың инде алайса, хәерле булсын. Алла ярдәм итсен үзеңә, мин синдәй кыю кемсәләрне бик якын күрәм, яратам ук,— диде.

Сөйләшә-сөйләшә, фикерләшә-фикерләшә, уйлаша-уйлаша, уртага салынган авыр мәсьәлә Гыйрфан мулла файдасына хәл ителде. Галимҗанны мәдрәсәдә калдырырга булдылар.

— Үзең килү бик муафыйк булды, алып кайтып кит, икенче сыйныфка китереп куярсың, Аллаһы боерса; тик шундый шарт белән инде, Гыйрфан әфәнде: бундан булай андый ахмаклыклар, нәҗес эшләр кыйлмасын,— диде Вәли мулла.

* * *

Март азаклары иде инде. Бәгъзе бер урын кардан тәмам әрчелеп беткән. Алалы-тиләле җирләр дә бар. Койма төпләрендә кояш күзеннән мәхрүм булган кар өемнәре дә күренгәли. Алар инде бозга әверелгән. Өсләрендә пычрак-чачрак, ләпек-чәпек, алама-солама...— тагы да әллә нинди нәҗес әйберләр дөнья ямьсезләп тора. Ә инде урам уртасындагы юллар хәзер тап-такыр. Аз гына җил иссә, тузан күтәрелергә тора хәтта. Әмма яз кояшының йомшак, җылы, шифалы нурлары һәр кемсәне, һәр тарафны, һәр тереклекне илаһи бер олы, сөйкемле мөкиббәнлек белән иркәли. Бу нурлар гарше көрсидән адәм балаларына фәкать савап рухы алып килә кеби. Фанилыкта әле менә әйтерсең һичнинди яман эшләр кылынмый. Гүя һәммәсе ал да гөл.

Юк, гөнаһ шомлыгы, барысы да алай түгел икән шул. Түгел. Түгел. Мең кат түгел. Вәли әфәнденең мәнсезлеге Гыйрфан мулланың кәефен нык кырды. Әгәренки Гыйрфан мулланың өенә моңача һич таныш булмаган бер адәм заты мохтаҗлык илә килеп керсә, буш кул белән чыгарып җибәрер идемени? Юк, җибәрмәс иде. Аслан җибәрмәс иде. Ә бу җаһил диндар ерак юлдан йончып килгән Алла бәндәсенең авызын да чылата алмады: бер чынаяк чәй дә куймады. Күңел өчен генә булса да: «Самавыр куйыйк, Гыйрфан әфәнде»,— дисен иде. Ә ул, Гыйрфан: «Юк, Вәли әфәнде,

мәшәкатьләнмәгез, эчкән чаклар булыр әле»,— дияр иде. Санга сукмаслык әллә нинди бер брәдәк түгел бит әле ул. Троицкиның данлыклы мәдрәсәсендә баш мөдәррислек эше кылган шәхес. Кирәк иҗһар[1] булсын, кирәк тәфсирне аңлау булсын, ул бит өстенлек күрсәткән диндар. Әллә аңламыймы ул җаһил Вәли мулла мантыйгының менә хәзер таралып төшәргә торган шыгырдык арба хәлендә икәнлеген? Илаһым! Кеше белән кеше аермасы — җир белән күк аермасы, дип юкка әйтмиләр икән. Үлемнән оят көчле, дигәне дә бар. Ояла белми икән бу җаһил.

Шундый уйлар давылы борчыды Гыйрфан мулланы. Вәли мулла капкасы төбеннән киткәч, башта ул атын үз иркенә куйды. Аннан, ашыгырга кирәклекне уйлап, юырта башлады. Вәли мулланың гамьсез күркә кебек кабарынып утыруы исенә төшсә, дилбегәсен ачу белән каты гына тартып, чаптырып та ала. Бу вакытта тимер арбаның тәгәрмәчләре, шаңгыр-шоңгыр өзек тавышлар чыгарып, артта куе тузан болыты сузып калдыра. Аңа хәзер җәһәт кенә «Хөсәения» мәдрәсәсенә барып җитәргә кирәк. Аннан Шакирҗанны алып, Галимҗан янына ашыгу мәслихәт булыр. Шәһәрне чыккач, беренче авылда атны ял иттерерләр, кичегеп китсә, шунда кунып калулары да ихтимал.

Шакирҗан янында артык озак мәшәкатьләнмәде ата кеше. Кереп табу белән тиз генә әйберләрен җыярга кушты да тизрәк Галимҗан янына ашыгырга кирәклекне әйтте.

— Әткәй, чәй эчеп алыйк,— дисә дә, Шакирҗан, гәрчә тамагы нык кипкән булса да, чәйләп утыруны ул бу мәлдә мәгъкуль күрмәде.

— Галимҗанда бергәләп эчәрбез, Алла боерса, арбада әнкәгез җибәргән сый-нигъмәт тә бар, әйдә, улым, җәһәт кылан,— дип ашыктырды.

Мәдрәсәдән күпләр киткән иде инде. Якын авыллардан булганнары үзләре җәяүли. Бәгъзе берләре, югары сыйныфтагылар, төрле завод-фабрикаларга, шахталарга, алтын прискаларына эшкә китә — киләсе ел уку өчен акча кирәк. Икенчеләре казахлар арасына юл тота. Язын-җәен анда мөгаллимлек кылып, бераз адәм рәтенә кереп, азрак көрәеп, кесәсен хәлләндереп кайта. Шакирҗан да дәртсенгән иде. Сәбәпсез сәгать тә йөрми дигәндәй, ике сәбәп аның җилән итәгеннән тартып туктатты. Беренчесе — атадан рөхсәт алынмаган: икенчесе — Галимҗан бәласе.

Бу хакта, ашыга-ашыга әйберләрен җыештырганда, мәдрәсәнең менә бүгенге хәлен аз гына булса да күз алдыңа китереп бастырыйм дигәндәй, әтисенә җайлап-җайлап әйтеп бирде Шакирҗан. Әткәсе аларны юньләп тыңламады да.

---

[1] Иҗһар — кычкырып уку, кычкырып сөйләү сәнгате.

— Һм... нигә кирәк сиңа әллә кая китү, әллә өйдә эш беткәнме, — дип кенә куйды.

Галимҗан өчен әтисе нык ачуланыр дип курыккан иде Шакирҗан. Шуны уйлап, әтисен төрле-төрле сүзләр белән әвәрә кылырга тырышты. Ни дисәң дә, әле шәкертләр китеп бетмәгән. Тыз да быз чабып йөргәннәре дә, йокымсырап утырганнары да, чәй эчү белән мәшгуль булганнары да бар. Әтисенең кызу канлы икәнлеген белә Шакирҗан. Галимҗан өчен менә хәзер үк, шул тыз да быз йөргән шәкертләр туктап тыңлар дәрәҗәгә җиткереп, сүгә башлар кебек тоелган иде. Шулай килеп чыкмасын өчен, янә бер яңалык әйтеп ташлады:

— Әткәй, монда Гаяз Исхакый дигән бер бик мәгълүматлы мөдәррис киләчәк икән, ул китаплар да, әдәби әсәрләр дә яза, имеш, — диде.

Әткәсе өчен бу яңалык та ике чабатаның бер кием булганы сымак кына тоелды. Галимҗанны карамаган, күзәтеп тормаган өчен Шакирҗанның колагын менә хәзер үк борырга иде аның нияте, әмма ләкин тыелды: кеше йортында авыздагы кара канны да төкерергә ярамаганны белә ич ул.

Әйберләрне җәһәт-җәһәт чыгарып бетереп, арбага төягәч:

— Әткәй, син юлда арыгансыңдыр, кая, атны үзем тотыйм, — дисә дә Шакирҗан, ата кеше ризалашмады.

— Җәтрәк менеп утыруыңны бел, теләсә кемгә баш бирә торган байтал бардыр шул миндә, — диде коры гына.

Шакирҗан сизә: әткәсенең кырт-мырт килеп торуы, утка баскан кебек кылануы, дөньяга сыймастай булып чабалануы — Галимҗан өчен. Ә инде үзен, һаман шул элеккечә, җиде кат күк түбәсенә куеп, балалары башына кимсетеп карый: «Теләсә кемгә баш бирә торган байтал бардыр шул миндә», имеш. Үтерде ул бу сүзләре белән Шакирҗанын. Егетлек дәрәҗәсен челпәрәмә китерде.

— Әткәй, нигә әле син мине ул кадәр түбәнсетәсең? — дияр иде — ярамый: ата кеше сүз кайтарганны яратмый.

Хәер, аны әйтергә форсат та юк. Әтисе, дилбегәне тоту белән, аны шактый нык кагып, байталга җәһәтлелек кирәклекне аңлатты. Байтал, колакларын торгызып, шундук ут кебек томырылды. Әйтерсең Сабантуйдагы чабыш мәле. Әтисенең эчендә җил-давыл, өермә барлыкны аңлады Шакирҗан. Бер сүз әйтсәң, әтисе шартлап ярылып, ул давыл-өермә үзенә ябырылыр кеби тоелды. Әллә кансыз дамы аның әтисе?

Юк, алай ук түгел. Бердән, Галимҗан өчен үлеп ачуы килсә, икенчедән, берникадәр кызганып та куйды әле Шакирҗан улын: кипкән, корыган, яңак сөякләре калкып чыккан — менә ни дәрәҗәгә төшерә бу мәдрәсә хәяте адәм баласын.

Менә Су урамы белән Татар тыкрыгы чаты. Менә Вәли мулланың кадим мәдрәсәсе.

— Тыр-р-р...

Байталны ат бәйли торган махсус баганага бәйләп куйдылар.

— Әйдә, чәй эчеп, тамак ялгап алыйк та, аннан кайтыр якка тәвәккәлләрбез, караңгы төшкәнче якындагы берәр авылга барып баш төртеп алырга кирәк булыр,— диде дә ата кеше, ризык-ашамлык төйнәлгән төенчекне күтәреп, капка аша үтте. Шакирҗан аннан калмаска тырышты.

Ихатага кергәч, аларны әллә нинди нәҗес чүп өемнәре каршы алды. Гыйрфан мулла, шуларны күреп, чыраен сытты, маңгаен җыерып, тәмам гаҗиз булып калды. Күз алдына әле генә борчак чүмәләседәй кукраеп утырган Вәли мулланы китерде. Бу чүп өемнәре дә әнә шул борчак чүмәләседәй җәелеп утырган Вәли мулланы хәтерләтте. Ул өемдә ниләр генә юк: иске чабата, күгәреп-череп каткан җирәнгеч чүпрәк-чапрак, сасыган бәрәңге кабыклары, тагын да әллә ниләр, әллә нәмәкәйләр... Алардан нindидер сыек зәңгәр бу-төтен күтәрелә. Әллә көя, әллә яна — шайтан да белерлек түгел. Шулардан тирә-якка косасыны китерә торган тәмсез, әчкелтем-төчкелтем, сасы ис таралган. Илаһым! Боларны күреп, адәм йөзе генә түгел, кояш йөзе кызарырлык бит. Кит инде. Кит! Ничек җаннары түзә? Ничек йөрәкләре әрнеми? Ничек ертылмыйлар боларны күреп? Гарьләнеп үләрлек бит, валлаһи! Ислам дине адәм балаларының рухи хәяте дә, тышкы дөньясы да, күңел халәте дә саф вә пакь булуны таләп итә. Бу пычрак өемнәр якты дөньяга, инсаниятнең ак йөзенә, хәтта ки гарше көрсинең үзенә кара сөрем җибәреп тора лабаса. Гыйрфан мулла да мөдәррис булды бит. Тазалык — сәламәтлек нигезе, дигән иманга тугрылыклы булдылар. Ихата кардан әрчелү белән, бөтен чүп-чарны түгеп, тирә-якны ялт иттерәләр иде. Мәдрәсә эчендә тәмле исләр генә аңкып торыр иде. Ун-унике ел шушы чүп-чар арасында чиләнгән мескеннән адәм рәтле нинди диндар, зыялы бәндә чыксын ди дөнья күзенә. Бу бит кешедән, якты дөньядан, милләтеңнән, хәтта ки Аллаһнан көлү дигән сүз. Иренчәклеккә йөз тоткан бәндәнең шайтан алдында калтырап шүрәле кеби булуын аңламыймы болар? Зур гөнаһ бу. Гарьлек. Нәҗеслек.

Инде беренче каты җиргә сеңгән таш мәдрәсәсен күр. Ташка үлчим. Таш араларына яшькелт мүк, күгәргән мәшкә, тагын да әллә ниләр сыланган. Сытык йөзле туксан яшьлек картны хәтерләтеп тора.

Шакирҗан әтисенең кешегә үтә җитди, таләпчән, сынау күзе белән караганлыгын яхшы белә; шулай да әткәсенең бер дә юкка юньсезлек кылмаганлыгын да аңлый. Әле менә

чыраен сытып, кашын җыерып, күңелсезләнеп карап торуы тикмәгә генә түгел: мондагы чүп өемнәре аның саруын кайната. Бу күренеш Шакирҗанның үзен дә гаҗәпләндерде. «Хөсәения»дә мәдрәсәнең эчен, тышын тазартып таралыштылар бит. Нигә монда ашыкмыйлар? Матур яз мондый пычраклык белән килешми ич.

Гыйрфан мулла:

— Тфү!.. Эт бәйләсәң дә торырлык түгел бит монда,— диде дә атлап китте.

Шакирҗан аннан калмаска тырышты. Күпме генә ачуы килсә дә, фикерен «эт» сүзенә бәйләп аңлатуны көтмәгән иде ул. Ничек кенә булмасын, әтисе хәзер үзен һич кенә дә яраланган коточкыч җанвардан ким тотмый. Аны Галимҗан язмышы шулай тотнаклылык чылбырыннан ычкындырганлыкны, җенләнү дәрәҗәсенә җиткергәнлекне аңлый ул. Хәзер Шакирҗанның бөтен курыкканы шул: килеп керү белән кеше арасында Галимҗанны сугып җибәрмәсә ярар иде. Кан кызганда, җан да кыза, диләр бит. Җаны кызган бәндә аны-моны уйламый, ни кылганын да белми.

Йөзенә, тән күзәнәкләренә, бөтен күңеленә әллә нинди нәҗес нәмәкәйләр үскән туксан яшьлек картның эчке дөньясы да саф-пакь түгел икән. Килеп керү белән аларны шундый ук чүп өемнәре, сасыган сулы ләгән, шалкан чәчәрдәй пычрак идән, тегендә-монда аунап яткан каткан киемнәр, комганнар, чүмечләр каршы алды.

Гыйрфан мулла хәзер боларга игътибар итмәскә тырышты. Хәтта башына шундый уй килде: саф күңелле, ачык йөзле, пакь вә ак куллы остабикәсе пешергән ризыкларны бу пычрак җирдә ашап утыру гөнаһ булыр. Иң муафыйклысы шул: Галимҗанны алырга да тизрәк таярга моннан. Чәй эчәр урын бетмәс әле. Ходай җан биргәнгә юнь биргән. Бу — хакыйкать. Хакыйкатькә, кем әйтмешли, хөкем юк.

Ул, кызу-кызу атлап, Галимҗан бүлмәсенә үтте. Ләкин анда Галимҗан юк иде. Утыз яшьләр чамалы бер кемсә басып тора. Аның хәлфә икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Бүлмәләрне тикшереп, караштырып йөридер. Әле монда да шәкертләр китеп бетмәгән. Күрше бүлмәләрдә көлешкән, бәхәсләшкән тавышлар да ишетелә. Галимҗан да, бәлки, шулар арасында буталып йөридер. Озын буйлы, ач яңаклы, соргылт күзле бу кемсә — Зарф хәлфә иде. Алар арасында шундыйрак сөйләшү булып алды:

— Сез хәлфә буласыз шикелле?

— Әйе, Зарф хәлфә булам.

— Минем улым Галимҗан кая китте икән?

— Улыгыз Галимҗан юк инде.

— Ничек инде ул юк?

— Юк нәрсә юк була. Мантыйк...
— Ул сезнең чыбыкны сындырган икән?
— Күрәм: сез аның атасы буласыгыз?
— Әйе, атасы.
— Галимҗан юк инде, кабатлап әйтәм.
— Аңлыйм, сез миңа ачулы. Шулай да Галимҗан...
— Галимҗан качты.
— Качты?
— Әйе. Качты. Җирдә дә юк, күктә дә...

## *Бишенче бүлек*

Килә шатлык булып бу дөньяга бала.
Бөтен җиһан аны сөенеп каршы ала;
Ярты гомерен бирә һәр балага ана,
Нигә бала аны кайгыларга сала?

*Ана зары*

### I

Ярсу йөрәкле чибәр кыздай елмаеп-көлеп, алсу таңнарын балкыта-балкыта, юмарт-мул кояш нурлары белән бөтен тирә-якны иркәләп-сөеп, сүнгән йөрәкләрдә яшәү дәрте кабыза-кабыза, менә тагын да бер яз килде. Басу-кырлар өстенә ап-ак йомшак мамыктай түшәлгән карлар эреп, аның сулары Җир-ананың йөрәге-бавырына шифа булып сеңде. Урамнарда шаулап аккан гөрләвекләр җылы яз күкрәгеннән кайнап чыккан мең төрле көй яңгыратып торды. Аларга сыерчыклар, сандугачлар моңы килеп кушыла да үзенчә бер гаҗәеп нида-симфония хасил итә. Ләйсән яңгыр явып, кояшның җылы нурлары белән парланып-иркәләнеп иркен тын алгач, җир сабый бала кебек шатланып-куанып калды. Аны гүя оҗмахтагы кәүсәр суы белән юдылар.

Мондый чакта Гыйрфан мулланың йөрәге чабышка әзерләгән тулпарныкыннан ким ярсымый. Сабаны, тырмасы, чәчү тубалы...— бөтен кирәк-ярагы әзерләнеп куелган була. Җитмәсә, аны әле кырыкмаса-кырык якка тарткалап җәфалыйлар. Берсе чәчү орлыгы сорый, икенчесе — сабан, өченчесе — ат, дүртенчесе — тырма. Тормыш бит борының белән боз ярып, тешеңне кысып, уртыңны чәйнәп булса да алга барырга куша. Түбә сайгагына төкереп ятып, песи шикелле көне-төне йокы симертеп яшәп буламы? Итәгенә ут төртсәң дә ыжламый бәгъзе берсе. Ишәкне алтынга урасаң да, ишәк булып калган кебек, кабыргасын очлы без белән төткәләсәң

дә, ялкау ялкау булып кала, илаһым! Бу нинди мәнсезлек? Бу ниткән иҗтиһадсызлык? Кайчан күзе ачылыр безнең крестьянның? Кайчан яшәргә өйрәнер?.. Хәят түгел бу! Яшәү түгел бу! Йокымсырау. Мәлҗү. Мәмрәү. Гарьлек. Дөньяны шулай матурлап буламы? Ни калдырабыз киләчәк буынга? Бездә, караңгыда гөл үстереп буламы? Булмый. Баз кебек өйдә тончыккан баладан ни көтмәк кирәк? Кырмыскалар көн-төн хәрәкәттә. Бал кортлары. Кошлар. Ходай Тәгалә һәрберсенә эшләп ашарга куша.

Җитмәсә, «Гыйрфан мулланың җире яхшы», «аңа Ходай Тәгалә үзе ярдәмгә килә», «аның авызы бәхетле» кебек сүзләр канат җәеп таралган авылда. Бәхет әйтерсең борчак чүмәләсе, алдыңа китерәләр дә өяләр. Һм, тот капчыгыңны. Өйделәр ди.

Гыйрфан мулла үз җирләрен дүрт төргә бүлеп карый. Беренчесе — кара туфрак. Икенчесе — каралыгы уңа башлаган. Өченчесе — катнаш. Дүртенчесе — уңдырышсыз кызгылт балчык. Шул түбән сыйфатлы урыннарда да күпереп торган бодай үстерә ул хәзер. Һәр кишәрлек җир тиешле тирәнлектә сөрүне таләп итә. Сабанны шуңа яраклаштырып көйләргә кирәк. Мәсьәләне ул гына да хәл итми әле. Җирең гәрчә яхшы сөрелгән, менә дигән итеп тырмаланган булса да, елы әйбәт кенә килсә дә, орлыгың гәрәбәне хәтерләтеп тормаса, көзен бура төбеңнең ыңгырашканын көт тә тор. «Ашлаган җир аш бирә!» — дип, бик борынгы ата-бабаларыбыз да әйткән. Һәр бөртекне тирес белән сыйлап, тукландырып торырга кирәк җирне. Иген игү бөек бер сәнгать ул! Тирән сер, илаһи бөеклек. Аны әле иң әүвәл акылыңда, уй казаныңда, йөрәгеңдә, күңелеңдә, хис-тойгыңда үстерәсең. Бик борынгы заманнарда ук әйткән бит бер алтын баш:

Ирләр зарлана җирләр яман, дип,
Җирләр зарлана ирләр надан, дип, —

дигән.

Менә терәкә! Каты әйткән бит. Чатнатып. Надан башка нишләп җир буйсынсын, ди. Атабыз Адәмне, анабыз Хаваны яраткан җир бит ул. 930 ел яшәгән атабыз Адәм галәйһиссәлам. Әллә аңа җиңел булганмы? Эшне тырышып эшлә, дөнья авызлыгын вакытында нык тешлә, дигән сүзләрне әтисе дә, картәтие дә даими рәвештә тугылап тора иде. Авызлык җитми күпләргә. Авызлык. Авызлыклап алгач, чыбыркыларга да кирәктер әле.

Мисалга әллә кая китәсе түгел. Әнә Хәмәтдин карт. Басуы янәшәдә. Бәрхеттәй елкылдап торган кап-кара җир. Ни сөрүе, ни чәчүе, ни тырмалавы, ни утарының рәте юк. Мыскыл итә җирне. Көлә җирдән. Каһкаһә көлә. Аннан алаптай авызын ерып, черегән тешләрен ыржайтып, эчкә баткан нур-

сыз соры күзләрен тоздай итеп карап тора-тора да синең игенеңә: «Ходай Тәгалә ашлыкны да кешесенә карап кына бирә», — дип үрсәләнә. Җитмәсә, оятын олтырак итеп, чәчү орлыгы сорап килгән. «Монысы соңгысы, башка вакытта мазасызламам, Мөбахис мәзингә бара алмыйм бит мин, ул комсыздан кышын кар сорап та алып булмый», — дип юмакайлана. Шул җитте бит Хөрмәтулла башына. Шул Хәмәтдин җаһил җитте. Имеш, борынына ит исе килеп бәрелгән. Хөрмәтулла Мөбахис мәзиннең сарыгын суеп ашаган. Шул әләкләмәсә, Хөрмәтулла тукмалмый иде. Шул кыйналудан соң сәламәтләнмәде бит Хөрмәтулла. Кан коса икән. Үлем түшәгенә яткан, ди. Шуларны уйлап, куып кына чыгарасы иде дә бит ул Хәмәтдин дигән хәсисне. Юк, булмый. Әлеге: «Таш белән атканга аш белән ат», — дигән борынгылар сүзе канга сеңгән. Аңларлар, дисең. Балалары ач калмасын, дисең. Өлге-үрнәк алсыннар, дисең. Юк. Юк булгач — юк. Зилзилә гарасаты белән дә кузгата торган түгел. Мүкләнгән таш. Тутыккан тимер.

Әллә нинди акыллы башлар әйткән сүзләрне әлеге гамәл дәфтәренә язып та куйган иде бит: «Яхшы игенче — кешелек хәятенең беренче игелек иясе»; «Игенче — бөек кеше»; «Ипи валчыгы ат башы кадәр алтыннан да авыррак»; «Икмәк — тормыш ул, ана кебек...»

Троицк мәдрәсәсеннән хәлфәлекне ташлап кайтуы да иген игү сәнгатен үзләштерү өчен бит инде. Быелгы яз да шул хис-тойгылар давылы эчендә үтте. Биш вакыт намаз. Йокысыз төннәр. Борчулы көннәр. Җирнең җылы куенына гәрәбәдәй орлыкларны салып калдыру өчен җан ату. Ходайга шөкер, бөтенесе дә ал да гөл булды шикелле. Инде чәчүләр бетте. Матур гына итеп, яңгырлар явып үтте. Җир суга туенды. Ел яхшы килер кебек. Алда — сабан туе. Ат чабыштыру.

Тик... нигә бу «бәхет» дигән илаһилыкның бер як чите гелән генә китек була? Шул китекне, кем әйтмешли, уртыңны чәйни-чәйни, тешләреңне алагаем кыса-кыса, йөрәк бәгыреңне мең тапкыр әрнетеп, ямап куясың. «Инде булды» дип, күз кабагың ачылып, үткән эшкә тәһарәт алып, дога кылакыла салават әйтеп, амин тотасың, әмма янә дә алданган буласың: бәхет казаныңның янә дә икенче бер урыны тишелгән булып чыга — тагын да ямарга кирәк. Галимҗанның — киләчәктә нәсел-нәсәп тамырыннан алтын кәүсә-багана утыртырга тиешле Таш маңгаеның — җир упкандай юк булуы бәхет казанының тишелүе генә түгел, шартлап ярылуы — күңелсез хәл. Уф, ни гөнаһлары бар икән? Нигә Ходай бу тиклем рәнҗетә аны? Әгәр кирәк булса, булдыра алса, коры

җәйдә кеше игененә яңгыр булып явар иде; яки яңгырлар шәйсез күпкә китсә, биниһая зур канатлы сәмруг кошка әверелеп, күктәге болытларны таратып йөрер иде, вә дәхи дә күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы төннәрдә илаһи бер нур булып, кәрван юлын яктыртып торыр иде. «Яраткан бәндәсен Ходай төрлечә сыный», — дигәне дә бар. Әллә шуның бер галәмәтеме бу?

Хәлбуки, бу кичерешләрне, йөрәк януларны, бәгырь телгәләнүне остабикәсенә сиздермәскә тырышты ул. Чөнки аз гына караш катылыгын йомшартсаң, теле белән чеметкәләргә тотына. «Холыксыз ир тормыш яме ала, хатыны йөрәгенә яра сала», — дип ычкындырды беркөн. Дөрес, аны ул аңа төбәп түгел, икенче бер холыксыз иргә карата әйтте. Шулай да тел төбенең үзенә барганлыгын аңлады мулла абзый. Әйтсен анысы. Моңа бер тарлык та юк. Ирләр хатын-кызның лачкылдатып сагыз чәйнәвенә түгел, акыллы сүзенә мохтаҗ. Адәм иткән дә хатын, әрәм иткән дә хатын, дигәне дә бар. Шулай да беркөн Нәгыймәне күзләргә Бәгәнәш авылы мулласын остабикәсенең ошатмавы аның күңеленә берникадәр кырпак кар төшерде. Ике арада кырач җиле — сырт җиле исеп алды. Остабикәсенең әйтүенчә, юньле адәми зат булса, ул Бәгәнәш мулласы Хафиз хәзрәт утыз бишкә җиткәнче өйләнми йөрмәс иде. Имештер, тыштан күренеп, күзгә бәрелеп тормаса да, аның эчке хосусиятендә кылдый-былдый, кәкре-бөкре, кытыршы-мытыршы яклары бардыр. Булса соң? Адәм баласының берсе дә хатадан хали түгел. Берәүне дә корычтан коеп куймаганнар. Иң әүвәл аның кешелекле булуы кирәк. Монысы — йөрәк иманы. Калганнары — шул иманны яктыртучы нурлы йолдызлар. Хафиз муллада ул иман бар. Монысы бер булдымы? Бер булды. Соңгы вакытта муллаларның әлеге каһәр төшкән «зәмзәм суы» белән авыз пычратулары шәйләнә башлады. Хафиз муллада андый гадәт аслан юк. Ике булдымы? Ике булды.

Битендә азрак шадрасы бар икән, аңа карап кына кешене түбәнсетергә ярыймы соң? Шадра — йөрәк яндыра, диләр ич. Яндырыр әле. Бардыр эчендә яндыра торган галәмәте. Әллә Мөхәммәт пәйгамбәрдән соң килгән Әбүбәкер, Гомер, Госман, Гали кебек хәлифәләрнең «китек» ягы булмаганмы? Булган. Тормыш һәммәсен дә акрынлап төзәтә — ямый бара.

Остабикәсенең йөзендә ык-мык итү чаткылары сизелгәч, ым кагып, тышка алып чыгып китте ул булачак киявен. Абзарга барып, кул кысыштылар да куйдылар. Шуның белән вәссәлам. Бетте-китте. Бу җитди мәсьәлә соңгы ноктасына җитте. Нәгыймәгә кияүне ныклап күрсәтмәделәр дә: кәҗәләве бар — соңгы вакытта кызлар «мәхәббәт» дип авыз суы

түгә башлады. Әнисе дә хәтта бер арада үз гамәл дәфтәренең бер сәхифәсенә язганын укып күрсәтте: «Мәхәббәт — бик нәзберек үсемлек сыман, әгәр аны һаман күз яшьләре белән сугарсаң, беркайчан да озак яши алмый». Кем сүзләредер — монысы ата кеше өчен караңгы. Шундый мәгънәле, матур, күркәм сүзләрне остабикәсенең язып куя торган гадәте бар. Хәер, аның үз теленнән дә гәүһәр тама. Җыр чыгара. Шигырьләр яза. Вакыт-вакыт моң дәрьясында йөзә. Үз сүзләредер, бәлки.

Бу сүзләрне дә башта үз йөрәгенә алды ата кеше. Хәтта ачыктан-ачык әйтте:

— Тормыш булгач, табак-савыт шалтырамый тормый, анасы, күз яшьләре дә чыккалый, әмма безнең «гыйшык-мыйшык» дигәнебез һич тә син уйлаганча түгел лә инде,— диде ул.

Абыстай мәсьәләне ныклабрак аңлатып бирде:

— Син барысын да үз күңел сандыгыңа гына җыя барма әле, атасы, без яратышып кавыштык, Аллага шөкер, моңа бер Ходай үзе шаһит; мин бу сүзләрне Нәгыймә язмышы өчен борчылып әйтәм; үзеңә мәгълүм ич: ул да минем кебек нечкә күңелле, йомшак табигатьле, артык итагатьле...

— Хатын-кызга каты күңелллелек әллә килешәме? Әмирҗан әнә хатынын ни өчен изә? Каты телле булганга. Әле кичә генә аяк-кулларын сындырып бетергән.

— Әмирҗан үзе кем соң? «Чупай ябалагы» дигән даны бар. Теле каты булса да, хатыны Оркыяның күңеле йомшак аның. Шуны аңлыймы соң ул Чупай ябалагы?

Ничек кенә булмасын, туй кебек зур мәшәкать тә шаулап-гөрләп, җилләнеп-давылланып, ызгыш-мызгыш белән, тирә-якка дан чәчеп үтеп китте. Гореф-гадәттәгечә, кода-кодагыйлашу, ике яктан да кунаклашу, атлар, сыерлар, тәкәләр сую — берсе дә калмады. Кардәш-ыру, туган-тумача, дус-иш, күрше-күлән сыйланып рәхәтләнде. Башкорт дуслар Котлызаман, Көнсылу, чуаш дуслар Әптерәй, Кәтринә, тагы да әллә кемнәр, әллә кемнәр туй шатлыгы кичерде. Хәзер инде Нәгыймә мулла куенында. Рәхәт яшәсеннәр. Бәхетле булсыннар. Ходай олы мәхәббәт бирсен. Әмма Нәгыймәнең мулласына уналты мәхәббәт җимеше — уналты бала бүләк итәчәген әле берәү дә белми. Бу яктан ул җиде буында булмаган дәрәҗәгә ирешә. Менә нәсел-нәсәпнең тамырлары ничек үрчи. Кем әйтмешли, мыжылдашып тора. Нәгыймәнең соңгы баладан соң дөнья куячагы хакында да берәүнең дә ике ятып бер төшенә дә керми иде әле. Ни бу? Язмыш җилләренең кире яктан исүеме? Анысы инде аның бер Ходайга гына мәгълүм.

## II

Көннәрдән бер көнне Галимҗан кайтып керде. Берүзе генә түгел — бүлмәдәше Йосыф мәхдүм белән. Кичкә таба иде бу. Кояш, бөтен дөньяны яз сулышы белән хозурларга-сөендерергә теләгәндәй, гүя, баесам, шифалы нурларымнан мәхрүм булырсыз дип, күк читенә-офыкка ашыкмый гына хәрәкәт итә. Хәер, аның хәрәкәте дә аслан сизелми. Ул, әйтерсең, туктап калып, һәркемне күзли, сынаулы күз карашлары белән аңа мөкиббән китеп карап тора: дус булыйк, дөньяны бергәләп ямьлик, ди. Кояш дөрес уйлый: якты йөз-чырай белән караса, кешеләр күңеле аяз-күтәренке була, болыт белән капланса, адәм балаларының йөрәгендә кара йомгак хасил була, шунлыктан ул боегып кала.

Кояш бүген берәүне дә боектырмаска тырышты. Аның көләч йөзен каплардай болытның әсәре дә булмады. Гыйрфан мулланың зур-зур тәрәзәләреннән пөхтә өй эченә үтеп кергән кояш нурлары да гүя һәр гаилә әгъзасына яшәү хозурлыгы, күңел илаһилыгы, бәхет-сәгадәт гәүһәрләре өләшә иде. Галимҗанның суга төшкән балтадай юк булу кайгысы һәрберсенең җилкәсенә кара көйгән тау булып өелсә дә, һаман шулай бер килеш йөрәк сызлануы белән яшәү мөмкин түгел иде.

Газапны Ходай башта тауга биргән — күтәрә алмаган: биле сыгылып, чүккән, җиргә убылган, урынында су хасил булган. Әгәр бу дәвам итсә, дөньяны су басар иде. Шуннан кайгыны Аллаһы Тәгалә адәм баласына биргән. Күтәрә адәм баласы. Чыдый. Түзә. Бөгелми. Дөньяның рәхәтеннән михнәте күбрәк, дигәне дә бар. Шул хакта уйланды Гыйрфан мулла. Аннан соң һәр килгән кайгы өчен утка бастырылган шайтан урынына үрсәләнүне шәригать тә мактамый бит әле. Бу — кешелеклегеңне тәмам югалту дигән сүз. Ахыр чиктә ул адәм баласын гөнаһ сазлыгына өстери, иманга хилафлык китерә. Аллаһы Тәгалә каршында булган саф вөҗданыңа кара күләгә төшерә. Остабикәсенә дә «баланы син боздың», «иркәлек һәркемне ирәйтә», «иркә бала итәк ерта» кебек төшенчәләрне аңлата торган бозлы караш ташлаудан тукталырга тырышты. Вакыт-вакыт эчтән кара көйсә дә, тыштан ялтырауны максат итте. Гаилә башлыгы күңелендәге кара төернең хәләл җефетенә вә балалар күңеленә күчү хакыйкатен белә ич ул. Күчте дә инде. Остабикәсенең бөтен хәяткә, табигатькә, инсаниятә сөеп карый торган күз карашлары мәзәкләнеп-зәгыйфьләнеп калды. Көләч йөзенә хәсрәт пәрдәсе тартылды. Сөйләшкәндә, матур иреннәре вакыт-вакыт

көзге яфрак шикелле дерелдәп тора. Кипте. Ябыкты. Корыды. Хәзер инде ул әйтерсең балык сеңере. Әлбәттә, аның да эчтәге утны тышка чыгармаска, йотарга, йөрәгендә калдырырга тырышуы сизелеп тора. Ул гына да түгел, ул бит әле сине дә кайгыга баш имәскә, арыш боламыгыдай мәлҗемәскә, йөрәк януын кешегә сиздермәскә өнди. Чын мәгънәсендә алиһә инде!

Шундый хисләр дулкыны эчендә тибрәнеп йөрде ул бүген. Бу дулкын-хисләр көне буе баш очында елмаеп, адәм балаларына сәҗдә кылып торучы кояш нурлары дулкыны белән аралашып, аның күңел дөньясына яктылык хозурлыгы өстәде. Нәгыйммәнең шушы бүгенге яз кояшы кебек балкып килеп керүе өй эчендә капылт-кинәт икенче бер кояшның пәйда булуын хәтерләтте. Дөрес, әле ул үзе генә килгән. Мулласының шөгыле бар икән. Шуңа килә алмаган. Әйткән Нәгыймә моңа: «Ак калфагымны алырга оныткანмын, иртәгә ашка шуны киеп барырмын дигән идем, ерак ара түгел бит, байталыңны җигик тә тиз генә барып киликче, әткәй-әнкәйне мәшәкатьләп, чәй-фәлән дә эчеп тормабыз»,— дигән. Әйткән моңа мулласы: «Мине бит бер бабайга ясин чыгарга чакырдылар, тарантаска байталны җигәм дә теге син ошаткан терекөмештәй тере кучерны утыртып, юлыгызга ак җәймә җәеп озатып калам»,— дигән.

Килеп керү белән Нәгыймә, ашыга-ашыга, шул хакта сайрап салды да кучер малайның әле аты белән капка төбендә калуын әйтте. Ата-ана моңа ифрат шат иде. Ир кеше хатынын ялгыз килеш бер җиргә дә җибәрми. Имеш, шәригать кушмый. Аннан соң, арбаның төбе юк, Алланың кеме юк дигәндәй, ялгыз йөри торган хатын турындагы берәүнең гайбәте бик тиз урам авызына күчә. Бозык авызлар «ул хатын фәлән дә төгән», «ирле ирдәүкә», «иргә баш бирә торган түгел» кебек гайбәтне, чүбек чәйнәп май чыкмаганлыкны белсәләр дә, мәңге өзелмәс сагыз урынына чыртлатып чәйни бирәләр. Бу — хатын-кызга ышанмау бәласе. Хәләл җефетеңне арыш капчыгына тыгып, авызын чабата киндерәсе белән алагаем кысып бәйләп яшәтергә тырышу галәмәте.

Гыйрфан мулла, Ходай үзе шаһит, нинди генә җитешмәгән-килмәгән яклары булмасын, җир алиһәләрен алай читлектә яшәтү кебек күңелсез хәл белән килешә алмый. Хәсәнә абыстай да ата кешенең бу күркәм сыйфатлары өчен мең-мең шөкрана итеп яши. Кияүләре Хафиз мулланың да ахмак күңелле ирләр арбасына утыра торган зат булмау табигате аларның күңелләрен җиде кат күккә күтәреп җибәрде. Әлбәттә, ата-ана Нәгыймәгә бу хакта әйтмәде. Артык сүз — аркага аркан дигәндәй, бу хакта гәп кузгату баш әйләндерү

генә булыр иде. Нәгыймәнең елмаеп-көлеп килеп керүе, әтиәнисен кочаклап алуы, Габделхәкимне кысып-кысып сөюе, күз карашларының ягымлылыгы, ап-ак йөзенең шатлык тойгылары бөркеп торуы...— барысы аның тарантаска утырып түгел, бәхет арбасына утырып йөрүе турында сөйли иде.

Бөтен гаилә шундый шатлыклы хис-тойгылар дулкыны эчендә сәгадәтле минутлар кичергән мәлдә, Галимҗанның ниндидер тәти егет белән бергә кайтып керүе янә бер кояшның балкуы кебек тоелды.

Килеп кергәч тә, иң әүвәл, Йосыф мәхдүм йомшак, моңлы тавышы белән «Әссәламегаләйкем!» диде. Гыйрфан мулла күрешү шатлыгын йөзенә ул кадәр чыгармаска тырышып, ата горурлыгын саклаган хәлдә, җиңелчә генә тамак кырып, «Вәгаләйкемәссәлам!»не әйтте. Аннан соң, тораташтай катып, сүзсез генә бер-берсенә карашып калдылар. Галимҗанның эчен курку шайтаны тырный иде: әтисенең, котырган үгездәй ташланып, йә сугып җибәрүе, йә тел камчысы белән теткәләве бар — кеше алдында бу һич тә килешә торган эш түгел. Шулай да Галимҗан, булачак давыл-гарасат алдында нык торырга кирәклекне аңлап, каушап-җебеп калмады, йөзенә курку галәмәтенең мыскалын да чыгармаска тырышты. Әткәсенең йомшак җилекле кешене, мәмәй авызны, куян йөрәклеләрне яратмавын белә ич ул. Мескен белән киңәшмә, дигән сүзләре дә хәтерендә.

Дөрес, сөзешергә әзерләнгән үгезләрдәй карашып тору озакка бармады. Киметеп әйтсәк, чыпчык канат каккан вакыт та үтмәгәндер. Авыр тынлык, эссе кояш нурында тиз таралган сыек болыттай, ә дигәнче юк булды. Ул болытны таратучы Ана-Алиһә иде.

— И балам! Галимҗаным!..— дип, шул йөрәк канына манчылып чыккан ике сүз аша күңел яраларын, әрнү-өзгәләнүләрен аңлатып, улын килеп кочаклагач, бер-берсенең күз карашларын бәйләп торган авырлык җебе кинәт кенә үткер кылыч белән тураклап ташлангандай булды. Галимҗанны сабый чагындагыдай кысып-кысып сөеп, бит очларыннан чүтчүт үбеп алгач, ананың күзләре яшькә тыгылды. Елап җибәрмәскә бөтен көче белән тырышты ул. Чит кеше алдында, бала каршында ярамый, килешми. Шулай да, башкалар исәнлек-саулык сорашып күрешкәндә, аның сабыр ихтыярына һич буйсынмыйча, йөрәк итен ярып чыгып, керфек очына эленгән әрсез гәүһәр күз яшен яулык чите белән тиз генә сөртеп алырга онытмады ул.

Бу авыр очрашу ата кешене дә нык тетрәндерде. Ни эшләргә, шанлап җибәрергәме, кем әйтмешли, эттән алып эткә салып сүгәргәме? Ярамый. Ни өчен? Беренчедән, чит ке-

ше бар; икенчедән, бу күренеш әнкәсенең йөрәген шартлатырга мөмкин; өченчедән, балалар алдында килешми; дүртенчедән, таш маңгайга сугып, үз йодрыгыңның челпәрәмә килүе ихтимал. Соңыннан сайрашырлар, барысы да ачыкланыр. Ә хәзергә илтифатлылык саклау хәерле булыр.

— Нихәл, улым, исән-аман гына йөреп кайттыңмы? — дип килеп күреште ул, эчтә котырынган ачу өермәсен тышка чыгармаска тырышып. Кыскасы, хәзергә ике арада бернинди шайтан тавы булмаганлыкны аңлатуны мәслихәт күрде. Шулай да күрешкәндә, күзенең бер як чите белән генә булса да, аның өчен эчендә боз барлыкны сиздерми калмады. Яраткан атлы булып аркасыннан сыйпаганда да, элекке кебек, аталык хисе җылылыгы тоелмады. Моның күңел өчен генә икәнлекне юләр дә аңларлык.

Галимҗан зур җәнҗал-буран көткән иде. Хәзергә буранның дәррәү купмавы, тиз арада кадер кичәсе көнендәгедәй тынычлык урнашуы аның күңелен күтәреп җибәрде. Гаилә җылылыгын хәзергә, тышкы яктан гына булса да, күрсәтеп тору Йосыф абыйсы алдында аеруча кирәк иде. Шундый авыр минутларны үткәреп җибәргәч, ул күзләре белән ашардай булып карап торган Нәгыймә апасы белән барып күреште. Аннан энесе Габделхәкимне барып сөйде. Йосыф мәхдүмне дә һәммәсе белән күрештереп чыкты. Шуннан соң Хәсәнә абыстай:

— Син юкта бик изге эшләр дә булып алды, Галимҗан улым, Нәгыймә апаңны Бәгәнәш мулласына бирдек; бик затлы нәсел мәгәр, үзебез кебек тамырлы кешеләр, — дигәч, өй эчендә янә шатлык хисе канат җәйде.

Хәзер инде бер-берсенә булган карашлары язгы җылы агымны хәтерләтә иде. Инде табын әзерләп, күгәрчендәй гөрләшә-гөрләшә, кичке ашка чаклы җыйнаулашып чәйләп аласы гына калды.

— Нәгыймә кызым, син ашыкма әле, табын әзерләш... — дип, Хәсәнә абыстай, элеккечә, яшь кызлар кебек, җиңел хәрәкәтләнеп, үзенең хәзергә чыгып торуын белдерде. Галимҗан белән кунакка берәр бүлмәдә ял итеп торырга кушты. Ләкин Нәгыймә кайтып китәргә кирәклекне әйтте:

— Мин, әнкәй, аңа икенде намазына кайтып җитәргә вәгъдә биргән идем, юл кешесенең юлда булуы хәерле, чәйләп тормыйбыз инде, ерак ара түгел бит, йә үзегезне чакырырбыз, йә үзебез килеп җитәрбез, җизнәсенең Галимҗанны күрәсе бик килә, — диде.

— Кучерың ач түгелме?

— Түгел, әнкәй, түгел. Кайткач, сыйлармын әле...

* * *

Хәсәнә абыстай өстәл әзерләү мәшәкатенә күмелде. Нәгыймә хушлашып чыгып китте. Аңа Галимҗан да иярде.

Галимҗан өчен Нәгыймә апа гына түгел, сердәш тә, дус та иде. Хәер, башка гаиләләрдә дә ир бала белән кыз бала күбрәк дуслашучан. Бәлки, табигатьтәге шушы яшерен серлелек чаткылары алар йөрәгенә дә тәэсир иткәндер. Шакирҗан абыйсы белән тарткалашкач, сүзгә килгән, хәтта якалашкан чаклары да була. Ә инде Нәгыймә апасы белән аның арасында беркайчан да сырт җиле исмәде. Нәгыймә апасы — әнисе табигатьле. Берәр сер сөйләсәң, аны йөрәге белән кабул итә. Ачуланырга тиеш булганда да, төсен бозмый, авыр сүз әйтми, үзен зурга куеп масаймый. Теге вакытта Мәдинә белән булган хәлне дә бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде. Аның җырын, моңын мактады, үзен «Акчәчкә» дип атавын әйтте. Бу яңалык Нәгыймә өчен көтелмәгән хәл иде. Шуңа күрә ул аңа һич тә битараф калмады. Уйланып торды-торды да:

— Синең борыныңа ис керә башлаган, кара аны, малай, сак бул, уйлап эш ит, андый нәрсә белән уйнамыйлар, — диде.

Галимҗанның шаярта торган гадәте дә бар. Бу юлы да уйнап-көлеп җавап бирде:

— Акчәчәкне ярату язык түгел, минем күзем шайтан таягына төшмәгән бит әле.

Әле дә менә, чыгу белән, шаярып сөйләшүгә күчте:

— Син, Нәгыймә түткәй, тагын да матурланып киткәнсең, җизнинең кочагы бик кайнармы әллә?

— И хәчтрүш, тапкан сүз, әллә кайда йөреп, бозылып кайткан. Кайда булдың?

— Анысын аңламассың. Башка вакытта сөйләрмен.

— Күрдеңме әнкәйне? Кипкән таяк булып калды бит. Синең кайгың шулай итте аны. Әткәйнең сакалын кара. Син агартып бетердең аны. Җитмәсә, шаярып маташа. Әле синең зур киләчәгең алда. Укыйсың, кеше буласың бар. Шуны бел: ата-ананы рәнҗетеп, ата-ана фатихасы алмаган бала бәхетле булмый ул.

— Син телә бәхетне.

— Чыбыкларга кирәк сине. Колагыңны борырга...

Нәгыймә капкага таба китте. Чөнки әйләнеп кенә чыгасы булгач, атны алар ихатага да кертеп тормаган иде.

Галимҗан апасыннан калмады. Үз өйләренә якынлашканда ук ул капка төбендә җигүле ат һәм ун-унике яшьләр чамалы кучер малайны күргән иде. Димәк, ат аларныкы булып чыкты.

Ян капкадан чыккач, Нәгыймә тарантаска менеп утыр-

ды. Кучер малайның дилбегәне кагуы булды, ат җил җитезлеге белән кайтыр якка очты. Артта тузан болыты күтәрелде. Галимҗан, алар күздән юк булганчы, карап торды.

## III

Чәй табынында сүз ул кадәр куермады. Хәсәнә абыстай ясап тора — тегеләр эчеп тора. Ата кеше улының Йосыф мәхдүм белән кайтып керүенә шат иде. Чөнки Ырынбурда Галимҗанның ниндидер өлкәнрәк шәкерт белән бер бүлмәгә урнаштыруын үтенгәч, Вәли мулла шушы Йосыф шәкертне китереп күрсәткән иде. Йосыф тышкы кыяфәте, җылы-ягымлы күз карашы, матур сөйләшүе, инсафлылыгы белән билгән иде аның күңелен. Мәдрәсәдә уку беткәч, үзләре әйтмәсә дә, Галимҗанның шушы мәхдүмгә ияреп китүе хакында фараз итте ата кеше. Шуңа күрә, бер-ике чынаяк чәй эчкәч, Гыйрфан мулла сүзне үзе үк башлады.

— Ху-у-ш, шәкертләр, инде мәдрәсәдән качып китеп, кайдадыр югалып йөрүегез хакында сөйләсәгез иде,— диде.— Мин бит башта Шакирҗан янына бардым, аннан Вәли мулла мәдрәсәсеннән сине алып китүдә иде уем, Галимҗан, әмма ләкин анда сезнең арттан җил генә искән...

Җавапны Галимҗанның үзеннән көткән иде ата кеше. Әмма ул уйлаганча килеп чыкмады. Әллә Галимҗанны авыр хәлдән коткару нияте белән, әллә гаиләдә ызгыш-низаг чыкмасын дип уйлап, бу «бәла»не үз өстенә алырга булды Йосыф мәхдүм.

— Бөтен гаеп миндә, Гыйрфан бабай, Галимҗанны үзебезгә кунакка алып китәргә мин өндәдем,— диде ул.

Ләкин сизгер күңелле, дөреслек яратучы, ялганны җене сөймәгән Гыйрфан мулла мәхдүмнең сүзләре белән килешмәде:

— Син, Йосыф улым, теге вакытта ук белгәнемчә, затлы нәселдән, яхшы ата-ана баласы; бәс, шулай булгач, мантыйкта ялгышма, фикерләреңдә салулама; Галимҗан арбага таккан дегет чиләге түгел бит, ул теләсә кемгә тагылып йөрергә тиеш түгел, аның әти-әнисе бар, шулар белән киңәшләшмичә, үз белдеге белән каядыр китеп югалырга аның хакы юк. Аның аркасында мин Шакирҗанның да тиресен күп каезладым, остабикәмне дә аз рәнҗетмәдем.

Шул сүзләрне ишеткәч, өй эчендә авыр тынлык урнашты. Галимҗан әле әнисенә, әле әтисенә карап алды. Бала өчен ата-ананың күпме йокысыз төннәр үткәрүе, әрнүе-сызлануы, башын ташка бәрердәй булып үрсәләнүе турында ишет-

кәне бар аның. Ата-ана рәнҗетүче андый балаларга аның нәфрәте дә чиксез иде. Мин беркайчан да алай булмам, әткәм-әнкәмне кайгыларга салмам, дип эченнән иман әйткән чаклары күп булды. Тик тормышта һич тә син уйлаганча килеп чыкмый икән. Алла шайтаныннан адәм шайтаны яман, дигәнне ишеткәне бар аның. Әллә ул адәм шайтаны котыруына биреләме? Әллә иң абруйлы Йосыф шәкерт тә шайтан булып чыктымы? Алай дисәң, ул гаепле түгел ич. Әлеге мәдрәсәдән куылганын белгәч, кайтып, әти-әнисе, туганнары күзенә күренүнең авырлыгы турында сөйләде ул. Йосыф мәхдүм аның кайгысын үз йөрәгенә алды.

— Алайса, әйдә, Галимҗан, безгә кунакка китик. Мин сине Илеш бабай авылы табигате, аның матур күңелле кешеләре белән таныштырырмын, аннан соң, Солтанморатка килеп, сине ата-анаң кулына тапшырып китәрмен, аңа чаклы үпкә-сапкалары да басылыр,— диде.

Галимҗан шатланып ризалашты. Илеш авылының матурлыгы, Сөн, Агыйдел, Чулман елгаларының гүзәллеге хакында сөйләп, ул Галимҗанның күңелен тәмам ярсыткан иде инде. Галимҗанның шул гүзәллекне күрәсе, шул гүзәллектә иркәләнәсе, шул гүзәллектә хозурланасы килде. Әлбәттә, үз авылының табигате дә оҗмах-җәннәттән ким түгел. Ләкин бит моңача таныш булмаган чит җирләрне күрү — үзе бер яңа дөнья белән ләззәтләнү. Аннан соң Йосыф абыйсы аны пароход белән Казанга алып барачагы, барганда, әлеге Агыйдел белән Чулман кушылган урыннарны күрсәтәчәге, аннан Иделгә барып чыгачаклары турында әйтте. Болары да әле аның ул кадәре әһәмиятле түгел. Иң әһәмиятлесе — алар Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыячак. Вәли мулланың кадим мәдрәсәсе Йосыф мәхдүмне дә канәгатьләндерми икән. Галимҗанның Вәли мәдрәсәсеннән куылуы — зур бәхетсезлек. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга баруы — зур бәхет. Менә бит ничек тора эш. Бәхет, кем әйтмешли, үзе үк сандугач урынына уч төбенә килеп кунарга тора.

Бөтен әйткәннәрен җиренә җиткереп үтәде Йосыф абыйсы. Казанда аның әтисе ягыннан танышлары да бар икән. Әтисе белән туганнан туган агасы Габдрахман хәзрәт Казан шәһәрендәге Акмәчеттә эшли икән. Ул боларны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укытырга вәгъдә бирде. Аларда атна-ун көн кунак булып, Казанның барлык тарихи-истәлекле урыннары белән танышып чыккач, хәтта дарелфөнүн залларында да башта куяндай курка-курка, аннан соң әрләндәй әрсезләнә-әрсезләнә, ахырда бөркеттәй канатлана-канатлана йөреп, вакыт-вакыт төлкедәй иснәнеп, «их, шушындый оҗмах-җәннәт кеби җирдә укырга» дигән татлы хыяллар дулкынында ләз-

зәтләнеп, әмма ул хыялларның кайдадыр җиде кат күк дөньясы артында икәнлеген аңлаган хәлдә, алар пароходка утырып китә, Уфага барып, аннан Солтанморатка юл тоталар.

Табында чәйне чынаяктан акрын гына чөмерә-чөмерә, тәмтомны һич тә кабаланмый, итагатьлелек саклаган хәлдә каба-каба, гәпкә ялкын кушмаска тырышып, сүз шәкертләрнең әнә шул сәфәре хакында барды. Сәфәр турында күбрәк Йосыф мәхдүм сөйләде. Әлбәттә, Гыйрфан мулла вакыт-вакыт үзен энә очында утыргандай хис итте, менә-менә ярсып, кабынып, Галимҗанны дөмбәсләп ташлау чигенә җитте. Андый чакта аның йөзенә чыккан ут ялкынын Хәсәнә абыстайның сабыр карашы салкыны сүндерә. Кеше алдында үзеңне нык тот, кигәвен тешләгән аттай чәбәләнмә, хәзер генә кымырҗып, пычагымны да кыра алмыйсың, ди аның карашы. Бусы — бер. Икенчесе шул: Йосыф мәхдүм бик килештереп, чама белән, сүзенә су да, корым да кушмыйча, матур итеп, тәмләп, мантыйкны эшкә җигеп сөйли. Сүзе — еланны йоклатырлык, үгез котырынуын басарлык, кабарган күркәнең канатларын төшерерлек. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый дигәндәй, Гыйрфан мулла хәзергә аларның тоткан юлына аягын аркылы салмаска булды. Аның үзенеке үткән инде. Үткән гомер — сүнгән күмер, ди. Ялкынланган. Сүнгән. Беткән. Әйдә, болар ялкынлансын. Алтын — утта, адәм михнәттә сынала, дигәне дә бар. Михнәт күрәкүрә чыныксыннар. Утырган таш шикелле мүкләнүдән ни файда? Зынҗырлы аю түгел лә инде алар. Шулай да авыз йомып калмады Гыйрфан мулла. Ул үз фикере тәртәсен теләсә кемнән бордырырга тиешме? Юк. Аслан юк.

— Беркая да китмисез, ашны казанда кайнаттың ни, чүлмәктә кайнаттың ни; кайната белмәсәң, барыбер тәмсез була ул, — диде дә Ырынбурда Вәли мулла белән мәсьәләнең мөгезеннән тотып сөйләшүе, аның якасыннан алагаем эләктереп алуы, шуннан куркып, Галимҗанга укуын дәвам итәргә ризалашуы турында әйтте.

Шулай да Гыйрфан мулла тегеләрнең авызын нык томалауны сүз капкачын тәмам каплауга санамый иде әле. Бу әле аларның уй кылын тартып карау гына. Мондый гадәт әтисендә дә бар иде. Вакыты белән кырт кисә. Давылда чайкалган агач кебек, боргаланырга-сыргаланырга аслан җаең калмый. Әмма ул һич тә җиде уйлап бер кискән фикер түгел икән. Җилегең катымы? Уй-фикерең тишек иләк түгелме? Баскан җиреңдә салулап китмисеңме? Шуларны сынар өчен, кырт кисә икән ул. Бала ялганга ышанса — чүбек баш дигән сүз. Хакыйкатьне аңламаса, аңгыра карга була. Ул, күрәсең, кылыңны төрле яклап тартып карап, һәммә сыйфатыңны сынап, сине билгеле бер низам-тәртип калыбына

сукмак булган. Ат аунаган җирдә төк кала, ата рухыннан балага йөк кала, ди. Нинди йөк? Матди йөк? Рухи йөк? Атаның барлык рухы бөтен күңелеңә сеңешмәсә дә, тән күзәнәкләреңдә, хәтта чәч бөртекләреңдә, күз төпләреңдә яшидер ул. Гыйрфан мулла әле шуларның фәкать берсен — уй голувиятен үстерү үзенчәлеген искә алды. Әйтте. Бетте. Вәссәлам. Хәзер уйлансыннар. Фикерләрендә нык тора алырлармы? Салуламасларммы? Адәм фәрештә булмас, әрекмән кәбестә булмас, ди. Тыштан кояштай ялтыраса да, Йосыф мәхдүмнең эчендә ни барын кем белгән. Нигә әле бала язмышын чит кеше кулына уптым илаһи тапшырып куярга? Янә дә әллә нинди зыян-зәхмәт булмасын кем белә?

Чәй табыны шундыйрак сөйләшүләр, шундыйрак фикер йөртүләр, шундыйрак фараз-мараз итүләр кысасындарак үтте. Дөрес, бу әле самавырны кат-кат бушата-бушата, тир сөртеп юешләнгән тастымал-сөлгене мең мәртәбә сыга-сыга, илаһи бер иркенләп, җәелеп, дөнья мәшәкатьләрен онытып эчә торган чәй түгел иде. Бу әле җиңелчә, юлда тамагы янган ике шәкертнең сусынын бастыру өчен генә әзерләнгән чәй. Аннан соң Гыйрфан мулла Патша әтәчне чалды. Бу әтәчтә мең төрле табигать төсе бар: ак, кызыл, яшел, зәңгәр, сары, кара... Һәр каурыенда — бер төс. Әйтерсең Ходай Тәгалә аның бөтен җиренә болын-дала чәчәкләренең һәммә төсен китергән дә буяган-каплаган. Кикригендә дә гүя гәүһәр бөртекләре җем-җем итеп тора. Муенына асылынган бармак башы зурлык кечкенә шарчык кебек нәмәстәкәйләр дә энҗе-мәрҗән кеби ялтырый. Аһ, аның горурлыгы! Шул мең төрле бизәкләр белән төсләнгән матур башын югары тотып, шундый ук бизәкләр белән чигелгән галәмәт киң түшен генералныкыдай киереп, тавыклар арасында ай-һайлап, үзен төрек солтаныннан мең өлеш өстен куеп, дөньяга сыймастай булып йөргүен күрсәң икән. Моның дәрәҗәсенә җитмәсә дә, аңа охшаш әтәчләр ел да булып тора. Әмма бу аларны яшәтми: йә чукып үтерә, йә ихатадан куып чыгара. Шуңа күрә Патша әтәч дип аталды ул.

Мондый гали затны мең-мең яшәтергә иде. Әмма ләкин соңгы вакытта артык комсызланып китте. Ихатада иллеләп тавык җырлап йөри. Агы бар, карасы, чуары, саргылты... Аларның да бәгъзе берсе мең төрле чәчәк төсе белән нәкышләнгән. Карап, сөеп туярлык түгел. Шулар арасында ул берүзе генә күкрәк киереп йөрсен, имеш. Тагы бер-ике әтәч булса, нигә, әллә дөнья тармы аның өчен? Әллә нинди ахмаклыклар кыла башлады: тота да күрше тавыклары янына кереп китә. Ярый, керсен, бер күңел ачып чыксын: күрше хакы — Тәңре хакы, дигәне әтәчкә дә кагыладыр, бәлки. Ләкин бит анда инсафлы гына йөреп, күрше тавыклары матур-

лыгы белән илаһи бер сокланып, тыныч кына күңел белән кайта белми. Иң әүвәл аларның әтәчләренә ташлана. Үтергәнче чукый, изә. Ике як күршедән дә хәзер әллә нинди колак ишетмәс, җан күтәрмәс ачулы бәддогалар ява: Гыйрфан мулла, имеш, күрше әтәчләрен кырдыру өчен, усал эттән дә яман әтәч тота. Бер юньсез әтәч өчен күршеләр белән низаглашып, якалашып яшәргәме? «Әтәч азса — хуҗа башына, патша азса — халык башына» ди бит. Бисмилләһиррахмәнир-рахим!.. Хуш, азгын Патша! Хуш инде! Бәхил бул! Яшең дә шактыйга китте шикелле. Вакытында яшьнәдең. Горур булдың. Һәрнәрсәнең чамасы бар.

Патша янында янә бик иркәләнеп, ыспайланып, җырлап йөргән ике симез «Патшабикә»не дә тотып чалды Гыйрфан мулла. Хәсәнә абыстай аларны пешекләү, йоннарын йолку, аш салу эшенә кереште. Эш белән әвәрәләнгән вакыт тиз үтә. Кояш исә, гәрчә адәм балаларының аһ-уһ килеп мәшәкатьләнүен күреп торса да, бер генә секундка да аларга артык вакыт бирми, Алланың үзе кебек тугрылыклы булып, куйган максатына ирешү юлыннан читкә тайпылмый — җай гына бара бирә.

Бүген дә ул тәртиплелек иманына тугрылыклы булды. Ут шарына әйләнеп, баерга ярты дилбегә чамасы калгач, бөтен җир йөзенә алсу-кызгылт нур сибеп, икенде намазы җиткәнлекне искәртте. Кырык эш кырык җирдә кырылып ятса да, аларны хәзергә бер як кырыйга куеп, Гыйрфан мулла остабикәсе Хәсәнә абыстай белән парлап намаз укыды. Икенче бер бүлмәдә шул ук фарыз эш ике шәкерт тарафыннан да башкарылды. Әлеге ярты дилбегә буе ара, кем әйтмешли, күз белән каш арасы кебек кенә. Кызыл шар төсенә кергән кояш офык читендә сылу кыздай елмаеп торды-торды да, утлы нурларын җир өстенә тагын да мулрак сибеп, таулар артына яшеренде. Менә Ходайның рәхмәте: нәкъ шул вакытта ахшамсафа гөле, нәкъ кояш кызыллыгы кебек итеп, янып торган кызыл чәчәк атты. Бу юлы да аны башта Галимҗан күрде. Күрде дә барысын да гөл янына чакырды. Бу, үзенчә, ниндидер күренмәгән киләчәк, булачак бәхет балкышы иде.

* * *

Шакирҗан балыкка киткән иде. Нәкъ ахшамсафа гөле чәчкәсе балкышы вакытында елмаеп-көлеп кайтып керүе, үзен кәүсәр күлендә юынып чыккан кешедәй хозур тотуы, күзләренең ниндидер бер җылылык сирпеп торуы бу балкышка яңа төс, илаһилык, күңеллелек өстәгәндәй булды.

Балыктан буш кул белән кайтса, аның сөмсере коелган,

маңгае җыерылып, күз бәбәкләре мәзәкләнгән, борыны салынган була. Әле борын салынмаган, киресенчә, тәкәббер кешенеке кебек, күккә чөелгән. Димәк, балыкны күп чәлдергән. Аның юлы уңган яки уңмаган вакытта үзен ничек тотуын Йосыф мәхдүмнән башкалар яхшы белә.

Шакирҗан тышкы кыяфәте белән чын балыкчыга охшап тормый иде. Чөнки ул, балыкка киеп барган киемнәрен чоланда калдырып, гадәти чалбарын, күлмәген киеп килеп керде. Алып кайткан балыгын да чоланда калдырды. Галимҗан белән Йосыфны күреп, берчә аптырап, берчә гаҗәпләнеп торды ул. Хәзер инде Галимҗанның Вәли мәдрәсәсендә Йосыф шәкерт белән бергә гаип булуын аңлау кыен түгел иде. Мал да ашаган җиренә кайта. Моның гадәте дә шуның шаенчә икән. Тик бу уй-хиснең тамчысын да сиздермәскә тырышты. Әйтерсең бернинди кәкре-бөкре эшләр булмаган: болар көндез бал-май белән чәй эчеп калган, ул, Шакирҗан, кунак егете өчен тәмле-тәмле балыклар алып кайтырга китеп барган.

Сокланышып, гаҗиз булып карашып тору озакка бармады. «Әссәламегаләйкем», «вәгаләйкемәссәлам» әйтелешеп, күрешеп алынды. Аннан соң, авызларына су капкан кешеләрдәй, янә сүзсез тын калдылар. Авыр тынлык иде бу. Кем ни әйтергә белми тик торды. Тынлык катылыгын ата кеше җимерде:

— Күз кабагың нык ачылган, Шакирҗан улым, димәк ки, Кондызлы күл сиңа бүген артык мәрхәмәтле булган...

— Әйе, әткәй, бу кадәр дә күп эләккәне юк иде, кунакларның ризыгы киң икән...

«Кунак» сүзен ишетү белән, Галимҗанның әрекмән колаклары тырпаеп, төсе берникадәр бозылып куйды. Сүзне кунак ягына борып, әлеге аларның теге вакытта җир упкандай юк булу мәсьәләсе калкып чыгарга мөмкин. Аннан инде китә авыздан саескан очырулар. Шакирҗанның беркатлылыгы да көчле. Һич уйламый-нитми, әллә ни әйтеп ташлавы бар. Аның әле берникадәр мактана торган гадәте дә юк түгел. Шуны уйлап, башта сүзне шаянга борды Галимҗан:

— Минем кармакныкына караганда, синекенә азрак эләгә иде, Шакирҗан абый, әллә бүген, оясына туры килеп, балыкны сөзеп кенә алдыңмы?

Аның бу сүзләреннән соң бәгъзе берсе көлеп җибәрде, бәгъзе берсе елмаеп куйды. Өй эчендә җанлылык хасил булды. Шуннан Галимҗан:

— Мин шаярттым гына, безнең Шакирҗан абый балыкның телен белә, шуңа күрә алар аңа күбрәк каба; әйдә, карыйк әле, Кондызлы күл балыклары сагындырды бит, төш-

ләремә керде, әйдә күрик әле үзләрен,— дип, тышка чыгып китте.

Шакирҗан белән Йосыф аңа иярде.

Өйалдында кәрзин тулы балыкны күреп, һәммәсе ләззәтле минут кичерде. Ә Шакирҗан исемнәрен әйтергә тотынды:

— Корбан балык... кызыл балык... мыеклы балык... табан балык...

Йосыф мәхдүм дә балык төрләрен яхшы белә. Чөнки алар авылы янындагы Сөн елгасында да, тирә-яктагы күлләрдә дә балык, арттырып әйтсәк, мыжлап тора. Шуңа күрә Шакирҗанга сорау бирде ул:

— Әллә сезнең якларда корбан балыгы белән табан балыгы бер үк суда йөзәме?

Шакирҗан ачыклык кертте:

— Юк, алай түгел: табан — күл балыгы, корбан — елганыкы. Без бүген Мөхөмәй белән бик озак йөрдек. Корбанны — елгадан, табанны — күлдән тоттык...

* * *

Кичкелекне ашап, ястү намазы укыгач, алар өчесе — Галимҗан, Йосыф, Шакирҗан — ишегалдына чыкты. Йа Хода! Нинди матурлык! Кояшның офык читендә калдырган кызыллыгы әле һаман янып тора. Хәзер инде ул кызыллыкта күксел-зәңгәр, сыек-зәңгәр, алсу-зәңгәр, чия-көрән...— тагы да әллә нинди төсләр, бизәкләр бар. Ахшамсафа гөле чәчкәсе дә шулай бит. Анда ахшам кызыллыгы өстенә әлеге төсләрнең барысы да бөрчек-бөрчек булып сибелгән. Әллә күк белән җирнең сөешүеннән, үбешүеннән хасил булганмы бу могҗиза-чәчкә? Табигатьнең нинди сере бу тагы? Халык шушы серлелекне ничек аңлый икән? Әллә аның йөрәге табигать йөрәге белән бәйлеме? Кендекләре кояш нурларыннан ясалган күренмәс серле тасма белән тоташканмы?

Табигать күренеше белән хозурланганда, һәркем әллә күпме хис-тойгылар кичерде. Галимҗан белән Шакирҗан, берсе икенчесен бүлә-бүлә, кунакка ахшамсафа гөле атамасының серен сөйләп бирде. Шуннан һәрберсенең күңел күгендә ахшамсафа гөле чәчкәсе бәхет күбәләге булыпталпынгандай тоелды.

Болар чыкканда, шәфәкъның кызыллыгы һаман уңа барган төс белән аралашкан зәңгәр кич иде. Акрынлап, назлы кызны сөяргә-иркәләргә ипләп-җайлап кына килгән әдәпле егет кебек, бу күксел-зәңгәрлеккә төннең кара күз алмасыннан сыек кара нурлар килеп кушыла башлады. Һаваның тәмен һич аерыр хәл юк. Әле кибеп тә бетмәгән язгы җирнең йомшак бу-парына кичке савым вакытында таралган җы-

лы сөт исе сеңеп калган кебек. Дәхи дә шуңа йөзләп моржалардан чыгып җәелгән төтен исе килеп кушылган. Алар яшь үлән, яшь кычыткан, яшь яфраклар исе-тәме белән аралашкан. Шуларның һәммәсе уптым илаһи бергә кешеләргә фәкать сихәт бирә торган шифа булып кушылган диярсең. Җиңел, йомшак, тәмле һава борын очларын кытыклау белән үк син инде үзеңдә искиткеч бер көчле ләззәтлелек тоясың. Сикерәсе, ыргыйсы, йөгерәсе килә. Ә инде зәңгәр күктәге миллионлаган йолдызлар җирдәге бәндәләрнең илаһи бу матурлык эчендә хозурланып яшәүләреннән көнләшәләр кебек.

Һәркемнең сөйләшәсе килә иде. Шакирҗанның бөтен теләге — айлар буе боларның кайда югалып йөрүләрен белү. Бу хакта ул сорамый калмады. Галимҗанның аз сүзле икәнен яхшы белә. Шуңа күрә сорауны күбрәк Йосыфка бирде. Йосыф мәхдүм, һич икеләнмичә, түкми-чәчми дигәндәй, бар булган кадәресен бөртекләп сөйләп бирде. Шулай да берәүнең дә сүз дәрьясына кереп чумасы килми иде. Чөнки монда, сүзләргә караганда, хисләр өстенлек ала. Табигать күп сөйләргә кушмый. Йомшак куллары белән, шәфкатьле аналар кебек, ул аларны һаман әле назлап-иркәләп тора.

— Юл газабы — гүр газабы, арыгансыздыр, әйдәгез керик, ятыйк, иртәгесе көн безнең кулда, тагы да иркенләп сөйләшербез, — диде дә Шакирҗан, икесенең дә аркасыннан җиңелчә генә назлап куйды.

Өйгә кергәч, һәркем үзе өчен тәгаенләнгән урынга барып ятты.

* * *

Хәсәнә абыстай үзләре өчен урынны беренче каттагы сәкегә җәйде. Мамык түшәк, мамык ястыкка чумгач, «ә» дигәнче, тәмле, татлы йокыга кителер кебек иде. Бу фани дөньяда зур эшләрдә генә түгел, хәтта йокыда да көткәнеңнең киресе килеп чыга. Менә күз йомыла, менә әвен базарына киттем, чәнчелеп катсын дөнья мәшәкате, көне-төне буе эшләп ватылган тәнеңне ял иттерү өчен бирелгән, дип уйлыйсың да песи йокысы белән изри башлыйсың; нәкъ шул вакытта каһәр төшкән бер юньсез уй баш миеңә чәчрәнләп килеп керә дә бөтенесен дә челпәрәмә китерә. Бераз тын гына яткач, мулла абзый азрак сайрашып-гәпләшеп алмакчы, Галимҗан турында мең-мең уйлап, таштай каткан башын аз гына йомшартмакчы, шуның белән күңел күгендәге кара болытын берникадәр таратмакчы булды. Тора-бара бу уеннан да кире кайтты. Аңа остабикәсе дә кызганыч иде. Аның да йоклый алмавын сизеп ята. Авыр-авыр тын алуы, анда-санда «уф» дип куюы, үрсәләнү-өзгәләнүе болай да талган-алҗыган йө-

рәккә без белән чәнечкәндәй була. Шуңа күрә эндәшмәскә, аны борчымаска, бала кайгысыннан яраланган җәрәхәтенә тоз сипмәскә тырышты. Бәгъзе бервакыт, үз уйларыңа пәрәвез җебенә уралгандай чолганып, эндәшми-нитми, мыштым-мыштым гына, тирән вә киң хыял-хис дөньяңа чумып, фәлән-фәсмәтән итәм, дип тилереп яту хәерле. Кайгысы да, шатлыгы да, уеңның тәмлесе дә, тәмсезе дә үзеңнеке. Кайгы ул — шатлыкка тагылган дегет чиләге. Бәй, кайтты, күңелгә нур сипте, сүнгән йөрәккә җылы өрде, өй эченә җан керде; булды, Ходайга шөкер, хәят кояшын каплаган кара пәрдә ертылды, дисең; ләкин һич алай булмаган икән, шатлыкка икенче дегет чиләге килеп тагылды, кояшны янә кара болыт каплады: Казанга китәбез, дип хыяллана. Нәселе яман сыердан үле бозау туар, ди. Бер бала да үле тумады анысы. Ә менә туганын саклап булмый. Әнисенең йөрәк җимеше нәфис Нәфисә дә озак яшәмәде. Нәркис гөледәй назлы, матур, сылу иде бит. Атасының уң канаты булырдай Гобәйдулла да, бу авыр фани дөньяны нигәдер хуп күрмичә, оҗмах-җәннәткә ашыкты. Инде бу таш маңгай Казанга барып кайнамакчы. Һм, кайнарсың да... пешеп, өтелеп, канатсыз калып миңгерәрсең. Яман чир тиз йога, яман гадәт тиз керә, ди. Яман чире дә бар бит әле үзенең. Яман гадәт артыннан кууы да юк түгел. Әтисен, әнисен кайгы кочагына ташлап, әллә кая китеп олагуы яман гадәт түгелмени? Юк, җибәрмим әллә кая, тыңламаса, чыбыкка, чыбыркыга кире кайтырга туры килә, дип, елга буе уйларына буа буды ул.

* * *

Остабикәсе дә, шул хакта уйлап, мең төрле фаразлар дулкынында тибрәлеп ятты. Уйлар әйтерсең аның күз алдында санап бетергесез аллы-гөлле күбәләкләр булып оча. Кайсын тотып алырга ул йөз-мең төстәге күбәләкләрнең? Әмма берсе дә керфек очыңа да, уч төбеңә дә килеп кунмый. Шаярталар алар сине. Уйныйлар, үртиләр. Илаһым! Шул күбәләк-уйларның иң зурысы — Галимҗан белән әтисе арасында булачак көрәш уты. Икесе дә чыбыкны тоткан җирдән сындырырга ярата. Галимҗан хәзер Вәли мәдрәсәсенә бармас өчен теше-тырнагы белән каршы торачак. Әтисе үз сүзен сүз итү өчен җан атачак. Бу инде — яңа низаг, яңа якалашу, яңа ызгыш. Ә аңа, ана кешегә, кайдадыр барып, берсенә дә күрсәтмичә, балавыз сыгып алырга туры киләчәк.

Уйлар! Уйлар! Очы юк. Кырые юк. Диңгездәй тирән. Дөньядай киң. Әмма йокы да үзенекен итә. Аның кануннары бар. Адәм баласын әдәпкә кертә торган канун. Кешенең яшәеше, сәламәтлеге, рухи вә җисмәни ныклыгы йокыга бәй-

ләнгән. «Сәламәтлекнең иң түре — йокы» дигән борынгы ата-бабалар. Тора-бара аларның икесенә дә йокыдан тегелгән ефәк юрган ябылды.

* * *

Балалар икенче катка (өске бүлмәгә) җайлашты. Анда ике караваt, бер кәнәфи-диван. Караватлар ике түр почмакка урнаштырылган. Уртада — язу өстәле. Галимҗан, Габделхәкимне кочаклап, уң як почмактагы караватка ятты. Нәгыймә апасын якын күргән кебек, Габделхәким энесен дә нык ярата ул.

— Шәкерт абый, минем чынаяк тәтиләрем бик күп хәзер, у-у-у, дөнья хәтле, иртәгә күрсәтермен әле менә, — дип, Галимҗанның куенына песи баласыдай йомарланып ятты ул.

— Ярый, акыллым, шулай итәрсең, икәү уйнап та алырбыз әле менә; тик кара аны, тәтиенә кызыгып, чынаякны юри вата күрмә, — дип, энесен кысып кочаклап, бер сөеп тә алды Галимҗан.

Алар, тегеләргә ишеттермәслек итеп, колакны-колакка куешып, чыш-пыш, ык-мык килешеп, аз гына гәпләшеп алдылар. Әмма ул озакка бармады. Көне буе уйнап-йөгереп, андамонда чабып, малайлар белән бөтен урамны пыр туздырып йөреп арыган-алҗыган Габделхәкимне йокы тиз басты. Аннан әле яшь бала исе дә китмәгән кебек. Аның керпе чәнечкеседәй тырпаеп торган каты чәч төпләреннән, бөтен тәненнән, тын-сулышыннан тышкы һава исе, яз һавасы исе, кояш нуры исе, җир исе аңкып тора. Ул хуш-исләрнең барысы бергә кушылып, туган җирнең илаһи бер ямен, тәмен, ләззәтен искә төшерә. Аның куенында әйтерсең мышный-мышный энесе түгел, болыннардан җыеп ясалган бер зур чәчәк йомарлагы ята. Сагыну тойгыларының никадәр көчле, мөкатдәс, сихерле икәнлеген шушы минутта янә бер тапкыр ныклап аңлады Галимҗан. Әтисен, әнисен, Шакирҗан абыйсын, кендек әбине, Акчәчкәне, кырларны, болыннарны, атларны, сыерларны... — барысын, һәммәсен өзелеп сагынды ул.

Шулар арасыннан илаһи бер зат-фәрештә калкып чыга. Бу фәрештәнең мамык-ефәктән торган ике канаты бар. Шул канатлар белән кочакласа, син гөнаһсыз сабый-нарасый балага әвереләсең. Йомшыйсың, эрисең, шатлык диңгезенә чумасың. Бөтен кайгы, әрнү, алама як кул белән сыпырып ташлагандай юк була. Йомшак-нәфис куллары белән чәчләреңнән, битеңнән сөйсә, үзеңнең назлы колынга охшаганыңны сизми дә каласың. Күз карашлары җылысы белән иркәләсә, шифалы саба җилләре исеп, алар бөтен тәнеңдә уралып, сеңеп, йөрәгеңә ниндидер сихри яшәү оеткысы салынгандай

тоела. Бу — ана-фәрештә канатлары. Бу — ана-фәрештә куллары. Бу — ана-фәрештә карашлары.

Тик бу матур, сөйкемле, гүзәл фәрештәнең күркәмлегенә тормыш авырлыгының кара пәрдәсе тартыла башлаган. Күз карашларында моңсулык, уйчанлык, хәсрәт сөреме... — тагы да әллә ниләр сизелә. Яңаклары эчкә баткан. Йөзендә ниндидер сары самавыр шәүләсе бар төсле. Юк, тормыш авырлыгыннан түгел бу. Бала кайгысы авырлыгы шулай киптергән аны. Галимҗан кайгысы. Нәгыймә апасы чатнатып әйтеп китте ләбаса инде. Ул — туры сүзле. Кылдый-былдый, ык-мык, килделе-киттеле кылануны аслан белми. «Кемнеңдер сүзе тугры булса, ул кешенең матурлыгы һәм кадере артык булыр»,— ди бит. «Күрдеңме әнкәйне? Кипкән таяк булып калды бит. Синең кайгың шулай итте аны»,— диде. Моны әйткәндә, Нәгыймә апасының иреннәре дерелдәп, күзләре мәзәкләнеп, бөтен тәне калтырап куйды. Ананың газизлеге, бөеклеге, илаһилыгы әнә ничек икән. Бу хис-тойгыны Нәгыймә апасы күз сирпеп алган мизгелдә күрсәтә белде. Ә ул, Галимҗан, нигә алай түгел? Әллә кара йөрәклеме ул? Таш бәгырьлеме? Юк, юк, Ходаем сакласын андый бозлы сүзләрдән. Изге күңелле, олы йөрәкле, матур табигатьле, сөйкемле анасын өзелеп-өзелеп сагынды ул. Йөрәгендә анасына карата утлы, кайнар мәхәббәт бар. Ул ут, кайнарлык эчкә сыя торган түгел. Әгәр өреп тышка чыгарсаң, боз тауларын эретерлек. Менә шуны ничек белдерергә? Кемгә әйтергә? Ә нигә белдерергә? Нигә әйтергә? Эчтә саклансын. Анага зур мәхәббәт саклаган йөрәк — олы йөрәк ул. Анага булган зур мәхәббәт баланы бәхетле итә. Бүген ахшамсафа гөленең чәчәк атуы да, мөгаен, шуның бер хикмәте-хасиятедер әле. Ана белән бала мәхәббәтен нурландыру-бизәкләү өчен чәчәк аткандыр ул ахшамсафа.

Күпме генә әйтмә, әллә нинди тирән, бинихая зур фикерләр йөртмә, ана мәхәббәте, баланыкына караганда, мең-миллион өлеш зурraктыр ул. Шулай булмаса, «Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада» димәсләр иде. Һич югында, Шакирҗан абыйсына әйтеп китәргә кирәк булган. Баланың бер ахмаклыгы ана йөрәгенә тау дәүмәллеге кара кайгы булып ята икән. Баланың бер кайгысы ананы әллә ничә елга картайта икән. Менә кем икән ул ана! Ананың балага булган мәхәббәтеннән дә бөек мәхәббәт юк ул дөньяда!!! Юк, юк, юк...

Нәгыймә апасы тагын ни диде соң әле? «Әткәйнең сакалын кара. Син агартып бетердең аны»,— диде. Димәк, аның югалу кайгысы ата йөрәгенә дә кара таш булып яткан. Каты бәгырьле кешегә санап йөри иде ул әтисен. Катылык эчендә дә йомшаклык, илаһилык, кешелеклелек була икән ләбаса.

Аның хәбәрсез югалуы әтисенең сакалын тагын да ныграк агарткан. Димәк, ул әтисе өчен дә бик-бик кадерле. Йосыф мәхдүмнең әтисе:

— Һәр эшнең ахырын фикерләп һәм уйлап эш кылмаган кешенең башы бәла вә кайгыдан чыкмас,— диде бер сөйләшкәндә. Әллә ул моны аңа, Галимҗанга, төрттереп әйттеме? Йосыф шәкерт Галимҗанның ни өчен алар ягына барып чыгуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде ич. Димәк ки, ул аның бу кыланышын килештереп бетермәгән.

Мең, миллион төрле утлы-давыллы уйлар диңкетте аның башын. Диңкетте. Изде. Мәмрәтте. Шул уй дулкыннары аны урап-чолгап алды. Шул дулкыннар эчендә, бишектәге сабый баладай тибрәнеп, тирән йокыга талды бервакыт.

* * *

Йосыф шәкерт тә уйсыз түгел иде. Илештә аларның да йорт-курасы, миндәй зиннәтлене көндез чыра яндырып эзләсәгез дә таба алмассыз дигәндәй, хан сараен хәтерләтеп, әллә кайдан балкып, горур пәһлеванга охшап күренеп тора. Боларныкы да шул сыйфаттарак икән. Артыграк тадыр әле. Чөнки Йосыфларныкы бер генә катлы. Ә боларныкы — аслы-өсле өй, ягъни ике катлы. Аннан соң аскы өйнең дә, өске өйнең дә тәрәзә кашагаларында, киштәләрендә, төрле-төрле чөйләрдә абыстай һәм кызы Нәгыймә чиккән сөлге-тастымаллар, челтәрләп, нәкышләп эшләнгән нindидер япмалар эленеп тора. Мендәр, ястык, түшәк өемнәре дә ал, кызыл, зәңгәр, яшел, сары, тагы да әллә күпме төстәге җепләр белән чигелеп эшләнгән япкычлар белән ябып куелган иде. Стеналарда да төсләрен санап бетергесез җеп белән нәкышләнеп эшләнгән матур-матур келәмнәр эленеп тора. Идәнгә җәелгәне дә — шулай ук зиннәтле, күз явыңны алырлык матур, искитмәле. Аңа абыстай һәм кызы Нәгыймәнең йөрәк кайнарлыгы, күңел уты, хатын-кызда була торган үтә нечкә хис-тойгы ялкыны кушып чигелгәндер. Ул җәйгечкә аяк белән басу да килешми кебек. Гөнаһ булыр төсле. Өй эчендәге нурлылык, төрле гөл чәчәкләреннән килгән хуш-ис, чисталык-тазалык күңелеңне тәмам исертә, әсир итә. Син үзеңне нindидер матурлык дөньясына килеп эләккәндәй тоясың. Бөтен күңел зәвыгын кушып, тәлеңне йотарлык тәмле аш пешерү, өй эчен оҗмах-җәннәт кебек итеп тоту, илтифатлылык — хатын-кызның иң уңай сыйфаты бит ул. Ананың йөрәк кайнарлыгыннан, җылы күз карашларыннан, матур хис-тойгыларыннан сирпелгән шәфкатьлелек баланы зыялы, күркәм сыйфатлы, бәхетле итә!..

Хәсәнә абыстай күлмәк кенә түгел, хәтта хатын-кызлар

читеге дә, чүәк тә тегә икән әле. Галимҗан, җаен туры китереп, аз гына вакыт эчендә аларын да күрсәтеп өлгерде. Димәк, әнисенең алтын куллы булуы белән ул бик нык горурлана.

Бакчадагы шау чәчәккә күмелгән алма, чия, карлыган агачлары, матур булып тезелеп киткән түтәлләр ата кешенең дә, Шакирҗанның да иҗтиһадлылыгы, эш сөючәнлеге, җегәрле икәнлеген сөйләп тора.

Беренче чәйдән соң, икенде белән ахшам арасындарак, Галимҗан аны ат абзарына алып барды:

— Менә монысы туры бия, менә бусы алмачуар,— дип горурланып, берникадәр мактану тойгысы белән сөйләп, атларның ялларын биш бармагы белән тарый-тарый, муеннарыннан кочаклап сөя-сөя, маңгайларыннан үбә-үбә, һич аңлатып бирә алмаслык күңелле хисләр кичерде.

Монда килүенә бик шатланды Йосыф мәхдүм. Күп ил күргән — күпне белгән, ди. Яхшы кеше белән аралашкан — җанына ризык тапкан, ди. Биредә җан ризыгы, рухи байлык, күңел хозурлыгы бар. Әмма хәзергә шул аклыклар өстенә ата белән бала арасында килеп чыккан низаг-үпкәләшүнең кара пәрдәсе ябылган. Әтисе Вәли мулланы Галимҗанны мәдрәсәгә яңадан кабул итәргә күндереп кайткан. Ә болар Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укымакчылар. Әлбәттә, зур тарткалаш, көрәш, күңелсезлекләр булачак. Кем җиңәр? Монысын хәзергә бер Ходай үзе генә белә.

* * *

Шакирҗан да утлы уйлар өермәсе давылында чайкалып ятты. Галимҗан өчен әтисе, үз тиресенә сыя алмаган арыслан шикелле котырынып, аның өстенә йодрыкларын төйнәп ташланды, вакыт-вакыт чәйнәп ыргытырдай ерткычтай кыланып, «у-у-у», «уф-уф» кебек ымлыклар белән аһ итеп, юләр кешедәй тешләрен шакылдатып, әллә нинди түбән сүзләр белән кимсетте:

— Син,— диде,— мәхлук җан иясе, бердәнбер энеңә күз-колак булып тора алмадың, җебегән, арыш боламыгы, черегән көпшә,— диде. Галимҗанның югалу кайгысын тау-тау итеп, аның җилкәсенә алагаем өеп куйды.

Кайчак әнисенең ялыну-ялвару сүзләрен дә ишетте ул:

— Атасы, Ходайдан сабырлык сора, бу кадәр кылануларың һич кенә дә яхшылыкка түгел, Шакирҗанның ни гаебе бар монда,— дип юатты аны әнисе.

Ничек кенә булмасын, Шакирҗанга бик кыен иде. Әтисенең холыксызрак, кырыс кеше икәнлеген белсә дә, бу кадәр намус күтәралмаслык сүзләр әйтер дип уйламаган иде. Шакирҗан әтисенең эчендә дөрләп янган утның кайнарлыгын

да белә: бала югалту ата кеше өчен энә югалту түгел бит. Ләкин Шакирҗан нахак сүзне бик авыр күтәрә. Эшләгән гөнаһ өчен тукмак алудан аслан курыкмый ул. Гаебеңне чатнатып, күзеңә, йөзеңә бәреп әйтсеннәр. Ялган балдай баллы сүзгә караганда, әремдәй әче дөрес сүзнең өстенлеген аңлый ич инде ул.

Бусы бер булсын ди. Икенче кире галәмәте килеп чыкты бит әле, шайтан алгыры, бу четерекле мәсьәләгә бәйләнешле. Үз агаңнан кач та чит-ят кешегә ияр дә кит. Аны абыеңнан өстен күр. Әтисе аны янә әллә ниләр әйтә-әйтә битәрләячәк:

— Туганлык җылысы юк синдә, мәмәйсең, авызың ачык каргасың, — диячәк.

Уйлап карасаң, чыннан да шулай бит. Ник күзәтсә, һәрвакыт күз уңында тотса, янына еш килеп йөрсә, чын ага була белсә, мондый күңелсез хәл килеп чыкмас иде. Тирәнрәк уйласаң, гаепнең тәртә башы ахыр чиктә аңа килеп төртелә. Намуслы, кешелекле, әдәпле икәнлеген белә ул. Әллә адәм баласын чын шәхес итәрлек шулардан өстен янә бер хикмәт бармы? Остазның да остазы була, диләр бит. Ул остазлык кәбестә шикелле һаман-һаман катлаулана барадыр. Аннан, үрмә гөлгә әверелеп, өскә, югарыга үрлидер. Аңа инде унҗиде яшь. Кем әйтмешли, яшьлекнең яшел бакчасына алагаем аяк баса, егетлек кодрәтеңне хакыйкый эшләр белән күрсәтә, ташып торган көчеңне исбат итә алырлык чак.

Юк, Галимҗанны Казанга җибәртмәячәк ул. Моңа әтисенең дә, әнисенең дә көче җитмәячәк. Ә менә Шакирҗан, авыр мәсьәләне чишкән кебек, гаиләне бу кыен хәлдән коткарачак. Кеше күңеле җиде кат җир асты кебек тирән булса да, Шакирҗан ул тирәнлеккә чума да белә. Анда адәм бәндәсенең күңел кылы бар. Әнә шул кылны табу, аңа чиртә белү кирәктер.

Төне буе диярлек Галимҗан күңелендәге шул кыл турында уйлап ятты ул. Йокыга киткәч тә шуның белән саташты: кыл, кыл, кыл...

## IV

Патша әтәч хәзер юк инде. Иң әүвәл ул таңны яңгыратып кычкыра иде. Тавышы үлем йокысы белән йоклаганнарны уятырлык каты, таш йөрәкләрне хисләндерердәй моңлы, барлык тавыкларны дәртләндерерлек көчле була иде. Әйтерсең бөтен авыл әтәчләренә Патша әтәч кисәтү ясаган: «Тирә-якта иң бөек Галиҗәнап кикрикүкмен, булыр-булмас тавышыгыз белән мин-

нән алда кычкырып адәм көлдерсәгез, дөнья ямьсезләсәгез, шушы кылычтан үткер томшыкларым белән чукыйм да үтерәм, берегездән дә матур таңның котын җибәртмәячәкмен», — дигән. Җәнлек, хайван, кош-кортларның теле бар, диләр бит. Аларның «га-га-га-га», «бак-бак-бак», «ку-ку-ку-ку», «мә-ә-ә», «өм-мә-ә-ә» диюләрендә әллә күпме мәгънәле сүзләр бар, имеш. Патша әтәч, «ки-к-ри-күк» дип сөрән сала-сала, үзенең «генераллыгын» аңлаткандыр. Көндезге шау-шу, ыгы-зыгы эчендә аның сөрәне әллә ни сизелмәскә дә мөмкин. Әмма таңда аның тавышы таш яра. Иң башта ул кычкыра. Аны башкалар күтәреп ала. Шулай итеп, әтәчләр моңы симфониясе башлана. Бүген ул юк инде. Патша әтәч белән сугыша-сугыша, чүкешә-чүкешә, бер-берсен канатыша-канатыша, Ак әтәч башлап җибәрде бүген симфонияне. Аның да тавышы болай сөбханалла икән. Үлем йокысына сеңгәннәрне дә сикертеп торгызырлык. Хәер, гәрчә бер генә әтәч тә мазасызлап кычкырмаса да, Чулпанның таңны уятканы, таңның кешеләрне торгызганы һәр крәстиәнгә аягындагы чабатасы, өстендәге киндер күлмәге, башындагы бәлтерәгән эшләпәсе кебек мәгълүм бер хәлдер. Бу вакытта ул барыбер уяна. Аның бит әле аңа төбәп әйтелгән әллә күпме мәгънәле хикмәтләре бар: «Кем кояштан алда тормаган, шул иң уңмаган»; «Ялкауны таң әтәче дә уята алмас»; «Йокыга моң кеше әтәч тавышын сөймәс».

Әлбәттә, тәмле таң йокысыннан үзеңне суырып алу берәүгә дә җиңел түгел. Әмма җиңел-җилпе эзли-эзли, чуртан авызына эләккән чабактай, аварлык авызына барып кабуың да көн кебек ачык. Гыйрфан мулла гаиләсендә бу мәсьәлә таштан койган коймадай кагыйдәләшкән. Иң әүвәл йорт хуҗасы сикереп торды. Аннан — хуҗабикә, балалар.

Тиз-тиз, берәм-берәм, аллы-артлы тәһарәт алдылар. Мулла абзый бүген иртәнге намазны мәчеткә барып укыячагын әйтте. Аңа Шакирҗан да, Йосыф та, Галимҗан да иярде. Капкадан чыгу белән, Мөбахис мәзиннең иртәнге намазга азан әйткән моңлы тавышы яңгырады. Йосыф мәхдүмнең күңеленә ул бик хуш килде:

— Менә кемдә икән моңның илаһилыгы, — дигәнен сизми дә калды ул. — Мондыйны бөтен Ырынбурдан таба алмассың.

Галимҗан аның бу ак фикеренә кара тамызды:

— Ул моң эчендә кара шәүлә бар, Йосыф абый.

Бу сүзләр Йосыф шәкертне тәмам нәүмиз итте. Сәбәбен сорарга уйлаган иде, намаз алдыннан сүз көрәштерәсе килмәде. Галимҗан бәхәс ярата. Гәрчә аннан күпкә кече булса да, бәхәстә гел өстен чыгарга тырыша. Бу гадәте хәзер аның канына сеңгән. Хәер, ул һәрвакыт үз фикерендә нык торып,

кешене ышандырып, мантыйк белән сөйләп сүз көрәштерә. Моң эчендә кара шәүлә булуның бер хикмәте бардыр. Бу хакта соңыннан сорар — Галимҗан әйтми калмас.

Иртәнге намаздан соң алар бергә кайтты. Авыл беразга гөж-мөж килеп торды. Башта сыер көтүе китте. Аннан — сарыкныкы. Шакирҗан белән Галимҗан да үз малларын капка ачып урамга чыгарды. Бервакыт ишегалдында Галимҗан белән Йосыф мәхдүм икесе генә калды. Шунда сөйләп бирде Галимҗан әлеге моң эчендәге каралыкның ни икәнлеген, Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалу, шуны Хөрмәтулла дигән кеше урлаган, дип, аңа нахак бәла тагу, аны үлем чигенә җиткереп тукмау, соңыннан югалган малның табылу хәлләрен бөртекләп сөйләп бирде. Бу күңелсез хәлнең бөтен авылда кара кайгы тудыруын әйтте.

Галимҗан күп сөйләргә яратмый иде. Ә бу юлы, бер ачылып киткәч, аның сүзләре ничектер чишмә суыдай агылып торды. Тик ул сүзләрдә чишмә суы сафлыгы түгел, ә сафлыкны бозучы керлелек бар иде. Бөтен йөрәге белән әрнеп, күңеле тетрәнеп, вакыт-вакыт тешен кыса-кыса, уртын чәйни-чәйни сөйләде дә:

— Менә нинди ялган диндарлар бар, Йосыф абый, Алладан да, хаклыктан да, иманнан да курыкмыйлар, адәм башын ашау алар өчен чебен үтерү урынына да тормый.

Бу сүзләрдән соң Йосыф мәхдүм алдында Галимҗан дәррәү үсеп киткәндәй булды. Димәк, аның күңел дөньясында ак-кара уйлар дулкыны көрәшә. Аклык өскә чыгарга тиеш. «Кешелеклелек» дигән төшенчә дә сеңгән аның канына. Кан йөрәк аша үтә. Тормыштан алынган кире сыйфатлар ул канны кайната, ярсыта, ургыта. Боларның барысы да Галимҗанның кырыс йөзенә аламалыкка каршы нәфрәт ташкыны булып чыкты. Йосыф шәкертнең шул тукмалган кешене күрәсе килеп куйды хәтта.

— Мөмкин булса, Галимҗан, әллә шул кешене барып күрәбезме?

— Тик әти-әнигә әйтергә ярамый.

— Нигә?

— Каршы килүләре бар. Яманлыкны алар миннән яшерергә тырыша. Алар өчен мин әле һаман йомырка сарысы.

Бераздан аларны Шакирҗан аскы өйгә чәйгә чакырды. Керсәләр, өстәл өстендәге сый-нигъмәтне күреп исләре китте: табада майда йөздерелгән коймак өеме, бер як кырыйдарак чәкчәк, гөбәдия, тагы да әллә ниләр бар...

* * *

Чәйдән соң Галимҗан белән Йосыф мәхдүм матур гына киенеп алдылар: өстә — җилән, башта — түбәтәй, аякта —

читек... Шулай киенү — вакытына күрә килешеп тора: әле яз белән җәйнең кул кысышкан чагы — көн салкын да, эссе дә түгел, җылымса гына. Кояш та бүген, җәйге челләдәгечә, бөтен дөньяны көйдерердәй булып, уттай янып чыкмады. Офыктан дилбегә буе чамасы күтәрелгәндә дә, аның йөзе салкын канлы кешенекен хәтерләтә иде әле. Әлбәттә, төшөйлә вакытларында аның чырае кайнар йөрәкле кешенекедәй кайнап торырга мөмкин. Ә хәзергә һава уртача. Көтү киткәндә күтәрелгән тузаннар инде, аз гына вакыт аралыгы эчендә аерылышу-сагыну хисләре кичереп, аналарын сөепяратып яшәгән нарасый балалардай, Җир-Ана өстенә күптән кабат төшеп түшәлделәр. Әле кибеп тә бетмәгән җир пары исе аңкый. Уйсулыкларда, елга буйларында, Кондызлы күл өстендә ефәктәй аксыл, юка томан эленеп тора. Алар тиздән Җир-Ана белән аерылачакларын сизеп моңаялар төсле. Дөрес сизенгәннәр: кояш нурлары аларны үбеп-сөеп-назлап торды-торды да бервакыт үз кочагына алды.

Ата кеше, Шакирҗанны ияртеп, печәнлекләрне карап кайтырга дип китте. Аннан ары ишегалдында Галимҗан белән Йосыф шәкерт кенә калды. Алар күңелләрне күбәләкләндерә торган иртәнге саф һава, йөрәкләрне җилкендерердәй матурлык, гүзәллек белән илаһи сәҗдә китеп, ләззәтләнепхозурланып, инде китәргә дип торганда, өй эченнән мич каршында аш әзерләүдән бит очлары алсуланган Хәсәнә абыстай килеп чыкты да, ай-һай, боларны тагын да югалтмыйм дигән төс күрсәтеп, борчулы тавыш илә:

— Кая барасыз, Галимҗан улым, бик еракка түгелдер бит? — дип сорады.

Галимҗан әнисен тынычландырырга тырышты:

— Без йөрештереп кайтабыз, әнкәй, борчылма, әллә кая китмәбез, Йосыф абыйга авылны күрсәтәсем килә...

— Кунакны бик йончытма, кара аны, ишетсен колагың, әллә кая китеп олакмагыз.

Галимҗан җавапны шаяртыбрак бирде:

— Юк, юк, әнкәй, менә күрерсең, кояш кебек әйләнеп, тиздән кайтып та җитәрбез. Кайнар сумсаларыңны суытмый сакла.

Капкадан чыгып бераз киткәч, аларга Апуш очрады. Ул, балтасы суга төшкән кешедәй, бик кайгылы кыяфәттә, гамьсез генә атлап килә иде. Аның бите, кулы пычранып беткән. Кырык ямаулы киндер күлмәге, киндер ыштаны аның бик ярлы тормыш баласы икәнлеге турында кычкырып сөйләп тора. Галимҗан шушы кергә каткан тәкәббер Апушны да, терекөмеш Әптерәйне дә, кысык күзле Мөхәммәтне дә, тагы да кара борынлы, үткер карашлы, сандугач телен, төлке хәйләкәрлеген белгән авыл малайларының барысын да, һәммә-

сен дә сагынып кайтты. Тик әле менә Апуш нигәдер сырт йонын кабартып тора. Галимҗан кулын сузгач, аны кабул итмәде. Үз кара кулы белән шәкерт дустының ак кулын пычратасы килмәде, күрәсең. Сүзләр дә, киселгән икмәк телемедәй, нигәдер берекмәде, таркау, ятышсыз булды. Чөнки Апуш бу мәлдә үзен гөл бакчасындагы шайтан таягы итеп сизде. Башта бит Мөбахис мәзиннең югалган сарыгын бергәләп эзләгәннәр иде. Ә инде соңгы мәртәбәсендә Галимҗанны ияртми генә киткәннәр. Әлеге Чирле чәүкәне йончытмыйк дип уйлаганнардыр, бәлки. Бу хакта да әйтми калмады Галимҗан:

— Дуслыкны боздың, Апуш, теге вакытта сарыкны эзләргә миңа әйтми генә киткән булдыгыз,— диде.

Апуш берничә сүз белән генә җавап бирде:

— Кем тапса да барыбер түгелмени?

— Миңа ул вакытта бик кыен булды.

— Сарык табылуда ни файда? Хөрмәтулла абзыйны нахакка рәнҗеткән өчен Мөбахис мәзингә берни дә булмады. Карга күзен карга чукымый шул. Аны яклаучылар күп.

— Хөрмәтулла абзыйның хәле ничек?

— Ә сез барып карагыз... Ул телдән калган, кан төкерә, ди.

Апуш теш арасыннан чыртлатып бер төкерде дә китеп барды. Болар юлларын дәвам итте.

Галимҗан юлда барын да сөйләп бирде. Хөрмәтулланың гармунда уйнавын, хатыны Мәликә, кызы Мәдинәнең моңлы итеп җырлавын, кыскасы, аларның моң эчендә олы йөрәкле булып яшәүләрен бәян итте. Мәдинәне Акчәчкә дип атавын, әле менә аны күрәсе килүен дә яшермәде.

## V

Хөрмәтулла өенең тышкы күренеше, ихатасы, абзар-курасы башка ярлыларныкыннан артык та, ким дә түгел. Шул ук җимерек читән, картайган капка, күп кайгы кичергән лапас, дөнья авырлыгының коточкыч төс-йөзен чагылдырып торучы балчык өй. Алар, бик мәдәнилек-илтифатлылык саклап, акрын гына ишек шакыдылар. Башта җавап булмады. Шакуны шактый көчәйткәч тә әле эчтән бернинди тавыш ишетелмәде. Галимҗанның башына өч төрле уй килде: беренчесе — өйдә берәү дә юк; икенчесе — авылда, шәһәрдәге кебек, ишек шакып tормыйлар, шуңа күрә бу дөбердәтүне гәрчә ишетсә дә, Хөрмәтулла абзый аңа игътибар итмәскә мөмкин; өченчесе — Хөрмәтулланың телдән калуы турында әйтте бит Апуш, бәс, шу-

лай булгач, «керегез» дигән сүзне әйтә алмый ич ул. Яшь зурлыгы ягыннан чыгып хөкем йөрткәндә, тырышлыкны хәзер Йосыф мәхдүм күрсәтергә тиеш иде. Тик ул кунак кеше — ярамый. Шуңа күрә Галимҗан кыюлыкны үз кулына алырга мәҗбүр булды: ишекне ачып, дәррәү эчкә үтте, Йосыф аңа иярде.

Өй эче Ак түтинеке кебегрәк. Шул ук җир идән. Озын кеше сузылып ятса, аягы ишеккә тиеп торырлык кыска сәке. Көн яктылыгын өй эченә аз гына төшереп торучы карындык тәрәзә. Шулай да өй эчендә пөхтәлек, җыйнаклык, күркәмлелек сизелә. Морҗа — агартылган. Ул Мәликә түтинең ак, көләч йөзен хәтерләтә. Тәрәзә кашагасына элеп куелган чигүле сөлге Мәликә түти белән Мәдинә-Акчәчкәнең моңнарыннан нәкышләнгән диярсең. Мондый хис-тойгы Галимҗанның уй даирәсендә дулкынланды. Ә инде Йосыф мәхдүм күңеле әле ул хисләр дөньясында йөзә алмый иде. Чөнки ул болар хәятен белми. Шулай да Галимҗан аларның нindирәк һава сулап яшәү рәвешен сөйләгән иде инде. Димәк ки, аңа да Хөрмәтулла абзый, Мәликә түти, кызы Мәдинә турында фараз итү мөмкинлеге юк түгел.

Хөрмәтулла, йокыга мәңге моң булган песи шикелле йомарланып, сәкенең уң як почмагында ята иде. Ул, бәлки, йоклаган булгандыр, шуңа күрә шакыганда тавыш бирмәгәндер. Аның баш астында үзенең йодрыгы зурлыгы гына мендәр. Өстенә үзе белән бергә дөньяның мең авырлыгын кичергән ямаулы чикмән ябынган. Ят кешеләр килеп кергәч, бик авырлык белән булса да, ул торып утырды. Сез, тәти егетләр, яктылыктан качкан ярканатлар шикелле, ни эшләп әле мондый караңгы базга килеп кердегез дигәндәй, гаҗәпләнеп, соры күзләрен чекерәйтеп карап торды. Күзләр дигәннән, аларның инде хәзер сорылыгы да, күрү өчен иң кирәк-әһәмиятле бер әгъза булуы да сизелми. Чөнки тирәнгә, эчкә батканнар. Яңаклар да суырылып эчкә береккән. Башы теге вакыттагы йодрыгы зурлыгында гына калган. Әлеге гер ташыдай мускуллар шиңгән бәләкәй шалканны да хәтерләтми. Шәлпек иреннәр яңгырсыз елда эсселектән корып кипкән яфрак диярсең. Керпе энәләредәй тырпаеп торган каты чәче йодрык зурлыгы калган баш түбәсен авырттырып, кытыклап тора сымак. Кыскасы, ул инде хәзер карга күтәреп китәрлек хәл-әхвәл фаҗигасе дәрәҗәсендә. Бөтен рухында шәлпәйгәнлек күләгәсе шәйләнә. Мендәр янында көл салынган ярык чәркә тора. Димәк, Апуш әйткәнчә, кан төкерүе дөрес булып чыга. Шунысы гаҗәп: әлеге ярык чәркәдән әллә ни ерак булмаган урында кесәгә сыярлык гармуны. Димәк, шуны уйнап, вакыт-вакыт ял ала, күңел күтәрә, җантәслим кылыр чагын моңы белән берникадәр озайта бара.

Ул моңга Мәликә түти дә, Мәдинә-Акчәчкә дә кушыладыр. Шуларның бөтенесе уптым илаһи йөрәк утын, күңел дулкынын, җан сызлануын, нахакка рәнҗетелү газабын бераз басып торадыр.

Ул нидер әйтергә теләде. Теле күпме генә тибрәнсә дә, әлеге кипкән яфракны хәтерләткән иреннәре күпме генә дерелдәсә дә, аның сүзе чыкмады. Бугазына гүя кырлы таш утырган. Юк, таш түгел, укмашкан кан төере икән. Көчәнеп-көчәнеп, күкрәген тотып, бизгәк тоткан кеше шикелле дерелдәп торганнан соң гына ул чәркәгә йөрәктән килгән канын төкерде. Төкергәч, чәркәдәге көл порыхлап күтәрелде.

Галимҗан килгәненә үкенеп тә куйды. Йосыф абыйсы алдында аңа бик кыен иде. Аның бит әллә ни уйлавы бар. Хәзер инде капыл гына ташлап чыгып китү дә килешми. Бу кешене санга сукмау була.

Шулай да ул бераздан телгә килде:

— Сез... сез... ни эшләп җөрисез?.. Сезгә миннән ни кирәк?..— дип сорады авырлык белән.

Җавапны Галимҗан бирде:

— Мин Гыйрфан мулла улы Галимҗан булам. Ак түтиләрдә танышкан идек бит. Ә бу — Йосыф мәхдүм. Ырынбурда бергә укыйбыз.

Хөрмәтулла, тамагына балык кылчыгы утырган кешедәй, сүзләрен янә әйтә алмый торды. Бераздан, чәркәсенә тагын да бер лачкылдатып төкергәч, һаман шулай бөтен күкрәге белән авыр тын алды да:

— Җарый... сине аңладым... Җахшы нәселдән... ә бу җегет... әллә тагы да миңа нахак бәла тагарга җөрүчеме? — дип куйды.— Тагыгыз... мин аннан тамчы да кырыкмаем... Гүпчи... Вәт кәк.. Пәтәмүште... Мин ырлашмаган... Анысын бер Ходай үзе белә... Шул... шул... сез... аксөякләр... ярлы-ябагай өстенә кара пычракны лаканы белән аударсагыз... Алладан куркырга кирәк аз гына...

Бу сүзләрне, сакау кеше кебек тотлыга-тотлыга, йөрәк утына чыдый алмыйча, вакыт-вакыт җен суккан кешедәй калтырана-калтырана, күңелендә кайнаган давыллы дулкынын көчкә тыеп, әрнеп-әрнеп сөйләде Хөрмәтулла. Аның җаны елаганны, йөрәге өзелер чиккә җиткәнне таш бәгырьле кеше дә аңларлык. Булып үткән коточкыч афәтне, фаҗигый хәлне, нахак корбанына әверелүен кемгәдер сөйлисе килгәндер, күрәсең. Башта йөрәк тамырларын сыкрандырып, сызландырып килгән кара кайгы каны тамак шешен яра-яра үтсә дә, сүзе бөтенләй чыкмый иде. Ә инде кара кан төере сүзләргә юл ачкач, йөрәк-бавыр, аң-акыл, хис-тойгыга сеңгән кара сөрем, кубып, кан артыннан тышка сүз-сөйләмгә әверелеп чыга башлады.

Галимҗан үзе дә кан түкергән кеше. Кан аны «Хөсәения» мәдрәсәсендә хәлфә, мөдәррис, мулла, шәкертләр алдында хур итте. Ул вакытта җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр иде ул. Кан аны, бөтен тирә-якны дан тоткан шөһрәтле «Хөсәения»дән, Шакирҗан абыйсы белән бер бүлмәдә тору бәхетеннән аерып, җәһаләт Вәли мулланың караңгы базына китереп тыкты. Кан, кан, кан... оһ, ул каннар!.. Әллә кан Хөрмәтулла агасы белән икесен бер язмышлы итмәкче буламы? Шул кан уртаклыгы алып килдеме әллә аны монда? Тик менә хәзер нишләргә? Ни өчен килгәнлекне ничек әйтергә? Әйтми чыгып китү дә әллә ничек. Бу авыр минутларда Йосыф абыйсы ничек уйлыйдыр — монысы аның өчен әле ул кадәр әһәмиятле түгел. Әһәмиятлесе — Хөрмәтулла агасының күңел кылына дөрес чиртә белү. Аның горур, баш имәс кеше, «ярлы тәкәббер» икәнлеген дә яхшы белә. Хәйләне, икейөзлелекне, боргалануны яратмый. Ташны балта түтәсе белән бер бәрүдә сугып ярырга ярата.

— Без хәлегезне белергә дип килгән идек, Хөрмәтулла абзый,— диде ул, үзенең авыр сулаганын, кыенсынганын белгертмәскә тырышып.

Хөрмәтулла әлеге, эчкә баткан песинекедәй соры күзләрен акайтып, маңгаен җыерып, болай да бозылган төсен аңламаслык дәрәҗәдә үзгәртеп, гасабиланып карады да чәркәсенә янә бер кан төкереп куйды:

— Хәлме?.. Күреп торасыз бит... Кешене үтерү җиңел, ә менә үлгәнне терелтеп булмый... Тәк бит... Ну... миңа былтыргы күзегез белән карамагыз... Аны гүпчи җаратмыйм... Жәлләмәгез дә... Мин маңка малай түгел... И вчү... Мондый тукмалган эт көнендә сасып җатучы әллә мин генәме?.. Һи-и-и... алар дөнҗа тулы... Вәт тәк... Ә сез... тәти егетләр... тутый кошлар... укымышлы, башлы кешеләр... Җазыгыз мына шушы хакта... Дөнҗага бер гыйбрәт булсын, хи-хи...

«Языгыз» дигән сүз шәкертләрнең икесен дә тирән уй диңгезенә китереп салды. Чыннан да, кешелеклелек-кешелексезлек, шәфкатьлелек-шәфкатьсезлек, яхшылык-яманлык турында сөйлиләр ич. Киләчәктә яхшылыкның җиңүе турында фәлсәфә саталар. Коръән, дин, укулар да шуңа корылган. Әмма ләкин меңнәр, миллионнар шушылай нахакка рәнҗетелсә, кешелеклелек җиңмәячәк. Матурлык фәрештәләре нур чәчеп йөремәячәк. Хөрмәтулла абзый язарга куша. Шушы минутта меңнәр-миллионнарның рәнҗетелгән, яраланган йөрәге шуны көтеп ятадыр. Һәр яманлыкның, йогышлы авыру кебек тиз таралып, дөнья йөзенә кара ягуыннан куркалардыр. Мең-миллион үкчәле итек белән таптап изәсе

иде ул яманлыкның башын. Яхшылыкның башы да, гәүдәсе дә мәңгелек бәхет пәйгамбәре булып калсын иде.

Берникадәр авыр тынлыктан соң сүзне бу юлы Йосыф мәхдүм башлады:

— Хөрмәтулла абзый! Мин, сез уйлаганча, бер дә нахак бәла тагарга йөрүче кеше түгелмен. Менә сез язарга кушасыз. Бик һәйбәт фикер. Ләкин бит без сезнең үткәнне белмибез...

Тагын да шактый озакка сузылган авыр тынлык булып алды. Хөрмәтулла теле белән әлеге кипкән иренен ялап куйды, хәлсез куллары белән керпе энәседәй чәчен сыпырып, нурсыз күзләре белән боларга карап катты.

— Әйе... эчтә кайнаган кайгыны кемгәдер сөйләсәң, җөрәккә җиңел булучан... Пәтәмүште... берәүнең җөрәге икенчесенеке белән бәйле дә була... Аны Ходай шулай җаратткан... Күрәм... Икегез дә болай миһербанлы күренәсегез... Тыңлагыз әле минем гыйбрәтле хәлемне.

* * *

«Безнең әти карт... мәрхүм... авыр туфрагы җиңел булсын... нәсел-нәсәпнең унөч буынын белер иде. Вәт кәк. Пәтәмүште, борыны озын еракттан сизәр дигәндәй, беләк буе борыны белән мең төрле алтын базын казып, ул алтыннарны, чүп-чардан аера-аера, синең алдыңа таудай өеп куяр иде. Акыл алтыны бу, туганкайлар. Сүз алтыны. Буйга биек үскән кешенең акылы тубыгыннан, дигәнне ишеткәнегез бардыр. Аның буе кыска иде. Кәтүк дип җөреттеләр. Ә баш, мин сиңа әйтим, Мөбахис мәзиннең казаныннан гүпчи дә ким булмас. Әнә шул казанда алагаем кайната иде ул акылын. Чәпчим кайнатып бетергәч кенә аны кешегә кашыклап-кашыклап өләшергә тотына. Вәт сөйләр иде. Прәме... авызына карыйсың да катасың. Картәтинең әткәсе Салават батыр чирүендә булган. Әх... ыхым... ни... Салават аны кәпитән итеп куйган. Вәт кәк. Бу ни шуткы, брат, ышту син. Теләсә нинди ахмакка тәтетмиләр аны. Улмы? Җанаралга җиткән булыр иде. Канлы көрәштә шәһит була мәрхүм».

«Канлы» сүзен әйткәч, бугазына таш утырган кешедәй, капыл-кинәт тын алалмас булды Хөрмәтулла. Эчкә баткан соры күзләре мәзәкләнеп китте. Башын артка ташлап, җим көткән кош баласыдай, авызын ачты. Ул гүя әллә кешеләрдән, әллә табигатьтән, әллә гарше көрсидән, сүнеп барган гомерен озайтыр өчен, тәненә-вөҗүденә, йөрәгенә ниндидер яшәү шифасы өмет итә иде. Кем тамызыр аны? Бер бөртек гомер җимешен? Корыган тәнгә аз гына яшәү чаткысы бирердәй матдәне? Шул хакта уйланамы Хөрмәтулла? Бу миз-

гел-секундта, чалт аяз күктән яңгыр өмет иткәндәй, киселеп барган гомерне сипләрлек нәмәстәкәйләр эзләү хыялы аның башында әле аслан юк иде. Әйтәсе килгәннәрне, мөлдерәмә тулы чиләкнең суы түгелүеннән курыккан кебек, тиз генә әйтеп калырга ашыкты ул. Сүзләре дә, майлы табада шуган коймактай, ничектер җай гына агылып торды. Ходай ярдәм итте шикелле бу минутларда. Ә менә, ап-ак сөткә тамган дегет тамчысыдай, тамак төбенә әлеге кан төере килде дә утырды. Башын күтәреп, аны кире йотарга уйлады ул. Чөнки кеше алдында көлле чәркәгә кан төкереп утыру килешми. Ләкин ул канын йота алмады. Чәчәде. Горык-чорык ютәлләргә кереште. Буылып-буылып ютәлләде. Эчен тотатота, тәгәрәп китә-китә ютәлләде. Галимҗанның күңеленә: «Бетте Хөрмәтулла абзый, бәхилләшә бу якты дөнья белән», — дигән шомлы уй килде. Йосыф мәхдүмнең дә ак йөзе күгәреп катты.

Шулай да Хөрмәтулла бирешмәде. Әлеге чәркәгә алагаем кан төкерде дә, сүземне дәвам итәргә әзермен, курыкмагыз, мин әле ул тиклем йомшак җан иясе түгелмен, дигән төс күрсәтте. Ул, мөмкин кадәр үзен кулга алырга тырышып, җаным чыгып китмәсен дигәндәй, учын нык йомарлап, төртелә-төртелә, тагын да сөйли башлады:

— Ызначит тәк... Зур авызлы адәм сүзчән була дигәндәй, атай мәрхүмнең борыны гына түгел, авызы да ифрат зур иде. Сүз... прәме... чишмә суы урынына агыла... и вчү... ыххым... Ул әйтер иде... Картәти мәрхүм... Тә-ә-к... Әлеге Нәпәлиүн сугышына катнаша... Ул да башын сала... Вәт тәк... Кем өчен? Ил өчен!.. Халык өчен... Киләчәк өчен... Ыштубы да мазасызлык булмасын... Виш кәк... Шуннан атай карт үзе дә китә... Касыйм түрә белән бергә сугыша. И... прәме... теге нигә... Әх... тел төбендә генә... каһәр төшкере... Пар... пар... пар... Парижга барып керәләр... Тәки оялатмыйлар Париж җыланын Мәскәү җылысында... Пәтәмүште... анда оялап алса... ул бит... Уралга таба да ыслар иде... Шуңа күрә ул җыланнарны үз ояларында дөмектереп кайтканнар...

Әткәй әле ул чакта бик яшь, өйләнмәгән була. Нәпәлиүнне чәнчелдереп кайткач, яраланган арысландай, ары сугыла, бире бәрелә, башын ташка бәрердәй булып кылана, пәтәмүште жит нады... Өйләнеп алгач та, бәхет дигән хитри нәмәкәй койрыгын тоттырмый. Әйтә иде мәрхүм: Эстәрле өязендә, диер иде, пәмиччикләрнең часный ат заводы бар, диер иде, вәт кәк... кхым... ыхы-хы... Минзәлә өязендә Әхмәтов дигән пәмиччикнең дә ат заводы булган... Тәкме?.. Тәк... Анда, җанкисәккәйләрем, «башкорт породасы» дигән атлар... Картәтәң, диер иде әткәй, әнә шунда этләнгән... Көн-төн тир

түккән, бил бөккән, тез чүккән, диер иде, мәгәр үзенә ат җүнәтү түгел, җүгәнен алырлык та кәликә эшләй алмаган, диер иде. И вчү... кәнис-мәнис-нәкәнис... Ат җанлы булган ул. Ат җараткан. Атның тирен, исен исни торган булган. Ә үзен пәмиччик Әхмәтовның бер усал айгыры тибеп үтергән. Прәме... арт аяклары белән маңгаена гына бәргән... И вчү... кәнис-мәнис...

Әйтер иде әткәй: сез укып җөрегән Әринбур губернәсендә 69 алтын базы... әй лә... оныттым... при... при... прискә бар, диер иде... Шуларның утызы, диер иде, часнәй кулда, диер иде... Шуларда этләнгән әткәй... Ат башы зурлыгы алтын табып биргән бер прискә хуҗасына... Ә үзенә шиш... Кәпикә дә тәтемәгән. Шуннан... Киткән бу агач загатовит иткән җиргә... Җагу өчен... өй... йорт салырга да... Көнҗак Урал завутларына җылгадан агач озатып торганнар... ыххым... вәт кәк... Анда да рәт булмагач... киткән авылга... көтү көтәргә... Җитмеш җәшендә дә сыер, сарык, кәҗә артыннан җүгереп җөри әле. Әнә ничек куа дөнҗаны. Әмма куып җитә алмый. Хәлсезләнә. Үпкә авыруы эләктерә. Бер котырган үгез сөзеп үтерә моны... мәрхүмне... Бик шат кеше иде дә бит... Алдарга да җарата иде. Ул бәгъзе берәүнең акылын сынап карау өчен алдаша иде. Ышанмастайны ышандыра. Ә теге чүбек баш җалганга ышанса, олы авызын колагынача җырып, шаркылдап көлеп җибәрер иде. Мәгәр кешенең кәпикәсенә дә тимәде. Харам мал, диер иде, ашказанында тирес корты белән бер, диер иде. Их, әткәй, әткәй!.. Их, әткәй, әткәй!..

Ул сөйләвеннән тагын да туктап калды. Ата фаҗигасе күзенә яшь китерде, күрәсең. Әлеге тамак төбенә килеп тыгылган кан төере кебек, бу да йөрәк канына манчылып чыккан канлы яшьтер, бәлки. Аны ул боларга күрсәтмәскә тырышты. Сөртеп тә алмады. Йә үзеннән-үзе кибәр, йә килгән юлына кире китәр дип уйлагандыр.

Шәкертләрнең икесенә дә кыен иде. Тыңлавы күңелле, билгеле. Ләкин Хөрмәтулла артык интегеп, газапланып, авырлык белән сөйли. Ә үзенең йөрәгендә кайнаган барлык кара кайгыларын, күңел көлләрен, эч-бавырын өзгәләгән әрнү энәләрен...— барын-барын менә шушы мәлдә чыгарып түгәсе килә кебек. Шуларны газаплана-газаплана әйтү өчен кемнеңдер килүен көткәндер ул, бәлки. Аның салкын, нурсыз, әрнүле күз карашлары да хәзер боларны ашыкмаска, ташлап чыгып китмәскә, тыңларга өнди сыман тоела. Бу исә шәкертләрне чыгып китүдән тотып тора. Алар һаман шулай баскан килеш тыңладылар. Сәке читенә утырсаң, Хөрмәтуллага җилкә күрсәтеп тору була. Ә утыргыч-урындык дигәне монда бөтенләй юк. Шуны уйлаптыр, бәлки, ул ку-

накларны утырырга кыстамады да. Хәзер менә чыгып китсәләр, килешеп бетмәстер шикелле. Аннан соң аларның әле Хөрмәтулланың үзе турында бер-ике сүз ишетәселәре килә. Шуны аңлагандай, бераз тын алгач, ул, авыр бер көрсенеп, сүзне үзе үк башлады:

— Минме?.. Картәти, әти карт сукмакларыннан да җөрдем. Күп җөрдем. Завут, шахты, күмер базы...— берсе дә калмады, нәкәнис... Ыһым... уф... Кхи... Җаратмыйм мин завут, шахты хәҗәеннәрен... Көллесе хамнар... алдакчылар... Көтү дә көтеп карадым... Бу да батмый. Пәчәму? Пәтәмүште бер көн бай хатыны сыерымны имгәнсең, дип җәбеште... вәт иблис... Кешенең энәсенә дә тимием мин... Әти карт әйтмешли, йөрәк кимерә торган тирес корты бит ул. Ат ырладым, дип җүри әйттем. Әткәй мәрхүм ышандырып алдый иде. Ә миннән булмый. Шабаш. И вчү. Сез минем телдән көләсездер. Шахтыларда, завутларда тел бозылып бетте. Сүз тапмаганда урыччаны кыстырып җиффәрәм. Үземнең җаны читәнне сыер тизәге белән сылаган кеше кебек икәнлегемне беләм мин. Аңлыйм. Әле мына әлләниләр сайрап саласы килә. Тик... сандугач теле бездә юк шул инде ул, бәгырькәйләрем.

Аны Йосыф мәхдүм юатты:

— Сез бик мәгънәле сөйлисез, Хөрмәтулла абзый.

Сүзгә Галимҗан да кушылды:

— Әйе. Безгә тыңлау бик күңелле.

Шуның белән аларның сүз җебе өзелде. Бераз тын торгач, өзелгән җепне Хөрмәтулла үзе ялгап җибәрде:

— Күрәм... сез мине җәллисез... Бая әйткәнчә... кирәкми. Нахакка тукмалуымны да җөрәгегезгә авыр алмагыз. Шахтыда Ычтапан бабай әйтер иде: бәхет өчен көрәшергә кирәк, диер иде, былай эт көнендә җәшәү никуды ни гәдитсә, диер иде. Мына... терелеп аякка баскач, Алла боерса, шушы хакта кәнкритнә уйланырга туры килә. Завуткамы, шахтыгамы китермен, пожалуй. Рабучи брат арасында күңел ризыгы бар. Аларда чистый душа. Вәт тәк. И вчү... Хәзер бит безнең ише братка бераз ысвобуды бирелде... Ана, әти картның агасы теге ни заманында... крипосной права чорында... бер иблис пәмиччиктә этләнгән... Бәйләп куйган эт хөкемендә... Аннан ни шагу... Ни куда... әйтерсең аны шунда сумала белән җәбештереп куйганнар... Китеп кара... Җә илле камчы калҗасы, җә смирт... И вчү... Аннан аны... теге нине... тагы оныттым... Ә... Әйе... Крипосной праваны үзгәрткәннәр... Теге ни... ничәнче җылда соң әле?.. 1861 җылда үзгәрткәннәр... туис... бетергәннәр... Хәзер без бер пәмиччик корсагын гына калынайтучы әдәми зат түгелбез. Дүрт җагың кыйбла... и вчү...

Хөрмәтулла, сүзләрем сезнең өчен карга борчак чәчү шикелле генәдер дигәндәй, сөйләүдән туктап калды. Инде чыгып китсәгез дә ярый, дигәнрәк төс күрсәтте. Шәкертләр моны сизде. Шулай да аның йөзендә әле җибәрмәскә тырышу галәмәте чаткысы да беленде. Тагын да нидер әйтергә теләгәнен аңлау кыен түгел иде. Ул, чыннан да, шулай булып чыкты. Бер көрсенеп, авыр тын алгач, ул өзелгән сүз чылбырын янә ялгап алып китте:

— Әмма ләкин... дүрт җак кыйбла да... Мең төрле кара язмыш көтә сине... Пәчәмү?.. Пәтәмүште... Кешене чәпчим кеше дип белмиләр... Мына мине эт урынына изеп ташладылар... Мин бит адәм баласы!.. Бер адәм баласын нахакка үтерүнең гөнаһасы... ай-яй-яй... шуны аңламыйлар... Кешене түгел, тычканны да үтерергә җарамый. И вчү... Бер тычканны үтердеңме? Үтердең. Мының белән син миллион тычканны юк иттең. Пәчәмү? Пәтәмүште... унлап тычкан җитмәсә, бер төлке пропал... Унлап төлке җитми икән, арыслан ачтан чәнчеләчәк... Бер арыслан ким булды ди... мында инде, туганкайларым, үләксә ашаучы мең төрле козгыннар пропал дигән сүз... Җир үләксә белән тулса... җәшәү чәпчим чери башлый... Шуннанмы?.. Шуннан... ахыр заман җиткәнче үк, барлык адәм баласы... мескен ачтан үлә... И вчү... Мынымы?.. Мынымы?.. Мыны, җанкисәккәйләрем, шахтыда чакта Ычтапан дигән бер дәдәй сүләгән иде... Жизен шулай ул... Вәт тәк...

Боларны сөйләп бетергәч, Хөрмәтулла тагын да буылып ютәлләргә кереште. Кан төкерде. Шәкертләр хушлашып чыгып китәргә торганда, Мәликә белән Мәдинә кайтып керде. Икесенең дә кулында ниндидер иске япкыч-чүпрәк белән төрелгән зур төенчек иде. Төенчекләр, күрәсең, тартыпсузып, көчләп-көчләп бәйләнгән. Чөнки алар нык бүселеп тора. Япкыч очлары бер-берсенә җитмәгәнлектән, алар чабата киндерәсе белән озайтылган. Бәйләгән урыннардан балтырган яфраклары чыгып тора. Димәк, алар урманга шуның өчен барган: үлән белән тукланалар. Икесе дә төенчекне сәкегә куйгач, өй эченә яшь үлән исе таралды. Аларның үзләреннән дә урман исе, болын исе, чәчәк исе бергә аралашкан хуш ис аңкып тора иде. Мәдинәнең кулында бәләкәй генә чәчәк бәйләме дә булган икән. Төенчеген сәкегә куйгач, аны әтисе кулына китереп тоттырды. Моның күңел күтәрү өчен икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Бу хәрәкәтләр бик тиз — күз ачып, күз йомган арада эшләнде. Бер үк вакытта алар бер-берсенә караш сирпешеп алырга да онытмады. Бусы да гаҗәп тиз — «ә» дигәнче кылынды. Мәдинә, чәчәк бәйләмен әтисенә биргәч, болан баласыдай матур хәрәкәт ясап,

боларга йөзен күрсәтмәскә тырышкан хәлдә, юк эшне бар итеп дигәндәй, мич алдына барды, кулына әремнән ясалган себерке алып, нидер сыпырыштыргандай итте. Мәликә түти исә ягымлы, сораулы карашлары белән шәкертләргә карап катты: нинди җилләр ташлады, нинди язмышлар китерде сезне, тәти егетләр, бәйләп куйган шайтан да тормастай бу караңгы базга, ди иде аның гаҗәпсенү тойгысы. Бу тойгыны Хөрмәтулла да сизде шикелле:

— Шәкертләр хәлемне белергә килгән, Мәликә җаным, бар икән дөнҗада җакшы кешеләр, шулар өчен генә булса да җәшәрлек,— диде дә әлеге кызы бүләк иткән чәчәк бәйләмен иснәп куйды.

Шул мизгелдә аның эчкә баткан күз төпләрендә, яңак чокырларында, керпе энәседәй тырпаеп торган чәч бөртекләрендә киләчәк өчен яшәү өмете чаткылары, адәм балалары күңеле төпкелендә яшеренеп ята торган кешелеклелек гәүһәрләре, хәяти самимилек балкып киткәндәй тоелды. Аның сүзләрен Галимҗан җөпләде:

— Әйе, Мәликә түти, без Хөрмәтулла абзыйның хәлен белергә килгән идек,— дип, Йосыф мәхдүмнең кем икәнлеге, Ырынбурда бергә укулары, бирегә ничек килеп чыгулары турында ашыгып-машыгып, өстән-мөстән, эш кешеләренең вакытын алудан куркып кына сөйләп чыкты.

Хөрмәтулланың хәзер «Хөрмәт», «Хәрти» дигән атамалары гына түгел, «Хөрти» дигәне дә бар. Димәк, «хөрт кеше» була. Әле менә Галимҗан «Хөрмәтулла абзый» дип, матур итеп авыз тутырып әйткәч, Мәликә түтинең күңеле тулып китте хәтта. Әтисе Гыйрфан мулланың кара халыкка «аңгыра сарык» дип карамавын, һәр кемсәне зурлавын, кешеләргә кешеләрчә җылы мөгамәләдә булуын белә ул. Бу хакта аларның матур, җәннәткә тиң, илаһилык балкытып торган дөнья-тормышларында даими кайнашкан кендек әбисе Хәмдия абыстай да әйтеп тора. Шул инде: борынгылар белми әйтмәгән: өзелеп төшкән алма агачыннан ерак тәгәрәми. Оясында ни, очканында шул. Яхшы оядан очкан баланың канаты — нык, акылы — җитү, зиһене зирәк була.

Шулай уйлады да:

— И гөлкәйләрем, и акыллыкайларым, и йөрәккәйләрем, безнең ише кара кешене санга санап килүегез, олылавыгыз өчен бетмәс-төкәнмәс рәхмәтләр яусын үзегезгә. Ходай Тәгалә юлыгызга ак җәймә җәйсен, авыр укуыгызны җиңел итсен,— диде.

Алар хушлашып чыгып киткәч тә, озак кына матур, ләззәтле, күркәм хис-тойгылар дулкыны тибрәнде Мәликә күңелендә. Әллә ниләр уйлап бетерде ул: бу дөнья, кешеләр

күңеле, яшәү рәвеше әллә бик-бик серлеме? Бу серне адәм балалары аңлап бетермиме? Әгәр аңлап бетерсәләр, яшәү тигез, бик күңелле, гаҗәп күркәм булыр иде.

Шәкертләрнең килүе Мәдинәнең дә күңел кылларын кытыклады. Аның өчен бу килү ышанмаслык иде. Җитмәсә, чыгып киткәндә, Галимҗан «абыйсы» аңа ниндидер утлы, көйдергеч, аңлаешсыз караш та бүләк итте. Никадәр генә күз ташламаска тырышмасын, булдыра алмады Мәдинә. Башкаларга сиздермәскә тырышып, Галимҗанга күз тутырып бер карап алды. Йөрәк төпкеленнән үк килгән кайнар хисләр агымы икесенең дә күз карашлары ялкынында очрашты. Бер мизгел. Секунд. Бу кайнар мизгел әйтерсең тойгылар җебен мәңге чишелмәс мөкатдәс серләр белән төенләде.

* * *

Алардан чыкканда, кояш төшлек төбәгенә якынлашып килә иде инде. Һәр тараф тын. Моңсу. Ямансу. Дөнья үзендә ниндидер тирән сер саклый сыман. Яхшылыкмы ул? Яманлыкмы? Аклыкмы? Каралыкмы? Шәфкатьлелекме? Шәфкатьсезлекме? Кеше боздай караңгы йортта яши. Ә тышта — яктылык. Монда энә очы зурлыгы да кара тап юк кебек. Вакыт-вакыт әтәчләр кычкырып куя. Юк, кычкыру түгел, сайрау бу. Сандугач сайравы. Аннан да артыгraктыр әле. Сандугачныкы еракка яңгырамый. Әтәчнеке таш ярырдай була. Юк, ташны түгел, йөрәкне яра ул. Йөрәк күзәнәкләренә әллә нинди ярсыткыч, җилкендергеч, шаштыргыч моң салып, сине бераз тилертеп ала, әллә нинди кайгы-хәсрәтсез якты дөньяга әйди, күңелеңне хозурлык биләве белән били. Әтәч караңгы, яңгырлы, котсыз-шыксыз көннәрдә болай моңлы кычкырмый. Андый чакта ул өнен дә чыгармый әле. Димәк, әтәч моңы дөнья, яшәеш, хәяти моң белән бәйле. Аны көн матурлыгы, кояш нурлары назы, җир белән күкнең берберсен хөрмәтләп сөешү мәле-мизгеле шулай сайрата. Мондый көндә эт тавышлары да моңлы була. Алар кемгәдер ачу, нәфрәт белән өрми, кара тормыш авырлыгына әрнеми, хуҗасы өчен мәңге сакта торган тоткынлык язмышына зарланмый, ә фәкать, иркә бала ата-ана алдында шатлыктан бер очынып куйгандай, кояшлы көләч көндә дөнья йөзенә үзенең бер рәхмәтен белдерү җәһәтеннән моңлы өн чыгарып ала. Мондый чакта әтәч моңы, эт моңы, кеше моңы, табигать моңы, тагын да әллә нинди серле моңнар үзенчә бер зур моң йомгагы хасил итә.

Караңгы баздай өй эчендә яшәгән Хөрмәтулла абзый, Мәликә түти, Мәдинә-Акчәчкә кебек мең-миллионнарның да йөрәк моңы табигатьтәге вак һәм зур әйберләр хәрәкәте моңы

белән бәйле түгелмени? Ничек кенә бәйле әле. Әгәр Хөрмәтулла абзый шул йодрык зурлыгы гармунын сайратып җибәрсә, Мәликә түти белән Мәдинә-Акчәчкә аңа кушылып җырласа, шул караңгы, бәләкәй өй эче мең өлеш яктырып, зураеп китәр, йөрәкләрне олайта, хозурландыра, ярсыта торган моң белән тулыр иде. Хөрмәтулла абзыйсының гармун моңын, Мәликә тутасының, Мәдинә-Акчәчкәнең җыр-моңын бик-бик тыңлыйсы килгән иде Галимҗанның. Әрнү-сагыш, шатлык-кайгы, яшәү-гомер итү тойгылары белән аралашкан ул илаһи моңны Йосыф агасына да ишеттерәсе иде. Тик Хөрмәтулла абзыйсында хәзер гармун уйнау дәрте ялкыны сүнгән шул инде. Балтырган җыеп кайткан Мәликә түти, Мәдинә-Акчәчкә, гәрчә шат йөзле булып күренергә тырышсалар да, шактый нык арыганнар. Хәер, аларның җыры, моңы турында бәйнә-бәйнә сөйләгән иде инде Галимҗан Йосыф мәхдүмгә. Хәзергә ул шул кешеләрне — моңлы йөрәкләрне күрсәтә алуына да канәгать. Киләчәктә, бәлки, моңнарын тыңларга да насыйп булыр. Өмет итик. Шайтан гына өметсез була бит ул.

Шундый уйлар дулкынында йөзде Галимҗанның күңеле. Алар сүзсез генә атлады. Бүген үк ул Йосыф мәхдүмгә авылның тирә-як табигатен дә күрсәтмәкче иде. Әмма ул фикерләреннән кире кайтты. Иртәгә дә көн бар лабаса. Барын да берьюлы кочакларга тырышып, һәммәсеннән мәхрүм калуың бар. Төшке ашка кайтып җитмәсәләр, аның югалуыннан болай да яраланган ананың йөрәге тагын да ныграк сызлаячак. Моны ул Йосыф агасына да әйтте:

— Мин Зәңгәр чишмә, Кондызлы күл, Исәнбикә болынын, Ямanташны күрсәтермен дигән идем, төшке ашка соңларбыз кебек,— диде.

— Авылның табигате, аның кешеләре белән горурлануыңны беләм, Галимҗан, барын да карарга, күрергә җитешербез әле, Алла боерса, ә менә Хөрмәтулла абзый янына алып баруың өчен мең-мең рәхмәт!..

— Нигә?

— Мин бәләкәй генә кешенең олы йөрәген аңладым.

Аның сүзләренә төзәтмә дә кертте Галимҗан:

— Мин кешеләрне бәләкәйгә, зурга аермыйм.

— Анысы шулай, Галимҗан. Бәләкәй төркемгә мин гавам халкын кертәм.

— Гавам халкы зур ул, Йосыф абый!

Йосыф мәхдүм мондый сүз башлавына үкенеп куйды. Галимҗан күп сөйләшергә яратмый. Юк-бар бәхәскә катнашмый. Буш сүз турында зур фикер йөртүне далада җил куып йөрүгә тиңли. Бу хакта аның үзенең дә чатнатып әй-

теп куйганы бар. Шәкертләр арасында зур фикер осталыгы күрсәтергә, сүз мантыйгының чынлыгын ачыкларга, чуалчык мәсьәләләрне анык-дөрес чишәргә кирәк булганда гына барып керә бәхәс дулкынына чумучылар уртасына. Ә бу — кеше турында сөйләшү — очсыз-кырыйсыз вакыт таләп итә. Үз фикерендә котырынган давылларда да селкенмәгән таштай торган Галимҗанны хәзер тынычландырырга кирәк иде.

— Әйе, Галимҗан, килешәм синең белән, безнең заманда кешеләрне вакка, зурга бүлү — җәһаләтлек-наданлыкның бер күренешедер ул.

* * *

Алар кайтып кергәндә, аскы катта ниндидер бәйрәм тантанасына охшашрак күңеллелек сизелә иде. Күрше-күлән, дус-иш, кардәш-ыру җыелган. Алар арасында Көнсылу белән Котлызаман да бар. Әптерәй һәм Кәтринә дә шунда кайнаша. Бер якта Әләксәй басып тора. Шакирҗан да, әтиләре Гыйрфан мулла да әйләнеп кайткан басудан.

Шәкертләр икесе бергә «әссәламегаләйкем»не әйттеләр. Аларның тавышлары моңлы, йомшак, ягымлы иде. Җавап урынына шундый ук күркәм тавыш белән «вәгаләйкемәссәлам» әйтелде. Йосыф мәхдүмнең һәммәсенә сөеп, эчке җылылык, миһербанлылык белән каравы, чибәр йөзе, Галимҗанның да шактый үсеп китүе барысының да игътибарын җәлеп итми калмады. Бер мәлгә карашып тору, күз карашлары белән дә исәнләшү булып алды. Шулай да ул озакка бармады. Иң әүвәл Көнсылу тәтелдәргә кереште:

— И Ғалимйән, йәнкисәкәйем, куркыттың бит, куркыттың, әсәйең, атайың ғына түгел, һинең капылғара шулай юғалу кайғыһыннан без зә ут йотоп йөрөнөк, Котлозаман ағайыңдың да телендә гел һин булдың, ай-һай-һай, бөтә ауыл халкының исе-акылы китте...

Сүзгә Котлызаман да кушылды:

— Эйе, Ғалимйән туған. Көнһылу еңгәң рас әйтә, был кайғыны бик ауыр кисерзек, инде Хоҙай быннан ары башкаһын бирмәһен...

Аның сүзләрен Әптерәй куәтләде:

— Бес тә уштан языр чиккә еттек, Галимьян, телепестә гел син пулдың; әле пына кайтканыңны ишеттек тә парыпыс та килеп тә еттек...

Галимҗан Йосыф мәхдүмгә әтисе-әнисенең башкорт, чуаш дуслары булуы, аларның башкарак тел белән сөйләве, килеш-килбәт, буй-сыннары хакында да әйткән иде инде. Шуңа күрә әле менә аларның кем икәнлекләрен аңлатып тору-

ны кирәк тапмады. Ул хәзер бер хакыйкатьне, кем әйтмешли, төбе-тамыры белән аңлады: бу ахмаклыгы ата-анасын, туган-тумачасын гына түгел, барлык дус-ишләрен, аларга теләктәшлек күрсәтеп яшәгән бөтен авыл халкын, тирә-якны зур кайгыга салган. Ата-ананы санга сукмау, бер гөнаһның тамырлары бик ерак китү, аның әллә кемнәр, әллә кемнәр йөрәгенә кара шытым булып керүе, иҗтиһадлылыкны югалту, мин-минлек... искиткеч куркыныч хәл икән.

Галимҗан, өй эчендә ертык-мыртык киемле кешеләр дә булганы өчен, Йосыф мәхдүм алдында берникадәр кыенсынды да. Чуаш Әптерәй аеруча кылка киемнән иде. Киндер күлмәк, киндер ыштан, озын сары чәч, сары сакал аны бик котсыз, ямьсез күрсәтә. Бакча карачкысы итеп куйсаң, бер генә кош-корт та якын килмәс иде. Шулай да моның өчен ул артык нык борчылмады. Чөнки Йосыф мәхдүм, бәгъзе бер аксөяк кебек, кешеләргә югарыдан торып караучы ваемсыз зат түгел.

Чыннан да, Йосыф мәхдүмнең башында андый уйның әсәре дә юк иде. Ул үз әтисенең зыялы мулла икәнлеген яхшы белә. Әмма алар ихатасына ертык-мыртык киемле, чабаталы мужиклар бик аяк басмый. Эче караңгының йөзендә нур булмас, ди. Мондагы кешеләрнең йөзендә нур балкып тора. Димәк, эчләре караңгы түгел. Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай шундыйлар белән дә дус була, адәм балаларының кадерен белә торган зат икән. Бу үзенчәлекләре Галимҗанга күчкән. Шулай булмаса, үлем белән көрәшеп яткан Хөрмәтулла янына алып барыр идеме аны? Алып бару гына түгел, аның язмышын үз йөрәгенә ала бит әле ул. Аның өчен сызлана, өзгәләнә, аны үлем авызына вакытсыз китереп тыккан комсыз Мөбахис мәзинне күралмый.

Җыйнаулашып көндезге ашны ашаганда да, чәй эчкәндә дә бер-берсенә карата булган күркәм мөнәсәбәт, җылы караш, күңеллелек тойгылары сүнмәде-сүрелмәде. Иске кайгыны искә алу яңаны чокып чыгара, ди. Иске кайгыны берәү дә телгә алмады. Ходай яңасын күрсәтмәсен. Гыйрфан мулла да бу күңелсез хәлне кара йөз күрсәтеп түгел, якты чырай белән капларга тырышты. Хәтта мәзәк сөйләп, мәҗлесне җанландырырга, килүчеләрнең күңелен күтәрергә тырышты, вакыт-вакыт көлдереп тә алды. Хәзер инде Йосыф мәхдүм алдында Галимҗан әтисенең күңел күге икенче бер сыйфаты белән ачылды — шаян табигатьле дә икән әле үзе. Хәзер инде ул эчтән генә үзен тиргәп тә утырды. Әллә кая алып китеп, әтисен-әнисен, туган-тумачасын, дус-ишләрен авыр кайгыга саласы калмаган. Их, бу тилелек! Их, бу наданлык! Их, бу акыл җитмәү бәласе!

## VI

Йосыф мәхдүм Солтанморатта ике атна чамасы кунак булды. Болай озак торырмын дип һич тә уйламаган иде ул. Өч-дүрт көннән дә арттырмаска иде исәбе. Ләкин төрле сәбәп чыкты да торды. Сәбәпсез сәнәк тә урыныннан кузгалмый, агач яфрагы да селкенми, дигәнне дә яхшы белә. Сәбәпкә сылтанып, кеше мазасызлап яшәү һич тә муафыйк эш түгел, ваемсызлык була. Ләкин аны җибәрмәделәр. Ул халыкның «Кунак — беренче көнне алтын, икенче көнне — көмеш, өченче көнне — бакыр» дигән сүзләрне дә әйтеп көлдерде. Яхшы-акыллы кунак кояштай балкып килер, кояштай балкып китәр, кояшны болыт каплаган кебек, аның да йөзенә кара күләгә төшүе ихтимал кебек сүзләрне дә әйтеп карады. Әмма Гыйрфан мулла да сүз өчен кеше кесәсенә керә торган зат түгел икән. Ык-мык, кылдай-былдай килмәслек, боргаланыр-сыргаланырга урын калдырмаслык итеп чатнатып әйтә дә куя.

— Син ашыкма-кабаланма әле, Йосыф улым, «Сабыр төбе — сары алтын, сабыр иткән — морадына җиткән» дигәнне ишеткәнең бардыр,— диде ул бер сөйләшкәндә. Сабырсызлык-пырдымсызлыкны Мөхәммәт пәйгамбәр дә яратмаган. Ә инде Ягъкуб пәйгамбәр улы Йосыф пәйгамбәр, монысы үзегезгә дә мәгълүмдер, артык шашып, чыгырыннан чыгып, мәхәббәт кайнарлыгыннан ярсып барган Зөләйханы әнә ничек юата:

Сабыр берлә эшләгел ошбу эши,
Сабыр берлә эшләнер эшләр башы;
Морадына тиз йитәр сабырлы кеше,
Бу эш эчрә күрекле сабыр кылгыл имди.

Алар, һәр форсаттан файдаланып, озак-озак гәпләшеп, фикер алышып, бәхәсләшеп ала торган булып киттеләр. Ата-бабаларыбыз — болгарлар — кем булган? Мәҗүсилек чорында алар ничек яшәгән? Ни өчен күп Аллага табынганнар? Ислам динен болгарлар бик соң — унынчы йөздә генә кабул иткәннәрме? Әгәр без болгарлардан килеп чыкканбыз икән, аларның да чал тарихта ерак ата-бабалары булырга тиеш бит. Кемнәр алар? Һуннар, аланнар, сарматлар, хазарлар, кыпчаклар...— тагын да әллә нинди көчле кавем-ыруглар булган. Болар төрки телдә сөйләшкән. Кайда алар хәзер? Нигә комга сеңгән су кебек юк булганнар?

Гыйрфан мулла Троицкида шәкертләргә дин тарихыннан да сабак биргән иде. Аны кавемдәш-кабиләдәшләренең дә ерак тарихы кызыксындырды. Әмма ләкин, бу галәмнең чиксез-кырыйсыз икәнлеген һич тә күз алдына китерә алмаган

кебек, ерак кавемдәшләренең тарихы-тамыры кайдан килгәнлекне аслан ачыклый алмады ул.

— Ни өчен бәгъзе бер кабилә яши, тарих көзгесе була, тантана итә, ә икенчесе тапалган үлән кебек бетеп-череп кала? — дигән сорауга шәкертләр дә төпле җавап бирә алмады.

— Көчле көчсезне җиңә,— диде Йосыф мәхдүм.

Галимҗан да шулайрак әйтте. Әмма ул үз фикерен шаяртулар, чагыштырулар аша аңлатты:

— Вак балык — чуртанга азык; чуртан — акула ризыгы; акула — кит ашказанына майлы аш. Халыклар да шулай: вагын — эресе, эресен — аннан да эрерәге, аннан да эрерәген иң эресе йота. Бу — табигый хәл.

Боларны Йосыф мәхдүм дә белә иде. Шәкертләр арасында бермәл бәхәс вакытында бер алтын башлысы әйтеп салган иде. Тик мәсьәләне алай куертып, тирәнәйтеп сөйләүне ул килештермәде — кеше өендә ярамый: инсафлы булырга кирәк. Ә инде Галимҗанның олылар алдында үзен шулай зирәк күрсәтүе әтисен дә, әнисен дә гаҗәпкә калдырды. Ни дисәң дә, хосусан Шакирҗан вә Йосыф мәхдүм белән чагыштырып караганда, ул бит әле тай янындагы колын кебек кенә.

Хәлбуки бу минутта Галимҗанның янә җиде елдан — 1907 елда — Казанда чыгачак «Әль-ислах» газетасында «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясе басылачакны, тиз арада зур язучы булып китәчәкне, бер үк вакытта, җиң сызганып, әлеге кардәш-ыруг кавемнәренең ерак тамырын-тарихын өйрәнәчәкне, зур галим булып китәчәкне берәү дә белми иде әле. Һәр алсу таңның кичке шәфәкъ балкышы, һәр караңгы төннең якты көне булачак һәрберсенә биш бармагы кебек мәгълүм. Әмма Галимҗанның киләчәктә Йосыф пәйгамбәр кебек җитмеш төрле һөнәр иясе булачагы берәүнең дә ике ятып бер төшенә дә керми әле.

...Йосыф мәхдүмне барысы да: Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай, Шакирҗан, кардәш-ыру, туган-тумача, дус-иш нык яратты. Тиз генә җибәрмәскә тырышуның бер сәбәбе шул иде. Алар өчәүләп — Йосыф мәхдүм, Шакирҗан, Галимҗан — даими рәвештә балыкка йөрде. Кондызлы күл, Зәңгәр чишмә буйларында, Исәнбикә болыннарында булу, Түрсәгәле белән Авыргазы елгасы кушылган урыннарны күрү, Солтанморатның искиткеч матур табигате белән ләззәтләнү, хозурлану аларның күңелен илаһиландырып, хис-тойгыларын баетып җибәрде. Мондагы бәгъзе бер чәчәкләрнең озынлыгы, арттырып әйткәндә, кеше буедай булыр. Аларның башы — үзе бер гөләп-йөз төрле төс белән нәкышләнгән гөл бәйләме. Йосыф мәхдүм көннәрдән бер көнне бу халыкка

Ходай Тәгаләнең ни өчен мондый оҗмахтай ямьле урын бирүе, ни өчен авылның Солтанморат дип аталуы белән кызыксынды.

Моны аларга Гыйрфан мулла бәян кылды:

— Һәр кавемнең, һәр ыругның, һәр кабиләнең, һәр халыкның чишмә башы була, балалар,— дип сөйләп китте ул, инде яртысы диярлек көмешләнгән, йөзенә гаярьлек-сөйкемлелек, бераз кырыслык биреп торган матур, түгәрәк сакалын сыйпап, җитдилек өчен чын көчле ирләрчә тамак кырып.— Бу хосуста без берникадәр гәпләшеп алган идек инде. Хосусан ата-бабаларыбыз, аларның яшәү рәвеше, иҗтиһадлылыгы, килер буынга, ягъни дә мәсәлән, безгә, нинди рәк эзяктылык калдырулары хакында. Бәс, шулай булгач, сүзне асла дилбегә буе сузмыйча, кыскача гына әйтәм. Мәгълүм ки, һәр чишмә бу якты дөньяга мең газап-авырлык чигеп, тауташ күкрәген бәреп чыга. Чишмәнең чыгышы нинди — суы агышы да шундый. Көмештәй ялтырап чыга икән — суы да көмеш. Иштә безнең Зәңгәр чишмәнеке кеби. Шуңа күрә андый саф чишмәгә кадер-хөрмәт тә, гавам халкының дикъкате дә, ихтирамы да зур. Аны күз алмасыдай хис кылып саклыйлар. Ә инде чишмә суы көмештәй ялтырап түгел, бакыр төсле булып чыкса, һаман шулай агып торса, бәндәләр аңа чырай сытып карый.

Шуннан мулла абзый, артык җәелеп китмәдемме дигәндәй, остабикәсенә, башкаларга күз сирпеп алды. Ул, мөдәррис-мөгаллим буларак, сүз җилемен һәрвакыт бертөрле тартып торуны яратмый, вакыт-вакыт, җае килеп чыкса, сүз тәменә, аның сәнгатенә әллә ни зыян китермичә, көлдереп тә ала иде. Бу юлы да шулай итте. Әлеге «бәндәләр аңа чырай сытып карый» дигәнгә «кара чырайлы усал хатын йөзенә караган ир-ат кебек» дип куйды. Барысы да, шаулашып, бер көлешеп алдылар.

Хәсәнә абыстай, ансын алай, монсын болай итеп, тавык чүпләсә дә бетмәслек үз шөгыленә күмелеп, ихлас күңелдән мөкиббән эшләп йөрсә дә, болар сүз-фәлсәфәсенә дә һич тә игътибарсыз түгел иде. Кулы — эштә, колагы мулласының авызында булды. Барлык мөселман хатын-кызлары кебек, ирләр сүзенә катышырга яратмаса да, бу юлы үз фикерен әйтми булдыра алмады:

— Сиңа әйтәм, атасы, ни эшләп әле олы башың белән шәкертләр алдында шундый мәгънәсез сүз әйтеп утырасың? — диде.

Гыйрфан мулла җилкәсен кашып куйды:

— Ник мәгънәсез булсын?

— Йөзе кара булса да, күңеле актыр, бәлкем, ул хатын-

ның. Ак түтинеке кебек. Кемнең эчендә нинди асылташ ятканны кем белә.

Галимҗан түземсезләнә башлады:

— Әткәйне бүлмик әле, әнкәй!

Гыйрфан мулла янә тамак кырып куйды:

— Әйе, бүленгән сүз — өзелгән чылбыр. Аны соңыннан ялгау бик кыен була. Хәзер ялгыйбыз, Алла боерса. Әйе, кабатлап әйтәм, һәр кавемнең чишмә башы булган шикелле, һәр авылның да, ягъни мәсәлән, Солтанморатның да, чишмә башы, үз тарихы бар. Аллаһы Тәгалә бу урыннарга уңдырышлы җир, күркәм табигать, чәчкәле болын, көмеш сулы чишмә, мыжылдап торган балыклы күл, елгалар биргән. Ходайга шөкер, бу яктан бәхетлебез. Авылның исеме дә бик күркәм, мәгънәле, олылыклы. Солтан — гарәп сүзе. Патша, хөкемдар дигәнне аңлата. Солтанат дисәк, мәһабәтлелек, олылык, зурлык кеби төшенчәләр аңлашыла. Морат та — гарәпнеке. Максат, теләк, теләгән әйбер, аңлатылырга, белдерелергә уйланган нәрсә. Бәс, шулай булгач, сезгә һәммәсе биш бармагыгыз кеби мәгълүм инде. Кыскартып әйтсәк, Солтанморат мәһабәтлелеккә, зурлыкка ирешү өчен максат куеп яшәү була. Бу изге максатны аклый алдымы Солтанморат халкы? Аклады. Зәңгәр чишмәнең дә суы әйбәт. Саф. Пакь. Ләкин дә ераграк. Авылга су кертергә кирәкме? Кирәк. Имән торба ясап, авылга кем су кертте? Солтанморат халкы. Чөнки ул иҗтиһадлы, эшчән, батыр йөрәкле.

Аның сүзен янә Галимҗан бүлде:

— Ялкаулары да җитәрлек, әткәй!

— Бармаклар да тигез түгел, улым!

— Ә шулай да?

— Басудагы игенгә дә бәһане бер ялкау кишәрлегенә карап бирмиләр. Тормыштагы кара якларга гына карап яшәсәң, алтын базыннан чүп эзләүчегә әверелүең бар.

— Ярый, әткәй, хәзер авылның ни өчен Солтанморат дип аталуын, аның кем булуын әйт инде безгә.

— Солтанморатмы? Ул гаярь, йөрәкле, каһарман кеше булган. Бу урынны аңа патша зур көрәштә батырлык күрсәткән өчен биргән. Иле, халкы, Ватаны өчен теләсә нинди утка, суга керүдән аслан курыкмаган. Әмма ләкин авылыбыз халкы бик чобар. Әллә кемнәр, әллә кайлардан килеп җайлашканнар. Шулай бит ул: әле генә Галимҗан әйтмешли, чуртан вак балыкны йоткан кебек, эре дулкыннар вак дулкыннарны тарткан шикелле, зур авылларга бәләкәй авыллар күчүчән, аңа матурлыкны үзе төзи алмаган юка җилкәләр кызыгып караучан...

Бу юлы аны Шакирҗан бүлде:

— Әткәй, авыл халкының чобар булуы нәрсәне аңлата?

Ата кеше, иркен тын алып, янә һәрберсенә җәһәт кенә күз сирпеп, монысын аңлату шактый кыен-авыр, дигән төс күрсәтеп, бераз аптырабрак торганнан соң, тагын да сөйләп китте:

— Ул бит, балалар, әлеге дә баягы тарих вакыйгаларына, бәндәләр язмышына, яшәү рәвешенә бәйләнгән хәл-әхвәл күренешләре. Зур тарих кешеләрнең күңел сәхифәләренә языла бара. Бер акыллы баш әйтмешли, алтын хәрефләр белән. Ул хәрефләрнең күбрәге, дәхи дә күңел иләгеннән үткән иңиң эреләре, зирәк-зиһенле-акыллы затларның ми күзәнәкләрендә. Бу күзәнәкләрдәге акыл энҗеләре икенче алтын башның ми күзәнәкләренә күчә бара. Аны, Ходайга шөкер, иҗтиһадлы галим кешеләр китапка терки. Теркәлмәгәне, монысы үзегезгә мәгълүм, күңел китабына языла. Ул «чобар» турында, соңыннан укып карарсыз, әнә теге Коръән эченә дә бер кәгазьгә язып салган идем. Сезгә әле ерак буыннардан килгән тарих галәмәтләренең бүгенге көнгәчә бәндәләр күңеле аша килеп җиткәнлеген бәян итәм. Болай, 1691 сәнәдә, ягъни дә мәсәлән, елда бик каты ачлык була. Кайда дисезме? Казан якларында. Идел буенда. Үләннәр корый. Җирләр ярылып кибә. Малга, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, табарлык бер бөртек үлән булмый. Атлар, сыерлар, сарыклар, кәҗәләр тәгәрәп үлә, бәндәләр чебен урынына кырыла...

Гыйрфан мулла, шул урынга җиткәч, тамагына таш утырып, кинәт тыны кысылган кешедәй, сүз чылбырын капыл өзеп куйды. Нигәдер аның киң маңгае җыерылып, әле яшьләрнекедәй гайрәт чәчеп торган күз карашлары моңсуланып калды, йөзендә кайгы-борчылу күләгәсе хасил булды. Моның моннан ике йөз елдан артык элек яшәгән кешеләрнең фаҗигасен, авыр язмышын үз йөрәгенә алу икәнлекне аңлау кыен түгел иде. Хәтта аның берникадәр күңеле тулып китү хәтлесе дә сизелде. Тик ул йомшаклыкка бирелмәде, мәмрәп төшмәде, тиз арада үзен кулга ала белде. Ә тыңлаучылар «хикәят»нең дәвамын түземсезләнеп көтте:

— Шуннан? — дип куйды Галимҗан.

— Шуннан...— дип, янә берникадәр сүзсез торгач, күңеле белән һаман шул ач халыклар арасында йөргән хәлдә, хис-тойгыларны йөгәнләп, салкын канлы булырга тырышып, җай гына сөйләп китте: — Шуннан... Богдан Ирбулат улы Әхмәтов хәләл җефете һәм күп балалары, кардәш-ыру, туган-тумача, таныш-белеш, дус-ишләре белән бай табигатьле, уңдырышлы туфраклы башкортлар җиренә күчәргә булалар. Күчәләр. Ни өчен, ягъни дә мәсәлән, безнең авылда Богдановлар күп? Әнә шуңа күрә. Менә сезгә бер чобарлык. Инде икенчесе. Бусының тарихы, Ходай үзе шаһит, тагын да ераграк, әллә кайда, әллә кайларда. Уникенче гасыр башында ук әле пол... пол... поляклар һөҗүме була.

Хәзер егерменче гасыр башымы? Әйе, егерменче гасыр башы. Димәк ки, сигез гасыр элек була бу хәл. Сигез йөз ел элек. Урыслар белән дә су болгана. Шуннан... Сембер җирендә гомер иткән Алатыр мишәрләре күчмәк була якка. Әнә бай җир кайдагы адәм балаларын үз кочагына тарта. Алатыр мишәрләре бармы Солтанморатта? Бар. Күп. Дәхи дә бер чобарлыкмы? Дәхи дә бер чобарлык. Менә бит аның хикмәте кайда? Шуннан... киң күңелле башкорт дуслар үзләре бер урам төзи. Янә бер чобарлык. Тегеннән-моннан да күп күчеп киләләр Солтанморатка. Менә бит ул ничек. Кояш нуры барлык тереклекне үзенә караткан кебек бу. Безнең нәсел-нәсәпнең җиде буыны, яхшы оя эзләгән сыерчык шикелле, төрле урында җылы оя эзләп йөри. Солтанморатка минем картәти Әхмәтне Бөре өязеннән чакыртып китерәләр. Ул анда ахун булган. Мәдрәсә тоткан. Үзе белән шәкертләрен дә алып килгән.

Сүз һаман әле су буе сузылгач, Гыйрфан мулла, һәрберсенә җиттеме инде дигән караш ташлап, туктарга кирәклекне белдерде. Хәсәнә абыстай да, шәкертләр дә бу сөйләшү өчен бик канәгать иделәр. Тел белән әйтмәсәләр дә, күңел балкышлары шуны сиздереп торды.

## VII

Көннәр, бер-бер артлы җепкә тезелгән-теркәлгән гәрәбә кебек, үз җае, шау-шуы, мәшәкате белән үтеп торды. Сабантуйлар гөрләп үтте. Ул көннәрдә Гыйрфан мулла, яшь егетләрчә мең мәртәбә дәртләнеп, шул ук вакытта Тулпарының чабышта сынату-сынатмавы турында борчылып, аһ-уһ килеп йөрде. Моның белән ул әллә ничә ел шөгыльләнә инде. Чабышкысы беренче урынны алса, түбәсе күккә тия, үзен гарше көрсидәге илаһи бер бөек — гали зат итеп тоя, ә инде андый бәхет тәтемәсә, борыны салына, җир тишегенә керер чиккә җитеп гарьләнә, атны да, үзен дә җәбегәнлектә гаепләп котырына. Башкорт дусты Котлызаман да ат ярата. Аларның күңел җебен, йөрәк кылларын әнә шул ат мәсьәләсе бәйләде дә. Аю гәүдәле, карап торуга ук әкияттәге Сәетбаттал батырны хәтерләтеп торган Котлызаман көрәштә дан тотты. Шуңа күрә сабантуй мәйданына атын түгел, үзен әзерләде. Әмма ат җене кагылган, атның колын чагында ук басып торышы, күз карашы, боты, бәкәле, башын ничек тотуы буенча ук нинди булачагын эчке сиземләве белән аңлаган башкорт чабышка һич тә битараф булмады. Ул чабыш атлары үстерергә яратты. Туры биясе аңа болан баласыдай матур, үткер күзле,

ньк бәкәлле колын бүләк иткәч, ул йөгерә-атлый Гыйрфан муллага килде:

— Мулла абзый, һәй, эттәгенәһе. Хоҙай Тәғәлә бирергә теләгән колына сығарып куйған юлына тигәндәй, аттан һинең дә, минең дә бәхет бар икән, Туры бейәм бөгән таңда карап туймаслык колын килтерҙе бит, Толпар тип исем куштым, теге әкияттәге толпар аттан мыскал да кәм булмаясак был, мин уни һиңә сабышка үстерәм,— дип такылдады.

Ике елдан соң аны Котлызаман Гыйрфан мулла кулына үзе китереп тоттырды. Бәясен сорагач, Котлызаманның кашы җимерелде, сөмсере коелды, әлеге бит очларындагы тавык йомыркасын хәтерләтеп торган бүлтәймәләре биеште:

— Һин, мулла абзый, мине түбәнһетәһең, әллә ниндәй бер мыйылдык, комһоз бәндәгә һанайһың; башкорт әйтмешләй, дуслык малга корылмаган, бүләк өсөн акса алырға мин бит оңкот әҙәм түгел,— дип үпкәләде.

Аңлады ул вакытта Гыйрфан мулла башкорт дустының йөрәген. Зур, эчкерсез, илаһи йөрәкне аңлап шатланды.

Атлар дөньясы — үзе бер зур хәят. Ниндиләре генә юк аларның. Күктә йолдызлар ничаклы, алар төре шулчаклы. Тулпар дигәне әллә шул йолдызларның берәрсеннән җибәрелгән җан иясеме? Булыр да. Тулпар — галәм киңлекләрендә очып йөри торган канатлы ат ич ул. Аның хакында әллә күпме риваятьләр йөри. Шуларның берсен Котлызаман мулла абзыйга сөйләп бирде:

— Бына һин тыңла әле, мулла абзый, акыллы тыңлар, дурак һөйләр, ти, әйҙә, мин шул элеккесә диуана булып калайым, һин акыллы булып кал.

Гыйрфан мулланың хәтере калды:

— Тукта әле, Котлызаман, әллә кайсы якка борма сүзеңнең тәртә очын, кайчан минем сине диуанага санаганым бар. Ә?

— Юк, юк, мулла абзый, былай шаярып кына әйтәм, якын күреп.

— Шулай диләр аны; әйдә, сөйлә, бүлмә.

— Бәй, шулай инде ул, мулла абзый, эйе, бына былай, мин бары тик кешенән ишеткәнемде әйтәм: «Атабыз Әҙәм менән Һауаны күктән ергә аткас, ер өстөндә кешеләр ишәйеп йәшәй башлағас, күктә тороп калган фәрештәләрзең дә ергә төшкөһө килгән. Улар, хәйлә табып, Алланы алдамаксы булғандар. «Ергә Әҙәм яраттың, улар унда гөнаһ кылалар, беззе лә ергә төшөр, без уларзы хөкөм итәрбез»,— тигәндәр. Алла ике фәрештәгә Әҙәмгә булған нәфсене биреп, гөнаһ эштәр кылмаска һүззәрен алып, береһен казый, икенсеһен мөфтөй итеп, ергә төшөргән. Шунан былар хөкөм итеп йөрәй башлағандар.

Бер мәлде ирле-катынлы берәүзәр казыйға хөкөмгә кил-

гәндәр. Был ирзең катыны шул тиклем һылыу булған, казый ирзе генә хөкем итеп, зинданга ултыртырға уйлаған, ә һылыу катынды үзенә алмак булған. Мөфтөй ҙә казый карарын хуплағас, ирзе зинданга ябып куйғандар былар. Бына хәзер былар катын өсөн талаша башлайзар. Катын да һәтти үк акыллы булған. Быларға шарт куйған: «Беренсе шартым шул: миңә доньялағы иң матур йөзөктө табып бирегез, икенсе шартым — хәзер хәмер эсегез. Кем күп эсә — мин шуныкы»,— тигән.

Теге икәү осоп йөрөп, катын һораған йөзөктө табып килтереп, тегенең камыш кеүек бармағына кейзереп куйгандар за кемузарзан хәмер эсергә тотонғандар. Катын был Маыззарға[1] ерәнеп карап торған-торған да ғәрлегеннән илай башлаған. Быны күреп, ике фәрештә, күктән төшөп, катынды күккә осороп алып киткән. Зөһрә үзенең йөзөгө менән күктә шул көндән бирле балкып тора башлаған. Ана, Зөһрә йондоз калай барлыкка килгән. Ерзе бик һағынған сағында, Зөһрә һылыу Толпарзы үз янына сакыра, ти. Сакыра ла уға эс серзәрен һөйләй, Ергә кайтып уны бер үбеп, көмеш шишмәләрендә битен йыуып ләззәтләнәһе килгәнде әйтә икән. Тыңлай Толпар. «Ә» тигәнсе атландырып, канаттарын йәйеп, кояш нуры тизлегеннән әллә нисә миллиард артык тизлек менән көнө буйы осоп, кискә уны тағы ла үз урынына илтеп куя икән. Бына ниндәй ул Толпар».

Гыйрфан мулла аны исләре китеп, илаһи бер мөкиббәнлек, хис-тойгылар давылы белән тыңлады. Котлызаманның хәләл җефете Көнсылуның телгә оста, тәтелдәп-чәтрәнләп торуын, вакыт-вакыт сандугач булып сайравын, йөрәккәеңне өзеп ташлардай тирән моң белән җырлавын, чылтырап аккан Зәңгәр чишмә тавышлары чыгарып көлүен, талдай нечкә билен чегән кызлары кебек бөгелдерә-сыгылдыра йөрүен белә ул. Кыскасы, бер болын-дала чәчкәсе инде. Баштарак, танышканның тәүге мәлендә, ни эшләп бу болын чәчәге аю гәүдәле, куркыныч кара йөзле, тупас кыяфәтле Котлызаманга барды икән, дип уйлый иде. Котлызаман тыпырдатып бии дә бит әле ул. Биегәндә, аяк табаннарыннан ут чәчри кебек. Бу вакытта инде аның аю гәүдәсе бөтергечтәй уйнаклап тора. Ике кулын бөркет канатына охшатып җәеп тә җибәрсә, менә-менә күккә очып китәр сымак. Мондый чакта аның шомырт кара күзләре очкынлана, кара йөзендә ниндидер дәртләндергеч нур уйный, үзе белән бергә әлеге бит очларындагы тавык йомыркасыдай бүлтемнәр дә бии. Бу мизгелдә

[1] Мавыз — куркыныч әби рәвешендә күз алдына китерелгән мифик зат, убыр әбие.

Гыйрфан мулла аннан аз гына көнләшеп тә куя. Нигә ул да шулай түгел? Нигә өздереп биергә өйрәнмәгән? Аның да яшь чагы булды лабаса. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, диләр. Бию — шул һөнәрнең берседер әле ул. Әтисе алдашмаска, иҗтиһадлы булырга, хезмәт сөяргә өйрәтте, иман нуры белән яшәргә кушты. Әмма ләкин даими рәвештә мөселман халкы өчен бию, кычкырып җырлау, музыка, рәсем сәнгатенең гөнаһ булуы турында әйтеп тора иде. Әнисе дә шул рухта тәрбияләде. Дин кушмый, янәсе. Аллаһы Тәгалә тарафыннан тыелган. Мөхәммәт пәйгамбәр бу хакта үзе ничегрәк фикер йөртте икән? Әллә уйларга вакыт-форсат булмаганмы? Гавам халкы таба лабаса җаен. Уйный. Көлә. Бии. Җырлый. Соңгы тиененә гармун сатып ала. Сигезәр-унар бала үстерә. Ач. Ялангач. Торырга юньле куышы юк. Әмма күңел ача белә. Барлык кайгысына, авырлыгына төкереп яши. Бу яктан да ул вакыт-вакыт алардан көнләшеп куя. Хөр күңелле, кешелекле, гади-садә булганнары өчен.

Ә инде Котлызаманның ат кадәр ат бүләк итүе, шундый илаһи йөрәкле, олы җанлы, матур күңелле булуы Гыйрфан мулланы дөнья, яшәеш, кешелеклелек турында тагын да тирәнрәк уйланырга мәҗбүр итте. Әлбәттә, бу бүләкне ул бише белән кайтарачак. Бер яхшылыкка биш яхшылык эшләү аның канына сеңгән. Әтисе мәрхүм дә шулай иде. Таш атканга аш белән атарга өйрәтте. Монысы авыр мәсьәлә, билгеле. Бер дуңгызы сине котырган үгез урынына сөзәргә килсен, ә син аның юлына ак җәймә җәеп тор, алапай ач авызына ризык-нигъмәт сал, имеш. Нишлисең, яхшылык, кешелеклелек җиңсен дип яшисең. Моны аңламаган чучкалар да бар. Ә бәгъзе берсе аңлый. Ташына аш бирсәң, бервакыт алдыңа килеп тезләнә. Ә син иркен тын алып куясың: бер дуңгыз бәндәне яман уйлардан коткардым, янәсе.

Котлызаман кебек тышы салкын, эче ялкын, тышы котсыз, эче гәүһәр булган кебекләр күп, билгеле. Ходай бәхетне һәммәсенә өем-өем бирсә, ай-һай ла, шәп булыр иде дә бит. Ләкин...

Ярый, монысы бер хәл. Хәзергә икенчесе шул: Котлызаман биргән Тулпар сабантуйда беренчелекне алды. И аның матурлыгы. Илаһым! Төсе — бурлат. Елкылдап тора. Шәфәкъ нуры белән төренгән диярсең. Бармак очы тидерергә дә куркып торырлык. Тигезсәң, әлеге елкылдап торган шомалык, шәфәкъ нуры япмасы бозылыр төсле. Ялы — ефәк көлтәсе. Ул әле җем-җем итеп тора. Күз явыңны алырлык. Башы аның, горур егетләрнеке кебек, һәрвакыт югары. Маңгаенда — йолдыз. Әйе, әйе, йолдыз. Әллә Зөһрә йолдыз үземе? Зөһрәне дөньясыннан Җирне үбәргә алып төшүче Тулпар шушы үземе?

Сабантуйда беренче килгәч, аңа сокланмаган кеше калмады. Матур кыз кебек бит бу, дип кычкырды кемдер. Ә Тулпар, гүя моны ишетеп, шуны аңлап, башын һаман югары тота, чибәрлеге белән мактанып тора, ярсыганлыгын да сиздерми.

Чабышка аның өстендә Котлызаман улы Хәерзаман барган иде. Бу исә ике гаиләнең дуслыгын мәңге өзелмәс алтын чылбырлар белән бәйләп куйды. Гыйрфан мулла бер кысыр бия, өч сарык чалып, бөтен авылны бәйрәм иттерде. Күрше-күлән, ярлы-ябагай, дус-иш, кардәш-ыру... берсе дә калмады. Һәммәсен сабантуй шатлыгы белән сөендерде. Чөнки бу аныкы гына түгел, бөтен Солтанморат даны иде. Ә инде авыл даны — бәләкәй төшенчә түгел. Котлызаманга исә бер сөтле сыерын бүләк итте. Хәерзаманны баштан алып аягына хәтле чем-ясау итеп киендерде.

...Йосыф мәхдүм сабантуйлар үткәч китәргә җыенды. Ләкин әлегә кайда укыячаклары мәсьәләсе төене һаман әле чишелмәгән килеш кала килде. Ул төенне чишәргә Гыйрфан мулла да артык кабаланмады. Нингдидер бер җае чыгар кебек тоелды. Ашыгып ашка пешүдән курыкты. Әлбәттә, Йосыф шәкертнең кылын кат-кат тарткалап карады:

— Йосыф улым, үзең теләсә нишлә, тик мин Галимҗанның әллә кая китеп югалуын һич мәслихәт күрмим бит әле, — диде бер сөйләшкәндә.

Бу минем өчен һич тә катлаулы мәсьәлә түгел дигән кыяфәт күрсәтеп җавап бирде Йосыф:

— Мин аны көчләмим, котыртмыйм да, мулла абзый, үз иркендә...

Хәсәнә абыстай белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә дә шундыйрак сүзләр әйтте.

Соңгы чиктә Шакирҗан белән киңәшләшеп карарга булды ата кеше:

— Син, Шакирҗан, Галимҗанга ага кеше ләбаса, энеңнең язмышы бер дә борчымыймыни соң, һаман шул элеккечә гамьсез күркә кебек йөри бирәсең, — диде.

Ата кешенең бу сүзләре Шакирҗанның рухын җимерде. Ул бөтенләй икенче төс алды. Берникадәр усаллык галәмәте күрсәтмәк булды. Чөнки «гамьсез күркә» дигән атама гарьләндерде аны. Шул эчтә кайнаганны әйтми калмады:

— Гомер буе мин сезнең өчен «гамьсез күркә», Галимҗан «пәйгамбәр» булды, әткәй, аны, артык иркәләп, үзсүзле иттегез, болай ук кирәкмәс иде.

— Соң, балам, чирләшкә булды бит, шуңа күрә күбрәк игътибар аңа бирелгәндер инде.

— Мин әнине кызганам. Галимҗан Казанга китсә, ул нык борчылачак. Әни йөрәген тоткалый. Авырта шикелле. Безгә сиздермәскә генә тырыша.

— Әниең өчен үрсәләнүең әйбәт. Минем хакта аз гына булса да уйламыйсызмыни?

— Минем өчен икегез дә бер. Ата-ана бала өчен ике канат. Тапшырыгыз Галимҗан эшен үземә. Мин аны алып кала алам. Сез уйлаганча, бер дә «гамьсез күркә» түгелмен.

Бу сүзләрне Шакирҗан бик тыныч кына әйтте. Тик ул тынычлык эчендә көчле давыл бар иде шикелле. Ул давыл җиңү көче булып тоелды. Шакирҗан улы гүя атасы алдында кинәт кенә янә бер карышка үсеп китте.

* * *

Шакирҗан Галимҗан белән үзе генә сөйләште. Әлбәттә, «синең сәламәтлегең начар», «еракка китәргә ярамый», «уку кайда да бер» кебек үгет-нәсихәт бирә торган сүзләр әйтүдән сак булды ул. Галимҗанның холкын белә. Андый сүзләр аны ярсытып кына җибәрәчәк.

Йосыф мәхдүм шигырьләр яза икән. Үзе өчен генә булса да. Киләчәктә шагыйрь булып китә алырмы-юкмы — анысын бер Ходай үзе белә. Ләкин шигырь язган кеше барыбер шагыйрь йөрәкле була. Шагыйрь йөрәклелек адәми затны зыялы, матур күңелле, хис-тойгылы итә. Мондый үзенчәлек Галимҗанда да сизелә. Мандолина уйный. Җырлый. Дөрес, ул боларны беркемгә дә сиздермәскә тырыша. Күрәсең, үзенең әле бик оста уйнамаганлыгын, җырламаганлыгын аңлый. Ул бит җиңеп яшәргә ярата. Кешедән түбән буласы килми. Ул табигать матурлыгына исе китеп, илаһи бер соклану, гаҗәпләнү белән карап тора. Кешеләр язмышы өчен борчыла. Китаплар күп укый. Вакыт-вакыт язарга теләге булуны сиздереп куя.

Быел яз Шакирҗан укыган «Хөсәения» мәдрәсәсенә мөдәррис булып бик зур язучы киләчәге турында хәбәр таралды. Кайчан киләчәген тәгаен генә әйтүче юк. Мәгәр бик гыйлемле, зыялы, гали зат, имеш. Ә үзенә егерме яшь чамасы гына икән. «Тәгаллемдә сәгадәт», «Кәләпүшче кыз» әсәрләре, «Бай угылы» романы, «Өч хатын берлә тормыш» драмасы язган, ди. Шулар өстенә тагын «Теләнче кыз» романының беренче кисәген тәмамлаган икән.

Шул хакта сөйләп биргәч, Галимҗанның күзләре шардай булды, йөзе яктырып китте, шул ук вакытта уйчанланды да.

— Кем икән соң ул? — дип сорады, бераз тын торгач.

— Гаяз Исхакый, диләр.

Галимҗан Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин кебек фикер ияләрен, галимнәрне, укымышлыларны яхшы белә. Каюм Насыйриның 1895 елда нәшер ителгән «Әнмүзәҗ» исемле хезмәтендәге кагыйдәләрне ят-

лый-ятлый, башы диңкеп беткән. Гаяз Исхакый хакында да әллә күпме имеш-мимешләр йөрде. Имеш, аның татар Пушкины булыр чамасы бар. Пушкин сүзе Галимҗан йөрәгенә аеруча якын. Мөгаллим Сәет авылдагы өчьеллык урыс мәктәбен яхшы тәмамлаганы өчен Пушкин әсәрләре белән бүләкләгән иде бит аны. «Пушкин — унтугызынчы гасыр урыс әдәбияты пәйгамбәре, ә син, Галимҗан, егерменче гасыр пәйгамбәре бул,— дигән иде. Әнә кем алыштыра икән татарда Пушкинны. Гаяз Исхакый дигән бөек зат. Егерме яшендә әллә күпме әсәрләр язып өлгергән. Галимҗан Пушкинның «Капитанская дочка» дигән әсәрен әллә ничә кат укып чыкты. Аның теле дә бик сәнгатьле кебек. Эчтәлеге дә кызык, мавыктыргыч. Пугачевның язмышын белү генә ни тора. Тик... аңлап бетереп булмый. Әлеге татарда Пушкинны алыштырырдай пәйгамбәр Гаяз Исхакыйның шул «Капитанская дочка» дигән әсәрен татарчага тәрҗемә итүеме, итәчәгеме турында да сүз йөрде. Шәкерт колагы күпне ишетә, шәкерт күзе күпне күрә, шәкерт аягы күп йөри. Дөрес, мондый яңалыклар күбрәк дини китаплар белән генә чикләнмичә, качып-посып барып булса да, кибеттән төрле-төрле әсәрләр сатып алып укыган алдынгы, мәгълүматлы, зиһенле шәкертләр авызыннан чыга. Берсе элеп алса, икенчесе селкеп сала, өченчесе дөньяга тарата; шуннан авыздан чыккан хәбәр канатлы кошка әверелә, шәһәр буйлап очып йөри, тәрәзәләрне, ишекләрне ватып кереп, кешеләрнең колаклары аша күңел сандыгына үрмәли.

— Мин сине үз яныма, «Хөсәения» мәдрәсәсенә алырмын, Галимҗан, ул Гаяз Исхакый кебек бөек кеше кулында уку безгә бик күңелле булачак,— диде дә озак-озак Ырынбурга китәргә өндәде энесен.

Галимҗан барыбер тиз генә җавап бирмәде. Чөнки аның Йосыф мәхдүмгә биргән вәгъдәсе бар ич. Шулай итеп, ул ике ут арасында калды.

— Ярый, абый, иртәгә әйтермен: кичке акыл — ярты, иртәнге акыл — бөтен, диләр бит,— диде.

* * *

Озак уйланып ятты Галимҗан. Йокыга таң алдыннан гына китте. Һәм гаҗәп уйландыргыч төш күрде. Имештер, Казан белән Ырынбур арасына салават күпере тартылган. Галимҗан яланаяк килеш шуны үтәргә тиеш. Бәй, читенә килеп басса, атлап китим дисә, салават күпере сират күперенә әверелә. Ул кылдан нечкә, кылычтан үткер икән. Шуны белеп, Галимҗан кире чигенә. Әй тотына йөгерергә, хәлләре бетә, күзләреннән утлар чәчрәп чыга. Шуннан ул «куркак»

дигән тавыш ишетә. Артына әйләнеп караса, күктә бер фәрештә талпына. Шул кычкырган икән. Ул янә тавыш бирә: «И куркак адәм баласы, сиңа бит бу сират күперен барыбер бер үтәргә туры киләчәк, яшь, гөнаһсыз чагыңда тәвәккәлләвең мең өлеш яхшырак булачак»,— ди.

«Куркак» дигән сүз Галимҗанның ачуын китерә, җенен кабарта, үрле-кырлы сикертә. Йөгереп-чабып килә дә ул сират күперенә менеп тә китә. Чыннан да, кылдан нечкә, кылычтан үткер икән. Ләкин, ни гаҗәп, ул бара да бара, кош җиңеллеге белән бара; кылыч аякны кисми дә, канатмый да. Димәк, аның, фәрештә әйткәнчә, бернинди гөнаһы юк әле. Аска караса, гаҗәеп матур күренеш: гөлбакча, җимешлек, кәүсәр күле, хур кызлары... «Син, акыллы зат, оҗмах өстеннән үтәсең» дип кычкыра әлеге фәрештә. «Үткәч, оҗмахта хур кызлары белән бергә яшәрсең». «Миңа оҗмах та, хур кызлары да кирәкми, минем җирдә яшисем килә» дип кычкыра Галимҗан. Шуннан кинәт кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күпере өзелеп китә, Галимҗан оҗмахка оча. Ләкин оҗмах түгел, тәмуг уты булып чыга бу. Яна. Яна. Яна. Әмма күмергә әйләнми Галимҗан. Әллә нинди утлы чүкечләр белән башын төяләр. Утлы кылычлар белән телгәләп бетерәләр. Шулай да ул тышкы кыяфәтен югалтмый. Мең, миллион, миллиард еллар гына түгел, мәңге-мәңге шулай булачак, диләр аңа. Бервакыт икенче тавыш ишетелә: «Юк, ул мәңге янмаячак, аны җиргә кире кайтарам, ул әле гөнаһсыз». Бу әлеге фәрештә тавышы икән. Фәрештә аны җәһәннәм төбеннән тыны белән тартып чыгара да үз ягына ала, канатларына утыртып, җиргә китереп куя. Бәй, бусы нәрсә инде моның тагы да: фәрештә әлеге Ырынбурга киләчәк яңа хәлфә Гаяз Исхакый булып чыга. Әмма Ырынбур дигәне Казан каласы икән.

Уянгач, озак кына уйланып ятты Галимҗан. Ырынбурга китәм дисә, янә Казанга барып чыккан. Төштә күргәннең киресен эшләргә кирәклек аңа мәгълүм инде. Ул, димәк, Ырынбурга китәргә тиеш. Юк, төш кенә аны җиңмәде. Көндез бер уй давылы эченә кереп чумсаң, шул төшеңә керми калмый. Төш сине әллә нинди кыяфәтләргә кертә. Монда икенче мәсьәләнең мөгезеннән тотарга кирәктер. Әти, әни, абый, тагын да әллә кемнәр... аның Ырынбурга баруын тели. Шакирҗан абыйсының күз карашлары, өндәге сөйләшүе һич кенә дә игътибарсыз калдырырлык түгел.

— Ата-ананы рәнҗетеп яшәгән бала бәхетле була алмый, Галимҗан туган,— диде ул, эчке бер әрнү белән. Бераз тын торгач, янә дәвам итте: — Ата-ана фатихасы бала өчен Алла биргән кодрәт белән бер, мәңгелек иман ул синең өчен.

Бу сүзләр нык тетрәндерде Галимҗанның күңелен. Нә-

гыймә апасы да шулайрак әйтте ләбаса. Димәк, апасы да, абыйсы да кеше язмышы турында зур уйлый. Ә ул, җилне кирегә истерергә маташып, сырт кабартып йөргән була. Алай булмыйдыр ул тормышта.

— Җиңдең мине, Шакирҗан абый, рәхмәт, син әйткәнчә булыр,— диде ул иртәнчәк.

Шакирҗан абыйсы аны кочаклап сөеп куйды:

— Үзеңә рәхмәт, Галимҗан, әткәй-әнкәй бик шатланыр инде...

* * *

Шатлык бик зур булды: өйгә, ихатага, авылга, дөньяга сыймаслык. Гыйрфан мулла Шакирҗанга элеккечә кырын күз беләнрәк түгел, миһербанлы караш текәп карый башлады. Галимҗанның Казан ягына караган уй тәртәсен Ырынбур уңаена борырга бик ышанып бетми иде әле ул. Ә менә Шакирҗан һич көтмәгәндә капыл каерып борды да ташлады. Хәзер инде ата кеше эчтән генә, берсенә дә сиздермичә, үз уйлары утында янып, сыкранып йөри. Нигә ул моңа кадәр Галимҗанны гарше көрсигә күтәргән дә, Шакирҗанны тәпи-тәпи генә йөреткән? Нигә бала аерган? Җисмәни вә рухи көчнең иң илаһилысы Шакирҗандадыр, бәлкем. Ул бит әле үзен авылда гали бер мулла, оста игенче, ат чаптыру өчен җан атып йөрүче дип кенә хис итми, Троицк мәдрәсәсендәге хәлфәлек-мөдәррислек һөнәрен дә даими искә алып, мөгаллим-укытучы дип тә исәпли иде. Үз баласының эчке халәтен, рухи дөньясын, йөрәк тибешен аңламаган ата ни эшләп чын хәлфә-мөгаллим була алсын ди?

— Рәхмәт, улым, бер бәладән коткардың, көч бар икән үзеңдә, Аллага шөкер, синнән менә дигән мөдәррис-хәлфә чыгачак, Ходай уң кылса,— дип, Шакирҗанны кысып-кысып сөеп куйды ата кеше.

Бу минутта Гыйрфан мулла Шакирҗанның чыннан да оста мөгаллим-укытучы булачагы, үзенең бөтен гомерен халык мәгарифе эшенә багышлаячагы, яшь буынны тәрбияләүдә зур маһирлык күрсәтәчәге, кеше бәхете өчен яшәячәге турында, билгеле ки, аслан аң-хәбәрдар түгел иде әле. 1937 елда Галимҗан «халык дошманы» дип кулга алынгач, ул фаҗигале елларның кара сөреме белән төренгәч, бу сөремнең бөтен нәсел-нәсәпкә, шул исәптән Шакирҗанның ак-саф күңеленә төшәчәкне кайдан белсен ди инде ата кеше. Аның әле бөтен уй-хисе — балалар үрчетү, җирдә, бу фани дөньяда ныклы нәсел тамыры, якты эз калдыру. Ә инде Йосыф шәкерт белән махсус үзе сөйләшергә булды ул:

— Син, Йосыф туган, бу хәлгә авырсынма инде, бик ипле,

инсафлы, зыялы икәнлегеңне беләм, майлы чүлмәкнең тышыннан билгеле дигәндәй, төсең-битең үк балкып тора. Казанда урнашып алгач, хат яз, араны өзмик, яхшы кешеләр белән мөнәсәбәткә керү минем гомерлек хыялым ул, — диде.

— Минем сезгә рәхмәттән башка тагын да әллә нәрсәләр, әллә күпме изге теләкләр әйтәсем килә, мулла абзый, сүз генә таба алмыйм; биредә яшәү өчен бик күп фәһем алдым, сез искиткеч шәфкатьле, ачык күңелле кешеләр, Аллаһы Тәгалә барлык кайгы-хәсрәтләрдән араласын, бала бәхете күрергә язсын, — дип дога кылды Йосыф мәхдүм.

Пар ат җигеп, Йосыфны Уфага хәтле илтеп куйды Гыйрфан мулла. Берочтан ул Шакирҗанны да, Галимҗанны да алды. Аны Уфа белән Казан арасында йөри торган пароходка утыртып җибәрделәр. Моннан аңа әллә ни ерак түгел. Бөре, Дүртөйле, Исмаил пристаньнарын үткәч, Аю пристане бар. Әнә шунда төшеп калачак Йосыф мәхдүм. Аюдан аның туган авылы Илеш күз күреме җир генә...

## VIII

Җәй күңелле үтте. Зур мәшәкатьләр белән. Печән чабу. Урак уру. Көлтә бәйләү. Ашлык сугу. Башта боларның һәммәсе менә алмастай текә кыя сыман тоелып тора. Әмма ул кыя крәстиәнне хафага салмый. Җиң сызгана да ул, крепость алырга әзерләнгән солдаттай, күкрәген киң киереп ташлана кыяга. Бөтенесен уптым илаһи тозлап-борычлап җиренә җиткергәч, яз, җәй көннәрендә такырайган бура төпләрен көзен янә алтын бөртекләр белән тутыргач, крәстиән иркен тын алып куя: ул үзен әлеге текә кыя түбәсенә менгәндәй хис итә.

Эш каты була, билгеле. Уңган игенче кояшны басуда каршылый. Эшеннән кояш офык артына күмелгәч кенә туктый. Җәйге төн — бер тотам. Төн уртасы җиткәндә дә әле караңгылык куермый. Кара-зәңгәрсу төстә була ул. Төн таңга авышкан мәлдә генә ниндидер караңгы пәрдә тартыла. Тиздән ул да сыеклана. Караңгы чырайлы кешенең кинәт кенә йөзе яктырып киткән кебек. Ул арада таң әтәчләре сайрарга керешә. Ярсый-ярсый, ярыша-ярыша, ут чыкканда чаң каккандай сөрән салалар: җәй йоклаган — кыш ризык тапмаган, дигән кебек.

Шакирҗан белән Галимҗан да баштанаяк эшкә күмелде. Колач җәеп, тирли-тирли печән чабу, ямь-яшел печән исен йөрәккә шифа итеп алу, аннан соң иген исләре белән исерү, басуда кунып ятканда, төнге зәңгәр һаваны юрган итеп ябынып иркәләнү, таңның алсу нурларында коену... — бо-

ларның барысы да аларны җисми һәм рухи яктан ныгытты. Әйтерсең һәрберсенең тәне-вөҗүде таң төсе, көн йөзе, шәфәкъ балкышы, сихерле төн күзе нурларыннан җыелган гәүһәрләр белән нәкышләнеп чыныкты. Ал-ял белми, таңны — эңгер-меңгергә, көнне төнгә ялгап, ярсый-ярсый, вакыт-вакыт кара тиргә батып эшләгәндә, Галимҗан нык ябыкты, коры сөяккә калды. Әмма үрмә гөлгә охшап, буе һаман үсте, артты, калыкты. Бу яктан Шакирҗан абыйсын куып җитә язды. Кыр эшләре саегып, иркен тын алгач, әлеге коры сөяккә ит куна башлады. Беләк мускуллары ныгып, катып китте. Каз йомыркасы зурлыгында ук булмаса да, анда ниндидер бүлтәймә калыкты. Йөзенә төс керде. Карашлары җитдиләнде. Ул үзенең егет корына җитди якынлашуын, җир өстенә каты-каты басып йөрердәй гайрәте барлыгын сизде. Китәргә ике көн калгач, Галимҗан Кендекәйгә янә хәер илтеп бирде. Ни гаҗәп, анда Мәдинә-Акчәчкә дә бар иде. Галимҗан аңа карамаска, игътибар итмәскә, үзен кулга алырга тырышты. Шулай да вакыт-вакыт, ара-тирә күз сирпеп алырга да онытмады. Хәерен биреп, Кендек әбисенең фатихасын алгач, тиз генә чыгып китмәкче иде ул. Хәмдия абыстай моңа ирек куямы соң? Мең төрле сорау белән күмеп ташлады. Нигә Ырынбурның Вәли мәдрәсәсеннән качкан? Нигә Казанга барган? Үзе белән килгән шәкерт кем ул? Яхшы затланмы? Нәселе кем? Ат азгыны тайга ияргән кебек, нигә монда ияреп килгән? Тегесе-монысы, анысы-шунысы, фәлән-фәсмәтән... Аларның һәммәсенә җентекләп, җитди, төпле җавап бирү дә кыен. Хәер, Ак түти боларның барысын да белә инде. Нигә һаман шул бер балык башын чәйнәргә? Олы кешенең шул инде: ялыктырырлык, җилегеңә үткәрерлек, каннарыңны кайнатырлык итеп нотык укый. Кендекәй дә шулай итте:

— Мына син акыллы җегет бит, Галимҗан улым, әйе, хәзер җегет дисәм дә җарый, ай-һай-һай, зрә чибәр булып үсеп киткәнсең, хур кызлары күз атырлык... Әмма ликин ата-ана җылатып, баш бирмәгән мүкләк кәҗә кебек, әллә кайда шылай пыранлап җөрергә җарыймы соң... Җарамый... Ананың бер фатихасы — мең бала өчен мең иман. Мыннан кире аслан ана фатихасын бозып җөремә... Ишетсен колагың. Мин сиңә икенче ана. Кендек әбисе икенче ана ул. Фатиха алырга килүең өчен рәхмәт, колынчагым. Ходай Тәгалә авыр юлларыңны җиңел итсен, бетмәс-төкәнмәс зиһен-акыл бирсен, теләгем, берүккенәсе, фәрештәнең амин дигән чагына туры килсен!.. Сине сагалаган шайтаннарның күзе сукрайсын. Мына шылай...

Ак түти сөйләде дә сөйләде, теләк чүмәләсен аның алдына тау-тау өйде, фатихасын дөнья зурлыгында бирде. Тың-

лый-тыңлый тәмам арып, Галимҗан чыгып китәргә җыенгач, аңа Мәдинә-Акчәчкәне дә ияртте:

— Бар, кызым, бар, Галимҗан абыеңны озатып куй. Икегез бер көнне тусагыз да, ул сиңә абый була. Бу фани дөнҗага әз генә булса да алданрак килде бит.

Тышка чыккач, алар бер-берсенә карап каттылар да калдылар. Акчәчкә! Әйе, ак чәчкә кебек матур ул Мәдинә. Ак йөз. Бит очлары кып-кызыл булып янып тора. Аны киндер күлмәге дә, су кызыныкыдай таралып төшкән чәче дә ямьсезли алмый.

— Акчәчкә!..— диде дә аның кулларыннан алды Галимҗан, озак кына сүзсез торгач.

Мәдинәнең төсе үзгәреп, бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте.

— Акчәчкә?! Нинди Акчәчкә, Галимҗан абый? — Мәдинә кулларын тартып алды.

Галимҗан шунда ук үзенең каушавын, шуның аркасында ялгыш эндәшүен аңлады.

— Ни... Мәдинә... Мин... Мин... синең белән сөйләшергә телим... Әйдә... берәр җиргә...

Мәдинәне бу сүзләр тәмам гаҗиз итте. Кызның ак йөзенә нинди дер томан сыекчасы тартылды, бит очларындагы кызыллыкка янә кан йөгерде, алсу иреннәре дерелдәп куйды.

— Җарамый, Галимҗан абый, әллә шыны да белмисеңме: син — мулла малае, мин — җарлы кызы; бодайга кырлыкны кушмыйлар,— диде дә, кырт борылып, курыккан сарык бәрәнедәй тып-тып басып китеп барды.

Галимҗан, кулындагы тәти кошны ычкындырган кешедәй, аның артыннан үкенеп карап калды.

* * *

Өйгә кайтса, ни гаҗәп, артыннан ук Хөрмәтулла бастырып килеп керде. Мал — малга җитә, газраил — җанга җитә, ди. Үлем белән көрәшә-көрәшә, әллә ничә мәртәбә җан сорап килгән газраилның үзен дөмбәсли-дөмбәсли, йөрәк казанында кайнаган кара канны тәмам түкереп бетереп, ниһаять, аякка басты ул. Ни-нәрсә ярдәм итте? Җәйнең саф һавасымы? Сандугачлар моңыннан алган рухи илаһилыкмы? Ирегет гаярьлегеме? Ходай Тәгалә аны алты баласы ятим калмасын өчен саклаганмы?

Бу хакта авыл урамнарында төрле-төрле аяклы хәбәр йөрде. Ул хәбәр, кешеләрнең йә ишеген, йә тәрәзәсен алагаем ачып кереп, башта колак яфракларына эленде, аннан ми күзәнәкләре дулкыннарында чайкалды, шуннан авызга кү-

чеп, янә урамга чыга-чыга, бөтен тирә-якка гайбәт ташкыны булып җәелде. Гайбәтчеләрнең авызы — алапай казан, тешләре — үткер кылыч, сүзләре — җидееллык шөпшә. Алар башта әнә шул аяклы хәбәрне алапай авыз казанында кайната, аннан үткер кылыч тешләре белән тураклый, шуннан соң ул сүз, шөпшәгә әверелеп, гавам халкына тарала.

Хөрмәтулла, көчкә аякка басып, кешеләрнең үтеп-сүтеп йөрүләрен күзәтү, өзелеп-өзелеп сагынган киң дөньяны күрү теләге белән беренче мәртәбә үзе кебек кәкшәнләп беткән капка төбендәге ташка чыгып утыргач, әлеге гайбәтчеләрнең тел тегермәне ташы дер-дер әйләнә башлады: «И-и-и... шөйлә аякка басты бу иблис», «Таштан яралгандыр ул мәлгунь», «Шайтан затыннанмы әллә үзе», «Ат карагы ике йөрәкле була»... Шуларга охшаш мең төрле фараз-мараз, ялган-йолган, имеш-мимеш кара канат какты. Болар — адәм баласын чебеш урынына да күрмәгән таш йөрәклеләр.

Аяклы хәбәрнең икенче төрләре дә булды: «Илаһым, вакыт җитмәгәч, үлми икән бәндә», «Бетеп-беткән иде бит ул», «Аллаһы Тәгалә балалары бәхете өчен үз канаты астына алгандыр инде», «Эчкерсез бит ул, риясыз», «Бер гөнаһсыз кешене әрәм иттеләр бит», «Әй, бу нахак бәла тагучылар»... Мондыйлар — олы-матур йөрәклеләр. Алар күңелендә иман нуры, Алла кодрәтенә ышану, кешелеклелекнең гүзәл сыйфатлары бар. Шул илаһилык тәэсире шифасы белән коендырылгандыр Хөрмәтулла, бәлки. Шулар тартып алгандыр аны миһербансыз үлем тырнагыннан.

Гәрчә аякка басса да, аның хәле мөшкел иде әле. Эсседә әлсерәгән каз бәбкәсен хәтерләтеп торды. Шулай да акрынлап-акрынлап исәйде, көч җыйды, җәй азакларында урамнан элеккечә каты-каты басып китәргә тырышты. Менә килгән бит әле. Ни өчен? Ни хикмәт? Ни кирәк?

— Әссәламегаләйкем! — диде ул, килеп керү белән.

— Вәгаләйкемәссәлам! — диде Гыйрфан мулла.

Шуннан озак кына бер-берсенә карашып тордылар. Бу авыр тынлык һәрберсенең күңелен бозландырды. Бозны мулла абзый эретте:

— Ху-уш, Хөрмәтулла, әйдә, үт әле, утыр, нигә болай чит кеше кебек торасың,— диде ул, нык якын итеп, миһербанлы булырга тырышып.

Хөрмәтулла аягындагы чәчкә аткан чабатасына карап алды: мондый аяк киеме белән сезнең зиннәтле келәмегезгә басарга ярамый, дигәнне аңлатты ул. Киндер күлмәк өстеннән кигән кырык ямаулы бишмәте дә, киндер ыштаны да, башындагы тиргә каткан тишекле-мошыклы киез эшләпәсе дә аны бу җәннәт кебек нур чәчеп торган өй эченең түренә үтүдән тыеп тора кебек.

— Җук, мулла абзый, мин үтәргә килмәдем. Ни... ничек әйтим... мына шылай... шылай булды инде...

Ул уңайсызлана иде. Әйтерсең бүре алдында калтыранган сарык. Моны мулла абзый да, Хәсәнә абыстай да, Шакирҗан да, Галимҗан да сизде. Әмма Хөрмәтулла һаман әле үзен ятьмәгә эләккән балыктай хис итте. Аны авыр хәлдән Хәсәнә абыстай да коткарырга тырышты:

— Син инде, Хөрмәтулла, алты бала атасы, батыр йөрәкле ир-егет, нигә болай коелып төштең, әйдә, үт әле түргә, үт, үт...

Әнисенең сүзен Шакирҗан куәтләп җибәрде:

— Әйе, Хөрмәтулла абзый, болай килешми бит инде, балачага кебек...

Тик Галимҗан гына кысташуга катышмады: олылар алдында килешми. Ә Хөрмәтулла һаман каккан казык урынына тора бирде. Бу минутта ул атасыннан нык кыерсытылган төшенке күңелле мескен балага охшый иде. Әлбәттә, гәрчә тешләрен кыса-кыса, уртларын чәйни-чәйни, адәм рәтенә керергә өметләнеп йөрсә дә, аның хәленең мөшкеллеге күзгә бәрелеп тора. Яңаклар эчкә баткан. Очкын чәчеп торган чая күзләр тонган балыкныкыдай төссезләнеп калган. Ямьсез булса да, аның йөзендә ниндидер мәхәббәтлелек, горурлык, җитдилек чаткылары бар иде. Инде хәзер алар да сүнгән. Гәүдәсе дә бәләкәйләнеп калган. Аны гүя башыннан аягына хәтле бу авыр дөньяның кайгы кәфене белән ураганнар. Ул әле хәтта менә-менә елап җибәрер кебек кыяфәттә тора. Шулай да элекке горурлыгын барыбер югалтмаган икән. Ул тотлыга-тотлыга, авыр тын ала-ала, көч-хәл белән шундый сүзләрне әйтте:

— Сез... мулла абзый... Хәсәнә абыстай... Шакирҗан... Галимҗан... җакшы кешеләр... Тик миңа ылай... кызганып карамагыз... Вәт тәк... Мин гүпчи дә жәлке кеше түгел... Иртәгә завутка китәм... и вчү...

Ул тагын да нидер әйтмәкче булган иде, ләкин теле тибрәнде, сүзе чыкмады. Өй эчен янә авыр тынлык басты. Кешеләр телен тынлык җебе бәйләде. Бераздан ул җепне Гыйрфан мулланың сүз кылычы өзгәләп ташлады:

— Әллә юлга акчаң юкмы, Хөрмәтулла? Булмаса, кыенсынма. Алмак бар, бирмәк бар дигәндәй...

— Җу-у-ук... Мин аның өчен төгел... Мулла абзый... Фатихагызны алырга килгән ием... Тәк бит... җулга шылай чыгалар...

Ул әлеге кырык ямаулы бишмәте кесәсенә тыгылды, калтыранган куллары белән эзләп алып, аннан бакыр акча чыгарды. Бер аңа, бер боларга карап, үтә нык кыенсынып, аны Гыйрфан муллага сузды:

— Хәер китергән идем... мулла абзый... Аз булса да... кабул итеп алчы... Җулга шынсыз чыгарга җарамый... Догада булсагыз икән...

Гыйрфан мулла аны бик кыенсынып алды. Син бит балаларыңның соңгы тиенен алып килгәнсең, нигә болай кыланасың, фатиханы ансыз да бирә алам ич, дияр иде — ярамый. Хәерне кире кагып булмый. Дога кылырга кирәк. Хөрмәтулла, күпме генә кыстасалар да, түргә үтмәде. Шуңа күрә мулла абзый уң яктагы кәнәфи янына ике урындык китереп куйды. Алар икесе шунда парлап утырдылар. Барысы да дога кылды. Гәрчә укый белмәсә дә, Хөрмәтулла үзе дә, килештерергә тырышып, ике кулы бармакларын бер-берсенә якын китереп, өчпочмак шәкеле ясап укыгандай итеп утырды да башкалар белән беррәттән битен сыйпап куйды. Шуның белән эш бетте, фатиха бирелде, инде ак юл, бәхет телисе генә калды шикелле. Мулла абзый китмәскә, берникадәр сабыр итәргә, ныклап сәламәтләнергә кирәклекне әйтергә дә уйлаган иде, ләкин аның буш үгет-нәсихәт, коры вәгазь булачагын аңлады. Хөрмәтулланың холкын белә ул: бер дә юкка борчак чәчкәнне яратмый. Тик шуны гына әйтә алды:

— Иртәгә дүшәмбе, бу көнне сәфәр чыккан кешенең юлы уңмый калмый, без дә Ырынбурга китәргә дәртләнеп торабыз, Алла боерса,— диде.— Әле көннәр дә бик һәйбәт тора. Бозылып киткәнче, ашыгырга туры килер. Бәгъзе бер елда көзге көннең күге елак бала белән бер була — яше чыга да тора.

— Җарар... Мулла абзый... Хәсәнә абыстай... фатихагыз өчен рәхмәт... Җул кешесенең җулда булуы хәерле... шылай диләр бит... Китием инде...— ул урыныннан калкынды.

— Сабыр ит әле, Хөрмәтулла, сабыр төбе — сары алтын, диләр бит, алтын ук булмаса да, сиңа бирәсе әйберем бар иде.— Мулла абзый эчке бүлмәгә кереп китте дә бераздан бер төенчек алып чыгып, аны Хөрмәтулла кулына тоттырды. Хөрмәтулла, бер төенчеккә, бер Гыйрфан муллага карап, ни дияргә белми аптырап тик торды.

— Ни... ни... нәмәкәй соң бу, мулла абзый?

— Аз булса да акча...

— Кирәкми... Мин хәер эстәүчеме...

— Исәрләнмә. Биргәннең битенә төкермиләр. Алмасаң — үпкәлим.

— Мулла абзый...

— Йә, йә, котырынма...

— Алайса... бу... мин аны түләрмен... Шахтыга китәрмен мужыт... Анда зарпулатыны шәп, диләр...— ул урыныннан кузгалды.

Баядан бирле тын торган Хәсәнә абыстай телгә килде:

— Хөрмәтулла, утыр әле, утыр, мулла абзыең әйтмешли, сабыр ит, хәзер чәй эчәрбез.

— Рәхмәт, абыстай!.. Сездән күргән җакшылыкны мәңге онытачагым җук... Вәт тәк... и вчү... Теге шәкерт белән Галимҗан бездә булдылар бит... Санга санап килүләрен әйт... Мына шындай кешеләр күп булсын иде дөнҗада... Сезнең кебек... Җарай... Китим инде...

— Чәй...

— Җук, җук, абыстай, оялмыенча...

Күпме генә кыстамасыннар, Хөрмәтулланы чәйгә калдыра алмадылар. Мулла абзый, Хәсәнә абыстай аны озата чыкты. Ишегалдында көтәргә кушып, икесе дә чоланга кереп киттеләр.

Хөрмәтулла ихатадагы күркә, тавык, үрдәкләрнең көзге кояшлы көнгә сокланып, ләззәтләнеп, рәхәтләнеп горур гына йөрүләренә аптырап карап торды. Бер күркә, кабарынып, гол-гол-гол итеп куйды. Үрдәкләр, башларын югары күтәреп, бак-бак-бак, дип бакылдарга тотындылар. Аларның тавышы «тап-тап-тап» дигән кебек. Димәк, ашарга таптыралар. Ачыкканнар. Түшен алагаем киереп, байларның самавыры дәүмәллеге бер әтәч йөри. Аһ, аның горурлыгы. Иркә, сылу, назлы тавыклар аның тирәсендә кыланчыкланып бөтереләләр.

Менә тегеләр дә чыкты. Хәсәнә абыстайның кулында ниндидер бәләкәй капчык. Ул бүртеп тора. Эчендә нидер бар шикелле. Мулла абзый сул беләгенә бишмәт салган. Икесе дә килеп туктагач, сүзне Хәсәнә абыстай башлады:

— Менә монавында азырак ярма бар иде, ал әле шуны, Хөрмәтулла, бер генә дә авырсынма, ал, ал, ал...

— Абыстай... инде былай да... акча...

— Йә, йә, күп сөйләнмә, синнән аз файда күрмәдек, ул печән чабуларың, ул урак уруларың, ул абзар төзәтүләрең — кулың алтын бит синең...

Хөрмәтулла алмаска тырышып караса да, Хәсәнә абыстай чарага куймады:

— Аз гына тары ярмасы, балаларга ботка пешереп ашатырсыз, сиңа түгел, аларга бирәм, алмый чараң юк, — диде дә кулына тоттырды.

Абыстай әйткәнчә, ул һич тә аз түгел иде. Ярты пот чамасы булыр. Шуны сизде Хөрмәтулланың кулы.

Алар үзара килешкәч, Гыйрфан мулла аңа әлеге сул беләгендәге әйберне бирде:

— Бу — минем бишмәтем, Хөрмәтулла; иштә сиңа таман булыр, үзеңнеке бик тузган бит; син төсеңне бозма әле, кыенсынма да; кайткач, киеп карарсың...

Моның өчен Хөрмәтулла авыз тутырып рәхмәт әйтергә тиеш иде. Ләкин әйтә алмады. Күңеле тулды шикелле. Әмма мулла абзый белән абыстайга тел рәхмәте кирәкми инде. Йөрәге белән әйткәнлеген алар икесе дә аңлады.

Хөрмәтулланы капкага хәтле озата бардылар. Бәләкәй капкадан чыгарып җибәргәч, алар икесе дә тын калды. Чөнки Хөрмәтулланың атлап китмәве, олы капкага килеп сөялүе сизелде. Алар шунда колак салырга мәҗбүр булды. Ә Хөрмәтулланың мышык-мышык елаганы ишетелде. Ни өчен? Рәнҗетмәделәр ләбаса. Авыр сүз дә әйтмәделәр. Бу елау шатлыктан иде. Вакыт-вакыт шатлык та, кайгы да күздән яшь китерә. Кайгы яше —ачы, шатлык яше төче була. Шатлык яше гәүһәр төсле җемелди. Хөрмәтулла Гыйрфан мулланың капка төбендә гәүһәр яшь калдырып китте. Ул гәүһәрдә ярлы-ябагайның йөрәк җылысы, күңел кайнарлыгы, бәхет өмет итү чаткысы. Ул гәүһәр — җанлы, тере, мөкатдәс. Анда — кеше йөрәге. Кешелеклелек! Мәрхәмәтлелек! Шәфкатьлелек!

## IX

Кояш аязга баеды. Аннан офыкта озак кына кан-кызыл ут балкып торды. Тора-бара ул ут яңа төсләр белән алышынды: шәмәхә-кызыл, алсу-кызыл, күксел-кызыл, кара-кучкыл-кызыл... Янә бераздан төсләр буталышып, бер-берсенең эченә керешкәч, нәрсә хакындадыр серләштеләр-серләштеләр дә, озак кына кул кысышып торып, төрлесе төрле тарафка таралышты. Шулардан җанлы әйберләргә охшаш әллә нинди шәкелләр оеша-ясала башлады. Берсе аюга охшап тора, икенчесе — әтәчкә, өченчесе — кәҗәгә, дүртенчесе... дүртенчесе...— Тулпарга. Нәкъ аларның Тулпары лабаса бу. Их, атланып алып, көмеш ялларына тотынып, менә хәзер үк Ырынбурга җилдерәсе иде. «Ә» дигәнче барып җитәрләр иде. Бишенчесе... бишенчесе... бишенчесе... тукта-тукта... хас та теге әкиятләрдә сөйләнелгән су кызы. Чәчен тарап утыра. Тукта, тукта, Мәдинә-Акчәчкәгә дә охшый түгелме соң бу? Әйе, әйе, шул. Шул үзе... Әнә кайда менеп утырган табигать баласы. Айдагы Зөһрә кыз кебек. Күк белән Җир йөрәгенең кешегә күренмәс сихри ефәк җепләр, нурлар белән тоташуы шушымы? Җирдәге тереклек, матурлык, яшәеш сурәтләрен, күктә рәсем итеп, Ходай Тәгалә адәм балаларына яңа сыйфатта күрсәтәме? Мәңгелек дөньяда яшәүнең бер манзарасымы бу?

Галимҗан аларга исләре китеп карап торды. Менә шушы бәләкәй генә дөньядан, аларның ихатасыннан, күпме галәм уч төбендәгедәй күренеп тора. Их, әлеге күктәге Зөһрә-

не көн дә чишмәдә юынырга, Җир битен үбәргә алып төшә торган Тулпарга атланып, ай-йолдызлар илен гизеп кайтасы иде. Мондый хис-тойгы, тирән кичереш, йөрәк ярсуы анда еш була башлады. Бигрәк тә менә шушындый сихри кичләрдә, айлы төннәрдә, алсу таңнарда, моңсу иртәләрдә...

Ата кеше ихатада анысын алай, монысын болай, тегесен тегеләй итеп йөрде. Иртә таңнан сәфәргә чыгу өчен, арбаны, камытны, дуганы, атларны — һәммәсен, һәммәсен янә бер мәртәбә караштырып чыкты. Өйдә ныгынып чыкмасаң, юлда тиз бушанырсың, диләр бит. Юл газабы — гүр газабы, дигәне дә бар. Кояш, Ходайга шөкер, аязга баеды: иртәгә көн, Алла боерса, яхшы булачак. Пар ат белән җилдерәчәкләр генә. Гүр газабы күрергә насыйп булмасын.

Ата кеше берара авызы белән кош тотарга чамалаган кешедәй күккә карап каткан улына эндәште:

— Галимҗан улым! Кереп ял итәр идең. Иртәгә иртүк юлга бит.

— Хәзер, әткәй, әнә теге Тулпарга аз гына карап торам да...

— Беләм инде, улым, беләм, табигатьнең күзенә керәсең килә.

— Ырынбурда болар юк бит.

— Анда да бар ул, улым, карамыйсыз гынадыр. Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла.

Галимҗан әнисен генә матур фикерле, сүз тәмен нык белүче, ихлас күңелле дип уйлый иде. Әтисе дә, гәрчә кырыс холыклырак булса да, күңелендә әллә күпме асылташ саклый икән. Йосыф мәхдүм алдында ул асылташларын аеруча нык балкытты. Әллә нинди риваятьләр, әкиятләр, хәдисләр сөйләп, үзен чын мөдәррис-мөгаллим итеп күрсәтте. Уфада аерылышканда, Йосыф мәхдүм бу хакта Галимҗанга дулкынланып әйтте хәтта:

— Минем әти дә зыялы, белемле, итагатьле мулла, ләкин дә синең әтиең кебек бөтен эч серен ачып салмый, безнең белән иркенләп-ачылып сөйләшеп утырмый, риваятьләр дә сөйләми; синең әтиең дә, әниең дә телгә бай, телгә бай кеше фикергә бай була; аларның бу уңай сыйфаты сиңа күчми калмас, Галимҗан, аларны күп тыңла,— диде.

Моны Галимҗан үзе дә сизә. Әтисе дә, әнисе дә вакыт-вакыт бик кыйммәтле, мәгънәле, зур сүзләр әйтеп куя. Әле дә менә ни диде әтисе: «Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла»,— диде. Моны бит кайдадыр язып куярлык. Иң яхшысы — күңел дәфтәренә язу. Аннан аны берәү дә күчереп ала алмый. Ул ертылмый да. Аны көчле давыллар да очырып китә алмый. Ә үзе кем соң ул? Матур йөрәкleme? Табигать аңа берәр мәл ачылырмы? Ачылыр, ачылыр,

ачылыр. Ул адәм балалары кебек. Кешене сөйсәң генә, сине сөяләр. Табигатьне яратсаң гына, ул сине ярата. Кешене тукмасаң, ул сине тукмый. Табигатькә йодрык күрсәтсәң, ул синең башыңа утлы чукмар белән тондыра.

Шундый уй-хис давылы эчендә кайнашып керде Галимҗан өй эченә. Билгеле инде, әнисе юлга ризык-күчтәнәч әзерли. Ул шат. Йөгерә-атлый йөри. Мич алдында озак шөгыльләнүдән бит очлары кып-кызыл булып янып тора. Ул гүя тагы да әллә күпме яшькә яшәреп киткән. Гаҗәп матур, нәфис, сөйкемле күренә ул. Әгәр менә хәзер ихатага чыкса, рәсеме әлеге теге су кызы янына күчерелер иде. Аның әнисе шул су кызыннан да матуррак булып күренер иде әле.

Шакирҗан абыйсы да үз шөгыле белән мәшгуль. Җыештыра. Бәйли. Төенчекләр ясый.

— Галимҗан, син әллә кайда йөрисең, әйберләреңне караштырмыйсың,— диярга дә онытмады ул.

Галимҗан шаяртыбрак сөйләште:

— Мин, Шакирҗан абый, күктәге матур сурәтләрне күрдем. Менә шуларны тутырып бәйләргә иде синең төенчегеңә.

— Нәрсәләр бар соң анда?

— Барысы да... Табигать балалары да...

— Син хыяллана башладың соңгы вакытта.

— Мине табигать хыялландыра.

Шакирҗан башкача сүз әйтмәде. Бу минутта Галимҗан киләчәктә «Табигать балалары» дигән хикәя язачагы, аны 1914 елда «Аң» журналы нәшрияты чыгарган «Әдәби альманах»та бастырачагы турында аслан уйлый алмый иде әле. Зур язучы булу өчен, кешеләрне сөяргә, аларның кайгысын да, шатлыгын да үз йөрәгеңә алырга, табигатьнең иркә баласы гына түгел, зур көрәшчесе булырга кирәклекне әле кайдан белсен ди ул. Әмма ләкин аның чаткылары күңеленә, йөрәгенә һаман салына бара. Ул чаткылар әтисе белән пычкы тарткандагы хезмәт моңыннан, гәрчә әле бигүк урынлы булмаса да, Вәли мулла белән чәкәләшүдән, Хөрмәтулла кебек рәнҗетелгән язмышлардан киләдер. Шул очкыннар ялкынга әйләнәчәк бит бервакыт.

## X

Юстүдән соң, башка көннәрдәгечә, юк эшне бар итеп дигәндәй, китап-мазар укып фикерләшмәделәр: сәфәр алды төне тыныч йокы, күтәренке күңел, сәламәт кәеф таләп итте. Юл низам-тәртип ярата. Башкалар, бер-берсенә тәмле йокы теләшеп, рәхәтләнеп ятып йокладылар. Тик Хәсәнә абыстай гына ашыкмады. Ир-

тәнгә тәбикмәк изеп куйды, юлга ит кыздырды, сумса, бәлеш пешерергә булды. Ул өйдә каласы кеше. Болар киткәч, күзе бик йомылып мазасызлый, йөрәге ойый башласа, баш терәп алырга мендәрне сатып аласы юк.

Ләкин алсу таңга чаклы йокларга насыйп булмады. Икенче әтәчтән соң, кыямәт көнендә купкан тавыш-низагка охшап, бөтен авыл гөж килә башлады. Ямьсез итеп, котырынып, ниндидер фаҗигага барлыкны искәртеп, чаң кактылар. Аннан: «Янгын, янгын, янабыз, җәмәгать, су, су, тизрәк, тизрәк, харап булабыз, бетәбез»,— дигән ачы тавышлар яңгырады. Махсус кешеләр, уянсын өчен, капкаларга күсәкләр белән сугып йөрде. Бер үк вакытта әлеге «янгын», «янгын», «янгын» дигән сүзләрне дә кабатладылар.

Хәсәнә абыстай һаман ятмаган иде әле. Хәер, бу хакта ул уйламады да. Чөнки сәфәрчеләр торганчы тәбикмәкне пешерә башларга кирәк. Бу тавыш, гауганы ул ишетмәскә тырышты. Йоклаучыларның да тынгысызланмавын теләгән иде. Шулай да теләге фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәде. Иң әүвәл ата кеше сикереп торды. Ул, җәһәт киенеп, Шакирҗанны, Галимҗанны уятты. Алар да күз ачып, күз йомган арада аякка басты. Мондый чакта мәгълүм инде: һәркем бер сулы чиләк алып йөгерергә тиеш. Болар да шуны эшләде.

Капкадан чыгу белән, алар — ата кеше, Шакирҗан, Галимҗан, ут чыккан якка йөгерде. Аларга башкалар да кушылды. Дөрләп янган ут күренә. Ә менә кемнеке икәнлеге билгесез. Аларга каршы атка атланган берәү чабып килә иде. Үзе чаба, үзе кычкыра: «Янгын, янгын, янгын, тиз булыгыз, Мөбахис мәзин яна, Мөбахис мәзин яна, Мөбахис мәзин яна».

Ара шактый ерак иде. Шулай да берәү дә ыңгырашмады, соңгы көчен җыеп, чиләктәге суын түкмичә, йөгерде дә йөгерде.

Алар барып җиткәндә, Мөбахис мәзиннең йорты яртылаш янган иде инде. Ул шундый коточкыч яна, тәмуг уты да бу кадәр булмас. Кешеләр кырмыска урынына кайнаша. Берәүләр су сибә, икенчеләр көрәк белән җир казып ыргыта, өченчеләр, ут читкә китмәсен өчен, озын саплы тимер ыргак белән янган бүрәнәләрне, такталарны җиргә тартып төшерә. Су менә кайчан күп кирәк. Авыргазы, Түрсәгәле елгалары, Кондызлы күл дә ерак. Кое дигәне урамга берәү генә. Ярый әле тырыш Солтанморат халкы үзләре мең бәла белән ясаган имән торбалар аша авылга су китерде. Ләкин көчле янгын вакытында аның суы да шул ташка үлчим кебек кенә икән. Чиләк белән сипкән суны ялкын ялмап алып кына тора. Ул ялкын әйтерсең суга сусаган мең башлы дию

пәрие теле. Суны аны үлемнән коткару өчен алып киләләр. Шуңа шатланып, рәхәтләнеп, ләззәтләнеп эчеп тик тора ул.

Суны Мөбахис мәзиннең ике ягындагы өйгә дә сибәләр. Чөнки әлеге ялкын теле аларны да ялмап-ялмап ала. Ялкын аларга күчсә, бөтен авылның харап булуы бар. Ходайга шөкер, ул куркыныч булмады. Утырды да янды Мөбахис мәзин дөньясы.

Янгын сүнгәч тә халык җәһәт кенә таралышмады. Мондый вакытта төпчену, сәбәп эзләү, фараз итүләр башлана: кайдан чыккан ялкын, ни өчен, кем гаепле?..

Гыйрфан мулланың имеш-мимеш тыңларга вакыты юк иде. Аның сәфәр чыгасы бар. Шуңа күрә Шакирҗанны, Галимҗанны ияртеп кайтып китте.

* * *

Шатлыкны — кайгы, кайгыны шатлык алыштыра. Авылда янгын булу — фаҗига, күңелсезлек, кара кайгы ул. Утырды да янды Мөбахис мәзин дөньясы. Аның ялкыны бөтен авылны балкытып торды. Шул ялкын-балкышка иш-куш булыйм дигәндәй, кояш та уттай янып-кызарып чыкты. Төне буе мич алдында мәш килгән Хәсәнә абыстайның бит очлары да шул иртәнге кояш кызыллыгы төсле янып тора иде. Аллага шөкер, ул үз вазифасын җиренә җиткереп башкарды: юлга бөтен ризык-нигъмәт әзер — тамакларына аш булсын! Ходай Тәгалә тәннәренә-җаннарына сихәт бирсен. Тик әлеге шатлык белән кайгы аралашуы гына күңелгә көл сипте. Юньләп йоклый да алмадылар. Ничек чыга алалар инде алар шул килеш ерак юлга?

— Сиңа әйтәм, муллакаем, әйкәем, әллә сабыр итәсезме, бүгенгә ял итеп аласызмы, иртәгә чыгар идегез юлга, Ходай биргән көннең барысы да бер лә инде ул, — дип карады.

— Юк, юк, остабикә, һич кенә дә бер түгел, юл башы өчен дүшәмбе көн әйбәт, сишәмбе көн юлга чыгып беркайчан да уңганым булмады; кем әйтмешли, йокы песигә генә моң, үлмәбез әле; күрмисеңмени, көне нинди матур, җәй уртасы диярсең, әйтерсең Ходай үзе безгә шундыйны бүләк итеп бирде, — дип, тәртәсен үз ягына таба каерды ата кеше.

«Бүгенге эшне иртәгә калдырма», «Тәвәккәл таш яра», «Уйлаганнан кире кайту — кирәгеңне югалту» дигән мәкаль-әйтемнәрне дә искә алды ул. Үзен болай бик иркен, шат, шаян тотарга тырышты. Юлга чыкканда, балтасы суга төшкән кешедәй йөрүне, борын салындыруны, ык-мык килүне гомумән яратмый ул. Юл күтәренке күңеллелекне, хозурлылыкны, егетлелекне ярата. Бу — бер. Икенчедән, өйдә калачак хәләл җефетенең дә матур дога кылып, зур фа-

тиха биреп, хәер-догада торуын тели ул; Шакирҗан белән Галимҗан да, юлга чыкканда, ачык йөзле, күтәренке күңелле, дәрт-дәрманлы булсыннар.

— Ай-һай ла, көне дә көне, кояшын күр, ничек нур чәчеп килеп чыкты ул, нәкъ пәйгамбәрләр туган таң инде менә, — дип, бергәләшеп ат җиккәндә, дәртләнеп, егетләргә җиңеллек күрсәтеп сөйләнеп йөрде Гыйрфан мулла.

...1900 ел. Унтугызынчы гасырның кояшы баеды.

Егерменче гасыр кояшы... Нинди кояш булыр ул? Җиһанга нинди нур чәчәр? Ул нурда адәм балалары мәңге-мәңге, гомер-бакый таңнарга, кояшка, айга, йолдызларга карап, тирән сәҗдәгә китеп теләгән бәхет булырмы? Нурлардан бу мәшәкатьле хәяткә, авыр тормышка, кара көннәргә яктылык сирпелерме? Аның уллары ничек каршылар бу яңа гасырны? Уйлыйлармы бу хакта? Баш ваталармы? Әллә ике ятып бер төшләренә дә кермиме? Бала күңеле — серле урман, ди бит. Эчкерсез кебек тоелсалар да, сиңа иң кирәк булганын әйтеп салмый алар.

Ат җиккәндә дә, утырышып чыгып киткәндә дә, капка төбендә Хәсәнә абыстай яулык очы белән күз яшен сөртеп алганда да шул уйларыннан аерыла алмады ата кеше. Күңеле нидер өмет итсә дә, егерменче гасырда улы Галимҗанның әдәбият пәйгамбәре булачагы хакында аз гына да, ялгыш та уйлый алмый иде әле ул.

Менә тагы?.. Ни хикмәт?.. Кендек әби нигә чәчәрдәй булып килә?.. Бер-бер күңелсез хәл бармы?.. Инде пар атка тулы куәт биреп, чаптырып китәм дип торганда...

— Тр-р-р... тр-р-р... Малкайлар! — Ярсып торган атларны көч-хәл белән туктатты мулла абзый.

Алар бер-берсенә карашып алдылар. Кендек әбинең тыны тәмам куырылган, кобарасы очып, төсе киткән, хәтта сүзен дә әйтә алмый тора.

Мулла абзый түземсезләнеп сорады:

— Ни булды, Хәмдия абыстай, нигә бизгәк тоткан кеше кебек калтыранасың?

Хәмдия абыстай, юлга чыккан кешеләрне хафага салмыйм дип, курку вә калтырану сәбәбен яшерергә тырышты:

— Юк, юк, берни дә булмады, сезне озатып калыйм дип ашыктым, мына шылай йөгерә-атлый килеп, тәмам тончыктым; Аллаһу Тәгалә сезгә олы фатихасында булып, фәрештәләр барыр җулыгызга ак җәймә җәйсен. Амин!

— Фатихаң өчен рәхмәт, Хәмдия абыстай! Әйе, изге сәфәргә чыктык, Аллага шөкер! Рәхмәтле догаңда бул! Әмма ләкин нидер яшерәсең. Бу хакта йөзең, күзең, бөтен кыяфәтең сөйләп тора. Әйт, нинди күңелсез хәл булды? Мин юлга синең кайгылы йөзең күләгәсен алып китә алмыйм.

— Әй-һәй, Гыйрфан мулла, мәгәр үткер күзле, зирәк акыллы, сизгер җанлысың да инде; мәйтәм, җул кешесен борчымыйм, Хәсәнә белән генә мәслихәтләшием, дигән ием, былай булгач, җәшерә алмыйм инде, җук, җук, җук...

— Сөйлә, Хәмдия абыстай!..

— Хөрмәтулланы, тагын да эт урынына тукмап, теге ни... Нәҗметдин мәзин келәтенә ябып куйдылар бит.

— Ни өчен?

— Мөбахис мәзин йортына утны ул төрткән, җәнәсе дә...

— Кем күргән?

— И... һәй, кем күрсен... Кичә, сездән чыккач, шылар йорты җаныннан үтеп киткән. Китсә соң. Адәм баласы җөрмиенче торамы? Теге ни... аның күршесе имансыз җан Хәмәтдин әләкләгән Мөбахис мәзингә: ни дигән, синең дөнҗаңа Хәрти ут төртте, дигән; Ходай шаһит, үз күзләрем белән күрдем, дигән; тотып алырга уйлаган идем, качты мәлгунь, дигән. Шышы хәбәре өчен Мөбахис мәзин аңа бер әчмуха чәй, бер кадак шикәр, ярты пот он вәгъдә иткән. Судта да шыларның тамчысын да калдырмыенча ярып салырсың, дигән Мөбахис мәзин шыл Хәмәтдин хәсискә. И... и... и... җөрәгем җыртыла җазды, җөрәгем. Алар бу җалган җала сазына сине дә батырмакчылар икән.

— Мине?! Ни өчен?!

— Кичә Хөрмәтулла сездә булдымы?

— Булды. Моның ни гаебе бар?

— Имештер, Хөрмәтулланы Мөбахис мәзин җортына ут төртергә син котырткансың. Бу ачу теге вакытта сарык өчен мир җыенында Хөрмәтулланы яклаудан ук килә икән. Уф, Алла!.. Ни әйтием? Ниләр генә эшлием... Хөрмәтулла бу авырлыкны күтәрә алмас инде... Күп торса... ике көн торыр...

Бу сүзләрне ишеткәч, барысының да йөрәге шартлар дәрәҗәгә җитте. Дилбегәне Гыйрфан мулла үзе тоткан иде. Ул әле һаман Шакирҗанга да, Галимҗанга да ышанып бетми: арбага җигелгән пар атны уйнатып кына алып бару җиңел шөгыль түгел. Авыл урамнарын үткәндә, яшен уты урынына томырылырга кирәк. Җебегән борын, коры куык, чепи күзлеләр шаккатып, исе-акылы китеп, бөгелеп-сыгылып карап калсыннар. Тик... шайтан юлга тагын да киртә тотты. Тфү!.. Хәмдия абыстайның ялварулы карашы барын да аңлатып тора: ул ярдәм сорый.

Гыйрфан мулла артына борылып карады. Галимҗанның күзләре маңгаена менеп, калын иреннәре көзге яфрактай дерелдәп тора. Менә хәзер аның, теге вакыттагыча, арбадан төшеп йөгерүе, Хөрмәтулланы коткару чарасына ташлануы мөмкин. Булдыра аламы-юкмы — ул әле аны уйлап бетер-

ми, куркыныч давылына ташланырга гына тора. Шакирҗанның да кобарасы очкан. Дөрес, ул сабыр табигатьле. Түземле. Юкка-барга, пыр-пыр, мыр-мыр килеп, шайтан алыштырган нәмәстәкәй шикелле кыланмый. Шулай да барыбер аның йөзенә дә аптырау-гаҗәпләнү, кайгыру-хәсрәтләнү күләгәсе тартылган.

Гыйрфан мулла үзен ике ут арасында калган кешедәй хис итте. Менә хәзер чаптырып китеп барыргамы? Ихатага кире кереп, атларны тугарып ташларга да Хөрмәтулланы үлем базыннан өстерәп чыгару чарасын күрергәме? Монысын да эшләргә мөмкин. Ләкин көч җитәрме?

Барысын да Хәмдия абыстай хәл итте:

— И... Әйтәсем калмаган. Нигә мына шылай җулга чыккан кешене җаман хәбәр белән албыратам инде. Җүнсез мин. Акылсыз. Беркатлы...

Барысы да, авызларына су капкандай, беразга тынып калдылар. Тынлыкны Кендекәй бүлде:

— Җә... мына шылай... аңгыра тавыктай... миңгерәп тормыйк әле... Мин Хәсәнә җаным җанына керәм, ә сез җулыгызда булыгыз...

Гыйрфан мулла җан ачуы белән дилбегәсен тартты. Атлар, хуҗа ачуын чыбыркыдан да ныграк-катырак тоеп, пыр туздырып чабып киттеләр. Алар артыннан тузан болыты күтәрелеп калды.

* * *

Ул тузан, бер яхшылыкка тагылган мең төрле кара-куе болытны хәтерләтеп, алар артыннан авылны чыккач та һаман әле бик озак ияреп барды. Гыйрфан мулла атларын кара тиргә батканчы куды да куды. Әйтерсең бөтен ачуын шулардан ала. Аның каны кайный, күңеле шаша, йөрәге пәрә-пәрә өзгәләнә иде. Алда, Ырынбурдан кайткач, янә зур көрәш-низаг булачак. Җиңәргә көче җитәрме? Мөбахис мәзин җыен ялагай, йомакай, бер мыскал онга адәм баласын сата торган имансызларны җыеп алды үз канаты астына. Инде хәзер аңа, Гыйрфан муллага таба борды ачу-агу сөңгесен. Соң бит, анда сугылып, монда бәрелеп, өтәләгән тавык кебек булып беткән иде. Алып килде шул өтәләгән тавыкны, ашатты-эчерде, кеше итте, юлга бастырды, адәм рәтенә керергә ярдәм итте. Бинипая шул ашка хәзер канлы-кара таш ата. Уф! Ничек җир йотмый шундыйларны? Әллә җир җирәнәме югыйсә? Булыр да. Җирнең дә җаны бар аның. Бар, бар, бар... Ярый, аның үзенә пычагым да булмас. Хөрмәтулла җәл. Таланган чебеш хәлендә калган иде бит мескен. Шуннан... ир-егетлек көчен йодрыгына төйнәп, чебеш-

тән янә арысланга әверелеп килә иде. Тагы да борчак измәсе урынына изгәннәр. Инде хәзер измәдән адәм рәтенә күтәрелә алмас. Бусы Хөрмәтулланың соңгы изелүедер. Тфү!.. Фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәсен берүк.

Галимҗан да шул хакта уйлап бара иде. Теге вакытта, Йосыф мәхдүм белән аларда булганда, нинди матур сүзләр сөйләгән иде Хөрмәтулла абзыйсы. Нәсел-нәсәп, ил-ватан, узган-булган гыйбрәтле хәлләр, киләчәк өчен өмет... Шуларны язарга кушты бит әле ул. Ә ничек язарга? Бу үзе зур тарих бит. Шул тарих дулкыннары эчендә — адәм балаларының авыр тормышы, даими хәрәкәте, киләчәк матурлык өчен җан атуы. Җәренгә, укып ялга кайткач, аның белән тагын да очрашыр иде, сүзләреннән күп фәһем алыр иде, читкә ыргытылганнарның йөрәк тибешен, җан әрнешен, күңел сыкрануын тагын да ныграк аңлар иде. Тик... Хөрмәтулла абзыйсын яңадан күрә алмас инде ул. Барысы да бетте. Ватылды. Җимерелде. Чәнчелде. Челпәрәмә килде. Әтисе өйдә булса, бер җаен табып, яклар иде әле аны. Хәзер батырачаклар Хөрмәтулланы. Үлем түшәгенә ятарлык итеп тукмаганнардыр. Алар Ырынбурга барып җитмәс борын ук аның җан тәслим кылуы бар. Алты бала ятим калырмы? Мәликә түти нишләр! Мәдинә-Акчәчкә бик нечкә күңелле шикелле. Әтисе үлеме кайгысын күтәрә алырмы? Ул бит баш бала. Тормыш авырлыгы аның җилкәсенә нык төшәчәк. Калганнары, энеләре, сеңелләре ниндидер икән? Аларын да күрәсе килгән иде аның. Тик беркөн, Йосыф шәкерт белән барганда, өйдә булмадылар. Берәр җиргә уйнарга китеп барганнардыр, бәлкем. Кояшлы матур көндә бала-чаганы өйдә тотып буламы? Әллә ниләр сөйләде-сөйләде дә язарга кушты бит Хөрмәтулла абзыйсы. Ничек язарга? «Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә»ләр кебек итепме? Ай-һай, һай, андый әсәрләр язу өчен бер генә түгел, биш пот тоз ашарга кирәктер ул. Андыйны Шакирҗан абыйсы сөйләгән... Теге ни... кем соң әле... Гаяз... Гаяз... Исхакый... Әйе... Гаяз Исхакый кебек пәйгамбәр җанлы бөек затлар гына булдыра аладыр ул. Их, Ырынбурга тизрәк барып җитәсе иде дә... шул Гаяз Исхакый әфәндене бер күрәсе иде...

Шакирҗан да бу минутта гамьсез күркәдәй кукраеп утырып бармый иде. Аның да йөрәге шул бер үк уй-кайгы утында янды. Нигә тормыш болай корылган? Ни өчен кешеләр берберсен ашый? Нишләп дөньяга ялган-нахак албасты канат җәя? Бусы — бер хәтәр кайгы. Икенчесе — шушы минутта әтисен кызгану. Ул әле атларны шартлап ярылыр дәрәҗәгә җиткән йөрәген басар өчен шулай куалый. Ул гүя авылда алган кара кайгы капчыгын төшереп калдыру, аның арттан

иярмәвен теләп шулай шашына. Әтисенең гамьсезлекне, нахак бәлаләрне, имансызлыкны яратмаганын, җене сөймәгәнлеген белә ич ул. Тик... менә кирәгеннән артык ярсый бит әле. Котырган үгез белән бер. Тәгәрмәчләр җиргә тияртимәс әйләнә. Атлар күбеккә батты. Әллә акылыннан яздымы әтисе? Гәрчә кызу канлы булса да, юлда чакта бу кадәр дә котырынганы юк иде ич аның. Болай чапса, йә атларның януы, йә тәгәрмәчләрнең кырылуы, йә бер-бер кырын җирдә арбаның каплануы бар.

— Әткәй!.. Әткәй!.. Син арыдың, ял ит бераз, дилбегәне үзем тотыйм,— дип тә карады Шакирҗан.

Бу сүзләр әти кешене ярсытып кына җибәрде. Тавыкны йомырка өйрәтми, дип уйлады да, үзен сабантуйда чабыш аты өстендә утырган малайдай хис итеп, атларны алагаем куалый бирде. Бераздан нәкъ Шакирҗан уйлаганча килеп чыкты. Бер сөзәк урында, әллә нинди дуңгәләккә орынып, арба да капланды, атлар да тәгәрәп киттеләр. Дөньяның гүя асты-өскә килде...

## *Алтынчы бүлек*

Бу дөньяга күзен ачкан мәлдә
Әверелер агу язмышка.
Ни ул шөһрәт — адәм үтерүме?
Йә үлүме? Ни дип кан куша?

*Гомәр Хәйям*

### I

Караңгы, авыр, кайгы-хәсрәтле язгы төн. Шәкертләр ястү намазын да кичтән рәтләп укымады. Моназарә-бәхәс тә бүген башка вакыттагыча уттай кызмады. Түлле тавышлар мәдрәсә эчен җимерердәй итеп яңгырап тормады. Ни галәмәт? Кыш буе үпкәгә яткан кара тузан балалык-яшьлек ялкынына кургаш пәрдә булып сарылдымы? Яңаклары эчкә баткан саргылт йөзләрдә, хәлсез күзләрдә, алҗыган карашларда яшәү өмете чаткылары сүндеме? Язның көтелмәгән караңгы, шөкәтсез төне авырлыгы бастымы күңелләрен? Шуларның бөтенесе берьюлы сеңдердеме тирән вә татлы йокыга?

Галимҗан йокламады. Кичен, ахшам вакытында ук, карлы-бозлы яңгыр явып үтеп, давыл купкан иде. Ул, адәм балаларын хөсетлек утында яндырырга шашынган иблис шикелле, һаман әле котырына: бер караганда, коточкыч дию

пəриедəй шыңшый, икенче мəл яраланган арысландай үкерə йә ач бүре булып улый.

Йа Хода! Кем əйтмешли, хəерле каза булсын! Билхəер! Əмма ул давыл-гарасатлардан билхəерлек-изгелек көтү — шайтаннан шəфкатьлелек өмет итү кебек кенəдер. Табигать ул кешелəр сыман. Аның җаны бар. Ач кеше — ачучан, дилəр. Ач кешенең ачуын китерсəң, Ходай күрсəтмəсен, ул инде җенлəнə-шашына белə. Бəндəлəрдəге шул сыйфатларны сизгəн табигать йөрəге дə үрле-кырлы килə. Башта мəдрəсəдə дөнья корылышын əллə ничек томанлы итеп аңлаттылар. Җирне, имештер, үгез мөгезе күтəреп тора. Күп шəкерт моңа ышана. Бəгъзе берсе дөнья читен безне əйлəндереп алган офык сызыклары белəн чикли. Ə инде җəгърафия өйрəнə башлаганнар иде, дөнья-галəмнең искиткеч серле, киң, зур икəнлегенə инандылар. Рəсəй акыл җитмəс дəрəҗəдə зур икəн лəбаса. Аның янында Япония тузан бөртеге генə. Шул тузан бөртеге Порт-Артурны яулап алды. Бу бит черкинең филне җиңүе белəн бер. Ай-һай, нык какшаган икəн Рəсəй — нəкъ ярлы кешенең таралып төшəргə торган иске арбасы.

Бу арбаны төзəтергə кирəк, имеш. Тəгəрмəчлəре тимердəн булсын, янəсе. Башка иллəр белəн ярышка чыкканда, ул тəгəрмəчлəр беркайчан да ватылырга тиеш түгел, ди. Моның өчен тəгəрмəче кырылырга торган патшаны тəхеттəн тəгəрəтеп, аның урынына Йосыф пəйгамбəр ише җитмеш төрле һөнəре булган, адəм балаларына бəхет, мул тормыш китерердəй илаһи бөек затларны куярга кирəк икəн. Шул җəһəттəн давыл-гарасат купты. Аны инкыйлаб дип атадылар. Инкыйлаб давылы иң əүвəл Мəскəү, Петербург, Казан кебек зур калаларда котырынды. Аннан Ырынбурга да килеп җитте. Урамнарда халык ташкыны ургылды. Ул ташкынга яңалык эзлəүче шəкертлəр дулкыны да килеп кушылды. Галимҗан дулкын үзəгенə ыргылды. Ул үзəктə Шакирҗан да бар иде.

Үзəкне эшче-рабочий халкы тəшкил итə. Алар бер-берсенə тимер чылбыр белəн бəйлəнгəн. Шул чылбыр комсыз, кеше җилкəсендə яшəүче капкорсакларның муенын буачак, янəсе. Бер уйласаң, бəхет дигəнең һич тə əллə кайда, Каф тау артында түгел икəн лəбаса. Ятьмə белəн балык сөзеп алган кебек, аны əлеге тимер чылбырлар белəн кама да ал. Бəй, кемнең рəхəт яшисе килми кунакка килгəн бу якты фани дөньяда? Эшчелəрнең гадəттəн тыш авыр тормышын шəкертлəр дə яхшы белə ич. Аларның күбесе җəйге көннəрдə шахтага, заводларга эшкə китə. Кыш укыр өчен акча əзерли... Тəүлегенə ундүрт-уналты сəгать, бəгъзе бервакыт аннан да күп этлəнеп, ач-ялангач, салкын баракларда иза чик-

кән эшчеләрнең аяныч тормышын шәкертләр үз күзләре белән күрде. Тик әлеге чылбыр йомшак икән шул әле — юкәдән ишкән иске дилбегә шикелле генә. Ул дилбегә тиз өзелде. Тормыш тәгәрмәче коргаксыган булса да, патшаның халыкны буарга әзерләгән тимер чылбыры хәзергә каты икәнлек беленде. Патша рәхимсез, кансыз, миһербансыз икән ләбаса. Петербургта әнә үзләренең җитди таләпләрен аңлатырга барган эшче-туганнарны патша гаскәре кыра да сала. Халык каны урамда елга булып ага. Бу хәл башка шәһәрләрдә барлык эшчеләрнең йөрәген ярсыта. Канлы хәбәр чит илләргә дә яшен тизлегендә барып җитә. Жандармнар Ырынбурда чит ил социаль-демократлары җибәргән язмаларны таба. Канга — кан, җанга — җан, ачуга — ачу дигәндәй, бөтен җирне инкыйлаб дулкыннары чолгап ала. Дулкын Уфа заводларына да җәелә. Дулкынга солдатлар да, крәстиәннәр дә кушыла. Тик дулкын һаман-һаман инкыйлабчылар каны белән тирәнәя бара.

Шул дулкыннар арасында бәхет эзли-эзли ике мәртәбә нахак бәлагә юлыккан Хөрмәтулла да йөзеп йөри кебек тоелды Галимҗанга. Хөрмәтулла!.. Мөбахис йортына ут төрткән, дип, аны тагын да борчак измәсе урынына изеп ташлаганнар. Суд-хөкем ясап, аны Себер җибәргәннәр. Шул кадәр изелүләрне тагын да күтәрә алды микән? Әле исән микән? Исән булса, әлбәттә, кеше бәхете, гаделлек өчен көрәшкә ул да күтәрелгәндер. «Көрәш кирәк» дигән сүзләрне кат-кат әйткән иде бит. Ә нинди көрәш? Ничек көрәшергә? Нинди сыйфатта? Галимҗан моны үзе дә аңлап бетерә алмый әле. Ул әле мәдрәсәдә уку-укытуны яңарту, аңламаган гарәп сүзләрен ятлатудан арыну, динне генә түгел, тарих, җәгърафия, әдәбият, математика, физика һәм башка фәнне укытырга кирәклек өчен көрәшә.

Ни белән чикләнер бу көрәш? Дөньяны инкыйлаб дәһшәте чолгап алды. Давыл. Гарасат. Кан коеш. Табигать йөрәге шуны күреп әрниме? Тышта җил-давыл шуңа котырынамы? Торыгыз, йоклап ятмагыз, күтәрелегез, ялкаулар, изелгәннәр мәңге бәхетсез, диме? Җил шуның өчен ач бала имчәк сорап акырган кебек елыймы?

Кешенең баш миендә ундүрт миллиард чамасы күзәнәкнейрон бар, имеш. Алар да тормыштагы, табигатьтәге вакыйга-күренешләр, адәм балалары йөреше-кыланышы кеби, даими дулкынланып, чайкалышып торалар икән. Ул күзәнәкләрдә табигать, яшәеш, галәм-дөнья хәрәкәт-манзаралары чагыла, ди. Димәк, кешенең йөрәге табигать йөрәге белән бәйле булган кебек, аларның миләрендәге әллә күпме миллиард нейроннар да бер-берсенә керешеп яши булып чыга. Тормыш, яшәеш, фани дөнья манзаралары Галимҗанның ко-

лагына «яз, яз, яз» дип пышылдагандай. Аннан ул сүзләр колактан күңел түренә, йөрәк төпкеленә үтә, ми күзәнәкләре дулкынына үрмәли, уйландыра, ярсыта, яшәүне авырлаштыра. Ми күзәнәкләре дулкынына хәзер инкыйлабый-революцион көрәш турындагы мең-миллион бөрчекләрдән торган хис-тойгы, уй чаткылары килеп керде. Алар да ярсыта, үрле-кырлы китертә, күңелне шаштыра. Кешеләргә фәкать бәхет теләп, тышкы котсызлыгы белән күпләрне өркеткән-куркыткан, әмма эчендә гәүһәр йөрткән, нахак бәлаләрдән изелеп-тапталып та, кешелеклелек сыйфатын саклап кала алган Хөрмәтулла шикелле мең-миллионнар азатлыгы өчен көрәш мәйданына чыгарга иде. Мәдинә-Акчәчкә төсләләргә ничек бәхет китерергә? Аларны караңгы баздан, тормыш фаҗигасеннән нинди көчләр белән тартып чыгарырга? Уйлар! Уйлар! Уйлар! Алар тыштагы давыл-гарасаттан ким ярсымый. Бу ярсу, шашу, котырыну шаукымы белән тилергән йөрәк ташкынының бөтен Рәсәй киңлегендәге революцион көрәш дулкынына барып кушылачагын Галимҗан һич тә башына китерә алмый әле. Мөселман комитеты рәисе, ялкынлы революционер Мулланур Вахитовның ярдәмчесе булачагын, Ленин белән очрашачагын кайдан белсен ди Вәли мулла мәдрәсәсе шәкерте Галимҗан. Аның әлеге ми күзәнәкләрендә ниндидер көрәш кирәк булачак уй-хис дулкыннары гына кайнаша. Ул дулкыннар Галимҗанны төн буе йоклатмады. Ә таң алдыннан:

— Торыгыз!.. Иртәнге намазга!..— дигән тавыш яңгырады.

Тик Галимҗан моны ишетмәде. Ул инде уй дулкынына түгел, йокы дулкынына чумган иде.

Бүлмәдәше Шәһит, әлеге тавышка сикереп торып, тиз генә киенеп алды. Ашык-пошык, йөгерә-атлый, кабалана-кабалана барып, ничек җитте, шулай тәһарәтен дә алып килде. Ә Галимҗан, җәннәттәге кайгысыз хур егете сыман моңсызланып, һаман йоклый иде әле. Шәһит аптырап китте. Ул бит Галимҗанның мондый мәнсезлеген беркайчан да күрмәде. Бөтен эшне йөзенә кызыллык китермәслек итеп башкара. Вакытында ята. Вакытында тора. Ни булган аңа бүген? Әллә авырып киткәнме?

— Галимҗан!.. Галимҗан!..

— Әү...

— Тор!.. Мин инде әллә кайчан тәһарәт алып килдем... Иртәнге намазга соңлыйсың бит...

Галимҗан шаяртуга күчте:

— Син бүген минем өчен дә укы әле, Хак Тәгалә...

Йосыф Казанга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчкәч, Галимҗан бер бүлмәдә Шәһит белән яши башлады. Алар тиз

дуслашты. Шәһит ятим бала икән. Әтисе дә юк, әнисе дә. Ул бай шәкертләргә самавыр куеп, аларның төрле вак-төяк эшләрен башкарып яши. Моның өчен аңа, аз булса да, акча бирәләр. Вакыт-вакыт калган ашлар да эләгә. Башта Галимҗан аның бу гадәтен килештереп бетермәде: түбәнсенү, кеше табан астын ялау була, янәсе. Шәһит моны башкачарак аңлый икән. Авыл мәктәбендә дә ул кешеләргә хезмәт итә-итә укыган. Бу — аның маңгаена язылган язмышы. Аның фикеренчә, язмышлардан узмыш юк. Мәдрәсәдә дә язмыш аны көлеп-елмаеп, шатланып, чәбәкәй итеп түгел, тешләрен ыржайтып, йодрык төйнәп каршы ала. Боларны ул Галимҗанга беренче чәй табынында ук сайрап салды. Мәзәк итеп, бер урында сүзләрен чигүләп-матурлап, икенче урында майлап-баллап, өченче урында чәнечкеләп-кылчыклап сөйләде. Аның көр күңелле булуы, сүзнең җаен-чамасын белүе, авыр хәлен җиңеләйтеп, хәтта көлкеле итеп сөйләве ошады Галимҗанга. Ә инде бай шәкертләргә чәй кайнатуы, аш пешерүе, вак-төяк эшләрдә ярдәм итүенә ул аз гына да түбәнсенми. Моны да язмышка бәйли. Ходай шулай кушкан, ди.

— Мин бит урламыйм, Галимҗан, кешеләргә хезмәт итәм; моны шәригать тә, инсаният тә яклый,— дигән иде ул вакытта.

Шәһитнең нур сибеп торган моңлы күз карашлары, ягымлы сөйләшүе, матур елмаюы, чибәр йөзе, сөйкемлелеге һәркем тарафыннан яратырлык сыйфатлар иде. Аларны ул беркайчан да югалтмады. Кешеләргә карата булган ярату хисләре аны һаман-һаман олы йөрәкле итеп күрсәтте. Дөрес, аның кайбер гадәтләрен Галимҗан яратып та бетермәде: бай шәкертләргә тамак өчен вак-төяк хезмәт итү бервакыт аны артык вакламасмы, ир-егетләрдә була торган горурлыкны чүпләмәсме? Шуларны уйлап, акча белән дә, ашау ягыннан да ярдәм итәргә тырышты. Ләкин андый чакта Шәһитнең матур, көләч йөзе кинәт үзгәреп китә, моңсуланып кала, күз карашлары мәзәкләнә, хәтта иреннәре калтырап куя. Моны ул хезмәт итми генә тамак өчен кешеләргә ымсынып, кул сузып йөрүче теләнче эше дип исәпли иде.

Укуда ул, Галимҗан дәрәҗәсендә үк булмаса да, һәрхәлдә, алдынгы шәкертләр исемлегендә йөрде. Хәлфә соравына җавап биргәндә, бәгъзе бер йомшак бәдәнле шәкерт шикелле, аркасында чыбык чыжлаудан куркып, мескенләнеп-калтыранып тормады. Хәер, хәзер инде белеме, бәхәс вакытларында мантыйк эзлеклелеге күрсәтүе, акылы буенча алдынгы шәкертләрне генә түгел, мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла, Заһидулла хәзрәт, Зарф хәлфәләрдән нык өстен торган Галимҗан булмәсендә яшәп, нишләп әле Шәһит шәкертләр койрыгында болгансын ди.

«Шәһит» дип изге көрәшләрдә хаклык өчен җан тәслим кылган мөселман бәндәләренә әйтелә. Шәһитнең исеме җисеменә туры килә. Ул күңеле белән хак кеше. Шуңа күрә Галимҗан аны, яратып, якын күреп, берникадәр шаяртып, «Хак Тәгалә» дип атады. Тик әле менә Галимҗанның «Хак Тәгалә» дип эндәшүе, иртәнге намаз алдыннан шаяртып маташуы ничектер сәер тоелды. Шулай да Шәһит моңа әллә ни игътибар итмәскә тырышты. Соңга калмас өчен, кабалана-кабалана, иртәнге намазга йөгерде. Ә инде Шәһит әйләнеп кайтканда, Галимҗан яңадан йокы чүлмәгенә чумган иде.

## II

Ни гаҗәп? Нигә болай? Нишләп һаман тормый ул? Галимҗанның вакыт-вакыт авырып китүен белә Шәһит. Шуның өчен «Хөсәения» мәдрәсәсенә алмаганнар бит. Икенче ел укыганда, абыйсы Шакирҗан, кем әйтмешли, теше-тырнагы белән тырышып караса да, максатка ирешә алмады. Сәламәтлеген тикшергән чакта, Галимҗан тагын да нык ютәлләп җибәргән. Шулай да Галимҗанның моңа әллә ни исе китмәде. Кайда каралганмын, шунда агарыйм, дип, Вәли мулланың шушы караңгы мәдрәсәсендә үзен агартырга булды. Ә инде сәламәтлеге начарая баруын беркемгә дә сиздермәскә, үзен гел-гелән «горур», күтәренке күңелле, вакыт-вакыт шаян табигатьле итеп күрсәтергә тырышты.

— Галимҗан!.. Галимҗан!.. Мин инде иртәнге намаздан кайттым, ә син һаман йоклыйсың, хәзрәт-фәлән килеп керсә, өстеңә мең төрле кара бәла ягачаклар; тор, дускай, болай ярамый, мәдрәсәнең эчке тәртибен онытмагансыңдыр бит.

— Юк, юк, Шәһит дускай, онытмадым. Ә намаз өчен борчылма. Мин аны түшемдә укыдым.

— Шаяра торган вакыт түгел, Галимҗан!

— Ә мин чын әйтәм.

Дусты һаман-һаман төрткәләп торгач, хәтта чеметкәләп алгач, Галимҗан торып утырырга мәҗбүр булды. Шуннан ул бер строфа шигырь әйтте:

Бу дөньяга күзен ачкан мәлдә
Әверелер агу язмышка.
Ни ул шөһрәт — адәм үтерүме?
Йә үлүме? Ни дип кан куша?

Шәһит тәмам гаҗиз булды.

— Галимҗан!.. Син саташасың. Шигырь укып утырыр вакытмыни, валлаһи! Аңлыйм инде кичерешеңне. Әгәр Го-

мәр Хәйям әйткән агу язмышка әверелгән икән, аны төзәтеп буламы? Әгәр бүген адәм үтерү кем өчендер шөһрәт икән, Ырынбур урамнарында кан ага икән, ул кан елгасын гәүдәң белән генә буа алмассың бит.

— Ырынбур урамнарында гына түгел шул, Шәһит дускай, бөтен ил буенча. Син шуны бел: бу әле инкыйлаб каны диңгезенең чишмә башы гына. Ул каннар, аһ, күп булачак.

— Галимҗан!..

— Ярый, Хак Тәгалә, борчылма.

— Ник борчылыйм. Төне буе җил-давыл котырынды да, иртәнгә басылды бит әнә. Инкыйлаб гарасаты да шулай булыр.

— Син өстән-мөстән уйлыйсың, Шәһит дус!

— Ә син һәрнәрсәнең төбенә төшәргә тырышып бетерәсең үзеңне, авыруың турында да уйламыйсың. Сәламәтлек — кешенең көзгесе, дигән иде беркөн теге табиб.

— Сәламәтлекнең түре — йокы, Хак Тәгалә!

Шәһит кызып китте:

— Соң, шулай булгач, нигә бүген төне буе йокламадың? Үрле-кырлы килдең?

— Сәламәтлекне күз белән күрмиләр, колак белән ишетмиләр, тик җан-тән белән генә сизәләр.

— Соң, сиз алайса, җаның-тәнең белән той. Башыңда мең төрле хыял. Һәрберсе мөмтаз, изге булсын. Авырулар кешене сазга батыра.

— Ә мин әле сазга йөз тотмыйм.

— Йолдызларгамы?

— Без — йолдыз балалары.

— Оһ! Тагын да хыял.— Шәһит кул селекте. Бәхәстә, сүз көрәшендә сине җиңеп булмас, дигәнне аңлата иде бу.

Аларның низаглашуын бүлмәләр арасында акыра-бакыра йөргән Зарф хәлфәнең казан төбе кырган тавышлар чыгарып чәрелдәве бүлде:

— Шәкертләр!.. Мәдрәсәгә Вәли мулла җәнаплары үзе килде. Аның сезгә әйтер сүзе бар.

* * *

Мондый вакытта шәкертләрне махсус бер зур бүлмәгә җыялар. Аның сәкесе бар. Мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла, тамагын кыра-кыра, үзен Мөхәммәт пәйгамбәрдән дә өстен бер олы зат-шәхес санап, аның өчен махсус тәгаенләнеп куелган йомшак мендәргә менеп утыра. Аның кулына Зарф хәлфә сузылган еланны хәтерләтеп торган бер чыбык китереп тоттыра. Монысы инде аның «тәртип коралы» була. Сүз башлар алдыннан бу коралны уйнатып ала торган гадә-

те дә бар. Бу — аның үзен алып батыр кебек гайрәтле итеп күрсәтергә маташу галәмәте. Мондый чакта шәкертләрнең күзе тоздай була. Бәгъзе берсе бүре алдында торган мескен сарыктай калтырана. Болары — куркаклар. Икенчеләре үзләрен төлкечә тотарга тырыша. Болары — хәйләкәрләр. «Ни рәвешле ярыйм сиңа, и Вәли әфәнде җәнаплары»,— дип уйлаганнар. Өченче бер төрлеләре аңа каты карый. Мондыйлары: «Урын кешене бизәми, кеше урынны бизи»,— дип хис иткәннәре. Астыртын караучылар да була. Алар — астан кисеп, өстән ямый торганнар. Астындагы мендәрен тартып алып, аны как сәкегә утыртырга теләүчеләр.

Шул ук хәл бүген дә кабатланды. Шәкертләр җыелганда, Вәли мулла ике кат йомшак мендәр өстендә кукраеп утыра иде инде. Чыбыкны чыжлатып алса да, шәкертләргә ул мөлаем карарга тырышты. Әллә нинди куркыныч заман килгәнне әллә белмиме ул? Белә. Бәгъзе шәкерт, аның уйлавынча, имансызлыкның чигенә чыкты. Бөтен бәла әлеге дә баягы шул инкыйлаб дулкыннарының ярсуында. Имансыз шәкертләр шайтан котыртуына тиз бирелә. Шундыйларның берсе Гыйрфан мулла улы мәхдүм Галимҗан Ибраһимов булып чыкты. Әтисе кем? Нәсел-нәсәбе кем? Ә менә балалары — динсез, дәһри. Аттан ала да туганы, кола да туганы шушыдыр инде, илаһым! Күпме ут йотты, җан атты Вәли мулла аны кеше итәр өчен. Мәдрәсәдән бер куылгач, бер юньсез кеше булса, аны монда яңадан эз дә бастырмас иде. Теге вакытта «котылдым бу дуңгыздан» дип уйлаган иде Вәли мулла. Әмма ләкин дә әтисе Гыйрфан мулла килеп ялынгач, сүзләре белән йөрәгенә сары май булып төшкәч, баласының киләчәктә төзәләчәге хакында ант иткәннән соң, янә укытырга ризалашты Вәли мулла. Ит яхшылык — көт явызлык, дигәне шушы икән. Тагын әллә нинди мең төрле таләпнамә язып килгән. Имеш, кадимчә уку хәзерге шәкертләрне кызыксындырмый. Яңалык җилкәдән ала, янәсе. Барлык фәннәрне укытырга кирәк.

Әллә бу хакта Вәли мулла белмиме? Белә. Әллә баш ватмыймы? Вата. Башын ташка бәрердәй була бәгъзе бер вакыт. Бәрсәң — баш ватыла. Биреп кара син Зарф хәлфәгә ул теге ни... илләр өйрәнә торган фәнне... ягъни дә мәсәлән... җәгъърафияне... Үз авылының кай төбәктә икәнлеген белмәгән кибәк баш... Әлеге теге ни... Парт... Парт... Парт... ар... ар... ничек соң әле, каһәрең?.. Әйе, Пуртартурны тартып алып... Русия ярасына тоз сипкән Җан... Җан... Җапуниянең кайсы төштәрәк икәнлеген ничек чамалый алсын да... шәкертләргә аны хәритәдән[1] ни рәвешле

[1] Хәритә — карта.

таптыра белсен. Хасиятсез бер кибәк баш бит ул. Тыштан кояштай балкыган була. Эчендә, баш миендә, мең пот аңгыралык шаукымы.

Монысы бер булсын, ди, ягъни дә мәсәлән. Икенчесе шул: хәзер монда килүче хәлфә-мөгаллим юк. Имештер, Вәли мулланың мәдрәсәсе караңгы баз белән бер. Анысын да рас әйтәләр. Ләкин бит диварлары череп, туксан яшьлек карттай бәлтерәп торган ул мәдрәсәне күз ачып йомган арада алтын сарай итеп булмый. Моның өчен Алла кодрәте кирәк. Ә ул бәндәләрдә юк.

Янә азгын шайтан урынына кытыклап торган өченче бер куркыныч бар: Вәли мулла үзенең уй тубалында җил уйнаганны яхшы белә. Ә инде Зарф, Шәех, Хәмзә кебек хәлфәләр монда башка мәдрәсәдә артык калҗа булганга килде. Ярлының бура төбен мең кат себерсәң дә, бер уч он чыкмаган кебек, мәдрәсә таягы белән көн дә яткырып мең мәртәбә тукмасаң да, аларны инде хәзер адәм рәтле хәлфә-мөгаллим итеп булмый. Шулай да Вәли мулла өчен алар — ифрат дәрәҗәдә кыйммәтле асылташлар: синең белән бәхәсләшә алмыйлар, табан астыңны яларга әзер торалар, мәдрәсә эчендәге кара тапны һич тә урамга чыгармыйлар. Галимҗан кебекләр ул селәгәйләрнең авызын тиз томалый шул инде хәзер. Аларныкын бикләп, Вәли мулланың үзенекен капламакчы. Шул котыртты шәкертләрне. Хәзер алар оясына таяк тыгып болгаткан кырмыскалар урынына кайнаша. Бу низагның янә дә шулай котырынуы мөмкин түгел. Котылырга бу шайтан арбасыннан төшеп калган имансыздан! Моның өчен Заһидулла хәзрәт, әлеге шул Зарф, Шәех, Хәмзә хәлфә-мөдәррисләр белән киңәшләшү булды. Алар әле, патшаның тән сакчыларына охшап, Вәли мулланың як-ягында утыралар.

Вәли мулла, үзенең шөһрәтен вә мөмтазлыгын күрсәтү өчен, иң әүвәл дөнья хәлләре турында берникадәр сафсата сатты. Япон сугышын искә алды хәтта. Борының сыймастай тишеккә башыңны тыгарга маташма дигәндәй, киң дөньяга сәяхәт иткән булып, теленең капкынга эләккәнлеген сизми дә калды.

— Рәсәйдән биш мәртәбә зур Җапуния мәгърибдән, сугыш башлап, Пуртартурны алды, — дигән иде, мулланың хатасын тиз аңлаган шәкертләр, кых-мых килеп, көлеп җибәрде. Вәли мулла, шау-шуны басар өчен, чыбыгын чыжылдатып алды да янә иҗтимагый-сәяси хәлләр дөньясына кереп китеп, соңгы вакытта булган инкыйлабый вакыйгаларны, кан коелу мәсьәләләрен телгә алды. Боларның халык бозылудан, динсез-дәһриләр арта барудан, күпләрнең Аллаһы Тәгаләне бар дип белмәүләреннән килүен әйтте. Баксаң, андый

дәһриләр менә шушында, аның әйтүенчә, дин вә изгелек бакчасында тамыр җәя башлаганнар. Бусы инде, Ходай үзе сакласын, гөлбакчадагы шайтан таягы кеби. Шундыйларның берсе — иң куркынычлысы — Гыйрфан мулла улы Галимҗан Ибраһимов. Вәли мулла, тамак кыра-кыра, ашыкмыйча, җайлап-майлап кына, Галимҗан өстенә чиләкләп-чиләкләп пычрак су коярга тотынды. Имештер, Галимҗан башта мәгъсумлек, сафлык, тырышлыкның гүзәл өлгеләрен күрсәтүче мәгърур шәкерт булган. Ә хәзер мәгыйшәтлек, нәҗеслек, аламалык юлына баскан. Аны күп мәртәбәләр сыраханәдә күргәннәр. Сары сакаллы урыслар белән аракы эчеп, тәмәке тартып, кәнтәй Мәрүскәләр янына барып йөри, имеш. Дәхи дә адәм балаларын юлдан яздыра, йә котырта, көфер итә торган китаплар укый икән. Шундый шайтан җанлылар күбәйсә, Ходай үзе сакласын, мәдрәсәне яшен сугуы ихтимал. Бүгенге Рәсәйдәге канкоеш Галимҗан кеби бозык канлы кешеләр аркасында. Аллаһы Тәгалә бәндәләргә авырлыкны шуның өчен сала. Хөрриятпәрвәр булам дип, бәйдән ычкынган эт шикелле, үз нәфесең өчен генә яшәү — Алла алдында зур гөнаһ эшләү.

Озак сөйләде Вәли мулла. Тәмләп, ләззәтләнеп, түгәрәк сакалын сыпыра-сыпыра, вакыт-вакыт кикерә-кикерә, тәмам ышандырыйм дигән ният белән сөйләде.

— Әлхасыйль, шәкертләр, Гыйрфан мулла углы Галимҗан мәхдүмне без мәдрәсәдә моннан ары бер генә көн дә тота алмыйбыз, чүп үләнен вакытында юк итү хәерледер, — дип бетерде сүзен.

Шуннан соң сүз тынлыкка бирелде. Озак торды тынлык. Дәшмәде. Нәүмиз булып калдымы? Уйланырга мөмкинлек бирдеме? Адәм балаларының сабырлыгын авыр, караңгы, куркыныч мизгелдә сынап карыймы? Аларның яктылыкны күрмәүләренә хәйран калдымы? Шәкертләрнең бәгъзесе — оһ, бу шомлы таяк минем башыма төшә күрмәсен, дип шүрләп утырганы коелды да төште. Икенче бер төрлесе — Галимҗанга карата булган сүзләренең нахак икәнлеген аңлаганнары — Вәли мулланың бүлтәеп торган кызыл бит очларына барып ябыша язды. Өченчеләре — Вәли мулла сүзләренә ышанган аңгыра-җиңел акыллылары — эчтән генә Галимҗанның тетмәсен тетте: аның аркасында бөтен мәдрәсә йөзенә кара ягыла, янәсе.

Тынлык сабыр булды. Тынлык эндәшмәде. Тынлык сүзне янә Вәли мулланың үзенә бирде. Вәли мулла хәзер Галимҗанны мәдрәсәдән куу өчен язылган әмернамәне укырга тиеш иде. Ләкин Галимҗан моңа ирек куймады. Аягүрә басты да тынлыкка колак салды. Тынлык ашыкмаска, каушамаска, нык торырга, көрәшергә кушты.

Ашыкмады Галимҗан. Каушамады. Калтыранмады. Иң әүвәл Вәли муллага карап катты. Каты карады. Ул караштан Вәли мулланың әлеге ике бит очындагы кызыл бүлтәймәсе күгәреп катты, кулындагы чыбыгы төшеп китеп, күәс чиләге юанлыгы гәүдәсе калтыранып куйды. Шуннан Галимҗанның утлы карашы Заһидулла хәзрәтнең дә йөзен көйдерде, табан яларга ятратучы хәлфәләрнең дә кашын җимерде. Аннан утлы караш ялкыны һәммә шәкертнең йөзен берәм-берәм ялмап алды. Куркак күзләр, агарып каткан йөзләр, салынып төшкән борыннар күрде Галимҗан. Әмма күпләрнең йөрәге үзенеке белән бергә типкәнлекне, каннары бердәй кайнашканлыкны, бер хис-тойгылар кичергәнлекне сизде Галимҗан. Шәһит тә, сикереп торып, Вәли муллага менә-менә ташланыр арысландай утыра. Шәһит яклылар Галимҗанның Вәли мулланы он-талкан итәрдәй бик каты сүз әйтүеннән дә курыкмадылар. Галимҗанда усаллык та җитәрлек ич. Шулай да көткәнчә килеп чыкмады. Тынлыктай тыныч иде Галимҗан. Ул Вәли муллага Япониянең мәгърибтә түгел, мәшрикъта икәнлеген әйтүне дә кирәк санамады. Карганы кырык мәртәбә сабынлап юсаң да агартып булмаган кебек, карт наданның миенә кырык көн буе ак нур өрсәң дә, аны барыбер аңлы итә алмассың.

Галимҗан, үзен һаман шулай горур тотып:

— Юк, кирәкми, укымагыз, мин, сез кумасагыз да, мәдрәсәгездән китәргә җыйналып беткән идем инде,— диде.

Вәли мулла иркен тын алып куйды. Бәй, Ходайның рәхмәте, бу авыр төен бик җиңел генә, бернинди низагсыз чишелә ләбаса. Әмма Галимҗанның соңгы сүзләре Вәли мулланың капкорсагын чак шартлатмады.

— Карга оясына бөркет беркайчан да кунмаячак, кара базга кояш бервакытта да төшмәячәк,— диде дә тып-тын басып чыгып китте.

Галимҗанның хәзер киная белән, мәкаль-әйтемнәр кыстырып, үткен сөйләвен һәммәсе белә иде инде. Вакыт-вакыт ул надан башка аңлавы кыен булган чагыштырулар да куллана. Әмма бу кадим мәдрәсәсен карга оясына охшатуын дивана да аңларлык. Ә бөркетләр кем? Үземе? Йә булмаса шул «ирек-азатлык» дип җан аткан, селәгәй агызган әтрәк-әләмнәрме? «Кара баз», имеш. Кояшы нәрсә? «Яктылык өчен көрәш» дип авыз ерталар. Үзләрен кояшка саныйлармы? Әллә-ләл, әллә-ләл, мәгыйшәтне, тормышны, «ә» дигәнче, кояш нуры белән коендырмак булалар. Тот капчыгыңны! Юкара кулыңны мең кәррә сабынлап...

Галимҗан чыгып киткәч, кара болыт таралып, әнә шул якты кояш ялтырагандай тоелган иде. Ләкин аслан алай түгел икән. Уртага Шәһит чыгып басты. Мәдрәсәдә үз го-

мерен башкаларга хезмәт итеп үткәргән, аз сүзле, миһербанлы, күндәм, мөлаем йөзле бу шәкерттән фәкать яклау сүзләре көткәннәр иде. Тик ул, фикер тәртәсен бөтенләй башка якка борып җибәреп, суны Галимҗан тегермененә коярга керешде:

— Сезнең әмернамәгез белән килешмим. Галимҗанның күп укуы дөрес. Аның хәзер белмәгәне юк. Ул һич тә кирәкмәгән китап укымады. Нигә сез сыраханәләрдә, кярханәләрдә, фәхешханәләрдә йөргән, ун ел буе ми черетеп, әлифне таяк дип белмәгән җәһаләт шәкертләрне кумыйсыз, ә? Нигә шәкертләр арасында үзен пәйгамбәр итеп күрсәтә алган Галимҗанга каныгасыз? Бу пычрак эшегез өчен мин сезнең өстән Уфага — әһле мәгарифкә язачакмын. Ә хәзер, Галимҗан китсә, мин дә аннан калмаячакмын!..— дип, шуларга охшаш тагын әллә күпме куркыткыч сүзләр әйтеп, чыгып китте.

— Мин дә китәм...

— Мин дә...

— Галимҗаннан калмыйбыз...

— Нигә яшереп тәмәке тарткан Гыйсмәтне күрмисез?..

— Фәхешханә юлыннан кайтмаган Рәхмәй ал да гөл яши.

— Хәмер чөмергән чучка борын Шәйхисламны куарга кирәк.

— Шушыларны әһле мәгарифкә язмый калсаммы...

— Оясын туздырабыз...

— Нәләт бу мәдрәсәгә...

— Ләгънәт...

Шундый сүзләр әйтә-әйтә, хәтта йодрыклар күрсәтә-күрсәтә, Шәһит артыннан егермеләп шәкерт чыгып китеп, Галимҗан бүлмәсенә кереп тулдылар. Аларның барысы да ярсу иде. Бәләкәй бүлмәдә аяк басар урын да калмады. Хәмит исемле шәкерт Галимҗан, Шәһит чыгып киткәч булган хәлләрне кыскача гына бәян итте дә:

— Барыбыз да мәдрәсәдән бүген үк китәбез,— диде.

Ләкин Галимҗан моңа каршы төште:

— Юк, дуслар, алай ярамый, мәдрәсәдә «Шәкертләр иттифакы» төзедек. Сез аны таркатырга тиеш түгелсез. Көрәшергә кирәк. Мин үз урыныма Шәһит Әхмәдиевне калдырам.

Шәһит аның сүзен бүлде:

— Юк, юк, Галимҗан, мин синең белән...

— Ярамый, Шәһит дус, очрашырбыз әле, хатлашып торырбыз.

— Ә син кая китмәкче буласың?

— Казанга. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә. Анда остазым Йосыф мөдәррис икән инде. Сәләтле иде ич ул. Соң, хатын укып күрсәткән идем бит инде, Шәһит.

Сүзгә төптән үк юан үскән калын тавышлы Хәмит кушылды:

— Галимҗан, мин гаҗиз булып калдым, нигә сиңа китәргә ярый да, безгә юк, ә?

Галимҗан уратмый-чуратмый, гади генә итеп аңлатып бирде:

— Миңа калырга ярамый, туганнар! Күз алдында әмернамә язылган бит инде. Алар өчен иң куркынычлы кеше идем. Ә хәзер сезгә тимәячәкләр. Чөнки куркалар. Мәдрәсә шәкертсез калса, Вәли мулла армиясез генерал кебек булачак бит...

## III

...Аллаһы Тәгалә көферләрне нык күзәткән вә үз рәсүленә каршы көрәшүчеләр булуны искәрткән. Мөхәммәт пәйгамбәр (Аңа данлау һәм хөрмәт булсын) үзе урынына туганнан туган энесе Гали Ибне Әбүталипны калдырып кача. Аллаһы Тәгалә исә Мөхәммәтне үтерер өчен сагалаучыларга йокы җибәрә. Мөхәммәт киткәч, аны эзәрлекләүчеләр йокыдан арынып өйгә килеп керсәләр, Мөхәммәт урынына Әбүталипны күреп хәйран калалар.

Их, Мөхәммәт пәйгамбәр кебек булса икән Вәли мулла. Үзе урынына мәдрәсә башлыгы Заһидулла хәзрәтне калдырып, якасыннан алучыларны йоклатып, күзләрен сукырайтып бетерергә иде. Мәдрәсә хәзер рәсүл алдында калтыранып торган мәҗүс хәлендә калды. Укырга килүчеләр саны елдан-ел кими бара. Шәкертләр бар — мәдрәсә бар. Шәкерт юк — мәдрәсә юк. Ач күз Заһидулла хәзрәткә, Зарф кеби җебегән авызларга ышанып шушы көнгә калдымы ул? Әллә үзенең ми казаны тишек булып чыктымы? Беркөн теге эт авыз Габдрахман сәүдәгәр:

— Япония җиһанның кай төшендәрәк? — дип сорагач.

— Мәгърибтә,— дип җавап биргән иде бит.

Алдаганмы тирес бит, кеше алдында аны адәм көлкесенә калдырырга уйлаганмы, әллә үзе дә белмиме? Ул бит Җапунияне Рәсәйдән мең кат зуррак дигән иде. Монысын да аны сынар өчен көлеп әйткәнме хәшәрәт? Ни эшләде бу кешеләр? Нигә аннан каһкаһ көлә башладылар? Нигә Алладан курыкмыйлар? Әллә Аллага ышанмый башладылармы? Алласы бармы бу яхшыдан туган яман Галимҗанның? Беләме ул үзе бу диннең чишмә башы кайда икәнлекне?

Галимҗан боларны белә иде инде. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәтендә менә ничек яза ул: «Пәйгамбәрнең тормышын һәм эшләгән эшләрен белү — шәригатьчә ти-

ешле икәнлеге, хәлифәлекләр заманында һәм гадел хәлифәләр заманында булган яулап алу сугышларының үзенчәлекләрен аңлауның хөкемнәрен үтәүдә зарурияте, хәдисләрнең дөреслеген тикшерү кирәклеге кебек хәлләр — мөселманнар арасында ислам тарихын, пәйгамбәрләр тарихын, ислам дине эшлекleләренең тәрҗемәи хәлләрен, яулап алу сугышлары тарихын мәйданга чыгарырга мәҗбүр итте. Мәгариф гыйлеме дәверенә кермәс борын ук тарихның тууына сәбәп булды. Болар башта телләрдә генә йөрелә, телдән укыла иде. Бара торгач, китаплар языла башлады. Ислам тарихы бөтен тармаклары белән барлыкка килеп, ислам каләмнәре тарафыннан тарих китаплары язылды.

Ислам тарихына караган иң беренче китап язучы һиҗри белән 93, милади белән 711 елда вафат булган Гарвәт бине Зөбәердер.

Һәр гыйлемнең, һәр фәннең, хәтта һәр хакыйкатьнең тамыры бар. Галимҗан бөтенесен дә әнә шул төбе-тамырыннан башлап өйрәнә. Үзлегеннән өйрәнә. Бервакыт мәдрәсәдә Коръәнне кем язу турында бәхәс купкан иде. Берсе дә әйтә алмагач, үзен бик белдекле санап, йөзенә менә мин сез җаһилләргә кем икәнлегемне күрсәтим әле, дигән төс чыгарып:

— Коръәнне Мөхәммәт пәйгамбәр язган,— диде чатнатып.

Галимҗан анда да Вәли мулланың ялган авызын каплады:

— Мөхәммәт пәйгамбәр укый-яза белмәгән бит.

Сүкте дә китте Вәли мулла Галимҗанны:

— Ахмак... мин сине аңлы шәкерт дип йөрсәм... Кеше алдында әйтә күрмә бу сүзләреңне...

Бу хакта Галимҗан шәкертләргә аңлаткан иде инде. Коръәннең гасырлар буе халык күңеле иҗат иткән энҗе-гәүһәрдән торуы, анда яшәү рәвеше, әхлак кануннары туплануы, сафлык-инсафлылык, намуслылык, кешелеклелек-инсаниятчелек рухының югары дәрәҗәдә куелуы, һәр сүзенең күп мәгънә аңлатуы, асылташтай кыйммәтле булуы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде. Вәли мулланың шуны да белмәве шәкертләрне нык аптыратты. Шуннан соң Вәли мулла шәкертләр арасында артык буталып йөрмәүне мәслихәт күрде. Күп эшне мәдрәсә башлыгы Заһидулла хәзрәткә йөкләде. Хәзрәт исә төлкедәй койрык болгаучы булып чыкты. Күп очракта шәкертләр белән килешү җаен чамалады.

Боларның һәммәсен биш бармагы кебек белә Вәли мулла. Үзенең һаман-һаман упкынга таба тәгәрәвен дә сизә. Әгәр җәренгә шәкертләр килмәсә, әһле мәгариф мәдрәсәнең ишеген алагаем кадаклап куячак. Бу Галимҗан дигән текә маңгайга кагыласы калмаган. Егермеләп шәкерт, анасыннан ка-

лышмаска тырышкан үрдәк балалары шикелле, аңа иярделәр бит. Әллә акның, караның кем ягында икәнлеген беләләрме шайтан алгырлары? Нинди замана килә соң әле? Егерменче йөз. Башы ук юньсезгә таба юл тотты. Ачлык. Сугыш. Атыш. Үтереш. Илаһым! Ни белән бетәр бу? Бер Ходайның үзенә генә мәгълүм.

Шундый тирән борчылу, хафалану, йончу уйлар давылы дулкынында кайтып керде Вәли мулла өенә. Үзе кебек үк юан, утар бияседәй симез, табак битле, кылыч борынлы, хәйләкәр елмаюлы остабикәсе Гыйззелбанат каршы алды аны. Башка вакытта, мулласы кайтып кергәч, инде карт биягә әйләнүенә карамастан, аның алдында куштанланып, боргаланып-сыргаланып торырга ярата иде ул. Ә бүген симез бәдәне аз гына да уйнакламады, песинекедәй соры күзләре елтырамады, кабарынкы куллары хәрәкәт итмәде. Чөнки мулласының сөмсере коелган, борыны салынган, күз карашларына кадәр мәзәкләнеп калган иде. Аңа якын бару да куркыныч. Менә-менә кеше йотарга әзерләнгән дию пәриенә охшап тора иде.

* * *

Менә бервакыт Галимҗан, Шәһит бүлмәдә икесе генә калды. Аларның икесенә 38 яшь бит инде. Яшьлек дәртенең ташып, кайнап, ургылып торган чагы. Быел җәй йә казакълар арасына бала укытырга, йә Рәмиевләрнең алтын приискаларына эшкә китмәкчеләр иде. Бу хакта Казанга — Йосыф хәлфәгә дә хат язган иде. Ул һаман әле Галимҗанны үз янына чакыра. Анда Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал кебек каләм осталары булу турында язган. Йосыф абыйсы үзе дә берничә шигырь бастырган. Галимҗанда да язучылык бөресе барлыгын әйткән. Әгәр Казанга барса, ул бөре ачылып китәчәк тә чәчәк атачак, имеш. Ул бөренең барлыгын Галимҗан үзе дә сизә. Шигырьләр язып карый. Ләкин, Йосыф абыйсы өмет иткәнчә, ул бөре чәчәк булып балкымый, нindидер чәнечкеле шайтан таягы булып килеп чыга. Аны ул бүлмәдәше Шәһиткә дә күрсәтми хәтта. Укып карый да, күңеленә ошамагач, ертып ыргыта, утка яга.

Галимҗан, үзен кая куярга белмичә, озак кына сүзсез басып торды. Шәһит белә гадәтен: мондый чакта аңа сүз әйтүнең бер файдасы да юк. Авыр мәсьәләне ул күбрәк үзе чишәргә ярата. Әле ул бер башын кая куярга белмәүдән гаҗиз. Хөрриятпәрвәр булу ягыннан Шакирҗан абыйсы аннан уздырып та җибәрде хәтта. «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләре үткән елда ук баш күтәрде. Яңача укыту кирәклек мәсьәләсен кузгаттылар. Әмма горур башлар шул күтәрел-

гән килеш калды. Башлар түбән иелмәде. Тик аларга түрәләр каты сукты. Утыз өч шәкертне мәдрәсәдән кудылар. Алар арасында Шакирҗан да бар иде. Әтисе Шакирҗаннан баш тартты. Шуннан Шакирҗан Орскига китеп, анда Әхмәт Исхакый мәдрәсәсендә укый башлады. Күпме генә хат язмасын, әтисе җавап бирмәде. Әнисе Хәсәнә абыстай гына бер хат күндергән иде. Ул әрни-әрни, сыкрана-сыкрана, өзгәләнеп язган. Хатка күз яшьләре тамган хәтта. Анда шундый сүзләр бар иде: *«И балам! Күз нурым! Йөрәк парәм! Әтиең бик котырына, бик дулый, бик җенләнә. Нигә алай шәригать кануннарына каршы киләсез? Үзегезнең нинди нәселдән икәнлегегезне әллә онытгыгызмы? Галимҗан кырысрак холыклы. Шулай да ул моны эшләмәде. Мондый башсызлыкны синнән аслан көтмәгән идек. Инде энең Галимҗан шундый ялгыш юлга баса күрмәсен берүк. Аннан минем якты көнем караңгы төнгә әйләнәчәк. Турыдан гына әйтмәсә дә, әтиең гел мине битәрли. Мин, имеш, сиңа дөрес тәрбия бирә алмаганмын. Әгәр Галимҗан да синең юлга басса, бу дөньяда яшәүнең бер кызыгы да калмаячак».*

Бу хатны Шакирҗан Галимҗанга җибәргән иде. Аны укып чыккач, Галимҗан ни уйларга да белмәде. Шакирҗан абыйсының тел төбен аңлады ул. Аның юлын кабатламасын, янәсе. Ата-ана хакы бар бит.

Ата-ана! Алар хәтерен саклап яшәү кирәк тә бит. Ә ничек сакларга? Тормыш бөтенләй башкача яшәргә куша. Ата-ана әйткәнчә түгел. Әтисе үзе дә мәдрәсәне ташлап киткән бит. Авылга кайткан. Дөнья көтәргә. Янә дүрт елдан соң — 1910 елда — әтисенең муллалыкны бөтенләй ташлаячагын белми әле Галимҗан. Дөрес эшлиме ул? Иманы йөрәгендә кала. Аллага ышана. Намазын өендә укый. Адым саен «Алла» сүзен әйтеп, халык алдап яшәүче Мөбахис мәзин кебекләр белән бер сафта намаз укып йөрергә яратмый ул. Алла исеме аның канында, җанында, йөрәгендә. Алланы алдарга ярамый. Дин кешелексезлек, әдәпсезлек, миһербансызлыклар белән килешә алмый. Шуны иман итеп алырга тиеш диндарлар.

Озак уйланды Галимҗан. Аның уйларын Фәсыйх мөдәррис килеп кереп бүлде. Бу әле күптән түгел килгән яңа мөдәррис. Троицк мәдрәсәсендә укыган. Шәкертләр аны тиз үз итте. Аны хәтта намускяр дип атадылар. Исеме дә җисеменә туры килеп тора. Фәсыйх — гарәп теленнән кергән сүз. Матур һәм килешле итеп сөйләүче дигән мәгънә аңлата. Сөйләме дә матур, холкы да күркәм, ак, чибәр кеше. Дөрес, әле ул түбән сыйныфларда сабак бирә. Шуңа күрә Галимҗанга аннан мәгълүмат алырга туры килмәде. Шулай да бәхәс-моназарә вакытларында фикер алышалар иде. Бу

мәдрәсәдә уку унике елга исәпләнгән. Кумасалар да, Галимҗан быел кайдадыр китәргә җыена иде инде. Чөнки җиде елда ул унике еллык кына түгел, әллә күпме белем алды. Әгәр Заһидулла хәзрәт аны «ярамаган» китаплар, урыс әдәбияты укыганы өчен даими рәвештә битәрләп торса, Фәсыйх мөдәррис, киресенчә, моның өчен Галимҗанны һәрвакыт мактап телгә алды. Чөнки Фәсыйх мөдәррис үзе дә әдәби әсәрләр укырга ярата икән. Тургенев, Толстой, Достоевский, Пушкин, Лермонтов әсәрләре буенча алар фикер алыша торган булып киттеләр. Урыс телен Галимҗан Солтанморатта мөгаллим Сәетнең өч еллык школасында ук ару гына өйрәнгән иде. Урыс әдәбиятын укый-укый, ул һаман ачыла барды. Мәдрәсәдән әллә ни ерак тормаган бер урыс белән танышып алды хәтта. Шуның белән сөйләшә-сөйләшә телен чарлады. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Әбелкасыйм Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Каюм Насыйриның «Фәвакиһелҗөласә»-се... кыскасы, кулына ни эләксә, шуны укыды Галимҗан. Фикер алышканда, ул бәхәснең очын кешеләр язмышына, инсаниятлелек мәсьәләсенә китереп тери башлады. Мондый очракта теге яки бу сәбәпнең нигезен гомум яшәештән эзләде. Бер сөйләшкәндә, безнең эрага чаклы ук яшәгән борынгы грек философы Аристотельнең: «Дәүләт кануны һәркем өстеннән хакимлек итәргә тиеш», — дигән сүзләрен әйткән иде. Безнең эрага кадәр яшәгән грек философы Платон сүзләрен дә искә алды. Ул болай дигән: «Әгәр кануннарның көче булмаса һәм ул аерым шәхесләр кулында гына яшәсә, мин андый дәүләтнең тиздән фаҗигагә очраячагына ышанам».

Бу сүзләрне Галимҗан дәфтәренә язып куйган. Дәүләт кануннары кем өчен чыгарыла? Нигә алар үтәлми? Нигә ул кануннар аерым патшалар кулында гына яши? Ни өчен Хөрмәтулла кебек меңнәр, миллионнар нахактан рәнҗетелә? Ни өчен Мөбахис мәзин кебекләргә канун юк?

Мондый тирән уйланулар Галимҗан күңеленә 1905 елгы революция дулкыннары аша килеп керде. Бер теле кычытканда, бу хакта Фәсыйх мөдәррискә дә әйткән иде ул. Фәсыйх мөдәррис, әдәби әсәрләрне күп укыса да, фәлсәфә белән шөгыльләнүче борынгы зур шәхесләрне белми иде. Үзенең һәм башкаларның бу мәдрәсәдә Галимҗаннан бик түбән торуларын аңлады ул.

Ничек кенә булмасын, Фәсыйх мөдәррисне кешелеклелеге, намускярлелеге, аңлылыгы өчен яратты ул. Яңа гасырның мәдрәсә тормышына да яңалыклар алып килә башлавына шатланды. Тик андыйлар диварлары черегән мондый мәдрәсәдә бик озак тормыйлар шул, китеп баралар. «Хөсәения»гә килгән Гаяз Исхакый да надан, җаһил мөгаллим-мө-

дәррисләр белән тыныша алмады. Галимҗан анда еш барды. Бер сөйләшкәндә әйтте Гаяз Исхакый:

— Сиңа язарга кирәк, Галимҗан туган, — диде.

Бу вакытта Гаяз Исхакыйның берничә әсәрен дә укыган иде инде ул.

Шушы ук фикерне аңа Фәсыйх мөдәррис тә әйтте:

— Фикерең дә зур, сөйләмең дә үткен, кеше язмышы турында да нык уйланасың, сиңа язарга кирәк, Галимҗан, — диде.

Әле дә ул шул фикерне әйтергә кергән. Моннан ике атна чамасы элек ниндидер йомыш белән Уфага киткән иде. Кайту белән, мәдрәсәдәге күңелсез хәбәрне ишетеп, Галимҗан янына аның кайгысын уртаклашырга кергән.

— Мин моны көткән идем, Галимҗан туган, ләкин син кайгырма, кит Казанга, анда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырсың; остазың Йосыф мөдәррис тә анда бит, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал әфәнделәр белән аралашып яшәрсең, сиңа язарга кирәк, — диде.

Галимҗан тиз генә җавап бирмәде. Мәдрәсәдән куылуына кайгырмый түгел ул. Әтисе Шакирҗан абыйсыннан баш тартты. Шул ук язмыш, кайгы Галимҗан башына да төшәчәк. Һәр елны, җәйге ялга кайткач, уку мәсьәләләрен сораштырып, кызыксынып торды әтисе. Галимҗанның күп белүенә исе-акылы китә. Чыннан да, нәселдән бер пәйгамбәр чыкты лабаса, дип уйлый. Бу фикерен Галимҗанның үзенә дә әйтте. Ә менә хәзер башлы пәйгамбәр түгел, башсыз пәйгамбәр булып чыкты. Әтисе сүгәчәк. Әнисе күз яше коячак. Алларына мәдрәсә бетерү турында шәһадәтнамә алып кайтып салса, түбәләре күккә тияр иде дә бит. Тик ул бәхет тәтемәде.

Язарга? Нәрсә язарга? Ничек итеп?

...Фәсыйх мөдәррис чыгып киткәч, сүзне Шәһит башлады:

— Галимҗан, безнең йә казакълар арасына, йә Рәмиевләрнең алтын приискаларына барып эшләү нияте бар иде бит?

— Бу ният барып чыкмас шул инде хәзер, Шәһит дус!

— Ни өчен?

— Әткәйгә ярдәмче кирәк. Ул күп иген чәчә. Һәр җәйне нык эшләгәнне беләсең бит. Шакирҗан абый да өйдә юк. Әткәй аннан баш тартты.

— Әтиең мәдрәсәдән икенче мәртәбә куылганың өчен сине...

— Анысын да аңлыйм. Башта әйтмирәк торырга кирәк булыр. Белсә дә, әллә нишләп булмый. Бер давыллаңыр да туктар әле. Нигә хакыйкатьтән качарга? Мин инде, Ходайга шөкер, унтугыз яшьлек егет.

## IV

Солтанморат авылы, үз шатлыгын, үз кайгысын кичерә-кичерә, бер-бер артлы булып торган авыр дөнья мәшәкатьләрен җиңә-җиңә, кем әйтмешли, чыгырдан ычкынмаска тырышып, яши бирә. Елның дүрт фасылы, кунакка һич кичекми килгән тәртипле кеше кебек, вакытында пәйда була да куя. Күңелләргә якты нур бөркеп, йөрәкләрне ярсытыр дәрәҗәдә сихерләп, сандугачлы яз килә. Аны чәчәкле җәй алыштыра. Аның артында — чуар көз. Шуннан соң кыш бабай җирне мамык кар юрганы белән каплый. Әмма соңгы елда дөнья бозылды. Әгәр Алланың бер ахмагы йә аягы, йә таягы белән күпме көч түгеп, җәфа чигә-чигә, сокланып туя алмаслык матур итеп өйгән кырмыска оясын бутаса, ул мескен изге җаннар күпме михнәт чигә, адәм балаларының шундый ерткыч, түбән җанлы, җаһил булулары өчен рәнҗи, аларга бәддога кыла. Кош-кортка, хайваннарга, бөҗәкләргә рәхимсез нәҗес җаннар дөнья тулы шул әле. Кеше җәмгысын таптый, изә, сыта. Инде хәзер бер-берсен үтерешү кебек хурлык, гөнаһ юлына бастылар. Суешу. Кан коеш. Ерткычлык. Япон сугышы, инкыйлаб җилләре, бөтен Русияне айкап-байкап, котырына-котырына, шыңшый-шыңшый исте дә, елый-елый, ач бүредәй улап, Солтанморатка аһ орып килеп җитте. Авыл халкы, әлеге кансыз хәшәрәтнең пычрак аягы белән туздырылган кырмыскалар шикелле, айкала-чайкала башлады. Берәүләр патша хезмәтенә китә. Икенчеләре «революция» дип җенләнә. Өченче бер төрлеләре байларга теш кайрый. Дөнья астына тәмуг уты ялкыны җибәргән зур казан урынына кайный. Яхшылыкка түгел бу. Түгел. Мең-миллион мәртәбә түгел. Илаһым! Кешеләрнең бер-берсен үтерешүеннән чәчрәгән кан дөнья йөзенә гөнаһлы кара тап булып ягыла. Гөнаһлы илдә бәндәләр имансызга әверелә. Имансыз ил күгәрә, чери, таркала. Ходаем, бу яңа гасыр шулай канга манчылып башланамы?

Әллә шуның тәэсиреме? Быел язы да дию пәриедәй котырынып, аждаһадай үкеренеп килде. Әле карлы-бозлы яңгыр ява, әле агачларны төбе-тамыры белән суырып алып ыргытырдай шашкын җил исә, әле яуган бозлар тау-тау булып өелә. Тик менә бүген генә елмаеп кояш чыкты, дөнья йөзенә нур сибелде. Кешеләр күңеле җылынып китте. Әлхәмделилла, яхшылыкка булды бу!..

Иртән ихатада, абзар-курада, тегендә-монда ансын алай, монысын болай итеп, бүгенге дөнья турында уйланып йөргәннән соң, өйгә кереп чишенгән иде Гыйрфан мулла; көтмә-

гәндә, бүгенге ялтырап чыккан кояш кебек, улы Галимҗан кайтып керде. Иләһи бу киң дөньяга ике кояш берьюлы чыктымыни!

Мулла абзый, быелгы язның шулай котсыз килү сәбәбен ачыкларга теләп, кулына ел фасылларының кәефе-холкы хакында теркәп барган язмаларын алырга уйлаган иде. Хәсәнә абыстайның шул инде: тавыклар гына түгел, бөтен дөнья күгәрченнәре чүпләп тә бетерә алмаслык үз эше — әле ул аш-су бүлмәсендә табак-савыт юу белән мәшгуль. Ата һәм ул башта бер-берсенә озак кына карашып торды. Галимҗанның карашы аңлаешсыз иде. Анда моңсулык та, кайгы да, берникадәр кайту шатлыгы да бар. Ул кулындагы төенчеген бер якка куеп, өстендәге җиләнен салып чөйгә элгәч, ата белән ул бер-берсенә янә карашып калды. Ата кешенең карашы каты һәм сынаучан иде. Мәгълүм инде: ул карашның төбендә, ачылып җитмәгән бөре кебек, кавышу шатлыгы чаткылары да яшеренгән. Ата кеше, шулай бераз карашып торгач, улын барып кочаклап алмакчы булды. Иллә мәгәр моны эшләмәде. Ниндидер яшерен сихерле көч, ашыкмаска, уйларга кушып, күлмәк итәгеннән тотып торды. Бераздан ул:

— Нихәл, улым, исән-аман кайттыңмы, нигә чит кеше кебек түргә узмый торасың? — дип, ике кулын сузып килеп күреште.

— Исән-имин генә кайттым, әткәй, бөтен килеш, күреп торасың ич, барлык мөчәләрем түгәл, кителгән-мителгән җирем юк, — дип, Галимҗан салкын гына елмаеп куйды.

Ничек кенә булмасын, «барлык мөчәләрем түгәл», «кителгән-мителгән җирем юк» дип шаян сүзләр белән җавап бирүе ата күңелен җылытып җибәрде. Галимҗан һаман шулай шаярып сөйләшүчән. «Кителгән-мителгән җирем юк» дип әйтүе, димәк ки, камил акыл белән кайтканлыкны да аңлата. Ата кеше янә барып күреште дә аннан соң, әле миндә ирлек гайрәте йомшармаган дигәндәй, улының ике беләгеннән тотып селкетте. Аннан аркасына чын аталарча сугып алган булды да:

— Әнкәсе, һәй, сиңа әйтәм, таш маңгаебыз кайтты бит, чык монда, ташла табак-савытларыңны,— дип кычкырды, шатлыклы, ярсулы тавыш белән.

— Мин бит табак-савыт юмыйм, атасы, сумса пешерәм, әллә ана күңеле бала кайтасын сизмиме, бүген төшемә үк кергән иде,— дип сөйләнә-сөйләнә чыкты да улының күкрәгенә барып капланды. Ана белән бала бер-берсенең кочакларында озак иркәләнештеләр. Хәсәнә абыстай җитеп беткән улын сабый чактагыдай кысып-кысып сөйде дә, калтыранып-йомшап, яшькә тыгылды. Бала алдында яшь күрсәтмәү ана

иманының бер күркәм сыйфаты иде. Әмма ләкин бу юлы иманының бер як чите кителде. Күпме генә үзен кулга алырга, ярсыган күңелен басарга тырышмасын, буаны ерган көчле су кебек, йөрәк төпкеленнән үк килгән ачы яшьләр өзлексез агарга кереште. Бөгелеп-сыгылып, рәхәтләнеп, сабый бала шикелле үкседе ул. Гыйрфан мулла аны төрле сүзләр белән юатты:

— Йә, җитәр инде, анасы, нишләвең бу, гомергә булмаганны, син бит болай түгел идең, исән-имин кайткан лабаса, үзе әйткәнчә, бөтен мөчәсе — тән әгъзалары төп-төгәл, акылы камил...

Галимҗан, әнисенең күз яшьләренә ялкын өстәмәскә, күңелен күтәрергә тырышып, шаян сүзләр кыстыра-кыстыра сөйләште:

— Әткәй дөрес әйтә, әнкәй, һәр яздагыча, үземдә булган барлык мөчәләремне быел да кире алып кайттым, юлда бересе дә төшеп калмады. Аллага шөкер. Дәхи дә шуны әйтим: егет корына җиттем, акыл казаным зурайды, иманым артты, тирә-ягымда ырылдап йөргән шайтаннарны куар өчен Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән вә дә сезнең илаһилыктан алынган рухи һәм җисмәни көч-куәтем, гайрәтем бар.

«Шайтан» сүзе килеп кушылгач, ата кеше хәтта көлеп җибәрде. Хәсәнә абыстай да елмаеп куйды. Дөрес, ул сүз гөлбакчасында үскән шайтан таягын хәтерләтте. Шаярып сөйләшкәндә, Галимҗанның каты-каты сүзләр кыстыра торган гадәте бар шул. Ул бәгъзе берчак күңелгә кадак булып та кадала. Бу аның усаллыгы гына түгел, бер сүз белән күп мәгънә аңлату галәмәте дә. Гыйрфан мулла үзе дә шулай лабаса: тормыш ямьсезләүче шайтаннарны җене сөйми. Вакыт-вакыт аларны чәйнәп ыргытырдай була. Димәк, улы, аңа охшап, яшәү максатын куйган. Ә нишләп шулай булмаска тиеш әле? Аның каныннан, аның җаныннан, аның кабилиятеннән ләбаса! Дөрес әйтә каһәрең: үз тирәсендә буталып йөргән барлык убырлы, шайтаннарны капкынга эләктерәчәк бу таш маңгай.

Галимҗанның шаян сүзләре ананың күз яшьләрен дә корытты. Бу йомшауның шатлыктан икәнлеген дә аңлатырга тырышты ана. Чөнки Шакирҗан югалу кайгысы аның төн йокыларын качырды. Шундый хәл Галимҗан тарафыннан да эшләнә күрмәсен, Ходаем, дип үрсәләнде. Әгәр Галимҗан да шул юлга басса, Аллам сакласын, йөрәгем ярылыр, дип курыкты. Галимҗанны күрү шатлыгыннан түгелгән гәүһәр яшьләр алар.

— Сумсам хәзер өлгерә, атасы, син Галимҗан белән сөйләшә тор, озакламый чәй табыны әзерләрмен,— дип, тагын да аш-су бүлмәсенә кереп китте Хәсәнә абыстай.

* * *

Чәй табынында башта тынлык хөкем сөрде. Кайнар, тәмле, авызда эреп торган сумса ашап, бер-ике чынаяк чәй эчкәннән соң, сүз тезмәләре өстенлек алды. Ул башта изге күңелле кешеләрнең мөбарәк тәсбих төймәләрен берәмләп-берәмләп тартуын хәтерләтте. Тора-бара мөбарәк тәсбих өзелеп китте. Төймәләре чәй табынына чәчелде.

Сүзне ата кеше башлаган иде. Әлбәттә, йомшак кына, җай гына, аталык дәрәҗәсен саклаган кыяфәттә. Ул иң әүвәл юньсезлеге өчен Шакирҗаннан баш тартуын аңлатты. Аннан соң, җайлап-җайлап, Галимҗанның күңел кылларына чиртә башлады. Укулар ничек бара? Вәли мәдрәсәсе ни хәлдә? Вәли мулланың үз сәламәтлеге ничек? Шәкертләр арасына инкыйлаб шайтаннары кермиме? Тегесе-монысы, фәлән-фәсмәтән...

Галимҗан туры гына җавап бирмәде. Шаяртып маташты. Ул мәдрәсәдән куылу мәсьәләсенең җеп очын хәзергә яшереп торырга уйлаган иде: әтисен, әнисен борчыйсы килмәде. Әмма безне капчыкта яшереп тотып буламыни. Бервакыт тишеп чыга бит ул. Вәли мулла әтисенә хат язмый калмас. Чөнки алар дуслашып та киткән иде. Барган саен, әтисе аңа зур бүләк — күчтәнәч бирә. Хат килсә, мәдрәсәдән ни өчен куылганлыкны тәсдыйк итсә, аңа, Галимҗанга, әтисе, әнисе алдында тагын да авыррак булачак: «ялганчы» дигән шелтә сагызы ябыштырачаклар маңгаена. Әйдә, уты-ялкыны бергә булсын. Куылуын ул башта туры гына әйтмәде. Әлеге әтисе соравына җавап биргәндә:

— Революция шайтаннары күбәйде, әткәй, мәдрәсәдә, мин — шуларның берсе,— диде.

Ата кешенең күзләре маңгаена менде. Хәсәнә абыстай да калтыранып куйды. Сөйләшә-сөйләшә, сүз шуңа барып җитте: Галимҗан мәдрәсәдән куылуын ачыктан-ачык әйтергә мәҗбүр булды. Һәр ат карагының «һөнәре» энә урлаудан башлана. Вак-төяк алдау кешене зур алдакчы булу дәрәҗәсенә җиткерә. Соңгы чиктә ул икейөзле явызга әверелергә мөмкин. Боларны Галимҗан яхшы белә.

## V

Табигатьтә, яшәештә, кешеләр йөрәгендә, бөтен матди дөньяда, галәм киңлекләрендә — капма-каршылык. Көннәр бу арада тормышны, бәндәләрне, табигатьне яратмаудан мәңге эче пошып, сыкранып, үрсәләнеп йөргән кара йөзле кешенең аһ оруы кебек булып торды. Аннан соң матур күңелле, олы йөрәкле, хис-

тойгыларга бай кешенең елмаюын хәтерләтеп торган кояшлы аяз көннәр киләчәге — табигый хәл. Килде. Ялтырап кояш чыкты. Җиһан әле якты-җылы нурлар эчендә изрәп ләззәтләнә. Ә йөрәкләрдә — давыл, гарасат, томан.

Шул хакта уйлап ятты Галимҗан. Көне буе матур, җылы, кояшлы көн булды. Кояш, офыкка якынлашканда, кып-кызыл ут тәгәрмәчедәй булып янып торды. Офыкка килеп тәрәлгәч, ул алсу-кызгылт төскә әйләнде. Бу вакытта ул бит очына ал сөрткән көләч кызны хәтерләтте. Ә инде өске ягындагы сыек зәңгәрлек гүя сөрмә тартылган күз карашлары балкышы. Офыкта кояш моңаеп торды-торды да көне буе күк йөзендә исән-аман йөзүнең чигенә амин тотып, бәндәләр саулыгына дога кылып, матур төн үткәрергә фатихасын биреп, шифалы-йомшак нурлар калдырып баеды. Хәзер моңсу зәңгәр төн. Тынлык. Өскә кояш нурларыннан алып кергән йомшак юрган ябылган. Әмма эчтә давыл. Өермә. Зилзилә.

Галимҗан белән Габделхәким икенче катта йокларга булдылар. Галимҗан уң як стена буендагы караватка ятты, Габделхәким — сул яктагысына. Габделхәким хәзер ун яшьтә инде. Сабакны башта әти-әнисеннән алды. Хәзер мәдрәсәдә һәйбәт кенә укый. Җәй көне, җае туры килгән саен, аның белемен Галимҗан да тикшереп кенә торды. Башта алар бераз сөйләшеп яттылар. Габделхәким шул ук әтисе-әнисе биргән сораулар белән йөдәтте. Нигә куганнар мәдрәсәдән? Хәзер кайда укыячак? Йә хәлфә, йә мулла, йә мәзин булырга хокукы бармы? Тегесе-монысы...

Галимҗан башта аны шаяртып маташты. Комсыз Мөбахис мәзинне беркем дә яратмый, ул шуның урынына кайткан, мәчеттә моңлы итеп азан әйтәчәк, имеш. Аның моңыннан бөтен авыл халкы сокланып ләззәтләнәчәк. Шуннан Галимҗан аны икенче бер төрле моңнар арасына алып кереп китте. Җыр моңы, дала моңы, йөрәк моңы турында сөйләде. Тик аларны Габделхәким тыңлап бетерә алмады. Тирән, татлы йокыга чумды. Андый йокы белән Галимҗанның дә рәхәтләнәсе бик килгән иде. Ләкин уй чәнечкеләре йөрәген даими чәнчеп торды. Мәдрәсәдән куылганлыгын әйткәч, әтисенең күзләре котырган бүренекедәй ялт-йолт килде, тешләре озак кына шак-шок итеп торды, калын иреннәре тегермән ташы дырылдавын хәтерләтеп дерелдәде. Бу минутта аңа бер сүз әйтү дары мичкәсенә шырпы сызып ыргыту булыр иде. Шулай да Галимҗан сүзсез калмады.

— Әткәй! Дөреслекне якларга, иманга турылыклы булырга, алдашмаска син безне үзең өйрәттең бит; әнкәй дә шул рухта тәрбияләде, — диде.

Ата кешене бу сүзләр ярсытып кына җибәрде:

— Мәдрәсәдән куылу дөрес юлмы?

— Кайгырма, әткәй, югалмам.

— Ни эшләмәк буласың?

— Мәдрәсә бетмәгән бит.

— Һм... Кәккүк кебек оя сайлап йөрмәк буласыңмы?

Сөйләшү шактый озакка сузылды. Галимҗан, әллә күпме вәгъдәләр биреп, әтисен юатырга тырышты. Ике улының да мәдрәсәдән куылу кайгысын күтәрү атага җиңел түгел. Моны аңлый Галимҗан. Тик бер яманлыкның яхшы ягы булуны аңлату кыен. Вәли мулланың кадим мәдрәсәсеннән куылу — яманлык. Аннан котылу, икенче мәдрәсәгә барып уку — яхшылык. Шул хакта да әйтте ул әтисенә. Әмма әтисе, комнан аркан ишеп булмый, дигәнне аңлатып, кулын гына селекте дә:

— Оят! Адәм арасында оят! Авыл халкы бот чабып көләчәк,— дип гайрәт чәчте.

Әнисе сүзсез генә торды. Ул эчтән кичерә. Эчендә кайгы уты икәнлекне Галимҗан белә. Аны кызгана. Шакирҗан өчен хәсрәтләнеп, ярты гомерен югалтканлыкны аңлый Галимҗан. Шуның өстенә икенче тетрәү. Бер ана йөрәге бит ул. Ул йөрәктә ана мәхәббәте, сафлык, садәлек, аклык сакланырга тиеш. Ләкин балалар ул йөрәккә кара яга, ут сала. Әлбәттә, Галимҗан тынычландырыр яраткан, матур күңелле, олы йөрәкле анасын. Шундый уй-хисләр давылында йокыга талды ул.

Ата белән ана аскы каттагы сәкегә урын җәеп җайлаштылар. Гыйрфан мулла орчык урынына бөтерелеп-бөтерелеп ятты. Сизә остабикәсе: мулласының йөрәге яна, күңеле ярсый, үзен-үзе өзгәләп ташлау чигенә җитә.

Абыстай аны һаман шул элеккечә йомшак сүзләре белән юата:

— Мулла! Акылыңа кил! Ходайдан сабырлык сора! Әгәр ярсу йөрәгеңне баса алмасаң, иртән әллә нишләп ташлавың бар. Бу Галимҗанга кире тәэсир итәчәк. Аның әллә кая китеп югалуы мөмкин.

Остабикәсенең үгет-нәсихәтен аңлый мулла. Пырдымсызлыгын да таный. Шуның аркасында бәла-каза күрүен дә белә. Шакирҗанның кайтмавы да шуңа бәйләнгән. Теге вакытта җенләнеп китеп ат куу, бер сөзәк җирдә арба аву, атлар тәгәрәп китү...— боларның барысы да пырдымсызлык сөземтәсе. Андагы этләнүләрне Ходай дошманыңа күрсәтмәсен.

— Ярый, остабикә, син әйткәнчә булыр, кудым җанымны ярсыткан җеннәрне, иртәнге намазны бозык күңел белән каршыламыйк; иштә Ходай кушмаган эш булмас; Галимҗанны

җиңү авыр хәзер, ул Таш маңгай баш бирмәс байтал кебек, йоклыйк әйдә,— дип, мулла абзый үзе үк остабикәсен тынычландырырга тырышты.

## VI

Кеше күңеле бәгъзе бер вакыт бөтен галәмне сыйдыра ала. Яки ул матди дөнья әйберҗисемнәрен уч төбендә биетергә ярата. Биетеп-биетеп рәхәтләнгәч, учын йомарлый. Учында калганнарны, илаһилык мәрҗәнен ычкындырмаска тырышкан изге күңелле зат кебек, кысып тотарга тырыша. Әйтерсең шунда аның бәхет орлыгы, киләчәк язмышы, гомер сукмагы.

Кондызлы күлнең текә яр башында уйга чумып, моңаеп, хис-тойгылар ташкынында газапланып утырган Галимҗанны да әле шундый кемсәләрнең берсенә охшатырга мөмкин. Бирегә еш килә ул. Эш юкта. Һәр форсаттан файдаланып. Җәй зур мәшәкатьләр белән үтеп китте. Һәр елдагыча иген игү, печән чабу, урак уру, ашлыкны келәткә салу кебек эшләр башкарылды. Галимҗан һәркөн басу хезмәтенең үзәгендә-күзендә булды. Болай риядан гына түгел, ихлас күңелдән, ләззәтләнеп, ялкынланып, авыр кыр хезмәтенең үзенчә бер сәнгатен тоеп эшләде. Кичләрен Авыргазыга йөгерде, балыктай йөзеп, чумып-чумып, арыган-алҗыганлыгын елга дулкыннарына агызып җибәрде. Судан чыккач, үзен бөтенләй эшләмәгән, арымаган, җиңел сөякле кеше итеп тойды. Кыскасы, җисмани һәм рухи яктан чыныкты. Үзен рәйхан мае белән сөртелеп җиңеләйгән кешедәй хис итте.

Бүген сентябрь уртасы. Хәзер үзенчә бер матурлык. Агач яфракларында мең төрле бизәк: яшел, яшькелт, ямьяшел, сары, саргылт, сап-сары, кызгылт, соры-кызгылт, сарыкызгылт...— тагы да әллә нинди ләр. Табигать яшелдән сарыга тиз генә күчәргә ашыкмый. Адәм балаларының күз явын төрле төстәге бизәкләрен күрсәтеп алмак була, күрәсең. Аннан инде ул бизәкләр тәмам уңып бетә. Саргая. Корый. Көзге усал җилләр аларның язмышы белән нык шаяра: башта берәмләп-берәмләп, аннан күпләп-күпләп, ана имчәгенә ябышкан баладай үз ботагында иркәләнеп-эленеп торган яфракларны туздырырга, өзеп-өзеп ыргытырга тотына. Яфраклар, имчәктән аерылган бала кайгысын тоеп, яралдырып дөнья күрсәткән ботак — аналарыннан күз яшьлә-

рен түгә-түгә аерылырга мәҗбүр булалар. Алар җиргә төшәлә. Аларны таптап-таптап үтәләр. Алар өстенә бервакыт кар катламы җәелә.

Ләкин моңа шактый вакыт бар әле. Хәзергә — сентябрь уртасы. Әмма көн җылы. Җәйдәге кебек. Ай башында да шулай булды. Җылылык җәйнекеннән әллә ни аерылмады. Тик моның кире ягы да бар икән. Сентябрь шулай булса, кешеләр сәламәтлегенә зыян килә, имеш. Монысын Галимҗанның әтисе әйтте. Ул сынамышлар белән шөгыльләнә. Бөтенесен дә гамәл дәфтәренә яза бара. Андый көннәрнең серле-сихри кире йогынтысы, чыннан да, йомшак бәдәнле шәһәр халкының бәгъзеләрен бәлтерәтәдер, кан басымын күтәреп, әлсерәгән тавыктай йөрергә, йөрәк авыртуыннан зарланырга мәҗбүр итәдер. Авыл халкының бу хакта уйларга, йөрәк тотып җебеп утырырга, тышкы тәэсирләр белән гасабиланырга аслан мөмкинлеге юк. Аңа кышлык азык әзерләп куярга кирәк. Шуның өстенә ул баланын, миләшен, гөлҗимешен, шомыртын, мәтрүшкәсен — тагы да әллә ни төрле җимешләрне, шифалы үләннәрне җыеп куя. Ул җимешләрдән, ул үләннәрдән аңкыган хуш ис тәнеңә сарыла, борын тишекләреңне ярып кереп, бөтен эчке әгъза күзәнәкләренә сеңә. Менә сиңа шифа! Менә сиңа дару! Менә сиңа сәламәтлек!!!

Кешеләр әле һаман су керә. Елга аларны көләч йөзе белән каршылый. Үз кочагына алып, дулкыннары белән иркәли. Елгага адәм баласы ашкынып, ярсып, йөгерә-йөгерә килә. Алар елганы ярата. Шуңа күрә елганың да бәндәләргә карата булган мәхәббәте ифрат зур. Ул кешеләрне чыныктыра, сәламәтләндерә, матур күңелле итә.

Тик, җәй белән чагыштырганда, күк зәңгәрлегендә, көннең үз нурында үзгәрешләр дә юк түгел. Күк йөзенә, сизелер-сизелмәслек кенә булып, куе зәңгәр төс килеп кушылды. Өйләдән соң, кичкә таба ул аеруча нык сиземләнә. Көн яктылыгына бәлләвер төс өстәлә. Шуның белән бергә, күк йөзенә дә, көн яктылыгына да көзге моңсулык нурлары сибелә.

Галимҗан әле шушы моңсулыкны күзәтә. Кондызлы күл яры башында зур гына бер таш бар. Ул утынлыктагы бүкәнне хәтерләтә. Өсте тип-тигез. Әйтерсең Ходай Тәгалә аны кешеләр утырыр өчен махсус шулай эшләп куйган. Шунда утырып, Галимҗан озак-озак матурлыкка карап соклана. Якында гына йодрык зурлыгы янә бер таш ята. Аны-

сында җемелдәп торган вак-вак бөрчекләр бар. Ул бөрчекләр энҗе-мәрҗәнне, гәүһәрне хәтерләтә. Әллә, чыннан да, бу ташның эче тулы энҗе-мәрҗәнме? Асылташ дигәннәре шушымы әллә? Әллә якут ташымы бу? Килеп утыру белән, Галимҗан аны кулына ала. Шул энҗе-мәрҗәннәргә сокланып, исе-акылы китеп карап тора. Кеше өчен табигать нинди генә гүзәллекләр ясамый дип уйлый. Ул бүген дә шулай итте. Шул энҗе-мәрҗән, гәүһәр белән бизәлгән ташны кулына алып, озак кына илһамланып карап торгач, аны кире урынына куеп, күзен табигать гүзәллегенә ташлады. И табигать! Җанлы син! Олы йөрәкле син! Шагыйрь син! Илһам чыганагы син! Адәм балаларына аң-акыл, хис-тойгы, яшәү дәрте бирүче син!

Шундый татлы, тирән, серле, сихри уйлар дөньясында йөзә әле Галимҗанның күңеле. Ул иртәннән бирле табигать белән хушлашып йөрде. Авыргазы, Түрсәгәле, Исәнбикә буйларында, Зәңгәр чишмә янында булды. Табигать әйтерсең аның сөйгән кызы. Ул — шул кызны иркәләүче солтанат егет. Иртәгә ул Уфага китәчәк. «Галия» мәдрәсәсенә. Менә ни өчен хушлаша табигать белән. Авыл табигатен ташлап китү яраткан-сөйгән ярдан аерылу белән бер икән. Ә менә моннан, Кондызлы күл яры башыннан, бөтенесе дә уч төбендәгедәй күренә. Шул ук Авыргазы белән Түрсәгәле елгаларының бер-берсе кочагына ташланган һәм үбешкән урын. Зәңгәр чишмә. Исәнбикә болыны. Тугайлар. Болыннар. Кырлар. Аларның һәрберсенең йөрәге бар кебек. Ул йөрәкләр бер-берсенә мәңге өзелмәс хәяти чылбыр белән тоташкан. Чылбырлар буйлап йөрәк каны ага. Йөрәк каны, йөрәк тамырлары аларны илаһиique бербөтен табигать җисеменә әверелдерә. Бу җисемнән, гарше көрсидәге кебек, үзенчә бер яшәеш тәхете барлыкка килә.

Әле төш күптән авышып, кояшның баерга табан юл тоткан мәле. Кояшның йөзе ачык, тоник, ап-ак. Җәй көнендәге кебек эссе нурлары белән көйдерми. Шулай да җылы. Хәзер икенче төрлерәк нур: көзге, моңсу, сабыр нур. Күк йөзе — куе зәңгәр. Ә җирдә — кырлар, болыннар, тугайлар, елгалар, күлләр, гөлләр, чәчәкләр, җир рәйханнары, миләүшәләр, сөмбелләр, лаләләр... Әллә боларны ташлап китмәскәме? Әтисе кебек җир кешесе булып калыргамы? Өйләнә. Дөнья көт. Җир сөр. Сукала. Тырмала. Чәч. Ур. Ат, сыер, сарык, кәҗә, каз, күркә, тавык асра. Әтисе, гәрчә шушы эшләрне сөепяратып башкарса да, Галимҗанга алай кыланырга ирек бир-

ми. Укырга, тәмамланган мәдрәсә белеме алырга куша. Галимҗан башта Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен сайлады. Йосыф хәлфә кулы аша үтсә, бик тә яхшы булыр иде. Ләкин тора-бара ул уеннан кире кайтты. Ул үз кендегенең шушы туган җир кендеге белән нык бәйләнгәнлеген сизде. Аны өзеп булмаячакны аңлады. Ул үзен каты холыклы, кырыс табигатьле, усал кешегә санап йөри иде. Сагыну хисе көчле икәнлеген аңлагач, бу уеннан берникадәр кире кайтты. Үзен йомшаклыкта гаепләде. Ләкин бусы да дөрес үк түгелдер. Сагыну олы йөрәкле, матур күңелле, хис-тойгы бай кешеләргә хас, имеш. Моны бер акыллы баш әйткән. Галимҗан аны кайдадыр укыган иде. Димәк ки, сагына белүгә катылыкның, йомшаклыкның кысылышы юк. Ә инде боз йөрәкләр, хис-тойгыдан мәхрүм мескеннәр, кешелексезләр сагына белми, ди. Уфа ерак ара түгел. Кайтыр да килер, кайтыр да килер. Сагыну ялкыннарын урманнар, күлләр, елгалар, гөл-чәчәкләр арасында балкып утырган туган авылының мөхтәрәм кешеләре арасына кайтып басар.

Шундый уйлардан соң, ул табигатькә янә бер күз сала. Озак-озак моңаеп карап тора. Юк, бу моңаю гына түгел. Ярсу, хыяллану чигенә җитү, уй-хисләрнең иң тирән диңгезенә чуму бу. Шушы бай, моңсу, сихерле, шигъри табигать хозурландыра, шашындыра, җенләндерә аның күңелен. Бу сихерле табигать эчендә мең-миллион адәм балалары уйный, шаяра, матурлык белән ләззәтләнә кебек. «Табигать балалары» дигән хикәясе шуның бер манзарасы-күренешеме әллә? Шушы табигать сихерләдеме аның йөрәген? Шушы табигать уяттымы матур тойгылар? Шушы күркәм табигать кешеләрдәге матурлыкны күрә белергә өйрәттеме? Киләчәктә зур язучы булып китүендә шушы илаһи бай табигатьнең дә җуелмас шаукымы барлыкны беләме әле ул? Белми. Әмма сизенә. Күңелдә нindидер яңа, моңа чаклы булмаган хис-тойгы давылы купты. Ул давыл котыра, җенләнә, үрле-кырлы сикертә.

Ул әле «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясен ничегрәк итеп язу турында да хыяллана. Гаяз әфәнде Исхакый язарга кушты. Ул кешеләрне дүрт төргә бүлде. Беренчеләре — тормыш баскычының иң югары өлешендә торучылар. Болар — ил, халык мәнфәгате белән яшәүче Йосыф пәйгамбәр кебекләр. Халыкка инсафлылык, әдәплелек, кешелеклелек дине булган ислам динен иңдерүче соңгы пәйгамбәр Мөхәммәт галәйһиссәлам дә шу-

ца керә. Икенче төркем беренчеләрнең эш-гамәл тегермәне куласасына шифалы су коеп торырга тиеш, имеш. Яки алар ил, халык мәнфәгате дилбегәсен бергә тотарга хаклылар. Гаяз Исхакый әфәнде җәнаплары казакъ халкының бөек акыны Абайның бер шигырен дә әйткән иде. Галимҗан аны язып алды да соңыннан ятлады:

Ант итеп, антын бозган җаны корсын,
Кыска көндә кырык җиргә киртә куеп
Йөрүче хәйләкәрләр тагын корсын,
Бер атна йөз үзгәргән йөзе көйгер,
Үз-үзенә масайганның аты корсын.

Әйе, өченче төргә хәйләкәр кешеләрне керткән иде Гаяз әфәнде. Алар —әлеге беренче һәм икенчеләрнең кылган әмәлен үзенеке итеп күрсәтергә тырышучы кыл койрыклар. Дүртенче төрне ахмаклар тәшкил итә. Болар, Гаяз әфәнде әйткәнчә, хәйләкәр генә түгел, ә бәлки, кешенең хәяти сукмагына аркылы сузылып ятарга маташучы аңгыра сарыклар. Бу дүртнең үз эчендә тагын мең-миллион төрлелекләр бар, ди. Гаяз Исхакый җәнаплары әйткәнчә, язучы әнә шул төрлелекләрне аң-акылы, йөрәк хисе, күңел тойгысы белән сиземләргә тиеш. Ә ничек сиземлисең? Бармы соң Русия җирендә беренче төргә керүчеләр? Николай патшамы? Юк инде. Аның үзен бәреп төшерергә кыҗрыйлар. Революция шуның өчен булды. Әмма ул ялкынланды да сүнде. Күмере, көле генә калды. Иллә мәгәр ул күмергә янә дә ут салып, кабыза-кабыза, дөрләтеп җибәрәчәкләр, имеш. Революция тагын да катырак, бергәйлерәк, ялкынлырак балкыячак, янәсе. Патшаны тәхеттән бәреп төшерми торып, барыбер тынмаячаклар, ди. Нинди тәрәккыйпәрвәре булмаган патша ирәеп утырыр йомшак кәнәфиле алтын тәхеттә тагын да? Йосыф пәйгамбәр кебек хөрмәтле вә гыйззәтле була алырмы? Илгә, халыкка бәхет өләшерлек, аларны тәшвишкә салмаслык акылы, кодрәте булырмы? Бөтен Рәсәйне тәмуг төбенә әйләндереп ясалган өченче революциядән соң, тәхеткә Ленин утырачакны Галимҗан аслан белми иде. Милли эшләр тәкъдире Сталинның уч төбендә уйнаячагы аның ике ятып бер төшенә дә керә алмый. Мөселман комитеты рәисе Мулланур Вахитовның ярдәмчесе булачагын әле мәдрәсә шәһадәтнамәсе дә алмаган шәкерт-мәхдүм Галимҗан кайдан белсен ди. Язмыш ике төбәйле, диләр. Аның башында әле мең төбәйле уйлар, йөрәгендә кайнар хис-тойгылар кайнаша. Алар гавам халкы язмышына бәйле. Әтисе җирне дә дүрт төргә

бүлеп карый. Бәлки, бөтен галәм якынча дүрт катламнан торадыр: күк тәхете, безнең кояш иле — галактикасы, кояш белән җир арасы, җир үзе.

Шул хакта уйлап, мең мәртәбә баш вата-вата бөтен галәм киңлеген айкап чыккач, Галимҗанның күңеле янә җиргә — үз авылының изге туфрагына әйләнеп кайтты. Алланың нинди кашка тәкәсе керә беренче төргә? Авыл ыстарастасы Тәхлисме? Юк. Ул — сатлык җан. Җаһил. Аның өчен арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит. Кеше язмышы, кеше бәхете, кеше киләчәге — аның өчен сукыр бер тиен. Андагы тәкъвасызлык галәмәтен шайтан да чүпләп бетерә алмас. Хөрмәтулла абзыйның фаҗигале үлеме — аның аркасында: «сарык буры» дигән нахак бәла тактылар. Сарык табылды. Мөбахис мәзиннең өенә ут төрткән, дип, Себер җибәрделәр. Соңыннан ачыкланды: мәнсез остабикәсе абзар артына күмерле көл түккән булган; утлы күмерне җил очырып, коры салам арасына китереп салган. Монысы Ходай эшедер, бәлки. Чөнки харам мал бервакыт барыбер янарга тиеш. Мөбахис мәзин дөньясын яңадан тергезде. Менә дигән йорт салды. Ярый. Булсын. Яңа бер тарлык та юк. Хөрмәтулла абзый төрмәдән кайта. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, Мөбахис мәзиннең җирән кашкасы югала. Авылда янә «Хөрти урлаган» дигән хәбәр тарала. Бу юлы Мөбахис мәзин теге вакыттагы үчен җиренә җиткерү максатын куя. Сүзе аста калмасын, янәсе. Хөрмәтулла абзыйны тереләй күмәләр дә ташлыйлар. Галимҗан булса, моны эшләтмәс иде, билгеле. Ул инде ир корына җиткән егет кеше. Чәйнәшер иде. Тешләшер иде. Сүзе белән дә егар иде тегеләрне. Әтисе дә өйдә булмаган. Мондый вәхшилеккә ирек куймас иде. Көрәшер иде. Мөбахис мәзин үз табан астын ялаучы ярлыларны җыйган да хөкем чыгарганнар да куйганнар. Ике бозаугга кибәк аерып бирә белмәгән надан, җаһил ыстараста Тәхлис Мөбахис мәзиннең кубызына биегән. Бу бит — түбәнлек, имансызлык, хурлыкның иң пычрагы.

Бу гаделсезлекне, бу вәхшилекне, бу ерткычлыкны күтәрә алмый Мәликә түти. Акылдан яза. Кулына күсәк тотып килә дә Мөбахис мәзиннең тәрәзәләрен кыра. Шуннан унлап ир килеп, кулларын артка каерып бәйлиләр дә Нәҗметдин мәзиннең таш келәтенә китереп ябалар. Ул башта җан әчесе белән гел җырлап ята. Аннан тына. Өч көннән соң җан тәслим кыла. Баш бала Мәдинә-Акчәчкә хәзер ике энесе, өч сеңлесе өчен ана да, ата да булып калды.

Акчәчкә! Галимҗанның беренче мәхәббәте ич ул. Кайткан саен күрми калмады. Эч серен ачып салгач, кендек әбисе Хәмдия абыстай аңлады Галимҗанның күңелен. Бервакыт шул караңгы базында очраштырып, үзе чыгып китте. Тик Галимҗанның мәхәббәтен кабул итмәде Мәдинә-Акчәчкә. Теге вакытта:

— Кырлык белән бодайны бергә кушмыйлар, Галимҗан абый,— дигән иде.

Димәк, ярлы баласы булганга, үзен кырлыкка саный; бай нәселдән чыккан Галимҗанны бодайга тиңли.

Бу юлы:

— Җитен борчасы җитен чәчәген харап итә бит ул, Галимҗан абый,— диде.

Димәк, ул Галимҗанны җитен чәчәге дип исәпли, ә үзен шул чәчәкне харап итүче борчага охшата.

Кызның үткен телле, авыр табигатьле, шигъри күңелле, тәкәллефсез булуы Галимҗанның йөрәген янә мең мәртәбә ярсытып җибәрде. Акыл ияләренең мәхәббәт турында әйткән сүзләрен дә тугылады, кат-кат тәсдыйк итте ул. Мәхәббәтнең бай, ярлы баласы булуга нигезләнмәвен дә аңлатырга тырышты. Мәхәббәтнең асылы күңел байлыгына бәйләнгән. Галимҗан шул иманга инанды. Мәдинә — бай күңелле кыз. Шул җиткән. Аныңча, калганы тормыш көткәндә, майлы табада шуган коймак шикелле, үзеннән-үзе җайга салына. Мәхәббәт ул — бөек сафлык! Галимҗан, Ырынбурда чакта Галишер Нәвоине укыганда, аның бу хакта әйткән сүзләрен ятлап та алган иде. Шуларны җиткерде, кат-кат тәкрарлады ул Мәдинә-Акчәчкәгә:

Гыйшыкка сафлык җан кебек кирәк,
Чуар хисләрне сыйдырмый йөрәк.

Аларның икесендә ике тел иде: Мәдинә-Акчәчкә сүзләрне авылча «чәчә», Галимҗан зыялыларга хас назлы, йомшак, купшы лисан-тел белән эш итә. Шуның белән ялгышты да ул. «Гыйшыкка сафлык җан кебек кирәк» дигән сүзләрне Мәдинә-Акчәчкәнең йөрәге кабул итмәде. Чөнки ул үзен саф җан дип исәпләми. Әйтерсең аның җанына ярлылык кере сеңгән. Җитмәсә, әтисенең төрле яклап «пычрануына» Мәдинә бик нык кыенсына иде. Нигә шундый керлелек белән ак нәселнең саф чәчәге булган Галимҗанны каралырга? «Чуар хисләрне сыйдыра алмый» дигәне дә тетрәндерде Мәдинәне. Хисләре нинди Мәдинәнең? Чуармы? Кем белсен.

Караңгы баз кебек өйдә яшәгән ярлы кызының хисләре томанлыдыр инде ул.

Бу очрашу былтыр булган иде. Аларның икесенә утыз алты яшь иде бит инде. Мәхәббәт, яратышу, сөешү турында һич икеләнми, мөкиббәнә, эчкерсез сөйләшер вакыт. Шулай да Мәдинә-Акчәчкә кулын да тоттырмады, кочакларга да ирек куймады. Бу очракта да ул, хис-тойгысын халык әйтеменә нигезләп:

— Галимҗан абый, соңгы сүзем шул: минем сыерчык оясына ялгыш килеп эләккән чыпчык буласым килми, моннан ары болай әдәпсез кыланмагыз, чакырмагыз, очрашулар файдасыз,— диде дә матур гына елмаеп чыгып китте.

Бу Галимҗан өчен түбәнлек иде. Ул янды, көйде, үрсәләнде, йодрыгы белән маңгаен төйде. Ак түти кайтканчы чыгып китмәде.

Ак түти мәсьәләнең мәсләген тиз сизде.

— Ул сине җарата бит, балакаем, нык җарата, әллә шыны аңламыйсыңмы... Бакчи... кобараң очкан, төсең киткән, шылай җарамый бит инде... Ул җарлы кызы булганга кәмсенә...— дип, Галимҗанны төрлечә юату ягын карады.

Галимҗан исә:

— Юк, Ак түти, ул мине яратмый,— диде дә, ачуын уч төбенә йомарлап, кырт кына чыгып китте.

Чынында исә Галимҗанга гашыйк иде Мәдинә. Аны беренче мәхәббәте дип исәпләде. Ләкин... ләкин... ак күңелне каралыйсы килмәде Мәдинәнең.

Кешеләрне төрләргә бүлгәндә дә күңелгә әнә нинди уйлар килә икән. Югарыга әтисен дә куеп карады ул. Ләкин ул башлык түгел. Шуңа күрә ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска таба икенче баскычка бастырырга мөмкиндер. Яхшы, иҗтиһадлы башлыкка ул җанын фида кылырга да әзер тора.

Өченче төркемгә Мөбахис мәзин кебек хәйләкәрләр керә. Дүртенчесенә — ыстараста Тәхлис ишеләр. Ә менә Хөрмәтулла абзый сыманнарны кая куярга? Андыйлар, гәрчә үзләре кыерсытылган булсалар да, башкаларга аслан яманлык теләми. Димәк ки, олы йөрәкле, матур күңелле, кешелекле булып чыгалар. Аларны икенче төркемнең бер күзәнәгенә «сылап куярга» мөмкиндер, бәлки.

Авылга Мөхәммәтгали исемле яңа ахун килде. Аны мактыйлар. Кешелекле, иҗтиһадлы, эзлекле, имеш. Әйдә, аны югары шүрлеккә мендерик. Белеме, акылы, шәфкатьлелеге

белән авылга иман нуры чәчсен, бәндәләрнең рухын күтәрсен, Ходай Тәгалә кушканны гавам халкына түкми-чәчми җиткерсен. Амин!

Күңел сандыгына күп нәрсә җыелган икән. Аңа менә шушы күркәм табигатьнең аллы-гөлле чәчәкләр хуш исе сеңгән. Шушы гүзәллекнең энҗе-мәрҗәннәре, гәүһәрләре җыелган ул күңел сандыгына. Табигатьтән бар булган матурлык алынган. Ул булачак язучының йөрәк төпкеленәчә үтеп, бөтен эчке әгъзаларына таралган. Әллә нинди сихри көч аның колагына «яз, яз, яз» дип пышылдый; бу матурлык эченә генә сыеп бетмәс, аны башка урыннарда яшәгәннәргә каләмең белән сурәтләп-тасвирлап күрсәт, табигатьтән алганыңнан мең өлеш артыграк итеп сылулап-чибәрләп бир, ди. «Яз башы», «Табигать балалары», «Сөю-сәгадәт», «Диңгездә», «Яшь йөрәкләр» кебек гүзәл әсәрләр шушы табигатьтән алган илаһи матурлыкны халыкка тагын да күркәмрәк итеп күрсәтәчәген Галимҗан хәзергә белми әле. Мөбахис мәзин кебекләрнең чын йөзен ачачак «Карак мулла» дигән хикәя дә язылачак. Халыкның авыр язмышы, Хөрмәтулла абзый кебек кимсетелгәннәр, тормыш төбендәгеләр «Карт ялчы», «Көтүчеләр» исемле әсәрләрендә чагылдырылачак. «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» кебек зур күләмле повесть, романнарда инкыйлабый-революцион көрәш тасвирланачак. Ул инде табигать матурлыгы белән әсәрләнүче, хисләнүче, шашынучы хыялый зат кына түгел, тормышның әчесен-төчесен татучы, гаделсезлек, хаксызлык, юньсезлек өчен сыкранучы, Хөрмәтулла кебек миллионнарның язмышын үз йөрәгенә алучы шәхес булып та җитлекте.

— Җазыгыз менә шуларны,— дигән иде теге вакытта Хөрмәтулла абыйсы.

Әле дә менә мең-мең юксыллар, ярлылар аның колагына:

— Яз, яз, яз,— дип пышылдыйлар сыман.

— Язам, язам, язам,— дип ант итте Галимҗан. Менә шушында. Табигать кочагында. Гөлләр-чәчәкләр арасында. Туган туфрагында. Күп тә үтми, бер елдан соң, 1907 елда Фатих әфәнде Әмирхан мөхәррир булган «Әль-ислах» газетасында аның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясе басылачак. Ул 1907 елның октябреннән башлап 1908 елның 2 июленә кадәр барлыгы 17 санда чыгарылачак. «Өмид» матбагасында китап итеп бастырганда, Галимҗан Ибраһимов шундый сүзләр язачак: «Зәки шәкертнең

мәдрәсәдән куылуы» — минем үз гомеремдә беренче мәртәбә каләм сынап караудан килеп чыккан бер нәрсәм. Мин аны 1907 елда Кавказда мөгаллим булып торган чагымда җәй көне язган идем. Шул көзне Фатих әфәнде Әмирханов җәнапләренең кулына төшеп, ул аны яңа чыгара башлаган «Әль-ислах» газетасының фельетонында дәрҗ кыйлды. Хәзер инде китап шәкелендә чыгармак булам. «Әль-ислах» фельетонындагы хикәя белән бу рисаләчек арасында аерма булмаячак. Башлап язылганда ничек булса, әле дә нәкъ шул рәвештә калдырам. Бер җирен үзгәртмим, бер хәреф арттырмыйм, киметмим, тик имлясын гына бераз төзәтәм».

* * *

Озак утырды Галимҗан бүген Кондызлы күл яры башындагы бүкәнне хәтерләткән таш өстендә. Ул әйтерсең авылының бөтен табигать матурлыгын су урынына эчә, йота, бөтен әгъзаларына сеңдерә, чалбар кесәләренә тутыра, яңа мәдрәсәгә бер кышка җитәрлек хуш ис, болын һавасы, чәчәкләр шифасы алып китә. Ул бүген мәдрәсәдәгечә, шәкертчә киенмәде. Әнисе теккән кара чалбар, ак күлмәк киде. Күлмәкне чалбар эченә тыкмады, тышкы якта калдырып, билен әнисе ясап биргән бармак юанлыгы гына ефәк билбау белән буып куйды. Аның ике очы да биленең уң ягына туры килеп, шуның берсе озынрак калдырылды. Ул оч чачаклы-чачаклы булып, ун-унбиш сантиметр чамасы аска төшерелеп, асылынып тора. Очында төрле бизәкле җепләр. Ул чачаклы мәкне дә, чачаклы канәферне дә хәтерләтә. Күлмәге төз якалы. Изүе ачык. Сул як яка төз тора. Уң яктагысы өчпочмак шәкелендә кайтарылып төшкән. Җәй буе үскән кара чәчләр аны ифрат сөйкемле, нык, гайрәтле егет итеп күрсәтә. Чәч үстерүне башта әтисе дә, әнисе дә килештермәде.

— Улым, мөселман кешегә бер дә муафыйк түгел бит әле болай төксем булып йөрү,— диде беркөн әтисе.

Әнисе аның сүзләрен куәтләде:

— Әйе, әтиең дөрес әйтә, улым, озын чәчтән иман качар,— ди.

Галимҗан, берникадәр шаяртып, шул ук вакытта чын хакыйкатьчә җавап бирде:

— Иманым чәчемдә түгел, әткәй-әнкәй, йөрәгемдә, аның белән беркайчан да сату итмәячәкмен, борчылмагыз.

Галимҗанны бөгү авыр икәнлекне әтисе дә, әнисе дә ях-

шы белә. Аңа теге яки бу мәсьәләне тәфсилләп аңлатырга тырышу — ут чыкмаганга чаң кагу. Шуңа күрә бу хакта башкача сүз куертып маташмадылар. Дәхи дә шунсы мәгълүм: Троицкида да, Ырынбурда да, Казанда да шәкертләрнең чәч үстерә башлавы турындагы аяклы хәбәрләр йөри. Бәхәс, сүз көрәше, фикер мантыйгы буенча теләсә кемне егып сала торган Галимҗан ни эшләп әле шундый яңалыкның койрыгында өстерәлергә тиеш? Яңалык ул ташны тишеп үскән үлән белән бер. Аны аслан туктатып булмый. Такырбаш Галимҗан бертөсле иде. Чәчле Галимҗанга бөтенләй икенче мәһабәт сыйфат керде. Матураеп, гаҗәп күркәмләнеп, карап туйгысыз егет булып китте. Бу килеш Галимҗан үзен мәдрәсәдәге чапан яки җилән кысасы эчендә йомылган ирексез кеше итеп тоймый. Бу кием аны ирекле итә, үзенчә яшәргә илһамландыра, инде чын егет булып җиткәнлекне ышандыра. Хакыйкатән, шулайдыр. Әтисе-әнисе аны бүген сөйкемле күз карашлары белән озатып калды. Әнисе хәтта урамга чыкты:

— Галимҗан улым, бик озак йөрергә тырышма, иртәгә сәфәр чыгасы бит, аннан ары сөйләшеп тә утырырбыз; күпме генә карасам да сиңа, күзләрем һаман туймады әле, — диде.

Галимҗан һаман шаяртып маташты:

— Ярар, әнкәй, озак йөрмәм; кайткач, каршыңда төп кебек утырырмын да ике сәгать селкенмәм, тәгъзим кылырмын, ә син мине күз нурларың белән иркәләрсең.

Хәсәнә абыстай елмаеп куйды:

— Әниеңнең ике сәгать буе сиңа тилмереп карап торырга вакыты бардыр шул, әле юлга кирәк-яракларны да әзерләп куя алмадым.

— Бернәрсә дә кирәкми, әнкәй! Үзеңне-үзең бетермә. Борчылма. Ял ит. Беләм инде: бәлеш, сумса, коймак, чәкчәк... Төн йокламаячаксың. Кояш зурлыгы бер бодай икмәге булса, шул җиткән миңа...

Галимҗан артык ашыкмый, ләкин җитез-җитез атлап, китеп барды. Гәүдәсе төз. Адымы нык. Башы югары. Кул хәрәкәтләренә кадәр ипле, чамалы, бәгъзе бер кылтым егетнеке шикелле кылдый-былдый килми. Хәсәнә абыстай, күз нурларын җылы агым итеп, элеккедән мең кәррә артык сөеп-назлап карап, аналарда гына була торган бөек хис-тойгы белән, улы күмелгәнче аңа бәхетле-сәгадәтле киләчәк теләп торды. Шакирҗанын исенә төшереп, балавыз да сыгып алды.

Менә бервакыт мулласының лап-лоп атлап килгәне шәйләнде. Ул тиз генә күз яшьләрен сөртте дә ихатага керде. Елаганын сиздермәскә тырышып, яулык очы белән битен каплады да мулласыннан ерагаерга тырышты. Сәбәпсез Сәми дә сәндерәгә менми дигәндәй, сизде мулла абзый яулык белән капланган битнең сәбәбен.

— Син тагын да йомшаргансың, остабикә, — диде мулласы.

Хәсәнә абыстай, моны йөрәге кушмаса да, алдашырга мәҗбүр булды:

— Юк, юк, мулла, еламадым мин, күземә чүп керде...

Галимҗан боларын белми. Ә инде әнисенең күзләре талганчы озатып карап калуын белә. Шактый киткәч бер әйләнеп караса, әнисе һаман капка төбендә моңаеп басып тора иде әле. Ана! Бала өчен йөрәген ярып бирергә әзер тора ул. Ананың бөтен гомере «бала» дип үтә. Ул үзе өчен рәхәт тормыш та теләми. Фәкать баласы өчен яхшы булсын. Йокысыз төннәр. Бөтен кайгыны үз йөрәгенә алу. Бала аркасында михнәт чигүләр. Нинди яхшылык күрсәтергә мондый бөек анага? Ана-алиһәгә? Фәрештә-анага? Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап, кулга шәһадәтнамә алгач, алар Галимҗанның йә мөдәррис, йә мулла, йә ахун булуын телиләр. Әнисен-әтисен шуның белән канәгатьләндерергәме? Язмыш җилләре аны әллә кайларга, әллә нинди ят җирләргә алып китеп диңкетмәсме? Кайда егылырыңны белсәң, шунда салам түшәп куяр идең, диләр бит. Тормыш бабай аслан әйтми ул кай төштә башыңа чукмар белән тондырасын. Ә инде әсәр язарга теләк барлыкны әйтсәң, янә гауга, низаг, зилзилә бураны котырачак. «Нигә кирәк ул лыгырдыкнамә, синдә бит пәйгамбәрләр башы, андый вак-төяк шөгыль шалапайлар өчен хас», — диячәк әтисе.

Шул уйларны да, тәсбих төймәләре шикелле итеп, башыннан кичерде Галимҗан. Тирә-ягына янә бер каранып алды. Таш бүкән яныннан ук чабылмаган озын үлән мәйданы сузылып китә. Үләннәр арасында төрле-төрле чәчкәләр. Аларның бәгъзе берләре, гәрчә җәйге кебек җылы булса да, көз сулышына бирелеп, зәгыйфьләнгәннәр. Кайсыберләре әле горур чибәр кызны хәтерләтеп балкып утыра. Таҗлары түбәтәй зурлык булганнары да бар. Әллә яңадан чәчәк аттылармы? Булыр да. Шундый үзенчәлекле көз бит бу: алмагачлар, чияләр икенче мәртәбә чәчәк атты. Картлар моны төрлечә аңлата: берәүләр яхшылыкка юрый, икенчеләр — яманлыкка. Галимҗанның әтисе моны уңай күренеш дип

исәпли. Урыс-япон сугышы, инкыйлабка бәйле рәвештә халыкка искиткеч авырлык килде. Яхшылык белән яманлык, аязлы-болытлы көн кебек, алмашынып торучан. Шул яманлык артыннан Аллаһы Тәгалә бәндәләргә матур көз бүләк итте, янәсе. Бирсен Ходай! Шулай булсын! Табигать матурлыгы белән назлану, ләззәтләнү, хозурлану кешене олы йөрәкле итә.

Үлән мәйданы бик озынга сузылмый. Аннан кара урман башлана. Анда җиләк, гөлҗимеш, шомырт, миләш, балан үсә. Аның эченә кереп китсәң, син үзеңне оҗмах-җәннәткә сират күперсез генә килеп эләккән кешедәй хис итәсең.

Чү! Кем җырлый? Урман эчендә көмеш моң агыла. Мең сандугач моңы бергә килеп кушылган диярсең. Галимҗан аягүрә басты. Урманга карап йөгерергә уйлады. Ләкин тыелды. Йөгерсә, ул моң өзелер, киселер, югалыр кебек тоелды. Хәтта тын алырга да курыкты. Әйтерсең тыны белән җылы һава дулкыныдай агылып торган моңны каплый. Галимҗанның алдыннан гына әллә күпме ак күбәләк очып китте. Алар уйный, шатлана, көн матурлыгына куана. Гомерләре бигрәк кыска шул. Нибары бер көн. Изге әрвахларның җаны күбәләк булып җиргә кайта, дигән сүз дә бар. Моның өчен аларга фәкать бер көн вакыт бирелгән, имеш. Кайта да, бала булса, ата-анасын, туганнарын, туган туфрагын, авылын күреп китә. Күбәләкләр уйнаклашып, очынып, назланып очтылар-очтылар да гөлләргә, чәчәкләргә, үләннәргә тезелешеп кундылар. Алар да әлеге урман ягыннан килгән моңга әсәрләнделәр шикелле. Очмый, селкенми, канатларын салындырып, шул моң эченә йотылдылар. Бераз шулай тын гына торгач, янә һавага күтәрелделәр. Икесе урман ягына таба җилпенеп очып китте. Кем белә, алары Хөрмәтулла абзый белән Мәликә түти җаннарыдыр, бәлки. Җырлаган кызның Мәдинә-Акчәчкә икәнлеген аңлады Галимҗан. Хөрмәтулла абзый белән Мәликә түтинең җан иясе булган ике күбәләк Мәдинә-Акчәчкәнең моң эченә барып керәчәк. Чү! Галимҗанның ике беләгенә ике ак күбәләк килеп кунды. Мөгаен, карап туймаслык бу якты дөнья белән бик иртә хушлашкан сеңелләре Фәрдәнә белән Нәфисәнең җан гәүһәрләредер алар. Галимҗан нишләргә дә белми аптырап тик торды. Каушады. Йомшады. Әсәрләнде. Бик авыр вакытларда да, ишелеп-ишелеп кайгы-хәсрәт килгәндә дә, дөреслек өчен кешеләр белән якалашканда да болай җебеми торган иде бит ул. Әле менә коелды да төште. Күбәләкләрнең икесен дә

алып сөясе, иркәлисе, назлыйсы килде. Ләкин курыкты. Саксыз кыланып, имгәтеп ташлавы бар. Кул белән кагылсаң, алар очып китәчәкләр. Моны Галимҗан теләми. Озак-озак шулай иркәләнеп, назланып, хозурланып торсыннар әле абыйсының беләгендә кунаклап. Ә урман эчендәге моң агыла да агыла. Теге вакытта, кендек әбисе өендә җырлаганда, Мәдинә-Акчәчкәнең тавышы, гәрчә бик моңлы булса да, бала-чаганыкы кебек кенә иде әле. Ә хәзер инде ул җиткән кыз. Тавышы көр. Моңы тирән. Йөрәгеңне кисә. Үзәгеңне өзә. Күңелеңне телгәли.

Нәкъ шушы урында Галимҗанның сандугач сайраганын тыңлап торганы бар. Ул гел бер моң белән генә сайрамый. Бер моң белән бераз сайрагач, кешеләр күңелен икенчесе белән хисләндерим дигәндәй, башкасына күчә. Алар бик күп. Сансыз. Чамасыз. Бихисап. Мәдинә-Акчәчкәнеке дә шулай икән. Моңнарны ул алыштырып кына тора. Берсендә шушы гүзәл табигатьнең кешеләр йөрәгенә матур тойгылар салуы, күңелләрен күбәләктәй канатландыруы, хис-тойгылар дөньясында ләззәтләндерүе булса, икенчесендә әтисе-әнисе язмышы өчен өзгәләнү, өченчесендә авыр тормышка каргыш яудыру кебек моңнар сибелә. Бу моңнарны күбәләкләр, үләннәр, гөлләр, чәчәкләр, бөтен урман тыңлый. Шул моңнар шаукымында Җир белән Күк үбешеп ала төсле. Баерга юл тоткан Кояш та аптырап туктап калды шикелле. Ул гүя хәзер ашыкмый, моңлы кызны калдырып китәсе килми.

Галимҗан һаман шулай бер килеш басып торды да торды. Барыргамы янына? Барса, билгеле, ул җырламаячак, моң киселәчәк. Ә инде аның киселүен теләми Галимҗан. Бармаса, иртәгә Мәдинә-Акчәчкәне күрми сәфәр чыгачак. Аның хәзер авылга башка сукмак белән кайтып китүе дә бар бит әле. Юк, барырга. Янына барырга! Рәхәтләнеп, эч серен бушатканчы, күңел булганчы, йөрәкне йөрәккә кушып, бер сөйләшергә. Моннан да уңай вакыт-урын мәңге-мәңге табылачак түгел. Урман. Табигать кочагы. Чәчәкләр. Гөлләр. Алар икәү генә. Яшьлек тилелеге белән ярсыган, шашкан, гасабиланган йөрәкнең давыл-ташкыннарын мәхәббәт шифасы белән басарга кирәк. Иртәгә юлга...

Галимҗан башта акрын гына атлады. Теге ике күбәләк тә бара аның белән. Әмма... әмма... Шәп-шәп атлап китим дисә — әллә аны сөешүдә җиңү казану тәмам ярсыттымы — аяк астындагы бер түмгәккә абынды да егылды. Шулай да ул озак ятмады. Ата селәүсен тизлеге белән дәррәү сикереп

торып, өстен каккалап алды. Каударлыгы, мәхәббәт алдында сөмсез кемсә шикелле кылануы өчен эчтән генә үзен сүгеп-битәрләп тә куйды. Ә теге ике күбәләк-әрвах — сеңелләренең җан ияләре очып киткәннәр иде инде. Ярый, егылганда сытылмаганнар. Моның өчен шат Галимҗан. Әнә алар әле һаман уйнаклап-уйнаклап очалар. Әйләнеп-тулганып очтылар-очтылар да авылга таба юл тоттылар. Димәк, Фәрдәнә белән Нәфисә җаны туган йортына китте. Анда бакчадагы сирень куакларына, алмагач ботакларына кунып шатланачаклар. Әтисе-әнисе чыкса ихатага, карап куаначаклар, җилкәләренә барып кунарлар, бәлки. Бер җай табып, ачык ишектән өйгә үтүләре дә мөмкин. Анда — ахшамсафа гөле, рәйхан гөле, сөмбел гөле... Шуларның чәчәкләренә кунып рәхәтләнәчәкләр. Хушыгыз ике күбәләк — ике җан иясе! Кайта торыгыз. Мин дә озакламам. Туган йортта очрашырбыз! Тизрәк очыгыз! Тизрәк! Тизрәк!!!

Күбәләкләрне күздән югалганчы карап торды Галимҗан. Аннан соң тирән хис-тойгылар, күңел тетрәнү, йөрәк ярсу аны урман ягына — мәхәббәте-бәхете янына ашыктырды. Ләкин аңа анда барырга туры килмәде. Чөнки йөрәгенең парәсе Мәдинә-Акчәчкә үзе монда килә иде. Ул инде хәзер җырламый. Ике кулында ике төенчек-капчык. Алары аның җиметер инде. Йә балан, йә миләш-фәләндер.

Каккан казыктай басып тик торды Галимҗан. Нишләргә дә белмәде. Ә Мәдинә-Акчәчкә, яшьлек ярсуларымны түкми-чәчми сиңа тапшырам дигәндәй, туп-туры аңа таба килә. Бераздан Галимҗан да, бәхет сандугачын тизрәк эләктерергә чамалап, ашыга-ашыга атлап китте. Менә очрашты алар. Мәдинә-Акчәчкәнең ике кулбашында ике ак күбәләк иде. Әкияттәге сыман бу. Серле дөньяның мәңге ачылмас серләре диярсең. Бу гүя оҗмах-җәннәтнең үзе. Ике ак күбәләк Галимҗанга да кунды. Мәдинә-Акчәчкәнең дә кулбашларында тын гына иркәләнеп утыралар. Болар инде, мөгаен, әтисе-әнисенең җан ияләре. Мәдинә-Акчәчкә ашыкмый, җай гына, бик акрын атлап килде. Шул әрвах-күбәләкләрнең очып китүеннән курыккандыр, бәлки. Килеп туктагач, иплә кенә, тәнен-бәдәнен төз тоткан хәлдә, ике төенчеген сак кына җиргә куйды. Аның берсе тузган-ямаулы капчык иде. Аны ул аркылы-торкылы чабата киндерәсе белән бәйләгән. Таралып төшүдән куркыптыр инде. Эчендә нәрсәдер — анысы Галимҗан өчен мәгълүм түгел. Икенчесе — ашъяулык булса кирәк. Анда күп итеп балан төрелгән. Ашъяулык та шак-

тый иске, ямаулы, тормыш авырлыгы төсен сиздереп тора. Ул дүрт почмагын бергә китереп төйнәп куелган. Шул төйнәлгән җирдә буш калган урыннан кызарып пешкән баланнар җемелдәп күренеп тора.

Алар кул бирешеп күреште. Нәкъ шул вакыт әлеге ике күбәләк очып китте. Авыл ягына. Болар икесе дә алар күздән язганчы карап тордылар. Аннан, бер-берсенә карашып, катып калдылар. Мәдинә-Акчәчкәнең киемендә берникадәр үзгәреш тә бар. Ул кышкы көннәрдә Галимҗанның әнисе янына килеп, аннан тегүгә, чигүгә өйрәнгән икән. Шуннан кул белән кешеләргә күлмәк тегеп бирә башлаган. Монысы инде энә белән кое казу кебек. Шулай да күлмәкләрне бик ипле, килешле, матур тегә икән. Галимҗанның әнисе белә кул белән күлмәк тегүнең авырлыгын. Кызгана моны. Шуннан аны аяклы машинада тегәргә өйрәтә. Көндезләрен килеп, бер көн эчендә бер күлмәк тегеп китә. Чигүгә дә тиз өйрәнә Мәдинә-Акчәчкә. Кияүгә китәсе кызлар сөлге-тастымал, кульяулык, ашъяулык кебекләрне аннан чиктерә башлады. Шуның белән шөһрәт казанды ул авылда. «Алтын куллы Мәдинә» дигән даны бар хәзер. Хәсәнә абыстай аны укырга-язарга да өйрәтте. Моңа да ул тиз төшенде. Чөнки һәр эшкә ихлас, мөкиббән, йөрәге белән бирелеп керешә. Дөрес, җәй көне, Галимҗан мәдрәсәдән кайткач, аларның өендә бик буталып йөрмәскә тырыша. Галимҗанның күзенә чалынудан курка. Шулай да беркөн очраштылар. Чигүгә кызыл җебе беткән икән, Хәсәнә абыстайдан шуны сорап килгән. Галимҗан берүзе генә иде. Моны белгәч, кыз тиз генә чыгып китү ягын карады. Тик Галимҗан ирек куймады. Кулыннан алды да:

— Мин бүре түгел, Мәдинә-Акчәчкә, ашамам әле үзеңне, әйдә үт, — дип, аны кәнәфигә китереп утыртты.

— Сез мине нигә «Акчәчкә» дисез, Галимҗан абый, бу миннән көлүегезме?

— Мин, Акчәчкә, кешедән көлмим, андый гадәтем юк, кеше бөек ул!

— Шайтан таягын акчәчкә итеп буламы?

— Син алай түбәнсенмә, Мәдинә-Акчәчкә! Әнкәй сине нык мактый. Белмәгән эше юк, акылы да алтын, кулы да алтын, ди.

— И... Хәсәнә абыстай бит ул кешенең яхшы ягын гына күрә, яманында эше юк; үзенең күңеле матур булганга шулайдыр инде; кайда инде ул безгә алтын булу, бакыры да җиткән.

— Син тиз генә бакырга әйләнмә әле. Минем өчен Акчәчкә син. Ак чәчкәгә охшагансың.

— Сез, Галимҗан абый, матур сөйлисез. Андый тел бездә юк инде ул. Бездә агач тел, чәнечкеле тел.

— Ә мин чәнчеп сөйләүчеләрне дә яратам. Әгәр ул урынлы чәнчә белсә.

— Сез яхшы күңелле, Галимҗан абый! Әтиең дә, әниең дә шулай. Хәер, картлар әйтмешли, алма агачыннан ерак тәгәрәми бит.

— Синең дә әтиең-әниең яхшы күңелле кешеләр, Мәдинә-Акчәчкә, аларны аңлый белергә кирәк.

— И... аңлыйсың ла ул, Галимҗан абый, аңлау белән генә булмый икән шул; әнә, әтинең өстенә күпме нахак пычрагы өйделәр, җитмәсә, имгәтеп ташладылар.

— Килер бер көн, Мәдинә-Акчәчкә, кешеләр арасында яхшы мөнәсәбәт булыр, алар бер-берсен рәнҗетмәс, аңлашып яшәрләр.

Мәдинә елмаеп куйды:

— Кызыл кар яугачмы, Галимҗан абый?

— Кызыл кар яугач түгел, кызыл көчләр алып киләчәк андый тормышны.

— Мин аларны аңламыйм, Галимҗан абый!

— Кызыл көчләрме? Хәзер аңлатам. Ул болай...

Нәкъ шул мәлдә Хәсәнә абыстай кайтып керде. Боларның сүзләре, кинәт өзелгән җеп кебек, капыл туктап калды.

— Кунак бар икән ләбаса, ә мин күршегә кергән идем... Хәзер менә чәй эчәрбез,— дип елмайды Хәсәнә абыстай, керә-керешкә.

— И... нинди кунак ди инде ул, абыстай, еш киләм бит, әле менә кызыл җебем бетте дә...

— Кызыл җепме? Табарбыз, гөлкәем, табарбыз.

Хәсәнә абыстай Мәдинәне өске бүлмәгә алып менеп китте. Галимҗан ялгызы гына калды.

Бәйрәм ашы кара-каршы дигәндәй, Мәдинә-Акчәчкә Хәсәнә абыстайның яхшылыкларын мең өлеш кире кайтару уе белән йөрде. Бер килгәндә, «ә» дигәнче ике катның да идәннәрен ялтыратып юып чыга, икенче тапкыр керләрен чайкап бирә, өченчесендә янә нидер эшли. Яз көне бакчада түтәлләр казый. Аннан чүп үләннәрен утарга килә. Көзен урак урыша. Нинди генә хезмәткә тотынмасын, кем әйтмешли, эш аның кулында биеп тора. Менә шундый киленең булсын иде, карт көнемдә рәхәтләнеп кенә яшәр идем, дип уйлый

Хәсәнә абыстай. Бервакыт бу фикерен Галимҗанга да әйтте ул.

— Бәй, әнкәй, сакла алай булгач Мәдинә-Акчәчкәне минем өчен, мәдрәсәне тәмамлап кайту белән туй ясарбыз,— диде Галимҗан, берчә шаяртып, берчә чынлык белән.— Ул минем беренче мәхәббәтем, моны кендекәй дә белә, син дә сизенәсең булыр.

— Атаң авылда мәдрәсә ачарга хыяллана. Шунда мөдәррис булырсың. Мәдинә укырга-язарга тиз өйрәнде. Бик зирәк бит ул. Бергә яши башлагач, мәгълүматын үзең дә күтәрерсең, ул бөтен нәрсәгә тиз төшенә.

Бу сөйләшүдән соң, Галимҗан әнисен кочаклап үбеп алды хәтта. Үз анасының олы йөрәкле булуын янә бер мәртәбә ныклап аңлады ул. Димәк, ул кешеләрне ярлыга, байга аермый. Ул күңел байлыгы, күңел ярлылыгы буенча эш итә; ярлы күңелле бай, бай күңелле ярлы булуны аңлый. Әтисе дә шулай лабаса. Димәк ки, Мәдинә-Акчәчкәне шушы өйнең нуры итүгә ул да каршы килмәячәк. Әтисе-әнисе капма-каршы холыклы булсалар да, дөньяга караш, күңел байлыгы, кеше йөрәген аңлау ягыннан бер-берсенә ике тамчы су кебек охшашлар икән. Алар гүя икесе бер җан сыйфатына әверелеп кәрәзләнгән. Шундый мәсләкле, иманлы, олы йөрәкле, бөтен авыл өчен мөхтәрәм вә хөрмәтле ата-ана кулында тәрбияләнүенә үтә канәгать Галимҗан. Дөрес, шау-шу, низаг, өермә, давыллар булгалап ала. Хәер, тормышта табаксавыт шалтырамый тормый, диләр. Шалтырауга ата-анасы түгел, күбрәк үзләре гаепле. Ата-ана өчен бала тәрбияләүнең никадәр авыр икәнлеген Галимҗан үзе дә ныклап аңлады инде хәзер. Соңгы ахмаклыгы да аларны аз йончытмады. Инде киләчәктә булмасын. «Галия» мәдрәсәсен алар йөзенә кара тап якмаслык итеп тәмамларга язсын! Амин! Быел бит әле ул киләчәк өчен искиткеч матур өметләр белән китә. Әнисе Мәдинә-Акчәчкәне килене итәргә җыена. Рәхмәт сөекле ана! Бөек ана! Фәрештә ана! Алиһә ана!

Менә аның күз алдында Мәдинә-Акчәчкә үзе басып тора. Зәңгәр ситсы күлмәк өстеннән ак алъяпкыч бәйләгән. Аягында читек. Артка чөеп бәйләгән ак яулыгы астыннан ике калын толым сузылып аркасына яткан. Ул толымнар алтын төсле елык-елык килеп тора. Тын алганда, калку күкрәге дулкынлана. Моңа чаклы күзләренә тутырып караганы юк иде. Зәп-зәңгәр икән алар. Зәңгәр күк төсле. Тирән. Серле. Уйчаннар. Ике бит очы алмадай кызарып то-

ра. Әллә бу кызыл сөртеп куштанланып та йөри башлаганмы дип уйлаган иде башта Галимҗан. Юк, алай түгел икән. Ул кызыллык, бәлки, кояштандыр. Анда, бәлки, эчке йөрәк кайнарлыгы бәреп чыккандыр. Яшьлек дәрте кызыллыгыдыр. Әллә, матур күрсәтер өчен, төн фәрештәсе кызыл якканмы аның бит очларына? Андагы сизелер-сизелмәс сипкелләр энҗе җемелдәвен хәтерләтә. Аксыл йөзгә аларның барысы да бик килешле, урынлы, табигый кебек. Уң як бит очында, әлеге энҗе-сипкелләр арасында, зәңгәрсу миң бар. Анысы хас та кыйммәтле мәрҗән. Авызы уймак кебек кенә. Пешкән чиядәй кызарып янып торган сутлы иреннәр таш йөрәкне дә эретерлек. Бу иреннәр нишләп шулкадәр кызыл, әллә буяганмы дигән уй килгән иде башта Галимҗанның күңеленә. Ләкин бу очракта да ул ялгышты. Ул кызыл иреннәрне дә аңа табигать бүләк иткән икән. Моны ничек дип атарга? Урман кызы? Су кызы? Табигать кызы? Ә нишләп урманга бу кадәр матур киенеп килгән ул? Әллә Галимҗанның монда икәнлеген белгәнме? Барырга йөрәге кушканмы? Җимеш җыюы бер хәйлә генәме? Белмәссең. Аңламассың. Гаҗәп нәрсә. Ә бит үзе элекке кебек йөзен дә, карашын да яшерми. Зур зәңгәр күзләрен чекерәйтеп карап тик тора. Мин синеке, Галимҗан абый, курыкма, тартынма, кочакла дигән кебек. Авызга керердәй булып тора. Бүген әйтерсең Ходай Тәгалә үзе очраштырды аларны.

Галимҗан аның мамыктай йомшак кулларыннан алды, аннан иплəп кенә бөтен гәүдәсен үзенә таба тартты. Аннан кысып кочаклап, бит очларыннан чут-чут үбәргә кереште. Мәдинә-Акчәчкә ләм-мим бер сүз әйтми тик тора. Үз гомерендә беренче мәртәбә татыган бу ләззәттән ул гүя йомшарды, эреде, җебеде. Кыздан кояш нурлары белән аралашкан чәчәкләр исе, урман исе, дала исе килә иде. Галимҗан шул хуш исләр сихеренә йотылды. Мондый сөешү бәхетенең аңа да тәүге мәртәбә елмаюы бит әле. Нинди кадерле минутларны, Ходаем, нишләп әле сөлектәй егетне унтугыз яшенә хәтле шушындый татлы рәхәтлекләрдән мәхрүм итеп килдең? Дөньяда барыннан да өстен торган сөешү кебек мәңгелек, сихри бер бөек көч бар икән. Алар сөешүне озак кына дәвам итте. Ләкин берсе-бер сүз әйтмәде. Хәзер инде аң-акыл да, уй да болар иркендә түгел. Тик хис-тойгы, ярсу, шашып сөешү генә хөкем сөрә. Мәдинә-Акчәчкә үзе үк таралып төшкәндәй булды. Йомшарды. Хис давылына күмелде. Аның өчен хәзер бөтен дөньясы сукыр бер тиен тора. Аның өчен сөе-

шү кебек бөек ләззәт кенә бар. Ул үзе дә Галимҗанны кысып-кысып сөя, күзләреннән, маңгаеннан, бит очларыннан чут-чут үбә башлады. Аннан иреннәр очрашты. Монысы — иң кайнар үбешү. Мин — синеке, син — минеке, дигәнне аңлата торганы. Йөрәкләр йөрәккә беректе. Кысыша торгач, алар гүя икесе бер-берсенең тән күзәнәкләренә керешеп, бербөтен мәхәббәт илаһилыгына әверелделәр. Бервакыт, киселгән агачтай, кочаклашкан-үбешкән килеш җиргә ауганнарын үзләре дә сизми калды. Аннан алар берникадәр зәңгәр күккә карап яттылар. Сүз һаман юк. Фәкать ике яшь күңелне шашындырган, ярсыткан, җенләндергән кайнар хис-тойгылар давылы гына бар. Бераздан алар, яткан килеш кочаклашып, янә үбешергә керештеләр. Мәдинә-Акчәчкәнең ирененнән бал тәме, чәчәкләр хуш исе тәме килә. Алар янә кысышты. Икесе бербөтенгә әверелде. Мәхәббәт йомгагы дияргә мөмкин моны. Сулып-шиңеп барган көзге чәчәкләр, яшел төсләрен җуеп, кибә башлаган озын үләннәр арасында барлыкка килгән яңа адәми чәчкә дип атарга да мөмкиндер, бәлки.

Бервакыт Мәдинә-Акчәчкә һушына килде. Ялт сикереп торды да өс-башын каккалады. Күлмәген рәткә китерде. Яулыгын яхшылап бәйләде. Аннан соң, кинәт җендәй кыланып, сөешү хисләре исереклегеннән һаман айнымый яткан Галимҗанны кулыннан тотып җилтерәтеп торгызды. Алар арасында шундый сөйләшү булып алды:

— Галимҗан абый, сез мине алдап кына йөрисезме? Мыскыл итәргә уйлыйсызмы?

— Мин, сөеклем, урынсызга беркайчан да кешедән көлмим.

— Мине хатынлыкка алырга уйлыйсызмы?

— Әйе. Әнкәй дә мактый үзеңне.

— Әгәр алсаң, чәчем белән җир себерер идем.

— Алай түбәнсенмә, Акчәчкә.

— Мин бик усал бит, Галимҗан абый, бу яктан әткәйгә охшаганмын, түзәрсеңме?

— Син акыллы усал.

— Бу холкым белән Хәсәнә абыстайны хафага салмаммы?

— Әнкәй кешеләргә бәяне йөрәгенә карап бирә.

— Энеләремә, сеңелләремә ярдәм итәрсеңме соң?

— Мин бу хакта, син әйтмәсәң дә, уйланам.

— Син бик изге күңелле, Галимҗан абый!

— Тормыш чәчәгем булырсың, Мәдинә!

— Һи, син бит иртәгә китәсең.
— Киләсе җәйдә туй ясарбыз. Көт.
— Көтәрмен лә ул. Кайткач, алмасаң?
— Мин вәгъдәле кеше.
— Вәгъдә — иман.
— Әйе. Вәгъдә — иман!
— Галимҗан җаным!
— Әү!
— Озакка сузмыйк моны.
— Ничек алай?
— Син мине хәзер үк хатын ит.

Бу сүзләрне ишеткәч, Галимҗанның аркасыннан меңләгән кырмыскалар йөгерешеп үткәндәй булды. Аның исе-акылы китте. Йөзенә кара коелды. Ул арада Мәдинә, әллә нинди мәзәк-сәер тавышлар белән шаркылдап көлеп чалкан ятты да тәүфыйксызланып, тәкатьсезләнеп, Галимҗанны янына чакырды:

— Кил, җаныем, курыкма, монда берәү дә юк бит. Алмасаң да, баламны сиңа такмам. Төсең итеп тотармын.

Галимҗанның җен ачуы чыкты. Кызып китте, Мәдинәне җилтерәтеп торгызды да:

— Исәр икәнсең,— диде.

— Ә син куркак. Бай балалары шулай җебегән була. Сез бит йомшак көпшәләр. Ха-ха-хау...

Бераз тырпаеп торгач, ямьсез итеп көлде дә Мәдинә:

— Тот... тот... тота алмыйсың...— дип, тыр-тыр йөгереп китте.

Шулай итеп, бер мизгелдә барлыкка килгән олы мәхәббәт күз белән каш арасында кәмиткә әйләнде. Галимҗан йөгермәде аның артыннан. Мәдинәне кат-кат чакырып карады. Ләкин ул якын килмәде, тәкәбберлек күрсәтте. Менә бервакыт, әтисе тарафыннан рәнҗетелгән сабый бала шикелле, баскан урынында кычкырып елап җибәрде. Галимҗан аның акылы җиңеләйгәнлеген аңлады. Димәк, әтисе-әнисе кайгысы аны да бөккән. Йа Хода! Ник син оҗмахтай бу матур җир йөзендә Мөбахис мәзин, Тәхлис кебек бәндәләр язмышы белән шаяручыларны яшәтәсең?

Галимҗан, куянны качырудан куркып атлаган саклык белән акрын гына атлап, Мәдинә янына барды:

— Мәдинә-Акчәчкә! Әйдә кайтыйк.
— Иртәгә туй ясарбызмы?
— Ясарбыз.

Мәдинә аның күкрәгенә башын куйды:

— Мин бит, Галимҗан абый, синең монда икәнлегеңне белеп килдем. Шуңа матур киенергә тырыштым. Әллә бу күлмәгем, бу алъяпкычым ошамыймы сиңа?

— Ошый, Мәдинә-Акчәчкә, син бик гүзәлсең; әйдә, кайтыйк.

— Юк, кайтмыйк, Галимҗан абый, куныйк шушында гына. Безне берәү дә күрмәс. Иртәгә никах укытырбыз.

Мәдинә сөйләде дә сөйләде. Сүзләрендә ул нык бутала, ялгыша башлады. Галимҗан кайтырга күпме генә кыстамасын, тыңламады, киреләнде.

— Мәдинәм! Акчәчкәм! Энеләрең, сеңелләрең көтәдер; алар ачтыр, әйдә, кайтыйк, — дигәч кенә берникадәр акылына килде. Бер төенчекне Мәдинә үзе алды, икенчесен — Галимҗан.

Юлда Галимҗан гел яхшылык турында гына сөйләргә, Мәдинәнең сорауларына нык уйлап җавап бирергә тырышты. Чөнки тагын да акыл эзеннән язмасын өчен, аның күңелен даими күтәреп торырга кирәк иде.

* * *

Галимҗан Мәдинәне юл буена гел юатып барды. Ул йә елап җибәрә, йә шаркылдап көлә, йә Галимҗанга әллә нинди күңелсез сүзләр әйтә. Галимҗан исә аның өчен сүзләрнең гел матурларын сайларга тырышты. Яхшы сүз котырган бүрене дә тынычландыра, дигәнне ишеткәне бар иде аның. Чын икән. Аның шашынган вакытында бер яман сүз ычкындырсаң, ул тагын да мең өлеш җенләнеп китәргә мөмкин. «Син бик чибәр, Мәдинә-Акчәчкә», «Энеләрең, сеңелләрең өчен кайгырма, аларны үзем карармын», «Без бик матур яшәрбез» кебек сүзләрне әйтсә, Мәдинә тынычлана, моңсулана, тирән уйга чума.

Шулай парлашып, икесе ике төенчек тоткан хәлдә, авылга кайтып җитеп, урам буйлап атладылар. Үзләренең өе яныннан үткәндә, аларны Хәсәнә абыстай күреп калды. Икенде намазын укыгач, ул, Галимҗанның озак кайтмавына хафаланып, капка төбенә чыккан иде. Аларның парлашып үтеп китүләре Хәсәнә абыстайны тирән борчуга салды. И илаһым, бу нинди ахмаклык инде тагы да, и бу Галимҗанны, һаман балалыктан аерылмый, халык ни әйтер, көпә-көндез никах-

сыз житкән егет белән кыз урамда парлашып төенчек күтәреп йөрсеннәр, имеш, дип сыкранды. Кычкырыйм, чакырыйм дисә, алар шактый ераклашканнар иде инде.

Галимҗан Мәдинәне Ак түтигә алып барды. Аларны кендекәй якты йөз, күтәренке күңел белән каршылады. Шул ук вакытта аның чыраенда нык гаҗәпләнү чаткылары бар иде. Мәдинәнең үзен генә калдырып, Галимҗан кендекәйне ишегалдына чыгарга ымлады. Чыккач, мәсьәләнең барын да сөйләп бирде.

— И... бигрәк миһербанлы булдың инде, балакаем, ничек түземлекләрең житте монда алып килергә, берәү булса, ташлар да китәр иде,— дип, Галимҗанның аркасыннан кат-кат сөеп куйды Ак түти.

— Хәзер кайтып, мин моны әнкәйгә әйтәм, ул монда килми калмас, кендекәй, борчылма инде, Мәдинәгә авыр сүз әйтә күрмә.

— Әйтмәм, балакаем, әйтмәм. Кешеләргә болай мәрхәмәтле булганың өчен, Аллаһы Тәгалә үзеңә таудай бәхет, корычтай сәламәтлек, пәйгамбәрләрнекедәй акыл бирсен! Барыр юлларыңа фәрештәләр гөл сипсен! Намаз арты саен олы бәхет теләп дога кылырмын үзеңә. Мин бит синең икенче анаң. Кендекәйнең изге теләге кабул булмый калмый ул...

— Рәхмәт, кендекәй, әйткәннәрең фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килсен; фатихаңны Ходай Тәгалә үзе кабул итсен дә аннан миңа кайтарсын,— дип чыгып китте Галимҗан.

Ул кайтып кергәндә, әтисе белән әнисе аскы өйдә иде. Галимҗан бар булган хәлне түкми-чәчми сөйләп бирде. Мәдинәне әле кендекәйдә калдыруын әйтте. Аннан соң:

— Әткәй, әнкәй, аларга ярдәм кирәк, безнең мөмкинлек бар бит, игеннәр дә быел, сөбханалла, каерылып уңды,— диде.

Әтисе улының бу сүзләренә матур җавап бирде:

— Әйе, улым, әлхәмделилла, игеннәр быел Аллага шөкер!.. Дин кануннары буенча без икмәкнең кырыктан бер өлешен ятимнәргә, ярлыларга, Ак түти кебек карт-корыга бирергә тиешбез. Тәңрем үзе шаһит, мин аны биш тапкырга арттырам. Яшь кенә көеңә кеше язмышы турында болай житди уйлануың сине бик зурлый. Андый зат-шәхесләр бәхетле була. Иншаллаһ, Аллаһы Тәгалә моның өчен беркайчан да рәнҗетмәс үзеңне!

Хәсәнә абыстай да сүзсез калмады:

— Әйе, әтиең дөрес әйтә, балам, яхшылык җирдә ятмый, ул адәм баласының үзенә кире кайта. Мин инде аларга болай да кулдан килгәнчә ярдәм итеп торам. Әле менә Мәдинәгә ак күлмәгемне, читегемне, алъяпкычымны биргән идем. Ул үзе дә бит бик ярдәмчел. Быел, үзең беләсең ич, ярты урагыбызны Мәдинә урды. Җен кебек эшли бит ул. Җен кебек. Тик бәхеткәйләре генә булмады. Бәхеткәйләре генә. Нигә шулайдыр инде. Үтә эчкерсез, гөнаһсыз, матур күңелле кешеләр иде бит югыйсә. И Аллам! И Ходаем!

Остабикәсенең сүзләрен мулла абзый дәвам итте:

— Әйе, бигрәк уңган кыз иде бит. Тик... син, Галимҗан улым, борчылма, тыныч күңел белән кит, без монда күз-колак булып торырбыз, киемен дә юнәтербез, ашлыклата да ярдәм итәрбез; Ходайга шөкер, буралар быел аркылып тулды, бодай, арыш, тары... Аларны ач итмәбез, әтиләре, әниләре дә миңа күп файда итте; авыр туфраклары җиңел булсын! Кем уйлаган аларның гомере шулай күңелсез өзелер дип. Кем уйлаган. И бәндәләр, бәндәләр! Нигә болай котырыналар икән? Бер дә юньлелеккә түгел бу. Бервакыт Ходай Тәгалә моның өчен аларны утлы табага бастырачак бит. Мондый әшәкелек бөтен илне какшата ул. Бөтен илне. Әгәр дә мондый яманлыклар дәвам итсә, Ходаем үзе сакласын, киләчәктә илебез бик мөшкел хәлгә төшәчәк бит. Мөшкел хәлгә. Гөнаһлы ил озак яшәми. Чүп баскан бакчага әверелә ул.

Шулай итеп, үзе дә сизмәстән, сүз иярә сүз чыгып, киләчәк дөньясына, халык, ил язмышы мәсьәләсенә, инсаниятлелек тойгыларына кереп китте мулла абзый.

— Син, атасы, әллә кайда, гарше көрсидә, чүпләнгән бакча эчендә йөрмә әле, аяк астындагыны, борын төбендәгене күр, — диде мулласының сүзен бүлеп Хәсәнә абыстай.

— Нәрсә бар борын төбендә?

— Һм... и бу ирләрне... Әллә Мәдинә язмышы борчымыймы сине?

— Соң, остабикә, шуңа ут йотып утырабыз бит.

— Харап икән берәүләр: ут йота. Ә кем су сибәр?

— Менә тагы... иманлы авыздан яман сүз... Сиңа ни булды бүген?

— Сезнең гамьсезлек аркасында килеп чыга шундый күңелсез хәлләр. Йокымсырыйсыз.

— Менә тагы...

Әнисенең сүзләрен Галимҗан куәтләде:

— Әнкәй дөрес әйтә, әткәй. Әлхак[1], начарлыкка каршы көрәшә белмибез.

— Аллаһы Тәгалә иртәме-соңмы залимнәргә, җаһилларга, юньсезләргә үз хөкемен чыгармый калмый ул, балам!

— Алла хөкемен көтеп ятарга кирәкми, әткәй!

— Чү! Аллага тел тидермә. Иманыңнан язарсың.

— Имансыз кеше буш тубал ул, әткәй. Ә минем буш тубал буласым килми. Иманым үзем белән. Алласыз кеше дә буш капчык. Минем буш капчык та буласым килми. Аллам үзем белән. Йөрәгемдә, күңелемдә. Зиһенемдә. Минем өчен кайгырмагыз. Дингә ышанган булып, Алла исеменнән яманлык кылучылар борчый мине. Әгәр бу юл белән китсәк, киләчәктә Алланың да, мулланың да, диннең дә кадере калмаячак.

— Мин монысын аңлыйм, улым, дөрес әйтәсең, әмма ләкин...

Галимҗан әтисенең сүзен бүлде:

— Әткәй! Менә хәзер мин синең үз иманыңны тикшерәм. Тыңлап тор. Әнкәй син дә тыңла. «Әмәнтү билләһи үә мәллә икәтиһи үә күтүбиһи үә рүсүлиһи үәл-йәүмил. Әхири үәл-кадәри хайриһи үә шәрраһи минәл-лаһи тәгалә үәлбәген бәгдәл-мәүти». Аңладыңмы, әткәй?

— Аңладым.

— Алайса, үз телебезгә тәрҗемә ит, мәгънәсен әйт.

— Коръән тәрҗемә ителми.

Галимҗан көлеп җибәрде:

— Тыңлагыз, әткәй-әнкәй: «Иманым Аллаһы Тәгаләгә вә дәхи Аның фәрештәләренә, вә дәхи Аның китапларына, вә дәхи Аның пәйгамбәрләренә, вә дәхи ахирәт көненә, вә дәхи тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуына, вә дәхи үлгәннән соң янә терелүгә». Менә, әткәй, иманны ничек аңларга кирәк. Коръән теле гаҗәп серле, шигъри, мәгънәле. Ә сез аның мәгънәсен белмисез. Бу сезнең динне, Алланы, Ходайны алдавыгыз түгелмени? Әмма ләкин, син уйлаганча, әткәй, дөньяны надан муллалар белән генә алып барып булмый. Галәм — зур, серле, баш җитмәслек чиксез. Аны халыкка аңлату өчен, диндарның тарих, җәгърафия, физика, математика, һәндәсә-геометрия, мантыйк, тел, әдәбият фәннәрен белүе мотлак. Чөнки киләчәктә дарелфөнүн-университет тәмамлаган акыллы башлар күп булачак. Мин үзем

[1] Әлхак — дөресен генә әйткәндә.

дә шундый изге максат белән яшим. Күп китаплар язачакмын. Халкыбызның тарихы, тел, әдәбият, сәнгать, психология, педагогика, методика... — мине барысы да кызыксындыра. Ул сарыф, нәхү, әнмүзәҗләр искерде, әткәй! Яңаларын мин язачакмын. Алла боерса!

Ата-ана бер-берсенә карашып алды. Менә кем икән безнең улыбыз, дигәнне аңлата иде ул карашлар.

Галимҗан дәвам итте:

— Әткәй! Син күп нәрсәне аңлап бетермисең. Синеңчә, Шакирҗан абый юлдан язган, имансыз, Алласыз. Бер дә алай түгел. Рәнҗетмә аны. Хат яз. Эрет ике арадагы бозны. Шакирҗан абый матур күңелле, йомшак табигатьле, ул менә дигән мөгаллим-укытучы булачак.

Бу сүзләрдән соң Галимҗан ата-ана алдында янә тау дәүмәллеге булып үсеп китте. Хөрмәтуллалар язмышы өчен янып-көеп йөрүе, хәзер кызы Мәдинәгә җанын ярып бирергә әзер торуы, Шакирҗан абыйсының йөрәк-күңелен шулай тирән аңлавы, кешелеклелек, гомумкешелеклелек тойгылары белән яшәве, аң-акылының бәяләп бетергесез камил булуы ата-ана күңелен күк тәхетенә хәтле күтәрде. Гыйрфан мулланың Уфада да мәгълүматлы дуслары юк түгел. Алар үзләрен әллә кемгә санап, зур куеп сөйләшә. Менә шуларны улы Галимҗан белән моназара кылдырасы иде. Үзләренең йомшак җирләрен тиз сизәрләр иде. Масайган мәнсезләр. Шул: пәйгамбәрләр башы бар монда. Пәйгамбәрләр башы!

— Ярар, улым, ниятең изге, карашың киң, акылың алтын, пәйгамбәр башы бар үзеңдә...

— Пәйгамбәр булу өчен, әткәй, хәзер бөтенләй башка баш кирәк.

Бәхәснең озакка сузылачагын сизеп, Хәсәнә абыстай аларның сүзен бүлде:

— Йә, җитте инде, атасы, сүзне җилем урынына сузуда бер файда да юк; акыллы тыңлар, юләр такылдар, дигәнне дә онытма, иртәгә юлга чыгасы, шуңа әзерләнегез; мин Ак түтиләргә барып кайтыйм әле. Хәер дә бирәсем бар иде.

***

Хәсәнә абыстай, зур бер бодай икмәге, чәй-шикәр, майфәлән алып, Хәмдия абыстайларга китте. Ул барып кергәндә, кендекәй белән Мәдинә ару гына сөйләшеп утыралар иде. Идәндә әлеге ике төенчек ята. Хәсәнә абыстай, исәнлек-сау-

лык сорашкач, Ак түтигә хәер бирде, иртәгә Галимҗанның сәфәр чыгачагын әйтте. Шуннан алар тиешлесен эчтән генә укып, дога кылдылар. Бу изге эшкә Мәдинә дә катнашты. Тик... «Галимҗан» дигән сүз генә аны тетрәндереп җибәрде. Хәтта сорау бирергә мәҗбүр итте:

— Галимҗан кайчан кайтыр, Хәсәнә абыстай?

— Киләсе язда, акыллым, Аллаһы боерса!

— Ә иртәгә безнең туй булмыймыни?

— Туймы? Ярый, балам, уйлашырбыз. Борчылма. Әйдә, үзегезгә барыйк.

Хәсәнә абыстай «киттек» дигәнне аңлатып ым какты да Ак түтигә күз ташлады. Бер төенчекне алып чыгып та китте. Икенче төенчекне Ак түти күтәрде. Мәдинә нишләптер аңа әллә ни игътибар итмәде. Ак түти, төенчегенең бер урынына ябышып, гамьсез генә атлый бирде.

Мәдинәнең Җәмилә исемле бер сеңлесе — унбиштә, Хәдимә исемлесе — унөч яшьтә, Сәлимәсе унбердә инде хәзер. Тугыз яшьлек Мөхәммәтҗан, җиде яшьлек Газизҗан... — барысы да өйдә иде. Килеп керү белән, чөйдә эленеп торган ашъяулыкны алып, аны сәкегә җәеп, Хәсәнә абыстай әлеге кабарып пешкән зур бодай икмәген телемләп ташлады. Бер савытка салып, маен да куйды табынга. Моны күреп, балаларның күзләре тоздай булды. Моның чынлыгына ышанмый тордылар хәтта. Ә Мәдинә, берни булмагандай, көлеп карап торды да энеләрен, сеңелләрен сөяргә тотынды. Мәгәр андый-мондый сүз ычкындырмады. Акылына килде дип уйлады Хәсәнә абыстай. Аңа ашыгырга кирәк иде. Галимҗанны юлга әзерлисе бар. Шуңа күрә исәнләшеп чыгып китте. Ак түти дә аннан калмады.

— Мин монда куна калам, Хәсәнә абыстай, хафаланма берүк, берни дә булмас, Аллаһы боерса, тыныч күңелең белән кит,— диде дә Ак түти кире өйгә кереп китте.

## VII

Кызарып кояш чыкканда, сәфәрчеләр юлга әзер иде инде. Хәсәнә абыстай төне буе диярлек юньләп керфек какмады. Башка вакыттагы кебек юлга ашамлык әзерләде: ит кыздырды, бәлеш, сумса, коймак, чәкчәк пешерде. Гыйрфан мулла да черем итеп кенә алды. Юлга чыгасы булса, аның тынычсызла-

ну гадәте яшь чагыннан ук килә. Бүген бигрәк тә җаны түзмәс булды. Чөнки Уфада танышлары да күп. Шуларның берсенә — Габдрахман хаҗиларга керәчәк ул. Күчтәнәчләрне Хәсәнә остабикәсенең иң югары сыйфатлы итеп әзерләячәген яхшы белә. Бу яктан күңеле тыныч. Алмачуарны тимер арбага җигеп барырга уйлады ул. Уфа — Ырынбур кебек ерак түгел, 70 — 80 чакрым чамасы, бер көнлек юл. Тарантас җигеп кенә дә җилдерергә булыр иде. Шулай да, кем әйтмешли, чамага — чанасы, чанага — чамасы туры килми. Фырт егеттәй кылануда фәтва юк. Ходай эшен кем белә: ул әле сине Уфада ике-өч көн кунарга кушар. Тегендәмонда борын төртеп, базарына-мазарына барып печән, солы эзләп, ух-пух килеп йөрүне җене сөйми Гыйрфан мулланың. Ярый, бардың да ди. Солтанморат болыннарында үскән туклыклы печән — моны ул ант итеп әйтә ала — ихластыр менә, бөтен тирә-якта гына түгел, җир йөзендә юктыр. Солтанморат бит ул! Ходай Тәгалә аңа оҗмах бакчасының бер як читен кисеп биргән. Мөбахис-Төбахис, Тәслих-Мәслих ише бәндәләрнең җилкәсен кимерүчеләр, Хәмәтдин-Мәмәтдин шикелле ялкаулар булсалар да, уптым илаһи алганда, аның кешеләре — иҗтиһадлы, гаярь, хезмәт сөючән. Аллаһы Тәгалә бу авыл кемсәләренә шуңа күрә биргәндер оҗмахтай җирне. Аның кара бәрхеттәй кабарып торган туфрагында бүртеп үскән туклыклы солысы да — монысы өчен дә ул кулына икмәк тотып ант итә ала — бер җирдә юк; хәтта ки көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Алмачуар бик назлы, нәзберек. Ул әле теләсә кемнең, ни җитте кешенең солысын, печәнен ашамый да, суын да эчми. Аңа, тәмле тамакка, оҗмахтагы кәүсәр күле суы тәме килеп торганы гына кирәк. Солтанмораттагы Зәңгәр чишмә суы кебек. Шуңа күрә үзенең Исәнбикә болынынннан чапкан чәчкә печәнен дә тимер арбага мул төяп, солысын да, арыш икмәген дә (Алмачуар — тәмлетамак аны да бик яратып ашый) күп алып, кичтән хәстәрләп бетерә алмаганнарын иртәнге намаздан соң җиренә җиткереп куйды. Юлга ул Кояш-бабай җир йөзенә сөйкемле карашларын ташлаганда, күңелләргә моң, йөрәкләргә дәрт, бөтен бәдәнеңә куәт бирердәй нурлар сипкәндә чыгып китәргә ярата. Бүген дә шулай итте. Иртәнге намаз укылган. Чәй эчелгән. Ат җигелгән. Йөрәк кагып, ярсып тора. Күңелләр шат. Атны Галимҗан белән бергә җиктеләр. Ата кеше гел сөйләнеп эшләде:

— Пәйгамбәр улымны, башлы, зиһенле улымны Уфага

«һә» дигәнче илтеп куям. Ә таңы нинди, көне нинди, нәкъ пәйгамбәр туган таң төсле. Карачы: бөтен офык кызарып янып тора. Сәфәр алдыннан Ходай безгә шундый матур таң бүләк итте. Пәйгамбәрләр таңы! Пәйгамбәрләр таңы! Сиңа да, улым, Таш маңгаем, дәверебезнең пәйгамбәре булырга насыйп итсен.

Капка ачык. Алар, печән төягәннән соң, алда үзләре өчен калдырылган махсус урынга менеп җайлаштылар. Галимҗан — сул якта, әтисе — уңда. Дилбегәне үзе алмакчы булган иде Галимҗан, ләкин әтисе ирек куймады. Бу картлач һаман әле безнең көчкә, ныклап ат тота алуыбызга да ышанып бетми, күрәсең, дип уйлап, җиңелчә генә елмаеп куйды Галимҗан. Әнисе әллә ничә мәртәбә кысып-кысып сөйгән иде инде. Арбага менеп утыргач, йөгереп килеп, янә иркәләргә тотынды. Әтисе:

— Йә җитте инде, әнкәсе, әллә кайда, җәһәннәмгә китми ләбаса, Уфа ерак җир түгел, үзебез дә барып торырбыз, ул да кайтыр да килер, йә, кит инде, кузгалабыз, тәгәрмәчкә уралуың бар,— дигәч кенә, Хәсәнә абыстай аерылырга мәҗбүр булды.

Дилбегәне аз гына, сак кына кагу белән, Алмачуар тоҗрылу ягын шәйләде. Аның, пырдымсызның, башын чайкыйчайкый, дулап-дулап китүе дә бар. Шуны уйлап, дилбегәне нык тартып тотарга, Алмачуарга җендәй ярсып чабарга ирек куймаска тырышты мулла абзый. Әмма капканы чыгу белән, ул алды да китте. Берәр җиргә орып, тончыктыруы да бар бит әле аның. Гыйрфан мулла, тешләрен кыса-кыса, дилбегәне урап-урап тотып, авызлыгын нык каергач кына, Алмачуар, хуҗасының көчле кулын тоеп, ахмакларча артык шашынмаска булды.

Хәсәнә абыстай, алга төшереп бәйләгән яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп, алар күмелгәнче моңаеп карап торды. Күмелгәч, кереп, янә бер мәртәбә утырып дога кылды. Исәнаман барып җитүләрен, мулласының исән-сау әйләнеп кайтуын теләде. И Ходаем, балаларга, барлык бәндәләргә бәхет бир, бозыклыклардан сакла, илдә тынычлык булсын, дип амин тотты.

---

ЭЧТӘЛЕК

*Беренче бүлек*
БАЛА КӨТКӘНДӘ...
*3*

ТӘПИ БАСЫП КИТКӘЧ...
*34*

*Икенче бүлек*
БӘЛА — АЯК АСТЫНДА...
*52*

КЕШЕ КҮҢЕЛЕ — ТИРӘН ДӘРЬЯ
*63*

*Өченче бүлек*
ХУШ, АВЫЛЫМ, ХУШ ИНДЕ!..
*74*

*Дүртенче бүлек*
*110*

*Бишенче бүлек*
*163*

*Алтынчы бүлек*
*234*

Литературно-художественное издание

*Поварисов Суфиян Шамсутдинович*

РАССВЕТ ПРОРОКА

*Роман*

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *А.А.Фомин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.Х.Касыймова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.08.2004.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 15,12 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 15,96.
Нәшер-хисап табагы 16,95 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ Э-540.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru  E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.